
ISSN 0206—418



# КАЗАН УТЛАРЫ

5.1989






**Советлар Союзы Герое,**
**Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил**

**(1906—1944)**

*А. Тимергалина рәсеме.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1989**

**5**

**(799)**

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*

ТАТАРСТАНДА БАШКОРТСТАН АССР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ


М. КӘРИМ. **Исәнмесез! Инде без килдек...** 3
Г. БӘШИРОВ. **Хуш киләсез, кадерле дуслар!** 3

С. КУДАШ. **Үкенәм.** *Шигырь* 5
З. БИИШЕВА. **Кешечә.** *Шигырь* 5
Н. НӘҖМИ. **Ут күрше.** *Шигырь* 6
М. ГАЛИ. **Башкортстан таулары.** *Шигырь* 6
К. КИНҖӘБУЛАТОВА. **Тукайга.** *Шигырь* 6
Я. КОЛМЫЙ. **Телгә тел дошман түгел.** *Шигырь* 7
Г. РАМАЗАНОВ. **Шигърият чишмәсе.** *Шигырь* 7
Ә. АТНАБАЕВ. **Маймыллар белән әңгәмә.** *Шигырь* 8
Р. САФИН. **Тальяным.** *Шигырь* 8
М. КӘРИМОВ. **Тирмә корам.** *Шигырь* 9
А. ИГЕБАЕВ. **Сукмагымнан адаштырма.** *Шигырь* 9
С. ӘЛИБАЕВ. **Үзенекен итә ел мизгеле.** *Шигырь* 9
Р. БИКБАЕВ. **Кем гаепле?** *Шигырь* 10
К. АРАЛБАЕВ. **Моң.** *Шигырь* 10
Ф. ТУГЫЗБАЕВА. **Уйладым мин.** *Шигырь* 10
А. ХӘЛИМ. **Энергия.** *Шигырь* 11
Р. МИФТАХОВ. **Һай, Салават — җир күрке.** *Шигырь* 11
Т. ИОСЫПОВ. **Сагыш бураны.** *Шигырь* 12
Ә. ӘХМӘТ-ХУҖА. **Башкорт теле.** *Шигырь* 12
Г. ЮНЫСОВА. **Кымыз ясаучы кызлар.** *Шигырь* 12
Р. ХИСАМЕТДИНОВА. **Буранбай.** *Шигырь* 13
АСЫЛГУҖА. **Кыңгырау чәчәкләренә.** *Шигырь* 13
З. КОТЛЫГИЛДИНА. **Кайгы, кая барасың?** *Шигырь* 14

Р. СОЛТАНГӘРӘЕВ. **Үтәлмәгән васыять.** *Хикәя* 14

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ. **Башкортстанда туйлашу** 23


ПРОЗА


Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Кенәри — читлек кошы.** *Роман* 33

Г. КАШАПОВ. **Убырут.** *Повесть* 113

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60.
баш редактор урынбасары — 53-07-09.
җаваплы секретарь — 53-07-09.
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

ОСТАХАНӘ

**М. ШАҺИМӘРДӘНОВ. Өч чакрым юл.** *Хикәя* 155

**Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Мансур Шаһимәрдәнов хикәясе турында** 161

ПУБЛИЦИСТИКА

**М. РАФИКОВ. Бүдәнә генә елыймы?** 163

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Заман һәм шигырь** *(Әдәби бәхәсне йомгаклауга багышланган редколлегия утырышыннан чыгышлар)* 170

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**Г. АХУНОВ. Бүгенге татар романы** 180

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ-ЯЗУ

**Тугызынчы дәрес** 187

**Культура тормышы көндәлеге** 190

**Тышлыктагы сурәтләр** 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Дни литературы и искусства Башкирской АССР в Татарии: Приветственные выступления аксакалов башкирской и татарской литератур М. КАРИМА и Г. БАШИРОВА. Стихи башкирских поэтов. Рассказ Р. СУЛТАНГАРЕЕВА «Неисполненное завещание». Статья фольклориста Р. МУХАМЕТЗЯНОВА о поэтике свадебных обрядов. «Проза» — продолжение романа Р. МУХАМАДИЕВА «Львы и канарейки».

Повесть Г. КАШАПОВА «Чертополох».

«Литературная мастерская» — рассказ М. ШАГИМАРДАНОВА «Три версты» анализирует писатель Р. ТУХВАТУЛЛИН.

«Публицистика» — статья М. РАФИКОВА «Почему плачет перепелка».

«Литературная критика» — отчет из заседания редколлегии журнала, посвященного итогам дискуссии «Время и поэзия».

Навстречу XI съезду писателей Татарии: Статья Г. АХУНОВА «Современный татарский роман».

«Навыки чтения и письма на основе арабской графики». Занятие 9-е.

Дневник культурной жизни.

На наших облажках: один из популярных видов шамаиля; вид церкви в Казанском кремле. XIX век. Репродукция с линогравюры английского художника Э. Турнерелли.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректор *Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 1.03.1989 ел. Басарга кул куелды 17.04.1989 ел. ПФ 05154. Офсет ысулы белән басыла
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14.2. Басма табак 12(16.8).
Тираж 77049. Заказ Б-101. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

С «Казан утлары», 1989 ел.

*Татарстанда Башкортстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре*

## ИСӘНМЕСЕЗ! ИНДЕ БЕЗ КИЛДЕК...

*Җырлашып, моңаешып аерылышуга бер ел гомер үтеп тә китте. Татарстаннан безгә сәнгать һәм әдәбият бәйрәме алып килгән дусларыбыз ул чак болай дип хушлаштылар:*

*Без килдек тә кунак булдык,*
*Инде үзегез барыгыз.*

*И-и-и ул көннәр! Ыктан Җаекка тикле бөтен Башкортстанда татар моңнары, татар җырлары яңгырап торды, татар биюләреннән далалар селкенде, урманнар тирбәлде, елгалардагы сулар чайпалды. Татар бизәкләреннән заллар балкып торды. Безгә шулай тоелды. Чөнки аларның һәммәсе безнең күңелләребезне тетрәтте, рухларыбызны иркәләде, йөрәкләребезне канатландырды. Хисебез шашып, үзебез җырга кушылдык, дәртләнеп, биергә төштек. Күзләргә күз карашканда җаннарга җан омтылды. Тере Тукайны күргән кебек булдык, Сәйдәшевнең үзен кочаклагандай хис кылдык, әйтерсең, Туфанның җылы кулларын кыстык, Сара апа Садыйкованы күтәреп алдык. Сагынышканбыз да икән!..*

*Киемгә карап каршылау, акылга карап озату гадәте булган элеккеләрдә. Киемнәргә карап каршыламадык без. Хәер, яшермим: купшы, матур киемнәргә карап та, мөлаем, чибәр йөзләрне күреп тә сокландык. Ләкин талантларны танып кабул кылдык, талантларга хәйран калып озаттык. Уебызда шик-шөбһә, күңелебездә дәгъва булмагач, җырдан ертык эзләмәдек. Эзләсәк тә — таба алмас идек. Кыскасы, күршедә генә торып, сирәгрәк күрешкән туганнарыбызның зур казаныш-*

## ХУШ КИЛӘСЕЗ, КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!

*Мәрхәбә! Дүрт дәрья иле Татарстан, чал тарихлы, күп милләтле Татарстан сездәй якын күршеләрне, гасырлар сынавы үткән танылган дусларны колачын киң җәеп, казан асып, чын туганнарча сәламләп каршы ала.*

*Сигез йөз яшьлек чал Казан, Көнчыгышның мәгърифәт үзәге булып танылган нурлы Казан үзе, аның Чаллы, Бөгелмә, Алабуга, Минзәлә кебек дистәдән артык борынгы энекәшләре-сеңелкәшләре — һәркайсы сезне — үт күршебезнең талантлы әдәбият һәм сәнгать осталарын — эчкерсез якты чырай белән чын күңелдән тәбрик итәләр.*

*Агыйдел буйларыннан алып республикабыз чигендәге Илләт урманнарынача, Идел ярларыннан башлап борынгы Нократ якларына кадәр, һәр авылда, морҗасыннан төтен чыккан һәр йортта Сез кадерле кунакларга капкаларыбыз ачык, табыннарыбызда сый-хөрмәт әзер. Рәхим итегез!*

*Җәй артыннан кыш килде, аны да узып, яз җитте, без исә елның ел буена һәмишә Башкортстанда узган дусларча очрашулар тәэсирендә яшәдек. Урал тауларының үзләре кебек биеккә өндәүче, башкорт далалары сыман киң сулышлы озын җырларыгыз, киң болыннарны, җиләкле аланнарны искә төшерүче курай моңнарыгыз һәрвакыт күңелләребезне хушландырып, сезне сагындырып торды, җилдәй җитез биючеләрегез күз алдыбыздан китмәде.*

*Ул кадерле истәлекләр безне дулкынландырды, вакыт-вакыт тирән уйларга талдырды, яңа заман сулышы күңелләрдә яңа теләкләр, яңа гөманнар уятты. Һәр-*

*ларына куандык. Үзебезгә карата алдагыны уйлап, сагаеп та калдык. «Инде үзегез барыгыз...»— диделәр бит. Ләкин бөтенләй үк каушап та төшмәдек. Без, башкортлар, тәвәккәл халык. Бар һөнәребезне, тартынмый, ихлас тырышып күрсәтербез. Һөнәр җитмәгәндә, үзебезне күрсәтеп калырбыз.*

*Дөресен әйткәндә, озынрак булып чыкты бу ел. Атналарын, айларын санап көткәнгә шулайдыр инде. Менә мизгел җитте, сулар тонып, җирләр яшәрде. Көннәр озайды. Ямьле чакта килеп төштек без. Якын аралардан юл тотсак та, ерак заманнардан килдек. Болай дип әйтүем шуннан: бүген яки кичә тапкан-табынганнарны гына түгел, борынгы ата-бабаларыбыздан мирас булып калган рухи хәзинәләрнең дә үрнәкләрен китердек.*

*Гасырларның түбәләре аша күкрәп узган җырларыбызны, кобаирларыбызны, ничәмә буыннарның буыннарына, ягъни кан тамырларына ут үрләткән биюләребезне, тарих авазлары белән киләчәк оразнарын бергә кушкан курай моңнарын, думбра чыңнарын алып килдек без. Халкыбызның, туфрагыбызның тарихи иманы булган Салаватның сүзләрен, Акмулла, Бабич, Гафури варисларының — илгә даннары таралган заманыбыз шагыйрьләренең тавышларын ишетерсез. Безгә тылмач кирәкми. Сезнең авыздан чыккан сүзләр, үз оясына кергән кош шикелле, безнең күңелләргә кереп сеңә. Безнең сүзләребез дә нәкъ шулай кабул ителәдер дип уйлыйбыз, ианабыз.*

*Тел, рух, гореф-гадәт ягыннан ничаклы якын булмыйк, бер-беребез өчен без сер дә булып калабыз. Бәлки, шуның аркасында бер-беребез өчен кызыклырак быздыр да. Минем фронтташ дустым Күктәкә егете Вәгыйзь Вәлиев әйтә иде: «Ике арада Ык кына агып ята, ә башкорт ягы без балалар өчен йөрәкне җилкетеп торган серле як иде». Кешеләр һәм халыклар арасында ахыргача ачылып бетмәгән мавыктыргыч серләлек, табылып бетмәгән табышмак яши. Әнә шул табышмак булмаса, табышлар да, бер-береңне ачышлар да булмас иде. Без Татарстан иленә үзебезнең мәхәббәтебезне ачып салырга, сәнгатебез, әдәбиятыбыз аша үзебезнең кардәшлек ихласлыгыбызны күрсәтергә килдек. Моннан тыш тагын бер максатыбыз бар: җир-суыбызның, күкләрегезнең, тормыш-көнкүрешегезнең, күңел дөньягызның серләрен күбрәк ачасы иде дибез. Сер бүлешүдән якынлык арта гына бит ул. «Уртак мәҗлесләргә җыелышып, дуслык яңарту йоласы яшәсен!»— дип, инде без килдек.*

*— Исәнмесез!*

**Мостай КӘРИМ.**

*сәдер теләгәнчә, көткәнчә үк гамәлгә ашмый, нидер җитенкерәп бетми сыман. Кайчагында үзеңә-үзең сорау да бирер карыйсың: Болгар бабаларыбыздан ук калган шул изге дуслык мирасын без һәрвакыт кадерен белеп саклый алабызмы икән, бер-беребезгә ихтирамны һәм игътибарны тагын да югарырак баскычка күтәрү өчен барлык көчебезне дә салабызмы икән? Уйлап карасаң, уй-фикерләр тирәннәргә алып керә. Безнең бит җир-суларыбыз, болын-урманнарыбыз гына түгел, телләребез, көйли торган моңнарыбыз, хәтта гореф-гадәтләребез дә бер-берсенә бик якын. Шундый якын, бу ифрат та кешелекле якынлык тойгысы матур әдәбият белән сәнгатьтә дә эзсез калмасын, Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» шикелле ике халыкның да горурлыгы булырдай әдәби шедеврлар булсын, рухи дөньябызны тагын да баетып, бер-беребезгә мөнәсәбәтләрне тагын да якынайтырга сәбәп булсын иде.*

*Хәер, андый сәбәпләрне һич көтелмәгәнчә иттереп, кайчак тормыш үзе үк алга китереп бастыра. Әнә бит, кем генә белми, «Озын-озак балачак» Башкортстанда язылган, «Намус» романы исә Казанда басылган. Ә узган ел алар Мәскәүдә очраштылар да икесе бер тышлык астына «өйдәш» керергә булдылар, ул да түгел, ике бертугандай җитәкләштеләр дә ил буенча сәяхәткә чыгып киттеләр. Нинди генә сәяхәт әле!*

*Без үзебез ифрат та беркатлы эчкерсез халык. Кайчагында узган замандагы хәлләрне искә төшереп, чын-чыннан юксынып та куябыз. Нигә шулай булды соң әле бу? Нигә хәзер дә, элекке еллардагы кебек, Уфа белән Казан арасында, өч иделне бер иттереп, ике республика арасындагы шәһәрләргә, авылларга сәлам бирә-бирә, аккоштай ак пароход йөзми икән? Ул бит гади пароход кына түгел, ике халык арасындагы җан җылысын сүрелдермичә, гел яңартып торучы игелекле илче иде. Яисә нигә татарлар башкорт концертларын, башкортлар исә татар моңнарын ешрак тыңлый алмыйлар?..*

*Кыскасы, яңәшә утырып киңәшәсе, фикер алышасы нәрсәләр бихисап әле.*

*Узган ел аерылышкан вакытта ике халыкның әдәбият, сәнгать әһелләре, очрашуның ядкаре итеп, Агыйделгә чәчәк бәйләме салганнар иде. Ул нәфис бәйләм, башта Агыйдел өстендә, аны узып, Кама дулкыннарында тирбәлә-тирбәлә, ниһаять, безнең тарафларга иреште.*

*Сәламегез килеп җитте, инде үзегез рәхим итегез!*

*Мәрхәбә, кадерле кунаклар!*

Гомәр **БӘШИРОВ.**

## Сәйфи Кудаш,

*Башкортстанның халык шагыйре*

### Үкенәм

Үтмәс төсле булды бер чак гомер,
Ә ул сине һич көтеп тормый икән.
Инде шуңа өзгәләнә карт күңел,
Шул гамьсезлек өчен бүген үкенәм!

Хезмәт икән барлык яме гомернең,
Тик моны бераз соңлап төшендем.
Хәзер әрнеп шуңа чын күңелемнән,
Эшсез үткән көннәремә үкенәм!

Тормышыңның ярты яме яр икән,
Булса ярың, канатларың пар икән.
Нишләп шуны әлек белмәдем икән?
Ялгыз үткән көннәремә үкенәм!

Алтын икән туган җирнең туфрагы,
Ширбәт икән чишмәләрнең сулары.
Инде шуны бүген килеп төшенәм,
Шулай соңлап төшенгәнгә үкенәм!

Иң изгесе кешенең — әни икән,
Ул синең өчен генә яши икән.
Тик шуны син аңлап җитмисең икән,
Шул гамьсезлек өчен инде үкенәм!

Дус булмаган кебек һәрбер мактаган,
Дошман булмый икән һәрбер әрләгән.
Кайчак күңел шуны аңлый белмәгән,
Инде бүген шуның өчен үкенәм!

Җирдә кеше тик бер кат тора икән,
Ни чәчсә, тик шуны ура икән.
Ни күрсә дә үзеннән була икән,
Шуны алдан белмәгәнгә үкенәм!

Әгәр дә мин тагын бер кат яшәсәм,
Иҗат юлын өр-яңадан башласам,
Карт йөрәкне болай яндыртмас идем,
Үкенергә урын калдырмас идем!

## Зәйнәп Биишева

### Кешечә

Әйтмәем, иркә булдым, дип,
Яшәдем, дип, ваемсыз.
Ватанымның мәхәббәте
Булды, диеп, талымсыз.
Әйтмәем, нәкъ сөт өстендә
Каймак булдым һәрчак, дип,
Җемелдәп кенә гел өстә
Йөзеп үтте яшь чак, дип.
Мактанмаем, илем һәрчак
Сыйпады, дип, аркамнан,
Алдымда гел кояш булды,
Ай торды, дип, артымнан.
Кирәгенчә сөйде илем,
Кирәгенчә өйрәтте.
Хәтта кайчак гаделсезлек,
Тигезсезлек йодәтте.
Булды чатлама суыклар,
Кояшлы язлар булды.
Күңел кайчак шатлык белән,
Кайчак зар белән тулды.
Кайчак нәфрәттән бузарып
Ал каным ургып акты,
Кайчак йөрәгем сөюдән
Янар тау булып какты...
Кешегә хас булды барсы,
Кешечә янды йөрәк.
Кешечә әрнеп, куанып,
Хезмәттә талды беләк.
Кешечә ашкынып очты
Җиһанга тынмас җаным.
Авырда җиргә таянып,
Яшәүнең тойдым ямен.
Кешегә хас горур, кыю,
Саф булды минем йөрәк.
Ят итте ярап яшәүне,
Җиңелне — сөйгән теләк.
Кешечә бәхетле булдым,
Яндым, көйдем кешечә.
Туган илне, газиз җирне
Ярсып сөйдем кешечә.
Кешечә булды һәммәсе,
Кешечә булды фәкать.
Канәгать-сабырлы килсен
Илаһи соңгы сәгать.

# Н а җ а р   Н ә җ м и

## Ут күрше

Булган заман... Утны чакма чагып,
Алгангамы икән ул чакта,
Кешеләрдә һич ут өзелмәгән,
Кабыныр ут калган учакта.

Уты сүнсә, кергән күршесенә
(Күршенең дә була төрлесе).
Булган аның якыннардан-якын
Ут алырга кергән кешесе.

Ут алырга... йөрәгемдә минем
Утым беткән, сүнгән чакларда,
Мин ут алдым, алдым кешеләрдән
Алган кебек чакматашлардан.

О, миндә дә аз-маз ут табылып,
Кинәнсәләр икән кешеләр.
Әйтсә иде алар, аның белән, дип,
Без ут күрше, без ут күршеләр.

# М у с а   Г а л и

## Башкортстан таулары

*Әмирхан Еникигә*

Талгын гына баеп барган кояш
Ирәндекнең үпте ташларын...
Онытыр төбәк җирдә бардыр ла ул,
Онытып кара Баймак якларын.
Акыл, хыял монда бер тамырдан,
Тормыш белән әкият — игезәк.
Үткәннәрдән безгә сабак укып
Асыл таулар ята җир бизәп.
Сабантуйга без дә килдек әле...
Син бик өлкән, мин дә яшь түгел.
Сабантуйлар өчен гомер нәрсә,
Бар бит әле бездә яшь күңел!
Атлыйсың да, бу нинди тау, дисең,
Бу үзәндә, дисең, ниләр бар.
Атайлардан калган асыл мирас —
Озыннардан озын көйләр бар.

Шул көйләргә күптән син мөкиббән...
Йөрәгеңә моңнар уралсын.
Аларда бит катлы-катлы тарих,
Көйләрсең дә уйлар уйларсың.
Атлыйсың да, бу нинди тау, дисең,
Бу үзәндә, дисең, ниләр бар.
Чал дөньяның кырыс җилләреннән
Йөрәкләрдә калган җөйләр бар.
Үзгәрер бу дөнья, тик яман көч
Кул якмасын җирнең төсенә.
Син тауларга бактың, ә мин сиңа,
Сиңа бактым — таудай кешегә.
Тауларыма карап хәйран булдың...
Уралмыни сиңа ят төяк.
Кояш баеп бара. Син көйлисең
Әллә әкият, әллә васыять.

# К ә т и б ә   К и н җ ә б у л а т о в а

## Тукайга

Язгы таңнар,
Язгы ярсу таңнар,
Сине гелән искә төшерә,
Әллә нинди авыр заманалар
Искә төшсә, күңел күшегә.

Язгы таңнар,
Ярсып туган таңнар,
Йөрәгемә уелып кердегез,
Бөек шагыйрь булып килдегез,
Күңелемне моңга күмдегез.

Үксез ятим —
Кемгә бала кирәк? —
Дип язмышың сине рәнҗеткән.
Ул чак язмыш — үзе тере ятим:
Кемнәрдәндер җылы сүз көткән.

Язгы таңнар.
Язгы ярсу таңнар,
Күкрәүләрең ләйсән яудыра.
Әллә ләйсән, әллә синең җырлар
Заман аһ-зарларын юдыра.

Кара төннәр кара килгән саен,
Якты йолдыз булып калкындың,
Иманы да, намусы да булдың
Шагыйрь иткән бөек халкыңның.

Язгы таңнар,
Сызылып аткан таңнар,
Бөек шагыйрь алып килдегез.

Моңга-җырга безне күмдегез дә,
Нигә тагын кире җилдегез?

Язгы таңда сары ла сагышларым
Нигә арта икән бу кадәр?
Язлар уза,
Язлар итеп бит мин
Гомерем буе шагыйрь озатам,
Сыктап-елап шагыйрь озатам.

# Якуп Колмый

## Телгә тел дошман түгел

Бер милләттән булмасак та,
Телгә тел һич дошман түгел.
Ни әйтергә теләсәң син,
Шул уеңны аңлый күңел.

Ана сүзе һәр телдә бар,
Тик ул
Охшаш түгел бер-беренә.
Аны үз телендә әйтеп,
Хөрмәтлиләр һәрбер җирдә.

Чөнки ана үз сабыен
Тик үзенчә сөеп назлый.
Шуңа аның һәр сүзкәен
Кече яшьтән бала аңлый.

Бәлки аңны ачкан шул тел
Кирәкмидер чит бер илдә.

Ә мин Байрон шигырьләрен
Укыр идем үз телемдә.

Башкортның киң сәхнәсендә
Пушкин сүзе ялкын яккан.
Салаватның телен аңлап,
Дус халыклар яуга чапкан.

Халкы барның иле дә бар,
Җырлап яши үз телендә.
Ана телен кыерсытсам,
Типмәс сыман йөрәгем дә.

Телгә тел һич дошман түгел,
Бер үк уйда син дә, мин дә.
Бер кояштан җылы алып,
Шат яшиек азат илдә.

# Гыйлемдар Рамазанов

## Шигърият чишмәсе

*Сибгат Хәкимгә*

Чыга таулар, ташлар ярып,
Чыга җир үзәгеннән,
Уза шигырьләр чишмәсе
Халыкның йөрәгеннән.
Татыган саен чишмәне
Үзәк өзелеп ала.
Тукайлар эчкән суларның
Тәме сизелеп кала.
Бу шигърият чишмәсендә —
Солдат күңеле сафлыгы,
Бар дөньяның кайгылары,
Бу заманның хаклыгы.

Чишмә кырлар, үзәннәргә
Җиләс җилләр өләшә.
Иркенләп татар телендә
Ленин белән сөйләшә.

Шагыйрьгә һични кирәкми,
Ил даны — аның даны,
Ул — тарихның күз-колагы,
Ул — халыкның вөҗданы.

Булмасын нинди тетрәүләр,
Нинди җилләр исмәсен,
Утка, давылларга каршы
Бармый шагыйрь нишләсен?

Ялгышмый халык, белә ул —
Күпме еллар үтмәсен,
Адашмый эзләп килә ул
Ихлас җырлар чишмәсен —
Чын шигърият чишмәсен.
Безнең Сибгат чишмәсен!

# Әнгам Атнабаев

## Маймыллар белән әңгәмә

*Сухумидагы маймыллар питомнигын караганнан соң.*

Экскурсовод кызның сөйләвенә
Караганда, сезнең хәлләр дә
Шәптән түгел икән — хөр икән:
Цивилизация шартларында читлек
Кадерлерәк икән иректән.

Иң маймыллы илләрдә дә чөнки
Соңгы вакыт маймыл уңмый, ди,
Экспортка сатып алырга да,
Алтынга да табып булмый, ди.

Кырыласы үзе кырылып беткән,
Ә кырасын — кырып беткәнбез;
Шуның өчен хәзер питомникта
Үрчетергә мәҗбүр икәнбез.

Сез читлектә,
мин ирektә кебек,
Миңа кызык сезнең кыланыш...
Нидер лыбырдыйсыз...
Телегезне
Аңлап кына булмый — кызганыч:
Сез һаман да безнең телне «белмәс»,
Без сезнеңчә «не понимаеш».

Сез бит борынгылар — әллә ничә
Миллион еллар ята арада;
Шуңа күрә хакым бардыр сезгә
«Безнең предки» дип карарга.

Чөнки үземнең дә «улым» диеп
Иркәләгән колга-сабыйлар
Күптән инде миңа, маймыл итеп
Һәм «предки» итеп карыйлар.

Аларга да кызык тоеладыр
Минем гадәт,
холык,
кыланыш;
Мин сөйләшкән телне алар «белмәс»,
Мин аларча «не понимаеш».

Үзебезнең баштан үткәннәрне
Аңлатмакчы булам «әлеп»ләп;
Елмаялар һәм әрлиләр мине,
Консерваторлыкта гаепләп.
Алар мин җитмәгән горизонтка —
Ашыгалар һаман алга тик,
Беркайчан да кире борылмыйлар,
«Әтиебез артта кала», дип.
Нишләтәсең, тормыш законы шул:
«Предкилар» кала агымнан...
Сезнең хәлләр белән минем хәлләр
Менә шулай, иптәш маймыллар!

# Рафаэль Сафин

## Тальяным

Йөрәгемне сагыш биләп алса,
Кайгы чыгып басса юлыма,
Йә сирәкләп шатлык килеп керсә,
Тальянымны алам кулыма.

Әллә нинди тылсым бар шул анда!
Дөньяларым тагы нурлана.
Явызлыклар, мәкер, хыянәтләр
Юк шикелле була дөньяда.

Эх, уйнале, тальян! Өздер әйдә,
Моң-шәрабың белән исертеп.
Килеп яткан картлык борылып китсен,
Яшьлек моңы синдә ишетеп.

Синең белән без бит бала чактан
Үз кешеләр булып аңлаштык.
Бала чактан мин бит, әй тальяным,
Моңнарыңа кереп адаштым.

Сагынганда йөрәк, юксынганда,
Азмыни син мине юаттың!
Сөйгәнемне эзләп илләр гиздем,
Кичә таптым, бүген югалттым.

Эх, сип әле көмеш моңнарыңны,
Онытылсын калган хәтерләр!
Без китәрбез, калган ярлар безне,
Елый-елый, барыбер хәтерләр.

Без бит яшәмәдек үзебез өчен.
Бер җаныбыз өшеп, бер янып,
Бу дөньяның шатлык-кайгыларын
Ил алдына чыгып җырладык.

Сыздыр әйдә, тальян! Юлларымда
Синең белән бергә кот барыр.
Бу дөньяның көйсезлекләреннән
Тылсымлы моң безне коткарыр.
Эх, уйнале, тальян!

# Марат Кәримов

## Тирмә корам

Борынгыма багам: иркен дала,
Дала уртасында тирмә тора.
Бүгенгемә кайтам: шаулы кала,
Кала уртасында... төрмә тора.

Тирмә эчләрендә җыр агыла,
Бар табигать тыңлый җырлаучыны.
Төрмә челтәрендә ниләр булсын:
Тоткын зары белән богау чыңы.

Минем дә бит күңелемдә төрмә,
Шуңа вөҗдан артык «чуалмады».
Дөрес сүзләр кәгазьләргә төшми
Тоткын булып калды — чыгалмады.

Күпме җырлар язылмаган, диеп
Хәзер нигә җанны телгәләргә!
Эчке төрмә булган өчен дә бит
Эләкмәдем тышкы төрмәләргә.

Көткән заман килде! Хәзер инде
Тыюлардан азат җирдә торам.
Күңелем даласында, төрмә сүтеп,
Җыр яңгырап торыр тирмә корам...

# Абдулхак Игебаев

## Сукмагымнан адаштырма

Мин дә мәхрүм калмаганмын
Өлешем көмешеннән,
Җаныма сихәт булырлык
Тылсымлы суларны эчтем
Мәхәббәт инешеннән.

Кайсы чакта зарлансам да
Йөрәгем тибешеннән,
Йөрәк ярасын басарлык
Шифалы дәвалар таптым
Мәхәббәт инешеннән.

Юк, артыгы кирәк түгел
Үземә тиешеннән.
Тик син, язмыш, һичкайчан да
Сукмагымны адаштырма
Мәхәббәт инешеннән!

# Сафуан Әлибаев

●

Үзенекен итә ел мизгеле:
Сулар ага, дулкын чайкалтып;
Син кайтмагач,
минем күңел генә —
Гашыйк алмый калган сай култык.

Киде муел
ап-ак туй күлмәген,
Чеңләү әйтә кошлар, һай, назлап!
Карлыгачлар күкне кайчылады —
Китәр инде көннәр аязлап.

Касәсендә
тәүге чәчкәләрнең
Мөлдерәшә чыклар —
көн үтә.
Офыгымда озак көтеп торды
Син су ташыр җәйгор-көянтә.

Кабатланмас төстә
гөлләр уйный...
Миндә генә сагыш һич бетми.
Үзенекен итә мизгелләре:
Сагындыра,
килә,
кичекми.

Син, көттереп,
тагы кичектердең:
Хатың гына килде:
«Яз, көтәм!..»
Ә мин шаулы язның уртасында
Өмет өзми,
һаман яз көтәм...

## Равил Бикбаев

Кем гаепле икебезгә
Бер үк ялкын капканга,
Бер үк сүз сискәндергәнгә,
Бер үк җыр моңайтканга?

Кем гаепле яз тумастан
Сандугач сайраганга?
Кем гаепле көз җитмәстән
Яфраклар саргайганга?

Кем гаепле кышны көтми
Суларның туңганына?
Минең иртә туганыма,
Синең соң туганыңа?

Тик үземә, тик үземә
Алам барлык гаепне.
Тик кем өзәр тозакларын
Вакыт дигән бәй-җепнең?..

## Кадим Аралбаев

### Моң

Бу тиклем дә көйне каян алдың?
Озынлыгы булыр Уралдай:
Гүя торып Бозлы океаннан,
Уятасың кебек Аралны.

Бу тиклем дә моңны каян алдың?
Халкың тарихыдай борынгы,
Әйтерсең, ил аны тыңлап барган,
Булган чакта юлы караңгы.

Кайдан килә бу моң?
Дала иңләп,
Туфан суы гүя таралмыш,
«Диңгез тубыктан!» — дип кичкән батыр
Урал түбәсендә яралмыш.

Сызылып үтә җырда
Зөлхиҗәнең
Тоткындагы кара төннәре,
Алыс Балтикадан килеп җиткән
Салаватның курай өннәре.

Кайдан килә бу моң?
Тойгыларны
Шау моңсызлык басып барганда,
Бишек янындагы әнкәң кебек,
Тыны белән тартып алгандай.

Кайдан килә бу моң? —
Урал таудан
Ишелеп-ишелеп ага
Моң-сагыш.
Тик табигать баласына гына
Табигатьтән бүләк бу тавыш.

Әй шул моңың,
Кабатланмас моңың,
Җанкайларны ала көйрәтеп...
Җырга мөмкин әле өйрәтергә...
Моңга гына булмый өйрәтеп.

## Факиһә Тугызбаева

Уйладым мин, акчарлаклар
Горур була икән, дип,
Канатлары — кыйгач, гүя
Диңгездәге җилкән, дип.

Чыр-чу килеп талашалар
Кулымдагы җимнәргә,
Әллә кемнәр тартышкандай
Вак сукыр тиеннәргә.

Акчарлаклар, ни бар сезгә
Тып-тыныч яр буенда?
Сезгә дигән алтын балык —
Диңгезнең куенында.

Табигыйдыр, бәлки, кошның
Җим дип җаннар атуы.
Авыр миңа, акчарлаклар
Сезнең хактагы хыялны
Мәңгегә югалтуы.

# Айдар Хәлим

## Энергия

*Фәрит Гәбдерәхимовка*

Бер мәхшәрдән икенчегә кердем.
Энергиянең бар законы:
Басым кысса, мәхшәр кайнарыннан
Хасыйл була котып салкыны.

Тәнгә генә салкын, җанга җылы
Буровойга кунган түтәрәм
Айның ыргагында җир астыннан
Сезгә йөрәк ташы күтәрәм.

Йөрәк ташы — ул таш йөрәк түгел.
Йөрәк ташы — ирлек мыскалы.
Моабиттан кайтып, «Сез ирекко
Тугрымы?» — дип безне кыскан ул...

Их, карларның, үлемсезлек эзләп,
Төнге буровойга керүе!
Заңгәр баткак ясап, иңнең кайнар
Энергиясендә эрүе!..

Кәркәлемнең соңгы туе сыман
Бу карлар да атлы-чаналы,
Кыңгыраулы... Кыңгырауның теле
Агач, ахры — моңы чамалы...

Әй, моң җаным! Син өстеннән җирнең
Киткәч, кипте һәр җан иясе.
Инде җир астыннан эзлим сине,
Йөрәк ташым энергиясе...

Түбәбезне каерып кергән айны
Икегә ярган трос-канатны
Өзгән чакта, энәгә кадалып,
Йөрәк башкайларым канаттым...

Нишләргә соң? Сезгә юлы бикле
Энергиям көмеш бораугa
Китсен, дидем. Бардан юк булмый бит.
Җыр бит иман эсти коралга.

Эш өстендә искә төшсәң син, моң,
Җиргә нурын сибә тулган ай.
Кызлар җыры, яңа чапкан печән
Исе белән кайный буровой...

Чуеннарның кара сәхнәсендә
Кем ул бии — аклы күлмәктән?
И, моң җаным, син бит! Минем өчен
Тагын исән үттең әлмәктән...

...Турбаслы өстендә төн куера.
Яңа — әлегә зәгыйфь! — таң керә.
Ике мең ат җиккән дизельләрем
Йөрәк ташы даулап үкерә...

*201 нче буровой,*
*Турбаслы авылы яланы.*

# Риф Мифтахов

## Һай, Салават — җир күрке

*Салаваттай батыр булмаганда.*
*Бу илләрнең безгә ни күрке?*

Халык җырларыннан.

Кыш халыгы далада,
Кош талпына һавада,
Атлар тауда дан ала,
Егет яуда сынала,
Егет яуда сынала.

Кылны кырыкка ярырлык
Чәчән сүзе — батырлык.
Телне кылыч иттереп
Алда бару — шагыйрьлек,
Алда бару — шагыйрьлек.

Шоңкар идең һавада,
Толпар идең далада.
Лачын кебек егеттән
Сүнми торган дан кала,
Сүнми торган дан кала.

Бәйгедә дә, яуда да —
Ил чәчәне кайда да
Син идең бит, Салават,
Дөнья үзе таң кала,
Дөнья үзе таң кала.

Батыр егет — яу күрке,
Чәчән егет — дау күрке.
Икесе дә син идең,
Уралымның бөркете,
Һай, Салават — Ил күрке,
Һай, Салават — җир күрке!

## Тимер Йосыпов

Сагыш бураны кагылды
Язларның бавырына.
Чайкалсам да,
Бирешмәдем
Кайгының авырына.
Кара кәгазьләр алганда
Кистемме төн карасын.—

Кайгыны авыр, диделәр,
Мин күтәреп карадым.
Ачлык татып үткәнемдә
Мизгелләрнең арасын,
Дөньяны авыр, диделәр,—
Мин күтәреп карадым...

## Әсхәл Әхмәт-Хуҗа

### Башкорт теле

ӨЗЕК

Язылгансың сырлы маңгаена
Дисбе тоткан сабыр картларның...
Хәтерләт син авыл малаена
Әкиятле сабый чакларын.

Сылуларның «сөям!» дияе син
Хәләленә өзелеп-өзелеп.
Тау-кырларның «көям!» дияе син,
Җәй мәлендә эссе җил өреп.

Кодаларны коштай сайратасың,
Туй кызганда, илләр аманда.
Салаваттан кылыч кайратасың,
Кузгалганда хәтәр заманнар.

Корыч-булатларның алышы син.
Ораны син яу-дау елының.

Кырыс гасырларның сагышы син.
Аһәңе син бишек җырының.

Гыйльмияза, Сибай-кантоннарның
Син түгелме тиңсез моң-сазы?!
Тылда җәфа чиккән хатыннарның
Син түземле, өнсез авазы.

Илнең яме, чәчәннәрнең чәме,
Агыйделдә дулкын кагышы...
Иреннәрдә һәр сүзеңнең тәме,
Агылдисә курай тавышы.

Әй газиз тел! Рухың җанны өтә,
Син — безнең кан, яшәү сутыбыз...
Безгә синең бары чаткың җитә
Дөрләр өчен йөрәк утыбыз!

## Гөлфия Юнысова

### Кымыз ясаучы кызлар

Кызлар таңда бия сауган чакта,
Төшләр күреп йоклый күк урман.
Урман өсләреннән күтәрелә
Кымыз күбегедәй ак томан.

Яшь кызларның күңелләре төсле
Ак сөт тула калай чиләккә.
Гөбердәп лә аккан моңга кушып,
Җыр чыгара кызлар бүләккә.

Җыр әзерли кызлар егетләргә,
Килеп җитәр алар бүген кич.

Җиткән кымыз сымак әче бу җыр,
Кымыз гайрәтедәй исерткеч.

Күк урманга кичке томан төшсә,
Җан кергәндәй бердәм сукмакка.
Бер-берсенә сиздермичә генә,
Кызлар карый башлый шул якка.

Егетләрнең башы әйләнгәндер,
Әйләнә дә монда киләләр.
Кымыз вакытлары бер мәл генә
Икәнлеген яхшы беләләр.

## Рәмзилә Хисаметдинова

### Буранбай

Аяк өсте басып,
түбәтәен салып,
бер карт җыр башлады:
«Буранбай».
Мондый җырлар басып җырланыла,
мондый җырлар утырып җырланмый.

Халык кайгысыдай озын көй бу,
Себер юлы төсле озын көй.
Әй озын көй, озын Уралдай,—
Буранбай.

Әй Буранбай, синең язмышкаең
кайсы төбәкләрдә буранлай?

Мин — оялчан башкорт кызыкае,
Сөюемнән әмма тартынмам:
Нәкъ декабрист хатыннары төсле,
мин китәрмен синең артыңнан.

Чылбырларның чыңын басар иде
күңелләрең язган моңлы җыр,
кулыбызны беректерсә әгәр
сөю дигән иң нык бер чылбыр.
Әй Буранбай,
синең белән бергә
башкорт иле өчен янаем.
Илкәемә картлар елатырлык
табак-табак хатлар язаем.

Талдай нечкә кулларыма бакма,—
синең кебек мин нык кешемен,
кышның чилләсендә синең өчен
мүк җиләге төсле пешәрмен.

Себер бураннары озын-озын...
Озын көйдәй, озын бурандай.
Буранны да синең белән кичәм,
мин дә буран кошы, Буранбай.

Җыр өзелде...
Җырдан килде дә ул
Җырга кире китте Буранбай.
Йөрәгемдә олы мәхәббәтнең
озын хәсрәтләре буранлай.

### Асылгуҗа

❋

Кыңгырау чәчкәләренә
Күмелгән аклан иде...
Сөйгәнемнең күзе зәңгәр,
Кигәне актан иде.

Зәңгәр дөнья...
Ап-ак бәхет...
Мәхәббәттән исереп,
Җилкенгәндә, тойгыларның
Иң татлысын кичереп,
Сорадың:
«Безнең сөюгә
Төшмәсме кар-кыраулар?»
Эндәшмәдем.
Чәчкәләр дә
Әйтерсең, саңгыраулар...

Акты вакыт...
Бергә булдык
Буранлы елларда да,
Бергә үттек чәнечкеле,
Чәчкәле юлларны да.

Акты вакыт...
Яшьлек калган
Акланга килдек тагы,
Күзләреңнең әүвәлгечә
Зәңгәр нур сипкән чагы.
Елмаясың:
«Безнең сөю —
Төшмәслек кар-кыраулар!»
Эндәшмәем.
«Әйе шул!» — дип,
Баш кага кыңгыраулар...

## Зөһрә Котлыгилдина

— Кайгы, кая барасың?
— Картайтырга барамын.
— Сагыш, кая барасың?
— Саргайтырга барамын.

— Шатлык, кая очасың?
— Сөендерә барамын.
— Хәсрәт, кая качасың?
— Төн чигенә барамын.

— Өмет, ни ул иңеңдә?
— Канат алып барамын.
— Бәхет, юлың авырмы?
— Газап ярып барамын.

— Сөю, көчең нәрсәдә?
— Мәңгелеккә барамын.
— Гомер, юлың озынмы?
— Керфек каккан арамын.

## Рәшит Солтангәрәев

# ҮТӘЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ

хикәя



Бәхет турында күпме акыллы сүзләр әйтелгән, ә аны һәркем үзенчә аңлый.

Әхмәдулла бәхетнең нәрсә икәнән әле яңа гына белде. Ул шул тиклем гади һәм зур икән. Моңа кадәр Әхмәдулла гел бәхетле булган, тик үзе генә аңламаган-белмәгән. Бәхет ул — шушы дөньяда яшәү, ә калганы — барысы да вак нәрсә.

Һәр нәрсәнең кадерен аны югалткач кына беләсең, диләр. Әгәр дә бәхетсезлеккә юлыкмаса, ул моны, бәлки, гомерендә дә аңламаган булыр иде. Менә хәзер урыныннан торып китә алса, ул бөтен дөньяга ишетелерлек итеп:

— Әй, кешеләр! Сез бит бәхетле! Шуның кадерен белегез! — дип кычкырыр иде.

Мондый акыл, вакыты җиткәч, һәркемгә дә киләдер. Тик ул, кешелек өчен бик кадерле булган бу сүзләрне әйтеп кала алмыйча, үзе белән мәңгегә алып китәдер инде...

Кичә аны профессор карады. Карады да, янындагы врачка нидер әйтте. Ул моны латин телендә әйтсә дә, Әхмәдулла барыбер аңлады. Профессор, әлбәттә, егет озакламый китәчәк, дигәндер. Шулай димәсә, ят телдә сөйләшмәсләр иде.

Берәү дә мәңгелек түгел. Картинәсе әйтә торган иде: туымнан калмагач, үлемнән калып булмый...

Анысы дөрес тә бит, әмма гомер азагы бигрәк кинәт килде. Үлем, әйтерсең, кара балтасын тотып, караңгы почмакта сагалаган да торган. Хәтта яшеренмәгән дә... Ваемсыз барган кеше аны күрмәгән. Теге, ыргып чыгып, бәрде дә куйды. Дөньяда шуннан да зур гаделсезлек һәм мәкер юктыр.

Ул еш кына Зариф дигән бер авылдаш абзыйның сүзен исенә төшерә: шулай бер тормыш, гомер турында сүз чыгып китте дә, теге абый ихлас күңелдән: «Әле мин яшәгән сымак та түгелмен»,— дип куйды. Әхмәдулла таң калды. Аның өчен инде Зариф абый — бик күпне күргән кеше. Алар ыштансыз йөргән чакта ук, абыең орден, медальләрен тагып, ярты дөньяны әйләнеп, сугыштан кайтып төшкән иде. Шул вакытта ук инде Зариф бик өлкән күренә иде. Хәзер ул заманнардан соң күпме сулар акты. Әхмәдуллалар үзләре ир булып житте. Ә теге абый инде ашарын ашаган, яшәрен яшәгән кеше төсле күренә. Менә хәзер исәпләп ята: бик өлкән күренгән теге абыйга сугыштан кайтканда нибары егерме биш яшь булган. Хәзер андыйларга, гомумән, малай дип кенә карыйлар.

Дөресен әйткәндә, моңа кадәр берәрсенең үлем хәбәрен ишетсә, артык исе китми иде аның. Әйтерсең, шулай тиеш. Шуннан картинәсе сымаграк уйлап куя: «Ярар, ашар ашы, эчәр суы беткәндер...» Аларга кадәр дә әллә күпме кеше яшәп киткән бу дөньяда. Барысы да үлә. Бу җәһәттән дөнья бик гадел.

Әхмәдулла, гомумән, тормышны бер тауга охшата. Тау биек. Түбәсе очлы. Иң түбәдә ул үзе тора. Ә калганнар — аңа тиклем яшәгән кешеләр — барысы да түбәндә, тауның итәгендә. Алар, әйтерсең, үз гомерләрен Әхмәдуллалар югарыдан бер тарих итеп торсын өчен генә яшәгәннәр. Дөнья, шунда барып житкәч тә, туктаган, ә калган ягы — мәңгелек...

Хәзер генә ул үзенең коточкыч алданганлыгын аңлады. Берәү дә мәңгелек түгел. Димәк, аның үзенең дә ашар ашы, эчәр суы, күрер көне беткән. Ул шушы тау итәгендә жиргә сеңеп, күмелеп калачак, ә тау торачак, ускәннән үсәчәк.

Бәлки, үлем үзе куркыныч та түгелдер. Тик тормыш кала, дөнья кала бит. Аннан соң да кояш көн д чыгачак, ел да яз булачак. Иптәшләре, һәр көн иртән автобуска утырып, вахтага китәчәк... Һәр дүшәмбе көн оперативкага җыелачаклар. Кычкырыш нык кына булса, кайтышлый ресторанга сугылып чыгачаклар. Ә анда Әхмәдулла булмаячак. Гомумән, беркайчан да булмаячак һич кенә дә башка сыярлык түгел. Ул дөньяны үзеннән башка күз алдына да китерә алмый иде. Баксаң, дөнья өчен ул берни дә тормый икән!

Әхмәдулла үлемне шулай күз алдына китерә: әнә, алда караңгылык. Шундый зур, әйтерсең, дөньяның нәкъ яртысы. Яртысы — ап-ак, яртысы — кап-кара. Шундый караңгы, хәтта капкачсыз баздан да хәтәррәк. Менә шушы дөнья аны әкрен генә үзенә суыра. Елан, күлдә ятып аждаһага әйләнә дә, кешене тыны белән тартып йота икән, имеш, дип сөйли торган иделәр элек. Хас шуның шикелле.

Хәзер ара да зур калмаган. Әхмәдулла карыша алмый, хәле юк. Акрын гына йотыла бара, йотыла бара. Менә озакламый кара дөнья аны бөтенләй йотачак. Йотачак та, таш шикелле итеп, бер киштәсенә салып куячак. Ул үзе дә күмер шикелле инде, тик күзләре генә ялтырый. Әхмәдулла шушы киштәдә ятачак та ятачак, ә үзе якты дөньяга караячак. Мәңге шулай... Йөрәгең ярылыр! Юк, беткәч, берьюлы бетсен, берни дә күренеп тормасын!

Әллә ниләр килә башка... Ә берничә көн генә элек аннан да бәхетле кеше булмаган. Шулар барысы да яңадан кайтса икән!

...Әхмәдулла күптән инде, путевка сатып алам да чит илдә йөреп кайтам әле, дип хыяллана иде. Быел шул турыда сүз кузгаткач, әллә кайсысы:

— Чит ил дигән буласың, ә үзең Башкортстаныңны да юньләп белмисеңдер әле,— диде.

Уйнап әйтелсә дә, бу сүзләр аның уйларын икенчегә борды да жибәрде. Дөрес сүзгә ни жавап дигәндәй, бер иптәше белән жәй, резина көймә сатып алырга да Агыйделнең башыннан алып Камага койган жиренә кадәр төшәргә дип сөйләштеләр. Тик иптәшенә ул чакта ял бирмә-

деләр. Әхмәдулла, бөтенесенә кул селтәде дә, авылына кайтып китте.
Аларның авыллары тирәсенә геофизиклар килеп тулган. Будкалар тартып китергәннәр, палаткалар корганнар, тирә-як гүләп тора.

Вакытны ни рәвешле үткәрергә белми йөргән кешегә шәп булды лабаса! Әхмәдулла көн дә шулар янында кайнашты. Студент чагында мондый разведкага йөргән иде ул. Элек бер дә исе китми кебек иде, үзенең туган яклары булгангамы, кызыкты да китте. Бәлки, берәр нәрсә табылыр. Ул әллә ниләр уйлап бетерде: менә көтмәгәндә нефть фонтаны бәрә, зур гына ятма ачалар, промысел оештыралар. Әхмәдулла да эшкә шунда кайта.

Шулай ул көн дә болар янына килә дә сейсмик карталарны өйрәнә, тегеләр белән бәхәсләшеп китә. Кайвакыт: «Син нәрсә беләсең, әзер нефтьне чыгаручы гына бит син!»— дип, үзеннән көлеп тә алалар.

Разведчиклар Суктай тавын бораулый башлады. Заманында Әхмәдулла аз таптамады бу якларны. Бәләкәй арбага утын төяп, шушы үзәннән йөрүләре әле дә онытылмый. Әй озын була торган иде дә соң шушы тау үре! Менәсең-менәсең, һаман очы күренми.

Менә шушы җирләрнең астында ниләр ята икән? Ул чынлап кызыгып китте, әйтерсең, инженер түгел, ә авыл малае. Партия начальнигы да, аның уен белгәндәй:

— Карыйк әле, син нәрсә таптап йөрисең икән? — дип, гел үзе белән бергә йөртте.

Скважинаны бораулап бетереп баралар, озакламый шартлатырга тиешләр. Әхмәдулла станок янына килде. Әйтерсең, хәзер Суктай тавы астыннан әкияттә генә сөйләнгән алтын-көмешләр килеп чыгачак.

Барысы да гадәттәгечә бара иде. Шофер двигательне җибәрде, бораулаучы тормоз кырына басты. Кинәт роторның гүләве генә ишетелеп калды — Әхмәдуллага искиткеч каты нәрсә белән китереп суктылар. Ул исәнгерәп китте. Каядыр очып барган сымак тойды үзен. Шуннан барысы да онытылды...

Әхмәдулла больницада гына аңына килде. Врачлар дөрес кенә диагноз куя алмадылар, бәхәсләштеләр-бәхәсләштеләр дә, дүртенче көнне самолет чакыртып, Уфага озаттылар...

Кичә ул күршесеннән көзге сорап алды. Аны хәлсез куллары белән көчкә-көчкә генә тотып, йөзе каршысына китерде. Каравы булды, куркуыннан шунда ук күзен йомды. Мондый ябык кешене гомердә дә күргәне юк. Бүтән вакыт булса, шушы кешенең үзе икәненә һич тә ышанмас иде. Элек көлеп торган күзләре, мае беткән шәм сыман, сүнеп калган. Йөз — сары, авыз — зур, яңак сөякләре чыгып тора. Ике атна бит инде, тәгам-ризык капканы юк. Тик су гына йоткалый.

Әлбәттә, врачлар да, күрергә килүчеләр дә: «Савыгырсың»,— дигән була. Алар, мөгаен, хәл өстендә яткан кеше баркатлы була дип уйлыйлардыр. Бәлки, аннан да түгелдер. Озак калмаганын Әхмәдулла тегеләрнең күзеннән үк күреп тора. Тик бу турыда әйтергә генә теләмиләрдер. Әйдә, юатсыннар, шуннан да рәхәт булып кала.

Әхмәдулла сызлануыннан төннәр буе йоклый алмый ята. Шуннан, йончуның чигенә чыгыптыр инде, йокымсырап китә, тагы уяна. Уянса, әлеге шул бер күренеш: дүрт стена, аның эчендә — чуар кием кигән аксыл йөзле кешеләр...

Аларның палатасы икенче катта. Тәрәзә төбендә генә бер карама үсеп утыра. Картайганлыктанмы икән, җәй утрасы гына булса да, аның яфраклары саргайган. Җиләс көнне шушы сары яфраклары шыбыр-шыбыр килеп үзара серләшәләр, ә җил шәбрәк булса, өзеләм-өзеләм дигәндәй чәбәләнәләр.

Әхмәдулла көне буе шул сары яфракларга карап ята. Әнә бер шөпшә, икенче көн инде, ireккә чыгып китә алмый, тәрәзә пыяласы буйлап чыжылдый. Монда нигә килеп кергәндер инде, мескенең. Кичә берәү тастымалы белән сугып үтерергә маташкан иде, эләктерә алмады. Әх-

мәдуллага шөпшә җәл. Хәле булса, тәрәзәне ачып, чыгарып җибәрер иде. Әйдә, очсын, дөнья тармыни, ул да җан иясе бит. Моннанерактагы бер катлы йортларның калай түбәләре дә күренә. Күпләре байтактан бирле буялмаган, ахрысы, тутыгып беткән. Әхмәдулла шул йортларга карап ята. Төнен бу күренешкә трамвай дугасыннан ялтырап очып калган очкыннар гына өстәлә. Әхмәдуллага күренгән бөтен дөнья менә шул.

Кызык, шушы вакытта трамвайда кемнәр китеп бара икән? Мөгаен, модалы киемле бер яшь егет янындагы кызга бик эре, белдекле кыяфәт белән нидер сөйләгән буладыр; ә авылдан килгән бер әби, төшә торган җире әле бик ерак булса да, әллә кайчан ишек төбенә килеп баскандыр да үтүчеләргә комачаулап торадыр. Кешеләр билет алу өчен бер-берсе аша кассага тиенлек тәңкәләр җибәрәләрдер. Һәммәсе дә күңелле, шат. Алар шушы вакыт Әхмәдулланың дару исе аңкып торган тынчу палатада, сызланып, бөтен дөньядан көнләшеп ятканын башына да китермиләрдер.

Эштә иптәшләре ни эшли икән? Бүген чәршәмбе шикелле. Мөгаен, Исәнголов кабинетында оперативка барадыр. Идарә начальнигы бишенче промысел мөдире Грабовскийны сүгәдер. Әллә нишләп яратып бетерми начальник шул кешене. Ә тегесе, гадәттәгечә, план үтәп җиткерә алмавын нефть катламында басым түбәнлегенә сылтыйдыр.

Бәлки, аны — производство бүлегенең өлкән инженерын да — искә алалардыр. Шулай әрепләшеп утырган чакларында Әхмәдулла, нииндидер уен сүз табып, ярсыган кешеләрне көлдереп ала торган иде. Хәтта Исәнголов та елмаймый түзә алмый.

Башта кем әйтер икән аның исемен? Мөгаен, һәрчак ишек төбендә генә утыра торган Тоня әйтер. Сөйкемле кыз ул. Очрашсалар, кыз берни әйтми, зур матур күзләре белән Әхмәдуллага тагы да якынрак булып китә.

Әхмәдулланың Сәгадәт дигән бер дусы бар. Кызык кеше ул. Хәзер инде картаеп барса да, мәктәптән калган гадәтен һаман ташламый — почта маркалары җыя. Кайчан да булса филателистлар конференциясендә катнашачакмын дип хыяллана. Әле һаман, көн дә иртән секретарь янына кереп, яңа килгән хатларның маркаларын сыдырып йөридер.

Шулай Әхмәдулла әллә нәрсәләр турында уйлап бетерде.

Кызык, кеше исән-сау чагында гына үзен шулай гаҗәеп көчле, бөтен дөньяның хуҗасы сымак тоядыр инде. Таза чакта ул нәрсә тели, шуны эшли ала. Менә ул үзе теләде — институтка керде, теләде — гомердә күрмәгән Татарстан промыселларында эшләп кайтты...

Бер шулай, студент чагында әле, төнлә бик соңлап кайтып бара иде. Ике егет бәйләнделәр. Күзләрендә өмет юк. Сүз, гадәттәгечә, тәмәке сораудан башланды. Әхмәдулла папирос чыгарып бирде дә китәргә чамалады. Тегеләр тагы туктаттылар. Күренеп тора, ниятләре яхшыдан түгел. Берсе килде дә, эре генә төс белән, монын пәлтәсен тотып карады:

— Ару, чишендерергә мөмкин,— дигән булды ул иптәшенә. Ни чамалаулары күренеп тора инде.

Әхмәдулла үзенең көченә ышана иде. Ул да тегенең бишмәтен капшап карады:

— Синеке хөрт, чишендереп тормыйм,— диде.

Тегеләр бераз каушап калды.

— Чамала,— дигән булды берсе. Болар өчәүләп бер-берсенә күзгә этәчләр шикелле карашып тордылар да, Әхмәдулла үз юлына китеп барды.

Менә ул хәзер дөньяда иң көчсез җан иясе. Тәрәзәдән күренгән бөтен нәрсәгә көнләшеп карап ята. Кояштан да, шул карамадан да, әнә шул иске йортлардан да, трамвайда китеп барган кешеләрдән дә... Әлек бөтен дөнья Әхмәдулланы бик якын күргән, үз кешесе санап ирка-

ләгән, аннан бернәрсәсен дә җәлләмәгән, бар ишекләрне дә киң ачып куйган сыман иде. Менә, авыр хәлгә тару белән, бернинди дә ярдәм кулы сузмый, йортлар да, агачлар да, күге дә, кояшы да, хәтта болытлар да хуш күңел белән карап торалар. Әйтерсең, алар өчен Әхмәдулла булды ни дә, булмады ни.

Шулай инде, бу галәм өчен нәрсә генә ул Әхмәдулла дигән бәндә! Үлгәч, якыннарына хәбәр итәрләр. Кешеләр килер, елашкан булырлар, әйбәт адәм иде, иртә китте дип үкенешеп утырырлар.

Ә шулай да, дөньяны калдырып, ялгызың гына китеп баруы бик тә авыр икән...

Янә ашарга китерделәр. Балык, ахрысы. Исеннән үк укшыта башлый. Әхмәдулла авырлык белән генә стена ягына борылды. Аның ашамасын беләләр бит инде, нәрсәгә китерәләрдер? Әхмәдулла алар өчен палатадагы бер гадәти әйбер кебек кенә, күрәсең. Врачлар ашатырга кушканнар да, болар инде кемнең кем икәненә карап тормыйча, китерәләр дә китерәләр. Әхмәдулланың җаны көя. Әрлисе, кычкырасы килә — хәле юк.

Кичә аларның палатасында бер кеше үлде. Ашказынында яман шеш, диделәр. Әй ябыкты, мескенең. Бала сымак кына торып калды. Әхмәдулла аңа карамаска тырыша торган иде. Ялгыштан гына күзгә чалынып калса да, кәеф бетә, әллә ни эшләп китә үзе. Ә теге, моңа карый да, әйтерсең, безнең икебезне дә бер нәрсә көтә бит, ди.

Ул чирлене монда барысы да белә иде. Профессор да, медсестра белән аш ташучылар да үзен исеме белән генә йөртә. Үз кеше. Әйтерсең, ул чирле түгел, ә больницаның бер җиһазы.

Ул адәм моңа тиклем дә ике рәт ятып чыккан икән. Операция артыннан операция ясаганнар. Кабат алмыйбыз дисәләр дә, көчләшеп янә кергән. Өченче операцияне күтәрә алмаган. Аңа да шулай көн дә аш китерә торганнар иде. Әхмәдулла кебек, ашамасын белсәләр дә китерделәр.

Йә, ярар... Бәлки, чынлап та эчәр суы, ашар ашы беткәндер. Кайбер адәмнәр аның ише дә яши алмый китеп бара бит әле...

Әхмәдулла кайсы вакыт шулай үз-үзен юата, язмышына күнегергә тырыша. Ни хәл итәсең... Тик бер үкенеч кенә кала дөньяда. Хәтәр үкенеч! Шунысы булмаса, калганы әллә ни авыр да тоелмас, язмыштан узмыш юк, дип тә куяр иде.

Күпме хыялланып йөрде, ә шуны эшләп бетерергә вакыт таба алмады. Кайда ул бетерү, хәтта башланмады да. Форсат тапмады. Кайвакыт барысын да атып бәрергә дә, әлеге эшенә утырырга дип хыялланды.

...Менә ул көтмәгәндә зур ачыш ясый. Кая барма, тик аның эше турында гына сөйлиләр. Бу хезмәтен хәтта чит илдән дә килеп өйрәнеп китәләр. Әхмәдулланы хәзер беркайчан да онытмаячаклар... Һәрхәлдә, Җир шарында тере җан бар чакта! Аннан инде бернәрсә дә үкенечле түгел бу дөньяда!

Нефтьчеләр алдында күптән инде бер проблема тора: ничә еллар күпме акыл ияләре баш вата, әмма һаман очына чыга алганнары юк.

Моңача кешеләр җир астындагы нефтьнең яртысын гына чыгара ала. Булганның яртысын ала, ә калганы мәңгегә шунда тора да кала. Көчле насослар куялар, су белән кысрыклап та карыйлар, тагы әллә ниләр эшләтәләр — мәгәр калган яртысын, хәтта аннан да күбрәген суыртып ала алмыйлар. Ни дисәң дә, кеше — өстә, ә теге — аста, сирпеп кенә алып булмый бит. Шулай маташалар, маташалар да, бу ятма искерде, бу урынның нефте бетте дип, икенче якка китеп баралар.

Нефть, әлбәттә, беркая да качмый, ята шунда. Берәр вакыт, бәлки, чарасын табарлар, анысын алла гына белә. Кешегә бит хәзергесе кыйммәт. Әле дә кайберәүләр катламга эссе су, кайсылары — пар, кайсылары төрле реагентлар кудырырга тәкъдим итә. Мәгәр файдасын күргәннәре юк әле.

Гади бер инженер булса да, Әхмәдулла да шушы турыда баш ватты. Үзенең ниндидер фикерләре дә бар иде.

Былтыр институтларында курсташлары белән очрашу булды. Шунда Әхмәдулла элекке кафедра мөдирләре белән сөйләшеп торган иде. Карт профессорга яшь инженерның фикере бик ошады.

Гомумән, профессор аны күрүенә ихластан куанды:

— Мин сине онытмадым, тик кайда икәнлегеңне генә белми идем. Хәтереңдәдер әле, диплом яклаган вакытыңда ук монда калырга тәкъдим иткән идем. Бәлки, эшләп алуың шәбрәк тә булгандыр. Хәзер сиңа командировка алып тәҗрибә үткәреп йөрисе түгел. Лабораторияң үз янында. Реферат язып китер. Тик озакка сузма, калганына үзем ярдәм итәрмен,— диде.

Әхмәдулла вәгъдә итте. Хәтта срогын да әйтте. Тик кайту белән онытты. Хәер, онытуын да онытмады, ничектер, вакыт таба алмады. Көннәр төрле мәшәкать белән үтә торды. Ярый инде, бүгенгә вакыт юк, иртәгә тотынырмын әле, диде. Ә иртәгәсен инде алдагы елдан башларга булды. Хәтта, бер җаен табып, китапханәдән кирәкле китаплар да алып кайткан иде. Иптәшләренә масаеп та ташлады, тик эш килеп кенә чыкмады. Китаплар ятты шунда, ара-тирә ачкалап карады да салып куйды. Нәрсәгәдер, һәрчак шулай тоела бит: әлегә вакыт юк, әллә нинди эшләр туып кына тора. Менә шул вак-төяк мәшәкатьләрдән арынып кына алсын. Бөтен зур эшләр алда! Әле яшисе көннәр бик күп бит әле. Барысы да эшләнәчәк.

Сәгать суккан шикелле, көннәр дә шулай бер-берсенә охшап үтә торды. Ә теге вакытын көтеп яткан нәрсәгә барыбер җитешә алмады.

Белми, бәлки, ул уйлаганча зур эш килеп тә чыкмас иде... Һәрхәлдә дә, әгәр үлеп-нитеп китсә, ул үзе белән бик зур серләрне алып китәр төсле. Ул уйлаганны, ул белеп кичергәнне беркем дә белми дә, кичерми дә. Бәлки, беркайчан да белә алмаслар.

Шуларны уйласа, үзәкләре өзелеп китәрдәй була. Кинәт ыргып торасы килә. Уйланудан хәтта сызланулары да бетеп киткәндәй була. Йөрәге дөп-дөп тибә башлый. Тукта, ни эшләп ята соң әле монда! Ул шундый көчле егет ләбаса. Менә кинәт одеялларын атып бәрде, ыргып торды!

...Әхмәдулла ыңгырашып җибәрде. Болар барысы да аның хыяллары гына иде. Үзе шул килеш ята икән. Тик, ничектер, яман кузгалып кына куйган.

— Ни булды?! — палатадагылар сикерешеп торды.

— Юк, болай гына...

Авырулар, аның янына җыелып, бераз карап тордылар да, урынnарына киттеләр. Әхмәдулла кире стена ягына борылып ятты.

Медсестра килеп керде. Хәбәр иткәннәр икән. Монда авырулар, берәрсенә хәтәррәк хәл булса, йә дежур врачны, йә медсестраны чакыралар. Бердәнбер күрсәтә алган хәстәрлекләре шул.

— Бураншин, хәл ничек? — медсестра аңа фамилиясе белән эндәште.

— Ару...— Әхмәдулланың җаны көйде.

Медсестра бик сылу, мөлаем кыз. Чәчләре сары, хәтта аксыл сары, буялганмыни! Бәлки, буягандыр да, хәзер белеп бетермәссең. Ә күзләре, энә, тәрәзәдән чак кына күренеп калган күк йөзе сыман. Шушы кыз алдында бер мескен булып ятты!

— Кайда?..— кыз сак кына итеп одеялны тартып куйды.

Әхмәдулла башын күтәрә төште. Сестра шприц тотып тора. Менә хәзер ул Әхмәдулланың как имән кебек каты тәненә шушы энәсен кадар. Әйдә, теләсә ни эшләсен, барыбер беткән баш...

* * *

Ул иртән уянганда тумбочкада бер сумка күчтәнәч тора иде.

— Кичә иптәшләрең килгән иде. Син йоклагач, уятып тормадык,— диделәр аңа.

Омтылып, күчтәнәчләрне алды. Китермәгән нәрсә калдырмаганнар. Ашый алмасын беләләр бит инде, барыбер китерәләр. Хәер, буш кул белән йөрү уңайсыздыр. Алар урынында үзе дә шулай эшләр иде.

Кем килде икән? Язу да калдырмаганнар. Әхмәдулла иптәшләрен күрә алмый калуына, нигәдер, үкенмәде. Алар алдында да мескен булып ятасы килмәде.

Әә, язу калдырганнар икән! Менә нинди көнгә калды кеше, хәтта кәгазьне дә тартып чыгара алмый.

Ниһаять, ул үзенең нәзек озын бармаклары белән кәгазьне тартырга тотынды. Ә-ә, Шик! Белорус егете. Җир асты ремонты мастеры. «Белорусь» тракторын «якташым» дип йөртә торган иде. Әхмәдулла көлемсерәп куйды. Шәп егет, шул килгән икән. Мөгаен, монда бер эш белән җибәргәннәрдер дә, юл уңаенда сугылгандыр. Җәй аларның бик тыгыз вакыты. Йә ялга чыккандыр. «Эштә барысы да әйбәт, тик сине генә юксынабыз»,— дигән булган. Анысын күңел өчен әйткәндер инде. Бәлки, ихластан язгандыр...

Әхмәдулла байтак кына шушы хакта уйланып ятты. Төшкә табан сызлануы янә көчәйде. Хәзер инде кабырга гына түгел, бөтен тән яна. Әйтерсең, теге утлы тимер бөтен тәнне урап алган. Кеше үзе дә, ай-һай, түзем җан иясе икән! Тәннең дә, җанның да шул сызлануларга көрәшер хәле калмагандыр инде дигән иде, менә һаман яши бит. Нәрсәсе белән шул кадәр каршы тора ала икән? Мөгаен, йөрәге белəндер. Ай-һай, шәп иде аның йөрәге. Хәтта врачлар да аптырап куя торган иде. Хәзер хәле бетәдер инде, ничә көн ашаган да юк бит.

Ашаганы?.. Ул әлеге күчтәнәчне исенә төшерде. Егетләргә бирергә кирәк, ашасыннар. Ул күзен ачты. Палатада беркем дә юк. Йөрергә чыгып киттеләрме икән? Көнне шундый матур дип сөйлиләр. Яңгыр да булып үткән, ахрысы, шуны да сизмәгән. Тәрәзә ачык, тыштан саф һава бәрә. Бәхетле кешеләр тышта йөриләр. Бәхетле?.. Монда яткан кеше бәхетле була димени инде? Шулай да, урамдагылар аннан бәхетлерәк.

Ул янә кичәге уйларын исенә төшерде. Чынлап та, нинди гамьсез кеше булган икән үзе. Йә, кара, күпме көннәрен бушка үткәргән. Вактөяк, кирәкмәгән күңел ачулар, мәгънәсезгә урам тапау, юк-бар үен-бәхәсләргә никадәр көннәрен, көчләрен әрәм итәләр иде бит.

Йә, шуннан бер генә көн булсын иде Әхмәдуллага! Әй белер иде ничек яшәргә икәнен! Секундын да әрәм итмәс иде. Күрсәтер иде вакытны ничек кадерләргә кирәклеген!

Тукта, әгәр дә чынлап та бер көн бирсәләр, ни эшләр иде икән? Иң элек әлеге эшенә тотыныр иде. Бернигә дә карап тормас, тотыныр да, эшләп тә бетерер. Сусап килеп чишмәгә юлыккан кеше сыман. Юк! Иң элек ул дөнья кешеләренә васыять язарга тиеш. Гомер турында, вакыт турында... Тукта, ә нәрсә дип язар соң? Мөгаен, шулай башлар:

«Әй, кешеләр, сез якты дөньяда яшәвегезнең кадерен белегез. Гомерегезнең бер бәләкәй генә өлешен дә бушка үткәрмәгез. Сез, бәлки, бөек эшләр дә башкара алмассыз, әмма үзегездән соң яшәр кешеләр өчен нинди дә булса истәлек калдырып китәргә тиешсез. Үкенечле гомер үлемнән дә куркынычрак. Гомерне мәгънәсезгә үткәрү — сине тудырган кешеләр алдында зур җинаять!..» — Әхмәдулла үз уйларына шул кадәр ышанган иде, хәтта авыртуларын да онытканы...

Озак уйлап ятты бу турыда. Аннан шулай корды планын: васыятен язып бетергәч тә, әлеге эшенә тотына. Хәтта танышларын, дусларын күрмәскә дә риза, тик уйлаганнарын гына эшләп өлгерсен. Ичмасам, кешеләргә бер файдасы тияр. Азак әллә ни булса да, ул тиклем үкенеч калмас.

Уф, тән яна. Түзәр генә әмәл юк. Нигә тизрәк операция ясамыйлар! Ни булса да булсын да...

Юк, мөгаен, үләр ул, озакка бармас. Шул ук көнне иптәшләренә, туганнарына хәбәр итәрләр, машина килер. Анысын карага кызыл баскан материя белән уратып куярлар. «Әхмәдулла үлеп киткән икән»,— диярләр. «Кайсы?!» «Әнә, производство бүлегендә эшли иде ләбаса, өлкән инженер...» «Китче әле? Вәт дөнья, ә! Нинди нык егет иде! Яшь бит әле, өйләнмәгән дә бугай...» «Жәл, әлбәттә, тик үлем карап тормый инде...»

Шулай сөйләшеп йөрерләр берничә көн. Кайберәүләр елар, әйбәт егет иде, диярләр. Кайда күмәрләр икән? Эшләгән җиргә алып барырлармы? Юк, туганнары риза булмас. Авылга алып кайтырлар. Тәртибенә китереп күмәрләр, шуннан баш очына бер таш куярлар. Шуның белән — вәссәлам! Әхмәдулладан бу олы дөньяга калган нәрсә шушы. Калганы барысы да вакытлы нәрсәләр булган.

Кайчан үләр икән? Мөгаен, шимбә көн булыр...

Әхмәдулла үзе дә аптырап китте. Мәгәр, барыбер, шимбә үләр сыман. Ул санарга тотынды. Шимбәгә кадәр ничә көн калды икән? Теге адәмгә кайчан операция ясадылар соң әле? Якшәмбе түгелме? Юк, дүшәмбе көн. Аннан соң ничә көн үтте? Кичә иптәшләре килде... Тукта, бүген пәнҗешәмбе үк түгелме әле? Өч!.. Кайда өч, ике генә көн калган ләбаса! Ни өчен шимбә үк дип уйлады соң әле? Хәзер киләсе шимбә аңа иң котсыз, кара төн булып күренә.

Шимбә... Мөгаен, бу көнне иптәшләре Караидел буена балыкка барырлар. Монда күп яклардан җыелалар. Хәтта икешәр йөз чакрымнан киләләр. Бердәнбер таза елга дисәң дә була аны. Калганнарын пычратып бетерделәр. Балыгы да юк, булганыннан да керосин исе аңкып тора, авызга алырлык түгел.

...Ә шулай да ничә көн калды соң әле? Чынлап та, бүген пәнҗешәмбе микәнни? Юктыр, егетләр кайткач сорар әле. Хәер, сорарга ярамый. Йә дөрес чыгып куяр.

Шулай итеп, васыять тә яза алмады, эшен дә эшли алмады инде? Суга тамган тамчы кебек кенә юк булыр да куярмы?

Юк, шимбә үк түгел! Соңрак... Бер-ике генә көнгә булса да — соңрак...

Кинәт бер хәл искә төште. Кемнедер җәзалап үтерәләр икән. Кисәргә дип башын бүкәнгә салгач, теге адәм палачтан тагы бер генә минут гомер бирүен сорый... Кайда укыган иде соң әле? Хәтердән чыккан. Кемдер көлә. Янәсе, бер минут нәрсә инде ул! Әхмәдулла да көлгән иде... Ә, исенә төште! Достоевский... «Идиот»...

Кинәт Әхмәдуллага түшәмдә люстра кузгалып куйган төсле булды. Әйе-әйе... Әнә люстра да, түшәм дә кузгала. Икесе ике якка китә. Стеналар да селкенә. А-а!.. Ярдәм итегез!..

Менә йөрәк тә тибүдән туктады шикелле. Аяклар суына. Әй, дөнья, нишләп шул тиклем рәхимсез, битараф торасың! Ярдәм ит, бер кешең үлә ләбаса! Нигә барысы да шулай тыныч' кына тамаша итеп тора бу хәлгә?!

Ичмасам, әлеге карамага күз салып алырга иде. Китәр алдыннан бер тапкыр гына. Тәңре бер көнен дә җәлләде, бирмәде. Күзе дә ачылмый, тик иреннәре генә кыймылдый шикелле.

Бөтен дөньяны, җирне караңгылык баса. Хуш, якты дөнья...

* * *

Операцияне профессор үзе ясады. Теге вакыт каты сугылудан ашказаны белән бавыр арасына кан укмашкан булган. Ул зурайганнан-зурайган, бавырны кыскан. Шеш дип ачсалар, бөтенләй икенче нәрсә булып

чыкты. Бу жирне кире тегеп, икенче урыннан тагы ярдылар.

Операция озак барды. Тик ул боларны үзе хәтерләми. Үтте инде, хәзер ашарга да ашарга гына. Китергән ризыкларны савыты-ние белән йотардай була. Өлешне аңа болай да зуррак бирәләр, иптәшләре дә китереп тора, юк, һаман туенып булмый.

Озакламый палата эчендә йөри башлады. Савыгып кына чыксын әле, белер ничек яшәргә икәнен!

Авариядән соң ай ярым дигәндә, Әхмәдулла больницадан үз аягы белән чыгып китте. Башта бераз авылда ятты, шуннан ике ай Кавказда ял итте. Хәзер инде барысы да элеккечә: һәр чәршәмбе алар Исәнголов кабинетына оперативкага җыелалар. Әхмәдулла, берәр кызык сүз әйтеп, кешеләрне көлдереп ала. Хәтта Исәнголов үзе дә елмаеп куя.

Әйе, барысы да элеккечә. Әхмәдулла да уйнап-көлеп кенә яши бирә. Кайвакыт больницадагы көннәрен дә исенә төшереп ала. Васыять язып калдырырга дигән уйларыннан көлеп кенә куя. Булгандыр инде, авыру кешенең башына ниләр килмәс дисең. Теге эшенә дә тотына алганы юк. Вак-төяк мәшәкатьтән бушап булмый. Булыр әле. Барысы да алда...

**Риф Мөхәммәтҗанов,**
филология фәннәре кандидаты,
фольклорчы

# БАШКОРТСТАНДА ТУЙЛАШУ

## 1. Туй йоласы

Татар туйлары гаҗәеп дәрәҗәдә бай поэзия тудырган йолаларның берсе. Нигездә туй поэзиясе йолага бәйле барлыкка килгән һәм туй барышында актив хәрәкәт итә торган иҗат төре булып күз алдына баса. Җырларда туйның иң мөһим яклары ачыла, катнашучыларның дөньяга карашлары, уй-фикерләре, тойгылары чагыла. Йолага бәйле рәвештә мактаулар, хурлаулар һәм туй җырлары үзара бик нык якыная һәм нәтиҗәдә бер жанрның стиль элементлары һәм эчтәлеге еш кына икенче жанрның образлы эчтәлеген һәм стилен тәшкил итә. Ләкин бу жанрның һәркайсысы үзенә генә хас стилистик форма белән аерылып тора.

Мәсәлән, гомум туй җырларында, әйтик, туйда катнашучыларның уй-фикерләре әйтелә. Сыктауларда инде туйга турыдан-туры катнашы булган кешенең, ягъни кияүгә бирелгән кызның шәхси эчке тойгысы, уй-кичерешләре чагыла.

*Ай-һай да гына башым авырта,*
*Кайда гына салып җатаем?*
*Кошлар җитмәс җиргә эткәй бирде,*
*Хет син яклар идең, апаем.*

*Су төбендәге шешәне*
*Алып ла булмый, туганкай.*
*Үзегез барып калым эчкәч,*
*Калып ла булмый, туганкай!*

Туйларда яңгыраган мактау җырларының алмашлыклары һәм фигыльләре, берлек формасында белдерелсә дә, нигездә аларга күмәклек мәгънәсе салына. Мәсәлән:

*Бишмәтеңдә биш төймә,*
*Бар да бохар көмеше.*
*Үзең тыйнак, сүзең бүләк,*
*Йөзең эрван җимеше.*

*Безнең кода — үзе хуҗа,*
*Күтәрә күңелләрне.*
*Әйткән сүзе алтынга тиң,*
*Уңгандыр киленнәре.*

Билгеле, бу төр мактаулар башка туй җырларыннан аерылгысыз рәвештә яши, ягъни алар туй җырларының органик тукымасына үрелеп керә. Кайчандыр алар йоланың асылын тәшкил итеп тә, соңыннан теләсә кайсы мәҗлестә яңгырауга күчә. Шуңа күрә кайсыбер тикшеренүчеләр аларны «мәҗлес җырлары» сыйфатында исәплиләр. Без дә аларны аерып карау ягында түгел. Чөнки башка халыклардагы шикелле, атап әйткәндә, руслардагы кебек, мәҗлес мактаулары туй җырларыннан аңык аерылып тормый. Туй җырларында да нигездә шул ук хөрмәтләү, дуслык-туганлыкка чакыру,

бәхет, шатлык, тигез гомер теләү (кияү, кәләш, аларның туган-тумачалары, аларны билгән уй-тойгылар) мотивлары төп урынны ала. Туй барышында саф драматик мотивлар да аз түгел. Мәсәлән, бөтен яклап кызны әйләндереп караулар, буен-сынын, йөзен, йөрешен, сөйләшен тикшерүләр кайвакытта комик, хәтта драматик төс ала. Кыз яшерүләр, ишек бавы өчен егетләренең сатулашулары, урын өчен тартышлары, кызның чәчен икегә ярулар, яулык каплаулар, кызның үз ахирәтләре, ирке, кыз күрке белән саубуллашулары, эти-әнисеннән аерылуы, туй җырларында аеруча җанлы сурәтләнгән каенана белән килен мөнәсәбәтләре, килен төшәчәк гаилә тәртипләреннән курку мотивлары, ахыр килеп, яшьләрне явыз рухлардан, яман кешеләрдән саклау чаралары күрүләр (борынгы кеше ышануынча, «туй пәрисез булмас», шуннан сакланулар: атларны амбарга ябып тотулар, мунчаны бикләп йөрүләр, капка саклаулар — дегет буяп-нитеп китмәсеннәр, янәсе, һ. б.),— күренүенчә, шактый зур кичерешләрне чагылдыралар. Ә менә аларның художество ягыннан бирелешендә драматик кискенлек юк: бары да шома, әйбәт, борынгыдан килгән ил йоласы белән, бер тапкыр урнашкан тәртип белән бара.

Билгеле булуынча, йола (туй) поэзиясе ул туй уенын озата, аны «оештыра», йоланың аерылгысыз өлеше булып килә, икенче төрле әйткәндә, йолага художестволы аңлатма, комментарий бирә. Ягъни шушы минутта, күп кешеләр катнашында барган хәлгә бәяләмә ясый, шуның эчтәлеген аңлата. Кыскасы, йола поэзиясендә хәзерге заман өстенлек итә, хәтта үткәндәге хәл турында сүз барганда да бүгенгесе күздә тотыла, шунлыктан туй поэзиясендә импровизация элементы зур урын ала. Академик Ю. М. Соколов күрсәтеп киткәнчә, «...елаулы җырлар (причитания) бик күп фольклор жанрларына характерлы, хас булганча, импровизация белән традицион поэтиканың кушылмасы»[1] ул.

## 2. Кыз елату

Туй йоласына ияреп туган сыктаулар чынбарлыкның хәзерге чагын чагылдыра. Ягъни кыз елатулар — күз алдында бара торган хәл турындагы әсәр, аның вакыты — хәзерге; художество ягыннан да, чынбарлыкка мөнәсәбәт белдерү ягыннан да — алар хәзерге. Дөресрәге, булып яткан хәл турында сөйләшү түгел, ә шуңа эмоциональ җавап булып тора алар. Шул ук вакытта кыз елату җырларында хикәяләү дә бар: бу хәл нилектән булды, әле ни бара, киләчәктә нәрсә булыр — шул турыда хикәя ителә. Әмма бу киләчәк хәзергегә — җанлы бүгенгегә буйсындырыла. Хәзерге — үткәннән чыга, киләчәк — хәзергедән барлыкка килә. Хәтта үткән белән киләчәк кыз елату җырларында бик зур роль уйный дип әйтергә дә мөмкин, чөнки хәзергене генә сөйләп, үткән белән киләчәкне телгә алмау — артык дәрәҗәдә хәзергене ярлыландырыр иде. Гадәттә аларны башкарган кеше (кыз үзе яки аның исеменнән җырлаучы хатын) сүзне бала чагына кайтып башлый, аннан соң да бик алга йөгерми, әзлекле рәвештә үстерә барып, яшьлек көннәрен искә ала, килә-килә бүгенге язмышына җитә. Җыр гадәттә чит-ят гаиләдә булачак тормышы турында куркып уйлану белән тәмамлана. Ягъни хәзерге вакыт — әле нилектән бу җыр туган — шул үткән заманда да, киләчәктә дә катнаша.

Сыктауларның (монда туй поэзиясе турында гына сүз бармый, үлем, кайгы, янгын, афәт һ. б. бәйле сыктап елаулар да күз уңында тотыла) гомумән самими хатын-кыз иҗаты булуы хәтсездән бирле инде тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Моның төп сәбәпләре итеп үз вакытында Н. А. Добролюбов түбәндәгеләрне күрсәткән иде: а) ирләр белән күпме генә гомум эшләрне башкармасын, хатын-кызларның үз уйларына күмелергә вакыты кала; б) аларның үзләренә хас эш төрләре дә (туку, чигү, тегү, эрләү, бәйләү һ. б.) шуңа булышлык итә, ягъни чәчү, сугу, уру, урман кисү эшләрендәге кебек түгел,— уйларга, хыялланырга уңайлырак; в) хатын-кызларда хыял итү, теге яки бу вакыйгага теләктәшлек итү ирләргә караганда көчле.[2] Безгә калса, Добролюбовның бу фикере бик урынлы. Чөнки туй йоласы, алда күреп үтүебезчә, үзе үк тоташ диярлек хатын-кызларның актив катнашлыгында үтә. Бигрәк тә кыз елату җырлары үзенчәлекле хатын-кыз иҗаты булып күз алдына баса.

Сыктаулар нигездә лирик поэзия, кеше кичерешләренең иң югары ноктасы. Бу төр поэзия әле XX йөзнең утызынчы елларына кадәр Ык буе районнарында яңгырый. Хәтта кыз үз теләге белән ярәшелгән булса да, үзенең ризасызлыгын, булачак гаиләгә нәфрәтен белдерүне аннан традиция таләп итә. Яраткан кешесенә бирелгән очракта да үз язмышыннан ул ачы зарланырга бурычлы. Чөнки йола шуны куша, әгәр ата йортыннан елап аерылмый икән, димәк, аның ата-анасына, туган йортына хөрмәте юк.

---

[1] Соколов Ю. М. Русский фольклор. М., 1941, 165 б.

[2] Добролюбов Н. А. Полное собрание сочинений. Т. 2. М., 1935, 270—271 бб.

кешеләр алдында ата-анасын кызарта диган сүз. Килен булып төшкәч, чит гаиләгә эләккәч, киресенчә, ул күз яше күрсәтергә тиеш түгел — чөнки яңа гаиләдә үзенә ачу уятуы ихтимал.

Сыктауларны башкаручының иҗат дөньясына үтеп керү кызыклы нәтиҗәләргә китерер иде. Кызганычка каршы, Башкортстан АССР районнарында кыз елату җырларын оста башкаручыларны хәзер очратуы бик авыр. Әмма алар турында хәтерләүчеләр бар. Сыктаучылар күбрәк тол, ятимә, җырга оста хатыннардан сайланган. Акчалата яки әйберләтә бүләк бәрабәренә алар кыз елату йоласын башкару өчен махсус чакырыла. Кияүгә китәсе кызны бүлмәсеннән башына ак яулык ябып ата-анасы, туганнары көтеп утырган бүлмәгә алып чыгалар һәм кыз исеменнән берәмберәм һәркайсысына елап мөрәҗәгать итәләр, зар түгәләр. Башкаручының бурычы — яңа бирелгән кызның бөтен кичерешләрен барлык тулылыгы белән тыңлаучыларга илтеп җиткерүдән тора.

Сыктауларны һәрчак профессиональ осталар тарафыннан гына башкарылган дип уйлау хата булыр иде. Алар чакырылган очракта да кызга үзенә дә күпмедер күләмдә җырлар башкаруны йола, традиция куша. Кыз елату йоласында бернична тапкыр катнашкан һәм үзе дә шактый кызыклы күзәтүләр язып калдырган тикшеренүче М. Акчурина шулай ук моңа игътибар итә.[3] Аерым урыннарда, әйтик, кызлар үз туйларында башкару өчен үсмер чактан ук өйрәнә башлыйлар. Ә ярәшелгәннән соң махсус рәвештә профессиональ, оста кыз елатучылар янына сабакка йөриләр. Ык буенда (Бәләбәй, Шаран, Бакалы районнарында), мәсәлән, аеруча ярлырак гаиләләр, артык чыгым, расход чыгарудан куркып, яки хәле җитмәсә, махсус җырчылар ялламый. Бу йоланы үтәүне кияүгә китүче кызларына йөкләтә торган булганнар.[4]

*Кое суга таш атсаң,*
*Батар китәр, әнкәем.*
*Чит җирләргә кыз сатсаң,*
*Ят итәрләр, әткәем.*
*Минем китәр юлыма*
*Балан утырт, әнкәем.*
*Балан беркөн корыса,*
*Балам, диген, әткәем.*
*Минем китәр юлыма*
*Чаган утырт, әнкәем.*
*Чаган беркөн корыса,*
*Чалдым, диген, әткәем.*
*Туган йортым — бишектә*
*Ризкым кала, әнкәем.*
*Кайнап торган казанга*
*Кызың салаң[5], әткәем.*
*Дус кызларым сораса,*
*Үлде, диген, әнкәем.*
*Агам-җиңгәм сораса,*
*Гүрдә, диген, әткәем.*[6]

Кайсыбер очракларда кыз үзенең яшь, тәҗрибәсез булуын да сылтау итеп куя. Югарыда китерелгән җыр өлгесендә яшь кызны чит-ят гаиләдә көтеп торган шыксыз, рәхимсез тормыш тетрәткеч буяуларда бирелә. Чит-ят гаиләдә хәтта дус кызларың белән дә аралашу мөмкин түгел. Кияүдәге апасы исеменнән җырланган юлларда хәл тагын да ачыграк әйтеп салына:

*Сеңелкәем китәсең чит-ятка,*
*Тамагыңа үтмәс ашларың,*
*Елан телле ерткыч каенанаң*
*Ашар инде синең башларың.*

*Каенатаң булыр мәрхәмәтсез,*
*Каенсеңелләрең — тупаслар,*
*Сеңелкәем, сине — ятимәне —*
*Иркә сүз белән дә уятмаслар.*[7]

Кияүдәге апасының сүзләре ярәшелгән кызга, билгеле инде, тагын да ныграк әрнү, үкенү, көенеч китерә, әтисенең ваемсызлыгы әчен пошыра, йөрәген куыра. Ул әтисенә турыдан-туры үз уйларын әйтүдән дә тартынмый:

*Әтекәемнең өендә*
*Ак тастымал чөендә.*
*Әтекәем ник җыласын,—*
*Себер паласы иңендә.*

---

[3] Акчурина М. Кыз елату.— «Шура», 1911, 20 сан.
[4] Мондый хәлне башка халыкларда да очратырга була. Кара: Лафарг П. Народные свадебные песни и обряды. В сб.: Очерки по истории первобытной культуры. Т. 2. М., 1926.
[5] Салаң — саласың.
[6] Ярмәкәй районы, Иске Турай авылында 1967 елгы экспедиция вакытында Гөлмәдинә Сәмигуллинадан (75 яшь) язып алынды.
[7] Бүздәк районы Күбәк авылында яшәүче Миңнетаҗи Шакирова (1897 елгы) бу юлларның авторына әйтеп 1970 елда яздырды.

Элегрәк, Октябрь революциясенә кадәр Себер сәүдәгәрләренең Уфа губернасына килеп кыз сатып алып китүләрен хәзердә дә Ык буе районнарында яшәүче өлкән буын картлар хәтерли.[8] Әле без китереп үткән җырдагы «себер паласы»ның телгә алынуы шуңа ишарә ясый булса кирәк. Гомумән, кыз елату җырларында ярәшелгән кызның яңа гаиләдә булачак тормышы турында алдан ук хәвефләнүе туй йола поэзиясендә үзенчәлекле пролог ролен үти. Алай гына да түгел, кыз моның социаль сәбәпләрен дә эзли. Ләкин еш кына әле ул үзенең ирексезләп чит-ят җиргә озатылуын әти-әнисеннән, рәхимсез җизнәсеннән, туганнарыннан күрә, яки үзен кодалап, яучылап йөргән димчегә, усал каенанасына сылтый. Андый очракларда кыз елату җырларындагы иҗтимагый мотив та кискенләшә төшә, драматик төс ала:

*Әткәй сукасын сукалый,*
*Сука да сабан сөрә, ди, микән?*
*Әткәй мине саткан чакта*
*Хайван саттым, ди, микән?!*

*Җефәк тә чаршау тасма бау*
*Син кордырттың, җиңгәкәй.*
*Килер дә җаучы китәр иде,—*
*Син бирдерттең, җиңгәкәй![9]*

Бу иҗат төренең үсеш чорын чама белән XIX йөз азакларына һәм XX йөз башларына туры килә дип билгеләргә мөмкин. Туй җырлары гадәттә сыктаулар белән башланып китә. Аннан соң туй көнендә мактау җырлары яңгырый. Дөрес, йоланың туй алды атнасында да күпмедер дәрәҗәдә мактау җырлары ишетелә. Әмма кыз үзенең ярәшелгәнен ишеткәч тә моңлана башлый. Бигрәк тә аклашудан соң (туй көнен билгеләгәннән соң) кыз елату көчәя.

## 3. Ярәшелгәч

Кыз елату җырларында асылда бертөрле мотив — ярәшелгән кызның туып-үскән җире, ахирәтләре, туган-тумачалары, ата-анасы белән аерылышуы, үзенең кияүгә китәсе килмәве, инде мәсьәлә тәмам хәл ителгәч, килен булып төшер алдыннан соңгы саубуллашуы, яңа гаилә (усал каенана, каената һ. б.) алдында куркып калуы тасвирлана. Җырларның берсендә, мәсәлән, кыз үзенең ни өчен киенеп-ясанып торырга тиешлеген бөтенләй аңламавын, әтисенең моны ни өчен кушканын да белмәвен хәбәр итә:

*Әтекәем куша киенергә,*
*Җефәк тасмаң үр, ди инәкәй,*
*Бәйрәм түгел, нинди кунаклар ул,*
*Атлап менеп йөри, инәкәй?*

*Нигә кирәк булдым мин сезгә,*
*Нигә килгән кунаклар безгә?[10]*

Йола ситуациясе кәләшнең психологик хәлен бирү өчен бер чара гына булып тора. Ул әтисенең рәхимсезлегенә аптырый:

*Аршын да аршын ак уканы*
*Аршынламый ничек сата икән?*
*Буйга җиткән үз балакаен*
*Эче ачымый ничек сата икән?!*

Ягъни елау җырларында кыз тормышындагы бу йола аның үз иркеннән башка эшләнгән вакыйга итеп бирелә. Әгәр дә кыз сулыгып-сулыгып, артык та елый икән, аны елаудан туктарга чакыралар, юаталар. Тик карчыклар гына тыелмаска кушалар, чөнки «ата йортында елап бетмәсәң, каената йортында күз-яшь түгәргә туры киләчәк» дигән ышану бар.

Туй көне алдыннан кызны бөтен әйберләре белән ак өй яки келәткә күчерәләр. Бу кызның үз ахирәтләре белән үткәргән соңгы төне, таң атканда, беренче әтәчләр кычкырганда инде ул мәңгегә яшьлеге белән, кыз чагы белән хушлаша. Шуңа күрә ул башта үз ахирәтләренә шушындый җыр белән мөрәҗәгать итә:

[8] Бакалы районы Божыр авылында Яков Алчинов бабай (1898 елгы) безгә хәтта шул хакта аерым тарихи легенда да сөйләде.

[9] Шаран районы Бурсык авылында 1971 елның июлендә Хәдичә әби Муллагалиева (72 яшь) яздырды.

[10] Ярмәкәй районы Тарказы авылында Галимә әби Кадрачевадан (62 яшь) 1967 елгы экспедиция вакытында язып алынды.

*Торыгыз, дусларым, торыгыз,*
*Канатларым минем каерылды.*
*Сизәсезме икән, күрәсезме,*
*Безнең юллар инде аерылды.*[11]

Нәкъ менә шул иртәдә алар таңкучат җыры башкара, кызның әтисенә шунда кыз исеменнән үпкә ява:

*Бикләдегез тимер йозакка,*
*Тимер йозакларны өзәлмим,*
*Тимер йозакларны өзәлмим,*
*Сезне дә күрми түзәлмим.*

Ахирәтләре китәчәк кыздагы бу үкенү тойгысын, кызганыч хәлне тагын да көчәйтеп җибәрәләр:

*Агач та башын яңгыраткан*
*Нинди дә кәккүк баласы?*
*Иртә таңда авыл яңгыраткан*
*Кемнең дә газиз баласы?*

Кыз әтисеннән ул-бу җавап ишетмәсә, тагын да әрнебрәк ахирәтләренә, үзен уратып алган җиңгәләренә мөрәҗәгать итә, зарланып ала:

*Мич асларында таш сандык бар,*
*Ташка ташласам да уалмый.*
*Таш күңел түгелдер бит әткәем,*
*Елап-сыктасам да уянмый.*

Әле ул һаман да нәрсәгәдер өмет итә, «тозактан» ычкынырга юл эзли, һич югында аныңча «язмыштан узмыш юк» икән, үз хәлен аз гына булса да җинеләйтергә тели:

*Айлы ла яулыклар бирдегез,*
*Айсыз яулыклар юкмыни?*
*Каенаналы җиргә бирдегез,*
*Каенанасыз җирләр юкмыни?*

— ди. Ык буе районнарында мондый җырлар күп булган, әмма аларның барысы да нәкъ менә таң әтәчләре кычкырган вакытта башкарылган булуы шикле. Чөнки соңга табарак бер йола вакытында башкарылган иҗат икенче йола вакытында да үтәлә, ягъни сыктаулар үзләренең туй йоласындагы ояларын югалта башлыйлар. Шул ук «таңкучат»ның да соңыннан теләсә кайчан, туй дәвамында, башкарылуы бик ихтимал.

## 4. Кияү мунчасы, килен мунчасы

Татар туй йоласының Ык буе вариантларында мунчага гаять зур роль бирелә. «Кияү мунчасы, килен мунчасы» — йола булып туй уенына береккән. Мунча гигиеник төшенчәне генә үз эченә алмый, аңа магик йола мәгънәсе салына, шунлыктан кияү килер алдыннан ул өч көн буе бикләп тотыла, махсус мунчачы хатын билгеләнә, кызны кияү куенына керер алдыннан мунча кертү, юындыру, чәчен тарату, махсус җырлар башкару һ. б. үткәрелә. Билгеле булганча, бу йола үзенең тамырлары белән тарих төпкеленә сузыла. Ул төрки, шулай ук финн-угор һәм славян халыкларының туй йоласына да ят түгел. Дөрес, бары тик Ык буе районнарында мунчага бәйле туган җырлар булуын хәтерләүчеләр очрамый. Әмма баланы беренче тапкыр мунчада чапканда әйтелә торган арбау-теләк җырларын ахирәтләренең килен булып төшәчәк кызга карап башкаруларын әле дә сөйлиләр. Мәсәлән:

*Атаң кискән утын түгел,*
*Анаң яккан мунча түгел,*
*Минем кулым түгел.*

[11] Кызның яшьлеге белән хушлашу төнендә (русларда да бу йола бар, «девишник» дип атала) яңгыраган таңкучат җырлары барысы да Бакалы районы Балыклы авылында Миңлеҗамал Зиятдиновадан (1898 елгы) язып алынды, 1966 ел.

*Башыңа ширбәт сиптем,*
*Шифалы булсын.*
*Ташыңа сулар салдым,*
*Сихәтле булсын.*
*Аю баласы,*
*Бүре баласы.*[12]

Ни өчен «аю баласы», «бүре баласы»? Баланы беренче тапкыр мунча кертКәндә әйтелә торган бу магик сүзләр туй йоласында да явыз рухлардан саклану, асылда ни барганын алардан яшерү өчен эшләнә. Билгеле, сүзләре беркадәр үзгәрә, йолага яраклаштырыла (кызга ширбәт бөркү килеп керә). Ләкин без бу арбауны «кыз мунчасы» йоласында туган җырлар рәтенә кертсәк, тарихи дөреслеккә хыянәт итү булыр иде.

Сыктаулардагы чынбарлык, реаль картина, кем сыктап-елауга карап, төрлечә бирелә. Мәсәлән, бер үк вакытта башкарылган җырларда кияү (каениш) йорты йә сарайга тиңләнә, икенче карасаң, ул — бөкресе чыккан тавык кетәге сурәтендә күз алдына бастырыла. Яки ата йортында кыз өчен бөтенесе дә асыл:

*Алтын да табак, көмеш кашык,*
*Ашадым ла, әткәй, ашымны,*
*Күршеләргә чыгып киңәш итми*
*Ашадың ла, әткәй, башымны.*[13]

Бер үк текстта фактларның төрлечә бирелүе, билгеле инде, кем тарафыннан әйтелүенә, кешенең психологик хәленә бәйле. Шулай итеп, кыз елату җырларында да поэтик хыял катнаша.

Кыз туып-үскән өеннән аерылып киткәндә әлеге елату җырлары янә көчәя. Бу вакыттагы җырлар да туй алдында башкарылганнарына бик якын тора, шуңа күрә алар бер-берсенең урынын бик иркен алмаштырып йөри. Ләкин инде хәзер яшь хатын кире кайту, йортта калу турында өмет тә итә алмый. Ул бары үзенең яшьлеге узуына үкенә, шул ук вакытта ире йортындагы киләчәк тормышы өчен элеккечә үк борчыла. Мәсәлән:

*Әй, әткәемнең морҗасы*
*Яшел кирпеч белән булсачы.*
*Әй, әткәемнең өеннән*
*Китмәс кенә җола булсачы.*

Ләкин андый «җола» юк. Шуңа күрә ул алдагысын уйлап көенә:

*Чылтыр да чылтыр чын чынаяк,*
*Чылтыратмый ничек юармын.*
*Каенанага ярау авыр диләр,*
*Каенанама ничек чыдармын.*[14]

Өстәвенә, ул инде каенанасы белән таныш, күңелендә тәү күрүдә начар фикер дә туган:

*Арьякта да саз башы,*
*Бирьякта да саз башы.*
*Шунда торган бианамның*
*Аждаһа тел, таз башы.*

Шуңа күрә үзен алдап, кодалап йөргән яучыга кызның нәфрәте тагын да калкып чыга:

*Алда киткән аткаемның*
*Эшлиясе яшел чук.*

---

[12] 1967 елгы экспедиция вакытында Ярмәкәй районы Усман-Ташлы авылында яшәүче Нәфисә Кәлимуллинадан язып алынды.

[13] БДУның татар филологиясе фольклор фонды. Бишбүләк районы дәфтәре. 1968 ел.

[14] Кыз киткәндәге хушлашу җырлары барысы да Туймазы районы Югары Бишенде авылында 1968 елгы фольклор экспедициясе вакытында Шәмсинур Камаевадан (1906 елгы) язып алынды.

*Яучы булган Гарифҗанны,*
*Ходаем, берүк яшен сук.*

Кызның елап әйтер сүзе, зарланыр урыны күп. Ләкин:

*Туганкайларым, сау булыгыз,*
*Атлар җигелгән китәргә.*

Бу да сәбәп түгел, башка олырак, аянычлырак сәбәп тә булуы мөмкин:

*Кушлап-кушлап тагарга*
*Куш төймәкәем юк минем.*
*Кушлап-кушлап сыктарга*
*Үз инәкәем юк минем.*

Әмма барыбер яшь хатын үзенең иң соңгы сүзләрен елап-сыктап әйтергә ашыга. Үз энисе булмаса, этисе, агасы-җиңгәсе бар, аларга эндәшә. Мәсәлән:

*Ата кәккук баласын*
*Атма, эткәй, алам дип.*
*Эткәй, үзең ятка саттың,*
*Әйтмә миңа «балам» дип.*

*Ишегем алды карагай,*
*Караштырып тор, агай,*

*Узган да барган кешедән*
*Сораштырып тор, агай.*

*Ай-һай ла күмәч пешердең,*
*Ыкшындың ла тыкшындың.*
*Бу убыр кайчан китә дип,*
*Син бит, җиңгәм, пошкырдың.*

Шулай итеп, кыз киткәндәге җырлар туйга кадәрге башкарылганнарга тематик яктан охшаш булсалар да, алар яңа үстерелеш табалар, йола барышына яраклаштырылалар. Үз өенә, туган-тумачаларына, атасына никадәр генә үпкәсе зур булмасын, алдагы тормыш китәсе кызга барысыннан да авыррак булып күзаллана. Өстәвенә янә бер аяныч:

*Карлыганнар җыйдым калдырып,*
*Уң беләккәйләремне талдырып.*
*Тиңдәшләрем минем карап кала,*
*Карлыгандай күзләрен талдырып,*

— дип әйтергә мәҗбүр ул.

Себер татарлары арасында киң таралган «Яр-яр әйтүләре»[15] дә шул кыз елату традициясенә барып тоташа булса кирәк. Дөрес, аларда ул туй булып, никах укылгач, кәләшнең чәчен «никах тарагы» белән тарап, ике толымга аерып үргәндә әйтелә торган була. Туй йоласының Ык буе районнары вариантларында исә туй көнендә, никах укылганчы, кәләш үзенең ахирәтләре, җиңгәләр белән «кыз мунчасы» кергән вакытында яки кияү куенына керер алдыннан җырланганын кайсыбер карчыклар әле дә хәтерлиләр. Борынгы язма истәлекләргә караганда («Бүз егет»), «Яр-яр» җырлары — кияү егетләре белән кыз ахирәтләре арасындагы әйтешләр, соңыннан исә яшьләрне мактау җырына әверелә. «Яр-яр»лар аерылу (бу очракта кыз матурлыгыннан — толымны уртага яру) вакытында яңгырый һәм тора-бара кыз елату җырларының эчтәлегенә якыная. Әмма «Яр-яр» җырларында читләтеп әйтү көчле. Егет еш кына кыелып, укталып очкан шоңкар, кәләше былбыл диелә. Шоңкар шул былбыл өчен егылып төшә, былбыл исә чыбылдык эчендә, чыбылдык читлек эчендә итеп бирелә. Күрәсез, нинди көчле поэтик параллель. Кызга ахирәтләре, җиңгәләре шул хәлне тасвирлап бирә. Менә-менә кыз үзенең яшьлеге белән, матурлыгы белән бәхилләшә. Шуңа күрә кыз да елап-сыктап, «яр-яр» әйтеп җавап кайтара:

*Әтекәем өендә*
*Көмешем калды, яр-яр.*
*Ризкым бетми мин китәм,*
*Өлешем калды, яр-яр.*

*Бурлат чаршау, кылыч бау,*
*Ник корасыз, яр-яр?*
*Мине үз арагыздан*
*Ник куасыз, яр-яр.*

[15] «Яр-яр» җырларының берничә варианты басылып та чыкты. Кара: Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. Казан, 1980, 107—112 бб.

*Бурлат чаршау шәүләсе*
*Йөзеңә төшәр, инәкәм.*
*Миңа тиң кошлар күрсәң,*
*Исеңә төшәр, инәкәм.*

*Тарак тешен сындырып*
*Ник тарыйсыз, яр-яр?*
*Бәхетен тапкан былбыл дип,*
*Ник алдыйсыз, яр-яр?*

*Өч аеры чәчбауларым*
*Чөйдә калды, җиңгәләр.*
*Сөймәгәнгә биргәннәрен*
*Сизми калдым, җиңгәләр.*

## 5. Куенга керү алдыннан

Кияүне — кызның әнисе, яки җиңгәсе, киленне — егетнең әнисе яки апа-җиңгәсе теләк сүзләре әйтеп каршылый. Бәләбәй районы Байморза авылы татар-мишәрләрендә «Шәмчырак» һәм «Ачы карәм» җырларын җырлап, кияүне озату йолалары әле кырыгынчы елларга кадәр дәвам итә, ләкин җыр текстлары — мәҗлес җырларында бүген яңгыраган сүзләрдән гыйбарәт. Ягъни йола үзе традиция рәвешендә яши, ә тексты йә онытыла, яки йолачылык эзләрен югалта. Ярмәкәй районы Иске Турай авылында язып алынган «Килен арбау» текстын китерик:

*Казаның өреле булсын,*
*Китмәскә килерең булсын.*
*Чөмергәнең май булсын,*
*Ашаганың бал булсын,*
*Семьяң ишле, бай булсын,*
*Абзарың тулы мал булсын;*
*Күңелең кинә тотмасын,*
*Авызың серкә йотмасын,*
*Сыер-танаң мөңгердәп,*
*Кош-кортларың көңгердәп,*
*Күз ачтырсын, киленем,*
*Көн ачтырсын, киленем,*
*Өлгерем бул, киленем,*
*Арбавым шушы минем.*[16]

Аерым урыннарда «ишек бавы» әйтүчеләрнең кияүдән җыр җырлатуы, кияү егетләреннән табышмак эзләттерүләре билгеле. Мәсәлән, кияү ишек токтасын саклаучы кызларга бүләк — акча өләшеп кергәннән соң, чаршау бавын саклаучы ике җиңгә (бу вакытта кияү егетләре кызның ахирәтләре белән атларда йөрергә чыгып киталәр) кияү җырламый торып, кызны чыгармый, үзен эчкә үткәрми. Мондый йоланы Туймазы районы авылларында әле дә хәтерлиләр. Түбәндә шул җырларның бер өлгесенә күз ташлап карыйк:

*Миннән теләк булсын бүләк,*
*Башыгыз кайгы күрмәсен.*
*Башыгыз кайгылар күрмәсен,*
*Йөзегездә нур сүнмәсен.*

*Ай зиләли, зиләли,*
*Сереӊ булса сөйләли.*

*Эчеңдә кер йөретмә,*
*Ятка сереӊ белгертмә.*

*Арт капканы кем ачкан,*
*Атларым чыгып качкан.*
*Гаеп-кыек юк бит инде,*
*Җиңгәм, чаршавың ачсаң.*

*Ай, зиләли, зиләли...*[17]

Бу йоланы икенче төрле «Зиләли әйттерү» дип тә йөртәләр. Кияү бер үк вакытта сакчы җиңгәләргә һәм чыбылдык эчендә тыңлап утырган кәләшенә багышлап җырлый.

Җиңгәләр һаман да кылыч бауны өзәргә рөхсәт итми, кызны чыгармаса, кияү зуррак бүләк бирә, йомшара башлаганнарын күреп, тагын җырлый:

*Ак куянның баласын,*
*Җибәр кырга, уйнасын,*
*Бер уйнасын, ике уйнасын,*
*Гаепләштин булмасын.*

*Ай, зиләли, зиләли...*

Шуннан соң гына җиңгәләрнең берсе чыбылдык эченнән кызны алып чыга. Соңгы елларда «Зиләли әйттерү»ләрнең безгә берничә вариантын язып алырга туры килде.

[16] Гөлмәдинә Самигуллинадан (Ярмәкәй районы, Иске Турай авылы) 1967 елда язып алынды.

[17] Туймазы районы Үрмәкәй авылында Мәрхүбҗамал Сәлимгәрәевадан (1894 елгы) 1970 елда безнең тарафтан язып алынды.

Хәтта янәшә яшәгән өч төбәктә алар өч төрле исемдә йөри. Туймазы районына караган Арсланбәк авылында Гәүһәр әби Шәрәфетдинова (1892 елгы) «зиләли әйттерүләрне» «кияү ябулар» дип атады һәм, безнең карашка, үтә кызыклы ике үрнәк әйтеп яздырды. Шуларның берсен генә китереп үтик:

*Яман булса — әйт туры,*
*Яхшы булса — әйт туры,*
*Безнең кызый — ил асылы,*
*Кияүкәй, булма угры.*

*Шау макталсын атыгыз,*
*Икәү булып ятыгыз,*
*Икәү булып ятыгыз да,*
*Өчәү булып кайтыгыз.*

Бакалы районының Божыр авылында яшәүче Татьяна әби Мельникова (1894 елгы) да аларны «кияү ябулар» дип атый:

*Кыз күрмәй — бил чишелмәй,*
*Су күрмәй — итек чишелмәй.*
*Кыз келәте тиз ишелмәй,*
*Тиккә коймак тишелмәй.*

*Алаша кибәннән өрекмәс,*
*Кыз кияүдән курыкмас,*
*Икәү булып ятыгыз,*
*Өчәү булып кайтыгыз.*

Кияү ябуларның, күрәсез, текстына әллә ни аңлатма бирү дә соралмый. Егет йола буенча кыз куенына керер алдыннан тун киеп килә, кыз бик нык яшерелгән билбау очын тиз арада табып, егетне чишендерергә тиеш.

«Тиккә коймак тишелмәй» диюләрдә дә зур мәгънә бар. Кызның гаебе ачылса, кияү егет иртәгесен йола коймагының тап уртасына пәке кадап чыгарган һәм шул рәвешчә кыздан баш тарткан. Җиңгә кеше алдан ук бер дә юкка кызны мыскыл итмәскә, кияүне кешелекле булырга чакыра.

Туй җырларының иң зур өлешен кода-кодачалар белән җиңги-кодалар (кыз ягы) арасындагы кара-каршы әйтешләр алып тора. Ык буе районнарында язып алынган йөзләрчә туй җырларында яңа тормыш юлына аяк басучы ике яшь кешенең язмышы турында гына түгел, бәлки, гомумән, тормыш, яшәү, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр киң яктырту таба. Кодалар капкадан килеп керү белән җыр башлана һәм алар киткәндә дә җыр авыл өстендә яңгырап кала. Бигрәк тә бүләк бирешү, кыз бирнәсен карау, мәһәр әйберләр элү (кияү йортында ул кабатлана) йолалары вакытында, туй мәҗлесендә җыр, әйтеш, мактау, тапкыр сүз өзелми.

Бүләк багу җырларыннан бер мисал (кияү өендә кыз әйберләрен элгәндә җиңгиләр җырлый):

*Агымнар су буып куйдык акмаска,*
*Канәферләр салып куйдык батмаска,*
*Бу әйберләрне без китерә килдек,*
*Кире әйләнеп лә диеп кайтмаска.*

*Атлар җибәрдек без чабышка,*
*Чабыш аткайлары узсын дип.*
*Бу сөлгеләрне без эләбез*
*Шушы йорткайларда тузсын дип*[18].

Бирнә биргәндә кыз әнисе җырлап бии, башкалар кул чаба. Мәсәлән:

*Бирнә, бирнә бирик тә,*
*Бирнә бирел бииек лә.*

Аңа кодача кушыла. Кыз әнисе аңа эндәшә:

*Бирнә, бирнә бирермен,*
*Бирнә кигәч биерсең.*
*Кигән бирнәгә каршы*
*Инде ниләр бирерсең.*

*Сыер бирсәң — аеры тояк,*
*Ат бирсәң — йомры тояк*[19].

Күрәсез, бирнәгә каршы бүләк бирү йоласы барлыгына җыр үзе үк ишарә ясый. Бүләк алышканнан соң, бер-берсен макташулар китә. Мәсәлән:

*Кодачаның колагында*
*Һай, алтын алкасы бар.*
*Кодачаның бите кояш,*
*Ай гына калкасы бар.*

*Гел җил көнне җәйгән җитенемне*
*Спас көнне җыеп талкыдым.*
*Агарыплай килгән сакалың,*
*Миллион сумлык синең акылың.*

---

[18] 1966 елгы фольклор экспедициясе вакытында Бакалы районы Акман авылында яшәүче Дарья Максимовадан (1908 елгы) язып алынды.

[19] Бирнә карау, бүләк бирешү һәм башка алга табан китерелгән туй җырлары Бакалы районы Божыр, Акман, Балыклы авылларында 1966 елда язып алынды.

Кызны какмый-сукмый, кадерләп тотуны үтенеп җырлаулар да онытылмый:

*Өй артындагы бакчаларгай*
*Чыгарып ла киртә тотыгыз,*
*Безнең кызларыбыз сезгә бара,*
*Какмый-сукмый гына тотыгыз.*

Үзләренә төбәп әйтелгән мондый җырларга каршы кода-кодачалар да җыр белән җавап кайтара:

*Кара сыер мөгезләрен*
*Каерып алырга килдек без.*
*Әнкәсенең газиз бәпкәсен*
*Аерып алырга килдек без.*
*Алырга дигәч алырбыз,*
*Яр куенына салырбыз.*

## 6. Туй арты

Ык буе районнарында туй арты ритуаллары дәвамында да җырлар яңгырый. Яшь кәләш белән таныштыру өчен кияү үзенең дусларын бераздан бит ачу туена җыя. Шуңа кадәр яшь килен кияү йортында шәл (бөркәнчек) ябынып йөри. Кияү егетләреннән шаян сүзгә оста һәм гореф-гадәтне яхшырак белүче бер егет чыбылдык эчендә ак яулык ябынып утырган кәләш янына килә һәм, ак таяк белән йөзен ача-ача, җырлап бии. Туймазы районының Тукмак Каран авылында бу йола җырларын «шәл салдыру»лар дип йөртәләр. Башкортларда ул «бит асыузар» исеме астында билгеле. Каракалпак халкында бит ачу җырлары аеруча киң таралган һәм «бит ашар» дип йөртелә. Ләкин анда бу йола киленне кияү йортына алып керер алдыннан үтәлә һәм профессиональ җырчы тарафыннан башкарыла. «Бит ашар» — яңа төшкән киленгә киңәш-теләк, кияү, каената, каенана, каениш, каенага, каенсеңле һ. б. алдында киленгә үзен ничек тотарга тиешлеге хакында традицион шигъри күрсәтмә ролен үти.

Патриархаль-ыру мөнәсәбәтләренең чагылышы булган бит ачу җырлары Ык буе районнарында XIX йөзнең азакларына, XX йөз башларына үзенең төп мәгънәсен бөтенләй югалта, шуңа күрә бу йола урынын да алмаштыра, туй арты ритуалы сыйфатында яшьләрнең шаян җырына әверелә. Дөрес, магик ышану эзләрен дә күреп була: ак яулык, ак таяк белән эш итү, «ил йоласына» ияреп, йөз ачу туе үткәрү, һәр җыр өчен башкалар акча салу, яшь киленне чыбылдык эченә утырту һ. б. Әмма җыр текстында магия-йола элементларын төсмерләү шактый авыр:

*Мыек борам, үзем көләм,*
*Егет уты ул мин булам.*
*Сылу кәләш алмам димәм,*
*Сәлам, килен, сәлам бирәм!*

*Вәгъдәгә бай, акылга сай,*
*Куштан абыз Котлыбай,*
*Ни бирсәң дә аңа хәрам,*
*Котлыбайга бездән сәлам!*

*Үрдәк кебек ава-түнә,*
*Сакал селкеп дөнья күрә,*
*Акылы юк, киңәше күп,*
*Әй, аксакал Миңнешаһит,*
*Сәлам сиңа, үзем шаһит!*[20]

Күрәсез, бит ачу җырлары төртмә яки хурлау җырларының эчтәлеген үзләштерә, ләкин 20 елларга кадәр күпмедер дәрәҗәдә үзенең самими формасын да саклап килә.

Янә дә Ык буе төбәгендә кияү егетләренең килен төшерү вакытында, юлдагы җырлары хакында да аерым информаторлардан ишетергә мөмкин. Андый җырларның Ярмәкәй районы татарлары арасында да таралуы хакында мәгълүматлар бар. Тик мишәрләрдә ул мәдәк (вәдәк) җыры дип йөртелә.

Туй җырларының тематикасы монда сөйләгәннәр белән генә чикләнми, әлбәттә. Биредә бары аларның төп эчтәлеге турында гына сүз барды.

[20] Туймазы районы Тукмак Каран авылында яшәүче Каррам Яушевтан (73 яшь) язып алынды, 1972 ел.

# ПРОЗА

## Ринат Мөхәммәдиев

# КЕНӘРИ — ЧИТЛЕК КОШЫ

РОМАН

21



Тоташ бәйрәм рухы басыла төште. Ә йокысыз төннәр дәвам итте. Шомлы һәм йончыткыч тынлык биләп ала иде кайчак... Капкаев белән очрашканнан соң, башка берәүгә дә күтәрелеп бәрелмәде Арслан. Детектив китаплардан алган тәҗрибәдән чыгып түгел, Лев Белялович шулай киңәш китте: «Сабыр...— диде.— Кабаланма. Һәр адымыңны күзәтәләр булса кирәк. Сер бирергә ярамый. Ашыкма, ачыкланмый калмас...»

Киеренкелек һәм көтү... Билгесезлек һәм хәвеф көтеп яшәү... Арслан үзенә ясалган һөҗүм тагы кайчан һәм кай тарафтан кабатланыр икән дигән курку белән көтте. Әшнәләренең үзенә мөнәсәбәте беркадәр салкыная төшүне чамалап алган Капкаев та, күрәсең, болай гына калдырмаслар, дигән шөбһә белән яшәде, койрыкларын җыебрак йөрергә омтылды. Асия иренең рәнҗүле сүзләрен, аерылышырга чакырып судтан кәгазь килүен көтте.

Ә Фидаил исә, рәхимлекнең күктән төшмәвенә күнеккән кеше буларак, күтеп вакытын уздырмады. Йокысыз үткән төннең таңыннан ук машинасына утырып, якын танышы янына барып чыкты ул, чара күрергә кереште. Таныш дигәне үзе кебек үк шофер егет иде. Машиналарының марка һәм төсләре бер үк булудан файдаланып, үзара килештеләр дә, вакытлыча, арткы уң як канатларын алыштылар. Шулай итеп, машинада төнге бәрелешнең эзе дә калмады...

Берәве дә: «Булдымы шундый хәл?.. Булса, нигә алай иттең?» — дип сорарга ашыкмады. Шулай да хәрәкәт башланды. Төш җитәр-җитмәс чакта, иң элек, юк сәбәбен бар итеп, үз хуҗасы чыгып әйләнгәләп йөрде машина тирәсендә. Арткы уң як канат турысына җиткәч, туктап торды хәттә. Әмма берни сорашмады... Йомыш төште дигән атлы булып, төш вакытында Капкаевка да барып чыктылар. Чакырганны да көтмичә, үзе килеп чыкты гастроном директоры. Коры исәнләштеләр. Җитәкчеләр арасында җитди сүз буласын тоеп, кибетне урап чыкты Фидаил. Күрсеннәр, тикшерсеннәр...

---

Ахыры. Башы 4 санда.

Никадәрле генә озак булырга тырышмасын, ул чыкканда, Капкаев әле һаман арткы канат тирәсендә бер-бер тамга табу нияте белән кайнаша иде. Фидаилне күргәч кенә торды чүгәләгән җиреннән, уңайсызланды да булса кирәк. Хәйләгә кереште:

— Рессорларың сынмаганмы икән дим... Ай-һай хәтәр кайттың бит син,— дигән булды, кулындагы тузанны каккалап.

— Рессор сындыралар димени...

Капкаевта ул чакта рессор кайгысы идемени соң. Фидаил белмиме?! Кенәриен кочаклаган көйгә йоклап киткәнен белми... Тегесе исә, шәһәргә кергәчтен машинаны туктатып, алга күчеп утырды. «Исергән, дуңгыз,— диде, аңарга ишетелерлек итеп.— Авызыннан селәгәе ага...» Өйләре янына җитеп, төшкән чагында көләч елмаеп Фидаилгә болай диде: «Берни күрмәдем, ишетмәдем һәм берни белмим дә...»

Капкаев иңсәләрен сикертеп куйды, «Бу нинди хәл бу — өнемме, төшемме?..» — дип әйтүе иде булса кирәк.

Ә хуҗасы иркен сулыш алып, Фидаилне мактаган булды:

— Фидаилгә сүз тидерәләрме соң?!. Кем-кем, әмма ул белә машина кадерен!..

Машина кайгысы идемени Фидаилдә... Бөтен өметләре пыяла сыман уалган, челпәрәмә килгән чак бит аның. Бар яшәве, эше — Асия өчен иде бит аның. Инде хәзер ни эшләргә, кем өчен дип яшәргә кала аңарга?! Дөрес, аның улы бар...

Хатынына ул башка һичкайчан «Асия» дип дәшә алмаячак. Аны күрү Фидаилгә шатлык алып килмәс. Күз яшьләрен коеп еласа да, каршысына тезләнеп ялварса да, гафу итә алмас ул аны. Араларында упкын сыман тирән, караңгы баз тора, кеше түгел, кош очып уза алмаслык текә кыя... Һәм нәфрәт. Тоташ нәфрәт...

Ә эш сәгате беттеме, аяклары өйгә тартты. Асияне күрәсе килеп кайтты. Үзен күрү нәфрәттән башка тойгы уятмый иде югыйсә. Ә барыбер сагына...

Асия өчен дә җиңел булмаячак иде ул беренче очрашу. Куркудан түгел, курыкмый иде ул аңардан. Уңайсызлануы да чама белән генә. Чөнки үзен хыянәтче санамый иде ул. Күңеле кушканча яшәгән, җанына газиз кешесенә омтылган гашыйкны ничек хыянәттә гаепләргә мөмкин?! Хисләренә хыянәт итмәде ич ул! Һәркемнең көтеп алган, өлешенә чыккан бер яратуы була. Арслан — шул бердәнбере ич аның. Ничек баш тарта алсын аңардан Асия?!. Ә Фидаил? Ул инде бер тапкыр кичерде Асияне.

Язылышып кайтканнан соң, беренче тәүге кичтә, йокларга яткач, Асия яшермәде, дөресен әйтте Фидаилгә:

— Фидаил...— диде.— Мин сиңа кадәр бер егет белән йөргән идем бит... Мин аңа алдандым,— диде.

Фидаил башта озак кына дәшми торды, аннан соң аның күзләренә карап торды, әйтте:

— Син алдангансың... Тик син мине алдамадың бит, мин сине яратам...— диде.

Әйе, бер тапкыр кичерде инде аны Фидаил...

...Шулай да, әнисенең үгет-нәсихәтләре каршында көчсез калган Асия, никахлашкан ире янына әйләнеп кайтырга мәҗбүр булды. Трамвай тукталышыннан ук ялгыз тәрәзәгә күз төшерде ул. Үзе атлый, ә күзләре — тәрәзәдә. Кайтып җиткәнче, карашы шул сыңар тәрәзәдә булды. Арлы-бирле үтеп торучыларга да күз салмады, хәтта аяк астына карамады, кая басканын белмәде. Дистәләгән-йөзләгән тәрәзәләре белән балкып, яктырып торган ыгы-зыгылы, мәшәкатьле тулай торакның дүртенче катындагы утсыз, караңгы тәрәзәдән күзен алмады.

Әйләнә-тирә күршеләрнең һәммәсе дә өйдә — якты тәрәзәләре әллә кайдан балкып тора. Яңа тормыш корып яши башлаган гаиләләрнең тәрәзәләре шулай якты була һәрчак. Чөнки шул сыңар тәрәзәгә йокы

булмәсе дә, ял булмәсе дә, балаларга дигән һәм аш пешерергә дигән булмәләре дә сыя аларның. Шул ялгыз тәрәзәләргә ир белән хатын мәхәббәте генә түгел, балалар мәшәкате дә сыйган була. Бары шундый кысан булмәләрдә тормыш көтә башлаган парлар гына аңлый булса кирәк чын гаилә бәхетенең ни икәнлеген. Булмәләре кысан, аның каравы күңелләре киң, киләчәк турындагы хыяллары очсыз-кырыйсыз...

Сүнгән өмет сыман караңгылыкка чумган тәрәзә — кара тап ул, кара нокта. Шул ноктаның як-ягында якты нурлар... Ярый әле башкалар белми, сизенми торгандыр ул караңгылыкның хикмәтләрен... Шулай да түзәргә кирәк, тиздән, бик тиздән Асиянең үз тәрәзәләрендә дә ут кабыныр. Әйе, бер түгел, әллә ничәшәр тәрәзәле иркен, матур фатирда яшәрләр алар. Һәм шул фатирның һәммә тәрәзәләрендә дә берьюлы ут кабыныр. Яктырып, балкып торыр аларның тәрәзәләре... Ә әлегә, вертикаль буенча да, горизонталь буенча да, утсыз тәрәзә аларныкы гына.

Ниһаять, ул баскычта. Югары күтәрелә. Дүртенче катка менеп житәр өчен күпме баскыч үтәсе?.. Шушы көнгәчә ул аларның санын да белмәгән. Шул дүртенче катка кош сыман канатларын җилпеп менгән чаклары да бар иде аның. Ә хәзер — балтырларына таш асканнар диярсең. Чөнки ул, киләчәккә түгел, тонык һәм бертөрле булып канына сеңгән үткәненә кайтып килә. Гелгә калырга дип түгел, ара өзәр өчен, бәхетле киләчәгенә узып барышлый гына...

Ишек катына менеп җиткәч, сулышын тыеп, бермәл тынсыз торды. Сак кына сумкасыннан ачкычларын алды. Үч иткәндәй, баскычта караңгылык, лампочка кирәк булган кемгәдер... Йозакны эзләп табарга кирәк, ачкыч тишеген... Биек үкчәләренә басмый гына, эчкә узды. Ишекне япты. Һәм сулыш алырга да уңайсызланып, бераз тын булмәгә колак салып торды. Шул мизгелдә Асияне читтән күзәтеп торучы булса, ул аны, һичшиксез, идән ярыгыннан башын тыгып, өй эчен күзәтеп, чарасыз калган тычкан баласына охшаткан булыр иде. Үткән белән хушлашу, үткәнеңә кире кайтуны җиңел дип кем әйтер?!

Сак кына утны кабызды. Сискәнеп куйды һәм кире сүндерергә ашыкты утны. Өй түрендәге зур караватта ире белән улы дөньяларын онытып йоклап ята. Күзләренә төшкән яктылыктан тынгысызланып, сабыеның кинәт борылганын, әтисенә табарак сыенганын абайлап өлгерде ул. Ананың күңеле талпынып, нечкәреп куйды — күзләренә яшь килде аның. Барып, улының йомшак аркасыннан сыйпыйсы, ачылган өстен ябасы килде. Кыюлыгы җитмәде караватка якын барырга...

Бертын басып торганнан соң, чишенә башлады ипле генә. Дөм сукыр кешедәй бармаклары белән кармалана-кармалана, үзенә кирәкле әйберләрне эзләп тапты. Карыны да ачкан, чәй эчәсе килә... Әмма чәйнеккә үрелү, суыткычны ачып карау уенда да юк. Гүя аны чит фатирга китереп ташлаганнар, ни эшләргә белгәне юк. Шулай да, беркадәр кыюлыгын җыеп, стена буенда торырга тиешле креслоны эзләп китте ул. Кызганыч, бердәнбер кресло буш булып чыкмады, аркасына Фидаил чалбарын элгән, утыргычында сабые киемнәре. Киемнәрне урнаштырырга һәм утырып ял итәргә иде дә бит югыйсә. Кыймады. Әйтерсең, бу булмә эчендә аңарга урын калмаган... Үч иткәндәй, урамда да утлар янмый икән — идәндә бала уенчыклары булуы ихтимал, шуларга китереп басудан уңайсызланды Асия һәм кире чигенде...

Сәер килеп чыга, үз өендә урын юк аңарга. Ятып ял итү, йоклау өчен түгел, барып таянырлык урын калмаган. Бала караватына менеп, дүрткә бөкләнә алмас бит инде.

...Бәлки баланы үз урынына урнаштыру кирәккәндер. Фидаил белән янәшә ятарга... Юк, Асия алай итмәячәк, моңарга хокукы юк аның хәзер. Арсланга да тугрылыклы булу кирәк... Ишек катына чыгып, өстәл астында кармалана торгач, буш табуретка табып алды. Утырды. Һәм борчулы башын өстәл өстенә салды...

Бераз черем итә алдымы, юкмы — төнне ул шул рәвешле уздырды.

Тәрәзә артында аертылган сөт сыман сыек кына яктылык шәйләнә башлагач, каршы як стенадагы фоторәсемнәргә текәлеп утырды. Ул рәсемнәрдә анын үткәне. Ә киләчәге Арсланга бәйләнгән, тулысы белән Арслан кулында. Анын белән яшн башласа, Асиянен моңаерга да арасы калмаячак, менә күрерсез. Шуңа да аны Арслан Сәхипович диләр, олылыйлар, хөрмәт итәләр, аңарга буйсыналар. Чөнки ул көчле һәм гайрәтле. Әнә кемне ярата Асия. Асылынсаң — асылын агачның асылана дип, юкка гына әйтми ул халык. Исеме җисеменә туры килгән чын арыслан бит ул. Асия һәм Арслан... Арслан һәм Асия... Бүгенге хәле нәрсә, ул үтәчәк, онытылачак бик тиздән. Ә киләчәге турында уйлаганда, рәхәт булып китә аңар. Анда Арслан бар!..

«Арслан Сәхипович»,— дип дәште ул аңар күңеленнән. Шаярганда, яратканда һәрчак шулай олылап дәшәчәк ул аңарга. Арслан Сәхипович — нинди яңгырашка ия, үзен күргәнче үк, дәрәҗәле, мәһабәт ир-ат хакында сүз барганлыкны аңларга мөмкин. Арслан Сәхипович...

Асияне татлы уйларыннан бүлеп, шунда, көтмәгәндә, будильник чәрелдәргә кереште. Фидаилгә җан керде: иң элек ул, урыныннан кузгалмый гына, баш очындагы сәгатьнең төймәсенә басты. Аннан җәт кенә идәнгә сикереп төште.

Иренең хәрәкәтләрендәге кискенлекне күреп, Асия дә сискәнеп куйды һәм, ирексездән, аягүрә торып басты. Аны шулай торып басарга ни мәҗбүр иткәнлекне үзе дә аңышмады кебек. Ипле генә атлап, мин монда дигән сыман, бүлмәгә таба узды Асия. Шунда гына киерелә-сузыла күлмәк кияргә азапланган Фидаил анын өйдә булуын абайлап алды. Теге көнне юлда карашлары очрашканнан соң, бу ир белән хатынның беренче күрешүләре иде...

Бермәлгә югалып калдылар. Авызлары ачылса да, сүз чыкмады авызларыннан. Карашлары идәнгә текәлде. Шулай да беренче булып Фидаил дәште. Хатынын өйдә күрү анын өчен шулай ук зур яңалык иде булса кирәк:

— Син өйдәмени?..

— Өйдә...

— Ә кайда?..— дип башлаган соравын тәмамларга уңайсызландымы — ярты юлда җөмлә тәмамлады Фидаил. «Кайда йокладың соң?» — дип әйтү авыр тоелды аңарга. Әмма чын-чынлап Асия турында кайгыртып соравы иде бу анын.

Асия дөрес аңлады. Көтелмәгән кайгыртучанлыктан калтыранып куйды хәтта. Ничек итеп, шулай, кайгыртып сөйләшергә, сорашырга мөмкин булып узган вакыйгалардан соң?!

— Әнә, урындыкта...

— Урындыкта?..

— Сезне уятырга кызгандым...

— Бала урыны буш торган ич...

— Уяныр дидем, кызгандым.

Фидаил кинәт, сөйләшүдән туктап, дәшмәс булды. Нидер хәтерләдеме ул шулчак — үзе генә белә. Караватта сузылып йоклап яткан улына күз салып алды. Гүя, нидер хәтерләп, нәрсәнедер таба алмый изачигә.

Шул хәлендә байтак онытылып торгач, башын күтәрми генә, ишек катына узды ул.

— Шулай итәләрмени инде, Асия? — дигән сүзләр саркылып чыкты анын күңеле түреннән.

Аннан тиз-тиз генә юынып алды, өстенә киенде. Аягүрә генә, чәйнектән салкын чәй агызып эчте һәм, хушлашырга да кыймыйча, өйдән чыгып китте.

«...Шулай итәләрмени инде?...» Үз авызыннан ялгыш чыгып очкан шушы сүзләрдән уңайсызланды булса кирәк ул. Үзе булып, үзе аңламады ул бу сүзләрнең мәгънәсен, әйтерсең анын гаебе бар. Ә Асия ничек

аңларга тиеш ул сүзләрне? Сорау булдымы бу, әллә шелтәләүме?.. Үкенүме, әллә бәгырь ярасыннан саркып чыккан иңрәү авазымы?.. Юк, Асия аңардан моны ишетергә теләмәгән иде. Ир-ат сыман тузынсын, гомерендә бер сүгенсен иде ул һич югында... Идәнгә типсен, өстәл төйсен, урындыкны гына булса да тибеп җибәрсен иде ичмаса. «Шулай итәләрме» имеш, ничек аңларга шуны?!. Ни дигән сүз соң бу? Нигә газаплый инде ул аны, йә?..

22

Тәрәз йөзлекләренә аркылы такта кадакланган өйгә кайтып төште Фидаил. Әнисен югалту хәбәрен хәрби хезмәттә вакытта да авыр кичерде ул. Әмма моны ялгызлыктан, шыр ятимлектән иңрәп калган туган нигездәге тәүге сәгатьләр белән чагыштыру мөмкин идеме икән?.. Әлегәчә ышанмый яшәгән икән ул зур кайгы китергән хәбәргә. Өметләнгән, ышанмаган, үз хәлен бөтен тирәнлеге белән кичерә алмый йөргән.

Капкадан керүгә үк, тәрәздәге аркылы такталарны кубарырга кереште. Имән борысларга үтеп кергән йөз дә иллеле кадаклар, авыр сыкрап, чыелдау авазлары чыгарып елады. Җил капка, ул кайтасын белгән кебек, киерелеп ачылган иде. Хуҗаның кайтып керүен сизенгән сыман, ишегалдыннан көтүе белән кәҗә өере килеп чыкты. Болдыр баскычындагы һәр такта, менә сынам, менә сынам дигән сыман, авыр шыгырдап каршы алды аны. Өй эче — моннан ике ел элек нинди хәлдә калган булса, шул хәлендә. Һәркайда әнисенең эзләре, әнисенең кул җылысы сакланган кебек. Стенадагы кадакларда аның өс киемнәре... Аш-су хәзерләгәндә кия торган ак алъяпкычларына кадәр үз урынында. Өстәлдә — самавыр, мич буенда кисәү агачлары, сәке түрендә кабартып куелган мендәрләр. Түшәм белән тәрәз арасында эленеп торган ап-ак кашагалар... Тартып куелган тәрәзә өлгеләре... Хәтта аралыкны бүлеп торган чаршау да үз урынында... Шул чаршау менә-менә селкенеп куяр да, аның артыннан, онга буялган итәкләрен сыпыра-сыпыра, улы каршына, колачын җәеп, әнисе килеп чыгар төсле. Йөгереп килеп, сак кына улының аркасыннан сөяр. Һәм, кабаланып, тәрәз өлгеләрен ачарга керешер, самавырын күтәреп, өйалдына таба чыгып йөгерер. Тупсага җитәм дигәндә, башын күтәрер һәм, куанычын уртаклашкан сыман, борынгы шәмаилгә күз салып алыр. Ирennәре кыймылдап куяр аның шулчак, белгәннәрен укыр... Ул шәмаилдә ни язылганын белми Фидаил, бормалы-сырмалы гарәп хәрефләрен танымый. Ә әнисе укый иде, яттан белә иде анда язылганны. «Изге сүзләр...» дигәнен дә хәтерли әле...

Өйдә бар нәрсә әнисен хәтерләтә. Аралыктагы чаршау гына, үч иткәндәй, кыймылдамый да кыймылдамый һаман. Өстәлгә һәм бөтен өй эченә җылылык өстәп торган самавыр кайнап чыкмый. Уф, ятимлектән дә авыррак нәрсә юктыр ул дөньяда. Әти-әнисез торып калган сабыйлар бер кызганыч булса, буй җиткергән, чәчләренә чал кергән ир-атлар да авыр кичерә ятимлекне...

Армиядән кайткан көненең икенчесендә, ишекне киереп ачып, Фидаил янына өлкән яшьләрдәге, әмма үтә дә җиңел хәрәкәтле бер ир-ат килеп керде. Бригадир дип таныштырды үзен. Аяк киемен салып тормый гына түргә узды. Килешле итеп папиросын кабызып җибәрде.

— Кем... Фидаил бит әле... Слушай, эшкә чыгарга җыенасыңмы син, юкмы? — диде ул, төтен өрә-өрә. Әйтерсең, кичә генә кайтып төшкән солдат белән түгел, айдан артык гомер җил сугарып йөргән килмешәк белән сөйләшә.

Башта аның кем булуын ачык кына хәтерли алмый торды Фидаил. Таныш та кебек, түгел дә сыман — онытылган.

— Әшсез ята торган чак түгел, слушай,— дип дәвам итте ир-ат.— Бер-бер һөнәрең бармы?

— Шофер.

— Шуфир дисең инде, ә, слушай,— дип, дөнья кендеге сыман уйга калып торды ул бермәл. Чал чигәләрен кашыгандай итте.— Барыгыз да шуфир, тракторист хәзер, едриона...

Менә хәзер таныды. Сүгенеп әйткән беренче сүзеннән үк танып алды үзен Фидаил. Аларның өй түренә үтеп, аягын чалыштырып, хуҗаларча тәмәке тартып утыручы бу адәм әлеге дә баягы шул Куштан Закир булып чыга түгелме соң?!. Үзенә дә аздан гына «Куштан Закир» дип ычкындырмады.

— Закир абый,— диде, тыелып калып. Вакыт теләсә нинди үпкәачуны да тонықландыра икән ул.

— Шул, үзе,— диде ир-ат, үзен танучыга кәефе булып.— Закир абыең булам...

— Теге, авыл советында эшләгән...

— Үзе!

— Пләвәй булып йөргән...

— Слушай, парин, ну хәтер икән үзеңдә!.. Хәзер бригадир икәнемне дә онытма!

Үзенең кем икәнлеген ассызыклап, синең белән артык сөйләшеп торыр ара юк дигән сыман, капылт кына торып басты ул. Авызындагы папиросына төкереп, аны мич алдындагы калайга таба ыргытты. Өстәл каршысына килеп, хуҗаларча тәвәккәллек белән, савыт-саба өстенә капланган шадра тастымалны тартып алды.

— Кая, нәрсә алып кайттың?.. Өеңә кергән кунакны, шулай, буш чыгарып җибәрергә җыенмыйсыңдыр бит, слушай.

— Ни бит... Юк иде, Закир абый,— диде егет уңайсызланып.

— Едриона...— диде теге, бу юлы инде аяк очына гына төкерде.— Әрмиядән буш кул белән кайталармыни?!.

— Соң, чәй эчик булмаса,— дип, әле булса уңайсызлану кичереп торуын дәвам итте Фидаил.

— Чәй...— диде һәм кыргый көлү белән пошкырып куйды бригадир.— Менә сиңа мә, чәй дисең инде ә, едриона?!. Чәй эчкән бар ла ул, дип әйткән ди әнә анда берәү!..

Егетнең дәшәр сүзе калмаган иде. Шунда гына тәмам өметен өзде Куштан Закир һәм янә бер кат идән уртасына лач иттереп төкереп куйды. Як-ягына каранып алды, фуражкасын батырып киде. Күн итекләре белән махсус каты басып, ишеккә юнәлде. Тупсага житкәчтен, шулай да, башын борды:

— Бу нәрсә бу? — дип, бармагын төртте ул баш очында торган шәмаилгә.— Слушай, парин, бу нәрсә?!.

— Шәмаил ич, күрмисеңме? — диде егет сабыр гына.— Әни истәлеге... Изге сүз...

— Ул нинди изге сүз?!. Ул нинди шәмаил ул?!. Слушай, едриона...

Куштан Закир, кулларын болгый-болгый, гел урынсызга сүгенергә, ду куптарырга кереште. Һәм, әллә ни арада, ишек өстендә дистәләгән еллар эленеп торган жиреннән кубарып, шәмаилне идән уртасына тотып атты. Ул да түгел, йөгереп килеп таптарга, тибенергә кереште. Пыяла ватыклары идәнгә чәчелде. Бу йортка мәңге игелек сакчысы буларак хезмәт итәргә тиешле изге язу вак-вак кисәкләргә ертқаланып, ботарлап атылды. Яшел язу кисәкләре тавис кош канатлары сыман талпынып-талпынып куйдылар...

Фидаил өчен башка сыйдыра алмаслык хәл иде бу, ни диярга белми, тораташ сыман катып калды ул бермәлгә.

Ә Куштан тузынды, пыран-заран китерде өй эчен.

— Ну, слушай, едриона, үзең комсомолдыр әле тагы... Замполитларыгызны әйтер идем...

Шунда кинәт әллә нәрсә булды Фидаилгә. Идәндә яткан пыяла ватыклары арасында әнисе иң изге дип санаган нәрсә — шәмаил мәсхә-

рәләнгән. Көн дә иртән торып, шул язу куелган пыяланың тузанын сөртеп йөргән әнисен күз алдына китерде ул... Хәтер томаны артында Юлдашның шәүләсе калкынып куйды... Шушы адәм аркасында авылны ташларга мәҗбүр булган Мәхмүт абыйлары... Тотлыга торган булып калган Илдус...

— Югал... Эзең булмасын! — дип кычкырып җибәрде ул шунда җан авазы белән.— Сиңа әйтәм, Куштан Закир!

Ә тегене куркытырсың, бар, алай гына. Чыгар юл турында уйларга да җыенмый. Күрәсең, үзенә кычкырганга, үзен куганга, гомумән, күнекмәгән. Дистә еллар дәвамына, ни теләсә — шуны эшләгән, бөтен авылга коткы салып торган затны алай гына җиңү мөмкинме соң!.. Авыл кешесе андыйлар белән буялмауны артыграк күрә, ызгыш, талаш, бәхәс — ул әле сәламәт кешеләргә хас күренеш. Моның белән — «Каберең якын булмасын»,— дип теләк теләргә генә кала. Чөнки ул үзенең һәммә этлеген, үзе әйтмешли, «калхуз» яисә «сәвит» исеменнән кыла, яраклаша...

Колак яфраклары шәмәхәләнеп чыкты тегенең, муены кызарып күпте. Күзләре кысылды, иреннәре калтырарга керешге, аскы һәм өске тешләре бер-берсенә бәрелеп шак-шок килә башлады Куштанның.

— Нәрсә, слушай!.. Нәрсә диден, ә, едриона?!.

Үз өстенә тешләрен ыржайтып килгән адәм гомер буе аның канына тоз салып торучы лабаса... Гүя аяк түгел — солдат күн итеге үзеннән-үзе очып кунды Куштанның арт шәрифләренә. Ишек аша, атлап түгел, мәтәлчек атып чыкканын сизми дә калды ул үзенең. Чакырылмаган кунак шул рәвешле урамга ук озатылды. Соңрак, шактый ук кичегеп аңлады Фидаил үзенең ни эшләгәнен. Тизәккә басма — сасысы чыгар, дигәнне онытkан ич!..

Куштан Закир бу юлы да үзе булып калды. Иң әлек, туп-туры медпунктка барып, справка алып кайтты. Һәм районга шалтыратып, милиция чакыртты...

Шулай итеп, хәрби хезмәттән кайткан көненең иртәгесендә аны унбиш тәүлеккә ябып куйдылар... Аның белән генә бетсә, бер хәл. Авылга кайткач, инде ике кыш тимер-томыр арасында ташландык хәлдә тырпаеп торган иске машина бирделәр үзенә. «Ремонтла да йөр, янәсе, һәркем шуннан башлый яшь чагында...»

Нурлы Аланда изгелек теләгән кешеләр күбрәк иде егеткә. Шулар ярдәме белән машинага җан кертте... Ләкин авылга ул кешеләр түгел, бригадир Закир ишеләр хуҗа иде шул: машинасы төзекләнгәч, бензин бирмәделәр. Йөк төясә, үзе йөкче булды. Эш хакы алырга дип барса, алырга акчаң юк, үзең бурычлы, диделәр... Язларын бакча сукаларга ат бирми аптыратты бригадир, такта ярдырыйм, койма тотыйм дисә — пилорамда эшләүчеләр аның белән кул биреп исәнләшергә курыктылар...

Бер кыш түзде Фидаил. Бер яз түзде. Җәйне дә уздырды зур кыенлыклар белән... Чираттагы көзгә кергәч, бер җай табып, ир-атларча сөйләшеп карарга булды үзе белән.

— Закир абый,— диде, ялгыз чагын туры китереп.— Кешечә эшләргә, яшәргә бирәсеңме син ирек, юкмы?!.

— Едриона...— дип сүгенде бригадир.— Шушы яшькә житеп, кул күтәргән кеше юк иде үземә. Тамырыңны корытырмын!.. Һәй, тамырың булса икән...

Тешен кысып гафу сорады Фидаил. Нишләсен, болай яшәү мөмкин түгел.

— Көнбагыш итеп киптерермен, киндер сыман сыгармын, кандала урынына сытармын, едриона!..

— Булган — беткән, бер ирләрчә утырып сөйләшик тә онытыйк, Закир абый,— дип кабатлады егет. Аны гүя ишетмәде. Авылда туган-тумачасыз яшәү җиңел түгел иде аңар болай да.

— Ирләрчәме?!.— дип, теш арасыннан усал көлеп ысылдады Куштан.— Ирләрчә сөйләшәсең килдеме?!. Ирләрчә сөйләшүнең ни икәнлеген

күрсәтермен әле мин сиңа!.. Едриона...

«Каберең якын булмасын үзенә...» дигәннәре шул икән. Сөйләшеп аңлаша алмады Фидаил. Ул арада, егет бер башын кая куярга белмичә икеләнеп йөргән шул көннәрдә, иске председательне башка эшкә күчереп, яңа председатель сайлап куймасыннармы?!. Кемне дисез?.. Куштан Закирның үзен! Колхозчыларның гомуми җыелышында «сайладылар». Куштанның кем икәнлеген беләләр белүен, әмма берәү дә күңелендә булганны ярып әйтә алмады. Кыюлык җитмәде, яшисе бар... Хәер, карышуның мәгънәсезлек икәнлеге дә һәркемгә мәгълүм. Чөнки районнан килгән вәкил тәкъдим иткән кешенең үтми калганы булмагандыр ул еллар тарихында. Дөреслек дип, кемнең сүзле буласы килсен...

Ике-өч көн узды микән, Куштан Закир, хәзер инде председатель Закир, Фидаилне машинадан алып, тирес төяүгә күчерде. Сәбәбен сорарга килгәч, кабинеты түрендә көе генә чыгар юлга күрсәтте җитәкче һәм кисәтте:

— Мин сүземдә торам, монысы башы гына,— диеп кычкырып көлде.

Фидаил шул рәвешле җанына үз булган кырлардан, су буйларыннан аерылырга мәҗбүр булды. Туып-үскән авылы Нурлы Аланны, сабыр холыклы, түзем авылдашларын калдырып, кала юлына барып чыкты... Балачак хыяллары, истәлек һәм хатирәләр белән тулып торган авыл элеккечә үк артышлы сөзәк тау итәгендә боегып утырып калды.

Кая барганын, кая тукталып, беренче кичне үк кайда кунарын да белми чыкты ул кала юлына. Әмма үзенә ышаныч, яшьлек бирешергә юл куймады аңар, дөнья киң икән ул. Ә менә Нурлы Аланны сагыну, кайры астына кереп оялаган корт сыман, берөзлексез кимерәчәк иде әле аны, бу хакта уйлап җиткермәде.

## 23

Иң элек селектор шыгырдавы ишетелеп алды. Бераздан Энзия Закировнаның көр тавышы яңгырады:

— Асия, сине чакыралар... Профсоюз киңәшмәсенә... Хәзер үк...

«Киңәшмә» сүзенә без күнеккән, авторитетлы сүз. Бу юлы да ник берәве шунда шиккә калсын. «Ул нинди киңәшмә икән, профсоюзга Асиянең мөнәсәбәте бармы?» — дип уйларга һичкем базмады. «Киңәшмә» дигәнебез кайчандыр эштән сызу өчен җитәкчегә сылтау булган булса, инде хәзер һәммә хезмәт ияләре оста файдалана аңардан. «Киңәшмә» яисә «утырышка» дисең дә чыгасың да китәсең. Күпләр йөри хәзер киңәшмәгә.

— Кая китеп барыш?

— Киңәшмәгә...

Барысы да аңлашыла, берәү дә кайтарып сорамый. Вәссәлам!

Кайчандыр ир-ат халкы йөри иде киңәшмәгә. Киңәшмә үзе дә ирләр эше буларак кабул ителә торган иде. Инде хатын-кызлар да өйрәнеп җитте. Хатын-кызга хәтта килешәрәк тә төшә башлады әле ул хәзер. Күз һәм ирен тирәләренә каләм-карандаш тидереп ала да, иңсәсенә сумкасын ыргытып, тырт-пырт китеп тә бара. Туктатырга базучы юк, сорау — артык. Аңлашыла ич болай да — киңәшмәгә китеп бара...

Киңәшмәгә дип кузгалган Асияне Арсланның шоферы каршы алды. Болай да күп сүзле егет түгел ул, ә бүген исә телсез калган диярсең. Баш күтәреп исәнләшмәде дә хәтта, ым кагып кына җавап кайтарды... Арткы утыргычның уң почмагына кереп оялаган хатын үз эшләре белән мәшгуль иде. Кулына җыйнак көзге алып, берничә кат каш-иреннәрен хәстәрләп чыкты. Француз хушбуен да ачып-ябарга онытмады. Тарак төшмәде кулыннан...

Телгә әрсез булмаса да, шофер егет тә мулла песие түгел иде, әлбәттә. Үз-үзе белән мавыгып барган хатынга әледән-әле баш очындагы көз-

ге аша күз төшереп алды ул. Хәер, ир-атның сокланып каравы түгел — карамавы гаҗәп тоелыр иде Асиягә. Монысы юл озын булганга һәм сүз уңаена гына, әлбәттә.

Шәһәр читендәге серле ярымутрауда, тимер капка каршысында, Арслан каршы алды Асияне. Бер читтә, таганга атланып, сабыйларча битарафлык белән башын артка ташлап, аякларын болгап утырган Җантимернең аларда уе да юк. Аның аяк очында диярлек, солдат каешы сыман телләрен асылындырып, әлсерәгән овчаркалар ята. Арслан белән Асия чәчәк түтәлләре буйлап түрдәге корылмага үттеләр. Күзләре күреште, карашлары хәл белеште, әмма әлегә бер-беренә сүз катарга кыймадылар.

«Башка берәү дә булмасын иде ярымутрауда,— дип, күңеленнән генә теләк теләп атлады Асия.— Туйганчы сөйләшергә, аңлашырга иде, ниһаять, икәүдән-икәү генә калып...»

— Исәнме, Асенька?!. Килеп тә җиттегезме?!.

Нарат күләгәсендә талчыбыктан үрелгән җиңел креслога җәелеп утырган Лев Белялович авазы икән. Сискәнеп куйды Асия. Хәтта сәламенә җавап кайтарырга да онытты булса кирәк.

— Кил, Асенька, кил, бирегә утырыгыз,— дип урын күрсәтте ул янәшәсендәге буш креслога ишарәләп.— Син, Сәхипович, безгә өстәл хәзерли тор... Кара аны, шәрабең суынган булсын!

Тәкъдим ителгән урынга утырырга гына калган иде Асиягә, баш тартыр өчен сәбәп юк.

— Гөлсинә кайда соң?

Бу очракта Асиянең авызыннан иң элек шундый сорау чыгуы бер дә гаҗәп түгел югыйсә. Әмма җавап бирүче өчен кулай сорау түгел иде ахры. Ирен читләре тартышып куйды карт арысланның, нәрсә дияргә, ничек итеп җавап кайтарырга белми югалып торды ул. Коелып төшә торганнардан түгеллеге дә мәгълүм. Күкрәген киереп, яңа мичтән чыккан түгәрәк күмәч сыман яңаклары белән балкып елмаерга өлгерде. Ихластан елмайганда да сирәк кешеләр генә булдыра алыр алай.

— Гулямы?!. Гуляны син оныт, ярыйммы, Асенька!.. Безнең арада ул очраклы кенәри иде.

— Ялгыз килдегезме? — диде хатын сәерсенеп.

— А-а-асенька!.. Оҗмах бакчасына ялгыз киләләрме?!. Син минем хакта яхшы уйламыйсың, Асенька!

— Гөлсинә юк дисез ич...

— Гөлсинә юк, ә кенәри — бар!.. Кызык бит ә, Асенька?..

— Шаяртасыз һаман...— Чын-чынлап төшенә алмый иде Асия.

— Күл читендә... коеналар,— дип, шул тарафка ым кагып алды Лев Белялович.— Шулай да Гуляны оныт син, ярыйммы... Кенәри түгел, саз чыпчыгы иде ул Гуля. Аңлашылдымы, Асенька?!.

Арслан күренми иде әлегә. «Түгәрәк»нең соңгы сүзләреннән Асиянең кәеф кырыла төште. «Саз чыпчыгы» ди бит әнә, күзен дә йоммый. Кайчандыр үзең кочаклаган-үпкән хатын-кыз турында ничек итеп шундый сүз сөйләргә мөмкин?!. Аерылышкан, ташлашкан очракта да ир-ат булып кала белергә кирәктер ич... Хәер, ир-ат халкы ул хакта уйланмый да бугай инде хәзер.

— Йә, Асенька, үзең ничек яшисең?.. Нинди яңалыкларың бар? — дип, өр-яңадан сүз башларга ашыкты «Түгәрәк». Күренеп тора: аны бу сорау түгел, башка нәрсә кызыксындыра. Монысы болай, кереш сүз урынына гына...

— Рәхмәт, Лев Белялович! Барысы да яхшы...

— Ялгышмасам, сез тормышта бугай, шулаймы, Асенька? — дип сорады кинәт. Утырган җирендә борсаланып куйды. Күренеп тора: бу сорауга биреләчәк җавап аның өчен күпкә әһәмиятлерәк.

— Бу шулай әһәмиятлеме? — дип, үз чиратында Асия дә көязләнеп алырга булды.

— Әһәмиятле, Асенька.

— Мин тормышта, Лев Белялович.

— Ирегез кем булып эшли? — Бераз тукталып алды ул һәм җавап көтү озаккарак сузылгач, өстәп куйды.— Сер булмаса, әлбәттә... Хатын-кызның сере дә булуы ихтимал бит әле...

Билгеле, юкка кызыксынмый ул аның ире белән — шундук төшенде Асия. Һәм икеләнеп калды. Арслан булып Арсланның аның ире хакында кызыксынганы юк, моңарга нигә кирәге чыкты соң әле Фидаилнең? Ике уйлап тормады, ялганларга кирәк тапты Асия. Нигә шулай эшләгәнен үзе дә абайламый калды:

— Инженер ул.

— Нинди инженер?

Инженерның ниндиләре булуы хакында уйлаганы юк иде Асиянең, теленә килгән беренче гыйбарәне әйтеп салды:

— Баш инженер.

— Кайда?

— Бер заводта шунда...

Асия гамьсез генә җавап кайтарып торды аның сорауларына, гүя бу хакта сөйләшүнең бер дә кызыгы юк аның өчен. Ә «Түгәрәк» әрсезләнүен дәвам итте.

— Кайсы завод икәнлеген әйтмисезме? Сер түгелдер ич?..

— Ә сер булса?!.

— Шулай да?..

— Шәһәрдәге барлык заводларны, алардагы инженерларны беләсезме?

— Барысын да белмәсәм дә, баш инженерларны беләм дип уйлыйм...

— Кайдан беләсез, сер түгелдер ич? — дип, чаяланган атлы булып, үз соравы белән төшәргә булды ул аның җелегенә.

«Түгәрәк» төртелеп калды. Үзенең эш урыны һәм кем булуы хакында кенәриләрен адаштырып йөртә иде ул һәрчак. Дус-ишләренә дә бу хакта информация чыгаруны катгый тыя килде.

— Ну-у, беләм инде... Белергә туры килә.

— Эшегез буенчамы?

— Ну-у-у, ничек дип әйтергә... Ярый, шулай да булсын ди...

— Әйтегез әле, Лев Белялович, сез кайда эшлисез соң?.. Нигә монда һәммәсе дә сезнең алда бармак очларына басып йөри?..

— Сер дип, сер түгел, Асенька... Ну-у-у, ничек дип әйтергә, аңлатырга икән соң сиңа?..— Төгәл җаваптан качу җаен эзләргә кереште ул, боргалану-сыргалану артына яшеренеп, вакытны сузарга итте. Урыныннан торып, өстәл өстендәге кымыз шешәсенә үрелде. Аны кыенлык белән генә ачып, икесенә дә берәр фужер сихәтле эчемлек агызды.— Яратам соң Минзәлә кымызын,— диган булды авызларын чәпелдәтеп.

Ул да түгел — махсус оештырсаң да алай вакытлы килеп чыкмас — күл ягыннан чәрелдек аваз ишетелде:

— Лева!.. Левочка, монда кил... Мунчага мин үзем генә кермим, куркам, Лева...

Асиягә таныш булмаган хатын-кыз тавышы иде бу. Әмма сүзләре, әйтелеше булсын — Гуля-Гөлсинәне хәтерләтте.

— Иркенләп сөйләшергә дә бирмиләр,— диган булып, борын астыннан мыгырдана-мыгырдана, шул тарафка китеп барды Лев Белялович. Бармый калсаң да яхшы түгел, янәсе...

Асия ялгызы калды: «Аның ире белән кызыксыналар... Очраклы кызыксынуга охшамаган бу! Теге төннең фаҗигале вакыйгасын ачыкларга җыеналар. Ачыкласыннар, ачыклау — ирләр эше. Әмма Асия үзе башлап сатачак түгел Фидаилне.

Шикләнү һәм гөманлаулары урынлы иде Асиянең. Юлдагы хәвеф, Арсланны шомландырган кебек үк, Лев Беляловичны да пошаманга сал-

ган иде. Бер карасаң, бары да гади кебек кенә дә бит, шаһитләрнең төрлечә сөйләве бик сәер. Әйтик, ни өчен Капкаевлар утырып кайткан машинада тырнак эзе дә күренми?.. Икенчедән, Капкаевның кенәрие Юлия бернинди дә андый хәл булмады дип раслый. Капкаев төрлечә сөйли, икеләнә, ачык кына берни белми. Шоферы да башын тилегә салгандай тота үзен. Әллә соң чынлап та башка бер-бер машина белән бутадыларммы?.. Алай дияр идең, Арслан һәм аның шоферы — икесе дә аермачык күргәннәр...

Нәрсә уйларга, кемгә ышанырга белмәссең — Лев Белялович шундый хәлдә торып калган иде. Асиянең ире хакындагы әңгәмәдә шулай ук файдалы бер-бер яңа сүз күренми. Зур заводта эшләүче инженерның аларга ни мөнәсәбәте булсын?! Ә шулай да юлдагы хәвеф — уйдырма түгел, ул үз күзләре белән күрде ич аларның машинасын... Ярар, Капкаевлар исерек тә булсын ди, шоферлары гомумән сала торган егет түгел диләр. Авылдан килеп, кайдадыр, тулай торакта көн күрүче шофер егетнең алар даирәсендәге арыслан һәм кенәриләргә ни мөнәсәбәте булсын, ул — башка дөнья кешесе!.. Димәк, нибарысы бер сорауга җавап эзләргә кала: кем кушуы белән?..

Асларына су кергән йомраннар сыман, ары бәрелделәр, бире бәрелделәр арысланнар. Җепнең очы Асиягә килеп тоташкан дип, ник берәве шиккә калсын?!. Асия язылышканнан соң да кыз фамилиясендә калды. Пропискасы әтиләрендә. Арсланга булсын, аның шоферына булсын, ул үзенең тулай торакта яшәве хакында сиздергәне юк...

Бер нәрсәне аңлый алмады Асия: нигә алар Фидаилнең үзе белән ачыктан-ачык сөйләшүдән качалар? Ул бәрдергәнне Арслан аермачык күрде, Юлия белән Капкаев та шунда иде. Туры сорауга Фидаил «юк» дип җавап бирә алмас, алдаша белми ул. Бәрелгән машинада тамга да калырга тиеш бит әле...

Лев Белялович белән Арслан Фидаилне эзләмәделәр. Чөнки ул сөйләшү шактый ук җитди нәтиҗәләргә китереп чыгарырга мөмкин. Фаш ителүгә кадәр! Фидаил күпне белә, аны куркытып та, юлдан алып атып та булмый инде хәзер — соң. Аның артында җитди һәм нык терәк бар, һәрхәлдә, булырга охшаган...

Арслан үзенең күңелендә тырмашкан шик-шөбһәләрен бүлешмәде Асия белән. Гомумән, кенәриләр сер сыйдырмый, дигән канун белән яши иде ул. Бәлки, хаклы да булгандыр. Әмма Асия, аның соравына җавап бирергә туры килсә, ялган сөйли алмаган булыр иде. Кызыксынмады Арслан.

Учактагы күмер сүрәнләнде, шампан шешәләре койма читендәге куаклыкка тәгәрәде. Ниһаять, алар тагы икәүдән-икәү генә... Тәрәзә артында кошлар сайрады. Чикерткә авазы тынып тормады. Әледән-әле күлгә төшкән үрдәкләрнең канат какканы, бакалар хәбәрләшкән аваз кабатланып торды. Ачык тәрәзәдән бөркелеп кергән җиләс урман һавасы, коры ылыс исе бер-берсен сагынышкан ир белән хатынның җаннарын иркәләде. Асиянең тел очында борчу, билгесезлек һәм бетмәс-төкәнмәс сораулар — уңайлырак очрак эзли. Арслан үзе сүз башламасмы шул хакта дип өмет итә. Ә санаулы сәгать һәм минутлар берөзлексез алга йөгерә, көтми...

Аның аша үрелеп, өстәл өстендәге сәгатен алды Арслан. Озак кына, ай нурларына куеп, вакытны ачыклады.

— Кузгала башларга да вакыт, җаный,— дигән сүзләре яшен ташы суккандай тәэсир итте Асиягә.

Ярый әле бүлмә караңгы, аның йөзенә чыккан үзгәрешне ярый әле Арслан күрми. Кай арада үткән ул вакыт?..

— Тагы берни сөйләшә алмадык...

— Сөйләшергә түгел, сөешергә килдек, җаный.

— Аңлашырга иде бит, Арслан. Миңа авыр, бик тә авыр болай яшәргә...

— Сиңа ни җитмәгән тагы?!.

— Беләсең...

— Ә син уйлама ул хакта,— диде ир-ат. Асиягә дә юлдагы хәвефкә бәйле вакыйгалар тынгылык бирми торгандыр дигән нәтиҗәгә килеп.

— Уйламыйча булмый, Арслан. Туйдым мин болай яшәүдән...

— Ничек?!. Миннән туйдым дисеңме?!.

Асияне аңламавы түгел, туры җаваптан, җитди сөйләшүдән тайчануы иде бу аның. Башны җүләргә салу кебегрәк...

— Түгел,— диде, күңелендәге хисләр, тел очында торган сүзләренә буылып, чарасыз калган хатын. Үзенең аңлаешлы итеп сөйли алмавыннан уңайсызлана иде ул. Гафу үтенгән сыман, Арсланга сыенды.— Син мине аңламадың, Арслан... Юк, дөресрәге, мин сиңа аңлата алмадым: менә шушылай аерым-аерым яшәүдән туйдым мин... Урлап кына очрашулардан туйдым.

Асия яныннан шома балык кебек кенә шуып, торып басты Арслан. Тирән уйга бирелгән атлы булып, чалбарын киде, күлмәген өстенә салды...

— Алай дисең икән... Куркыта яздың бит...

Хатын дәшмәде, шундый җитди сүзне шушы сәгатькә калдырганы өчен үз-үзен битәрләде... Арслан галстугын буды, кулына сәгатен тагарга да онытмады. Байтак кына ара кием-салым кыштырдаган аваздан башка берни ишетелмәде.

Шулай да өметен өзмәгән иде әле хатын, Арсланнан җанына тынычлык китерергә тиешле сүз көтте.

Көттереп кенә булса да дәште Арслан, барып ишекне ачты:

— Җантимер көттергәнне яратмый, Асия, тизрәк бул!..

## 24

Шәһәргә якынлашкан саен, Асиянең борчу һәм икеләнүләре арта барды: «Кая кайтып керергә? Ни йөзең белән кайтып керергә кирәк? Төн уртасы узды ич инде...» Нигәдер, соңгы арада уңайсызлану, читенсенү кебек, үзе өчен кайчандыр чит булган тойгылар били торган булып китте аны. Йомшарды ул, бирешле...

Әниләре яшәгән йортка йөз илле-ике йөз метрлар чамасы кала, урам чатында туктады машина. Күңдезләрен, иртә-кичләрен ыгы-зыгы килеп торган урам гүя йокыга талган, бер хәрәкәт юк. Аның бу машинадан чыгасы килми, Арслан янәшәсендә утырып кайту гына да рәхәт иде бит. Шофер дәшми дәшүен, әмма ул аның чыкканын көтә... Арслан, аның белән янәшәдә утырган җирендә, башын артка ташлап йокыга талган. Хәтта, очраклы рәвештә генәме, ни сәбәпледер, моторын да сүндергән иде шофер?.. Тынлык... Ул тынлыкны, әлбәттә, Асия өзәргә тиешле. Хушлашырга һәм ишек тоткасына үрелергә, чыгып китәргә кирәк аңар хәзер. Әмма кая, кем янына?.. Кем көтә икән аны шушы сәгатьтә?!. Кымшанасы килми хәтта... Әниләре аны — үз гаиләсендә, ә Фидаил — әниләрендә дип уйлый торгандыр. Ә ул — урам чатында. Үзенең бердәнберен ташлап, хәзер, менә шушы минутта ук чыгып китәргә тиеш ул машинадан. Аның чыгып китүен көтәләр... Шоферның да көткән кешесе бардыр... Арслан Сәхиповичның да үз гаиләсе...

Асия үзен ишек тоткасына үрелергә мәҗбүр итте. Аның бармаклары кагылганны гына көтеп торган сыман, ишек шартлап ачылды — төнге тынлык таралды. Уятмадыммы дигән шик белән Арсланга күз төшереп алды хатын. Уянмады...

Тротуарда берьялгызы торып калды Асия. Ә машина, аның Арсланы белән бергә, борылыштан кереп, күздән югалды. Кул болгаучы да булмады Асиягә. Төнге шәһәр уртасында шулай берьялгызың торып калу читен һәм куркыныч та икән бераз...

Ә каршыда — туып-үскән йорт, таныш тәрәзәләр. Һәммәсе төнге йокыга, караңгылыкка чумган... Тик бер тәрәзәдә ут бар. Чү, ялгыз тәрәзәдәге яктылык аның күңеленә өмет чаткысы китерә түгелме соң?.. Сания апа тәрәзәсе ич бу! Менә ничек әйбәт, димәк, ул йокламый. Шул яктылыкка таба очкан күбәләк сыман талпынып үк куйды ул хәтта.

Ишек туткасына чиертүгә үк йөгереп килеп житте Сания апа:

— Кем анда?

— Бу мин, Асия,— дип пышылдады хатын.

Ишек ачылды. Тупсага абынып сөрлеккән кешедәй, туктап калды Асия. Елаудан күзләре шешенеп беткән, чигәләренә чал төшкән Сания апасын танымый торды бер мәл. Һәрчак пөхтә, һәрчакта да күләчлеге белән үзенә тартып торган Сания апамы соң бу?!. Халат төймәләре ялгыш сәдәпләнгән, чәчләре тәртипсез тузгыган, уч төбенә юеш кулъяулык кысып йомарлаган.

— Әй, Асия-җаным,— дип, ишек катында югалып калган кунагының күкрәгенә килеп капланды Сания апа.— Алай да син бар... Алай да син бар әле хәлемне белергә...

Ни дияргә белми сагаеп калды Асия: «Бусы нәрсә дигән сүз тагы?!. Хәл белергә дип түгел, кунарга урын эзләп керде ич ул монда».

Сания апа аның саен бер башын, җанын кая куярга белми, аңарга сыена:

— Улы-ы-ым... Улым-бәгъремне нишләткәннәр бит!..

Юк, сорау түгел иде бу — сыкрап өзгәләнгән җан авазы. Үзен тыеп, тавыш чыгармыйча, иңле генә сулкылдап еларга керешге Сания апа. Асия аны тынычландырырга тырышты, үз борчулары икенче планга күчеп торды. Сания апасы юкка гына болай коелып төшә торганнардан түгел, авызы тулы кан булганда да төкерми торган хатын диләр андыйларны — зур кайгы килгән аңарга.

...Кухняга уздылар. Өстәл өстендә ачык хат. Конверты тәртипсез рәвештә ертылган. Башы белән ымлап, шул хатка күрсәтте Сания апа, укы, диюе иде бу аның.

— Әй, Асия-җаным, улымны — төпчегемне нишләткәннәр,— дип кабатлады янә, сабыр гына күзләрен, борыннарын сөртә-сөртә.— Улым...

Өстәл өстеннән шудырып, сак кына хатны үзенә таба тартты Асия. Күкрәк дәфтәреннән ертып алынган куш биткә язылган кыска гына хат иде бу. Рус телендә язылган. Сания апаның уллары, ике телне дә бер дәрәҗәдә яхшы белгәнгә, әниләре белән ана телендә сөйләшеп, ана телендә хат алышалар... Димәк, хатны башка кеше язган булып чыга, күңеленә шом керде Асиянең.

«Исәннәрмесез, Сания апа!

Бу хатны Сезгә Равилнең дусты Володя яза. Безнең бергә төшкән фоторәсемне Равил Сезгә җибәргән иде, хәтерлисездер?!. Миңа бу хатны язу бик тә кыен, әмма язмыйча да кала алмыйм. Равил белән шулай килешкән идек... Үзебезнең әниләр турында бик еш искә ала, сөйләшә идек без. Аның да әтисе юк, мин дә әни белән генә...

Кыскасы, болай булды: без кышлактагы әфган авылына азык-төлек, кием-салым илтә идек. Бер тарлавыкта безнең эшелонга дошманнар һөҗүм итте... Котылып та кала алган булыр иде Равил... Әмма ул, үз иптәшләренең гомерен саклап, төп ударны үзенә алды... Сез чын герой, ышанычлы иптәш үстергәнсез, Сания апа... Исән-сау кайта алсам, үз әниемне кайтып күргәнчегә кадәр, иң элек мин Сезнең янга керер идем... Нинди кеше, нинди ана үстергән икән Равилне...»

Хатның соңгы сүзләрен укый алмады Асия. Күз яшьләренә буылып, янә Сания апа килеп капланды аның кочагына.

— Әй, Асия-җаным, ничек күтәрергә... ничек күтәрергә миңа бу кайгыны?!. Әй, Асия-җаным...— дип, сулкылдый-сулкылдый елады ана.

Ни диярга, нинди сүзләр әйтеп юатырга, үзен ничек тотарга белми аптырады Асия. Бөтенләй чит, үенә дә кереп карамаган хәлләр, вакый-

галар һәм кара кайгы бар икән бит әле бу дөньяда... Туган-үскән якларыннан еракта башларын салган, еллар дәвамына ут эчендә йөргән егетләр бар икән... Ул хакта ишеткәне булса да, күз алдына китерә алмый иде ул аларны. Кайдадыр читтә һәм кемнәрдер... дип кенә абстракт фикер йөртергә күнегүчеләрнең берсе иде ул.

Сугышның бит һичкайчан туктап торганы юк. Кешеләр сугыша, яшүсмерләр дөмбәсләшә, илләр чәкәләшә — сугыш, ызгыш-талаш берөзлексез дәвам итә кеше булган җирдә. Кайчандыр ул да сугыш турындагы китапларны укырга ярата торган иде. Кино һәм телевизор экраннарында да сугыш күренешләре калыкканда, кызыксыну белән карый... «Ни җитми бу кешегә, берөзлексез сугыш дәвам итә?» — дип уйга калган чаклары да бар иде «Вакыт» программасыннан чираттагы көн вакыйгаларын карагач. Әмма бераздан алар онытыла, сугыш хакындагы сүз дә онытыла. Чөнки ул сугышлар чит дәүләттә, ерак төбәкләрдә бара... Нишлисең, булмасалар, бар кешеләр дә тату гына яшәсәләр, бер-мә-бер яхшы булыр иде дә бит... Сугышалар шул, әнә...

Асия кебек шул рәвешле фикер йөртүчеләр аз түгелдер ул. Әйтик, Арсланның да ул сугышлар хакында сүз кузгатканы юк әлегәчә. Лев Беляловичның да күңелен башка уйлар борчый. Капкаев ише башка арыслан һәм кенәриләр өчен дә әллә бар, әллә юк ул сугыш дигәнең...

Әфганстан — авыр яра. Чөнки анда кемнәрнеңдер улы, кемнәрнеңдер туганы бар диләр. Ә кайберәүләргә ул сугышның бары ни дә югы ни. Күнектеләр Әфганстанга да...

Сания апасының кече улы шунда хезмәт иткәнлекне белә иде бит югыйсә Асия дә. «Исәнлеге ничек, хаты киләме?» дип тә кызыксынганы булмады шушы көнгәчә... Сания апасы да урынлы-урынсызга сүз кузгатмый торган иде. Дөрес, аның күңелендә нинди уй-шик һәм курку булганлыкны каян беләсең?!.

Үзе берөзлексез Сания апасын тынычландырды... Ә күз алдына әле берничә сәгать элек кенә урман аланында, күл буенда булып узган вакыйгалар килеп аптыратты:

— Дөнья безнең өчен — арысланнар һәм кенәриләр өчен, сөю-сөелү өчен яратылган ул... Күтәрик булмаса,— дип аваз сала әнә Лев Беляловnatural. Аның ике улы бар, икесе дә университетның юридик факультетында укыйлар.

— Лева, Левочка... — дип, муенына өр-яңа кенәрие сарылган. Яшь, чибәр кенәри. Бәлки, бүген Әфганстанда ут эчендә йөргән бер-бер солдат егет, төн йокыларын йокламыйча, шул кыз хакында уйлап, хыялланып ята торгандыр әле.

Дөнья... Кемнәре генә һәм нинди каршылыклары юк аның.

— Белялыч тәкъдиме өчен... Лев Белялович исәнлеге өчен,— ди-ди тостлар күтәрәләр.

Ул да түгел, Капкаев җырлап җибәрә:

Барган идем Әсмаларга,
Кер чайкый басмаларда.
Барыбер сөям шул Әсманы,
Колактан ассалар да...

Асиянең ничек атлап килүенә сокланып карап торган Арслан шәраб тулы бокал тоттыра аңарга. Бер адым артка чигенеп, күзләрен майландырып ала янәдән, соклануын яшерә алмый, шигырь сөйли:

Тез өстенә тезен куйган,
Алып булмый күзне шуннан...

— Дөнья безнең өчен, арысланнар һәм кенәриләр... Артына тибеп яшибез ич, ә, Капкаев?..

— Сүзегез китап кебек, Белялыч, ха-ха-ха!..

— Ну-у, Капкаев!.. Кара аны, Капкаев...

— Шаярма, чама белү кирәк, Капкаев,— ди берәү. Арслан тавышы.— Муеныңны сындырырсың.

— Арысланнар муен сындырышмый, Сәхипыч... Шеф үзе әйтте ич... Монда һәммәбез дә тигез, монда — арысланнар һәм кенәриләр генә...

— Тигезлек — сүз, әмма башны да ия белү кирәк, Капкаев!..

— Житәр әле, бәхәс куертмагыз, арысланнар... Дөнья безнеке ич, күтәрик, булмаса!

— Ну-у, Лева... Лева дөрес әйтә, күтәрик...

— Күтәрик!..

...Сания апа таңгача үрсәләнеп, бәргәләнеп чыкты Асиянең күз алдында. Азга гына тынычлана икән дисә, «улы-ы-ым!..» дип, кабат сикереп торды, кабат өзгәләнде, кабат сулкылдады...

## 25

Фидаил белән башта, урап-читләп, йомшак кына сөйләшеп карадылар. Барып чыкмады. Инсәләрен генә сикертеп җавап кайтарды ул, белмим, янәсе, ни хакында сөйлисез соң сез, берни аңлый алмыйм... «Арысланнар өере»нең ни рәвешле тынгысызлануын, үзләрен борчыган сорауга ачык кына җавап таба алмый ыгы-зыгы килүен күреп торды ул. Шуңа ачыктан-ачык сөйләшергә кирәктер, бәлки, дигән икеләнүеннән кире кайтты. Бер җанына кереп тулган үч катыш гарьлек, ачу катыш кимсенүләр аңар ихтыяр көче өстәде. Үз-үзенең мәрхәмәтсезләнә баруын, хисләренең ташка әверелүен тоеп яшәде ул.

Көннәрдән бер көнне хуҗасы белән ике арада җитди сөйләшү булды. Шоферына, гомер булмаганча, сөзеп карады хуҗа:

— Йә, Фидаил,— диде.— Дөресен сөйлә әле, ниләр майтардың син анда?..

Хуҗасыннан яшертен сере булганы юк иде Фидаилнең әлегәчә. Үз чиратында, хуҗаның да бары ул гына белгән серләре аз түгел... Шулай да сорау тәгаен иде бит, җавапсыз калып булмый.

— Ялганламыйм,— диде Фидаил бертын уйга калып торгач.— Сөйли дә алмыйм.

— Болай булмый, Фидаил,— дип, йөзен чытты хуҗа кеше.— Мин сиңа ышана идем. Үтенечләреңне кире какканым юк... Ә син, пнимаешь ли, анда әллә ниткән мөгезләр чыгарып йөрисең икән...

«Мөгезләр...» сүзен ишеткәч тә сискәнеп, калтыранып куйды Фидаил. Әйтерсең, кинәя белән үзен үчекләп әйтелгән, мыскыл иткән гыйбарә иде бу. Ир-ат өчен шуннан да авыр, мәсхәрәлерәк тагы нинди газап уйлап табарга мөмкин?!. Бәгыренә яткан таш янә югары калыкты.

— Берни дә аңламыйм һәм сөйләшергә дә теләмим бу хакта,— диде ул кырт кисеп.

— Аңлыйсың!.. Син мине яхшы аңлыйсың,— дип, кызарып-бүртенеп, Фидаилгә текәлде хуҗа тиешле кеше.— Ә менә мин сине чын-чынлап аңламыйм, пнимаешь ли... Нәрсә уйлап, кемгә аркаланып шулай тиләрәсең син?!. Соң чиктә, син минем шоферыммы, түгелме?!. Шушыннан соң ничек ышанырга, янәшәңә утырып йөрергә кирәк, пнимаешь ли?..

Кем белән сөйләшкәнен яхшы белә иде Фидаил. Аның хуҗасы чын-чынлап пошаманга төшкән. Ике сүзнең берендә «пнимаешь ли» дип сөйләшә башлаган икән, бу инде аның дулкынлануы дигән сүз. Шаярып сөйләшә торган гадәте юк аның...

Әмма Фидаилнең үз хәле хәл. Үз авызың белән ничек сөйләргә мөмкин хатын хыянәте хакында!.. Вәгъдә ителгән фатирга кызыгып, чәч белән урам себерә, кеше көлкесенә, адәм мәсхәрәсенә кала алмый ич инде... Соң чиктә, ул фатирның кирәге бармы аның өчен хәзер?!. Хикмәт

хужада түгел, арысланнарда ич. Күрә, тоеп йөри Фидаил, ишетә: бата башлаган корабтагы күселәр өередәй борсалана, керер тишек тапмый ыгы-зыгы киләләр соңгы арада. Үз ирөге белән шуларга иминлек вәгъдә итәргә тиешме ул тагы?!.

Хуҗа кеше дустанә сөйләшергә дә итеп карады Фидаил белән — барып чыкмады. Тавышын күтәрде, янады, кулларын болгый-болгый сөйләде — максатына ирешә алмады.

— Болайга киткәч,— диде ул, барып чыкмаган әңгәмәне тәмамлап,— миңа үпкәлисе булма, пнимаешь ли... Әйтеп карадым, аңламадың. Үзеңне генә түгел, мине дә нинди көнгә калдырганыңны белмисең син!.. Ут белән шаярасың! Үкенерсең, соң булыр!.. Ярар, бигайбә, энем.

Фидаил аны аңлады һәм кызганды да әле бераз. Белә ич, ул арысланнар өереннән түгел, ниндидер, вакытлыча эленеп торган бер җеп аша гына элемтәдә алар белән. Тегеләр таләп итә, ә ул Фидаилнең телен чишәргә тиешле булган — барып чыкмады, шуңа хуҗа кеше пошаманга төште. Элгәрге заманнар булса, әлбәттә, гөкерерләр иде алар ниндидер бер шофер чыгарган хикмәтләргә. Заман үзгәрергә тора, бар хикмәт менә кайда!.. Гомер колакка чалынмаган «перестройка, үзгәртеп кору» дигән сүзләр чалына ич әнә радиодан...

Әлбәттә, укучы арасында да Фидаилнең йомыкыйлыгын, шулай яраклашып яшәвен ошатып бетермәүче булыр. Турысын әйткәндә, миңа да бигүк аңлашылып җитми аның шушы хәлләрдә үз-үзен тотышы, соң чиктә, егет булырга да кирәк бит әле!.. Нишлисең, егете шундый, характер, тәрбия, шартлар һәм башкалар... Эчне пошырса пошырыр, әмма хакыйкатькә хыянәт итә алмадым, шул хәлендә кабул итәргә туры килер аны да...

Иртәгесен машинасын гараждан алып урамга чыгуы гына булды, ГАИ инспекторы туктатты Фидаилне. «Тизлегең югары иде,— диде.— Күзләрең дә кызарган, әнә, салгансың ич, брат...» «Право»сын сорап алды һәм кире кайтармады...

Кичкырын кадрлар бүлегенә чакырдылар.

— Правосыз, эчкече шофер кирәк түгел безгә,— диделәр.

Гараж һәм машина ачкычын өстәлләренә салып чыгып китүдән башка чара калмады Фидаилгә. Машина йөртергә хокукы да булмаган шоферның, чынлап та, кемгә кирәге булсын?! Ә дөреслекне эзләп кара, бар, табарсыңмы икән?!.

## 26

Фидаил дөреслек эзләп маташмады. Җаваплы урыннарда эшләгән дус-иш һәм таныш-белешләре белән бөтен шәһәрне урап алган арысланнар өеренә каршы көрәшүнең нәтиҗәсез булачагына тиз төшендерделәр. «Право»сын юллап барган җирендә үзен чак алып калмадылар.

— Сезнең фамилия таныш безгә,— диде ишек төбендә утырган кече лейтенант, картотекадан аның фамилиясен эзләп.— Сез, иптәш, мең дә тугыз йөз дә сиксән бишенче елның егерме бишенче июлендә, салмыш баштан, авария куркынычы ясагансыз... Гаебегезне танымыйча, эз югалтырга, качып котылырга исәп тоткансыз... Бусы — бер булдымы?! Икенчесе-е,— дип сузып куйды ул, картотекада теркәлгән төгәл фактларны кире кагарлык дәлиле булмаган шоферның телсез калуыннан бер тәм табып.— Инде дә килеп, үнҗиденче августта, ниһаять, каптырганнар үзегезне. «Җиңелчә салмыш хәлендә» диелгән менә монда... Куллар куелган, пичәт сугылган, тәк чту ярдәм итә алмыйм, иптәш! Закун тәртип таләп итә!..

— Иптәш лейтенант...

Авызын да ачтырмады ГАИ хезмәткәре, кистереп үк куйды:

— Булмый, иптәш-гражданин, булмый... Әчкечелеккә нинди мөнәсәбәт икәнлеген беләсез! Заманалар үзгәрде, дус!..

— Мин, гомумән, эчмим, авызыма капканым юк, иптәш лейтенант.

Кече лейтенантларның үзләренә шулай мөрәҗәгать иткәнне яратуын ул яхшы белә... Әмма аңар гына эреп китмәде яшь офицер:

— Менә, иптәш, мин монда күпме утырам,— диде ул, ипле генә һәр сүзенә басым ясап.— Әле берәүнең дә, эчкән идем дип, үз гаебен таныганы юк. Хәтерләмим... «Минераль су диләр, бер йотым гына...» — диләр. Тәк чту, иптәш, менә шулай! Хәлегезне аңлыйм, әмма ярдәм итә алмыйм, закун тәртип таләп итә!..

Бәхәсләшеп торуның урынсыз икәнлеген аңлаган Фидаил чыгу юлына борылды. Кече лейтенант үз эшен яхшы белә, аңарга үпкәләр урын юк. Картотекага теркәлгән һәр сүз закон аның өчен...

Ә яшәргә, көн күрергә кирәк. Тулай торак өчен ике-өч ай түләнмәгән, балалар бакчасыннан квитанция биреп кайтардылар. Кредитка алынган төсле телевизор утыра бүлмәнең түр почмагында... Җыеп килгән акчаң юк икән, бер генә көн дә эшсез торып булмый шәһәр җирендә. Ашыйсы бар, эчәсе бар — акча кирәк!..

Машина йөртергә хокукы юк. Димәк, һөнәре дә юк аның хәзер. Эзләнгәләп йөри торгач, бер-бер кулай эш табылганга кадәр генә дип, тимер юл вокзалында вагон бушатып көн күрүчеләргә барып кушылды. Алты кеше — бер бригада. Тупикка кертелгән вагоннардан йөк бушаталар. Алтысы алты язмыш, һәркайсының үз тарихы бар монда килеп чыгу юлында. Үзләренең яшьлеге белән ике студент аерылып тора. Әмма аларның да язмышлары төрлечә. Берсе — кыш буе стипендиясез укудан иза чигеп, җәйге каникуллар вакытында киләсе ел өчен түл җыя. Икенчесе вагон бушаткан җиргә шәхси «Жигули»да килеп туктый, кенәгәгә акча җыя икән. Ашавы, кием-салымы ата-ана хисабына, аракы эчми, тәмәке тартмый. Кызлар белән типтерүен искә алмаганда, менә дигән егет!

Өченчеләре аспирант егет — кооператив квартирга җыя икән. Ә калган икесе яшь ягыннан шактый ук өлкән кешеләр. «Үзгәртеп кору» һәм «демократия» хакында сөйләшми ул икәве, иске тормыш белән яшәүләрендә дәвам итәләр. Көне буе авызларыннан тәмәке өзелми, эш беткәч тә сыраханәгә йөгерәләр. Йөк эшендә шактый ук тәҗрибәле үзләре, куллары ятып тора. Студентларга да, аспирантка да «студент» диеп кенә дәшәләр. Фидаил дә «студент» алар өчен...

Йөкчеләр бер-беренең тормышы белән артык кызыксынмады. Чөнки бу коллективның вакытлы икәнлеген аларның һәркайсы ачык белә. Шулай да студентлар кайчак, башкалар тәмәке тарткан арада, дөнья хәлләрен урап чыгалар. Әллә кайлардагы чит илләр, чит җирләрне белеп, андагы җитәкчеләрнең исемен атап сөйләшүләренә шаккатып тыңлый аларны Фидаил. Ә инде илдә барган үзгәрешләр, «үзгәртеп кору», «демократия», «хәбәрдарлык» төшенчәләрен кыстырып сөйләшә башласалар, гомумән, берни аңлый алмый. Үз башыннан кичкәннәр белән һич туры килми алар сөйләшкәннәр.

— Хыяллансыннар әйдә,— дип кул селти аларның сөйләшүен тыңлап торган карт йөкчеләр.— Безнең дә булды шулай хыялланган чаклар... Карарбыз...

Яшьләр сөйләшкәнгә колак салып тору кызык тоелса да, тормыш хакындагы фәлсәфәләре белән тәмәке төтәткән агайлар якынрак тоела Фидаилгә. Шундый сабыр, аз сүзле, куллары эшкә ятып кына торган кешеләрне кече яшьтән үк аерым бер ярату белән үз итә иде ул. Кендекләре белән кара җиргә береккән авыл агайларын хәтерләтә иде алар... Гомер-гомергә бәрәңге утырткан бакчасын күпсенеп кисеп китсәләр дә, тешен кысып түзә андыйлар. Артык баш дип, бозавын, сарык бәрәннәрен җыеп китүчегә дә сүз әйтми... Көтүдән кайтып килгән сыерын илтеп япсалар да, казлары муенын чыбыркы белән кәкрәйтеп атучыга да тавы-

шын күтәрми. Ни килсә, шуңарга түзеп күнеккән алар, житәкче халкы белә торгандыр, без кара мужикка буйсынып яшәүдән башка ни кала, дип фикер йөртергә, үз-үзләрен тынычландырырга күнеккәннәр... Хыял һәм якты өметнең ни икәнлеген белмиләр, тормыш йөген күтәрүдән җилкәләре салынып төшкән...

Әйе, Фидаилгә алар аңлашыларак төшә. Шунысы кызганыч, бу якынлыкны алар үзләре тоймый, «студент» дип дәшәләр аңарга да... Үзенең студент түгеллеген, шофер булып эшләгәнлеге, «право»сыз калгач кына йөк бушатырга мәҗбүр булуы хакында искәртеп карады ул берничә мәртәбә. Колакларына да алмадылар, ул карт йөкчеләр өчен барыбер «студент» булып калды.

Башта икесе дә шулкадәрле охшаш тоелып, аларны бер-береннән аера да алмый йөрде Фидаил. Киемнәре дә охшаш, атлап йөрүләре, бөкшәя төшкән җилкәләре. Икесе дә берөзлексез тарта, әчү дигәннең дә кимен куймыйлар... Шулай да, тора-бара арадан берсе игътибарын ныграк җәлеп итә башлады аның, хәтта кайдадыр күргән кешегә дә охшап куя иде. Киң җилкәләре яралы кош канатларыдай салынып төшкән бу агай кемне хәтерләтә соң аңарга, көннен-көн буена баш ватты Фидаил. Кемне хәтерләтте ул?.. Бәлки тоеладыр гына?.. Гәүдәсе булсын, йөз чалымнары булсын, тез башларынача сузылган озын беләкләре... Йөк ташыганда, бигрәк тә трап аша чыгып килгән җирдән каршы очраганда, теләсә-теләмәсә дә, карашы аның шул ир-атта булды.

«Әй, карт йөкче, мин беләм түгелме сине?!. Йөз чалымнарың таныш, кайдадыр күргәнем бар түгелме?...» — дип сорардай булып карады ул аңарга.

Карт йөкче үзе дә сизеп, тоеп йөргән булып чыкты әлеге карашны. Аулак җирдә туры китереп, беләгенә кагылды ул аның:

— Нәрсә, студент, нигә шулай сөзеп карыйсың?!.

Ни дип җавап кайтарырга белми туктап калды Фидаил. Текәлеп карады карт йөкчегә — ялгышмаган, йөз чалымнары таныш...

— Син кайсы районнан? — дип сорады ул, җавап ишетүдән өметен өзеп.

— Якты Яр районы... Нурлы Алан авылы...

Алай икән, аңлашыла дигән сыман, йөзен чытты йөкче ир-ат. Һәм башын гамьсез генә читкә бора төшеп, үзе ачыклык кертте:

— Нәрсә, этең бар идеме?! — диде ул, җавапның уңай икәнлегенә шиге калмыйча. — Монда да котылып булмый үзегездән. — Һәм, тагы нидер мыгырдана-мыгырдана, җилкәсен салындырып, йөк артыннан кереп китте.

Шул бер сүз, әле кайчан гына тышкы кыяфәте белән аңарга үзенең авылдашларын хәтерләтеп торган ир-атны карачкыга әвереләдерде дә куйды. Әйе, үзе — аның Юлдашын атучы, авыл буйлап малайларның этләрен кырып йөрүче кешеләрнең берсе иде бу. Соңрак, ул аңарга район хәрби комиссариатында очраган иде... Кыргыйлык һәм кансызлыкның чагылышы булып, малай чактан аның төшләренә кергән адәм икән ич!.. Бәгыренә мәңге төзәлмәс яра салган, дөньяны ачык төсләрдә генә күргән малайның кешеләргә, дөньяга ышанычын какшаткан Эт атучы! Эт атучы, димәк, үтерүче, кешенең кешелеген юкка чыгаручы вәхши дигән сүз. Әлегәчә исән икән әле, әлегәчә җир күтәреп йөрткән үзен...

Әмма эт атучылар да картая икән. Кайчандыр алар турысында капка баганасы сыман тырпаеп торган төз гәүдә гүя инде хәзер терәүгә калган. Янтая төшкән, җиргә чүккән... Хәрәкәтләре дә Юлдашны сыйрагыннан эләктереп чанага тотып быргыгандагы кебек җилле, җәһәт түгел, салмакланган. Кара чәчләренә ак мамык утырган, маңгай — җыерыла, күзләр — кысыла, муеннар кыскара төшкән. Игелекле, изге кешеләр генә картаядыр кебек иде аның өчен. Баксаң, эт атучы булып — эт атучы да бирешә икән вакыт каршында.

Бу көн чиксез озын тоелды Фидаил өчен, кич житмичә аптыратты. Бер-береннән качып, бер-беренең күзенә чалынып йөрүдән тайчанып буламы?.. Бер үк трап, бер үк сукмактан йөрделәр, әмма карашлары аяк очларын бораулады һәр икесенең.

Кич житеп, эш сәгате тәмамланырга барган саен, эт атучының адымнары авырая иде. Куллары тагы да сузыла, жилкәләре куырыла төште аның. Яшьләрдән калышмый авыр йөк бушату жиңел түгел күрәсен... Аның инде үз яшьтие белән дә сүз алмашмавына байтак гомер. Авызыннан папирос өзелгәне юк.

Кич житеп, йөкчеләр өйләренә таралырга торганда, жансыз өрәк сыман, сиздерми генә, янына килеп, Фидаилнең инсәсенә кагылды Эт атучы:

— Студент...— диде. Һәм сүз табалмый торды беркавым.— Синең вакытың булса, студент, бераз сөйләшергә иде бит?!. Миңа кайтабызмы әллә?.. Якташ та икәнсең, ә, студент?..

— Якта-аш...— дип, көлемсерәүдән башка чарасы юк иде Фидаилнең.

— Вакытың юкмы?..

— Сөйләшер сүзем юк!

— Минем хакка, студент?!. Минем әйтер сүзем бик күп сиңа...

Бу нинди аңламаган кеше син, дигән сыман, янә битараф карашын төшереп алды аңар Фидаил. Каныкты бит тәмам...

— Сүземне тыңла, ә, студент?..— Күзләрен мөлдерәтеп, өлкән яшьләрдәге ир-ат карап тора иде аңар. Карашында кансызлык һәм мәрхәмәтсезлекнең чырае да булмагандыр аның шул мизгелдә. Түбәнчелек белән гозерләп үтенгән кеше генә шулай карый ала башка берәүгә. Күңеле түрендәге нинди дер нечкә бер кылга барып кагылды Эт атучының шул карашы, аның хәленә кермәү мөмкин булмагандыр хәтта... Йомшара төшеп, кешеләрчә жавап кайтарды ул аңар бу юлы:

— Вакытым да юк... Бакчадан бала аласы бар...

— Хатының юкмыни?.. Ул алыр... Япа-ялгызым мин бүген...

Сәгатенә күз төшереп алды Фидаил. Шул мизгелдә әлеге ир-атны кызгана башлавын тойды ул үзенең, аның хәленә керәсе килде. Эт атучы дигәне дә кешегә охшаш икән ләбаса — ялгызлыктан газаплана белә, кичерү сәләтенә ия икән... Күзләрендә моң.

—Адресыңны калдыр,— диде Фидаил, күңелендәге йомшаклыкка буйсынып. Шулай да сер бирергә ашыкмады.— Баланы урнаштырыйм башта, аннан карармын.

Пинжәк кесәсеннән сигарет кабы чыгарды Эт атучы һәм шуның эченнән нәни генә кәгазь кисәге алып сузды:

— Мә, визит карточкасы...

— Нәрсә, синең адресмы? — дип кайтарып сорады Фидаил, визит карточкасына карамас борын ук. Бу адәмгә каян килергә мөмкин андый «визитка»?!

— Минеке!

Соңгы мәртәбә күз карашлары белән алмашып, икесе ике тарафка китеп барды алар. Эт атучыны бер читтә бергә сыра эчә торган юлдашы көтеп тора иде...

Ул кайтып кергәндә, Асия өйдә иде. Ишек катындагы электр плитәсе янында кайнаша. Кыска жиңле күлмәк өстеннән пөхтә ак алъяпкыч япкан, чәчләрен калфак сыман итеп чөйгән ак косынка астына жыеп куйган. Күзләре моңсу, әмма бит урталары алсуланып торалар. Кайчандыр, Сания апаларының кухнясында очрап, Фидаилнең йөрәген жилкендергән Асиягә охшаган иде ул бүген... Идән почмагында уенчык машиналары белән әвәрә килеп утырган Алмаз, ишектән керүгә үк: «Этием!..» — дип, аның муенына ташланды. Өйгә кәстрүлдән күтәрелгән бу белән тәмле хуш ис таралаган — пешкән ит исе. Өйгә кайтып кергәч тә, мондый иминлек, жылылык каршылар дип уена да кертеп карамаган иде бит ул. Байтактан тойганы юк иде аның бу жылылыкны...

Ләкин күңеленә килгән бу хисне — белгерту кая — яшерергә тырышты ул тизрәк. Улын коры гына сөеп куйгач, өстен-башын алмаштырды, чишенеп юынды да китәргә җыена башлады. Моны, махсус эшләгәндәй, Асиянең күз алдында башкарды ул. Әледән-әле күз төшереп алуына да карамастан, хатын күрмәмешкә салышты, сер бирмәде. Шулай да түземлеге чамалы булып чыкты. Фидаил, киенеп-ясанып ишек катына үткәндә, бераз калтырана төшкән салмак тавышы ишетелде аның:

— Аш әзер иде, Фидаил...

Соңгарып әйтелгән сүзләрне гүя ишетмәде ул, ишекне каты ябып китеп барды.

Шәһәрнең иске үзәгенә юл тоткан трамвайда кеше күп түгел иде. Иң арткы рәттәге буш урындыкка барып утырды Фидаил. Кесәсеннән Эт атучы биргән визит карточкасын тартып чыгарды. Саргая төшкән кәгазь кисәгенә язылган мәгълүматларга игътибар итте:

*Гирфанов*
*Усман Валидович,*
*профессор, язучы.*
*Шиһап Мәрҗани урамы, 17 йорт, 4 фатир.*

Бу визит карточкасының иясе кем?.. Ул ни рәвешле Эт атучы кулына барып кергән?.. Нигә дип әле ул ниндидер профессор, язучы торган фатирга чакыра аны?.. Әллә үзенчә мыскыл итүеме, шаяртуымы?.. Каяндыр табып алган да төрткән булса, әле бер хәл, яманракны да көтәргә мөмкин ич. Әйтик, бер-бер кешенең кыйммәтле әйберләрен урлаганда яисә талаганда ияреп килгән кәгазь кисәге булса?!. Ничек котылырга белмәссең ул очракта... Мондый «визитка»ның теләсә кемгә эшләнмәве билгеле ич. Шушы көнгәчә бары бер кешедә очратырга туры килде аңар әлегедәй таныклык-кәгазьне — Капкаевта. «Килгәем чыкса, рәхим ит!» дип, кесәсенә тыккан иде. Капкаев — гастроном директоры, билгеле һәм кирәк кеше! Зур-зур җитәкчеләр белән аралаша ул. Ә бу кем?!. Монда профессор дип язылган ич, язучы дип хәтта. Язучы кадәр язучы эт атармы?!. Башка сыймас хәл бит бу!

Ярый да шаярткан гына булса?!. Начар ният белән төртмәгәндер дип кем ышандыра ала?!. Үзе шикләнә, ышанмый, үзенең беркатлылыгыннан көлә Фидаил. Ә үзе һаман юлын дәвам итә... Чираттагы теләсә кайсы тукталышта төш тә кит бит, югыйсә... Кәгазь кисәген ертып атарга да, онытырга иде инде күптән... Җиңелчә чайкалгалап, ипле генә юлын дәвам иткән трамвайга, әйтерсең лә, арты ябышкан аның.

Мәрҗани урамы Кабан күленең уң як читенә сыенып утыра, ул тирәне белә Фидаил. Унҗиденче йортны да тапты. Ике катлы иске агач бина икән. Дүртенче фатирның ишеге киереп ачылган көе калган: «Әһә, дигән уй бызылдап үтте аның чигә турыннан,— талаганнар һәм аны җибәргәннәр...» Ул да түгел, кая килеп эләктем мин, дип торган җиреннән, аның каршысына чәйнек тоткан хуҗа килеп чыкты — Эт атучы үзе!

— Килдеңме? — диде ул тыныч кына. Әйтерсең ул килми кала алмый иде?!.

— Килдем...

Хуҗаларча туры атлап, бүлмәгә узды Эт атучы. Кунакка түрдәге күн креслодан урын тәкъдим итте. Ә үзе, кунак көткән кеше сыман, ишекле-түрле йөреп, чәй өстәле хәзерләү белән мәшгуль булды. Дәшмәде. Атлаган саен аягына элгән иске чүәге шап та шоп итеп үкчәсен кыйный. Стенада эленеп торган дәү борынгы сәгать шак-шок килеп, мизгелләрне саный.

Утыру һәм өй эчен күзәтү өчен уңайлы иде тирән кресло. Ишек катыннан ялгыз тәрәзәгә сузылган шактый ук иркен бүлмәдә яши икән Эт атучы. Һәр өч як стенаны идәннән түшәмгәчә сузылган китап киштәләре биләп тора. Бу рәвешле, тоташ китап киштәсеннән торган фатирны беренче күрүе иде әле Фидаилнең. Киштәләре дә нинди генә әле,

шыяла капкачлы. Ләкин шунысы гаҗәп, китап киштәләре, берничә урында тәртипсез рәвештә аунап яткан буш шешәләрне искә алмаганда, шыр ялангач калган. Бер сынар китап әсәре дә күренми үзләрендә... Әмма киштәләр элек-электән буш тормаган, шүрлек такталарының бушлыкларына да карамастан, сыгылган булулары шуны раслый. Чит-читләре затлап, сырлап эшләнгән бу киштәләрдә, күрәсең, кайчандыр тум-тутырык китап булган...

Ни өчен дип килгән иде соң әле ул монда — шушы китап киштәләренә карап утырырга дипме?.. Шулай да күз каршындагы күренешкә битараф кала алмады. Ул туып-үскән авыл китапханәсендә дә бу кадәрле уңайлы һәм күп урын булмагандыр... Сәер һәм шомлы күренеш. Кайчандыр рәт-рәт булып тезелгән китаплардан сыгылып калган буш шүрлекләр җир йөзендә яшәп тә юкка чыккан зур җәнлекнең шыр ялангач скелетын хәтерләтә иде сыман...

Тәрәзә каршысында әле тагы зур өстәл тора, имән өстәл. Утыргычлары калын күннән эшләнгән имән кресло. Тимер карават, кием элгече, люстра — һәммәсе борынгы һәм үз вакытында монда затлы гаилә яшәгәнлекне күрсәтеп тора. Соңгы утыз-кырык елда бу фатирга, китап киштәләрендә тәртипсез рәвештә аунап яткан буш шешәләрдән тыш берни кермәгән.

Өй эчендәге шушы халәт, озаккарак сузыла төшкән тынлык баса башлагандай булды Фидаилне. Якын туганына килгән кунак түгел бит — тынгысызланып, хуҗага мөрәҗәгать итте ул.

— Шушында торып ятыш дисез инде...

— Шушында.

Әле булса кулында тотып торган «визитка»га күз төшереп, көлемсерәп куйды Фидаил. Бу аның, үзенчә, иронисе иде булса кирәк.

— Профессор, дисез инде алай булгач... Язучы дисез...

Эт атучы дәшмәде. Егеттән мәкерле ирония көтмәгән иде булса кирәк... Паузадан файдаланып, Фидаил үзалдына сөйләнүен дәвам итте:

— Госман Вәлидович Гыйрфанов буласыз, димәк?..— Ә үзенең күзе һаман визит карточкасында, әле бер, әле икенче ягын әйләндерә-әйләндерә күзәтте ул аны.— Профессор һәм язучы дисез... һәм берочтан Эт атучы да...

Капылт кына кунагына таба борылып алды хуҗа. Гүя авырткан җиренә кагылдылар аның:

— Студент...— диде, тирән сулыш алып.— Госман Гыйрфанов минем әти була... Мин — Гыйлем атлы, аның улы...

— Менә ничек?!.— Чын-чынлап кызыксыну туды Фидаилнең күзләрендә.

— Әйе, минем әти татарларның билгеле әдәбият галиме, әдибе булган...

— Тукта, тукта,— дип бүлдерергә ашыкты аны «студент».— Ә син үзең кем?!. «Татарларның» дисең...

—Мин беркем дә түгел,— диде хуҗа, бу юлы инде тагы да авыррак күренеп.

Фидаилдә аның бу сүзләре балачакта күңеленә килеп алган бер уйны тулгандырып куйды: «Ничек эт атарга мөмкин?.. Нинди кешеләр икән бу?!. Ул белгән кешеләрнең берсенә дә охшамаган алар чөнки, тыныч кына, урам буйлап кан эзләре чәчеп, җан кыеп йөриләр. Кем булыр икән болар?.. Күрәсең, киноларда күрсәтә торган теге фашист дигән зат кебегрәк була торгандыр инде болар...» Эт атучының үзе белән әңгәмә корып утыра ул хәзер. Саф татарча сөйләшәләр, әмма үзен халык вәкиле санамый Эт атучы. Очраклымы бу?..

Егетнең житдиләнә төшүен, кызыксынып тыңларга әзер булуын чамалап алгач, ипле генә сөйләп китте Эт атучы:

— Ярар, кем булса да бер түгелмени!.. Бердәнбер улына Гыйлем дип

куштырган исемне эти... Укымышлы кеше, гыйлем иясе, галим булсын дигәндер... Белгәнеңчә, мин менә йөк бушатам... синең иште студентлар белән...

Чынлап та көтелмәгәнчә килеп чыга бит әле бу, ни диярга белми торды Фидаил бертын.

— Хикмәтле кеше икән сез... Профессор улы — йөк бушатучы, язучы малае — Эт атучы... Чынлап та, кызык...

— Кызык булмый... Сезгә тарих дәресләрендә сөйләми торганнардыр инде бу хакта?!. Ә, студент?..

Янә беркат, телен әрәм итеп, үзенең студент түгел, шофер икәнлеген аңлатып тормады Фидаил. Барыбер колагына элмәячәк.

— Тарихның ни катнашы бар? — дип кенә куйды ул.

— Тарихмы!..— дип элеп алды Эт атучы.— Тарих — катлаулы нәрсә... Сезгә өйрәткәнчә, Борынгы Рим һәм Мисыр фиргавеннәре һәм дә Наполеон, Колчаклар гына булмаган тарихта... Анда безнең иште — үзенең ни кылганын, кем булып, кая барып чыгачагын уйламый көн күрүчеләрнең дә язмышы чагыла, студент...

Үзе дә уйламаганда, янә тешен күрсәтеп алды Фидаил:

— Мин мужик халкыннан, абзый, профессор малае түгел. Тарихка мөнәсәбәт юк безнең...

— Беребез дә азат түгел тарихтан! Син, студент, алай кистереп куярга ашыкма әле!..

— Нәрсә, профессор улының эт атып йөрүенә тарих гаепleme?!.

— Әйе!

— Бер гаепсез авыл малайларын елатырга да тарих куштымы?!.

— Шулай булып чыга...

— Кара, ничек җиңел икән?!. Гомер буе ни телисең шуны эшләп йөрергә дә, җавап бирергә чират җиткәч, тарихны гаепләргә... Соң, абзый кеше, ике көпшәле мылтыкны да кулыңа тарих тоттырдымы?

Фидаилнең дулкынланып, җилкенеп-җилкенеп сөйләшүенә дә карамастан, Эт атучы үзен тыныч тотты. Үпкәләмәде, рәнҗергә җыенуын да сиздермәде:

— Әйе, шулай килеп чыга, студент... Кешенең һәр кылган эше — тарих хикмәтләре... Заман һәм язмыш дип тә алмаштырырга була тарих сүзен.

Әңгәмәдәшенең шулай тыныч булуына ачуы чыкты Фидаилнең. Әйтерсең, бер гаепсез әүлия сөйләшеп утыра аның каршысында.

— Соң син,— дип, урыныннан ук калкынып куйды ул.— Син... Синең кулыңа мылтыкны кем тоттырды?!.

— Шулай кирәк булды, студент... Кызма әле син, кызма, мылтыкны үзем алдым...

— Кеше атарга кушсалар, кешегә дә атар идеңме?

— Әйе димим... Ләкин, беләсең булса кирәк, студент, кеше атучылар да байтак булды...

— Тарих гаепleme?!. Җир аларны да күтәрергә тиешleme?

— Җир күтәрә ул... Әйе, алар да тарихны гаепле саный...

— Кеше кыяфәтендәге карачкы!.. Кеше кыяфәтендәге роботлар сез. Тарихны гаепләргә түгел, абзый кеше!

Дәшми генә торып, өстәл тирәли арлы-бирле йөренергә керешә хуҗа. Чәй өстәле хәстәрли иде ул, килгән «кунак» хөрмәтенә. Ни гаҗәп, үзен элеккечә үк тыныч тота... Холкы сабыр, үзе итагатьле, һич уйламассың... Фидаилне дә аңларга, аның да хәленә керергә кирәк: каршысындагы бу кешенең Эт атучы икәнлеген бер генә минутка да хәтереннән чыгара алмый иде ул. Малай чактан ук канга буялган сары кожаны белән төшләренә кереп йөдәткән, тышкы кыяфәте белән генә дә ничә мәртәбәләр куркытып уяткан адәм ич...

Дәшми-нитми генә чәйләп алдылар. Кыстатып тормады Фидаил, алдына куйганны ашады. Бүгенге физик эштән соң аппетит юклыкка

зарланырлык түгел. Каяндыр «Вермут» шешәсе менеп кунаклаган иде өстәлгә.

— Кабасыңмы? — дип, шешәгә ишарәләде хуҗа.

— Дуслык юк.

Тәкъдим итүче күе чәй төсендәге кызгылт сыеклык тутырылган шешәне кулына алып бөтерде-бөтерде дә кире урынына куйды:

— Ярар, синеңчә булсын...

Рәхмәт әйтергә базмадымы, онытты мы, креслога көчеп утырды Фидаил. Хуҗа кеше аның алдына шактый ук таушалган фотоальбом китереп салды. Ә үзе ашыкмый гына табын җыештырырга кереште. Өстәл өстендә әлеге дә баягы шешә һәм ике стакан гына утырып калды, аларына кагылмады.

Фидаил альбом актара. Әмма моның бер кызыгы да юк аның өчен. Ташлап чыгып китәргә дә уңайсыз кебек әлегә. Ә альбомда, Эт атучының үзеннән тыш, һичкем таныш түгел аңар... Кире кайтып, беренче биттә үк урнаштырылган фоторәсемгә карап утыра башлады: уң як почмагына «Петровъ» дигән келәймә сугылган. Революциягә кадәрге рәсем иде күрәсең, ә үзе саргаймаган. Елтыр күзле, киң тәкә маңгайлы бер яшүсмер карап тора аннан. Култык астына ниндидер чит-ят хәрефләр белән сырланган газета кыстырган. Ә бәлки журналдыр, иске язуны танымаган Фидаил өчен барыбер иде ул кадәресе. Шул кәгазь төргәгенең бер читендәге «Шура» диген сүзне генә укырга мөмкин, анысы хәзергечә. Әмма, барыбер, аның нәрсә аңлатканын белми ич ул. «Шура атлы хатын-кыз хакында язылгандыр, күрәсең...» дип кенә гөманлап куйды. Хәер, Фидаилне гаепләргә ашыкмыйк, кайчандыр шул исемдә Оренбург каласында татар телендә академик журнал чыкканлыгы хакында кемнең хәбәр иткәне бар киң массага ишетелерлек итеп?!

— Әтиемнең шәкерт чагы,— дип аңлатма кертте Фидаил утырган кресло аркасына килеп таянган хуҗа.— «Шура» журналында хәреф җыючы булып эшләгән ул.

Дәшмәде Фидаил. Әмма үзалдына кызыксыну белдереп, альбомның чираттагы битен ачты. Монда таныш кешеләр күренмәгәч, ары китәргә торган Фидаилнең кулыннан тотып алды Эт атучы, гүя кош тотты ул.

— Сул якта Ризаэтдин казый Фәхретдинев — журналның редакторы, уртада — Закир Рәмиев, Дәрдмәнд дип тә йөрткәннәр үзен, миллионер да булган, шигырьләр дә язган. Анысы Шакир Мөхәммәдов, язучы булырга тиеш... Сулда утырганы Фатих Кәрими атлы журналист. Ә теге артта басып торучы озын гәүдәлесе Җамал Вәлиди булырга тиеш...

Эт атучы сөйләгәннәр бер колагыннан ничек керсә, икенчесе аша шундый ук тизлек белән чыгып та китә барды Фидаилнең. Урта мәктәп тәмамлап та колакка чалынмаган, укытучылар тарафыннан телгә алынмаган ул кешеләрне хәтерләүдән ни мәгънә? Кыяфәтләре, үз-үзләрен тотышлары затлы күренә анысы. Затлылыкта гынамыни хикмәт, кылган эшләре шул чама гына булгандыр, күрәсең... Ә менә Мәхмүт Хөсәен яисә Мөхәммәт Садри булса, таныр иде ул аларны. Авылга да килгәннәре булды, ул эшләгән төзү оешмасында да чыгыш ясады соңгылары...

Бер-беренә таба янтая төшеп, янәшә утырган ир белән хатын фоторәсеме урнаштырылган битне ачкач, ирексездән, үзе үк карап куйды ул Эт атучыга.

— Болары кемнәр тагы?..

Сулышы колакка бәреп торган Эт атучы җавап бирергә ашыкмады. Танымый ахры дигән уй туып алды Фидаил күңелендә... Ә фоторәсемнән күзне алырлык түгел. Исәлеккә калган шушы мизгел аша гына да әлеге парның татулыгы, бер-берсенә нинди хөрмәт һәм ихтирам белән караганлыкларына сокланып туймаслык. Гүя өй кыегына кунаклап, янәшә гөлдерәгән пар күгәрченнәр...

— Минем əти белəн əни,— диде Эт атучы, шактый вакыт дəшми торганнан соң.

Бу яңалыктан сискəнмəү мөмкин иде микəн, бер фоторəсемгə, бер Эт атучының үзенə текəлеп карады Фидаил. Күпме генə жентеклəп өйрəнмəсен, дөнья мəшəкатьлəреннəн йончып өтəлəнгəн Эт атучының шундый мəhабəт həм игелекле сурəтле ир белəн хатыннан туу ихтималын күз алдына китерə алмады ул. Һичнинди уртаклык юк араларында. Бала — ата-ананың дəвамы булырга тиешле түгелме соң?!. Карашлары, үз-үзлəрен тотышлары белəн үк игътибарны жəлеп иткəн, күңелдə ихтирам уяткан кешелəр белəн — илле яшьтəн узып та, тормышта үз урынын тапмаган адəм арасында нинди уртаклык булырга мөмкин?!.

...Альбомның ахыргы битлəренə житеп килгəндə, тагы бер фоторəсемгə төртелеп торды əле. Аның игъибарын хужа да сизмəде түгел. Пауза озынга китə башлагач, үзе үк сорап куйды:

— Күргəнең бармы əллə?

Фоторəсемдəге егет түгел, сорау сəер тоелды бу юлы Фидаилгə. Мөлаем елмаеп торган мəhабəт гəүдəле бу егетне белүен белми ул, əмма кай төше белəндер, нəрсəсе белəндер ул аңар кемнедер хəтерлəтə дə сыман. Əмма кемне? Кайчан həм кайда күргəне бар аның бу егетне?.. Шул ук вакытта каян килеп таныш булсын икəн ул аңар, Эт атучы белəн аны нəрсə берлəштерə?!.

## 27

Өйдə үз-үзенə урын таба алмады Асия. Эштə дə гаме булмады. Уйламаган-көтмəгəндə адашып билгесез тарафларга барып чыккан юлчы хəлендə тойды ул үзен. Һəр яңа көн, həр сəгать аны күнегелгəн тормышыннан, үткəннəреннəн аера бара. Ə кай юнəлештə хəрəкəт итə ул, юлы кая илтəчəк — күз алдына да китерə алмый. Юлның ахырында аны ни көтə, билгесезлеккə төбəлгəн бу сəяхəт ни белəн тəмамланачак — берəү дə белми... Əнə шул билгесезлек газаплый да инде аны. Шул билгесезлек гаилə иминлеген пыран-заран китерде, инде иялəшеп, күнегеп житкəн эшеннəн аерды. Шул билгесезлек — йокыдан мəхрүм итте, жан тынычлыгын качырды. Кая барып терəлер həм кай жирлəрдə тəгəллəнер аның бу юлы— алла үзе генə белə...

Шулай да үкенми иде ул. Адашса адашкандыр, əмма башлаган юлыннан кире борылыргамы əллə дигəн уй килеп тə карамады. Белə ич ул, икелəнə торган чагы түгел аның хəзер. Йə барысына ия була, йə бернəрсəсез кала — икенең берсе... Күзлəрен чагылдырып, килəчəген балкытып торачак бəхеттəн нибарысы кул сузымы ераклыкта тора ич ул. Үрелəсе, тəвəккəллəп, соңгы адымны атлыйсы калган, томан артында шəйлəнгəн билгесезлек шундук эреп юк булачак...

Күңелен шундый уйлар борчыган көннəрдə, үч иткəндəй, Арсланның эзе суынды. Шылтыратмый да, Энзия Закировна аша «киңəшмəгə» дə чакыртмый... Югалды!

Көтеп-көтеп тə хəбəре ишетелмəгəч, үзенə шылтыратырга кирəк дигəн карарга килде ул. Ə бəлки, аның белəн бер-бер хəл, күңелсезлек килеп чыккандыр, Арслан аның ярдəменə мохтаждыр? Ничек моңарчы уйламаган ул бу хакта... Хəзер үк шылтыратырга кирəк. Хəзер үк урамга чыгарга да бер-бер аулак автоматтан шылтыратырга кирəк үзенə!

— Алло, тыңлыйм,— дигəн таныш аваз ишетелде аргы баштан. Əнə, ничек якын, янəшəдə генə икəн лəбаса ул. Тəүлеклəр буе аны уйлап газапланасы, көтəсе дə түгел, чыгасы да урамдагы телəсə кайсы автоматка ике тиенлек бакыр саласы həм бармак очы белəн алты мəртəбə

әйләндерәсе генә икән... Арсланның тавышын ишетүгә үк, куанып, шул рәвешле үз-үзен шелтәләп алырга да өлгерде Асия.

— Бу мин идем...

— Тыңлыйм!

Коры гына әйтелгән шул сүздән кабинет салкынлыгы исеп куйды. Ә Асия башка сүзләр көткән иде бит аңардан. Шуңа югалып калды, нәрсә өчен шалтыратканлыгын, ни сөйләшергә жыенуын онытты үзенең.

— Әйе, тыңлыйм сезне,— дип кабатлады тавыш.

Асия үз-үзен кулга алырга өлгерде, танымаган икән ләбаса ул аны. Танымагач, билгеле инде, башкача дәшә дә алмый ул. Чак үпкәләмәде тагы... Үпкәсен онытып, ягымлы һәм үз итеп дәште ул:

— Бу мин идем әле, Арслан... Мин...

— Кем ул, «мин»? Үзе өчен һәркем «мин»!.. Тыңлыйм... Арслан Сәхипович тыңлый!

Көлеп жибәрә язды Асия. Әле һаман танымаган икән ич ул аны, кызык бит...

— И-и-и, Арслан,— дип дәште бу юлы, янәшә торган чакларындагыча ягымлы итеп.— Онытып та бетергәнсең... Мин идем...

— Иптәш...— дип тавыш күтәрделәр аргы якта.— Шаяртырга вакытым юк! Исемегезне әйтегез һәм ни кирәк?!.

— Берни дә кирәкми,— дип, янә югалып калды Асия, тотлыга язды. Үч иткәндәй, телефон шыгырдый иде... Ниндидер чит авазлар да ишетелеп куйган сыман.

— Кирәкмәгәч,— дип жавап кайтарды кырыс аваз,— Эшегез беткәнме әллә анда?!.

Трубканы атып бәрергә үк жыена иде булса кирәк Арслан Сәхипович. Әмма шулчак, тонык шыгырдау авазына кушылып, таныш исем ишетелде:

— Асия иде бу...

— Кайсы Асия?!.— Сорау ялгыш ычкынды. Аның урынсызлыгын шундук абайлап, төзәтергә ашыкты Арслан.— Ә-ә, син идеңмени, Асия? Тавышың начар ишетелә... Нәрсә булды? Тыңлыйм сине, Асия...

— Берни булмады. Болай гына шалтыраткан идем,— диде. Тагы ни әйтә, нәрсә дия ала иде икән соң ул?!. Телефоннан сөйләшер сүзләре дә юк икән ич аларның, уйлый калсаң.

— Хальләр ничек?— диде, ниһаять, кем белән сөйләшкәнен төшенеп алган Арслан, мишәр акцентын махсус ассызыклап.

— Әйбәт...

— Нинди яңалыкларың бар?

— Беркөе, элеккечә...

— Яхшы алай булгач, яхшы...— дип, ни әйтергә, алга таба ни сөйләшергә белми төртелеп калды ир-ат тавышы.

Хатын-кызның сизгер күңеле дә шундук тоеп алды моны. Әмма үпкә белдерергә ашыкмады. Сораштырырга керешеп ул да, үз чиратында:

— Үзең ничек яшисең, Арслан?

— Түзәрлек.

— Эшеңдә күңелсезлекләр юктыр ич?..

— Әлегә тәртип, үзгәртеп корабыз,— диде һәм ипле генә ирония катыш көлгәндәй итеп алды.

— Көлүеңнең мәгънәсен аңламадым, Арслан?..

— Үзгәртеп корабыз дим, «перестройка»... Газеталар укымыйсыңмы әллә? Заманнан калышырга ярамый, Асия.

«Миндә газета кайгысы түгел шул әлегә...» дип әйтергә ачылган авызын тыеп калды Асия. Күренеп тора, аңлашыла, телефон аша гына жанына тынгылык иңмәячәк аның барыбер... Ә Арслан, әллә юри, әллә чынлап, бернинди дә конкрет тәкъдим әйтергә уйламый, читләп-урап сөйләшүен дәвам итә. Димәк, үзенә тәвәккәлләргә кала:

— Кайчан очрашабыз соң? — дип сорап куйды ул, уңайсызлану дигән төшенчәне онытып торып. Арслан ничек кабул иткәндер, сорау аның үзе өчен дә көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты. Артык төгәл һәм туры иде сорау.

— Очрашырбыз, Асия... Вакыт ягы кысанрак әле менә...

— Кайчан? — дип әрсезләнде хатын, ачык җавап ишетмәвенә күңеле рәнҗеп.— Кайчан очрашабыз?

— Карарбыз дидем, Асия... Вакытка карарбыз... Иң әлек кайбер нәрсәләрне үзгәртеп корырга, койрыкларны җыя төшәргә кирәк әле.

— Азга гына булса да... Минем сине бик тә, бик тә күрәсем килә, Арслан...

— Янмый торгандыр ич!..— дип әйтеп салды, ниһаять, ир-ат. Шалтыратучының үзен аңларга теләмәвенә ачуы кабара башлаган иде инде аның.

— Януын янмый да...

— Соң, янмагач!..

Үч иткәндәй, сөйләшүнең шул урынында, анасы артыннан йөгергән аксак каз бәбкәсе сыман пиб-пиб иткән аваз чыгарып, элемтә өзелде. Арсланның сүзләре ярты юлда эленеп калды. Кесәсендә ике тиенлек бакыр табылмады Асиянең... Урамга йөгереп чыкты, урамда йөреп торучыларның әле берсенә, әле икенчесенә очып кунды ул:

— Ике тиен бирегез... Ике тиенлек юкмы?..

Берәвенең дә ниндидер бер хатын өчен тукталып, кесә актарып торасы килмәде, «Юк...» — дип, китеп баруларын дәвам иттеләр. Почмактагы газета киоскысында утыручы әби дә: «Акча вакламыйбыз, күрмисеңме, күзең чыкканмы әллә...» — дип, итагатьле генә җавап кайтарып, шул хакта язып эленгән кәгазь кисәгенә күрсәтте. Башка сүзем юк дигәнне аңлатып, шапылдатып, пыяла тәрәзен дә ябып куйды аның борын төбендә...

Эш урынына әйләнеп кайтты Асия. Көтәргә кереште. «Нигә борчылырга?!.» — дип тынычландырды ул үзен. Сүзләре ярты юлда бүленде, теләсә, Арслан үзе чакырта ала ич аны. Телефонга чакырта ала, машина җибәрә ала, «профсоюз киңәшмәсенә» хәтта... Үзгәртеп кору башланган дип, дөнья тукталмас әле, тик әйләнер үз көчәрендә...

Күзләрен ишектән алмый көтәргә кереште ул. Аннан менә-менә, Арслан Сәхипович йомышын үтәү бәхетеннән канатланган Әнзия Закировна килеп керер төсле иде... Ул көнне булсын, иртәгесен булсын, ателье мөдире алар цехына аяк басмады. Тәрәзә каршысыннан җиңел машина үткән саен, җилкенеп куйды Асиянең күңеле. «Мине алырга җибәрелгән машина түгелме?» — дигән өмет бер кабынды, бер сүнде — кабатланып торды. Әмма алырга килүче дә, шатлыклы хәбәр җиткерүче дә күренмәде һаман.

«Әллә соң тагы шалтыратып карарсгамы икән үзенә?..» — дигән уй да ташламады аны. Бәлки бер-бер мәшәкате, нинди дә булса күңелсезлек килеп чыккандыр... Аңар, бәлки, Асиянең ярдәме, җылы сүзе кирәктер хәзер. Асия дә кул сузмаса, кем ярдәмгә килер Арсланга?.. Телефоннан сөйләшкәндә үк тою мөмкин иде ич кәефе бигүк яхшы түгеллекне... Шул, башына уй төшкән, борчу баскан аның Арсланын. Кичекмәстән эзләп табарга, ярдәм итәргә кирәк аңар!.. Шушы көнгәчә ничек бу хакта уйлап карамаган ул?!. Кул кушырып утырды, үпкәләгән имеш... Арслан әле дә аны уйлый торгандыр, аңардан ярдәм көтә. Горурлыгы гына шалтыратырга, үзе янына чакырырга ирек куймый торгандыр...

Эш сәгате дип тә тормады, рөхсәт тә сорамады — урамга атылып чыкты һәм очраган беренче машинага кул күтәрде Асия. Буш такси булып чыкты.

— Универсаль базага,— диде ул, сулышын чак тыеп.

Арткы рәткә кереп утырган хатынга, көзге аша берничә мәртәбә

сынаулы караш ташлап алгач, сүз кушты таксист:

— Нәрсә, апасы, бер-бер дефицит кайтканмы әллә?..

Дәшмәде Асия. Таксистның сүзләре тәрәзәдән сызгырып кергән җил сыман гына чалындына колагына. Ә теге, светофор каршында тукталган саен, күзгесе аша һаман күзәтүендә булды. Фуражкасының озын козырегы астыннан чираттагы мәртәбә күз салып алгач, урамга чертләтеп төкерде дә гөманларга керешеп ул:

— Хатын-кыз шулай кая ашыксын?!. Дефицит артыннан, билгеле. Ире янына кайтырга дип ашыкмас ич инде. Сөйгән яр кочагына дисәң, алар үзләре килеп ала торгандыр, шулай бит, апасы...

Таксист шулай ук үзенә күрә тәҗрибәле «арыслан» иде булса кирәк. Ике сүз әйтүгә үк таныды Асия, шуңа дәшмәде. Тыңлап кына барды... Юл кыска тоелды...

Өчлеген калдырды да рәхмәт тә әйтеп тормады үзенә. Арсланның эшенә якынлашкан саен, ныграк җилкенә барган йөрәге зур тимер капкага тартты аякларын.

— Апасы, сдача кирәк түгелме әллә?.. Ха-ха...— дип, кеткелдәп, ачык тәрәзәдән күзләрен шар итеп карап калды таксист. Кузгалырга ашыкмады.— Бәлки көтәргәдер, ә, апасы?!

Борылып карамаса да, итәге артыннан ияреп килгән комсыз карашны тойды Асия. Шул караш аның үз-үзенә булган ышанычын арттыра төште, тәвәккәллек бирде, гәүдә чигелешләренә гайрәтле хәрәкәт өстәде.

Ябулы йөк машинасын чыгарырга дип ачылган тимер капкадан ишегалдына узды ул. Каравылчы, ни сәбәпледер, бу хатынны туктатырга кыймады, карашы белән генә озатып калды. Ул да — таксист кебек үк хатын-кыз рәтен белә торган заттан иде булса кирәк — белгән догаларын укый калды.

Монда беренче тапкыр гына килүе булуга да карамастан, югалып калмады Асия. Административ бинаны складлардан аеру да кыен түгел иде, икенче катның түрендә үк урнашкан директор кабинетын да эзләп газап чикмәде. Кабул итү бүлмәсендәге кызга барып җиткәч кенә сөрлегә язды:

— Гражданка,— диде теге, юлына аркылы төшеп.— Сез кая?..

— Директор янына.

— Ул бүген кабул итми.

— Мине кабул итәр...— Бу яшь чибәр кызга, күрүгә үк, ачуы килгән иде Асиянең. Хәер, сөйгәненнән көнләшү хикмәте булгандыр, секретарь кызлар хакында имеш-мимешләрне аз сөйләмиләр ич.

— Директор занят... Сез кем буласыз?

— Кем булуым әһәмиятле түгел! Арслан Сәхипович мине чакырган иде...

— Чакырса, көтәргә туры килер, әлегә ул занят.

— Анда кеше бармы? — дип сорады Асия, күндәмләнә төшеп.

— Җитди эше бар дидем,— дип кабатлады кыз. Һәм, ниһаять, моньысын да туктаттым дигән нәтиҗәгә килеп, чәчләрен сыпыргалый-сыпыргалый, көзгегә таба узды.— Бу нинди аңламаган кешеләр бу... Әйттем ич, Арслан Сәхипович занят дидем, аның җитди эшләре бар дидем... Ә бәлки ул Мәскәү белән сөйләшә торгандыр...

Кыз канәгать сөйләшә-мыгырдана калды, Асия җәт кенә күн белән тышланган ишек артына кереп югалды. «Гражданка, гражданка, сез кая?..» — дигән сүзләрне инде ул Арслан кабинетына илтүче икенче кат ишекне япканда гына ишетте.

Баксаң, Арслан мул җиһазлы кабинетның түрендә берьялгызы, бөтен-ботка атландырып, креслога чумган да кофе эчеп утыра икән. Рөхсәтсез килеп керүчене күргәч тә кыбырсырга керешкән иде иң элек. Ышанасы килмичә, күзләрен челт-мелт йомгалады.

— Нәрсә?! Асия! — дип, гаҗәпләнүеннән торып ук басты ул. Тавышын күтәрә төште.— Нигә монда килдең?!. Кем рөхсәт итте?!

— Үзем килдем... Сагынып.

— Эш урынынамы? — дип, берни аңлый алмыйча, каршысына килеп басты ул хатынның.

— Өеңне белмим ич... Адресыңны калдырмадың! — Монысы инде Асия тарафыннан ярым шаярып әйтелгән сүз иде.

Шулай шаяралар димени — аңламады Арслан — күзләре маңгайга менә язды.

— Өй!.. Адрес!..— дия алды.

Хатын, киресенчә, Арсланны шулай эш урынында һәм сау-сәламәт күрүенә чиксез шат иде. Ничек каршы алуы әһәмиятсез... Белә ич: ир-ат халкы барысы да бер камырдан ясалган, гыйшык турында сөйләшеп икәүдән-икәү калганда гына арысланга әверелә алар. Ә инде урамда яисә эш урынында очрата калсаң, кая ул, кикрикләре шундук шиңә, уңлы-суллы карангаларга керешәләр. Әйтерсең, бөтен кеше аларны күзәтеп тора. Хатыны яисә бер-бер танышы белән барганда очратсаң, күрмәмешкә сабышып китәргә дә күп сорамыйлар. Арслан гына башка булмас...

— Күрәсем килде, шуңа килдем,— диде Асия, ягымлы елмаю һәм якты караш сирпеп.

— Ну-у, Асия,— дип баш чайкады пошаманга төшкән база мөдире.— Күрешә торган, сөйләшә торган җир мондамы инде?!. Тапкансың шаяртыр урын!..

— Бәлки миңа урын тәкъдим итәрсез, Арслан Сәхипович?!. Кунакны шулай каршылыйлармы?!

— Әйе, әйе, тәнкыйть кабул ителә,— дип, кабаланып елмайгандай итте Арслан. Асиягә ян стена буендагы иркен диваннан урын тәкъдим итте. Ә үзе аның янәшәсеннән утырмады, кабинет түрендәге эш өстәле артына үтте.

Аның бу кыланышы бер күрешү, очрашып кул кысышуга зарыгып, сусап килгән Асия өчен бөтенләй көтелмәгәнчә килеп чыкты. «Арслан да курка белә икән...» — дип уйлап алды ул һәм аны шул йомшаклыгы өчен кызганып куйды. Күңеле нечкәрә язып калды...

— Йә,— диде Арслан, өстәл артындагы креслога утыргач та тамак төбеннән ясалма көр тавыш чыгарып.— Хальләр ничек, сылу?!

Үзенең мишәр акцентына махсус шулай басым ясавы иде база директорының. Бу үз-үзенә тәвәккәллек өстәве иде булса кирәк аның.

— Бер көе, Арслан... Син мине ачуланма, яме!.. Мин сине бик сагынып килдем... Җитди сүзләрем дә күп җыелды... Кемгә сөйлим синнән башка?!

Арсланга чит тоелды Асиянең эчкерсез аңлашырга җыенуы. Шуңа сөйләп бетерергә ирек бирмәде:

— Ул җитди сүзне сөйләшә торган урын монда дип белдеңме?!.

— Сиңа әллә нәрсә булды, югалдың ич, Арслан!..

— Димәк, вакытым юк. Эшем күп, димәк... Шуны аңлый алмыйсыңмы?!— Дорфалыгын аңлап булса кирәк, тавышын баса төште бераздан.— Йә, тыңлыйм...

— Тыңласаң шул, Арслан, мин башка болай яши алмыйм...

Тагы ярты юлда бүлдерде аны Арслан.

— Мин аңлый алмыйм! — Ияген югары чөйде ул, кресло артында тук мал сыман киерелеп.— Үзең теләгәнчә яшә, кем сиңа аяк чала?! «Болай» яши алмасаң, тегеләй яшәп кара...

— Ничек, ничек, ул «тегеләй»?..— дип, урыныннан торып, база директорының өстәле каршына килеп басты Асия. Мөлдерәп тулышкан, чайкалса түгелергә торган күзләрен аңарга текәде.— Син нәрсә, көләсеңме, әллә мыскыл итәсеңме мине?..

— Җитәр, җитәр, Асия,— дип, урыныннан кузгалмый гына хатынны тынычландырырга итте Арслан.— Әллә ниләр сөйләмә әле!?

— Сузмыйк, Арслан!.. Мин болай яшәүдән туйдым, хәл итик.

Хатынның соңгы сүзләре калтыранып, бәгыреннән саркылгандай, тирәннән чыкты. Арслан да тоеп алды әлеге күңел тибрәнешен. Авырлык белән генә урыныннан торды һәм Асияне, кулыннан җитәкләп, кире диванга озатып куйды ул.

— Синнән беркая да китәргә җыенганым юк, Асия,— диде ул пышылдарга керешеп.— Тынычлан... Бүген үк кунакка чакырырга дип тора идем әле үзеңне...

— Э-эх,— диде хатын, тешләрен кысып. Кулъяулык чите белән борынын сөртеп алды... Көчсезләнде Асия, биреште. Ир-ат алдында гомерендә беренче мәртәбә йомшаклык күрсәтүе иде бу аның.— Мин бит сиңа бөтенләй башка нәрсә турында сөйлим!.. «Кунакка чакырырга...» имеш!

Янәшә басып тормады, вак-вак атлап, кире өстәленә таба чигенде Арслан. Пышылдавын дәвам итсә дә, тавышын күтәрә төште:

— Бу — эш урыны, Асия, кайда икәнлегеңне онытма. Балавыз сыкмый гына аңлашып булмыймы, кешеләрчә!..

Барын да гафу итәргә, теләсә нинди авыр сүзләрне дә күтәрергә әзер иде бүген Асия. Тик аны гына аңласыннар, ул дигәнчә булсын. Чигенә-чигенә әле һаман креслосына барып җитә алмаган Арсланны куып тотты ул. Иреннәре белән аның күкрәгенә кагылып алды, күлмәк якаларын хәстәрләде, галстугын турайтып куйды.

— Үзең дә арыгансың. Күлмәк якаларың да начар үтүкләнгән,— диде иркәләнергә итенеп.— Мин сиңа һәркөн юып-үтүкләнгән күлмәк кидерермен. Маңгай җыерчыкларың да юкка чыгар, Арслан...

База директоры аны, кабалана төшеп, янә бер кат диванга илтеп килде. Үз креслосына утыргач кына тирән сулыш алды:

— Син нәрсә сөйлисең, Асия,— диде ул, ияген горур рәвештә югары чөеп.— Минем хатыным бар, кызым — син моны яхшы беләсең. Син дә тормышта! Балалар үз әтиләре янында үсәргә тиеш!

Асиянең бу юлы да урыныннан сикереп торасы килде, әмма түзеп калды. Арсланга өстәмә мәшәкать тудырасы килми иде аның.

— Оныттыңмыни,— диде ул, мөлдерәгән күзләрен Арсланнан яшереп.— Үзең тәкъдим ясаган идең түгелме?!

— Юк, минем беркайчан да балалар ятим үсәргә тиеш дигәнем юк!

— Ә ярату?.. Синең яратам дигәннәрең?! Чын түгел идеме алар? Нигә мине алдап йөрттең, нигә шушы хәлдә калдырасың син мине, ә, Арслан?..

Корт чаккандагыдай сискәнеп алды ир-ат:

— Причем монда ярату?! Синнән берәү дә баш тартырга җыенмый!

— Ә мин башкача булдыра алмыйм болай. Аңлыйсыңмы, булдыра алмыйм,— дип, сыгылып төште хатын.

— Үзеңне кулга ал, Асия! Кайда икәнлегеңне онытасың!

Асия аның җикеренүгә күчүен гүя абайламады.

— Мин иремнән аерылам... Аның белән яши алмыйм башка. Ул мине һичкайчан гафу итмәячәк, аңлыйсыңмы?! — дип, күз яшьләренә буылып, һәр сүз саен тирән сулыш ала-ала аңлатырга, гозерләргә кереште Асия.

— Аерылганнар ди әнә!.. Гафу итми!..— Кабинетына фатир сорап кергән хезмәткәргә кычкыргандай шар ярды Арслан, өстәл почмагына китереп сукты. Уртасы чокыраеп торган киң ияген артка ташлап, текә муенын югары чөйде.— Причем монда аерылышу?! Синең өйдәге ызгышталашта минем ни катнашым бар!

Ике як яңагыннан йөгерешкән күз яшьләре хатынны кызганыч кыяфәткә керткән иде. Күз төбенә сыланган зәңгәр күләгә юл-юл булып няккәчә агып төшкән. Чәчләр тузгыган. Шунда гына ишекнең ачык икәнлеген, кабинетындагы хәлләрнең шактый ук хөртиләнә баруын чамалап алды база директоры. Кабаланып, сул кулы белән бер читтә

торган селектор төймәсенә китереп басты:

— Фая, син андамы?

— Әйе, Арслан Сәхипович.

— Мине көтүчеләр юкмы?

— Әлегә күренмиләр, Арслан Сәхипович.

— Мин монда юк, киңәшмәгә киттем, Фая! Аңладыңмы, бүген кайтмыйм, көтмәсеннәр.

— Сорасалар, нинди киңәшмә дияргә, Арслан Сәхипович?.. Профсоюз дияргәме?

Бераз гына уйлап торгач, ачыклык кертте база директоры:

— Райкомда диген, партия киңәшмәсендә!

— Аңлашылды, Арслан Сәхипович. Миңа да китәргә рөхсәтме?

— Нәрсә, киңәшмәгәме, ха-ха...

— Киңәшмә, Арслан Сәхипович, комсомолларда да була... Хушыгыз!

Кулын кнопкадан алып, ишек катына үтте Арслан. Ике катын да эчке яктан бикләде. Җай гына атлап, Асиягә якынлашты. Күзләре уйнап алды аның, креслода утырган хатынга сокланып күз салды. Һәм аның капрон оек аша матур булып ялтырап торган тулы сыйракларын күзләп, еш кына хәтерләргә яраткан шигырь юлларын кабатлады:

Тез өстенә тезен куйган,
Алып булмый күзне шуннан...

Соклanudан да бигрәк, Асиягә комплимент ясавы иде бу аның үзенчә. Шагыйрьләрең бер читтә торсын, әнә ничек килештерә...

Ниһаять, Асияне кулыннан җитәкләп алды, стенага уеп эшләнгән бар янына алып килде.

— Йә, житәр, Асия, житәр — тынычлан, барысы да көйләнер,— дип тынычландырды, хатынның биленнән кочаклап алды ул. Икенче кулы белән аның чуалышкан чәчләрен рәтләде.— Әйт, нәрсә эчәбез, коньякмы, әллә акнымы?..

Асиянең колак очында әле һаман үзенә адресланган баягы шигырь юллары эленеп тора иде: «Тез өстенә тезен куйган, алып булмый күзне шуннан...»

Инде ничәнче кат ишетүе аның бу сүзләрне. Ватык пластинка сыман һаман шуны кабатлый. Аяклары, шәрә ботларыннан башка сокланыр, мактап искә алыр яклары юкмы икәнни соң аның?!. Соң чиктә, дәшми торсын иде...

Арслан канәгать иде үзеннән. Тели икән, әнә шул рәвешле тиз генә юата, күңелләрен белә ала ул хатын-кызның... Тели икән, кырыс та була белә... Рюмкаларга коньяк агызды ул, берсен Асиягә сузды:

— Нәрсә өчен эчәбез, Асия?

Җавап ишетелмәде, күтәрелеп карарга да уңайсызлана иде әле хатын.

— Синең яшьлек һәм матурлыгың өчен, Асия!

Бүлмәдә җил-давыллап тузынып килгән җәйге яңгырдан соң утырып калган сыман тынлык хөкем сөрде. Рюмкаларны куеп, диванга таба үттеләр.

— Эх, Асия,— дигән дәртле пышылдау авазы яңгырады бераздан.— Үзеңне ничек яратканлыгымны белмисең шул син. Әгәр шагыйрь булсаммы?.. Шагыйрь булсаммы, эх, Асия... Поэма язар идем синең хакта... Роман...

Хатын дәшмәвен дәвам иттерде. Арсланның куллары аның билендә иде инде. Иреннәре күз яшьләреннән тозланган бит очларын, иреннәрен барлады. Бармаклары капшанырга керешге бераздан...

Поэма, алай гынамы әле, хәтта роман кадәр роман вәгъдә итсә дә, база мөдиренең пышылдау һәм назларына җавап кайтаручы булмады.

— Эх, Арслан... Син мине кемгә саныйсың, Арслан...— дип, сыгылып, хәлсезләнеп төште хатын.

## 28

Өстәлдә ялгызы утырып калган вермут шешәсе, шулай да, ачылды. «Студент»ның күпме генә кыстасаң да күнмәячәгенә инангач, Эт атучы Гыйлем, стаканын тум-тутырук итеп, үзе генә эчеп җибәрде.

— Фу-у,— дип башын чайкады ул, буш стаканны, әйләндереп, өстәлгә каплап куйгач.— Кандала даруы.

Креслога җәелеп утырган Фадаил күз карашы белән тагы бер мәртәбә шәрә китап киштәләрен барлап чыкты. Өй эче тып-тын. Хәтта форточка да ачылмаган. Ә почмакларында пәрәвез челтәрләреннән тыш һични булмаган буш киштәләр арасыннан шүрлекләрдән шүрлекләргә күчеп җил йөгерә, ачы җил үкерә гүя. Җил түгел, әллә бушап калган киштәләр сыкрап елыймы шулай. Ай-һай, ямьсез һәм куркыныч икән ул борынгы китап киштәләренең шыр ялангач торуларын күрү!.. Шомлы бушлык авазы башына капты Фидаилнең, чигәләрен кысарга керешге... Шул халәтеннән арынырга теләп, игътибарын хуҗага күчерде ул.

Күрәсең, Эт атучының үзенә дә авыр тәэсир итә иде шүрлекләрдән искән әлеге бушлык авазы. Ул да, әнә, сыңар башын ике учына салып, өстәлгә каплаган. Бирчәеп беткән дәү, таза бармаклары арасыннан чыбыркы сыман бүртеп чыккан чигә тамырлары гына күренеп тора. Ике чәнти бармак аша карап торган күзләрен кан баскан...

Күңел түгел, күз карашы күтәрә алмаслык күренеш иде бу. Кая карарга, карашын кая куярга белмәде Фидаил. Кай тарафка гына карамасын, анда сыкрап елаган буш киштәләр яисә кан баскан тонык күзләр чекерәеп тора. Шул халәттән котылу теләге белән, түземсезләнеп сорау эзләде. Әмма ул аңарга исеме белән дәшмәде. Дөресрәге, дәшә алмады. Эт атучы белән аның исеме — «Гыйлем» арасында һичнинди уртаклык, бәйләнеш күрмәде ул. Аның исеме җисеменә туры килми, бөтенләй ятышмый сыман иде. Шуңамы, читләтеп бирде соравын:

— Киштәләрең нигә буш?..

Теләр-теләмәс кенә кыймылдап, башын дәү учларыннан арындырды хуҗа кеше. Авызын зур ачып һава иснәп куйды.

— Киштәләрме?..— диде салмак кына. Янә өстәл өстендәге шешәгә үрелде. Бу юлы инде стаканга салып мәшәкатьләнмәде, шешә бугазыннан гына уртлап алды.— Киштәләр бушаган... Гомер узган... Тамырлар өзелгән... Нәсел тузган, студент...

Шигырь сөйләгәндәгедәй көйләп, тигез ритм белән тезеп китте ул. һәм тагы шешәгә үрелде. Ике кулында әйләндереп-бөтереп, аның төбендә калган куе кызыл сыеклыкка карап торды озак кына:

— Шушы вино кебек, бер кабасы һәм бер йотасы гына калган. Һәм вәссәлам!..— Дәшми утырды озак кына. Аннан каршында утыручының күзләренә текәлде.— Син дә мине Эт атучы дип кенә беләсең...

Һәр икесенә мәгълүм җавапны раслап тормады Фидаил. Хуҗа кеше дә моны көтмәде аңардан. Карашын кулындагы вермут шешәсенә текәде дә сөйләргә кереште. Гүя аның башыннан кичкәннәр шул шешә төбендәге ике йотым винога күмелгән, шуннан укый, шуннан сөзеп сөйли сыман:

— Оренбургтан Гражданнар сугышы елларында, Уралны ак гвардиячеләр камап алгач кына әйләнеп кайткан әти. Башта ниндидер гәҗит һәм журнал редакцияләрендә эшләгән. Мәкаләләр, хикәяләр, хәтта пьеса да язган... Төп эше укыту булган — төрле курсларны, бер ачылып, бер ябылып торган әллә нинди академияләрне җитәкләгән... Утызынчы еллар башында хәзерге педагогия институтының элгәре булган Көнчыгыш педагогия институтына доцент итеп күчерелә.— Шул урында, тыңлыйсың-

мы дигән сыман, игътибарын Фидаилгә юнәлтеп алды ул.— Син дә «пед»та укымыйсыңдыр ич?!. Анда укучылар синең эше басынкы, сабыр була...

Түгел дигәнне аңлатып башын чайкады «студент». Хуҗаның карашы янә шешә төбенә күчте.

— Шул көнгәчә өйләнмәгән булган. Соң гына, кырыкка якынлашып килгәндә өйләнгән минем эти. Әни дә шунда яшь укытучы булып килгән булган... Мин туганмын. Беренче бала — башлары күккә тигән... Киләчәктә уларын нинди язмыш көтәрен уйлап тормаганнар, күз алларына да китерә алмаганнар. Ике укытучы, ике галимнән туган малай кем исемле булсын? Гыйлем, әлбәттә! Ике төрле фикер булмаган. Шул мин туган елны үзләренә менә шушы фатирны биргәннәр. Шул елны этигә профессор дәрәҗәсе бирелгән, әни кандидатлык диссертациясе яклаган. Шул тикле яңалык, шатлык алып килгән ул ел — 1935 ел булган. Җәй дә матур килгән, убылып иген уңган диләр әле тагы.

Шешәдән күзен алмый гына пауза ясап алды хуҗа. Аның бугазына килеп тыгылган төер, пешкәк сыман, төшеп-менеп хәрәкәтләнүендә дәвам итте. Дулкынлана... Алга таба ничек дәвам итәргә, кайсыларын сөйләргә дә кайсыларын сөйләми калдырырга дип баш вата иде булса кирәк ул...

— Шуннан? — диде Фидаил, ирексездән, сөйләүчегә куәт бирергә теләп. Кемне тыңлап утыруы хакында бөтенләй хәтереннән чыгарган.

— Утыз җиденче елда этине кулга алганнар. Карлы-бозлы яңгыр явып торган көзге төн булган. Ишек шакыганнар, үз аягы белән барып ачкан эти. Кунарга урын сорап килүче бер-бер юлаучыдыр дип уйлаган, күрәсең. Биш минут вакыт биргәннәр үзенә — киенергә, хушлашырга. Ә мин, әнә шул, син утырган җирдә торган бала караватында йоклап калганмын. Мине уятудан куркып, ботинкаларын кулына тотып, аяк очларында ишек катына үткән эти...

«Юк, җибәрмим, ягылырга хакыгыз юк!... Ирем — совет профессоры»,— дип, карышырга теләгән, ишеккә аркылы баскан әнине читкә этәргәннәр.

«Бер гаебем дә юк, ачыклагач та кайтарып җибәрерләр, борчылма. Бала уянмасын...»,— дип тынычландырган аны эти. Иртәгесен ук әйләнеп кайтырмын дип уйлаган.

Шулай, студент, үземне хәтерли башлаганчы ук «халык дошманы» улына әверелгәнмен мин. Ул елларда әниемнән башка берәүнең дә үз исемем белән дәшкәнен хәтерләмим. «Халык дошманы» диделәр, «контр» диделәр... Иптәш малайларым арасында да «Гыйльмык» яисә «Гыйльмуш» булып кына йөрдем... «Бала уянмасын»,— этиемнең соңгы сүзе булган, шул китүдән кайтмаган. Әнине дә куганнар институттан, партиядән чыгарганнар, дипломын да алганнар. Озак кына ниндидер оешмада җыештыручы булып эшләде... Сугыш чыккач, заводка керде, фронт өчен үз-үзен кызганмый эшләде. Уникешәр сәгать станок артында басып эшләгән, аңлыйсыңмы, уникешәр сәгать!.. Һәм берүзе генә дә түгел! Эшеннән бирелгән ризыкны, ашамыйча, миңа ташый торган иде. Эти фронтта булмагач, безгә паек эләкмәде. «Халык дошманы» балалары ничек тели шулай көн күрергә тиеш булган...

Кимсенмәсен, дигәндер әни: «Әтиең җибәргән, этиең өчен бирделәр»,— ди-ди, икмәк кыерчыклары ташый иде ул минем өчен. Авызыннан өзеп җыйган өлешләре булган. Күрәсең — башкалардан ким түгел буй — ач тормаганмын, димәк. Бастырык буе... Ә әни... утыз алты яшен дә тутыра алмыйча китеп барды. Ашказаны белән! Шулай, студент, үндүрттә шыр ятим торып калынган. Эти юк, әни юк, абыең-апаң булса икән...

Суворов училищесына керергә өметләнеп йөргәнне хәтерлим, алмадылар. Эти фронтовик түгел! Кара сакал сыман, үзем күреп хәтерли дә алмаган этием күләгәсе ияреп йөрде. Әни эшләгән заводка да алмадылар өйрәнчек итеп. Завод бит... Мин — ышанычсыз нәселдән! Тире

эшкәртү комбинатына алдылар, чөнки анда эшләргә теләүче юк, сасы, пычрак. Авылдан килеп прописка эзләүчеләр эшли иде һәм минем ишеләр. Хезмәт биографиямне йөкче булып башлаган кеше мин. Тәк что, бел, студент, йөкче булып эшләүдә минем кырык ел чамасы стаж бар. Кем белән эшләгәнеңне онытма!..

— Эт атарга... Ә эт атарга кем өйрәтте?.. Кем мәҗбүр итте?— дип сорап куйды Фидаил, йокыдан яңа уянган кеше сыман кисәк кенә.

— Синдә эт кайгысы,— дип мыгырданып алды хуҗа һәм ипле генә сөйләвен дәвам итте.— Тире комбинатында ДОСААФка кердем. Тирда мылтык тотарга, атарга өйрәттеләр... Сугыш елларында бөтен хыяллланганым мылтык тоту иде, дошманнарга каршы бару. Әтиемне дә шул фашистлар алып киткәндер сыман тоела иде миңа. Хәрбиләрнең уллары-кызларына булган игътибар һәм хөрмәткә дә кызыгылгандыр... Суворов училищесы турындагы хыяллар да юкка гына түгел... Мылтык тотып, хәрби кием киеп алсам, бар кимсенүләрем таралыр кебек тоела иде.

Унҗидедә өйләндем. Акыл бирүче булмаган. Малай туды өйләнмәс борын ук. Хатын яшь, чибәр... Акча гына юк, кесәдә җилләр исә. Ә хатынга матур кием, Кара диңгез кирәк була башлады... Ну, акча юнәттем дә җибәрдем мин моны ял итәргә. Бер-ике мәртәбә акча сораткан телеграммасы килде, әмма үзе кайтмады шул китүдән. Баланы да, үземне дә онытты. Мыек чыкмас борын ук, яшь балалы тол ир булып калдым.— Сөйләвеннән бүленеп, күз төпләрен, маңгаен сыпыргалап торды ул бертын. Һәм кулын селтәде.— Хәер, боларның сиңа кирәге юк инде...

Әйе дип тә, юк дип тә дәшмәде Фидаил. Сөйләгәннәре дөрес булса, Эт атучының башыннан кичкәннәр, чынлап та, тыңлаучыны битараф калдыра торган түгел иде. Язмыш сынаган, шактый ук талкыган күренә үзен.

Кинәт хәрәкәт ясап, кулындагы шешәсен югары күтәрде хуҗа һәм, төбендә юшкыны калмасын дигәндәй, бертын әйләндереп-чайпалдырып торды да авызына койды виноны. Буш шешәне идәнгә төшереп, аяк очы белән җәт кенә китап киштәләренә таба тәгәрәтеп җибәрде. Берара буш шешә тәгәрәгән аваз гына ишетелеп торды өйдә. Ниһаять, арлы-бирле тәгәри торгач, шешә тынды. Сөйләвен дәвам итте Эт атучы:

— Яшь балалы тол ата булсам да, малайлык чыгып бетмәгән, күрәсең, тирга йөрүдән туктамадым. Ничек тә башкалардан аерылып тору, тизрәк ату булган бар хыялым. Яхшы атсам, мәңге тормышка ашмас хыялым да чынга әверелер кебек тоелган... Ә үземне армия хезмәтенә дә алмадылар — малай бар, кемгә калдырасың. Тире эшкәртү комбинатында чимал җитми башлады. Ә җылы итек, тун кирәк — планны киметмиләр. Ул чакта бит, тәртип — ай-һай, хәзер сез аны күз алдыгызга да китерә алмыйсыз. План төшерелә икән, утә! Кайдан телисең, шуннан тап тирене, план гына үтәлсен, итек һәм тун саны гына кимемәсен!.. Менә шуннан башланды инде, студент. Җыеп алалар да — районга, җыеп алалар да районга куалар. Биш йөз тире, мең тире, мең ярым тире дигән әмерләрне җибәреп кенә торалар иде югарыдан. Түләү — эт башыннан...

— Югарыдан?!— дип сискәнеп куйды Фидаил, урыныннан сикереп тора язды.— Эт атарга дипме?!.

— Эт атарга!.. Ну, районнан авылларга бүленгәндер план. Хуҗасыз этләр күбәйгән дигән сылтау белән, билгеле, тиктомалдан түгел. Синең этне атарга димәгән берәү дә. Халыкны әзерләү өчен, иң элек, кайсыдыр авылда шундый-шундый кешене котырган этләр талаган икән дигән, янсә әллә кайда гына бер баланы этләр ашаган икән дигән сүз җибәрә торганнар иде.— Шул урында—«студент»ның үзенә текәлгән нәфрәтле карашын сизепме — акланырга кирәк тапты хуҗа.— Юк, юк, коткы тарату безнең эш түгел! Ул эшнең үз белгечләре бар иде... Этләрен аттык анысы, яшермим... Аттык. Акчаны әйбәт түлиләр иде, эт башыннан!

Сезнең Якты Яр районында төпләнеп кала язган идем әле мин. Хәрби комиссариат тирында эш тәкъдим иттеләр. Эшендә түгел хикмәт, хәрби кием дә бирделәр! Хыялланганымны беләсең... Ну, бер хатынга йортка кердем... Балалар йортыннан малайны алдырдым... Берничә ел яшәдем дә әле мин сезнең Якты Ярда, бөтенләйгә төпләнергә иде исәбем. Анда нәсел-нәсәбемнең дә үткәнен белмиләр, тик яшәргә иде исәп тыныч кына. «Дошман» дигән исемем дә онытылды... Урамда очратып, берәрсе «Гыйлем Госманович» дип тә дәшсә, күзгә яшьләр килә торган иде. «Гыйльмык» кына идем ич мин аңа кадәр...

Кыскасы, барысы да көйләнеп килә иде инде, ипле генә яшәп яту иде. Хәрби комиссариатта да хөрмәт итәләр иде үземне. Гел көтмәгән җирдән килде миңа каза: синең ише малайлар теңкәгә тиярга кереште. Кайсы авылныкылар гына килмәсен: «Таныйсыңмы, кара, кара, әнә Эт атучы»,— дип бармак төртеп күрсәттеләр. Тора-бара якага ук ябыша башладылар... Кайсы авылдан диден әле үзеңне?

— Нурлы Аланнан.

— Юк, сезнең авылныкы түгел. Нииндидер, Комазаннан идеме?.. Бер малай күкрәккә мылтык китереп терәде. «Син, паразит,— ди бу миңа.— Минем этемне аткан идеңме?!.— ди.— Мә, ал!»,— ди, курокка басарга итенә. Алай да мылтык корылмаган булып чыкты, беткән идем... Бер төркем иптәшләре белән бергәләшеп кулларын артка каерып бәйләгәч тә, өскә сикерә, тибенә, тешләшә теге: «Барыбер үтерәм мин сине,— ди-ди яный.— Тамырыңны корытам, канга — кан, үлемгә — үлем»,— дип кычкыра. Кызганыч та, куркыныч та — кычкырып елый үзе, бичара...

Түздем-түздем дә китәргә мәҗбүр булдым. Бала-чага гына түгел, өлкәннәренә тикле «Эт атучы» дип бармак төртә башладылар, яшәрлегемне калдырмадылар. Бергә тормыш көтеп яткан хатынга да ошап бетмәде бу яңалык... Малайны җитәкләдем дә, әйдә, тай кире Казанга... Шулай, студент, без күргәннәрне күрергә язмасын сезгә!

Башын артка ташлап, тукталып, берара уйга калып торды Эт атучы Гыйлем. Алга таба ни сөйләшергә белми иза чигә иде бугай.

— Шулай да, теш кайрама, аңларга тырыш син мине, студент! Үч алыр җирем калмаган. Ятьмә койрыгына эләккән шыртлака сыман, буталып, чуалып беткәнмен. Аңларга тырыш мине, студент!..

Ничәнче кат тукталуы иде икән, янә сүзсез калды, телен тешләде. Карашын кая төбәргә, кулларын ни эшләтергә белми газапланырга кереште. Ике кулы белән алмаш-тилмәш бармакларын, кул аркаларын уалый, кыса. Мәрхәмәтсез кыса бармакларын, сөякләре шыгырдап куя хәтта, тегермән ташы астына эләккәннәрмени... Әйтерсең, кер сыга, гүя язмышына кунган тузан һәм тапларны кысып чыгарырга тели иде ул шулай...

Кызгана ук башлады түгелме үзен Фидаил?! Ләкин ул аны кызгана аламы соң?! Каршысында — Эт атучы! Үз гомерендә җанын бирердәй булып ярата алган бердәнбер дүрт аяклы дустын — Юлдашны мәңгегә юк итүче, тартып алучы... Малай күңеленә тәүге җәрәхәт салган адәм. Дөньяны якты һәм ачык төсләрдә генә күргән үсмернең ышанычын, өметен кыеп алучы...

Әй барыбер, ни генә булмасын, теге чакта хәрби комиссариаттагы очрашудан соң күп су аккан, күп нәрсә үзгәргән. Фидаил дә башка, аның кешеләргә карашы, дөньяга карашы башка — ышаныч нык кына кимегән. Күңел — хыянәт һәм мәрхәмәтсезлеккә күнегә төшкән. Ул чакта үзе дә өзгәләп атарга әзер иде ул әлеге адәмне. Эт атучының үзен дә дөнья аз талкымаган, бәхет дигәннәре аңарга да йөзен күрсәтмәгән. Эт атучы булуына да карамастан, кеше сурәтендә күренә башлаган иде ул Фидаил өчен бүген. Ни генә димә, бүген якасына барып ташлана алмый инде ул аның. Иңсәләре шәлберәеп төшкән, маңгай һәм куллары тоташ җыерчыктан торган бу бәхетсезгә ничек ягылырга кирәк?!

Язмышындагы кайсыдыр сәхифәләре белән хәтта беркадәр үз һәм якын да тоела башлады түгелме ул аңар?!

Шулай да бер мизгелгә күңелендә талпынып куйган миһербанлык хисенә ирек куймады Фидаил. Үз-үзен ялгышудан азат итәргә теләп, тизрәк сүз башлады:

— Дөньяга ачуыңны алдың, димәк?!. Бер гаепсез авыл малайларыннан үч алгансың!

Мондый сүзләр, мондый битәрләү ишетергә теләмәгән иде Эт атучы. Аз гына мәрхәмәтлелеккә өмет иткән иде булса кирәк.

— Берәүгә дә ачу саклаганым юк,— диде ул салмак тавыш белән.— Үчләнү ир-ат эше түгел.

Гүя ишетмәде аны Фидаил, үз туксаны — туксан:

— Сөйләмә, абзый кеше, дөньяга, кешеләргә ачулы син! Бер хәсрәтсез, борчусыз яшәп яткан авыл малайларын рәнҗетүдән тәм тапкансың! Син... Син әтиең өчен үч алгансың бездән!

— Студент,— диде хуҗа һәм теләр-теләмәс кенә башын борды аңа таба. Утырган урындыгы сыкрап алды хәтта.— Син нәрсә, студент?!. Бу өйрәнгән, моңарга ни әйтсәң, нинди пычрак өйсәң дә бара, күтәрергә күнеккән дисеңме?!. Беләсең килсә, үз гомеремдә минем берәүгә дә бармак янаганым булмады.

— Мылтык барында бармак янамыйлар...

— Мин кеше рәнҗетмәдем...

— Кеше...— дип кабатлады аның артыннан Фидаил. Теләсә-теләмәсә дә, бу кеше белән тыныч-ипле генә сөйләшә алмый иде ул, күрәсең.— Син — дистәләгән, йөзләгән малайларның күңелен, хисләрен канга буяган, челпәрәмә китергән адәм, абзый кеше!

— Юк, студент, мин кеше рәнҗетмәдем! Ялгышасың! Кеше рәнҗетүдән дә яман эш юк. Мин моны үземнән беләм — әтисез үстем. Сәбәпсезгә рәнҗетелгән кеше кызганыч... Һәм куркыныч та!

— Дөрес, куркыныч кеше син!

Гүя «студент»ны ишетми иде инде ул, үзалдына уйлануын дәвам итте Эт атучы Гыйлем:

— Нахакка рәнҗетелгән кеше куркыныч, дөрес әйтәсең анысын... Андый кеше үз-үзенә бикләнә, йомыла. Кешеләргә ышанмый, кешедән игелек көтмәскә өйрәнә. Билгеле, үзе дә уңга-сулга чәчәк өләшеп йөрми рәнҗетелгән...

— Икебез дә бер сүз сөйлибез ич, абзый кеше. Иртәме-соңмы барын да күтәргә мөмкин андый кешедән...

— Мин кеше рәнҗетмәдем!— Әллә башына киткән иде, әллә махсус басым ясарга теләде, шул ук сүзен тагы әллә ничә тапкыр кабатлады Эт атучы Гыйлем.

— Сәер килеп чыга, абзый кеше,— дип өстәде Фидаил. Бәхәс дәртеннән чыга алмаган иде әле ул да.— Берәүне дә рәнҗетмәдем дисең, ә үзеңә мылтык терәгәннәр. Көпә-көндез авыл буйлап кан коеп, өй борынча эт атып йөрү синеңчә рәнҗетү түгел инде, ә?!. Мин аңлый алмаган ул чакта, ничек инде өлкән кеше эт җанын кыеп йөрергә мөмкин дип гаҗәпләнгән идем... Әле генә аңладым — син үч алып йөргәнсең бездән. Безнең бәхетле балачак артык тоелган сиңа. Авыл җирендә хуҗасыз эт булмаганлыгын сез яхшы беләсез!.. Беләсең килсә, абзый кеше, теге чакта сез киткәннән соң мәет чыккан өй сыман бушап калды авыл. Кичләрен эт өргән аваз ишетелмәде... Мәктәптән озын тәнәфескә чыккан малайлар йөгермәс, уйнамас булды сездән соң. Бер-беребезгә туры карарга уңайсыз иде, борын салындырып йөрдек. Шул вакыйгадан соң, сугышлы уйнасак, фашистларга каршы түгел, эт атучыларга каршы атакага бардык. Таяк мылтыклар белән кырыкмаска-кырык мәртәбәләр терәп аттык, мылтык түтәсе белән кыйнадык без сезнең карачкыларны. Тетмәгезне тетә торган идек, таяк мылтыклар чыдамый торган иде... Шулай, абзый! Ә син, торасың да, кеше рәнҗетмәдем дисең?!.

Канатлары сынган карт бөркет сыман күзләрен мөлдерәтеп карап утыруын белде Эт атучы Гыйлем. Түзем иде ул, сөйләүчене бүлдерми.

— Дәвам ит, тыңлыйм, студент. Сүзләрең тагы калгандыр әле...

— Җитәр, абзый, әйтелгән кадәресе җитеп торыр әлегә!

— Дәшмисең?..— дип, сораулы карашын төбәде Эт атучы.— Алайса мине тыңла, студент! Хәтереңә язып куй, кирәге чыгар: Агачның кәүсәсенә балта чапсалар — аның эзе җуелмый, тамгасы кала. Кеше тәнендәге җөй сыман. Ә инде тамырына чапсалар, тамырын каерып өзсәләр — агач корый. Яфрак ярмый, уңыш бирми андый агач, кәүсә генә кала тырпаеп. Нәсел тамырына чабылган эз дә үзенекен итә — нәселне корыта, студент!

— Болар белән ни әйтергә телисең, абзый кеше? Әтиеңнең үчен авыл малайларыннан алдым дипме?..

— Ничек телисең, шулай аңла — синең эш! Тик шуны бел: синдә эт кайгысы. Ә без кешене дә эттән болайрак күргән заманда үстек.

— Кем гаепле? Минме?!.

— Гаепләне эзләмик, студент, юкса яшәргә ара калмас.

— Кешедән башкаларның үчен алыргамы?!.

— Алама сорау бирәсең, студент. Үч алу-алмау турында түгел сүз. Язмыш шундый безнең — буталган, болганып-тулганып беткән, гаепләмә безне! Тамырлар өзелгән безнең болай да...

— Үзең бар! Улың! Тагы нинди тамыр?!.

— Кабатлап әйтәм, студент, тамырлар өзелгән! Шәхес культы корбаннары чыгарып атылган әткәйләр белән генә чикләнми, ул — без, безнең дәвамнар — һәммәбез культ корбаннары!

— Мин дәме?

— Син дә корбан! Тамырың булганга охшамаган синең дә!

— Дөрес түгел! Син үзеңне аклау өчен генә сөйлисең боларны! Мондый коткы таратырга хакың юк синең, тукта!

— Юкса телемне тартып өзәрсеңме? Булмас! Өзелгән тамырларны яңартып булмый ул, туган! Йөзәрләп, меңәрләп атканнар безнең әтиләрне, каберләре дә калмаган җир өстендә. Телем дә, денем дә калмаган минем, студент!

— Тукта, сөйләмә...

— Эт атучыга закон юк, тыңла, студент! Уйлан! Галимҗан Ибраһимов булган. Нәселе кайда?— Юк! Шамил Усмановның?..— Юк! Фәтхи Бурнаш?..— Юк! Җамал Вәлидинең?— Юк!.. Кемнәредер яшәп ятсалар да, бел, студент,— нәселләре тамырсыз бу бөекләрнең! Каберләре юк! Нәселләре юк! Син — шулар оныгы, студент. Шуңа йөзеңдә бәхетсезлек синең. Эттә түгел хикмәт, этеңә кадәр үк иманыңны корытканнар. Шуңа җиреңнән, авылыңнан, туганнарыңнан аерылып, ялгыз каңгырап йөрисең син шәһәр җирендә!

— Тукта, Эт атучы! Син миңа кагылма, минем йөзгә чыккан бәхетсезлектә эшең булмасын! Селтәнсәләр, син селтәнең безнең бәхеткә иң беренче булып. Син!..

— Ярар, туктыйм! Туктадым...

Сүзендә торды Эт атучы — икесе дә тынып калдылар. Өй эчендә янә буш китап киштәләрендә хөкем сөргән моңсулык, ятимлек тантана итте. Фидаилнең колак төбендә аның саен Эт атучы авызыннан чыккан сәер, яман сүзләр яңгырап торды: «Тәнгә ясалган җәрәхәттән җөй кала... Тамырга чапсалар — нәсел корый!..» Ә аның, Фидаилләр нәселенең шулай таркалуына кем гаепле соң?! Әтисен чыгарып атмаганнар, кем гаепле?..

Шактый газапланды ул, Эт атучы сүзләреннән соң туган буталчык сорауларга җавап эзләп. Табылмады җавап. Ул дөньяга ачулы, шуңа ләгънәтле дөньяны. Әмма дөнья андый түгел, дөньяда бәхетлеләр дә бар! Димәк, хаклы түгел ул...

Шактый тынычлана төшкәч, сорап куйды Эт атучыдан:

— Малай бар диден... Кайда соң ул? Нигә өйдә түгел?..
Сорау кәтелмәгән булып чыктымы — сискәнеп куйды хуҗа кеше.
— Улыммы?..
— Әйе, малай бар дигән иден...
— Малайны укыттым. Медицина институтын тәмамлады.
— Әнә ич, ә син тамыр дисең... Улың врач булган, начар түгел ич.
— Түгел! Һөнәре әйбәт иде дә бит...
— Үзеннән рәт чыкмадымы әллә?
— Алай димим...
Хуҗа, ни өчендер, улы хакындагы сүзен сөйләп бетермәде. Хәер, Фидаил белән үзе арасындагы мөнәсәбәткә аның ни катнашы булсын?! Болай да сүз аз булмады.
Фидаил, ниндидер эчке бер кызыксыну белән, өстәл почмагында яткан фотоальбомга үрелде янә. Аның соңгы битен ачты. Озак кына андагы яшь, таза, төз гәүдәле һәм киң маңгайлы егеткә карап торды... Әйе, кайдадыр күргән сыман тоела ул аңа, йөз чалымнарымы, гәүдәсеме — кай төшләредер таныш та кебек. Кайдадыр күргәне дә бар сыман... Ләкин кайчан?.. Кайда?..

## 29

Каурыйлары йолкынып, канатлары таланган, бәпкәләреннән аерып алынган ялгыз ана үрдәк хәлендә торып калды Асия... Тегє көнне шундый зур өмет һәм ышаныч белән барган иде бит ул Арсланның эшенә. Гомеренең иң житди, хәлиткеч мизгеле килеп житкәнлеге, үзенең бу адымы соң дәрәҗәдә вакытлы һәм әһәмиятле булачагына аз гына да шикләнми барган иде. Гүя, атлап түгел, канатланып, очынып барган иде. Шулай килеп чыгар дип кем уйлаган бит аны...
Арслан аны аңламады... Аңлау кая, хәтта тыңларга да теләмәде. Бар хыял, өметләрен аяк астына салып таптады ул аның... Мәсхәрә итте...
Кире борылырга да соң. Күперләр яндырылган, үткәннәргә кайту мөмкин түгел. Дөрес, Фидаил дәшми әлегә. Дәшмәве белән газаплый ул аны.Ниләрдер уйлый. Ниндидер планнар кора, күрәсең. Ничек итеп һәм ни рәвешле аңардан үч алу турында уйланамы?.. Тыныч күлнең төбендә нәрсә булганын каян беләсең?.. Тыныч күл төбендә корт мыжгый торган була диләр... Үзгәрде, танымаслык булып үзгәрде Фидаил. Бер сүз дәшми, сөйләшми ул аның белән хәзер. Карашлары кырысланганнан-кырыслана бара — үзгәрде. Ниндидер иске киемнәр әлеп, бер караңгыда чыгып китә дә өйдән, икенче караңгыда гына кайтып керә. Хәлсезләнеп, төсе бетеп кайта — ни кылып, кемнәр белән һәм ни эшләп йөри торгандыр — ходай үзе генә белә. Машинасын гел күрсәткәне юк өй тирәсендә...
Әле кайчан гына, Асиянең өйдә чагы булса, бер түгел, көнгә дүртбиш мәртәбәләр кагылып уза иде бит ул. Юк йомышын бар итеп, аны сагынып, Асиясен күрергә дип кайта торган иде... Үз янына тартылып, берәүлексез өйгә ашкынып торган ирнең кадерен бел икән аның! Әле хәзер, шушы хәлдә торып калгач кына аңлады моны Асия. Бер-беренә тартылып, аңлашып яшәүгә житәме соң?! Ләкин, болар хакында уйлауның файдасы юк инде хәзер. Соң! Буласы — булган, кыласы — кылынган, терсәкне тешләп булмый.
Тора-бара кичләрен дә кайларгадыр китеп югалалый башлады Фидаил. «Кая барасың, хет әйтеп кит, белеп торыйм?!» — дип дәшәсе, юлына каршы төшәсе килгән чаклары булды хатынның. Тик аның кызыксынырга, карышырга хакы бар идеме соң?.. Андый сорау бирергә ярамый, ул сорау аның үзен кыен хәлгә куярга мөмкин...
Фидаил каршында һичнинди хокукы калмады аның. Шушы көнгәчә дәшмәве, тавыш-гауга кузгатмавы өчен рәхмәт. Бу хәбәр эти-әни-

сенә житсә, күрше-күләнгә мәгълүм булса, ни эшләр иде?!. «Арсланны яратам. Ятратканга күрә очрашам Арслан белән»,— дип, һәр кешегә аңлатып йөреп булмый ич. Мең рәхмәт Фидаилгә! Шушы кыен хәлендә дә ир-ат булып кала алганы өчен рәхмәт...

Фидаилгә хәтта күңелендә хөрмәт хисе уянды аның соңгы араларда. Ул аны хөрмәт итте һәм кызганды. Аңарга нәни генә буса да яхшылык итәсе, ничек тә булса бер-бер ярдәм күрсәтәсе килде. Әмма ничек?.. Әлегә Фидаилнең хатыны санала саналуын. Ул китмәгән, Фидаил ташламаган. Бер түбә астында яшәп, бер урын-җир өстендә йоклыйлар. Биргә биргәсен, ләкин бу — рәшә сыман, мираж сыман вакытлы күренеш. Мондый яшәү, әгәр аны яшәү дип атарга ярасa, озак дәвам итмәячәк. Һәр яңа туган көн, һәр сәгать ерагайта бара аларның араларын. Күк йөзендә бер үк вакытта икесе ике тарафка атылачак йолдыз сыман ич алар. Очрашу бармы ул йолдызларга кабат?..

Арслан мираж түгел. Арслан — ул чынбарлык! Ул аның бүгенгесе. Кем белә, бәлки киләчәгедер дә әле?!. Дөрес, теге көнне таш сын кебек салкын каршылады ул аны. Шул таш сынга бәрелеп челпәрәмә килде, уалды аның өметләре. Арслан бөтенләй яңа яктан күрсәтте үзен. Әле кайчан гына кеше сурәтендә йөргән фәрештә, идеал иде бит ул аның өчен. Горур, кыю, тәвәккәл... Шулар өстенә кулыннан эш килә, һәркем санлаша, хөрмәт итә үзен. Капкаев һәм Борисларның ничек итеп аңарга ярарга тырышканлыкларын күреп хәйран кала иде. Ателье мөдире Әнзия Закировна да, ул дигәндә, биеп кенә тора. Лев Белялович булып ул да — Асия өчен билгесез югарылыкта булган җитәкче — Арслан дип өзгәләнеп тора. Серләрен аның белән бүлешә. Очраклымы болар?..

Шундый кешеләр бер сәбәпсезгә: «Арслан Сәхипович!..»— дип өзгәләнеп торырга теләрме?!. Үзен шундый дәрәҗәле, мәһабәт кыяфәт һәм гәүдәгә ия, кайгыртучан ир-ат яратканлыгы белән горурлана иде бит Асия. Дөрес, соң чиктә, Арслан да фәрештә булып чыкмады. Аның эш өстәле артында креслода ничек утыруы әле дә Асиянең күз алдында тора. Ул кергәндә, ботын-ботка атландырып, кресло аркасына башын салып кофе эчеп утыруы иде. Гүя үзе генә түгел иде ул кабинетында, кемдер аңарга сокланып карап торадыр иде диярсең. Үз-үзеннән канәгатьлекнең чиге-чамасы юк. «Менә мин кем! Кем белән эш иткәнлегегезне онытмагыз!..»— дия иде сыман аның югары чөелгән киң ияге һәм алсуланып торган канәгать, тук яңаклары... Ул килеп кергәч тә, әллә нәрсә булды Арслан белән. Кыбырсырга кереште, кулларын, күз карашын кая куярга белми тынгысызлана башлады. Бүлмәдә үзләреннән башка һичкем юклыгы мәгълүм булса да, әледән-әле, кеше-кара күрмиме дигәндәй, як-ягына карангаларга кереште. Чираттагы һәр хәрәкәтен ясаганда, һәр сүзен әйткәндә, сагаеп, ишек тоткасын күзәтте... Ә инде арт ягы белән суга чумарга җыенган үрдәк сыман, чигенә-чигенә креслосына таба китүләре башка сыймаслык күренеш иде. Әйтерсең, кемдер аны тартып алырга җыена, ә хуҗасы бирергә теләми... Хәзер — яңадан кайтып искә төшергәндә — әле көлке, әле кызганыч тоела Арсланның шул чактагы кыланышлары.

Арслан Фидаил түгел инде барыбер. Фидаил дә Арслан түгел! Фидаилнең югалтыр креслосы юк югын да, әмма шул хәлдә торып калса, ул барыбер башкача тоткан булыр иде үзен. Хәер, нигә гөманларга. Фидаилне Арслан урынына куеп буламы соң?!.

Гүя ике яр арасында, зур дәрья уртасында япа-ялгызы торып калган иде Асия. Кая карарга, кай тарафка борылырга һәм кайсы ярга таба колач җәеп йөзеп китәргә белми икеләнеп калган. Бер ярда — Фидаил, икенчесендә — Арслан. Ә ул дәрья уртасында. Шаулап, ярсып аккан язгы ташкын уртасында гүя. Су тирән, тирәнлек үзенә тарта. Агым көчле — түбәнгә өстери. Ә аңарга батмаска да, акмаска да кирәк. Ләкин шунысы гаҗәп: ике яр да аңардан читкә этәрелә, ераклашканнан-ераклаша бара һәр мизгел саен. Ник бер ярдан кул изәүче, үз ярына чакыручы

булса икән. Кай ярга йөзәргә тиеш ул, ялгышмаска, сайларга һәм йөзәргә тиеш, йөзәргә... Дәрья уртасында чарасыз тора алмый башкача, вакыт үтә, хәл бетә беләктә. Агым өстери, су тирәнлеге аякларын төпкә тарта. Беләкләре хәлсезләнгәнне тоя ул, аякларны көзән җыерырга итә, тәндәге көчне су суыра...

Кем әйтер, кай тарафка йөзәргә соң аңарга?!. Актарылып-ургылып аккан бу дәрьяны ялгыз башы кичәр көч калганмы аңарда?..

## 30

Арысланнар өере һәм кенәриләр төркеме янә ярымутрауга җыйналды. Сый-хөрмәт тутырылган картон тартмаларны, гадәттәгечә, күтәрерлек түгел иде. Капкаевның тез буыннары сыгылып-сыгылып куйды үзләрен бушатканда. Кайсыдыр тартмада, без монда дигәндәй, серле генә челтерәшеп, шешәләр аваз бирде. Шешәләрне, шулай, яшереп йөртәләр хәзер — почет кимеде аларның. Әмма дәрәҗә төшмәде, артты гына төсле дәрәҗәләре... Эмаль чиләк эчендә яңа суйган бәрән ите күперә. Уксус, борыч, лавр һәм суган белән катышып, борын тишекләрен, сулыш юлларын кытыклап торган шул ит исе арысланнарның канын кайнатты...

Дөрләп учак янып китте. Тиздән күмере дә төшәр каен утынының. Борис укалы кәгазьгә төреп хәстәрләнгән шампур тимерләрен шылтыратып алды...

Юк эшләрен бар итеп, алларына җим салганны көтеп йөргән кенәриләр арасында Асия дә бар иде. Шактый дәшми, очрашмый торганнан соң, Арсланның гел көтмәгәндә үзе артыннан машина җибәрүе, әлбәттә, сәер тоелды аңа. Соңгы вакытларда инде кабат очрашудан өметен өзгән иде. Ул эзләп килмәячәк, үзем дә тагы бер тапкыр юллап бара алмыйм дигән уйлар белән ялгыз башы иза чиккән тәүлекләре иде. Арслан аның мәхәббәте генә түгел, нәфрәтенә дә әверелеп килгән көннәр, очраша калсалар сәламенә дә җавап кайтармаска дип антлар бирелгән... Ә шулай да ул монда — арысланнар һәм кенәриләр арасында.

Бүген төштән соң цехларына ательe мөдире килеп кергәч тә йөрәге сулкылдап куйды аның. «Миңа гына булсын иде... Арслан?!. «Профсоюз» киңәшмәсенәдер бәлки?..» кебек уйлар килде аңа бер мизгел эчендә. Урыныннан сикереп торып, ишектән керүче Әнзия Закировнаның каршысына чак кына атылып чыкмый калды. Тегесе исә, дөньяның анысын-монысын күргән хатын буларак, махсус сузды, махсус көттерде. Кинәт кабынган өмет инде тәмам сүнде дигәндә, ательe мөдиренең яңгыравык тавышы ишетелде:

— Асия, син кайда?.. Сиңа — киңәшмәгә!..

Бар кешегә ишетелерлек итеп, махсус кычкырып әйтте ул бу сүзләрне — бер дә яшерен эш белән шөгыльләнмибез янәсе — «гласность» заманасы хәзер. Ә инде күзләрендә өмет чаткысы кабынган Асия янына килгәч, иелә төшеп, башкалар күрмәгәндә генә, үз итеп, аның ботын чеметеп алды. Колагына пышылдады:

— Чатта машинасы көтә...

Ничек урыныннан кузгалганын һәм ни рәвешле, ничек атлап үзенең чыгып киткәнлеген хәтерләми иде Асия.

*

— Кенәриләр, сезне сауна көтә! — дип оран салды Капкаев. — Тиз булыгыз.

Соңгы араларда шактый гына югалып торган Гуля да килгән иде бу юлы. Кенәриләр килә, китә, бу ярымутрауда андый гына хәлләр, гомумән, булгалап тора. Гаепкә алынмый

Гуля-Гөлсинәнең янә араларына килеп эләгүе, әлбәттә, башка кенәриләр өчен көтелмәгән яңалык булды. Берәве дә көтмәгән иде үзен. Һәммәсе яхшы хәтерли: әле кайчан гына Лев Белялович ничек котылырга белми иза чигә иде аңардан. Менә сиңа мә, Гуля-Гөлсинә берни булмагандай янә игътибар үзәгендә, табын түрендә. «Логика кайда?» — дип әйтергә теләүчеләр булыр. Ул нинди логика — арысланнар һәм кенәриләр мөнәсәбәтендә логика була димени?!.

Кенәриләр арасыннан Гуля-Гөлсинә генә килешергә теләмәде Капкаевның тәкъдиме белән:

— Мин монда мунча керергә килмәдем лә,— диде ул турсаеп.— Подумаешь, Капкаев...

— Әйе, мин — Капкаев,— диде авызы колагына җитеп килгән ир-ат.

— Булсаң соң?!.

Янә җавап шул ук:

— Капкаев!

— Нәрсә син, ватык пластинка кебек, Капкаев та Капкаев,— дип бәйләнде үзенә Гуля. Чакматаш сыман, кагылмас борын ук очкын чәчеп тора. Сабырлык — юк, темперамент — чик-чамасыз, нервлары да нык какшаган, яшенә күрә түгел бер дә.— Син кем булдың әле, миңа приказ бирерлек, ул кадәр?!.

— Капкаев,— булды җавап. Үзенә ничек һәм ни рәвешле генә бәйләнмәсеннәр, кәеф төшми ич аның, күтәрелә бара. Шундый ул безнең гастроном директоры.

Ә Гуля-Гөлсинә сүз көрәштерүнең тәмен, рәтен белә:

— Кем соң син, Капкаев?!.

— Капкаев!

— Исемең ничек?

— Капкаев!

— Әтиеңнең исеме?

— Капкаев...— Ә үзе көлә, авызын җыеп ала алмый көлә Капкаев. Үзенең тапкырлыгына хәйран калып көлә.

— Фамилияң дә Капкаевмы?!.

— Каян белдең — Капкаев!

Берни аңлый алмыйм, дигән сыман, сәерсенеп торды кенәри. Һәм җитдиләнә төшеп сорады янә:

— Кайсы милләт вәкиле соң син, ә, Капкаев?!.

— Капкаев! Милләтем дә Капкаев.

Гомер уртасыннан узып барган ир-атның шундый сәерлеге, кемгә-кемгә, хәтта Гуля-Гөлсинәгә сәер тоелды. Кызганулы караш ташлады ул аңарга:

— Үзеңнең кем булуыңны оныттыңмы?!.

— Ә үзең кем?

— Мин — Гуля-Гөлсинә! Исемем бар, кирәксә фамилиям, милләтем дә бар...

— Мин — Капкаев,— диде гастроном директоры янә бер кат һәм үз-үзеннән канәгать булып кычкырып көлеп җибәрде.

Әлеге мәгънәсез әңгәмә, кем белә, бәлки әле озак дәвам иткән булыр иде. Лев Белялович тавышы бүлдерде үзләрен:

— Капкаев!..

— Әйе, Капкаев!

— Син нәрсә анда, өстеңә төшкән йөкләмәне җитмеш биш процентка гына үтисең?!.

Сүзнең ни хакында барганлыгына шундук төшенде Капкаев. Саннар һәм процентларга чос кеше ул, гомумән. Авызын ерды рәхәтләнеп. Ник ермасын авызын, Лев Белялович шаярта, димәк, кәеф начар түгел «шеф»ның. Андый чакта рәхәтләнеп ерырга була авызны...

— Җитмеш биш түгел, Белялович... ун проценты гына калды.

Гуляның башка өч кенәригә караганда шактый ук җыйнак гәүдәле булуына ишарә иде бу. Ир-атлар, кызык табып, дәррәү көлешеп алдылар. Гуля-Гөлсинәнең генә исе китмәде артык.

— Сезгә шул коровалар гына булсын! — диде ул, аларның үзләреннән көлеп.— Нәрсә аңлыйсыз соң сез?!.

Лев Беляловичка бигрәк тә кенәриенең тапкырлыгы ошап куйды. Ни генә әйтмә, үз кенәрие — үзенеке инде:

— Ишеттегезме?!. Ишеттеңме, Капкаев!..

Кенәри дә, күңеле булып, үзенең яклаучысы кочагына ташланды:

— Җыен надан, шулай бит, ә Лева?.. Авыл мокытлары, берни аңламыйлар, ә телләренә салыналар!

— Ә син аларга үпкәләмә, Гуля,— диде карт арыслан, күңеле булып.

— Капкаев та телен тыйсын! Юкса минем белән ничек сөйләшергә икәнлекне күрсәтермен үзенә. Бер генә тибәрмен!.. Беләм мин кая тибәргә икәнлеген...

Төпчек кызын юаткандай, ягымлы итеп чәчләреннән сыйпап куйды Лев Белялович:

— Кызма әле син, тынычлан, Гуля...

Кенәриен мунча ишегенәчә, юата-юата, үзе озата барды ул. Ирләрчә сүз булганын, шуңа үзләрен генә калдырып торырга кирәклекне аңлатты берочтан.

Житди сүз алдыннан ирләр дүрт борынга бер «Золотое кольцо» бушаттылар. Тел өстенә бер кашык кара уылдык салган Лев Белялович иреннәрен чәпелдәтеп куйды да Капкаевка мөрәҗәгать итте:

— Капкай дустым,— диде ул аның аркасына кулын салып.— Житди сүз алдыннан берне җырлап аласыңмы әллә!..

Белялыч үзе сораганда җырламый буламы соң, авыз гармунын бер шыгырдатып алды да кычкырып җырлап җибәрде Капкаев:

Барган идем Эсмаларга,
Кер чайкый басмаларда.
Барыбер сөям шул Эсманы,
Колактан ассалар да...

Аның карлыккан тавышыннан Лев Белялович үзе үк сискәнеп куйды хәтта. Баш очындагы наратлардан узган елгы күркә егылып төште, кошлар дәррәү кубып очып китте. Күл читенә чыгып кунаклаган бакалар кире суга сикерде. Җырласа җырлап күрсәтә инде ул Капкаев. Дәррәү кул чапты арысланнар, авызлар ерылды:

— Булдыра да соң безнең Капкаев!..

— Молодец, Капкаев!..

Капкаевның баш күккә тиде... Авызының да кай тирәдә булуын чамалыйсыз булса кирәк. Бәхет тулы күзләрен хуҗа кешегә төбәде ул:

— Мин бит әле, Белялыч, өр-яңа җыр өйрәндем!.. Анысын да җырлап күрсәтимме?

— Әйдә, Капкаев,— дип күтәреп алдылар үзен.

Изүләрен ачып җибәрде Капкаев — җырның өр-яңасын башларга җыена иде ич. Тынлык урнашты урман аланында.

— Тыңлагыз,— дип кычкырып җибәрде кинәт башкаручы.— Өр-яңа җыр, тыңлагыз:

Айга менә, айга менә,
Айга менә көтүче.
Мин дә айга менәр идем
Юк артыннан этүче...

Баягы көлү көлү булмаган икән әле ул. Баягы кул чабулар, баягы канәгатьлек чүп кенә булып калды. Урыннарыннан сикереп торды арысланнар... Креслоларында тәгәри-тәгәри көлделәр... Аеруча ошатканы Белялыч иде. Буылып-буылып көлде ул, күзләреннән яшь акты үзенең...

Жыр шәп чыкканын үзе дә белә иде Капкаев, шуңа, иреннәрен ялаштырып, тик елмаеп торды бер читтә. Сораучылар үтенечен канәгатьләндереп, тагы бер кат жырларга туры килде... Янә көлештеләр.

— Молодец, Капкаев,— диде Белялыч. Һәм шундук, житдиләнеп башкаларга да мөрәжәгать итте.— Дус-ишсез, әшнәсез яшәп булмый хәзер дөньяда. Капкаевның бу жыруын киртләп куегыз күңелләрегездә. Артыннан этүче, янсә кул сузып торучысы булса, шулай әнә, көтүче дә айга менә торган заманда яшибез. Ә ялгыз башың, ник шунда пәйгамбәр булмыйсың, берни майтара алмыйсың. Йә йолкып төшерәләр, йә тибеп очыралар, урмәли башласаң.

— Безнең дуслар житәрлек, шулай бит, Белялыч!— дип бүлдерде үзен әлегәчә жыр дәртеннән чыга алмый торган Капкаев.— Арттан этүче дә, кулдан тартучы да бар безнең, шулай бит ә, Белялыч?!

— Ашыкма,— дип, кулын күтәрде өлкән арыслан.— Сүземне тәмамларга ирек бир. Фамилияң Капкаев булса да, капканың юк әле синең.. Ә кабуың бик ихтимал, синең ишеләрне тиз каптыралар хәзер! Каптың исә, дусларыңнан жилләр исә — дөнья шундый, Капкаев, артык беркатлы булма! Берүзең, сыңар башың торып калачаксың!

Пошаманга төште Капкаев — нигә мондый сүзләр?!. Каршысында утыручыларга берәм-берәм карап чыкты ул күзләрен мөлдерәтеп:

— Сез... Сез дуслар түгелмени?!. Сез бар ич, Лев Беляловнч... Арслан Сәхипович бар... Борис...

— Шул шул, Капкаев, дусларның кадерен белер чак житте! Газета укый торгансыздыр... Күрәсездер... Нидер мәтәштерергә жыеналар анда — Мәскәүдә!— Бармагын югары төбәп торды ул байтак кына, шомлы карашы белән, барлагандай, дусларын күзәтеп чыкты.— Нидер мәтәштерергә жыеналар... Революция диләр әнә... Күпкә бармас баруын, әмма мәтәштерәләр!

— Ну, как укымаска! Укыйбыз гәжитне... Укыйбыз, Белялыч,— дип, сүзгә кысылырга ымсынып алды Капкаев.

— Укуың әйбәт,— диде карт арыслан сүзен дәвам итеп.— Укыгач, күрәсеңдер, синең ишеләрне бер-бер артлы каптырып кына торалар хәзер. Көнбагыш ярган сыман! Черт итәләр дә төкерәләр. Бар иде Капкаев — инде юк Капкаев!

— Жылатасың, Белялыч... Жылатасың, сөйләмә алай, Капкаев бар, Капкаев булачак диген, Белялыч!

— Ярар,— дип, сынаулы карашын Капкаевка төбәп торды сөйләүче озак кына.— Әйтик, менә сине гастроном коллективы күпчелек тавыш белән сайлап куяр идеме?!. Дөнья шундыйга китте хәзер, сайлап куярлармы?!.

— Какой такой сайлау!.. Әлегә мин директор! Алар мине түгел, мин аларны сайлыйм, телим икән — алам, ошамаса — куып жибәрәм... Сез нәрсә, Белялыч!.. Куркытырга телисез?!.

— Куркытмыйм, Капкаев. Мин сиңа сорау бирдем: коллектив үзеңне сайлармы, дим?..

— Сайламый, кая барсыннар,— дип, иркен сулыш алды Капкаев.— Торгның бар дефициты минем кибет аша үтә. Дефицит бар икән, димәк, аларга да өлеш чыга, аларга да керем бар дигән сүз. Һәркемнең тәмле ашыйсы, матуррак яшисе килә, Белялыч!

— Ә дефицит каян килә инде?..— дип, конфет суыргандагыдай итеп, тәмләп сорау бирде Лев Белялович.

— Берәүне дә рәнжеткән юк, Белялыч. Аларны да өлешсез итмибез.

— Шулай да...— дип, сүзне башка тонда, тагы да житдиләнә төшеп дәвам итте Белялыч.— Койрыкларны жыя, нәфесләрне тыя төшәргә туры килер, арысланнар... Ишеттеңме, Капкаев?!.

— Вәт, тагы... Тагы Капкаев,— дип, гел-гел үзен мисалга алуга үпкәләде гастроном директоры. Иңбашларын сикерткәләп куйды.—

Алайга китсә, Белялыч, үзгәртеп коруның аның минем өчен бер кыенлыгы юк. Хет бүгеннән үзгәрәм. Мин нәрсә, урлашмый гына да яши алам мин. Акча җитәрлек миндә, тотам да коры зарплатага яши башлыйм — берсеннән бер тиен алмыйм!— дип, тынгысызланып, шап-шоп кесәләренә суккаларга кереште.

— Бай кеше акча белән мактанмый,— дип әйтеп куйды моңарчы дәшми генә уйланып утырган Арслан.

— Арслан Сәхипович дөрес әйтә,— дип җөпләде карт арыслан.— Тагы шуны әйтим: бер йодрык булырга кирәк хәзер. Дуслар өчен дә җаваплылык тоеп эшләргә! Дус-иш кадерен белер чак җитте! Берочтан юк-бар өчен конфликтларга керү ярамый, салпы якларына салам кыстырып, кешеләрнең күңелен күрә белергә... «Исәнме-саумы?.. Хәлләр ничек?.. Бик әйбәт...»— диешеп йөри торган таныш-белешең ишлерәк булу зыян итми. Җанны ачмыйсың, авызны ачыбрак исәнләшсәң, шул җитә андыйларга... Обстановка шуны таләп итә хәзер, сайлый калсалар — шулар хәл итәчәк — «Исәнме-саумы?.. Хәлләр ничек?.. Бик әйбәт...»— дип йөрүчеләр.

Лев Беляловичны борчыган бу сораулар башкаларны да уйландыра иде соңгы араларда, шуңа тын да алмый тыңладылар дәрәҗәле кеше киңәшен. Ул сөйләүдән туктагач та чебен очкан аваз чыкмый торды.

Ә сүзне яңартучы Арслан Сәхипович булды:

— Бу оҗмах бакчасын нишләтәбез, Лев Белялович?..

— Оҗмах бакчасынмы?..— уйга калып торды карт арыслан.— Оҗмах бакчасы — төзелә торган объект әлегә. Шулай да, Арслан Сәхиповичның соравы урынлы, монда йөрүләрне дә сирәгәйтергә туры килер...

— Объект әлегә тәмамланмаган,— дип ачыклык кертергә ашыкты Капкаев. Әйтерсең аның авызына кергән майлы калҗаны тартып алырга җыеналар.

— Төзүчеләр теңкәгә тиеп беттеләр... Объектны тапшырырга кирәк диләр, артык сузып булмый,— дип җөпләде бу эшкә иң якын мөнәсәбәте булган Борис.

— Ә кенәриләр?!— дип аваз салды хафага төшкән Капкаев.— Кенәриләр шундый ошата безнең бу оҗмах бакчасын.

— Нәфсеңне тыярсың!

— Хы, нәфсеңне,— дип, борчылуын дәвам итте Капкаев.— Ярый ла син алтынчы дистә белән барасың...

— Әй, Капкаев, Капкаев, берни аңламыйсың син!... Беләсең килсә, йөрәк картаймый ул, Капкаев! Арысланнар да чабып барган килеш үлә! Белмисең син, берни аңламыйсың, Капкаев... «Эх, егетләр,— дип кычкырасы килгән чаклар була кайчак,— ник без картайган саен, кызлар яшәрә, чибәрләнә бара икән ул!»— дип.

Капкаев аңлады, каршы сүз әйтмәде, үзалдына офтанып кына куйды бары:

— Кемгә кирәк булды, кем уйлап чыгарды шул «үзгәртеп кору» дигәннәрен!..

Борис әңгәмәгә тагы да җитдирәк яңалык кертүне кирәк тапты:

— Кичә генә ниндидер кешеләр йөргән койма тирәсендә. Җантимер кертмәгән үзләрен.

— Кемнәр булды икән?

— Төзүчеләр булса кирәк...

Арсланны бөтенләй башка сорау борчый икән әнә:

— Ә Җантимер?!. Җантимерне кая куябыз?..

Капкаевны да битараф калдырмады әлеге сорау:

— Җантимер мине таный. Җантимер безнең һәммәбезне таный. Җантимер безне сатачак!..

— «Пароль»не кызганасыз,— дип шелтәләп алды үзләрен Лев Белялович. Аны да уйга калдырган иде ахры Җантимернең дөньяда барлыгы.

— Җантимерне монда калдырып булмый, Белялыч,— диюче Борис иде.— Үзе дә, этләре дә — имансыз! Калдырырга ярамый!..

— Нишләтәбез?

— Шифаханәгә озатыргадыр бәлки?..

— Карарбыз,— дип җөпләп куйды, тынычландырды үзенең әшнәләрен карт арыслан.— Соң чиктә, аның монда булуын белүче юк!..

— Сез нәрсә, Белялыч!..— дип, колагы ишеткәннәргә ышанмыйча, күзләрен түгәрәкләндерде Капкаев.

— Ә син борчылма, Капкаев. Булмаса, бер җырлап җибәрсәңме әллә?!

Ул да түгел, авыз гармуны чыелдап аваз бирде:

Айга менә, айга менә,
Айга менә көтүче...

Күл ягыннан бәхетле черкелдәшеп кенәриләр төркеме менеп килә иде...

## 31

Күңел биреп сөйләшер сүзләре дә калмаган кебек югыйсә, ә аяклары Кабан күле читендәге Мәрҗани урамына тартты Фидаилне. Нигә килә ул монда, нәрсәсен югалткан? Үзе дә белми, килә. Күл читенә сыенып утырган шушы тын урамда, юкә һәм өрәңгеләр ышыгына елышкан ике катлы иске тыйнак өйдә, әйтерсең, үзен зарыгып көтүче бар.

Көне буе бергә бер вагоннан йөк бушатып та, үзара сөйләшмәделәр. Ә кич җиткәч, тагы аның ялгыз фатирына килде. Өч тарафтан шәрә китап киштәләре уратып алган бүлмәдә утыралар. Өлкәне сөйли. Яше тыңлый. Икесе ике ноктага төбәлгәннәр, йөзләре чытык үзләренең. Гаҗәп күренеш иде бу бер читтән карап торсаң...

— Малаймы?..— дип кабатлап сорады Эт атучы Гыйлем. Теләр-теләмәс кенә сүзен дәвам итте.— Үзең күреп торасың, әткәйнең өметен акламадым. Гыйлем иясе итеп күрәсе килгән дә бит, барып чыкмады. Исемемнән ояла идем кайвакытларда. Ә шулай да ошый ул миңа — исемем. Әнием күк, авызларын тутырып, ягымлы һәм җылы итеп, ник берәрсе дәшсен икән үз исемем белән «Гыйлем» диеп... Исемемнән элегрәк кушаматларымны белеп, ишетеп өлгерәләр... Син дә качасың үз исемем белән дәшүдән... Белсәң иде, студент, кайчакларда шундый ишетәсем килә үз исемемне... Аңлата гына алмыйм, аңламыйсың син моны барыбер. Шундый матур, мәгънәле исем кушкан миңа әти белән әни... Гый-ле-ем,— дип, иҗекләп сузды ул үз исемен.— Шул исемдә әти белән әнинең акланмаган өмете, ышанычы саклана икән ич. Юк, бер дә эт атучы булсын дип дөньяга китермәгәннәр алар мине. Гыйлем иясе булсын дигәннәр...— Хәл алгандай туктап торды бераз. Сөйләнгән сүзләрен янә бер кат күңеленнән кичереп чыкты булса кирәк.— Малай... диден бит әле. Була, аның турында да сөйләргә була. Туган көненнән үк бердәнбер яшәү максатыма әверелде ул минем. Үзем ирешмәгәннәргә ирешсен, үзем кызыгып та күрә алмаганнарны күрсен, ашасын, белсен, өйрәнсен дип тырыштым мин аның өчен. Кимсенмәсен, рухы сынмасын ди-ди тартыштым дөнья белән. Үз әнисен күрмәгән, хәтерләмәгән баладан да кызганычрак кем булырга мөмкин?! Әнисез үсте. Ата гына түгел, ана да булырга тырыштым үзенә, кеше алдында ким-хур итмәдем.

Башын күтәрә төшеп, Фидаилгә текәлеп торды ул бер мәл. Әле ге дә баягы шул фотоальбомны кочаклап утырган «студент», аның карашын тоепмы, җанланып алды.

— Улыңны ким-хур итмәү өчен...— дип кабатлады ул, сөйләүченең кайда тукталуын искәртеп һәм ашыктыра төшеп.

Хәер, аның тел төбендә ни чагылганын дөнья күргән кеше шундук аңлап та алды:

— Әйе, эт атарга да мәҗбүр булдым... Әйбәт түлиләр иде... Шабашка! Мәҗбүр итмәделәр, бәйләп җибәрмәделәр — дөрес анысы!

Хуҗаның сүзләрендә үкенү, яшәлгән гомер, кылган эшләреннән канәгать түгеллек чагыла иде. Авызыннан чыккан һәр сүз, һәр хатирә күңелен тырнап, үзе генә белгән нниндидер җан җәрәхәтләренә кагылып уза иде сыман аның...

Фидаилнең үз шөгыле — фотоальбом битләрен ачып-ябып утыруында дәвам итте һаман. Андагы һәр рәсем, йөзләр таныш сыман иде инде аңар. Кайсы рәсем артыннан кайсысы килгәнен дә яттан белә. Ә үзе һаман актара, аерыла алмый серле фотоальбомнан, кайбер битләренә тукталып, озак кына текәлеп карап тора. Үзен биләп торган сорауларга җавап таба алмый, җавап эзли ул борөзлексез:

«Оренбургта татар журналы чыксын инде, ә?!. Язучылар, журналистлар һәм галимнәр яшәсен... Кайберләренең исемнәрен дә хәтерли башлады бугай инде: Риза Фәхретдинев... Фатих Кәрими... Дәрдмәнд... Җамал Вәлиди... Һәм тагы әллә кемнәр... Өй кыегына кунаклап гөлдер-гөлдер килгән пар күгәрчен сыман бер-беренә башларын кынгыр салган ата белән ана! Икесе дә — галим, укытучылар, укымышлы кешеләр... Ә уллары — Эт атучы... Һәм тагы, таныш та, түгел дә сыман тоелып, берөзлексез аның күз алдыннан китмәгән яшь егет — Эт атучының улы. Ничек шулар һәммәсе бер альбомга сыя алган? Ничек итеп бер нәсел җебен дәвам итүчеләр шундый капма-каршы язмышка ия?.. Башка сыярлыкмы шул?!. Бу нәрсә, саташумы?.. Саташу икән, кем саташа? Улмы, башка берәүме?.. Әллә тарих үзе саташканмы?!. Эт атучының «язмыш» диюләрендә, «тарихка» сылтауларында бер-бер хикмәт, ул күз алдына китермәгән сер бармы әллә?!.»

— Малай тырыш иде,— дип дәвам итте Эт атучы Гыйлем. Фидаилне өчсыз-кырыйсыз уйларыннан йолып алды ул беразга. Кабаланып-ашыгып сөйләргә керешге.— Мәктәптә дә гел яхшы укыды... Укуын тәмамлагач, медицина институтына барып керде... Сүземнән чыкмады, әйбәт кенә тапшырды экзаменнарын да... Гел күз-колак булып тордым үзенә. Миңа киңәш бирүче булмады үз вакытында, ялгышларымны улым кабатламасын дидем. Үзем иртә өйләндем, ахмак. Син дә ерак китмәгән күренәсең, хатын бар дидең, малай... Вакытсыз өйләнгән ир аттан да ахмаграк кем булсын!

— Мин бала-чага түгел, утыздан узган. Студент та түгел идем...

Тыңламады хуҗа, аның сүзләренә колак та салмады.

— Ярар, студент,— диде.— Өйләнгәнсең икән — синең эш беткән! Йөк бушатырга калгансың әнә, шулай шул, хатын-кызга аңа акча кирәк... Кызлар кайгысы кая,— дус егетләре дә булмады улымның, көнтөн укыды. Врачлар алты ел укый икән бит... Үзең кайсы институттан соң әле?..

— Студент түгел идем. Гади шофер мин, шофер!..

— Машина йөртә белүең дә әйбәт... Күреп торам — син медицинскийдан түгел. Синең ише егетләр мал врачлыгына яисә сельхозда укый. Ярар, кайда уку анысы синең эш! Укып-укып та сөрхәнтәй булып калучылар күбәйде хәзер. Диплом бар, ә эшлиселәре килми... Син андый түгел, күреп торам. Җилкәгә салып йөк бушаткан ир-ат кадерен җибәрми дөньяның... Кешене аны, иң элек, бер-ике ел авыр йөк ташытып яисә җир казытып сынарга кирәк. Кара эш эшләп караган кеше, җилкәсендә, уч төпләрендә сөяле булган кеше башкаларның муенына менеп атланмый. Сөрхәнтәй булмый беркайчан да...

«Сөрхәнтәй» сүзен ишетү кызык булып китте авылда үскән егеткә. Кайчандыр колакка чалынып та, онытылган сүз!

— Улың сөрхәнтәй булып чыктымы? — дип сорап куйды ул Эт атучыдан.

— Сөрхәнтәйдерме, юкмы — әйтә алмыйм. Рәт чыкмады төсле малайдан. Әйбәт кенә эшли дә башлаган иде. Хәтта аспирантурага кергән иде башта. Кулдан ычкындырдым шайтанны... Юаштан юан чыга дигән сыман, әллә кай арада гына юлдан язган кешеләр чорнап алды үзен. Өйдә күренсә — күренде, күренмәсә — юк.— Шул урында бүленеп, карашы белән өйне айкап чыкты ул.— Күрәсеңме шүрлекләрне?.. Малай эше! Ике мең ярым том китап бар иде. Бабасы җыйган китаплар... Ул ташып бетерде. Әни белән, сугыш елларында да, ачлы-туклы яшәгән чакларыбызда да кагылмаган идек үзләренә. Сорап килүчеләр, укып кына торырга дип гозерләүчеләр булды — кагылмадык, кузгатмадык. Әти төсе дип саклadык.

Кырык өченче ел иде бугай. Кыш бик салкын иде. Ягарга — утын, ашарга икмәк юк. Әнине эштән каршыларга дип чыксам, үзебезнең өй каршына бер абзый килеп туктады. Чана тартып килгән. Ә чанасында бер капчык он.

— Әйдә,— ди бу миңа.— Син миңа китаплар бир. Ә мин сиңа бер капчык он калдырам,— ди. Кыш буе кайнар кабартма гына ашап чыгарсың, янәсе.

Бер капчык оннан зур хәзинә юк иде ул елларда. Кабартма дигәч тә авыздан су агарга кереште. Ашыйсы килә шул кабартманы... Китапка кагылырга куркам, әни орышыр, дим.

— Бераз көтегез инде. Тиздән әни кайтыр,— дим тегеңә.

Ул ашыктыра. Әйдә, өйгә керик, булмаса, аяклар туңа, китапларыгызны карый торырмын, ди. Он алып килгән абзаңны кире борып җибәрмәссең бит инде, ди. Кертмәдем тегене өйгә. Һәм дөрес эшләгәнмен. Аның белән сөйләшеп тә тормады әни. Чанасын тартып килгән юлыннан китеп барды.

— Нигә ризалашмадың, туйганчы кабартма ашар идек синең белән,— дип теңкәсенә тидем әнинең.

— Китапны онга алыштырмыйлар,— диде әни. Ачулы иде үзе. Бая, урамдагы теге кешене күргәч тә, төште кәефе... Әнинең башка кемгә дә булса шулай нәфрәтләнгәнен хәтерләмим.

— Минем ашыйсым килми,— дидем әнигә. Кызгандым үзен.— Син үзең ашамыйсың, шуңа гына әйткән идем...

Ул көнне үз-үзен кая куярга белми йөрде әни. Ә бераздан ул миңа китапларның кадере турында сөйләде. Арада хәтта Тукай, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Камалларның үз кулларын куеп бүләк иткән китаплары булуы турында әйтте. Күңелемнән генә үзебездә шундый кеше кызыгырлык бай китапханә булуы белән горурланып йөрдем.

Чана тартып килгән кеше дә хикмәтле булган икән. Әни сөйләде: ул әтинең шәкерте булган башта, безнең өйгә килеп йөргән. Әнигә чәчәкләр алып килә торган булган... Ә көннәрдән беркөнне, шул шәкерте әти хакында «Кызыл Татарстан» газетасында зур мәкалә язып чыккан. Дөньядагы бар яманлыкны өйгән әти өстенә. Мәкаләсен: «Халык дошманы һәм корткычның шәкерте булудан баш тартам...» дигән сүзләр белән тәмамлаган. Шуннан соң алып киткәннәр әтине.

«Әтиеңнең башына җитүче кеше ул»,— диде әни аның хакында. Исеме күңелгә уелып калды. Әле дә исән үзе... Китаплары бар, исеме радиодан ишетелеп кала еш кына... Менә шулай, студент, укымышлы кешеләрнең дә төрлесе бар. Әти кебекләр онытылды. Ә тегеләр яши, тегеләр үрчи һаман...

— «Малай аспирантурага кергән иде»,— дидең. Ташладымы? — дип сорап куйды Фидаил, әле булса Эт атучының улы турында кызыксынуыннан туктамыйча.

— Бабасының кем икәнлеген искә алган берәү. «Медицинага халык» дошманнарының оныклары кереп тулды»,— дигән. Ике уйлап тормаган малай, яңагына чалтыраткан да тегенең үз юлында булган. Бу

хакта сонлабрак белдем, малайның бер яхшы эше булган икән. Авыр кичергән, ә миңа кайтып сөйләмәде. Мин аны укый, галим була дип йөргәнмен, ә ул, укуын ташлап, килде-китте кешеләр белән бәйләнгән... Көннәрдән беркөнне өйгә кайтып керсәм, өй бушап калган — китап киштәләре шыр ялангач. Китаплар да юк, малай да... Берничә көн югалып торганнан соң кайтты әле ул кайтуын. Кайтты да караватка барып ауды. Күзләре калайланган, йөзендә иман калмаган... Сорыйм мин моңардан:

— Китаплар кая? — дим.

— Нинди китаплар,— ди, шырык-шырык көлә.

— Бабаң китаплары,— дим, караваттан суырып алдым үзен.

— Халык дошманыныкымы? — ди, көлә һаман.

— Ах,— дидем дә, ишек ачык тора иде, тибеп очырдым үзен.— Бабаңа тел тидерәсеңме?

Шул китүдән юк менә... Белүче дә, күрүче дә юк үзен.

Гәүдәсен бора төшеп, тагы фотоальбомга күз төшерде Фидаил. Ганлә альбомының соңгы сәхифәсен ачты. Кайда күргәне бар соң аның бу егетне?..

Ялгызлыктан туйган, йончыган Эт атучы, җанын чистартырга теләгәндәй, янә сөйләнергә кереште.

— Булмагач булмый икән ул, студент, бәхет дигәнең... Э-э-эх, характер җитмәде минем үземә, характер!.. Кеше төсле итеп корып булмады тормышны. Агымга каршы йөзәр көч тапмаганмын үземдә. Малайны да тәрбияли алмаганмын — үзем гаепле, студент, үзем!.. Нык рухлы, теләсә нинди кыенлыклар алдында да баш бирмәслек итеп тәрбияләргә иде дә исәп... Булдыра алмаганмын, үзем гаепле, үзем!..

Берөзлексез сөйләп торырга әзер иде хуҗа, тукталырга гына булмасын. Күңелен, җанын бушатуга тели шулай...

Кинәт, нидер хәтерләп, урыныннан сикереп торды Фидаил.

— Гыйлем абзый,— дип дәште ул аңар онытылып китеп. Үз исеме белән дәште.— Ә улыңның, улыңның исеме кем иде?

— Олы җанлы, тимер рухлы булсын диган идем... Җантимер...

— Җантимер?.. Җантимер!..— дип кабатлады Фидаил. Һәм әйтергәме, әйтмәскәмә диеп икеләнеп торгач, кулындагы альбомны өстәлгә ташлап, хуҗага таба якынлашты...

## 32

Нәрсә көтә бу Фидаил?.. Нинди уңайлы очрак җиткәнне көтә?.. Нигә дәшми һаман, ник тузынмый ул аңарга?.. Нинди планнар корып йөри?.. Нигә Асияне, улы белән бергә, әти-әниләренә чыгарып җибәрми?.. Нигә үзе чыгып китми, һәркөн алар янына әйләнеп кайта?.. Берни тотмый, бер каршылык юк ич аның өчен!.. Канатлы кош сыман иркен бит ул югыйсә.. Дүрт ягы кыйбла. Ә барыбер ашыкмый, көтә... Бу билгесезлек һәм хәвеф көтеп яшәүнең бер чиге булырмы икән?!.

Яшәвендә мәгънә калмады Асиянең. Бу гаиләдә ул вакытлы кеше. Әшендә дә вакытлы, очраклы кеше итеп тоя башлаган иде инде үзен. Җан тынычлыгы югалды. Бер карасаң, барысы да элеккечә. Ә яшәве — тоташ газап аның өчен хәзер. Көннәр — озын, караңгы төннәр — мәңгелекнең үзе сыман очсыз-кырыйсыз... Нинди генә уйлар үтми аның ялгыз башыннан. Бөтен өмете Арслан турындагы уйларда иде бит аның. Ә Арсланның киләчәк хакында сүз дә кузгатасы килми. Арслан өчен үзенең чираттагы бер мавыгу, үзләренчә әйтсәң, «кенәри» генә икәнлеген чамалый иде инде ул. Үз-үзен алдап яшәргә теләми башка...

Нәкъ шуңа күрә дә үз аягы белән Фидаилне ташлап чыгып китәргә ашыкмый. Ә ул дәшми... Дәшсен иде, ачулансын иде ул аны

Асия тезләнеп гафу сорарга әзер иде аннан. Дәшмәве белән телгәли бәгырьләрен, дәшмәве белән үтерә...

Шулай да, нигә дәшми икән соң ул аңарга? Икеләнәме?.. Яраткан хатыны белән бергә улын да югалту ихтималы тотамы аны?.. Әллә берни белмәгән, күрмәгәнгә сабышырга исәп итәме?..

Түгел!.. Тагы бер кат түгел! Ташка әверелде Фидаил, каты бәгырьлегә. Күзләрендә, һәр хәрәкәтендә битарафлык һәм салкынлык аның. Елмаюның ни икәнлеген онытты. Борчу, хафаларын да күрсәтми. Кайнаса да, бозга әверелсә дә — барысы үз эчендә...

Бәлки Асиягә әти-әнисе янына кайтып китәргәдер. Фидаилне дә коткарыр иде янәшә булып аерым яшәү газабыннан, үзен дә... Булмый, әнисе аңламаячак һәм гафу да итмәячәк — юллар өзелгән. Ананы да аңлап була: укуын ташлады — бер. Аның рөхсәтеннән башка «баш өстендә түбәсе дә булмаган шыр ятим авыл малаена» кияүгә чыкты — ике. Инде хәзер бала ияртеп кайтып төшсенме?!. Булмый! Икесе ике аеры яшәп гомер кичкән ата белән ана янында ул — өченче ялгыз — ни эшләр?!.

Бу дөнья нигә шулай яратылган икән? Эзләгән — таба алмый, тапкан — югалта, югалткан — гомерлек газапка дучар ителә... Үзара аңлашып, ярдәмләшеп яшәүнең кадерен белми кешеләр... Күпме кеше, күпме ир һәм хатын, күпме туган-тумача, күпме күрше, үзараниләрдер бүлешә алмыйча, бер якты бишек астында уртак тел таба алмыйча чыгә, тарткалаша, бүлешә икән бу дөньяны?!. Бер коллективта эшләүчеләр, бергә чират торучылар, бер трамвайда баручылар да бүлешә... Ни җитми бу кешегә?!.

Асиягә ни җитмәгән иде?!. Әти-әнисе бар, ире, улы, хәтта җаны үз иткән гөнаһлы яры... Ул булып ул да шыр ялангач бүген җир йөзендә, япа-ялгызы...

«Асия, синең күзләреңдә сагыш, ни булды?..»— дип сораучы, хәл белешүчесе булсын икән... Урамдагы чит-ят бер очраклы кеше булса да белешсен иде аның хәлен. Юк, берәүнең дә аңарда эше юк. Һичкемгә кирәге калмады аның хәзер!..

Каршылыклы хисләрен уртаклашырга ниятләп, Сания апасына килде көннәрнең берендә. Аңласа, ул гына аңлар, төпле киңәшен бирер төсле иде.

Улын югалту кайгысын күтәрә алмый, озак кына шифаханәдә ятып чыккан иде Сания апа. Хәзер, чираттагы ялын алып, өендә утыра. Күрешмәгәннәренә дә ни гомер икән инде...

Чыкмаган җаны гына калган Сания апаның; чәчләренә чал кунган, күзләре батып кергән. Кулында берөзлексез күз төпләренә тартылып торган нәни кулъяулык. Шул гомер тынычлана алмый йөрүе икән...

Гадәтенчә, өстәл янына чакырды ул кунагын. Самавыры кайнап утыра. Ак тастымал астында суынырга да өлгермәгән пәрәмәчләр... Килүченең сүз башлаганын көтмәде, үзе башлады хәл белешүдән:

— Йә, Асия, ничек яшисез анда, сөйлә?..

Зарлана алмады Асия, эч серләрен дә чишәргә ашыкмады — вакыты түгел.

Үзгәргән Сания апа. Үзе генә түгел, кайчан кермә, яктырып, балкып торган өй эче дә, ничектер, бушап, моңаеп калган кебек иде. Асия моны әле ишек катына аяк басуга ук тоемлаган иде бая. Сәбәбен генә аермачык аңлый алмады. Сорарга да уңайсыз, кыймады. Һәр урынсыз сүз Сания апаның күңел җәрәхәтләренә барып кагылыр сыман...

Чәй өстәленнән кузгалып, берни аңлашмаган, уртаклашмаган көенчә, инде чыгып китү турында кайгыртыр чак җиткәч кенә Асиянең карашы суыткыч өстендә торган буш читлеккә төште.

— Кенәриләр...— дип куйды ул, кинәт өйдәге шәрәлекнең бер сәбәбен ачыклаган сыман.— Кенәриләр кая, Сания апа?..

— Кенәриләрем дә юк...— дип, сулкылдап, күз төбен сөртеп алды олы кайгы күтәргән ана.

— Ни булды?.. Кая соң ул кошлар?..

— Җим биргәндә читлекләрен ачык калдырганмын... Кенәри — читлек кошы. Иректә яшәү сәләтен югалта икән алар. Мәче тотып ашаган үзләрен...

— Менә ничек?!. Ә шундый матурлар иде... Сайраулары...— диде. Әмма башланган җөмләсен тәмамламады, ни өчендер. Уйга чумып сүзсез калды...

## 33

Эт атучы Гыйлем улы хакындагы хәбәрне ишеткәч тә үз-үзен белештермәс хәлгә килде. Фидаилне озата чыккан җиреннән кире борылып кермәде ул, төне буе урамда йөрде. Кабан күле тирәсендәге иске тар тыкрык һәм кысан урамнарның берсе дә калмады — аркылыга, буйга гизде ул аларны. Хуҗасыз эт һәм биләмгә чыккан ялгыз мәчеләрдән башка җан иясе калмады урамда. Ә ул бер җанын кая куярга белми йөри дә йөри һаман. Әледән-әле исеп куйган салкын җил агач ботакларында эленеп калган соңгы яфракларны йолкып өзә. Җәйге иртәләрне, лепер-лепер сер уртаклашып, бер тармакта каршылаган яфраклар, үзара хушлашырга да өлгермичә, сибелә, тарала җилдә. Үз ишләрен эзләп, үз ишләрен таба алмый инрәп очып йөри ялгызаклар. Яфракларга да шул бер үк язмыш — аерымлык, таралу, сибелү... Көз җитәсен, таң нурлары көнләшерлек саф яшеллекнең кайчан да бер сарыларга сабышасын әлгәрерәк искәрмәдеме икән алар?!.

Болында уйнашкан күбәләкләр сыман очып йөргән, асфальтка төшкәч тә, үз язмышлары белән килешергә теләмичә, янадан калкыныптапынып очарга итенгән яфракларны күзәтеп йөрде Гыйлем. Яфрак булып яфракларның аяк астында тапталып юкка чыгасы килми. Сыңар канат белән күтәрелеп китәселәре, нәни күлдәвекләрне дә дәрья итеп йөзеп китәсе үзләре... Кешеләргә ни сан?!. Үз язмышына, үз бәхетенә хуҗа була белмәгән кешегә ни җитми?!. Сары яфрак түгелләр ләбаса...

Шундый уйларга бирелеп ипле генә атлап килгән җиреннән кинәт сискәнеп куйды Эт атучы Гыйлем. Һәм, ике уйлап тормыйча, урамның аргы ягына йөгереп чыкты. Тротуар аша, юлын бүлеп, аның каршысыннан кара мәче узып бара иде, борын кистерәсе килмәде шуңарга. Улын кайгыртуы иде, аның язмышы хәл ителү алдында тора. Көтелмәгән бу очрашу һәм узышудан кара мәче иң элек үзе пошаманга төшкәнгәме, ул өлгеррәк булып чыкты — яшен ташы сыман атылып, аның юлын аркылыга кисте, һәм тимер рәшәткә артына кереп юк булды.

— Ух, җен камалаган нәрсә!..— дип сүгенүдән башка чарасы калмады Гыйлемнең, шып тукталырга мәҗбүр булды.

Колак төбендә генә ят тавыш ишетелде. Аңа дәшәләр иде түгелме:

— Мөэмин-мөселман баласы икәнсең, мәсҗет каршысында сүгенергә оят түгелме?!

Күтәрелеп караса, ни күрсен: чынлап та, мәчет урамына барып чыккан икән. Каюм Насыйри урамындагы Мәрҗани мәчете... Тимер рәшәткәнең аргы ягында аякларына киез-ката, башына кәләпүш киеп алган ап-ак сакаллы татар карты басып тора. Себерке сабына таянган, йөзе ачык, күңеле күтәренке...

— Ә син монда ни эшлисең? — дип кайтарып сораудан башка чарасы юк иде Гыйлемнең дә. Әле һаман үз борынын кискән кара мәчегә булган ачуыннан арына алмаган иде ул.

— Минме? — дип кабатлап сорады яшел рәшәткәләр артында тор-

ган ир-ат. Фәрештәнекедәй иппе, тыныч иде аның тавышы.

— Мәсҗет саклыйм. Төнге каравылчы буламыз...

— Каравылчы урам себерми,— дип, үзенчә картны ялганда тоткан сыман, төзәтмә кертергә омтылып карады Гыйлем. Бер очтан бу аның үзен уңайсыз хәлдән чыгарырга омтылуы да иде. Шул гәүдәсе белән мәче куып йөрсен инде...

Кулындагы саплы себеркегә карап, янә дә балкыбрак куйды карт, ак сакалынача яктырып киткәндәй булды үзенең:

— Аны әйтәмсез?.. Җомга иртәсендә башкарылган эшнең савабы зур була... Күрәмсез, таң беленеп килә — җомга көн!..— дип, кояш чыгышына карап куйды карт олы өмет белән. Шул мизгелдә гүя күзләреннән бер уч нур бөркелеп куйды аның.— Кардәшләр килүенә ишегаллары чиста, пөхтә булып торсын.

— Алай икән,— дип, сүзе беткәнлекне аңлатып, үз юлы белән китеп үк барырга җыенган иде инде Эт атучы Гыйлем.

Төнге каравылчы, ялгызлыктан гаҗиз идеме, рәхәтләнеп дәвам итәргә әзер иде әле әңгәмәне:

— Мин сине бер сәрхүш дип торам... Сәрхүш белән тулды дөнья... Төн уртасында болай япа-ялгызың ни эшләп йөримсең, мөэмин-мөселман баласы?..

— Йөрим әле,— булды җавап. Ни дия ала иде соң ул башкача, үз оясын туздырып, ялгыз тилгән сыман урманга качкан улы хакында сөйләсенме?!

— Таң беленә...— дип, янә бер йотым салкын чишмә суы эчкәндәгедәй сыман киңәеп сулыш алды каравылчы.— Җомга иртәсендә юлың уңсын, теләкләрең кабул булсын, олан! Изге эшләр белән йөрисеңдер, беләм...

«Беләм» сүзе кәефен кыра язды Гыйлемнең. Чак кына «беләсең пычагым» дип ычкындырмады. Шулай да мәчет каравылчысы мондый дорфалыкка лаек түгел иде, тиз төшенде:

— Кара мәче энә,— диде ихласка күчеп.— Юлны кисеп чыкты...

— Киссә соң,— диде һәм ап-ак сакал очын сыпыргалап кеткелдәп көлеп җибәрде каравылчы.— Дүрт ягыңа борылып, дүрт мәртәбә төкер дә әфсен-төфсен диген. Бала-чага сыман мәче белән куышып йөрү килешми синдәй иргә...

Сүзен тәмамлагач, янә, кулындагы себеркегә таянып, иппе генә көлүендә дәвам итте.

«Бар бит ул дөньяда бәхетле кешеләр...»— дип уйлап куйды Гыйлем үзалдына. Һәм картның күзләрендәге яктылык, риясыз мөлаемлеге гадәти кызыксыну тудырды:

— Син, агай, бәхетле күренәсең?!.

— Бәхет...— диде карт, мәгънәле генә кеткелдәвен дәвам итте янә.— Бәхетне сатып алмыйлар, олан, ул кешенең үзе белән бергә туа.

— Тууын туадыр да бит...— дип әйтеп салгач, сүзнең озынга сузылуын өнәмичә, бер мәлгә тукталып ук калган иде Гыйлем. Әмма үзенә текәлеп торган, очраклы юлаучы белән әңгәмә корудан да бер тәм тапкан өлкән кешенең кәефен кырасы килмәде, җөмләсен тәмамларга мәҗбүр булды.— Булган бәхетеңне тартып алсалар, нишләрсең?!

Тагы да җанлана төште мәчет каравылчысы. Төнге узгынчыны үз иткәнлеген белгертеп рәшәткә читенә үк килеп басты. Кулындагы себеркене иппе генә сөяп куйды. Исәп җиң сызганып, чишелеп сөйләшү иде үзенең:

— Аллаһе-тәгалә кушкан булса — бирәү дә тартып алмас, олан...

— Булса иде дә бит... Юк шул, агай, сезнең сүзләр белән җан ярасын төзәтеп булмый! Язмышлар язылган, хәл ителгән инде безнең!

— Тукта, олан, тукта, үзеңнең мәсҗет каршысында басып торганлыгыңны онытма!.. Ул нинди өметсезлек, ул нинди кул селтәү дигән

сүз ул?! Бераз гына утырып алыйкмы соң әллә?!.

Тузан кагарга теләгәндәй, кулларын сыпыра-сыпыра, җиңел атлап, яшел капкага таба ашыкты каравылчы. Халат кесәсеннән алган бер бәйләмнән үзенә кирәкле ачкычны табып алды... Кабалана төшеп, капканы ачты һәм үзе янына эчкә үтәргә чакырды.

— Кирә алмыйм,— дип тартынды әлеге кунакчыллык алдында бөтенләй югалып калган Гыйлем.— Вакытым да юк!.. Аннан...

— Нәрсә, аннан?..

— Мәчет тирәсендә йөргән кеше түгел мин. Аллага да ышанмыйм!

Як-ягына төкеренеп алды карт:

— Әстәгыфирулла диген... Авызың әйткәнне колагың ишетсен, олан! Әстәгыфирулла диген...

— Мин ул сүзнең ни аңлатканлыгын белмим, агай. Аннан гына файда булса иде икән?!.

Янә як-ягына карангалап алды мәчет каравылчысы.

— Ул кадәресен, олан, мин үзем дә белеп бетермим анысы... Хикмәт ышануда, олан!

— Ә нигә як-ягыңа каранасың алай?..

— Кеше-кара күрмәсен дим...

— Ә алла бит барын да ишетеп тора!

— Ишетә торгандырмы-юкмы, олан,— мин ул кадәресен белеп бетермим... Хикмәт ышануда дидем...

— Син ышанасыңмы?!

Бирелгән сорауның урынсызлыгыннан исе китеп, баш чайкап куйды мәчет каравылчысы:

— Ничек?.. Ничек яшәргә кирәк ышанычсыз?..

— Мин бернигә дә ышанмыйм, агай!

— Бәхетсезлегең шуннан, олан! Кеше табынырга тиеш, олан, ышаныч йөретә адәм баласын...

Эт атучы Гыйлем әллә ни зур игътибар бирмәде картның бу соңгы сүзләренә. Мәчет тирәсендә эшләп көн күргәч, башкача сөйләшергә ярамыйдыр, ни эшләсен инде... дип кенә уйлап куйды күңеленнән.

Мәчет каравылчысы җитдиләнеп китте, авызын ача төшеп, күзләрен хәрәкәтсез калдырып текәлде ул төнге узгынчыга:

— Ничек алай, олан!.. Шулай ук бернигә ышанмыйсыңмы?! Чынлап сөйләшүеңме бу?!.

— Юк! — диде Эт атучы Гыйлем.— Беркемгә һәм бернигә дә ышанмыйм мин хәзер!

— Әстәгыфирулла!.. Әстәгыфирулла!.. Әстәгыфирулла!..— дип кабатлады ул өч мәртәбә. Һәм, бер-бер кеше ишетеп, күзәтеп тормыймы дигән сыман, саклык белән як-ягына каранды. Балкып, көлеп, яктырып торган татар картын алмаштырып куйдылар диярсең...

Кызганыч тоелды ул шул мизгелдә. Ничектер, бер-бер җылы сүз әйтеп юатырга теләде аны Гыйлем. Бәлки бөтенләй туктап торырга, бу аңгәмәгә керергә дә кирәк булмагандыр аңа. Соң инде...

— Син, агай, ул кадәр үк ачуланма инде миңа,— диде ул ихластан.— Шушы яшькә җитеп, мәчет белән алыш-биреш иткәнем булмады. Манарасын күрдем, ә капкасы кай якка ачылганлыкны белмәдем. Мине гаепләмә син, ярыймы, агай!..

— Имансыз калудан саклан, олан!.. Имансыз калудан... Адәм баласы ышанырга тиешле...

— Өйрәтүче булмады... Әти-әни диндар кеше түгел иде,— дип, кечелекле сөйләшүен дәвам итте Гыйлем. Гүя акланырга керешә...

— Әтиең кем иде соң, улым?

— Атканнар...

Бер сүздән аңлап алды карт — кабатлап сорап тормады. Шулай укмыни дигән сыман, башын түбән иеп, сакалын селкетеп алды. Үзе берни сорашмады, дәшмәде...

Шул дәшмәве сәер тоелды да инде Гыйлемгә: Каян белә ул?.. Бәлки сугышта вафат булгандыр аның әтисе, фашистлар аткандыр?.. Бик тиз төшенде түгелме соң?!.

— Минә ничек,— дип куйды мәчет каравылчысы. Тынлыкны күтәрә алмавы иде.— Утыз җидедә мине дә атарга хөкем иткәннәр иде... Минә ничек!..

— Димәк, син дә?..— дип, карашын текәде Эт атучы.

— Әйе, мин дә — «халык дошманы»! — дип расланды тәмамланмаган сорау.— Авылда сәвит җитәкчесе идем. Мәчет манаралары кистердем... Иң элгәрге комсомол идем үзебезнең авылда...

— Монда — мәчеткә каян килеп эләктең?..

— Илле алтыга тикле утырдым... Унтугыз ел! Әйләнеп кайткач та изге кешеләр очрады юлыма... Монда урнаштым — иманым кайтты, кешеләргә ышанырга өйрәндем яңадан... Яшь чакта кылган гөнаһларымны юдым... Шулай, олан! Мәсҗет капкасын урап узарга киңәш итмим сиңа да...

— Унтугыз ел! — дип, хәйран калып карап куйды ул картка. Үз колаклары ишеткәнгә ышана алмый торды.— Ун-ту-гыз ел!.. Ә үзең «бәхетле» дисең, агай?!.

— Бәхетле, олан...

— Гаиләң бөтен, балаларың күптер?..

— Гаилә корыр ара булмады минем, олан! Сәвит өчен көрәштек иң элек. Аннан ары... үземнең арт сабакны укыттылар...

— Торган җирең кайда соң синең, агай?

— Әнә, күрәсеңме,— дип, мәчет ишегалдындагы тәбәнәк һәм җыйнак алачыкны хәтерләткән корылмага күрсәтте ул.— Ахирәткә кермәс борын ук оҗмахта яшимез.. Мәсҗет ишегалдында, олан...

— Бәхет... Шул буламы бәхет?!.

— Бәхет иманга ирешүдә, иманлы булуда, олан! Күңелең изгелектә булуда... Үч һәм ачу сакларга ярамый дөньяга!.. Дөнья матур, дөнья ямьле ул үзе... Шулай, олан!

Мәчет каравылчысы күтәрелеп килгән кояшка күз салып алды шунда. Уч төпләрен сыпырып алды һәм, кабаланып, себеркесенә үрелде.Ипле генә селтәнеп, мәчет ишегалды буйлап берән-сәрән сибелгән көзге яфракларны себерергә керешге ул. Дәшми генә үзеннән ерагая барган ап-ак сакаллы картка сокланып карап торды Эт атучы Гыйлем. Хәрәкәтләре салмак иде аның, әмма ышанычлы...

Капка турыннан ишегалдының уртасына җитеп килә иде инде төнге каравылчы. Шунда гына, туктап хәл алырга уйладымы, артына борылып карады ул — төнге узгынчыны искә төшерде:

— Ишегалдын әйтәм.. Кардәшләр килүенә пөхтә торсын дим...

## 34

«Улың исән... Шәһәр читендәге урманда, күл буенда яшәп ята...» — диде «студент». Үзенең вакыт табып бер килеп чыгарга тырышачагын вәгъдә итеп, китеп югалды. Менә көт инде хәзер — кайчан вакыт табар да кайчан килеп чыгар... Адресын-фәләнен калдырмады...

Көне дә, үч иткәндәй, ял көне иде бит аның. Җомга көтте, шимбә көтте... Якшәмбе көн дә узып китәр... Ә ул тамактан язды... Эшкә барганы юк... Сыраханәләрне дә ябып бетерделәр соңгы араларда, имеш, алкоголизмга каршы көрәшәләр... Тагы күпме көтәргә була шулай?!. Шәһәр әйләнәсендә күлләр күп анысы, эзләргә тотынганда, тапмаслык түгел шулай да... Чормадан иске велосипедын алып төште дә юлга чыкты Эт атучы Гыйлем.

Күлләр... Зәңгәр күктән чылбырдай тезелешеп очып барган кошлар төркемен хәтерләтә алар безнең шәһәр әйләнәсендә. Һәркайсының үз исеме, кабатланмас йөзе, әйләнә-тирәлеге бар. Самолеттан караганда, урман куенында яткан якты зәңгәр күзгеләрдәй игътибарны җәлеп итәләр...

Ярым бөкрәя төшеп, велосипед руленә яткан ир-ат өчен әллә бар ул ямьлелек, әллә юк... Баскан саен шыгырдап-чыелдап торган педальләрен тик әйләндерә — ашыгырга, караңгы төшкәнчегә кадәр табарга кирәк аңар улын!..

Якын ара түгел, ай-һай ерак икән күлләр әйләнәсе. Күл белән күл аралары тагы да ераграк. Тоташ урман, йөзьяшәр наратлар урап алган үзләрен. Һәр минуты газиз улы бәһасенә тиң тоелганда, ата өчен байтак кыенлык, каршылык тудырды ул наратлар да. Стена сыман калыккан агачлар кырык-илле адым алда ни булганын да күрер күздән яшереп тора. Ә инде тамырларын әйтергә дә түгел... Комлы туфрак өстенә бүлтәеп чыкканнар да җиде-сигез башлы аждаһа елан сыман күлгә таба сузылганнар. Велосипед көпчәге бер сикерә, ике сикерә дә тәртелеп туктап кала үзләренә. Утырып бару түгел, өстерәп барулары кыенлаша кайчак...

Эт атучы Гыйлемнең кул аркасы һәм муенында кабарып чыккан шундый ук тамырлар. Тимерчыбык сыман киереп тартылган шул тамырлар буйлап кан йөгерә. Чигәләрен китереп кыса шул кайнар кан. Йөрәк кага, дөп-дөп иткән аваз гүя урманга яңгырый. Күзләр талчыкты, бил тураймас булды, пинжәк астындагы күлмәк тәнгә ябышкан... Ә ул аның саен, ашыга-кабалана, алга ашыга, алга — улы янына. Нарат куелыгыннан атылып чыгуга ук, этенеп китеп, ике тәгәрмәчле атына атлана... Улың исән-сау, улың сине көтә дисәләр, урман эчендәге бу күлләрне генә түгел, Җир шарының үзен урап чыгарга да күп сорамас иде Эт атучы Гыйлем.

Күлләр чылбыры олы асфальт юлдан еракка алып китте аны. Ә улын күргән, ишеткән кеше дә юк. Тора-бара анда-санда очраштырып торган гөмбәчеләр дә күренмәс булды. Күл читләтеп сузылган буйбуй җәяүле сукмаклар да сирәгәя барып юкка чыктылар. Әмма күл читендәге бер генә корылма да аның игътибарыннан читтә калмады. Кайда нәрсә булуын, кайда кем яшәгәнлекне ачыкламый торып, ары китмәде.

Күлләрнең санын онытты инде ул, күлләр чылбырында адашканына да байтак гомер. Ә уйсулык дәвам итә, димәк, күлләр арырак та булырга ошаган... Карама һәм элмә үсә бу уйсулыкта, шомырт һәм зирекле аланнарга килеп чыгасың. Калкурак урыннарда сирәкмирәк кенә юкә һәм усаклар чалына күзгә.

Уйсулык адаштырмады, аны туп-туры чираттагы күл каршысына китереп чыгарды. Монысы, көтүдән калыша төшкән аксак бәбкә сыман, шактый ук ерак иде күлләрнең башкаларыннан. Йөрәге кысып куйды атаның, Җантимер шушында булырга тиеш дигән уй килде чигәсенә. Янә күнелендә, менә сүнәм, менә сүнәм диеп торган өмет уянды. Гәүдәсен турайтырга тырышып, иркен сулыш алды ата. Күзге көн тәмамланып килә. Кояш баешындагы наратлар очыннан алтын нурлар сузылган. Каршыда Алып батыр көзгесе сыман җәйрәп яткан күл. Аның өсте инде карасу зәңгәрлеккә талып бара. Бер мизгелгә табигатьнең матурлыгы каршында көчсез калып торганнан соң, янә велосипед педальләрен әйләндерергә кереште ул. Тимергә тимер ышкылудан чыккан чыелдау авазы көчәйгәннән-көчәя барды, көпчәк астыннан кипкән чыршы-нарат күркәләре атылды...

Сарыга сабышкан үләннәрне ерып, тәгәрәпме-тәгәри тәгәрмәчләр. Бу юлның башы кайда да ахыры кайда булыр?.. Тагы күпме ара, күпме юллар узарга кирәк икән аңар? Бу күл әйләнәсеннән дә тап-

маса улын, тагы кайлардан эзләр икән?.. Күлләр бармы икән тагын?.. Шундый уйлар белән онытылып, җан-фәрман куып барган җирдән, җир йотты диярсең, кинәт күздән югалды Гыйлем. Кайчандыр казылып та соңынтын онытылган тирән чокыр төбенә очып төшкәнлеген хәтта үзе аңыша алмый калды. Вак куаклык һәм куе булып үскән шайтан таяклары артында шундый тозак — тирән чокыр сузылган дип кем уйласын...

Ком һәм балчык арасыннан башын күтәреп, бармаклары белән йөзен сыпырып алды ул. Кабаланып, күзләрен ачарга ашыкты, кул-аякларын барлады. Авырту кая, талчыкканныкымы, берни тоймый иде гәүдәсе. Кыймылдыйсы килми хәтта, гүя мәрткә киткән. Ә икенче читтә сигезле кыяфәтен алган велосипед тәгәрмәче аунап ята... Шунда ярсып эт өргән аваз ишетелде аның колагына. Еракта да түгел, янәшәдә генә диярлек этләр өрә...

Эт авазы күзләрен ачтырды янә. Әмма кымшанырга, аякларына басарга ашыкмады. Җегәр юклыктан түгел, үзен биләп алган гамьсезлек, чарасызлыктан арына алмады. Тирән чокыр караңгылыгына чумып, дөнья мәшәкатьләреннән онытылып тору рәхәт иде аңар гүя.

Ә этләр һаман өрә. Тавышлары хәтта якыная да барган сыман тоелды Гыйлемгә. Шунда хәтерендә кайчандыр һәм кемнеңдер үзенә әйтелгән каргышлы сүзләре яңарып алды. Чынлап та ишетелә, җир авызыннан ишетелә сыман иде шул каргыш: «Үлемең этләрдән булсын!.. Үлемең... Үлемең...»

## 35

Ялгызлык! Янәшә булып та, бер-береңә дәшешмичә яшәүдән зуррак газап бармы икән кеше өчен?!. Сәгатьләр, хәтта тәүлекләр дәвамына бер-береңә күтәрелеп бер авыз сүз әйтми йөргән ир һәм хатыннар була...

Телсезләр дә үзара аңлашмый, хәбәрләшми тора алмый, ни өчен соң дәшми бу кешеләр бер-берсенә?! Күпме кыенлыклар кичереп аңлаша телсез һәм чукраклар! Аваз чыгара алмаган иреннәре алтыгасигезгә бөгелә, аңкаулары хәрәкәт итә хәтта. Куллар һәм бармаклар уйнап тора... Ни итсә итәләр, әмма аңлашу җаен таба үзләре. Телсезләрнең үзара аңлашканда ничек елмаюын күрүче булса, аңлар — алардан да бәхетле зат юктыр шул мизгелдә.

Туган көненнән үк аңлашырга тели сабый, кул-аякларын селкетеп, тешсез аңкауларын ача. «Ы-гы-ы» дигән беренче сүзен ишеткәч тә, башы күккә тия ата-ананың. Әби-бабайлар йөгерешә: «Улыбыз шулай диде... Кызыбыз болай диде...» Читтән карап торганыгыз бардыр,— үзләре сабыйны уздыра, авызларын бөреп-бөреп, сабый булып сөйләшергә, аны кабатларга керешәләр.

Яңа кеше дөньяга аваз салса — бәхет. Шул рәвешле үз-үзен раслый торгандыр сабый. Ә инде үзен өлкәннәр аңламаса, яисә аңларга теләмәсә, ул кычкырып елап җибәрә: «Ничек инде төшенмисез, мин бит сездән шуны сорыйм, шуны бирегез!..» — ди ул. Эх, үрмәләп китә белсәм, дия сабый... Үзеңне аңламауларыннан, бер-береңне аңламаудан да авыррак ни булырга мөмкин кеше өчен?! Аралашу, аңлашу кирәк кешегә!

Соң, шулай икән, ни өчен соң дәшми кешеләр бер-берсенә?!. Ни өчен алар читләшә бер-берләреннән?!. Җитди эше булса — ялгыз калдыр. Уйлана ул — дәшмә. Хыялга чумган — шыпырт бул. Иҗат итә — шылт иткән аваз булмасын. Ял итә — борын тартма, сулама... Эш өстәле артында — сөйләшмә, аш өстәле артында — сөйләшмә. Кеше шулай ялгызлык даулап яши үзе өчен.

Урамда очрап, йөзгә-йөз бәрелгәндә дә күрми, танымый сине ке-

ше. Бер урам турында сөйләшмибез — бер баскычта яшәп, кара-каршы күрше булып та — танымый, белешми, күрешми кешеләр. Бергә үскән дуслар онытыла, классташлар, курсташлар җуела хәтердән... Хат алышучы сирәк! Кунакка йөрешү онытылып бара. Туган көннәр сирәгәйде. Бәйрәм житсә, ишек артында бикләнәбез...

Сөйгән ярлар аерылыша. Ата-ана ялгыз кала. Туганнар күрешми. Әниләре — әтисен, сабыйлары әнисен белмәгән очраклар ишәйде. Ялгыз хатын-кызлар... Ялгызак ирләр... Картлар йорты тулы ялгыз карт һәм әбиләр... Тумас борын ятимлеккә дучар ителгән сабыйлар... Игълан нарга кара: торган саен кушылырга теләүчеләр түгел, аерылырга сусаганнар саны арта!..

Нигә шулай ялгызлыкка сусый икән кеше?!. Нигә бер-беренә дәшми кеше?!. Ни булган бу кешеләргә?!.

Фидаил дәшми һәм дәшәргә җыенмый да — аны аңларга була сыман. Асия дә үзе башлап дәшә алмый — аны аңламаслыкмы, йә!?. Бу дәшешмәү артык күпкә китте. Һәм тагы күпме дәвам итәр икән?!. Ире авызыннан бер сүз, бары бер ягымлы сүз ишетер өчен әллә ниләр бирер иде Асия. Ягымлы сүзгә лаек булу кирәк, ул югалтты андый хокукын. Ачулансын, авыр сүз әйтсен, җикеренсен — Асия күтәрер. Ә ул дәшми һаман, дәшмәве белән телгәли бәгырен... Тик яшиләр ике телсез, ике чукрак сыман. Хәер, шулай диюем белән чукракларны көлдерәмдер...

Кырыслана барды Фидаил. Шул дәрәҗә түземлек һәм ихтыяр көченә ия диеп кем уйлаган үзен! Ялгышкан булып чыкты Асия: Фидаил бит, аның карашынча, йомшак, ихтыярсыз, күндәм иде элек. Ул бит әле дә шуңа исәп тота — Фидаилнең сүз башлавына. Фидаил дәшми! Һәр сәгать, һәр яңа көн саен сокландыра, хәйран калдыруында дәвам итә ул Асияне. Бөтенләй башка кеше икән ләбаса ул! Торган саен ныгый, кырыслана, бозга әверелә барган Фидаил чын-чынлап ошый, үзенә җәлеп итә, тарта иде аны хәзер...

Нибарысы бер сүз, сыңар сүз чыксын авызыннан. Ягымлы буламы ул сүз, түгелме — барыбер. Бер генә сүз! Сузма, дәш тизрәк. Асиянең ул сүзне ни дәрәҗә өзгәләнеп, зарыгып көтүләрен тоймыйсыңмыни соң, Фидаил?!.

Каты бәгырьле икәнсең!.. Шул рәвешле үч аласыңмы Асияңнән?!. Ничек шулай кинәт үзгәрә алдың син?!. Хатының бит сине пешмәгән арыш камырына тиңли торган иде кайчандыр... Ә син, кирәк чакта, горур да икәнсең, рәхимсез дә...

Хәтерлисеңдер, Фидаил: өйләнгәчтен берничә көн дәвамына син миңа сүз дәшәргә, кагылырга куркып йөрдең. Укасы коелыр дигәнеңдер инде... Миңа бу сәер һәм көлке тоелды. Хәтерлисеңме икән, мин сиңа ни дидем көннәрнең берендә?

— Җебегән,— дидем. Шаярып әйтелсә дә, ихлас иде ул сүзләрем.

— Аңа караны күңелем яхшы минем,— дидең. Гомереңдә беренче тапкыр күзләремә карадың шунда. Озак дәвам итмәде бу, шундук читкә качырдың карашыңны, күзләрең челт-мелт йомылды... Дәү колакларың кызарып чыктылар. Шунда гына үземнең кемгә чыкканлыгымны аңладым мин — гади һәм гадәти бер авыл малае икәнсең, дидем. Оялчан идең өстәвенә һәм гөнаһсыз идең...

— Фидаил,— дидем, телемә салынып.— Нигә синең колакларың әрекмән яфраклары сыман,— дидем.

— Синең авыздан чыккан һәр сүзне ишетеп тору өчен,— дидең, сер бирмәдең. Ә мин көлдем...

— Борының курнос. Бер дә курнос егеткә чыгармын дип уйламаган идем...

— Үбешкәндә төртеп тормасын, комачауламасын өчен шулай ул,— дидең дә, гомереңдә беренче тапкыр мине үбәргә иттең. Батыраясың, кыю булып күренәсең килде минем алда...

— Абау, чәчләрең,— дидем. Чынлап та сәер тоела иде миңа ул чакта синең чәчләрең — үзләре җиз чыбык төсендә, үзләре кыл сыман каты да әле өстәвенә.

— Йөрәктәге ялкын кучкән, ут капкан аларга,— дигән булдың һәм, исең китмәгән атлы булып, күләргә керештен. Уңайсыз хәлдә калган чакларыңда син гел шулай көләргә итә торган идең. Ә үзеннең йөзең чытыла — кызганыч хәлдә торып каласың. Чөнки син аз гына да артист түгел, Фидаил. Ә безнең заманда һәр кеше, бигрәк тә шәһәр җирендә яшәүчеләр, азмы-күпме артист булып уйный белергә тиеш. Синең кебек күңел, намус һәм ихласлык белән яшәүчеләр сирәк, һәм җинел дә түгел сезгә. Ай-һай, җинел түгел, Фидаил!

Ә мин үзем туганнан бирле артист булып уйнадым. Әти һәм әни алдында уйнадым, укытучылар алдында. Кызлар һәм егетләр каршында... Урам буйлап үтсәм — урамда да мин үземне сәхнәдәгедән болайрак хис иттем. Тамашачы, синең рольгә кереп уйнавыңны чынга алучы, үзенә кушылып уйнаучылар бик күп, күпләр бу дөньяда, Фидаил...

Әйтик, минем әтине генә алыйк, син аны беләсең һәм хөрмәт тә итәсең. Ул дәшми... Ни өчен дәшми? Әйтер сүзе юклыктан түгел! Аны тыңлаучы юк, шуңарга дәшми. Әнинең үз туксаны — туксан. Хезмәт урынында да дәшкәнне, фикер йөрткәнне өнәп бетермиләр. Дәшәр иде — күңелсезлекләр, бәхәсләргә керергә туры килә. Дәшмичә яшәүгә ни житә. Дәшми яшәүче, аз сүзле, күндәм ир-атлар кирәк булган дөньяга. Минем әти шуңар дәшми. Уйлый китсәң, ул бит үзе дә бер дигән артист булып чыга соң чиктә.

Син дә дәшмисең, Фидаил. Әмма син, дәшмәүче күп кенә ир-атлардан аермалы буларак, ролеңне уйный белмисең. Дәшмәү — дәрәҗә, мәртәбә, авторитет китерә күпләр өчен. Синең дәшмәү үз максатыңда түгел!

Күптән оныткансыңдыр инде, ачу саклый белми идең ич син... Бервакыт мин сиңа тагы да авыррагын әйттем бугай сүзнең:

— Абау, бигрәкләр дә ямьсез икәнсең син,— дидем, көзге каршында үземне кочаклап алгач.

— Синең чибәрлегең каршында гына тоныкланам,— диден, югалып калмадың.

Шулай да шаяртасың килү шундук юкка чыкты. Син моны үзең күрсәтергә теләмәдең. Ә мин — күрәм. Шундый кызык була торган идең син шулай югалып калган чакларыңда. Елыйсың килгәндер бәлки, ә көләргә иткән булдың.

— Мин көзгегә ышанмыйм, Асия,— диден, шундук үзеңне кулга алып.— Синең күзләр матур күрсәтәдер...

Минем күзләрдәге чагылышың турында сөйләгәнлегеңне аңламадым. Шулай да ошады сүзләрең.

— Минем күзләр бит ул,— дидем...

— Ирләргә матурлык нигә! — диден һәм кочып күтәреп алдың үземне. Әйлән-бәйлән иттең шушы нәни бүлмәбездә.— Аның каравы хатыным — дөньяда бер чибәр...

Хатыныңны мактап, аның матурлыгы каршында тез чүгеп, бәлки, син ялгышкансыңдыр, Фидаил. Синең шулай диюең миңа ошый иде... Үзем дә нәкъ шулай уйлый торган идем мин, Фидаил. «Үзең ярату — әһәмиятле түгел, сине яратсыннар! Тора торгач күнегелә ул...»— ди торганнар иде. Дөнья күргән кешеләр юкны сөйләмәс дип тынычландыра идем үземне... Хак икән — яраттырдың! Әмма соңлап, соңлабрак килде миңа андый хисләр, Фидаил! Тормышымны яңадан башлыйсы булса, ике уйламас идем, мең кеше арасыннан сине сайлап алыр идем мин хәзер. Әйткән сүзләреңә колак салып, күзләреңә генә карап торыр идем... Соң! Соңарып яраттырдың, Фидаил!

Арслан белән очрашуларымны?!. Әйе, миңа иң кыен сорау бирдең

син!.. Әгәр син гафу итә алсаң, синең гафу итәреңне белсәмме?.. Борылып та карамас идем мин аңарга. Нинди хис?! Уен гына булган һәммәсе! Хисләрнең булган кадәресе дә күптән янды, күмергә, көлгә әверелде! Беләсең килсә, Фидаил, гомер буе артистландым, уйнадым. Гомеремдә бер уйнамыйм икән дисәм, үзем көлкегә калдым, чын кеше дигәнем — профессиональ уен остасы булып чыкты... Арслан — яраткан кеше түгел, яратачагы да юк! Чөнки үзен ярата ул, һәммә кешедән дә элегрәк үзен кайгырта. Минме аның өчен, башка берәүме — барыбер... Тиздән, бик тиздән барысы да онытылачак безнең арада, инерция көче генә алып бара үзебезне. Урамда очрашканда исәнләшми, сәламләшми узачак кешеләр без! Гаҗәпме? Гаҗәпләнмә — арысланнар һәм кенәриләрдә шулай кабул ителгән, аларда тәртип шундый, Фидаил. Хәер, нигә сөйлим соң мин боларны?! Син бит барыбер ишетмисең мине. Ишетсәң дә, аңламас идең! Син бөтенләй башка дөнья кешесе ич, Фидаил...

Менә шулай, мин гел синең белән сөйләшеп яшим соңгы араларда. Синең белән киңәшкәннән соң, җиңелрәк булып китә... Янәшәмдә син барлыкны тою көч бирә миңа, Фидаил. Үзең өйдәме син, өйдә түгелме — мин һәрвакыт фикер алышам синең белән. Ә син — ишетмисең, күз алдыңа да китерә алмый торгансыңдыр. Син мине мондый дип белмисең, чөнки. Үз-үземне таный, аңлый алмыйм ич мин хәзер...

Нигә дәшмисең син, Фидаил?! Дәшмисең, читкә дә тибәрмисең?! Ялгызлыктан куркам мин, Фидаил, гомерлеккә ялгыз калудан. Сине югалтудан!.. Чөнки беләм: төшендем хәзер — синең кебек ышанычлы бүтән кеше очрамаячак юлымда!.. Янәшә булып та, бер-береңә дәшешми яшәүдән зуррак газап юктыр ул кеше өчен...

## 36

Караңгы базны хәтерләткән тирән чокыр төбендә балакны ертып чыккан шәрә тезләрен кочаклап, шактый озак утырды Эт атучы Гыйлем. Ни эшләргә белмәде. Кымшанырга курыкты хәтта. Югарыдан, соры ком төсенә кергән тигәнәк һәм алабуталар аркылы саркып, тоныкъ яктылык сиземләнеп тора. Яктылык шулкадәр аз, янәшәдә үк бөгәрләнеп яткан велосипед тимерләре дә чак шәйләнә. Кымшанасы килми, сузылып ятарга да күзләрне йомасы гына калган. Һәм кем белә...

Караңгы уйлар тарала барып, тигәнәк һәм алабута аша тоныкъ кына сирпелеп торган яктылык сыман, өмет чаткысы да кабынып алды бераздан. Төшенкелеккә бирелергә иртәрәктер бәлки?.. Кул-аяклары исән чакта нәрсә дип шундый уйлар били соң әле аны?! Күп ара түгел, әлеге күлне генә әйләнеп-урап чыгарлык җегәр бар ич әле аңарда. Велосипед кына димәгән ич... Чаткы булып кабынган шул уй тәненә — җегәр, рухына канат иңдерде. Аякларына басарга итте. Әмма уң як кабыргаларның берсе эчке яктан чәнчеп алды — ток суктымыни, җиргә чүкте кире... Чалкан салкын туфракка ауды — рәхәт. Бармаклар белән капшана торгач, үз-үзенә диагноз куйды: астан өченче кабырга сынган. Бармак очы белән аз гына басу да җитә — эчкә китә. Бармакны аласың — кире үз урынына кайта...

Сыңар кабырганы сылтау итеп булмый, барыбер торырга кирәк. Урман эчендәге ташландык чокырга ашыгыч ярдәм машинасы килмәс. Үз язмышы үз кулында аның хәзер, берәү дә: «Абзый, кулыңны бир, тартып чыгарыйм үзеңне...»— диеп дәшмәс.

Сыкрауга охшаш көрсенеп алды да кулларына таянды ул янә. Сынык кабыргасын кыса төшеп, ипле генә аякларына басты. Сөзәгрәк урын табарга да күтәрелергә генә калды. Әмма тирәнлек шактый үк зур! Экскаватор ничек казып калдырган булса, шул хәлендә торган

чокыр. Димәк, авыртуга түзеп, күзне йомып тырмашырга кала — югары күтәрелергә...

Менеп житәм дигәндә, бер ишелеп төште комлы балчык белән. Ике... Әмма үзенекен итте Гыйлем, эңгер-меңгер төшеп килгән якты дөньяга чыкты. Юлын дәвам итте. Үзе егылган чокырның буйдан-буйга сузылып күл эченә кереп торган ниндидер ярымутрауны әйләндереп алганлыгын ул шунда гына аңлады.

Эт өргән авазлар яңарды бераздан. Ул сагая калды. Эт өргән аваздан шүрли, курка иде түгелме ул?! Әйе, күңеленә шом сала икән ич эт өргән авазлар. Үлемнән үзеннән курыкмаган Гыйлем эт өргән аваз ишетеп коелып төшә язды — менә гаҗәп! Эсселе-суыклы булып китте, тәненнән кырмыска өере чабышкандай булды...

Тирә-юньдә кеше-кара булырга охшамаган. Кичке урманда шом булуын искәрткәндәй, наратлар шаулый, наратлар чайкала. Кара урман уртасында бер ялгызың син дия иде сыман алар. Бер ялгызың... Һәм этләр! Чигә төбендә: «Үлемең дә этләрдән...» дигән таныш каргыш яңарып алды тагы.

Шулай да кире борылмады Эт атучы Гыйлем, өргән авазларга төбәлеп, туры атлап китте... Ниндидер биек таш койма шәйләнде бераздан. Ак кирпечтән торгызылган корылма... «Шушында!» — дип нәтиҗә ясады ата күңеле. Бердәнбер улыннан аны, күп булса, йөз-йөз илле адым ара аерып торадыр. Бәлки этләр Җантимернекедер әле. Эт дип дөньясын оныта иде ич кечкенәдән... Җантимер үзе дә этләре янында кичке табигать белән хозурланып йөри торгандыр... Әтисе килгәнен күрер дә ят кешегә санап өргән этләренә җикеренер ул иң элек. Ояларына куып кертер этләрен. Һәм, кочагын җәеп, каршы йөгереп килер...

Абына-сөртенә йөгерә башлавын да абайламады ул үзенең. Йөрәге, гүя канатлы кош, җилкенергә керешкән. Бу көндә беренче мәртәбә урман һавасы саф сулышын тойды ул күкрәгендә. Яфрак һәм ылыс исе борын тишекләрен ярып керде, аяк астындагы коры үлән исе бугазын кытыклады. Улы Җантимер сулый торган һава!.. Аның шундый матур табигать кочагында эшләгәне һәм яшәгәнлеге өчен дә куанып алды хәтта. Әтисе белән ачуланыштым дип, бер дә башын югалтмаган, кая китеп урнашырга белгән! Табигать кочагында аның улы... Урманда адашкан кеше дә исән кала, ачтан үлми. Димәк, өмет бар әле аның улында, өмет өзәргә иртәрәк аңардан. Таныш-белешләреннән дә качып китүе яхшы булган. Табигать, урман — игелекле... Нәселенә тагылган кушаматтан качкан... Кушаматсыз яшәп була урманда. «Халык дошманнары» да юк урманда, «Эт атучы» да!.. Һәммә кешене тигез итә табигать, бүлми, каршы куймый бер-берсенә. Улы исән!.. Димәк, яши, яшәп күрсәтә әле алар болай булгач!

Шундый уйлар белән үз-үзен юатып, ике катлы ак бинага якынлашты Гыйлем. Бакчаны әйләндереп алган таш койма читендә туктап калды. Ишегалдында этләр өрә. Икәү... Овчарка токымыннан! Бәйдә икән үзләре. Матурлар... Җантимер эт рәтен белә... Әле үскән чакларында ук эт һәм мәче өчен җан аткан бала иде бит. Урамда бер көчек күрсә, иярә дә китә иде шуның артыннан. Әтисеннән көчек сорап үтте сабый чагы. Ә ул эт-мәче заты кертмәде үз өенә. Шәһәр җирендә эт-мәче асрауның мәгънәсен аңламый иде ул. Авылда бер хәл! Болай да кысан булган шәһәр фатирларында кешегә урын тар, нигә хайваннар да газап чигәргә тиеш тагы?!.

Күрше малайларның этләренә кызыгып үсте Җантимер. Менә ич, соңарып булса да, әлеге хыялын да тормышка ашырган аның улы — бер түгел, ике эт асрый икән... Урманда этсез булмый, урманда асрасаң да була ул этләрне!..

Тынычланып, таш коймага килеп сөялде Эт атучы Гыйлем. Инде хәл алырга да була. Ләкин шунда, үч иткәндәй, мин монда дигән сыман, сынык кабырга үзен сиздереп куйды. Төшермәде күңелен Гый-

лем: кабырга нәрсә ул — сына да, ялгана да... Менә улын табу, улын табуы дөрескә чыкса?!. Шатлык, куанычының чиге булмаячак! Югары белемле врач та бит әле ул өстәвенә! Әтисе өчен өзгәләнеп, «Авыртмыймы, әти?..» — дип сораша-сораша, үзенә беренче ярдәм күрсәткән улын күз алдына китерде Гыйлем. Тамак төбенә килеп буылган төерне чак тыеп калды шунда...

Шул рәвешле, коймага сөялеп, урман һавасының рәхәтлегеннән изрәп хәл алып тора иде ул. Янәшәдә генә ишетелгән тавыш сискәнергә мәҗбүр итте үзен:

— Пароль!.. Пароль! — дип дәшә иде берәү аңа, кыргый дорфалык белән.

Ялгыш ишетеләме икән дип бакса, койманың аргы ягында шәүлә сыман берәү басып тора. Кайдан һәм ни рәвешле шулай якынаюын да абайламый калган ул аның. Әле һаман хәрәкәт итә үзе, башын түбән иган, йөз чалымнарын шәйләрлек түгел.

— Улым...— дип дәште Гыйлем, үз-үзен абайламас борын ук. Танып түгел, сискәнүдән, чарасызлыктан әйтелгән сүз иде бугай бу.

Шәүлә ишетмәде. Җавап та кайтармады. Тавыш килгән тарафка борылырга да кирәк санамады хәтта. Үзе һаман якынлаша, аңар төбәп килә. Күз карашлары гына читтә...

— Улым! Улым, Җантимер, син ич бу?!.

«Әйе, әти, бу мин. Ничек монда килеп чыктың? Ничек мине эзләп таптың?..»— дигән кайгырту сүзләре ишетермен дип уйлаган иде ата. Җантимер аңар күтәрелеп карамады. Аягастына текәлгән көе генә баягы сүзләрен кабатлады:

— Пароль... Паролең кая?

— Улым,— дип, өзгәләнеп, курешергә теләп кулын сузды ата. Алга омтылып куйды — таш койма...— Әллә әтиеңне танымыйсың инде, улым?!.

Таш ярыктан сузылган кулны читкә этәрде Җантимер. Тешләрен ыржайтып көлеп алды. Көлүен көлде, әмма бу көлүне, белмим, сау йөрәкле ир-атлардан башка тагы кем күтәрә алган булыр иде икән?! Иреннәре як-якка җәелеп алды аның, авызы ачылмады. Ә тонык шешә пыяласы төсендәге күзләре бөтенләй җансыз иделәр, хәрәкәтләнмәделәр. Күзләрендә генәме, йөзендә җан әсәре калмаган үзенең.

— Пар-р-роль? — диде ул, ватык патефон тәлинкәсе сыман тагы бер мәртәбә үз-үзен кабатлап. Әмма бу юлы «р»га махсус басым ясап, янап дәште.

Күрешергә зарыгып килгән, күзләрен мөлдерәтеп карап торган ата өчен, белмим, моннан да куркынычрак күренеш уйлап табарга мөмкин идеме икән?!. Басып торган җирендә чайкалып куйды ул һәм, егылудан сагаеп, уң кулы белән тимер-бетон баганага ябышты. Хәл алды шул рәвешле. Ә бераздан башын югары күтәрде:

— Капка кайсы якта, улым?

Баш кагып икенче бер читтә караеп торган тимер капкага күрсәтте Җантимер. Койманың эчке ягыннан иң элек үзе шул тарафка атлап китте.

Ата күңелендә өмет җан биреп алды. Таныды... Уңайсызланды да кебек хәтта... Улыннан калышмаска тырышып атлады ул да.

Капка төбендә тагы күзгә-күз очраштылар. Киеренкелек кимемәгән. Шуны сизгән сыман, хәтта этләр берара өрүләреннән туктап торды. Гәүдәсен турайта төшеп, капкага аркылы чыгып баскан иде Җантимер. Гыйлем өчен берни аңлатмаган, беренче ишеткәндә шаяру дип кенә кабул ителгән, шул бер үк сүзен кабатлады:

— Пароль?..

— Ул ниткән пароль, хәрби склад сакламыйсыңдыр ич, улым?!. Ач капкаңны, керт, аңлашырбыз аннан,— дип, килгән шәпкә эчке якка узарга итенде Гыйлем. Әмма битараф салкынлык белән, аркылы

басып, борын сызгыртып торган улын үтә алмады. Хәле дә чамалы, түземлек турында әйтеп тә торасы юк.

— Пароленне күрсәт, бармы?..

Әллә чынлап та бер-бер хәрби объект саклыймы соң аның улы — як-ягына карангалап алды ата. Әмма берни аңлый алмады. Бәлки улы өчен бик әһәмиятледер ул җавап, хезмәт урынында шаярырга ярамый торгандыр...

— Бар,— диде Гыйлем. Мин әтиең ич, танымыйсыңмы әллә дигән сыман, күкрәгенә дә сугып күрсәтте.

Шул бер сүз кирәк булган икән Җантимергә җан керде. Иң элек, ирен читләре кыймылдап куйды аның, йөзе яктыргандай булды. Көязләнеп, кул чите белән чәчләрен сыйпаштырып алды хәтта. Тел очын чыгарып, иренен яларга керешүе генә гайре табигый тоелды. Иреннәре арасыннан тигез булып тезелеп киткән тешләре күренеп калды. Ә күзләр, күзләрдә — һаман тоныклык шешә пыяласы төсе...

— Пароль бар,— дип кабатлады Җантимер һәм капканы ачты.— Булгач, рәхим итегез! Нигә баштук шулай димисез? — Кулын сузып, ишегалдына таба юл күрсәтте. Түбәнчелек күрсәтеп, лакейлар сыгалыгы белән, билләрен бөгә-бөгә иелеп тә алды. Бер каршысына чыкты әтисенең, бер артына чыкты, иңбашларына ябышкан үзле балчык кисәкләреннән аралады аның өстен-башын.— Нигә аны баштук шулай димәдегез, рәхим итегез, хөрмәтлебез...

Таныды дигән уй җылы җил булып исте ата күңеленә. Әмма шунысы гаҗәп: ул «пароль» дигәне ни өчен кирәк булды икән — бер-бер тыңлап тору бармы икән әллә үзен?..

Кунакны өркетмәгез дигәнсыман, әледән-әле җир тырнап өрүләрендә дәвам иткән овчаркаларына йодрык болгап барды Җантимер. Ике адым саен диярлек, баш иеп каршысына чыкты. Авызында һаман шул бер үк сүз:

— Хөрмәтлебез... Хөрмәтлебез...

«Пароль» дигәнен аңларга да булсын ди. Ә менә ата-бабада булмаган бил бөгү, ялагайлык каян килгән моңар?.. Әтисен таныган икән, нигә бил бөгәргә кирәк үз әтисе каршында?! Әллә соң, башка бер-бер кешене улы санап, Гыйлем үзе ялгыштымы?.. Чираттагы мәртәбә каршысына чыгып бил бөккәндә, «хөрмәтлебез»ен кабатлаганда, игътибар белән күзәтергә өлгерде ул аны. Үз улы — Җантимер! Күзләренә генә нидер булган...

Нинди хәлгә төшергәннәр аның улын?! Кем эше?! Кем хуҗа булган аның улына?! Шуның өчен дип үстергән, шуның өчен дип укыткан идемени соң ул аны?! Үз әтисе дә ярдәм кулы сузмаса, бу дөньяда тагы кеме бар соң аның?! Кан сауган кебек булды ата йөрәгенә.

— Улым,— дип, жиң очыннан тотып алды ул Җантимерне.— Сиңа нәрсә булды, улым?!

Атаның әлеге сүзләрен янәшә баручы ишетергә дә теләмәде. Алдынарак чыгып, бил бөгеп алды һәм кулы белән ишарәләп, бер читтә торган кирпеч корылмага күрсәтте.

— Рәхим итегез, хөрмәтлебез!..

Корылмага әтисеннән алданрак барып җитеп, кесәсеннән бер бәйләм ачкыч чыгарды Җантимер. Шәхси гаражны хәтерләткән сарайчыкның ишекләрен ачты. Керделәр... Ата белән ул икәүдән икәү генә калды.

— Йә, хөрмәтлебез?..— дип, җәлт кенә әтисе каршысына чыгып туктап калды Җантимер. Күзләренә карамады, кесәләрен айкады ул Гыйлемнең. Тел очы белән иреннәрен яларга кереште. Ә авызының ике як читеннән бер тоткарлыксыз мул селәгәй агып төшкән.

Өнемме бу, төшемме дип хәйран калган ата, бу күренешне күтәрә алмыйча, карашын читкә борды. Аның улымы соң бу?.. Тетрәндергеч һәм чиркангыч күренеш!.. Игътибарын читкә тайпылдыру максатыннан, әлеге сарайчыкның эчке күренешен тикшерергә кереште. Тәрәзә,

форточкаише нәрсәләр юк иде монда, күрәсең ул, кар базы янсә азык-төлек складь итеп төзелгән булгандыр. Караңгы почмакта сиртмәле тимер карават тора. Димәк, аның улы яшәгән торак шушы була, дип уйлап өлгерде ата. Күзгә ташланырдай берни юк башка, карават башында стенага эленгән асылмалы шкаф. Һәм шыр ялангачлык...

— Пароль! — диде Җантимер коры гына. Әлеге паузаның мәгънәсенә төшенә алмый аптыраган иде ул да.

Асылмалы шкаф пыяласы артында тәртипсез аунашкан кәгазь коробкалар, пыяла ампула һәм шприцларга күзе төште атаның... Тәне кызышты. Колаклары чыңлый башлады. Күз аллары караңгыланды... Менә ни өчен һәм нәрсә хакына үз-үзен корбан иткән аның улы! Менә ни өчен ул кара урман уртасында! Менә нәрсәгә алыштырган ул әтисен! Дөньясын алыштырган! Иманын!.. «Иман» дигән уй каян килде әле аңар?.. Келт итеп, әле ике генә көн элек мәчет ишегалдында булган очрашу килеп төште хәтеренә. Ак сакаллы карт — «бәхет» иясе...

— Кемгә хезмәт итәсең?.. Кемгә бил бөгәсең? — дигән аваз бәреп чыкты ата күкрәгеннән.

Мәчет картын аңларга да була, аллага хезмәт итәм дип ышандырган ул үз-үзен. Бу дөньяда кешечә яши алмавының әҗерен теге дөньяда — ахирәттә кайтарырга җыена. Ә моның максаты нидән гыйбарәт?!

Әтисе күкрәгеннән чыккан авазны да ишетмәде Җантимер. Аның йодрыкларыннан алмады карашын, анда үзе өчен алып киленгән көчтәнәчләр бардыр дип көтте. Пыяла күзләрен мөлдерәтеп, кулын сузды хәтта. Авыз читләреннән агып төшкән селәгәй, иякне узып, тамарга җыена иде инде.

Юк, үз улына суга алмады Эт атучы Гыйлем. Нәфрәт һәм ачуга караганда, аталык хисе һәм кызгану мең кабат көбрәк иде аның күңелендә. Җантимернең, хәер эстәүченекедәй, үзенә сузылган кулларын күргәч, чайкалып алды, авып китә язды ул. Шәфәкъ төсе иңгән күзләреннән уылдык сыман эре-эре тамчылар бәреп чыкты.

— Улым,— диде һәм, хәлсезләнеп, артка чигенде. Ни эшләргә, бер башын кая куярга белми иде ата.

Җантимер ишек катында. Аның киң җилкәләре болай да баз караңгылыгына чумган сарай эчен кичке эңгер-меңгердән каплап тора. Урнашып алган тынлыкны карлыккан аваз бүлдерде:

— Сезне, хөрмәтлебез,— дип, урам якка ымлады Җантимер,— анда көтәләр булса кирәк... Һәм елмаерга итте, авызын ерды.

— Мине?! — дип гаҗәпсенде ата.

— Сезне, хөрмәтлебез!

— Кемнәр?..

— Арсланнар һәм кенәриләр...

Саташа... Булуы житкән дигән уйлар үтте ата күңеленнән. Бер җөмләсен, бер генә хәрәкәтен дә аңлый алмый иде ул үз улының. Икесе ике дөньядан килгән ике зат, ике телдә сөйләшәләр иде диярсең...

Чигенер урын да юк иде атага. Бу дөньяда аның бердәнбер кешесе — улы бар. Каршысында тора. Бөтен ихтыяр көчен туплап башын күтәрде ул, стенада эленеп торган пыяла капкачлы шкафка карап дәште:

— Җыйган байлыгыңмы?..

— Әйе, хөрмәтлебез!..

Менә ничек дип уйлап куйды ата. Аңарга ни кыларга кала инде хәзер... Кинәт, күкерт сыман кабынып, үз-үзен белештермичә, шкафка ташланды ул, «эх» дигәнче, стенадан да суырып алды, тимер-бетон идән өстенә дә тотып тондырды. Пыяла кисәкләре Җантимернең аяк очына ук чәчрәде.

— Бирермен мин сиңа «хөрмәтлене»!.. Бирермен...— дип, сүгенә-җикеренә, идәнгә чәчелгән нәни тартмаларны таптарга кереште Гыйлем.

Пыяла ампулалар, шприцлар шытыр-шытыр килеп ватылды, чәрдәкләнде аның аяк астында. Шашкан кеше сыман сикергәли-тибенә таптады ул. Җир йөзендә булган иң әшәке хәшәрәтне изәмени...

— А-а-аһ,— дигән җан авазы яңгырады ишек катындагы Җантимердән. Әтисенең ниятен сизеп, нәтиҗә ясап өлгерә алмый калган иде ул ни сәбәпледер. Әле дә аның хәрәкәтләре гайре табигый килеп чыкты: үз хәзинәләрен коткару өчен йөгереп киләсе урында, ишектән үк чыгып чапты ул. Умарта кортларыннан качкан малай сыман, кулларын баш очында яман болгап, ишегалды буйлап капкага таба әлдерде.

Танырдымы әллә?.. «Хөрмәтлебез» дигәненең үз әтисе булуына төшендеме?.. Оят килдеме әллә үзенә?.. Оятыннан, ни эшләргә, кая барып бәрелергә белми йөгерүеме?.. Шундый сораулар узды ата күңеленнән. Сикергәләвеннән туктап, анда-санда качып калган ампулаларны иpле генә сытарга керешкән иде инде ул. Барысы да көйләнер, ипләнер, шәт. Шушы тузга язмаган нәрсәләреннән генә котылсын...

Бу юлы да ялгышкан булып чыкты Эт атучы Гыйлем. Бер атлаганда өчәр-дүртәр метр ара сикереп котырынып өрә-өрә, өстенә килгән ике овчарканы күргәч кенә төшенде ул үзенең ялгышканлыгына. Әмма нинди дә булса бер-бер чара күрергә, һич югында, ишекне эчке яктан ябып куярга да соңарган иде инде. Этләр өермә булып ишектән бәреп тә керделәр, сузып та салдылар аны бетон идәнгә. Арка белән барып төшкән җиреннән, йөзтүбәнгә борылып ятарга гына өлгерде... Пиджак җиңе, чалбар балаклары бер мизгелдә йолкып атылды. Котырынып өрүләрендә дәвам иткән этләрнең теш катылыгын, тырнаклары үткенлеген тоярга өлгерде ул. Дүрт аяклап тимер-бетон идәнне тырнады этләр. Ярсып өргән этләрнең теш араларыннан аның муенына кайнар күбек чәчрәп торды.

Этләр холкын яхшы белгәненә күрә, башын да калкытмады Гыйлем. Сулыш алыр арасы да юк иде аның: менә хәзер, менә хәзер өзгәләп атачак аны овчаркалар... Тирән чокыр төбендә ятып калган велосипедын искә алды ул. Үз улы тарафыннан шушы дәрәҗәдә мәсхәрәләнәсен белсә, үзенә дә шунда гына ятып калырга кирәккәндер дә бит. Беркем күрмәс, эзләмәс тә, һичкем берни белмәс иде. Ә монда, үзе генә түгел, улын да гаепләячәкләр. Шунысы үкенечле!

Этләр аның саен котырыныбрак өрә башлады. Тырнак асларыннан ут чәчри... Бер-бер артлы түшәмгәчә сикерәләр дә аның аркасына ташланалар. Ә ишек турына ниндидер шәүлә килеп баскан, этләренә җикеренә, этләрен өстерә:

— Фа-а-ас.. Фа-а-ас!..

Элегрәк этләрне «өс-с, өс-с» дигән аваз белән өстерәләр иде. «Өс-с»— эт телендә куала, куркыт дигәнне аңлата. Хәзер исә, әнә шулай, «фасс» ди-ди котырталар икән этне. Бусы инде: кабып йот, ботарлап ташла дигән боерык.

Башын кочаклап, колакларын томалап яткан Гыйлем шул берничә минут эчендә бөтен гомерен күз алдыннан уздырырга өлгерде.

Әтисе булган аның. Сөйләүләренә караганда, берөзлексез эштә — уку-язуда булган. Кайчак, төннәр буе кузгалмый утыра торган булган эш өстәле артында. Язучы булган, галим булган диләр... Язучыдан әсәр, галимнәрдән мирас кала... Ә ул әтисенең әсәрләрен дә, гыйльми хезмәтләрен дә белми. Истәлек өчен, дәфтәр калынлыгы гына булса да китабы калмаган... Үзе дә онытылган. Исеме дә... Фәнгә булсын, халыкка булсын, кирәге калмаган. «Халык дошманы» дигән атын да искә алучы юк инде хәзер. Кеше яшәгәнме-юкмы — белүче юк...

Әнисе бар иде аның. Бөтен гомерен аны — бердәнбер улын тәрбияләргә сарыф иткән ялгыз һәм тол әнисе... Кышкы озын кичләрдә, китап киштәләре каршысындагы креслоларга утырып, әңгәмә кора иде алар. Әнисе аңар ниндидер китаплар күрсәтә. Ул китапларны язучылар

турында сөйләгәндә, үзе бетми... Әледән-әле нелә төшеп аны аркасыннан сөя: «Ярый әле, улым, син бар,— ди-ди куана.— Үсеп зур кеше буларсың... Әтиең өлгермәгән эшләрнең һәммәсен тормышка ашырырсың...»— дип кабатлый иде еш кына. Нинди эшләр булгандыр, ул кадәресен хәтерләми инде Гыйлем. Әйе, әнисе бар иде аның. Ул да юк инде хәзер. Гыйлем үлгәннән соң хәтерләүче дә булмас үзен...

Гыйлемнең улы — Җантимер дә бар ич дөньяда. Тыйнак һәм сабыр Җантимеренең сабый чакларын хәтерләде ата. Улы — аның бердәнбере, Гыйрфановлар нәселенең дәвамы, киләчәге, соңгы могиканы... Ул, бары тик ул гына, Гыйлемнең тормышка ашмаган хыялларын хакыйкатькә әверелдерергә, Госман Гыйрфановлар нәселеннән мин дип әйтерлек эшләр башкарырга сәләтле булыр иде дә бит... Әле бүген, велосипедка атланып юлга чыккач та, бер түгел, әллә ничә мәртәбәләр өмет һәм ышаныч белән хыялланып алырга өлгерде ул бу хакта.

Ишек катында катып калган Шәүлә этләренә җикеренде:

— Фасс... Фас-с-с...

Еланнан да болайрак ысылдауга охшаш иде бу. Этләреннән канәгать түгел ул, шуңарга ысылдый.

«Гөнаһсыз сабыйларның күз яшьләре каргыш булып төшсен!.. Үлемең этләрдән булсын!..» ди-ди каргаган иде аны теге карчык. Әллә ниләр килә күз алдына: әнә, ул үзе — Гыйлем атлап килә урам уртасыннан. Аркасыннан оптик төзәү приборы булган мылтыгын салган. Зур күн итекләре белән ипле генә атлап килә ул, гүя авыл урамы буйлап хозурланырга чыккан. Камыт баулары шыгырдаган аваз, атларның пошкыруы гел кабатланып тора. Чана табаннары чиелдәп елый. Чана артыннан тамып барган тоташ кан юлларына баса-баса атлый ул. Һичнәрсәгә исе китми, берәүдән дә курыкмый. Авыл Советы биргән рөхсәт кәгазе бар чөнки кесәсендә... Авыл кешесе — бала-чагасыннан өлкәннәренәчә сагаеп, шик аша карый аларга. Әмма каршы әйтми, тәртип яхшы куелган. Үз этләренә дә үзләре хуҗа түгел алар... Хәтта үз-үзләренә! Буйсынмый кая барасың...

Ярым бөкрәйгән, тешләре төшеп беткән теге карчык юкка гына хәтеренә уелып калмаган инде аның — күпме эт атып, күпме авылларда йөреп, бердәнбер каргаучы булгандыр... Таянып килгән таягын болгый-болгый, як-ягына тәкеренә-төкеренә каргаган иде ул аны. Гыйлем кычкырып көлгән иде бер рәхәтләнеп. Ничек инде аны, кулында оптик приборлы мылтыгы булган шундый гайрәтле ир-атны, каргап куркытырга мөмкин?! Ай-һай беркатлы соң бу авыл карчыклары, әйтерсең, үз бил бавы белән кырып йөри ул этләрне. Тире эшкәртү комбинатына чимал җиту-җитмәү гаме юк аларның. Комбинатта күпме кеше эшсез тора чимал җитешмәү сәбәпле, техника тик тора... Суык якларда эшләүчеләр өчен җылы эт тиресеннән тегелгән итек-унталар кирәк! Бүрекләр... Туннар... Дәүләт эше белән йөрде Гыйлем... Үз-үзен кайгыртмады һичкайчан!

...Инде хәзер шиккә калды: каргыш дигәннәре дөрескә чыгамы соң әллә?! Аркасында әнә бозау кадәрле ике овчарка бии. Өрәләр... Бетон идәннең комын комга, цементын цементка аералар. Тик шунысы гаҗәп: этләр күпме генә котырынмасын, ни кадәрле генә ярсымасыннар, тән җәрәхәте ясамадылар Гыйлемгә. Этләрдә — этләрчә! Этләрнең үз әхлагы бар — яткан, егылган кешене тешләү, чарасызның бугазыннан алу кабул ителмәгән аларда. Ишек катындагы Шәүлә күпме генә ысылдамасын, күпме генә чәчмәсен төкереген, овчаркалар үзләренекен итте.

Билгеле, бу хикмәтне күреп, иң элек Шәүләнең кәеф кырылды. Илаңда ятучыдан да болайрак, үзенә буйсынырга теләмәгән этләренә кычкырынырга керешге ул:

— Фас-с... Фас-с... Әрәмтамаклар! Фа-а-ас-с...

Хуҗасы кычкыргачтын янә бер тузынып өреп, тырманып алалар

да бер-беренә карап туктап кала этләр, ни эшләргә белмиләр. Хуҗаларын аңлый алмыйлар алар...

Шәүлә кыза. Шәүлә һич кенә дә үзенекен итми тукталуны белми. Кулына ни эләксә, шуның белән сугарга, котыртырга керешә ул этләрен... Овчаркалар идәнгә йөзтүбән капланып хәрәкәтсез ятучыга тимәделәр. Ә бераздан өрүләреннән тәмам тукталып, алмаш-тилмәш сулкылдап чинарга керештеләр.

— Ах, әле сез шулаймы! — дип җикеренде Шәүлә. Муенчакларыннан эләктереп алды этләрне. Һәм аларны, идәндә хәрәкәтсез яткан Гыйлемнән аралап, ишегалдына таба өстерәде...

Баш исән дигән уй килде Эт атучы Гыйлемнең уена иң элек. Этләреннән аралады аны Шәүлә, чылбырларына бәйли, әнә... Сак кына башын күтәрер хәл тапты ул үзендә. Бармаклары арасыннан ишегалдына күз салды... Карады һәм тетрәнеп китте. Күзләренә ышана алмый торды, саташу гына түгелме бу?!

Шәүлә овчаркаларын чылбырга түгел, муенчакларыннан ике багана арасына тарттырылган юан тимерчыбыктагы ыргакларга асып маташа. Этләр, үзләрен ни көткәнлекне аңлый иде булсалар кирәк, сулкылдап чыйный, карышырга теләп тартылып карыйлар. Ләкин Шәүләнең куллары көчле һәм мәрхәмәтсез. Ике куллап штанга күтәргән сыман, югары өстерәде ул аларны... Буйсынмый хәлләре юк этләрнең дә. Чөнки Шәүлә — аларның хуҗалары! Этләрдә тәртип шундый — үзләрен тукландырган, тәрбияләгән, оя корып асраган кешегә һич карышусыз буйсыну кабул ителгән аларда. Әмерен үтәмәсәң, хуҗа буларак, ул сиңа үз хөкемен чыгарырга да хаклы. Үпкәләштән түгел!

Өрү кая, тимерчыбыкка асып куелган овчаркалар чак кына сулыш ала. Әллә нигә бер ишетелер-ишетелмәс кенә сулкылдап елаган — чинаган авазлары чалынды колакка. Җәза мәрхәмәтсез һәм кырыс, берни әйтеп булмый, арт аякларының тырнак очлары белән көч-хәл җиргә тияр-тимәс асылынып тора иде алар. Тетрәндергеч күренеш!..

Әле генә үзенә ярсып өргән, әле генә үз аркасында сикерешкән, башын калкыта калса, үзен өзгәләп атарга да әзер булган овчаркалар кызганыч тоелды Гыйлемгә. Җәза — аның өчен. Җәза — этләргә эт булып калганнары өчен!

Юан тимерчыбык, күрәсең, шул кадәр нык тарттырылган, бозау кадәр ике овчарка авырлыгыннан да сыгылмады. Җилгә киптерергә эленгән юеш чалбар балаклары сыман, акрын гына атынып, тартылып-тартылып куя иде алар асылынган җирләрендә. Алгы аяклары бушлыкны тырнап чәбәләнә. Муенчакка эленгән башларын, борыннарын югары чөеп, гүя күктән ярдәм көтә, ярдәм сорый иде алар. Ярымйомык күзләрен, әйтерсең лә, юеш томан урап алган.

Шәүләнең этләрендә дә, идәндә яткан үз этисендә дә гаме юк. Үз мәшәкатьләре аның: идәндә аунашкан катыргы тартмалар, пыяла ватыклары арасыннан энҗе бөртеге эзли диярсең... Әледән-әле мүкәләп китә ул идән буйлап, йә тукталып бер ноктага озак кына карап тора. Дер калтырана үзе. Әллә гыжлый, әллә җылый, гадәти булмаган сәер аваз чыгара үзе берөзлексез. Чыра кисәкләре алып, тупса янындагы ярыкларны каезларга кереште...

— Улым, Җантимер,— дип дәште түземлеген җуйган ата.

Шәүлә ишетте аны. Күтәрелеп карагандай итте тавыш килгән якка. Әмма исе китмәде, йөзенә булсын, күзләренә булсын, һичнинди үзгәреш чыгармады. Караңгы мич артында берөзлексез кычкырып теңкәгә тигән чикерткә тарафына гына шулай күз салалар. Тавышы ишетелә, борчый, тынгысызлый, әмма үзе юк. Һәм аны эзләүдән дә файда булмаячак...

— Ни эзлисең, улым?! Мин монда... Әтиең!..

Шәүлә, өметен өзеп, яңадан борыс тирәсендәге ярыкларда акта-

рынуын дәвам иттерде. Күсе сыман кыштырдый-кыштырдый, карават астына кереп китте бераздан...

Ишегалды ягында этләрнең берсе сулкылдап алганы ишетелде шунда. Бер ишегалдына, бер карават астында кармаланган Шәүлә тарафына карангалап торды Гыйлем. «...Этләр кызганыч — аның өчен газап чигәләр!..» Тезләренә таянды. Аннан ипле генә чүгәләде. Сынык кабырга чәнчеп алды. Хәлсезлектән изрәгән тәнне уятты кабырга. Аягүрә торды һәм сак кына атлап, ишегалдына юнәлде ул... Юлына каршы төшүче, туктатучы булмады. Артыннан да ияреп чыгучы юк иде аның.

Кичке эңгер-меңгерне уятып, бер түгел, дүрт күз янып тора иде аның каршысында. Этләрнең як-якка салынып төшкән башлары аңарга текәлгәннәр: «Коткарсаң, син генә коткара аласың», ди иде сыман алар. «Үч саклама, билгесез кеше!.. Без этләр — өрми чарабыз юк иде. Тәнеңә яра салган булсак та, ачуланма — без этләр генә бары... Ә син кеше. Кеше булып кала күр, зинһар?!»

Янә бер кат сарай ишегенә күз төшереп алды Эт атучы Гыйлем: «Чыгып килмиме?.. Күренмиме?..» Әллә курка да иде инде ул үз улыннан? Бар тәвәккәллеген җыеп, ике-өч адым алга атлады һәм тимерчыбыктагы ыргакларга үрелде ул — этләрне берәм-берәм үлем эләмәкләреннән азат итте.

Аяклары урман туфрагына тигәчтен дә этләр ни эшләргә, кая китәргә белми киерелеп-сузылып тордылар бер мәл. Җиңелчә чинау авазы калдырып, башларын салындырып читкә китеп бардылар.

Шәүләнең тавышы-тыны юк. «Этләр белән мавыгып, үз улын оныта язган түгелме соң Гыйлем?!.» Сарай ишегенә әйләнеп кайтты ул. Җантимере, кылган «этлекләре» өчен үкенеп, бер караңгы почмакка поскандыр да үксеп елап утырадыр кебек иде. Монда, этләрдән дә, аның үзеннән дә кызганычрак хәлдә калган Җантимер бар бит әле...

Чынлап та, караңгы почмакка сыенган булып чыкты Шәүлә. Пинжәк һәм күлмәкләрен бер читкә салып ыргыткан да шәрә беләгенә кәкрәеп сынган укол инәсен тыгып маташа... Ни эшләгәнен белешми, атылып керде ата. Шәүләнең кулыннан кош баласыннан да болайрак кадерләп тоткан шприцын йолкып алды. Алагаем кизәнеп, идәнгә тотып бәрде...

Йолкып алынган шприц артыннан пружина сыман суырылып менде Шәүлә, аякларына торып басты. Ни өчендер уңга-сулга карангалап торды бер мәл. Аннан күзләрен челт-мелт йомып алды. Һәм, гел көтмәгәндә, авызын килбәтсез рәвештә зур ачып, тешләрен ыржайтты:

— Үтер-р-рәм!..

Берни абайламый калды Эт атучы Гыйлем, муен тамырына тукмак сыман йодрык килеп төште. Гөлт итеп ут кабынып-сүнде күз алдында. Ул да түгел, нәкъ шул мизгелдә, ике бот арасына китереп типте кемдер. Чайкалырга да ара булмады, гөрселдәп бетон идәнгә авып төште ата. Инстинкт беләнме, әле бая гына котырган этләрдән котылган рәвешле, йөзтүбән капланып, беләкләре белән башын яшерергә азапланды. Гүя каршылык күрсәтмәгән ярдәмсезгә кагылмаслар...

Шәүләнең тонык пыяла сыман күзләрен кан баскан иде инде. Үзүзен белештермичә, кыргый авазлар чыгара-чыгара, аяк астында хәрәкәтсез ятучыга ташланды ул. Типкәләргә, таптарга керешге... Бетон идән өстендә бөгәрләнеп ятучының кай җиренә типкәнен һәм ничек таптаганын белми изде, котырынды Шәүлә. Әйтерсең, җир йөзендә булган иң куркыныч ерткыч бөгәрләнеп ята иде аның аяк астында, гүя ул әкиятләрдә генә була торган җиде башлы аждаһа елан белән көрәшә. Дию пәрие белән...

Авызыннан берөзлексез ак күбек чәчелеп торды Шәүләнең, авызында бер үк сүзләр:

— Үтер-р-рәм!..

## 37

Кул буена кунак төшкән кич иде. Күп булса, йөз-йөз илле метрлар чамасы арырак, ак кирпечтән торгызылган корылма ишегалдындагы җәннәт почмагында арысланнар һәм кенәриләр кәеф-сафа корып утыра иде шул мизгелдә. Мәҗлес түрендәге Белялыч, креслога чалкан ятып, шампан шәрабе чөмерә. Аның дәү бүксәсенә башын куеп, нәни кенәри Гуля-Гөлсинә сырпалана. Юк-юк та, гел көтмәгәндә чыркелдәп көлеп җибәрә әледән-әле. Кенәриенең көлүе Белялычның үзәгенә үтә, дәү корсагын уңга-сулга авыштырып утырган җирендә борсаланып ала ул, калын иреннәрен яңа табадан төшкән коймак кебек җәеп көлеп җибәрә. Кәеф шәп! Борис учак тирәсендә чираттагы шашлыкны хәстәрли, яшь чучка баласы маена кушылып, уксус һәм вино агып төшә утлы күмер өстенә — борын тишекләрең түзсен... Капкаев каяндыр тагы бер тартма шәраб күтәреп килде... Икенче бер читтә, изүләрен чишеп, күлмәк җиңнәрен сызганып ук җибәргән Арслан Асиягә үзенең мәхәббәтен аңлата, назлы сүзләр тезә...

Әле генә шартлау авазы чыгарып ачылган шешәне иң элек Белялычка күтәреп килә Капкаев:

— Сездән башлыйм, Белялыч...

— Рәхмәт, Капкаев!..

— Әйе, Капкаев,— диюченең бәхет колакка ук барып җиткән. Бәхетле күзләре елык-елык килә.

— Миңа да, Капкаев! — Гуля-Гөлсинә дә суза касәсен.

Касәләрдән тулып ага шәраб. Бәхет мөлдерәп тора...

— Яле, Капкаев, җырлап җибәрәбезме әллә үзебезнекен?!.

Авыз гармуны ерак түгел, кесәдә генә.

Барган идем Әсмаларга...

Хәйран калып, тын да алмый тыңлый арысланнар һәм кенәриләр — җыр ошый һәммәсенә. Капкаевның таланты алдында битараф калу, гомумән, мөмкин дә түгелдер ул.

— Тагы бер җырла әле, Капкаев!

— Җырла!

— Җырла...

— Бу җыруым сезнең өчен, Белялыч! — Сәхнә итеп, киселгән агачтан калган юан төп башына ук сикереп менә, кош булса җилпенеп очар иде шунда Капкаев:

Барган идем Әсмаларга,
Кер чайкый басмаларда...

## 38

Эш эзләү, эшкә урнашу мәшәкатьләре белән йөреп, вакытның ничек узганлыгын да сизми калды Фидаил. Якшәмбе көн кичкырын Эт атучы Гыйлемгә юнәлде: «Көтә торгандыр... Улын табышырга вәгъдә иткән иде бит...»

Ишек бикле булып чыкты. Шунда гына Фидаил үзенең, теге көнне Гыйлемгә улы хакында, кул буе хакында сүз катып, хаталанганын аңлады. «Улын эзләргә чыгып киткән!..»

Урамга атылып чыкты ул. Беренче очраган яшел күзле такси аныкы иде. Алгы ишекне ачып, шофер белән янәшә кереп утырды:

— Куала, тизрәк бул!..

Артына ут капкандай ашыгучы пассажирга карап, битараф кына башын чайкады таксист егет.

— Аңламадым...

Беләсез ич: таксист халкы син ашыксаң — кабаланмый, башка чакта артына ут капкандай куалый торган була. Моның сәбәбе нидә дә хикмәте нидә икәнлеген әйтә алмыйм кисеп кенә. Шулай да... Кешегә хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләгән бик зур күпчелеккә хас сыйфат бу. Бер максатсыз, бернинди сәбәпсезгә кешенең кәефен кырудан тәм табалар!.. Соң чиктә ул үзе начар кеше дә булмаска мөмкин, танышып сөйләшеп китсәң, менә дигән булып чыгуы да ихтимал... Шулай да йомышың төшмәсен, үтенечең тумасын үзләренә! Хет егылып үл каршыларында, теңкәңә тими торып, сине тыңламыйлар...

Яшь булуына да карамастан, әлеге таксист та профессиональ шул сыйфатны яхшы үзләштергән булып чыкты.

— Кузгалыйк! Мин ашыгам...— дип кабатлады Фидаил, сулышын чак тыеп.

Пассажир ашыга... Димәк, таксист рәхәтләнеп көлә, чыгып тәрәзәләрен сөртеп керә ала... Көзгеләрен рәтләштерә иплe генә...

— Исерек дисәң, исерек түгел, син нәрсә, брат?!

— Ашыгам мин. Әйдә, кузгалыйк тизрәк?!

— Ташбака да ашыга, ха-ха...

— Кузгалыйк дим!..

Таксист кеше елмаюын белә, кызык ич:

— Сәер кеше син, брат... Кая барырга икәнне әйт!

— Ә-ә,— диде Фидаил уңайсызланып, үзе гаепле икән ич.— Аккош күленә!

— Шәһәр читенә чыгарга ярамый, брат! Булмый...

— Миңа бик тә кирәк.

— Кирәкнең беткәне юк, брат... Булмый, төш.

— Барырга яраганны беләм, мин үзем шофер... Әйдә зинһар!.

— Үз машинаңда барасың инде алай булгач! Син ашыга дип, мин штраф түләргә, правосыз калырга тиешме?!. Булмый дигәч булмый, брат.

— Штрафны үзем түләрмен...

— Түләсәң соң, ГАИ кесәсенә акча кергәннән мин баемыйм!

— Үзеңә дә өлеш чыгар, кузгал гына... Анда кеше... Ярдәм итәргә кирәк,— дип, тешләрен кысып түзде, гозерләвен дәвам итте Фидаил. Чөнки ул яхшы белә — буш такси тоту җиңел эш түгел. Монысыннан колак каксаң, икенчесен сәгатьләр буе көтүең ихтимал. Сайлап алу хокукы булмау, конкуренция юклык түбәнсетә кешене.

Таксист та ул кадәре өметсез күренми. Әнә кызыксыну белдерә түгелме соң:

— Барсам, күпме түлисең?

— Кузгал гына... Әйдә, күпме сорасаң, шулай түләрмен.

Акча исәбе турында уйлаудан ераклашкан иде инде ул. Ә таксистны, әлбәттә, мондый җавап канәгатьләндерми.

— «Күпме сорасаң» дигән берәмлек юк акчада... Сумманы әйт, брат?!.

— Унны алырсың,— диде Фидаил, алдын-артын уйламыйча. Ун сум — аның өчен зур акча. Ярты көн йөк бушатырга туры килә ун сум өчен.

— Бер чирек! — Таксистның үз таксасы.— Син нәрсә, дус кеше, унлык өчен шәһәр читенә чыгып тормыйлар...

— Синеңчә булыр, кузгал.

— Акчаны алдан,— дип елмайды, ниһаять, яхшы ук эшләп алу мөмкинлеген чамалап алган «хуҗа».— Тәртип шундый. Синең кем икәнлегеңне мин каян белим. Акча!..

Йөзенә төкерергә төкеререң кызганыч булыр иде башка чакта, әмма

бәхәсләшер ара юк. Кем белә, Эт атучы Гыйлем бәлки аның ярдәменә мохтаҗдыр, аның аркасында бәлагә тарыгандыр... Ә ул сатулашып ятсынмы?..

Иренеп, теләр-теләмәс кенә бармак очы белән эләктереп алды таксист егерме биш сумлыкны һәм чалбар кесәсенә салды.

— Ярар,— дигән булды, кузгала башлап.— Сүзеңне тыңлап кына барам...

Дәшмәде Фидаил. Ян тәрәзәгә текәлеп, үз уйларына чумды. «Бер сыер бөтен көтүне буйый, дигән кебек. Менә шундый затлар аркасында кешедә таксистлар һәм, гомумән, шофер халкына мөнәсәбәтле дөрес булмаган фикер чыга... Намуслы, кешелекле шоферларны да аз белми ич ул...»

Ярымутрауга керү юлы никадәрле генә бормалы һәм буталчык булмасын, алар адашмады. Фидаилгә яхшы таныш юл... Туп-туры тимер капка каршысына ук килеп туктадылар: Хәрәкәт, тавыш-гауга күренми. Көзге урман сарылыгы һәм кечке эңгер-меңгер тантана итә әйләнә-тирәдә. Иң гаҗәбе, хәтта этләр өргән аваз ишетелми. Машина килеп туктау түгел, кигәвен очып узганда да сагаеп капкага күз сала торган каравылчы Җантимер дә күренми.

Кабинадан чыкты. Атларга-атламаска белми, бертын як-ягына карангалап торды, тынлыкка колак салды. Сәер тынлык!.. Җантимер кая икән соң?.. Овчаркаларга ни булган? Урман шаулаганы ишетелми хәтта.

Кузгалырга җыенып, тизлекне тоташтырган таксист та, нидер сизенеп, аягын муфтадан ычкындырмый сабыр итте.

— Нәрсә, көтүче юкмы әллә үзеңне? — дип кычкырды ул, тәрәзәдән башын тыгып.

Нәрсә аңлата иде соң бу тынлык, ничек аңларга? Әллә соң Эт атучы Гыйлем, аңардан өлгеррәк булып, үз улын шәһәргә алып кайтып киткәнме?.. Таба алмыйча, башка күлләр тирәсендә каңгырап йөриме әллә?..

— Китимме, көтәргәме? — дип кычкырды таксист. Машинасын әледән-әле гүләтеп торды үзе, газга басты.

Кулын сак кына күтәреп, «булдыра алсаң, көт аз гына, сабыр ит», дигән хәрәкәт ясады Фидаил. Шофер аңлады, машинасын сүндереп, ул да һава суларга чыкты.

— Таксометрны җибәрдем,— диде үзе, Фидаилне ашыктырып.

Ипле генә тимер капкага үтте Фидаил. Гадәттә ике-өч бик астында торган капка, ни гаҗәп, ачык булып чыкты. Эчке якка аяк басты. Кыяркыймас кына атлап китте. Шунда гына ишеге шәрран ачык торган сарайны шәйләп алды.

— Биш-ун минуттан артык көтә алмыйм, брат,— дигән аваз ишетелде аргы яктан. Таксист тавышы.

Аның шулай кычкыруы Фидаилгә көч өстәде: ялгызы түгел ич!

Сарайның тупсасында ишегалдына арка куеп ниндидер кеше утыра иде. Җантимер... Аны тану кыен түгел иде. Бары аңарда гына мондый гәүдә, шундый җилкәләр... Ишек тупсасында утыручының игътибарын җәлеп итәсе килеп, тамак кырып алды ул. Теге, гүя кадакланган, кымшанмады хәтта..

Ниһаять, янына ук килеп җитте. Борын мышкылдатып карады, нәтиҗәсез. Шунда гына Җантимернең җилкәсе өстеннән сарай эчендәге хикмәтне күреп алды ул һәм тетрәнеп китте: Җантимернең аяк очында гына овчаркалары. Арырак тагы кемдер, нәрсәдер бар кебек идәндә. Аермачык күреп кенә булмый, караңгылык урап алган...

Йөрәге «жу-у» итеп куйды Фидаилнең. Ләкин бер үк вакытта бары да тыныч һәм ипле кебек үзе. Гомер булмаган хәл, этләр булып, аларның тавыш-тыннары юк. Ничек аңларга, нәрсәгә юрарга белерлек түгел иде әлеге күренешне. Башын йодрыклары белән терәп хәрәкәтсез калган

каравылчы һәм аның каршысында ук телләрен асылындырып, күзләрен зәһәр елтыратып утырган этләр... Ә арырак? Арырак — караңгылык, хәрәкәтсезлек.

Ни булган боларга?!. Нигә Жантимер сикереп тормый?!. Ни сәбәпле ике этнең берсе күтәрелеп чыкмый, өрми аңарга?!. Башка вакытта бит бу бинаның капкасына якын килергә ярамый. Шоферларга машинадан чыгу, як-якка карану тыела иде түгелме соң?!. Жантимер түгел, әллә аның жансыз шәүләсе генәме соң анда?!. Фидаил ничек аңласын да ни рәвешле күз алдына китерә алсын монда булып узган вакыйгаларны...

Жантимер танымады үз этисен. Дөрес, ул аны иң элек күргән-белгән кешегә чыгарган иде. Чит кешедән «пароль» сорый торган гадәте юк иде бит аның. Капканы ачып кертте. Хәтта сарай тупсасын атлатты. Ә шул кеше ышанычын акламады аның — күпме хәзинәсен юк итте. Сулый торган һава, ашаган ризыктан да кадерлерәк наркотикларына кул күтәрде. Алда торган озын кышка житсен ди-ди саклап килгән байлыгыннан мәхрүм итте. Кышлар озын була урманда, ә кунаклар сирәгәя.

Үзе тупсада утыра ул әле дә, үзенең булып узган вакыйгаларга ышанасы килми. Гүя төш күргән ул, нибарысы куркыныч бер төш. Аның биләмәсенә ничек итеп инде чит-ят кеше килеп чыга алсын? Кемнең һәм ни рәвешле аның сараена үтеп керергә, ул гынамы, иң кыйммәтле шкафына кул сузарга хакы бар?.. Баш икәү түгел берәүдә дә!.. Ә этләренең чит-ят кешене ботарлаудан баш тартуы — монысы инде сыймый да сыймый башка. Мәгънәсез бер әкият шунда!..

Әле дә төш күреп утыра түгелме соң ул?.. Нинди бетмәс төш булды икән инде бу — ни гомер айный алмый газаплана?.. Соңгы арада әллә нәрсә булды бит әле аның белән: аягүрә йөргәндә дә төш күреп, саташып иза чигә. Хәл алырга дип кая булса килеп утырса, каршысына әллә нинди албастылар йөгерешеп чыга. Ятты дисә, корсагына басып, шүрәле, жен-пәриләр биешә... Менә тагы үзен жыен хәшәрәт кортлар, күселәр сырган. Тешләрен шыгырдата-шыгырдата, аның сөякләрен, сеңерләрен кимерәләр. Күзен йомса, стенада таракан, кыргаяклар йөгерешә башлый, берсен-берсе уздырып, әллә ничә башлы зәһәр еланнар ысылдашырга тотына. Түшәмнән сикерешеп төшкән күселәр аяк бармакларын, колакларын, хәтта маңгаена басып, борынын кимерергә керешәләр. Кулларын бутый-бутый сугыша, тарткалаша ул алар белән. Сулышка каба... Йөрәк кага... Чигәләрне китереп кыса...

Болар барысы да төш кенә. Шулай икәнлекне үзе дә аңлый ул вакыт-вакыт. Әмма, онытылып китеп, аягүрә атлап килгән чагында да кайчак шул еланнар, әрсез күселәр белән сугышырга керешә. Сугышмас та иде, үзләре тынгылык бирмиләр аңарга... Сагалап кына торалар ялгыз калган чагын. Кулларын бутый-бутый качарга, котылырга тели ул алардан. Ә тегеләр аңардан да житезрәк йөгерә...

Бүгенге төш — кешеләр катнашында. Кешеләр һәм аның үз этләре. Төштә дә үз этләреңнең хыянәтен күрү авыр икән ул!.. Тукта, уяу түгелме соң ул: менә баш... менә колаклары, чәчләре дә үзенеке... Гажәп, үзе уяу, ә үзе төш күрә. Баягы саташуларыннан аерыла алмый газаплана түгелме?!. Тупсада утырамы — тупсада. Йодрыклары имән борысны, аяклары бетон идәнне тоялар. Кичке урман һавасын, исеп алган жилне тоя, әнә... Этләренең еш-еш сулыш алуларын. Барысын да тоя! Ә идәндә аның саен төш дәвам итә: Тыңлаусыз этләр... Кеше сурәтенә кергән ниндидер афәт бөгәрләнеп ята. Дөрес, карышмый ул, хәрәкәтләнми дә инде. Әмма юкка чыкмый һаман. Тизрәк күз алдыннан китүен, күл өстендәге иртәнге томан сыман таралуын, юкка чыгуын тели аның Жантимер. Ә тege китми, ята... Күсе, елан ише хәшәрәтләрне таптый торгач, алар булып, алар качышып бетә торганнар иде. Бу — ята. Монысын куркыта алмады.

Юк, барыбер ул дигәнчә булачак. Хәл генә алсын менә, яңадан торып керешәчәк ул аңарга. Аһ-ваһына, ыңгырашуларына да карап тормас, йә качып котыла, йә жиргә сенә...

Идәндә ятучы сак кына башын калкытып алды. Саташу һәм төшләр вакытында һәммә җен-пәриләр, шулай, кеше булып сөйләшә:

— Улым,— дип дәшә, әнә, әлеге кеше сурәтендәгесе.— Җантимер, ни булды сиңа?!.

Исемен дә беләләр... Кайчак, күсе булып күселәргә кадәр аңар шулай үз исеме белән дәшә. Алдарсыз Җантимерне алай гына. «Улым», имеш... Каян килгән эти?... Беркеме юк Җантимернең! Әнисе юк! Әтисе юк! Гомумән, япа-ялгыз ул! Бу тормышта һәммә кешеләр шулай япа-ялгыз! Һәркем үзаеры!.. Һәркем үзе өчен генә... Башкаларның шатлыгында да, кайгысында да эше юк кешеләрнең... Кешеләр, әнә, урмандагы көзге яфраклар сыман алар. Һәркайсының югарыда, югарыгы ботакларда эленеп торасы килә. Ә тормыш — җил — тарта, йолкый. Мәңге югарыда торырмын дип үз-үзләрен ышандырган яфракларны йолкып кына ала һәм берсе өстенә икенчесен туфрак итеп өя.

— Улым.— диде әнә тагы. Кара син аны, аваз бирә.

Җантимер аның башына китереп басты. Тыны чыга, сулыш ала әнә. Күкрәгенә типкәләргә керешә... Нинди вәхшилек, бу төшкә ниләр генә керми. Ул инде өнендә дә сугыша шулар белән.

Әле бая, шушы идәндә ятучыдан үз овчаркалары аралады аны. Аның үзе өстенә сикерделәр. Аны яклап түгел, идәндә ятучыны яклап. Төш диген инде менә син шуны! Үз овчаркалары, әнә, якын да җибәрми, кузгалдыңмы ырылдарга керешәләр. Тагы аердылар аны, тупсага кысрыкладылар. Чит кешене яклап маташалар. Һай, ниләр генә керми бу төш дигәнеңә!..

Идәндә ятучы ыңгыраша. Ишегалдында икенчесе килеп җиткән тагы. Аңарга дәшә әнә:

— Әй, Җантимер, тор, нишләп утырасың анда?!.

Елан һәм күселәр гел шулай төрле яктан сырып ала торган иделәр аны. Төшеңә кешеләр кереп тинтерәтергә керешсә дә кызык түгел икән. Һәркайсы аңарга дәшә, һәркайсы исемен белә аның — үз итүләре янәсе...

Урам якта машина кычкырта түгелме тагы?!. Анысына ни кирәк?.. Мондагы тәртипне белми! Димәк, төш кенә... Бу ярымутрауга юлны белгән шоферлар тәртипне дә яхшы беләләр — тавышланырга ярамый, зур кешеләр (!) ялын тынгысызларга ярамый. Зур хуҗалар килгән чакта эт булып этләргә өрергә ярамый! Ә ул, әнә, машинасын кычкырта... Бәрәч, койманың аргы ягыннан да кеше кычкырганы ишетелә түгелме соң?

— Әй, син, күпме көтәргә була?..

«Бер дә төш димәссең, монысы гел кешеләргә охшатып сөйләшә түгелме?!.»

— Әй, сиңа әйтәм, нигә анда багана булып каттың?..

«Саташу! Җантимер утырып тора. Ә багана басып торырга тиешле, утыра белми багана...»

Саташу булмаса, этләр колак салыр иде шул тавыш килгән якка. Алар, әнә, аның аяк очында гына хәл алып яталар. Үз этләре аны каравыллый, үз хуҗаларына кымшанырга ирек бирмиләр — менә әкәмәт!.. Тукта, тагы машина кычкырта. Янә теге аргы яктагы тавышы:

— Минем план бар, слушай, брат...

— Булса соң, мин сине тотып тормыйм...

— Сиңа ни калган монда?.. Әйдә, караңгылана...

— Ашыксаң, кайт!

— Син дә кеше баласы ич... Тагы биш минут көтәм, ярыймы, брат!

«Бу нәрсә бу?!. Үзара сөйләшәләр! Булмас?!.»

— Ярар, көт алайса...

— Ләкин исеңдә тот, брат, без килер юл хакын гына килештек!..

— Акча дигәндә, чукынырсың икән...

«Җантимернең биләмәсе ят кешеләр белән тулган түгелме соң?!. Төш булмыйча, әгәр болар һәммәсе чынбарлыкта, өнендә шулай килеп

чыкса — ул очракта ни булачак?!. Зур хуҗалар монда... Теге шәрә башлысы иманын укытачак ич болар өчен... «Пароль» ташуыннан туктаячак. Кандала урынына киптереп, нарат ботагына асып куйса?..»

Баш очында гына кеше сулышын тоюдан сискәнеп китте Җантимер һәм сикереп үк торды. Аның белән бергә үк, шелтәле ырылдау авазы чыгарып, овчаркалар күтәрелде... Идәндәге кеше дә башын калкытырга итте. Ләкин күтәрелерлеген калдырмаган иде инде аның Җантимер, күтәрелгән башы «лып» итеп кире бетон идәнгә авып төште.

«Аңышырга кирәк: өнеме, әллә төшеме бу?.. Үз аякларында басып тора түгелме соң?!. Капшанды, чеметеп карады үз-үзен. Үзе! Идәндә ятучының да ыңгырашуы чынга охшаган. Төштә булса, сикереп торыр иде дә кычкырып көлеп җибәргән булыр иде ул хәзер. Ә бу — ята... Ишегалдындагысы кем?.. Капканың аргы ягындагысы?.. Идәндә ятучыга якынлашу мөмкин түгел иде башка, чигенергә мәҗбүр булды Җантимер. Ишегалдына таба чигенде. Этләр салкын идәндә ятучыны каравыллап калды.

Борылды... һәм үзенә текәлеп үк диярлек карап торган кешегә мөрәҗәгать итте Җантимер:

— Син кем?

— Кеше.

— Кеше,— дип, гаҗәпсенүендә булды Җантимер.— Ке-ше...

Күзләрен кылыйлата төшеп, ышанырга-ышанмаска белми, сак кына сынап карап торды ул Фидаилгә: «Кеше булса, ул монда нәрсә югалткан? Нинди ният белән килеп чыккан ул монда? Кеше түгел! — дип, үзен тынычландырырга ашыкты шундук.— Кешегә ни калган монда?.. Аннан ничек үтеп керергә, ничек юл табарга тиеш әле ул монда?... Кеше булган булса, аңарга аның этләре өрмәс идемени?!. Этләре янәшәдә генә ич, әнә, чит-ят кешегә күз дә салырга теләмиләр...»

Янә бер кабат үз-үзен барлап алды Җантимер. Куллары — үзенеке. Аяклары — үзенеке. Колаклары да үзенеке икән... Күзләре дә дөрес күрсәткәнгә охшыйлар. Шулай булгач, нигә соң саташудан туктала алмый ул һаман да. Күз алдындагы шәүләләр юкка чыкмый аның саен. Берсе — идәндә. Икенчесе — әйтсәң ышанмаслык, каршысында ук басып тора.

— Син кешеме әллә? — дип сорарга мәҗбүр булды бу юлы.

— Әйе, Җантимер... Әтиеңне эзләп килдем... Гыйлем абзый монда килеп чыкмадымы?..

«Кеше!..— диган уй зеңләп узды Җантимернең чигәсеннән.— Чит-ят кеше... Кемне эзләп килгән ул монда? Ә бәлки... Юк-юк, алай булса, ул аның исемен белмәс иде. Җантимер ди бит әнә. Барысы да Җантимер дип дәшә аңарга бүген...»

Кичке эңгер-меңгер куерганнан куера барып, инде караңгы төшәргә җыена иде урманда. Шулай да әле уңны сулдан, кешене шәүләдән аерырлык үзе.

«Ә бәлки, үз кеше торадыр аның каршысында — зур кеше?..»

— Пароль?..— дип мөрәҗәгать итте ул каршысында торучыга байтак кына игътибар юнәлткәннән соң.

— Нинди пароль? — дип гаҗәпсенде Фидаил. Киноларда гына ишеткәне бар иде аның бу сүзне.— Әтиең кайда, Җантимер?!.

— Нинди эти? — Тонык шешә пыяласы төсендәге күз кыймылдамады да хәтта.

— Синеке...

— Минеке?!. Юк минеке!

— Әтиең урманда. Ул сине эзли, Җантимер...

— Кемгә кирәгем бар,— дип куйды ул кинәт. Бары шул сүзне әйткәндә генә үз хәлен чамалады булса кирәк.— Кешеләр бер-берен эзләми... Кеше бер-береннән кача...

— Син качкансың! Ә әтиең эзли...

— Син кемне эзлисең? — дип сорап куйды кинәт янә җанланып алган Җантимер. Әйтерсең лә әңгәмәдәшен ялганда тотарга җыена иде ул.

— Синең әтиеңне...

Өнемме бу, төшемме соң дигәндәй, чираттагы мәртәбә күзләрен уалап алды Җантимер. Әмма төгәл генә бер фикергә килә алмады бугай:

— Әтиеңне...— дип, Фидаил артыннан кабатлады да кычкырып көлеп җибәрде. Ә хәрәкәтсез калган мөлдерәп торган күзләреннән яшь тамчылары бүселеп чыкты. Сәер, гайре табигый һәм тетрәндергеч күренеш иде бу: кеше мәгънәсез көлү белән көлә. Бер үк вакытта ул кызганыч, күзләреннән яшь ага...

Ярдәм итеп кара шуңарга. Аңлатып кара аңарга үзенең хәлен. Телсез калып карап торды аңарга Фидаил.

Шәүлә-каравылчы, кабаланып, кесәләрен капшап куйды. Нидер исәп итте ахры... Нәкъ шул вакытта чираттагы мәртәбә капка ягыннан машина кычкыртканы ишетелде. Һәм таксист тавышы:

— Әй, брат, баттыңмы әллә анда?..

— Күпкә түзгәнне, азга түзәрсең, брат...— дип, үзенчә җавап кайтарды аңар Фидаил.

Тегесе, әллә шаярып, әллә үртисе килеп, телен кашып алды:

— Миллионер...

«Бу ни дигән сүз инде бу, йә?!. Аның биләмәсен кемнәр сырып алган? Ни калган аларга? Берсе — сарай идәнендә. Икенчесе — каршысында. Капка төбендә тагы берсе. Уңайсызлану юк, читенсенү, гел хуҗа булып сөйләшә болар!.. Капка төбеннән тагы ниндидер авазлар килә түгелме соң?!. Машинада да кешеләр, димәк (машина эчендә акрын гына сөйләп торган радиоалгыч сәбәпче булды соңгы нәтиҗәгә). Кычкырып сөйләшәләр, әнә. Музыка белән, марш атлап киләләр... Ярымутрауны урап алган түгелме соң болар?.. Иң гаҗәбе — этләр өрми. Этләрен агулаганнар!.. Ә анда — таш пулат аръягында — зур хуҗалар... Иң-иң зур хуҗалар!.. Аларга хәбәр җиткерергә кирәк. Кичегергә ярамас. Зур, бик-бик зур хуҗалар гафу итмәс...»

Саклык белән генә уң кулын чалбар кесәсенә шудырды ул. Берөзлексез як-ягына карангалап торды — бер-бер кеше якынлашмыймы? Өстенә ташланучы юкмы?.. Сигнал ракетасы тартып чыгарды һәм, бер мизгелгә дә тоткарланмыйча, аны һавага чөйде. Иң җитди куркыныч янаганда, зур хуҗаларны ашыгыч рәвештә кисәтергә кирәк булу ихтималы туганда гына файдаланырга тиешле чара иде бу — моны Җантимер яхшы белә. Зур хуҗалар да яхшы белә!..

Һавага чөелгән ракета артыннан ук, умарта күченнән качкан аю сыман, кулларын яман болгап, «каравыл» кычкыра-кычкыра, күл читендә крепость сыман калкып торган ак бинага таба йөгерде Җантимер.

— Каравы-ы-ыл!..— дип акыра иде ул. Ни эшләгәнлеген белмичә, барып бәрелер, кереп качар урын таба алмый, арлы-бирле сугылырга керешә.

Кичке аяз күкне ярып очкан кызыл ракетаны күреп, ишегалдына таксист егет йөгереп керде... Сарай эчендәге караңгылыктан, башларын салындырып, тавышсыз-тынсыз гына ике овчарка килеп чыкты. Ишек катында ук торган Фидаилгә булсын, өсләренә төбәп килгән таксистка булсын, игътибар да итмәде алар. Чит-ят кешеләрнең янәшәсеннән сак кына узып, үз юллары белән китеп бардылар.

Этләрне күргәч тә сагая калган таксист, әкрен генә, үзалдына белгәннәрен укып куйды:

— Йо-ка-лы-мы-ны, о-пы-ры-сы-ты...

Бераздан, ул да Фидаил артыннан сарай ишегенә килеп капланды:

— О-пы-ры-сы-ты...— дип, догасын кабатлады. Һәм, бар икән монда хәлләр дигән сыман, үзалдына сызгырынып алды.

Күз алдындагы күренештән телсез-чарасыз калды Фидаил. Тупса аша сак кына узып, тезләнде. Хәрәкәтсез яткан Эт атучы Гыйлемнең авыр башын салкын идәннән күтәрергә итте.

— Улым...— дип дәште ыңгырашкан аваз. Күзләрен ача алмады ул. Хәлсез һәм салкын куллары белән Фидаилнең баш аркасыннан, яңакларыннан сыйпарга омтылды. Авызыннан, борын тишекләреннән агып укмашкан кара кан сулыш алырга ирек бирми иде аңар.

Гыйлемнең таш сыман каты һәм сөялләнеп беткән кулын муенында тоюга ук эсселе-суыклы булып китте Фидаилгә. Чирканмады, әмма уңайсыз иде аңарга ата кешенең алдануын тою. Бугазына яшен ташы сыман кайнар төер килеп тыгылды.

— Гыйлем абый, бу мин — Фидаил... Танымыйсыңмы әллә, Фидаил ич, «студент»...

— Улым... Барысы өчен дә үзем гаепле мин, улым... Үзем!

— Гыйлем абый, Гыйлем абый дим... Тынычлан!..

— Өйгә кайтыйк, улым... Без синең белән шундый итеп яшәрбез әле...

Ишегалды ягыннан берөзлексез тәрәзә төйгән, ишек шакылдаткан авазлар ишетелеп торды. Һәм бер үк сүзләр кабатланды һаман:

— Каравыл!.. Милиция... Кара-вы-ы-ыл!..

— Тиләләр йортымы әллә монда? — Бусы таксист соравы булды. Чираттагы мәртәбә белгәннәрен укыды ул.— Йо-ка-лы-мы-ны...

Фидаилнең беләгенә башын салган Гыйлем әле һаман саташуында: улын өйләренә кайтырга үгетли. Улына ялвара... Үз хәлен түгел, улын кайгырта, аның бәхетле булуын тели. Ул да түгел, канга катып укмашкан керфекләре читеннән каен суы сыман терекөмеш тамчылары йөгерешергә кереште... Ата елый! Эт атучы елый! Сулкылдап елый иде инде ул. Авыртудан, сызлануларыннан түгел, «улы кочагында» яту рәхәтлегеннән...

— Улым...— диде әле ул янә бер мәртәбә. Авыр ыңгырашып алды һәм тынды. Бүселеп аккан күз яшьләре кибеп калган иде. Авыр башы салкын идәнгә салынып төште. Әле яңа гына Фидаилнең муенында булган куллар, кош канатлары сыман, як-якка таралды...

— Гыйлем абый... Гыйлем абый, нишлисең син? — дип, җан тавышы белән тетрәнеп кычкырып җибәрде Фидаил. «Улың... Мин синең улың!» дип вәгъдә бирергә дә риза иде ул шул мизгелдә. Әмма ишетүче генә булмас... Яшәргә дә яшәргә иде бит әле, эх, Эт атучы Гыйлем...

## 39

Күккә чөелгән ракета, парашютлы иде гүя, озак эленеп торды баш очында. «Зур хуҗалар» белә: кызыл ракета — «тревога» дигән сүз! Күк йөзе ярып киткәч тә, йөзләренә куләгә төште арысланнарның, кыбырсырга керештеләр.

Гуля-Гөлсинә генә, ракета күргәч, тыпырдап биеп алды үзалдына:

— Кызыл ракета... Минә ичмасам бу здорово!

— Капкаев,— дип әмер бирде Белялыч. Хәвеф барын сизенеп, куырылып калган иде ул.

Учак тирәсенә җыелышкан кенәриләрне өр-яңа «төсле рәсемле» мәзәкләре белән авызына каратып торган Капкаев шундук, буйсыну белдереп, йөгереп килде:

— Әйе, Капкаев...

— Бар, күз салып кил! Җантимер саташмаганмы?!

Гастроном директоры өчен йомышмыни соң бу — уен гына:

— Капкаев йөгерде... Барам, күрәм, киләм, Белялыч!

Күл ягыннан сизелер-сизелмәс кенә салкынча җил исеп куйды.

Баш арыслан, торган урынына кире утыра алмый, уңлы-суллы каранды, тынгысызланырга кереште. Менә сүнәм-сүнәм дип янган учак тирәли йөренде ул арлы-бирле.

— Хәерлегә түгел бу,— диде хәлен белешергә килгән Арслан Сәхиповичка.

— Этләр өрми ич... Димәк, тәртип! — булды җавап.

— Кызыл ракета өчен Җантимер башы белән җавап бирә!

— Шаярмакчы булды микән?..

— Баш белән шаярмыйлар...

Нәкъ шул вакыт, үзе артыннан ишек ябарга да онытып, Капкаев атылып чыкты бина эченнән. Сулышы кабкан... Маңгаена тир бәреп чыккан... Пинжәк итәкләре җилфер-җилфер килә...

— Каптык! — дип хәбәр салды ул килә килешкә.

— Ачыграк сөйләш, нәрсә күрдең?! — дип, каршысына атылып чыкты аның Лев Беляловичӊ.— Сузма!.. Тизрәк!

— Җантимер каравыл кычкыра. Этләр юк. Ишегалды кеше белән тулган. Капка төбендә — машина...

— Нинди машина?! — дип, күзләрен акайтты баш арыслан.— Нинди машина дим?.. Синнән сорыйм?!.

— Әллә такси, әллә милиция шунда...

— Ахмак! Таксины милиция машинасыннан аера алмыйсыңмы?..

— Такси бугай,— дип, ачыкларга итте Капкаев.

Белялычның тавышы көр чыкты:

— Таксига монда ни калган!

— Милиция идеме әллә? — дип уйга калды Капкаев. Һәм каршысына тешләрен кысып, күзләрен түгәрәкләндереп килеп баскан Белялычтан куркып, әйтеп салды.— Милиция иде, әйе... Аннан соң... Теге, Сәхипычны бәрдерткән шофер малайны күрдем шунда...

Бер мизгелгә хәвефле тынлык урнашып торды. Берәвенең дә үзләренә куркыныч янау ихтималына ышанасы килмәде. Шулай күнеккәннәр. Башкача булырга мөмкин түгел сыман... Нәкъ шул вакыт таш диварлар аръягыннан Җантимер тавышы ишетелде:

— Милиция!.. Урап алдылар!..

Һәммәсе ишетте Җантимернең карлыккан тавышын. Лев Беляловичка текәлеп калдылар: «Коткарсаң син генә коткара аласың безне, зур хуҗабыз Белялыч! Синең кодрәт — чиксез, әшнәләрең — бихисап, тәвәккәллектә тиңең юк, әйт әмереңне, Белялыч!..» — дия иде сыман һәммәсе.

Гуля-Гөлсинәнең генә исе китмәде кебек:

— Исегез киткән икән, милици-и-ия...— диде ул авызындагы сигаретын учакка атып. Һәм нечкә сыйракларын киң җәеп, биленә таянды. Ирен читләреннән канәгать елмаю сибелде аның.— Между прочим, милициядә арысланнар муеннан минем...

Ул да түгел, коткаручыгыз мин булырмын дигән гаярьлек белән туп-туры чыгар юлга таба атлап китте ул. Ничек атлауларын, ул гәүдәсен, иңсәләрен ни рәвешле уйнатканын күрсәгез иде аның.

— Тукта! — дип кычкырды аңар күзләренә кан йөгергән баш арыслан.

Гуля-Гөлсинә туктады. Тыныч, әмма мыскыллы елмаю белән куркышып калган таныш-белешләренә — арысланнар һәм кенәриләргә текәлде. Иякне югары чөйде:

— Нәрсә, астыгызга су йөгердеме?!. Әй, сез, арысланнар!..

— Ишеккә якын барасы булма!

Үз Левасының киңәшен тотты Гуля-Гөлсинә, карышмады. Әмма иреннәрен турсайтып, янә бер кат кәперәеп алмый түзмәде:

— Кирәкмәсә — бармыйм! Мин бит үзегезне кызганудан гына...

Лев Беляловичның иреннәре калтыравын күреп, туктарга мәҗбүр булды кенәри. Ирен читеннән бер пошкырды да үз ишләре янына китеп барды.

Арслан Сәхипович килергә җөрьәт итте карт арыслан янына. Ул теләсә кайсы мәлдә ярый һәм яраклаша белә иде аңарга. Башын иеп, гаепле кеше сыман дәште әле дә. Һәр сүзеннән соң тирән сулыш алды:

— Барысын да сез кушканча эшләрбез, Лев Беляловиз...

— Болай итәбез, Арслан,— диде, күңеле нечкәреп өлгергән мәҗлес рәисе, дустының аркасына кулын салып.— Күл аша ычкынабыз. Милициясе бер хәл. Теге Фидаил дигәннәрне килгән анда. Артында кемдер бар дип уйлаган идем аны!..

— Күл аша?.. Ә көймә бармы?

— Көймә бар. Әмма бераү генә. Анысы да ике кешелек, җиңел көймә.

— Ике кешелек,— дип, остазының күзләренә текәлде Арслан Сәхипович. Һәм, бер мизгел уйга калып торган атлы булганнан соң, үз тәкъдимен житкерде.— Икебез генә ычкыныйк, булмаса, Лев Беляловиз?!.

Соңгы сүзләрне, ничектер, Капкаев ишетеп калган булды. Ике уйлап тормый кычкырып җибәрде ул шунда:

— Ничек икегез генә?!. Ә мин? Мине кайда калдырасыз?!.

— Ике кешелек кенә! — дип тавышын күтәрде Арслан Сәхипович. Бу аның остазы исеменнән дә әйтелгән сүзе иде үзенә күрә...

— Ничек ике?

— Ничек ике генә? — дип эләктереп алды кенәриләр дә.

— Шулай, ике генә! — диде иң элек йөгереп килгән Гуля-Гөлсинә. Ат дагалаганда бака ботын кыстыра дигән сыман килеп чыкты бу.— Иң элек, без Лева белән утырабыз! Шулай бит, ә, Лева? Әйт әле шуларга, Лева, шауләшмасыннар.

Ул да түгел, арысланнар һәм кенәриләр бер-берен этә-төртә күл читенә таба йөгерергә керештеләр. Озын торыклары белән ике генә сикерде Арслан Сәхипович, һәммәсен узды. Иң элек көймәгә ул менеп кунаклады. Янәшәсеннән Лев Беляловичка да урын алган иде... Һәммәсе көймәгә тулдылар. Ләкин көймәнең, су өстендә түгел, яр читендәге комда булуын берәү дә абайламады. Көймә борынындагы утыргычка җайлап урнашкан Лев Белялович авазы ишетелде шунда:

— Иптәшләр... Иптәшләр, шауламагыз әле! Көймә ике кешелек кенә. Әйдәгез, аргы ярга чиратлашып чыгыйк.

Арслан Сәхипович эләктереп алды аның сүзен:

— Төшегез, төш — көймә ике кешелек. Чират белән генә чыгыйк!

— Әйдәгез, чират белән,— диде барысы да. Һичкем карышмады. Тик берәүнең дә көймәдән төшәргә, үз чиратын көтәргә исәбе юк иде. Төшеп, көймәнең казыкка бәйләнгән чылбырын ычкындырыр кеше дә, суга этеп төшерүче дә күренмәде. Арысланнар арыслан булуларын, кенәриләр кенәрилекләрен оныттылар: «Бар, син! Нигә мин? Бар, син! Нигә мин? Бар, син үзең!» ди-ди төртештеләр.

— Болай булмый, иптәшләр,— дип, янә көймә башыннан карт арысланның мәртәбәле тавышы ишетелде.— Кызлар... Кенәриләр, сез төшеп торыгыз! Капкаев, син дә!.. Сезне яңадан кереп алырбыз!

— Әйе, әйе, Борис кереп алыр,— дип, шундук эләп алды Арслан Сәхипович.

Нәкъ шул мизгелдә Лев Беляловичның муенына Гуля-Гөлсинә килеп сарылмасынмы?!.

— Үлсәм үләм, синең белән, Лева!

— Җитәр, матурым, җитәр,— дип, үзеннән аерып алырга, этәргә азапланды арысланы.

— Лева!.. Син мине кемгә калдырырга җыенасың, Лева?!.

Чебен куган сыман, кулларын чәбәләндерде Лев Белялович. Әмма файдасыз. Гуля-Гөлсинәдән алай гына ычкынырмын димә икән.

— Капкаев,— дип әмер бирде ул, муенын бераз бушата төшеп.— Әйдә, төш инде көймәдән. Чылбырын ычкындыр да этеп җибәр. Комда утырабыз ич...

— Капкаев.— дигән канәгатьсез аваз ишетелде. Үзе күренми иде ул, чөнки күптән көймә төбенә сузылып яткан.— Капкаев булмый торсын әле. Капкаев та Капкаев... Тапкансыз тынлаулы кеше.

— Син нәрсә, Капкаев? — дип, яхшатланып тавышын күтәрде Арслан Сәхипович.— Кем белән сөйләшкәнлегеңне онытасың!..

Капкаев белән Арслан Сәхипович пыр тузып бәхәскә кереп киттеләр. Әмма чылбырны кем ычкындырырга тиешлеген ачыклый алмадылар барыбер. Моңарчы тавышы-тыны ишетелми торган, гомумән, аз сүзле Борис сикереп төште көймәдән.

— Арысланнар,— дип кычкырды ул.— Көймәне ярдан этеп төшерергә кирәк. Комда утырабыз!..

Чалбар балакларын сызганды, галстугын тартыбрак куйды Арслан Сәхипович. Тәкәббер ияген югары чөеп алды — минсез булдыра алмыйсыз инде, янәсе... Берочтан Капкаевның да кабыргасына төртеп куйды:

— Тор, Капкаев... Әйдә, этәбез... Кенәриләрдән ояла бел!

Торыйммы икән, юкмы дигән сыман, кенәриләргә күз йөгертеп чыкты Капкаев. Көймә түрендә пеләшен сыпырып утырган Лев Беляловичка текәлде:

— Йә, Капкаев, көттермә! — булды җавап.

Мыгырдана-мыгырдана торып, ком өстенә сикерде Капкаев. Ни барысы бер сүзен ишетте әйләнә-тирәдәгеләр:

— Яшисе килә...

— Яшисең килсә, яр буенда кал! — диде Арслан Сәхипович киңәш итеп.

— Милиция кулына эләгергәме?

— Милициягә эләккәнең су төбенә киткәнгә караганда артыграк.

— Акча күп бит минем, Сәхипович, яшәп каласы иде...

— Яшисең килгәч — этәбез. Әйдә, этәбез...— дигән авазлар, куәт бирүләр ишетелде.

Алай гына кузгалмады көймә, комга шактый ук нык утырганнар иде. Кенәриләр дә төшәргә мәҗбүр булды көймәдән. Итәкләрен җыя төшеп, суга таба этеп киттеләр көймәне. Ә Белялыч урыныннан кузгалмый гына көч биреп утырды:

— Әйдә... Әйдә!.. Әй-дә-ә...

Су өстенә килеп кергәч тә көймә чайкалгалап куйды.

— Әләй, суы салкын,— дип кычкырды берәү.

Эх дип әйткәнче һәммәсе көймәгә менеп кунаклады.

— Кая менәсез, кая?!— дип, тәртипкә чакырып карады Арслан Сәхипович.— Көймә ике урынлык кына...

Тыңлыйлармы соң!.. Колак та салмадылар. Яссы төпле көймә суга сеңде. Кенәриләр һәм арысланнар, гүя көймәдә түгел, менә батам, менә батам дип торган яссы такта өстендә иде диярсең. Борис белән Капкаев ишкәккә утырдылар. Арслан белән карт арыслан түрдә. Кенәриләр бер урында укмашып, бер-берсенә тотынышып басып бардылар.

Акрын гына чайкалгалап, аргы якка йөзеп киттеләр. Түзсә дә түзә икән ике кешелек көймә. Һәммәсе тынып калды, сулыш алырга да кыймадылар. Бары ишкәкләрнең тәртипсез чупылдашуы гына ишетелеп барды. Өмет тулы күзләр аргы ярда...

Бирге ярда гаме калмаган иде инде берәүнең дә. Мәхәббәт ярымутравын да, андагы бәхетле сәгатьләрне һәм тән сакчылары Җантимерне дә оныттылар. Артларына борылып карау, үткәндәге хатирәләр белән яшәүнең ни икәнлеген дә белми ул арысланнар һәм кенәриләр. Аргы яр, иртәгесе көн иминлеге, үз рәхәтлекләре әһәмиятлерәк...

Бирге ярда бер ялгызы калган Җантимер бәргәләнә иде. Кулларын болгый-болгый кычкыра, салкын ком өстеннән арлы-бирле йөгерене, әле бил тиңентен салкын суга йөгереп керә, әле кире яр читенә ташлана. Ул да түгел, ком өстенә авып тәгәри башлый, сабый балалан да болай

рак үксергә керешә... Берәзлексез кычкырудан тамаклары карлыккан:
— Мине дә алыгыз... Әй, зур хуҗалар!.. Зур хуҗа-ла-а-ар... Мине кемгә калдырасыз?!
Алдануын тою гарьлегеннән тәгәри-тәгәри елый иде Җантимер:
— Зур ху-җа-ла-а-ар.. а-а-ар... а-а-ар...
Ишетмәделәр түгел, ишеттеләр Җантимерне. Әмма аның кайгысы идемени соң арысланнар һәм кенәриләрдә?! Үз гомерләре кыл өстендә! Менә батам, менә батам дип барган мизгелләре...
Шулай да Гуля-Гөлсинә Җантимер авазына битараф кала алмады. «Таныш милиционерлар түгелме икән анда?»— дигән кызыксыну белән мәхәббәт ярымутравыннан күзен алмый бара иде ул. Милиция әле һаман күренми, ә Җантимер бәргәләнә.
— Куркаклар сез! Җантимерне калдырып качасыз!.. Арысланнар түгел, куркак куяннар сез!.. Су күселәре...— дип, битәрли башлады ул ир-атларны.
Гуля-Гөлсинәгә күтәрелеп караучы һәм җөрьәт итеп каршы сүз әйтүче булмады. Һәммә күзләр аргы ярда. Сөйләнсен әйдә, тел сөйләү өчен бирелә кенәриләргә дә...
Кыюланганнан кыюлана барган Гуля-Гөлсинә теләнә ни килсә, шуның белән битәрләде көймә борынына сеңгән арысланнарны. Бераздан муенына бәйләнгән косынкасын чишеп, Җантимергә изи башлады. Һәм бер адым аңарга таба тартылып алды.
— Җа-а-ан...— дигән урында өзелеп калды чәрелдек тавышы, чайкалып китте һәм, кулларын яман чәбәләндереп, күл өстенә очып барып төште. Тотып калырга тырышучы булмады аны. Әмма, мәтәлдем дигәндә, кулына туры килгән беренче итәктән тартып, Асияне дә үзе белән бергә салкын су киңлегенә өстерәп төшеп киткән иде ул.
Чырыйлап кычкырышырга керештеләр кенәриләр. Көймәдәгеләре дә, суга очып төшкәннәре дә.
Ишкәк белән житез хәрәкәтләр ясап, ярдәм итәргә дигән максат белән, көймәне кире борды Борис.
— Салкын... Кулыңны бир...— дип аваз салды, якында гына чупырдашкан Гуля-Гөлсинә, көймә борынында ук утырган арысланы — Лев Беляловичка таба үрелеп, кулын сузгандай итте.
Араларында, күп булса, кул сузымы ара булгандыр. Әмма ишетмәмешкә сабышты карт арыслан. Кул бирү түгел, борылып та карамады.
Асия исә, күлмәк итәге белән ишкәк тимеренә эләгеп калуы сәбәпле, тагы да якынрак иде. Бер бата, бер чума кулларын буташтырып көймә читенә, һич булмаса Капкаевның ишкәгенә ябышмакчы исәбе.
— Көймәгә ягылма,— дип тавышын күтәрде арадан берәү. Арслан Сәхипович иде булса кирәк.— Батырасың ич... Барыбызны да батырасың...
Ә Лев Белялович ишүләреннән туктап калган Борис белән Капкаевка җикеренде:
— Ишегез!.. Нәрсә карап каттыгыз, ишегез тизрәк!..
Капкаев акланырга ашыкты:
— Итәге эләккән аның... Итәге җибәрми...
— Эләксә, ычкындыр... Итәк бетмәс анда, баш исән булсын!
Көймәдәгеләрдән мәрхәмәт көтүнең урынсыз икәнлеген аңлап алган Гуля-Гөлсинә ул арада ярымутрауга төбәп йөзеп киткән иде инде. Оста йөзә иде нәләт. Лев Беляловичның: «Алайга түгел, безнең арттан, безнең арттан йөз...» — дигәненә колак та салып тормады ул.
Асия исә һаман бер урында чәбәләнә. Әллә начар йөзә, әллә арысланнардан мәрхәмәт көтә — аңламассың.
— Арслан! — дип кычкырды ул, кулына чуалган күлмәк итәкләрен бер читкә тибәреп.— Арсла-а-ан!..
Ишетмәде түгел, ишетте Арслан аның сүзләрен. Әмма Асиягә түгел, киңәш сорап Лев Беляловичка текәлде:

— Нишлибез?..

— Хатын-кызга берни булмый, эт каешы ич алар,— булды җавап. Һәм бераздан өстәп тә куйды «зур хуҗа».— Бетмәс монда кенәриләр...

— Бата-а-ам! — дигән аваз ишетелде көймә читеннән.

Тавыш ишетелгән тарафка аркасын куйды Арслан, гүя ишетмәде. Җитди уйга чумып баруы гүя...

Ул да түгел, Лев Беляловичишкәктәгеләргә әмер бирде:

— Нәрсә карап каттыгыз?!. Ишегез, иш әйдә!

Ике ир-ат киерелеп ишәргә керешкәч, җиңеләя төшкән көймә хутлы гына йөзеп китте. Аһ-ваһ, ыгы-зыгы артта калды. Көймәдәгеләрнең күңелен бер төрле үк матур, җылы уйлар биләп алган иде: «Ярый әле баш исән! Ярый әле мин түгел, башкалар мәтәлде боздай салкын суга... Ә бит киресенчә дә булырга ихтимал иде. Язмышка рәхмәт, бәхет бар икән әле...»

Борыны белән суга чүмәшкән яссы төпле көймә ипле генә атына-атына аргы якка якынлашуын дәвам итте. Берәү дә авыз ачып сүз катарга җыенмый иде әлегә, һәркем үз уйларына чумып изрәгән...

Шулай да ярга якынлашу тора-бара үзенекен итми калмады. Кулын сыңар ишкәктән аерып маңгай тирен сөртеп алган Капкаев аваз бирде иң элек:

— Арслан Сәхипович,— дип, үртәп дәште ул.— Сине яхшы йөзә диләр, дөресме шул?..

База мөдире аны-моны уйлап өлгермәдеме, сорауны туры мәгънәсендә аңлап, җавап та бирде:

— Беренче разряд иде.

— Әллә Асияңне алып чыгасыңмы соң?!

Күзләре түгәрәкләнде Арслан Сәхиповичның, Капкаевка җен ачуы чыкты:

— Телеңә салынма, торгаш!..

Дөресен әйткәндә, ул үзе дә салкын күл суы өстендә чупырдап калган Асия хакында уйлап бара иде. Кызганмый да мөмкин түгел, яхшымы-яманмы, үз кенәрие ич!.. Бу урманга аңарга ияреп килгән... Ләкин, аны коткарам дип, үз язмышын куркыныч астына куярга тиешме ул?!. Кенәриләр бетмәс! Кенәриләр күп алар... Ә ул — бер генә! Менә дигән гаиләсе бар Арслан Сәхиповичның — хатыны һәм кызы... Эш урыны — дан, дәрәҗә...

Капкаев җавапсыз калмады, тирән сулыш алды:

— Эх, син, арыслан! — диде сүза төшеп.

Әле тагын дәвам итәргә иде исәбе, әмма баш арысланның дәрәҗәле сүзләре яңгырады шунда:

— Капкаев!

— Әйе, Капкаев...

— Гуманист ясама үзеңнән! Ишүеңне бел! Астыңа су керергә тора, ә син телеңә салынасың...

Лев Беляловичның тел төбендә ни булуын чамаламады түгел, чамалады Капкаев. Үзен аңламаулары кызганыч, ул да шаярмый иде ич.

— Ишүен ишәрбез анысы,— диде ул, үзен чынга алмауларына кәефе кырылып.— Мин бит сезне кайгыртып сөйлим... Милиция кулына капсалар, ни эшләрсез?!. Шундук тикшерәчәкләр...

Баш арыслан сагаеп һәм текәлеп карады аңарга. Хәтта урыныннан күтәрелмәк булып, күл тарафына да күз төшереп алды: исәннәрме?.. Иплән кенә әйтеп куйды аннан ары:

— Беләсеңме, нәрсә, Капкаев... Фикер йөртүең, безне кайгыртуың яхшы анысы, Капкаев!.. Әмма кенәриләрне без милиция кулына тапшырмадык...

— Тапшырмасак, үзләре барып керәчәк алар.

— Кермәс, Капкаев! — кулы белән суга үрелеп алды зур хуҗа, аның салкынлык дәрәҗәсен чамалады. Аннан, канәгатьләнү хисе белән,

тартып алды кулын. Елмая төшеп җавап кайтарды.— Кием-салымнарының салмый гына, бар, йөзеп кара... Сунын төбе, аргы ярга караганда, күпкә якынрак аның, Капкаев!

Арадан кемдер кеткелдәп көлеп алды. Көлмәслек тә түгел, телгә оста һәм җор иде бит Лев Белялович.

Ул да түгел, нәкъ шул мизгелдә көймә борыны ярга килеп төртелде. Чүгәләп баручылар чак егылмый калдылар. Капкаев «Ур-ра» кычкырып куйды. Ни өчендер күтәреп алмадылар үзен, әмма яр читенә исән-аман чыккан кенәриләр һәм арысланнарның күңеле күтәренке иде, бусы бәхәссез. Этешеп-төртешеп ярга сикерештеләр...

— Сибелергә!.. Һәркем үз юлы белән!..— дип боерык бирде баш арыслан. Һәм иң элек үзе, карт аю сыман, әпән-төпән килеп, күл читеннән үк башланып киткән урман эченә кереп йөгерде. Ә бераздан, агачлар караңгылыгыннан янә тавышы ишетелде.— Аңладыгызмы?.. Бер-беребезне белмибез... Берәр ай узсын, аннан хәбәрләшербез... Ишеттегезме?!.

Башка күренмәде һәм дәшмәде зур хуҗа. Ул кереп югалган тарафта шартлап ботак сынганы гына ишетелде бары.

* * *

Күл ягыннан ярдәм сорап кычкырган авазлар ишетелгәч тә, анымоны уйламыйча суга сикергән Фидаил яр читенә үз хатыны Асияне алып чыкты. Таксист егет ягып җибәргән учак янында аның эчкән суын костырдылар, ясалма сулыш алдырдылар. Асия үзен коткаручының кем икәнлеген танымаган иде әле. Шуңадыр, әледән-әле ыңгырашуга охшаш аваз чыгарып, үз-үзен белешмичә: «Арслан... арысланым...»— дип, бер үк сүзләрне кабатлады ул.

Яр читендәге юеш, салкын комга барып капланды Фидаил. Урман шавын, чарт та чорт килеп янган учак тавышын ишетәсе килми иде аның.

Күл уртасыннан үзе йөзеп чыккан Гуля-Гөлсинә, әллә кай арада анадан тума чишенеп аткан да, алдын-артын уйламыйча, сабый бала сыман учак әйләнәсендә сикергәләп йөри. Үзе сикергәли, үзе берөзлексез Фидаилне мактый:

— Чын герой икән син, иптәш милиционер... Сиңа орден тиеш!.. Менә егет ичмаса... Менә егет...— дип, сикергәләгән көйгә, такмаклый. Аңлашылса кирәк, Гуля-Гөлсинә генә түгел, яр читендә һичкем Фидаил белән Асиянең бер-беренә кем булуы хакында белми һәм уена да китереп карамый иде.

Ә Фидаил берни ишетмәде, аңышмады һәм күрмәде. Ун бармаклап салкын комны тырный иде ул. Аякларын, кулларын, үз-үзен кая куярга белми өзгәләнә. Бөтен дөнья, бөтен кешелек каршында рисвай ителгән, түбәнлеккә төшерелгән кеше саный үзен. Учак тирәсендә сикергәләгән кенәри дә аны мыскыл итә, аңардан көләдер сыман... Түбәнлек... Нинди түбәнлек... Хурлык... Нинди олы хурлыкка төшерелгән бит ул! Учактан күтәрелгән ялкын телләре булып, алар да аңардан көлә, аны мыскыл итеп уйный, ялт-йолт итәдер сыман тоелды аңарга. Уч төпләрен ком ашады, теш араларында юеш ком шыгырдады Фидаилнең...

— Сиңа орден тиеш, иптәш милиционер, орден...— дип такмаклавында, сикергәләвендә дәвам иткән кенәри Фидаил янынннан да урап узарга өлгерде.— Менә дигән егет... Арыслан дисәң дә арыслан ичмаса!..

Шунда, җир астыннан үсеп чыктымы, чәчләре тузгыган, өсте-башы манма су булган Җантимер калыкты әллә каян гына. Иң элек Фидаилдән таләп итте ул нидер... Тегесе җавап кайтармагач, таксист янына йөгереп килде, аны җилтерәтте:

— Пароль? Пар-р-ро-о-оль?!!

Кычкырып кына еламый иде бичара. Тезләнеп, аяк очларына ятып

ялвара үзенә кирәген. Аңлаучы юк... Алай да барып чыкмагач, Гуля-Гөлсинәгә тагылды:

— Пароль?.. Пар-р-роль кирәк?!!

— Парольсез генә ал... Парольсез дә риза, Жантимер,— дип туктап калды тегесе. Кочаклашырга итенеп, ике кулын Жантимернең иңбашларына таба сузды.— Син миңа күптән ошый идең, Жантимер...

— Тимә миңа,— дип, карлыккан тавыш белән кычкырып, җан фәрманга акырып җибәрде Жантимер.— Син түгел!.. Миңа пароль кирәк... Пар-р-роль!..

Үзаңына килгән Асия, башын калкытып, иң элек озак кына күл өстендәге шадра дулкыннарга текәлеп утырды. Анда, көмеш тәңкәләрен елкылдатып, балыклар сикерешеп уйный. Гүя тоныкк кына төшеп торган ай нурларыннан ятьмә үрә иде сыман алар.

Сүрәнләнә, сүнә барып, күмер һәм көлгә әверелеп калган нәни учак каршысында Гуля-Гөлсинә таксистка үзенең хисләрен аңлату белән мәшгуль...

...Кинәт, уйламаган җирдән, салкын җил исеп куйды шунда. Тын да алмый тамаша кылып торган наратлар дәррәү шаулашырга кереште. Авыр кәүсәләре сыкрап-иңрәп куйды җилдә. Кипкән камыш сабаклары сулык-сулык итте... Тешләре-тешкә бәрелеп калтыранырга кереште Асия. Иреннәре слива кабыгы сыман шәмәхәләнеп чыкты. Бала йоны баскан аякларын, иңбашларын кочакларга, җылытырга итенде ул. Туңа... Җылы кирәк, җылы җитми аңа. Җылы... Җылы бирүче юк.

Башын түбән салындырып күл читеннән яланаяк атлап киткән Фидаилнең шәүләсе ерагайганнан-ерагая барды. Ул әле үзен алда нәрсә көтәсен, ниләр буласын белми, күз алдына да китерә алмый иде...

*Мамадыш — Казан*
*1986—1988 еллар*

**Газиз Кашапов**

# УБЫРУТ

ПОВЕСТЬ



Көчле җил купты, беравыктан чытырдатып күк күкрәде, ялт-йолт яшен яшьнәде. Төнге караңгылык тагын да куера төште.

Мәүләви сыкранып кына ятагына торып утырды, сусыман төссез, үзалдына яшьләнеп торган күзләрен угалап, кечкенә тәрәзә каршына килде, төн караңгылыгы аша нидер күрергә-абайларга тырышты, аннары колагын пыялага якынайтып тыңлап-тыңлап карады. Ләкин берни күрмәде, тавыш-тын ишетмәде: күзләре һәм колагы томаланган иде аның.

Шомлы тынлык дәвам иткән саен, Мәүләвинең барлык буыннары, кул һәм аяк бармаклары җелегенә үтеп керердәй булып сызлый иде. Әлеге сызлау-сыкрау аяк бармакларының иң-иң очыннан кузгала да, интектереп-җәфалап, астан өскә таба үрмәләп менә башлый, эчке әгъзаларын үтәли узып, тамак төбенә җитә һәм шунда чуерташ булып тыгылып кала.

«Бу ни хәл бу? Көзге яңгырларга иртәрәк, урак-мураклары да бетмәгән бугай әле, ниткән яңгыр?— дип уйлап алды Мәүләви, суда яткан бүрәнә башыдай авырайган аякларын ятагыннан салындырып утырырга азапланган килеш.— Нишләп кичкырын ук чамаламадым соң, кортлар да андый-мондый үзгәреш буласын сиздермәде шикелле. Усал унтагай, җыен хәерче токымы кереп, умарта ояларын актарып-нитеп китмәсен тагын».

Мәүләви карт, бал кортлары исенә төшүгә, уфылдап куйды, кабалана-кабалана ятагыннан төште, искереп, чалшаеп беткән, юкәдән үргән башмакларын капшанып эзләп тапты һәм, күпне күргән брезент плащын аннан-моннан җилкәсенә салып, ишектән чыкты.

Урманда күзгә төртсәләр күренмәслек дөм караңгы иде. Мәүләви, карурман уртасында адашып калган бер мескен шикелле, беравык аптырап басып торды.

Җаны нәрсәгәдер шомлана һәм нигәдер үзалдына курка-шөбһәләнә иде аның.

Әмма озак еллар буена урман белән аралашып яшәү үзенекен итте, бераздан Мәүләвинең күзләре аны-моны шәйләрлек булды, караңгылык чигенгәндәй тоелды.

Каршыдагы учарлы-учарлы йөзьяшәр имән, ботак-чатакларының

---

*Газиз* КАШАПОВ *(1942)— прозаик. «Сәмум җиле», «Еллар тыныч иде», «Язмышыңа ышан» һ. б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

ныклыгын сынарга теләгәндәй, көчле җил куәтенә тирән көрсенеп чайкала, тамырдашлары ышыгына сыенган агач ызба өстенә бөтен авырлыгы белән авардай булып сыгыла; аннары, җил басымы акрынайган арада, кабат ыңгырашып, гадәттәге хәленә кайтырга омтыла иде.

Агач яфракларына пыты-пыты итеп эре тамчылар тамды, һәм шундук чиләкләп яңгыр коя башлады. Кинәт якында гына:

— Кара син аны, йөзьяшәр имәннең дә сөякләре ничек сыкрый, менә шул инде ул картлык дигән нәрсә! — диде бераз карлыга төшкән Тавыш. Ят Тавыш!

Гомерен шушы урман арасында уздырган Мәүләви үзен куркаклар рәтеннән санамый иде. Әмма җиде төн уртасында әллә нинди куркыныч, әлек ишетмәгән ят, ләкин шул ук вакытта таныш та кебек серле Тавыш ишетелгәч, сискәнеп китте, гәүдәсен чымырдатып, аркасыннан «каз тәне» йөгереп үтте. Ул ихтыярсыздан як-ягына каранды, хәтта башын күтәрә төшеп, каршысындагы имән ботаклары арасына күз салырга өлгерде.

Күрер күзгә адәм заты юк сыман иде.

Урман аланының аргы башындагы имәннәр яшен утының елтыр-елтыр адашып йөрүеннән әкияти карагай сурәтләре хасил итәләр, аннары төннең шомлы караңгылыгына кушылып юкка чыгалар иде.

Мәүләвинең аяклары җиргә ябышып, сеңеп калдылар диярсең, ул баскан җиреннән ни артка, ни алга таба кузгалырга кыймады.

— Нигә дәшмисең, Мәүләви? Танымыйсыңмы әллә?

Тавыш, чынлап та, шундый таныш иде.

Мәүләви тәнендәге баягы чымырдау берьюлы күкрәк аша узып, кан тамырлары буйлап йөрәкнең үзәгенә барып кадалгандай булды. Аннары бөтен эчке әгъзаларын биләп өлгергән калтыравык кан агышы баш миенә үрмәләп менде, күз алларын томалады.

Ничәмә-ничә еллар буена дөньяны, урман тирәсендә бер-берсенә сыенышып утырган өч-дүрт авылны дер селкетеп, бик күпләрне куркытып яшәгән Мәүләви яшен ташы кисеп төшергән агач кәүсәсе кебек өнсез калып, җиргә, юеш яфраклар өстенә ауды...

* * *

Шушы сәерлек халәтендә күпме вакыт узгандыр, Мәүләви соңыннан да исенә төшереп чамалый алмаячак, әмма курку дигәнең бер канынкса каныга бит ул — Мәүләви, башын күтәреп, тирә-юньгә күз салырга өлгермәде, баягы Тавыш тагын ишетелде:

— Тор, Мәүләви, заманында авылдашларың сиңа юкка гына Убырут[1] дип кушамат бирмәде. Вакытында мондый хәлләргә исең дә китми иде синең. Тор да бас, турыдан-туры карап җавап бир, сөйләш Вөҗданың белән...

Монысын... монысын Мәүләви бөтенләй башына китермәгән иде.

«Ничек инде, ничек инде мин, үз акылымда килеш, юләр кеше шикелле үз-үзем белән сөйләшим?.. — дип уйлап алды ул. — Бу бит... бу бит...»

Ләкин шул ук мизгелдә Мәүләви ихтыярсыздан, һич көтмәгәндә, әлеге Тавыш белән гәпләшә башлады.

— Син... Син... кем буласың?.. Сиңа миннән ни кирәк? — дигән сүзләр Мәүләвинең күкрәгеннән гыжылдап чыкты. Әмма Мәүләви теге Тавышны да аермачык ишетә, төсмерләренә кадәр үзенеке икәнлеген тоя иде. Ул тагын як-ягына каранып, аңгәмәдәшен күрүдән өмет өзмәгән кеше кебек, болай да кечерәеп калган күзләрен чекрәйтә төшеп сорады:

[1] Убырут — шайтан таягы үсемлегенең диалекталь атамасы. (Автор.)

— Син кем... Сиңа миннән ни кирәк?

Яшен тынып торган арада бөтен тирә-як гүр караңгылыгына чума. Шул вакыт Мәүләвинең такыр башына, жыерчыклы йөзенә, кечкенә сакалына, берничә ел буена тоташ киюдән итәкләре каеш сыман ялтыраган пинжәгенә салкын тамчылар тама. Ләкин ул үзе аларга бөтенләй илтифатсыз бер хәлдә торараш булып баскан да ни кылырга белмичә эчтән калтырана иде.

«Югалмасмы?»— Мәүләви шулай уйларга өлгермәде, әлеге Тавыш тагын:

— Мин Мәүләви Риянов булам,— диде өздереп.— Ә син соң әле нишләп белмәмешкә салынган буласың?

Мәүләвигә, ниһаять, жан кергәндәй итте, шүрләве соңгы чиккә житте. Ул әйләнә-тирәсенә тагын бер кат күз йөгертеп алды һәм, үрмәли-үрмәли, урман каравылчысы чагында ук салдырган ызбасының ишегенә таба чигенә башлады.

«Йә хода,— диде Мәүләви артка таба үрмәләвен дәвам итеп,— картаймыш көнемдә акылыма жиңеллек килә күрмәсен, йә хода, үзең сакла...»

Ызба ишеге ярым ачык калган икән, «Тавыш иясе аягымнан эләктереп алмасын тагын»,— дигән уй Мәүләвине ашыктырмакчы иде, ләкин ул үзендә, аягына басып, эчке якка атларлык көч тапмады. Ишек тактасына ике куллап ябышкан килеш, кысыла-кысыла, бусага аркылы керде һәм бераз хәл алгач кына, үрелеп, тимерче Вахибтан махсус ясатып алган келәне элмәгенә төшерде. Тимергә тимер бәрелеп «чык» иткәч, Мәүләви жиңел сулап куйды.

Беравык тын алганнан соң гына алпан-тилпән адымнар белән мич янына килде, тояр-тоймас кулы белән капшана торгач, шырпы кабын тапты. Тагын, сагая төшеп, тирә-якны тыңлап торды. Бу юлы йөрәгенең дөп-дөп типкәнен генә ишеткәндәй булды, әмма асылмалы лампага таба омтылырга өлгермәде, бүлмә яңгырады:

— Ут алдың ни, алмадың ни, Мәүләви, мин барыбер монда.

Сыртына кисәү агачы сыланды диярсең — Мәүләви тагын хәрәкәтсез калды.

«Жиңеләям!»

Баягы шикелле үк, ихтыярсыздан Тавыш иясенә сүз кушты:

— Син түгел, мин — Мәүләви... Житмеш тугызынчы ел инде мин — Мәүләви... Син нигә мине, олы кешене, бимазалыйсың? Сиңа миннән ни кирәк? Мин монда, табигать иркендә жаныма тынычлык, сөякләремә сихәт табып яши идем. Бал кортлары үрчетеп...

Мәүләви хәле китеп, йөрәк тибеше ешайганны сизеп, сәке читенә сул кулын тидерде, аннары үзе дә шунда утыргандай итте.

— Бисмиллаһи иррәхман иррәхим...

— Мин дә Мәүләви,— диде үзсүзле Тавыш бу юлы ярыйсы ук кырысланып.— Син генә мине танымаган булып кыланасың. Әйе, мин дә Мәүләви. Тик хәзерге көндә үзен ил карты итеп танытырга тырышучы Мәүләви түгел, моннан күп еллар элек авызыннан ут бөркеп, тавышы күкләрне күкрәтеп, тол хатыннар, гөнаһсыз кызлар, ятим балаларны Дию пәриедәй куркытып торган Мәүләви. Ул чактагы эшләреңне оныттыңмыни соң?

— ...иллалаһе мөхәммәден рәсүлаллаһ...

Мәүләви сәке читендә утырган жиреннән салмак кына шуып идәнгә төште.

* * *

Коеп яуган яңгырга эләгеп, манма суга төшкән бохар мәчесенең таба-

нәк болдырга атылып менеп ишеккә бәрелүе Мәүләвине чынбарлыкка кайтарды. Ләкин бу кайту әле көчсез, ихтыярсыз кайтудан гына гыйбарәт иде. Мәче адәм заты янына керергә тырышып, ачы тавышка кычкырып, ызбаның ябык ишеген тырнарга кереште. Ишек тактасына кадалган тырнаклар йөрәк парәсен тырнап-тырнап алгандай итте. Мәүләвинең аңы мәче тырнашканны тоя, ләкин бу аңа әлеге дә баягы Тавыш хәрәкәте булып кына аңлашыла иде.

— Әй син, Мәүләви, усак яфрагы булма, курыкканга сабышып җиңел генә котылырмын димә. Теге чактагы шәфкатьсезлекләрең онытылыр да, тәүфыйк иясе булып йөрермен, дөньядан җәзасыз гына китәрмен, дип уйлыйсың бугай. Юк инде, алай булмый ул. Хөкем гаделлеге килеп ирешмәгән очракта, кеше үзенең вөҗданы каршында булса да котылгысыз җавапны бирергә тиеш. Сиңа, Мәүләви, кылган эшләреңнең җәзасын татырга туры килмәде, ләкин менә бүгеннән соң мин, синең Вөҗданың, теге чакларны туктаусыз исеңә төшереп торучы булырмын. Син миннән арына алмассың, алдан ук кисәтеп куям. Инәлсәң инәл, ялварсаң ялвар, әмма ләкин мин һәрвакыт синең янында булырмын...

Тавышның бу мөрәҗәгатен Мәүләви куркудан җаны-тәне куырылып, җилкәләрен җыерып (әйтерсең, аңа кемдер кисәү агачы белән кундырырга тиеш), калку калак сөякләрен тагын да турайтыбрак тыңлады. Баягы калтыравы яңадан әйләнеп кайтты, аннары бөтен тәнен биләде, ясалма тешләре бер-берсенә шакы-шокы бәрелә башлады.

Тыштагы җилнең көче инде басыла төшкән иде, шуңа күрә күк күкрәве тынган арада түбә калаена төшкән яңгыр суының шыбырдавы гына ишетелеп торды.

— Соң бит, канәт, үткән эшләрең дисең дә син... Ул чакта бит... Үзем өчен түгел...

Тавыш, Мәүләвигә әйтеп бетерергә ирек бирмичә, аны бик тиз бүлдерде:

— Ялганлама, Мәүләви. Чөнки ялган һәрвакыт куркаклыктан һәм көчсезлектән килә. «Хөкүмәт эшен кайгыртып йөрдем»,— дип өзгәләнүләреңне ишеткәнем бар. Кисәтеп куям: боргаланма! Ачыктан-ачык аңлашыр заман җитте. Син бит теге чакларда кеше алдында, дөресрәге, җитәкчеләр алдында гына өзгәләнә идең. Чынлыкта исә... Ярый, ярый, ул хакта сөйләшербез әле. Мин, Мәүләви, синең Вөҗданың, шуның өчен синең күңелеңә кердем дә... Син бит сизеп тордың... Нинди юллар белән булса да кертмәскә тырыштың. Синең мүкләнү генә түгел, ташка әверелгән күңелеңнән, бозланып каткан келәтләреңнән йозакны ватып чыгу бер генә дә җиңел булмады. Ничәмә-ничә еллар тырыштым мин ул тоткынлыктан чыгар өчен... Сине Убырут Мәүләви диләр, ә мин — сиңа кайчандыр атаң-анаң кушкан Мәүләви. Озак йоклаттың син мине, озак... Хәзер инде син, кешеләр алдында булмаса да, бәлки Вөҗданың алдында ул эшләреңнән ваз кичәрсең, бәхиллек сорарсың...

...Нәрсә соң ул вөҗдан? Гомумән, авыз суы корытып, бик күпләр «вөҗдан да вөҗдан» дип шапырына башладылар әле соңгы вакытларда. Эх-ма! Теге вакытлар, корыч куллы юлбашчы еллары булса... Белер иде Мәүләви андыйларның тишек авызларын томалап, телләрен аркылы тешләтү җаен, белер иде!..

«Вөҗдан, имеш». Шушы мыскыллы уй белән Мәүләви Тавышны бүлдерергә һәм нәрсәдер каршы әйтергә чамалап, авызын ача башлаган иде, тик күңеленең кай төшендер бохар мәчесе тырнап-тырнап алгандай итте. Аңа тагын баягы шомлану-шөбһәләнү тойгылары әйләнеп кайтты.

— Килештекме, Мәүләви?! Вөҗдан...

Мәүләви башына тимер күсәк белән тондырдылар диярсең — ул сыгылып төште, муенын җыерып, башын ике җилкә арасына сеңдергәндәй итте.

«Вөҗдан, имеш?!» Убырут Мәүләви андый төшенчәләр турында

уйланырга вакыт әрәм итеп тордымы соң? Юк, ул андый йомшаклыкка, алай гынамы, җебегәнлеккә беркайчан да ирек куймады, җәлләү-кызгану һәм миһербанлык хакында уйлап та карамады. Ләкин, нишләмәк кирәк, гомер уза, кигән кием туза дигәндәй, тора-бара заманалар үзгәрә, Мәүләви теләмәгән якка таба авышырга керешге. Төрле каршылыкларга очрап, вакытлыча менгән мөнбәрләреннән очып-очып төшсәләр дә, каһкаһәле көлүләрен дәвам итеп, һәр уңышсызлыктан рәхәт табып яшәп яткан Мәүләвиләрнең дә җаны тыпырчына башлады. Алар да җан иясе бит... Алар да бары тик чуеннан гына тормыйлар... Аратирә, авылның теге яки бу кешесе очраганда, йә булмаса берәрсен зират юлына таба озатканда, Мәүләвинең күңел төпкелендә: «Бу теге чактагыларны хәтерендә саклыймы икән соң?» — дигән уй калкып-калкып куйгалый иде. Дөрес, Мәүләви үзе авылның бер генә кешесен дә, хәтта атасы булып атасын да зиратка кадәр озатмады. Кеше өстенә бармады ул. Акланырга сәбәбен таба торды. Атын җикте дә районга чыгып киткәндәй итте — күрше авылга барып, көмешкә чөмереп кайтты. Яки урманга таба юл тотты, андагы агачларга кычкырып сәлам бирде, кошларга эндәшкәндәй итте, шулар белән сөйләшүдән җанына юаныч тапты...

Хәзерге авылдашлары йөзендә Мәүләви ачыктан-ачык күралмаучанлык, ым-шом сизмәгән кебек булса да, әлеге Хәтер дигән нәрсә сирәк-мирәк кыймылдап алгалый иде.

Урамда очраган авылдашы: «Мәүләви абзый, ни хәлләрең бар?» — дип хәл-әхвәлен сораштыргаласа да, җәелеп китеп, озын-озак гәпләшеп, юкны бушка аударып торудан баш тарта, тизрәк үз сукмагыннан атлау ягын карый иде.

Ни өчен соң Мәүләви абзагыз соңгы вакытларда әледән-әле хәтер сандыгында казына башлады, «каһәр төшкән сугыш»ны һәм аннан соңгы елларны искә төшерә, ул чактагы вакыйгаларны торган саен ешрак барлый? Картлык яки урмандагы ялгызлык галәмәте дияр идең, Мәүләви элек тә кеше арасында чын-чынлап яшәмәде. Күп вакыт үзе белән, үзенең уйлары һәм үзе корган төрле зурлыктагы уй-планнар белән яшәргә тырышты.

Шулай булгач, аның соңгы еллардагы уйлары эчпошыргыч бертөрлелек белән «теге дөнья»да бирәчәк җаваплары тирәсендә әйләнә башлаган икән инде, бу бер дә гаҗәп түгелдер.

* * *

...Егерме тугызынчы елның ахырлары иде бугай. Чистай базарына барган җиреннән әтисе Риян агай «хуҗалыкларны кумәкләштерәләр икән» дигән ят хәбәр ишетеп кайтты. Мәүләви аның карангы төшәр алдыннан кайтып кергәнен, атын тугарып, ашарына печән салып йөргәннәрен күтәп алганын һәм, өйгә кергәнче үк, болдыр алдында тукталып:

— Мәүләви, кил әле бире, сөйләшеп алыйк,— дигәнен бүгенгедәй хәтерли.

Ул чагында, давыллы еллардан соң, авылында җир сөреп, иген игеп йөргән һәм авылдашлары кичергән вакыйгаларның барысына шаһит булып яшәгән Мәүләви шушы сөйләшүнең үз тормышында ни хәтле мөһим, бәлки хәлиткеч урын алып торачагын уйлап та карамаган иде. Әтисе дөньяның кайсы якка таба авышканын бик дөрес чамалаган булып чыкты.

— Син, улым Мәүләви, менә нәрсә эшлә: артык шаулап-нитеп йөрмичә генә, җаен китереп, беренчеләрдән булып калхузга кер...— диде әтисе. Мәүләвинең дә колхоз дигән нәрсә турында беренче генә ишетүе түгел иде, төрле-төрле сүзләр арасында яхшысыннан начары

күбрәк йөрде. Шуңа күрә ул этисенең «калхузга кер» дип үгетләп торуына гаҗәпләнмичә булдыра алмады.

— Соң бит, эти, ни бит... анда хатыннар да... бергә була дип әйтәләр бит.

Риян агай мондый юк-барларга ышана торганнардан түгел иде.

— Син, улым, кеше ышанмас нәрсәне дөрес булса да сөйләмә. Атаң әйткәнне колакларың белән тыңла, акылың белән аңла... Калхузга, язылып, бераз йөргәч тә җайлап кына партиясенә дә керерсең.

Монысы инде бөтенләй кеше ышанмаслык хәл иде. Риян агай булып Риян агай шулай дип торсын әле.

— Мине, эти, алырлармы икән соң анда?

— Алырлар, ник алмасыннар?!— диде этисе, Мәүләвигә сынаулы карашын төбәгән килеш.— Алырлык итәргә, калхузның беренчеләреннән булырга кирәк. Атыңны да, сыерыңны да, инде әйтсәм әйтим, кирәге чыга-нитә калса, хатыныңны да илтеп бирерсең...

Аннан бирле байтак сулар акты, җилләр исте, әмма Мәүләви этисенең зирәклегенә торып-торып гаҗәпләнеп яшәде. «Каян белгән, ничек дөрес чамалаган»,— дип уйлый иде ул ялгыз гына калган минутларында этисен исенә төшереп. Рәхмәтләр әйтерлек, этисен җылы сүз белән искә төшерерлек иде. Әгәр дә мәгәр ул теге вакытларда шундый акыллы киңәш бирмәгән, ә Мәүләви шушы киңәшне җиренә җиткереп үтмәгән булсамы? Бәлки, Мәүләвине авылдан әллә кайдагы Себергә олактырган булырлар иде.

* * *

Элек Мәүләвине ялгызлык дигән нәрсә куркытмый, киресенчә, ул ялгызлыкка күнеккән, аңардан үзенә нииндидер яшерен тәм табып яши иде. Әмма соңгы елларда ялгызлык сиздермичә генә аның күңел тынычлыгын кимерә башлады. Кайбер төннәрдә Мәүләви саташып, әллә кайчан булып узган вакыйгаларны телевизордагы шикелле дәвамлы итеп күрә-күрә төшләнә торган булды. Ә аннары инде, бигрәк тә быелгы яз башыннан бирле, саташулар ешайды. Иң гаҗәбе шунда иде ки, ул йоклаганда гына түгел, уяу чакта да тормышындагы вакыйгалар искә төшкән саен күкрәгенә аңлашылмас шомлану тулудан манма тиргә чума һәм шуның сәбәбен аңламыйча интегә иде.

Бүген дә шушы саташуларның дәвамы булса кирәк.

Шулвакыт Мәүләви күкрәк кесәсендә нәрсәнеңдер кыштырдап куюын сизде. Ул да түгел, әлеге нәрсә, кыштырдап кына калмыйча, меңләгән энәләргә әверелеп, йөрәк турысына кадала башлады. Мәүләвинең уң кулы ирексездән камзул кесәсенә тыгылды.

Кичәгенәк Мәүләви, авылда гына кунармын дип, кичкә каршы чыгып киткән иде. Урыс капканың яртысын ачып, аны әйбәтләп терәтеп куйганнан соң, икенче яртысына килеп тотынуга:

— Мәүләви бабай, менә сезгә телеграмм китергән идем,— дигәнне ишетеп, сискәнеп китте.

Эшен бетермичә икенче нәрсәгә үреләә торганнардан түгел иде Мәүләви. Шуңа күрә бер тотынгач, урыс капкасының икенче ягын да ачып бетерде, иске кендек белән терәп куйды. Аннары, урам якка чыга төшеп, атының йөгәненнән тотып, ишегалдына кертте һәм шуннан соң гына телеграмма кәгазен сузып торган почтальон кыз янына таба атлады.

Кызга рәхмәт әйтү түгел, күтәрелеп карарга да онытты. Телеграмма кәгазен капшады, артын-алдын әйләндереп карады, ачык тәрәзәдән яртылаш чыгып карап торучы Кәрамиясенә икеләнергә урын калдырмыйча:

— Күзлекне,— диде.

Кәрамия, шул мәлдә артка тартылып, тәрәзә төбендә үсеп утырган гөлне эчке якка аудара язды. Беравыктан түгәрәк пыялалы күзлекне китереп тә житкерде.

Кәрамия, ләм-мим бер сүз эндәшмичә, картының хәрәкәтләрен күзәтеп торды, аның йөзендәге үзгәрешләрне күреп, иске китте. «Кайтканда болай ук түгел иде бит әле бу, хәзер бөтенләй әллә нишләде, нинди чебен тешләгән соң моны? Әллә тагын берәрсе?..»— дип уйлап алды.

Ул арада Мәүләви инде кәгазьнең жаен эләктереп алган иде, кул сузымы ераклыкта тоткан килеш укырга кереште.

*«Приезжаю на днях тчк ждите тчк Фалахутдин».*

Мәүләви бу сүзләрнең мәгънәсен һәм «Фалахутдин»ның кем икәнлеген тиз генә төшенеп житмәде. Шуңа күрә иреннәрен кыймылдата-кыймылдата икенче, аннары өченче тапкыр укырга кереште.

— Нәрсә дигәннәр, кемнән соң ул телеграмм?— диде Кәрамия. Ул инде түземлеген жуйган иде.— Сәгъдулладанмы әллә? Карале, ник дәшмисең? Бер-бер хәл булмагандыр бит?

Ләкин бу вакытта Мәүләви хатыны тавышын ишетүдән ерак иде. Хәтер йомгагы аны, еллар катламы аша, еракта калган вакыйгалар эченә бөтереп алып китте.

* * *

...Кырык беренче елның сентябрь ае бетеп бара. Мәүләви яңарак кына авыл советы рәисе булып алган иде. Шундый көннәрнең берендә кече туганы, ягъни мәсәлән, энесе Мәгафур белән якага-яка килеп бәрелеште.

Сельподан кайтышлый Мәүләвинең аты, юлдан чыгып, тегермән елгасы янына борылып кергән икән. Ул гына да түгел, камышлык арасында баткаклыкка бот төбеннән төшеп чумган. Бәхетсезгә жил каршы дигәндәй, Мәгафур шуннан әллә ни еракта түгел тракторы белән жир сөреп йөри иде. Бер борылыш вакытында камышлыкка кереп барган атны күрде, икенче әйләнеп килгәндә атның дугасы да күренми башлавын шәйләп алды. «Ул-бу булмагае»,— дип тракторын туктатты да шунда юнәлде. Караса — арбада абыйсы Мәүләви ята.

Атны туарганнан соң абыйсын төрткәләп-тарткалап уятырга кереште. Тегенең исерүе житкән, шуның өстенә йокысы да каты күрәсең, уянмый да уянмый. Мәгафур нишләсен, абыйсын арбадан күтәреп алып жиргә бастырырга мәжбүр булды. Аяк асты болай да тетрәнеп кенә тора, ә Мәүләви басып торырлык хәлдә түгел, ава-түнә берничә адым атлавына, камышларга бәрелә-бәрелә егылып китте. Битләре тырналу гына түгел, камышка тотынырга азапланганда куллары да киселеп канга манчылды.

Шушы әрнүдән булса кирәк, Мәүләви күзләрен ачты да акырырга, бакырырга тотынды:

— Әһә, син әле мине, авыл советы рәисен, баткаклыкка алып кереп үтерергә жыендыңмы? Атымны кертеп батырдыңмы? Эз югалтырга идеме исәбең?

Аңа каршы Мәгафур:

— Абый дим, абый, нишләвең бу? Мин бит бу — энең Мәгафур!— дип аңлатмакчы булды. Шунда гына Мәүләви аңына килеп беравык туктап торды.

— Мин нишләп монда?— дип сорады ул.

— Соң, атың үлән чемченергә борылгандыр да камышлыкка кереп киткәнен абайламый калгандыр. Мин аны ерактан күреп килдем. Син икәнлекне белмәдем бит,— диде Мәгафур.

Мәүләвигә житә калды. «Әһә, мин икәнлекне белгән булсаң, килергә исәбең дә юк идемени әле синең??»— дип бәйләнә башлады.

Мәгафур аңа карап-карап торды да, ачуыннан җиргә түкереп китмәкче булды. Ләкин кая ул, Мәүләвинең болай да энесе белән араны ничек өзәргә белми торган чагы, отыры тузына башлады:

— Хәзер үк тракторыңны мондарак китер дә атны тарттырып чыгар. Югыйсә, үтермәкче иде дип, бөтен авылны күтәрәм,— диде. Ул инде авылдашларының Мәүләви белән Мәгафур арасы тыныч түгеллекне, аның сәбәбен белүләрен уйлап алды. Эш Риян абзый вафат булыр алдыннан әйткән васыятьнең бозылуында иде. Әтиләре болганчык елларда бар байлыгын алтын-көмешкә әйләндереп өлгергән булган. Шуны үләр алдыннан гына Мәүләви белән Мәгафурга васыять итеп калдырды. «Уртак тотарсыз»,— диде. Әмма төп йортта калган байлыкны Мәүләвинең берәүгә дә бирәсе килмәде. Мәгафур берничә мәртәбә:

— Абый, йорт-җирем тузган. Яңартырга исәбем бар, зинһар, бераз ярдәм ит. Әти калдырганнан аз булса да өлеш чыгар,— дип йөзен ертып барса да, бушка гына иде. Ә соңгы бер сөйләшүләрендә Мәүләви авыл советы рәисе булып утырган иде инде.

— Әгәр дә мәгәр тагын бер шушы сүзне кузгатсаң,— диде ул энесенә,— борыныңны[1] алдырам да сугышның җәһәннәм җиренә озаттырам мин сине...

Күрәләтә тракторын баткаклыкка кертеп батырырга Мәгафурның да башы ике түгел. Ә исерек Мәүләвинең үз тугызы тугыз, һаман кычкырынуын белә:

— Хәзер үк тракторыңны монда китер!

Мәгафур аңа карап торды-торды да әйтеп салды:

— Әй, Мәүләви, Мәүләви, халык сиңа бер дә юкка гына Убырут дип әйтмәгән икән. Шайтан таягының да, синең дә бер икәнне белә идем. Ышанып ук бетмидер идем. Чынлап та дөрес икән,— диде дә кулын селтәп китә башлады. Ләкин егерме-утыз адым китә алмыйча, тораташтай катып калды. Мәүләвинең:

— Коткарыгыз, үтерәләр! Камышлыкка батырып үтерәләр... суялар,— дип кычкыра-кычкыра авылга таба йөгерә башлавын күрде. Әлеге тавышны ишетеп, сыерлар фермасыннан берничә хатын-кыз йөгерешеп чыкты:

— Кем үтерә, нәрсә булды, Мәүләви абзый?

— Әнә иблис, халык дошманы, Мәгафур үтерә... атымны камышлыкка кертеп батырды... Менә мине пычак белән кискәләп бетерде, көчкә генә ычкындым,— дип, нәрсә сөйләгәнен белеп тә бетермичә ялганының куркак, ябышкак ядрәләрен сипте...

Өч-дүрт көннән Мәгафурның бронен юкка чыгардылар һәм ул сугышка чыгып китте дә бер хәбәрсез югалды.

Аннары, кырык өченең карлы-буранлы бер төнендә, Мөсәлим бабайның карт эте Мәгафурлар йорты турына барып утырды да ач бүре сыман уларга керешге. Моны ишеткән Мөсәлим бабай мич башында морҗа ташларына аркасын терәп утырган килеш: «Тагын кемнең әҗәле җитте икән, кемнеңдер үлемен сизеп улый бит бу, мур кыргыры»,— дип сукранып куйды.

Чынлап та, берничә көннән урманга баручылар бәләкәй чана тартып утынга, чыбык-чабык сындырырга киткән Гайшәнең — Мәгафур хатынының калдыкларын алып кайттылар. Аны ач бүреләр талап үтергән иде.

Шулай итеп, күптән түгел генә шау-гөр килеп яшәгән гаиләнең ике терәге дә югалды, юкка чыкты. Кайчандыр гүрничә кебек өй уртасында җиде яшьлек кыз һәм аягына яңарак кына йөри башлаган ир бала утырып калдылар.

Гажилә белән Фәләхетдинне тирә-күршеләре, кем ничек булдыра, шулай карадылар, ләкин кырык өченең кышы авылдагылар өчен иң

[1] Бронь сүзен бозып әйтү.

авыр кыш булды. Сугышка кадәр тупланган запас бетте, яңасы исә беренче чиратта фронтка китте. Мәгафур ул елны байтак эшләгән иде, ләкин ул эшләп калдырган икмәк балаларына тимәде. Хәер, тигән очракта да җиде яшьлек кыз хуҗалык алып барырлык, энесен тәрбияләрлек түгел иде әле.

Март башларында Яңа урам кешеләре җыелышып авыл советына, Мәүләви янына килделәр. Аларга шушында ук эшләп утыручы Сагыну исемле хатын да кушылды. Алай гынамы, тегеләрне котыртып:

— Мәүләви абзый, туганыгызның балалары бит, бәлки... үзегезгә алырсыз. Аларны гына карарлыгыгыз бар,— дип куйды.

— Кемне карарлыгым барлыгын, Сагыну канәт, мин үзем дә бик яхшы беләм,— диде Мәүләви ул чагында һәм һич көтмәгәндә фикерен дә үзгәртеп ташлады:

— Ярый алайса, миннән булсын изгелек. Иртәгә Чистайга китәм, бүген үк кәгазьләрен әзерлибез дә детдомга тапшырырга тырышып карармын. Түлке... халык дошманының балаларын...

Яңа урам хатыннары аңа әйтеп бетерергә ирек куймадылар:

— Кешедән оял, Мәүләви абзый, нинди халык дошманы булсын Мәгафур? Туганың лабаса... Трактор маеннан кышын-җәен арына алмады. Оныт шул бәхәсегезне. Хәзер инде Мәгафурга мал кирәкми...

Мәүләви хатыннарның өзек-өзек әйткән мондый сүзләрен тыңласа да тыңлады, тыңламаса да тыңламады. Әмма инде кайсыдыр «мал кирәкми...» дип ычкындыргач, түзмәде.

— Барыгыз, алдыгыздан артыгыз яхшы, эшегездә булыгыз, түлисе бурычларыгызны онытмагыз,— дип кырт кисте.

Хатыннар да, түлисе бурычлары турында сүз чыккач, тизрәк этешә-төртешә чыгу ягын карадылар.

* * *

Балаларны Чистайга урнаштырганнан соң бер-ике елда аларның язмышы белән кызыксынырга туры килмәде Мәүләвигә. Соңрак кемнеңдер Чистайга барып балалар йортына кереп белешкәнен ишетте. Ятимнәрне каядыр бүтән йортка, ераграк шәһәргә, Башкортстан якларына күчергәннәр икән, диделәр. Аннары инде Мәүләви генә түгел, авыл кешеләре дә тора-бара ул балаларны оныттылар. Дөрес, хатын-кызлар аларны искә төшергәләп, күзләрен юешләтеп алалар иде, әмма үз кайгылары да җитәрлек бер заманда...

Баксаң, кырык биш ел үтеп тә киткән ләбаса!..

Телеграмма сугучы, димәк, Мәүләви кайчандыр балалар йортына тапшырган Фәләхетдин үзе булып чыга. Ул авылны, алай гынамы, этисенең абыйсының исемен дә онытмаган. Кайтмакчы була. Болай булгач, кайта да кайта инде.

Кинәт Мәүләвинең башына кайнар кан йөгерде. Ул, ни эшләгәнен белештермичә, ишегалдына кертеп бастырган атын яңадан борып алды һәм, өйдән йөгереп чыккан Кәрамиясен бәрдерә язып, урам буйлап урманга таба куып китте.

«Димәк,— дип уйлады Мәүләви,— әгәр дә мәгәр ул, малай актыгы, кайтып күренсә? Этисен хөкем аша сугышка җибәрүчене, үзләрен балалар йортына илтеп иленнән адаштыручының кемлеген аңа җиткерәчәкләр. Әйе, әйтәчәкләр... Авыл халкы моны онытмаган, әлбәттә. Бигрәк тә хатын-кызлар онытмаган. Димәк, Мәүләвигә шушы Мәгафур калдыгы каршында бәхиллек сорарга туры киләчәк... Юк инде, не шали, канәт. Мәүләви атлы Мәүләвине уен-муен белән, җиңел генә алдыра алмассың. Тиз генә бирешә торганнардан түгел ул Мәүләви Риянов. Аны бер дә юкка Убырут дип атамыйлар. Көче җитмәсә, тешләре белән ябышыр ул».

* * *

Тагын ялгышты Мәүләви. Бу уйларын үзалдына сөйләнеп утырасы булмаган икән.

Тавыш аны тыңлап-ишетеп торган, каһәр суккыры, Мәүләвинең күкрәгенә эчке бер калтырау салып:

— Ташла, андый уйларыңны, Мәүләви,— диде яшерен уйларны китап битеннән укыган шикелле итеп.— Яхшылап уйласаң, әйбәтләбрәк барласаң, бәлки... авылдашларыңнан гаф... гафу үтенсәң, ягъни мәсәлән, бәхиллек сорасаң, дөресрәк булмасмы?

Үзенә кирәк чакта Мәүләвинең башы тиз эшли, яхшы яки начарны тиз аера иде. Бу юлы да шулай булды: Тавыш сүзен төгәлләргә өлгермәде, Мәүләви ызба идәненең урта бер төшендә утырган килеш як-ягына каранып алды.

— Мин соң кемнән... кемнән и ни өчен бәх... бәхиллек сорарга тиеш булам? Туктале, агай-эне, мин бит... теге... ни бит әле... те-ген-дә китәргә җыенмыйм. Миңа монда да нач-чар түгел. Син нигә алай дисең соң әле?— диде Мәүләви һәм, һич көтмәгәндә, йөрәгенең уйнап-уйнап алуын тойды. Бу инде бер дә уен түгел, ниндидер Тавышның янавыннан болайрак иде. Йөр... рәк... Турысын әйткәндә, Мәүләви гомере буена аһ та ваһ килеп йөрде. Шуның өстәвенә теге сугышта да һәм монысында да фронтларга кадәр бармау җаен тапты, инвалидлык алуга иреште, бөтен авыл алдында арт санын сузыбрак йөри башлады... Әмма йөрәгенең болай уйнап-уйнап алуын моңарчы тойганы юк иде.

Тавышның бу хәлгә кәефе килде бугай, шул ук мизгелдә аның каһкаһәләп:

— Менә күрәсеңме? Бу инде, үзең әйтмешли, уен-муен түгел. Бу сине тегендә чакыруның ерак-еректан килгән беренче дулкыны,— дигәне ишетелде.

Мәүләвинең тыны кысыла башлады. Ул авызын берничә мәртәбә зур-зур ачып, судан җиргә алып ташланган балык кебек, сулыш алырга тырышып карады. Тик, барыбер, күкрәген кыскан кыршау иркенәймәде, киресенчә, тагын да катырак кыскандай булды, чәнчешеп-чәнчешеп куйды.

Бөтен әйләнә-тирәне көндезге кояш сыман яктыртып, яшен уты ялтырады. Шуның артыннан ук, вакытсыз сынган агач шикелле, нәрсәдер чатыр-чытыр итеп алды. Бер мизгелгә генә тынлык урнашты һәм — күк гөмбәзе барлык йолдызлары-ниләре белән җиргә ишелеп төште диярсең!— яшен туплары гөрс-гөрс атарга кереште.

Мәүләви, хәле берьюлы бетеп, идәнгә сузылып ятты. Икенчеме-өченчеме тапкыр «гөрс» иткәндә, артык түзеп тора алмыйча, ирексездән дүртаякланып ишеккә ыргылыш ясады, бусага аша чыгып егылды.

Мәүләвине көтеп торганнар диярсең, баягы шартлауларның барысын, барысын бергә туплаган дәвамлы гөрселдәү яңгырады. Мәүләвинең күз алдына тубал хәтле ут тәгәрәп килде һәм күп булса кырык-илле адымдагы йөзьяшәр имәннең куышланып торган ике ботак арасына кереп китте. Шул ук мизгелдә аннан кызгылт ялкын телләре күтәрелде, агачның юан кәүсәсе буйлап өскә үрмәләргә кереште...

* * *

Мәүләви һушына килгәндә, күк йөзеннән чиләкләп-чиләкләп су актарыла, баягы ялкын телләре исә аңа бирешергә теләмичә әрсезләнә, бер күренеп, бер югалып тора иде. Шулай да тагын беравыктан ут телләре җиңелде, чиләкләп актарылган су басымы астында сүнеп юкка чыкты. Мәүләви ирексездән өскә таба күтәрелеп карады да исе китте: дәү имәннең кәүсәсе гаять зур кылыч беләнме кисеп ташланган, аның учарлы ботаклары юкка чыккан иде.

Мәүләви гадәтенчә ярым пышылдап түгел, ярыйсы гына кычкыра-кычкыра дога укып җибәрде:

— Бисмиллаһ иррәхман иррәхим...

— Йә, Мәүләви, инде нишлибез? Болай булгач, теге вакытларындагы кебек курку белмәс гайрәт иясенә охшап ук бетмисең бит әле... Минемчә, иң һәйбәте, озын озакка сузмыйча, иртәгә үк авылга кайтасың да теге вакытларда үзең рәнҗеткән кешеләр алдына басасың. Соң түгел әле...— диде Тавыш.

Киеренкелектән шартлап өзелер хәлгә житкән Мәүләвинең карышып торырга бер генә мыскал да көче калмаган иде инде. Ниһаять, ул, иреннәрен сизелер-сизелмәс селкетеп, әйтеп куйды:

— Ихтыяр синеке, канәт, бүтән карышырлыгым калмады...

Мәүләвинең ясалма тешләре баядан бирле урыныннан кубып йөдәтә иде, ул хәзер генә шуларны яңадан урнаштырырга кирәклеген чамалады. Шушы эшен төгәлләгәч, Тавыш иясен күрергә теләгәндәй, як-ягына карана-карана, ярыйсы гына аңлаешлы итеп сөйли башлады:

— Ярый алайса, канәт. Син кодрәт иясе булгач, беләсең бит, мин үзем гомер буена көчленеке замана дигән нәрсәгә табынып яшәдем, минем инде тагын да карышырлык хәлем юк. Син әйткәнчә булсын соң. Тик ашыктырма гына. Үз җаема эшләрмен мин син теләгәннәрне...

— Юк, Мәүләви, мин теләгәнне түгел, син... син үзең теләгәнне.

— Ярый, ярый, канәт...

Тавышның җавабы ишетелмәгәч, Мәүләви сагаебрак, колакларын торгыза төшебрәк тирә-якны тыңлап карады. Тавыш ишетелми иде. Әмма инде Мәүләвинең дә: «Котылдым бугай, ходаем, узды бугай»,— дип уйлаудан узарлыгы, аннан да битәр Тавыш белән бәхәсләшерлеге калмаган иде. Ул көч-хәленә өйгә кереп сәкесе янына барды һәм кыйнап-җәзалап ташланган кеше шикелле урын-җир өстенә ауды.

Төш аралаш кына ул Тавышны ишеткәләгәндәй булды, тик аның сүзләренең мәгънәсе Мәүләвинең аңына барып җитәрлек анык түгел, шуңа күрә ул аларны ишетте дә, ишетмәде дә...

* * *

Ниһаять, йокысыннан уянды Мәүләви, бер-берсенә ябышкан күзләрен ачып җибәрде. Байтак вакыт аны-моны белештермичә хәрәкәтсез ятып торды. Аннары, торып утырырга уйлап, салмак бер омтылыш ясады һәм бөтен сөякләренең нигезгә салыр өчен киселгән имән бүрәнәсе шикелле авыр, искиткеч авыр икәнлеген сизде. Аннары аңында ниндидер тәртипсез ыгы-зыгы кузгалды. Төнге хәлләр барысы бергә тупланып, ачыкланырга өлгермәгән хәтерен били башладылар.

Ишекне ачып җибәрүгә Мәүләвинең күзләренә агачлар арасыннан кыйгачлап төшкән кояш нурлары килеп кадалды. Гадәттә, кояш нурлары ишеккә бәреп тормыйлар иде. Мәүләви: «Бу ни, бу?» дигәндәй исе китеп башын өскәрәк күтәрде, каршысындагы имәнгә карады һәм төнге хәлләрнең төш булмыйча, чын-чынлык икәнлегенә ышанды. Йөзьяшәр имәннең яртысыннан биегрәк кәүсәсе кырт киселеп җиргә кадалып төшкән, Мәүләви белә-белгәннән бирле каралып күренгән куыш тирәсе тагын да карала төшкән, күмерләнеп калган иде.

Һәммәсен дә аермачык итеп хәтеренә төшерде Мәүләви. Авыр сулап көрсенеп куйды, ызбасына кагылган эре кадактан йөгәнен табып алды, атын эзләргә китте.

Аланлык читеннән үк башланып киткән, аңардан башка берәү дә йөремәгәнгә ташландык хәлгә килә язган урман юлына таба атлады Мәүләви. Әмма аны нәрсәдер, чабуына ябышкан шикелле, тоткарларга тырыша сыман иде. Инде ничәмә-ничә еллар буена үзе яшәгән урман-

га, аланлыкка Мәүләви бүген генә күргәндәй гаҗәпләнеп, әллә нинди яңа күзләр белән карый иде. Бу үләннәр, юл буендагы ат арбасыннан биегрәк абагалар үзган төн эчендә генә үсеп чыкмаганнар лабаса. Алары ярый инде аның, ел саен көз көне саргаеп-шиңеп югала торган нәрсәләр, ә менә бу бер төптән үсеп чыккан биек каен агачлары күтәрелеп карасаң башыңдагы түбәтәең төшәрдәй булып бер төн эчендә үсмәгәннәрдер ич. Димәк, алар да булган бит. Булганнар, ләкин Мәүләвинең күңел күзенә генә чалынмаганнар. Ә инде кешенең күңел күзе күрми икән, маңгай күзенең нигә хаҗәте бар? Алар, агач кәүсәсендәге гаплгади ботак тишекләре сыман, чекрәеп кенә торачак.

Ул да түгел, Мәүләвинең баш очында диярлек кош сайрап җибәрде һәм, пырхылдап, бер ботактан икенчесенә сикереп кунды. Шул ук мәлдә Мәүләвинең колагына дыңгычлап тутырылган мамык бөкеләрне берьюлы тартып алдылар диярсең, урман шавы, тирә-юньдә әллә ничәмә төрле кош-кортларның чыркылдавы, чутылдавы, карылдавы, бөтенләй күзгә күренмәгән нәрсәләрнең безелдәве ишетелә башлады. Шуның өстәвенә агач яфракларының үзара лепердәшеп тирбәлүе, ул яфракларга кунган яңгыр тамчыларының ялтырап-ялтырап китүләре күренде.

«Гаҗәп,— дип уйлады Мәүләви ирексездән,— гаҗәп. Карале син аны, бу дөнья нинди иркен, бу табигать дигәнең күз явын алырдай матур икән ләбаса. Ничек соң мин урманда яшәп шуларны күрмәгәнмен, ишетмәгәнмен?..»

Ул урман юлыннан шундый уйлар белән, һәр нәрсәне беренче тапкыр күргән кеше кебек атлады, ләкин мондый халәте озакка бармады. Мәүләви юлдагы тәгәрмәч чокырында аунап яткан йодрык кадәрле соры нәрсәне күреп алды. Билгеле, элек ул мондый нәрсәләргә игътибар итмәгән дә булыр иде. Әмма бүген... бүген Мәүләви чокыр янына чүгәләп басты да әлеге йодрык кадәрле нәрсәне йөгәннең авызлык тимере белән тартып әйләндерде. Бохар мәчесенең нәни бер баласы иде бу. Шунда гына Мәүләви төнге саташу вакытында мәчесенең өзгәләнеп кычкырган тавышын ишеткәндәй булды. «Төн карчыгасы харап иткәндер моны»,— дип уйлап алды җан иясенең чукып тишелгән канлы маңгаена карап. Һәм... шул ук мизгелдә төнге вакыйгалар тагын күз алдыннан өерләре белән үтеп киткәндәй булды. Ул да түгел, колак төбендә төнге Тавыш һәм аның таләбе яңгырады шикелле.

Авылга иртәнге ун тулып узганда, җир сурыккач, йөзеннән каны качып кәфен төсенә кергән, күз кабаклары салынып-салынып төшкән хәлдә кайтып керде Мәүләви. Алашасын урыс капкага терәп туктатты да үрәчәле арбадан төшеп җилкапканы ачты. Карчыгы Кәрамия (үнөч яшькә яшьрәк булуына карамастан, Мәүләви янында байтакны кичергән, шуңа күрә яшь аралары беленми диярлек), ләкин әле ярыйсы гына таза хатын, җиз комганын тотып бакча ягыннан кереп килә иде.

Мәүләви ләм-мим сыңар сүз дәшмәде, тутыгып беткән иске кендек белән капканың бер ягын терәтеп куйды.

Кәрамия иренең төкселәнгән, агарынган йөзен, килделе-киттелерәк кыяфәтен күрүгә пошаманга төште. «Йә, ходай, тагын нәрсә булды икән инде моңа, алай-болай умарталарга тимәгәннәрдер бит?»— дип борчыла башлады. Ләкин арбадагы ак бидоннар тирәсендә очып йөргән бал кортларын күргәч, борчылуы басыла төште.

— Ни булды сиңа, этисе, нишләп болай ни иртә, ни кич дигәндәй, кайтырга булдың? Самавыр да сүнгән, казаным да асмаган бит әле,— дип, арбаның әле бер, әле икенче ягына чыгып бөтерелде.

— Пычагым булсынмы?— диде Мәүләви тәмам карлыккан, югалган тавышын бар итәргә тырышыбрак.— Тик тор, дим, мур кыргыры! Печән эчендә йөреп тә ашап туймадыңмы?— Алаша, тезмәдәге печәнгә үрелеп, кипкән үләнне авыз итәргә чамалап тора иде.— Йә, син нәрсә терәлдең, бар, чәеңне кара...

Шуны гына көткән диярсең, Кәрамия, аягындагы иске галошларын салырга да онытып, өйалдына кереп югалды.

Мәүләви ашыкмыйча гына алашасын тугарды. Аннары бал тутырылган сөт бидоннарын берәм-берәм кырыйгарак тартып китерде дә, әллә ни көчәнмичә генә, корсагы белән булыша-булыша келәт болдырына илтергә керешге.

«Быел бал ярыйсы ук булды, менә икенче тапкыр аерттым инде. Шикәр комы кушып бутагач... алтышар сумга сатсам да»...— дип уйлап бетерергә өлгерми калды, шыгырдар-шыгырдамас кына жил капка ачыла башлаганны ишетеп, бал исе аңкыган бидоннар өстенә ат япмасын ташлады. «Тагын кайсы йөри икән?»— дип капкадан кереп килүчегә төбәлде.

Гөлшәрифә икән...

Төп-төгәл хәтерли, егерме тугызынчы елның җәендә беренче тапкыр күрде Мәүләви Гөлшәрифәне. Авылдагы апасы янына утырмага килгәч күрде һәм... шул ук көнне Гөлшәрифәнең утыз яшьләр тирәсендәге сазаган кыз икәнлеген белеп алды. Кәрамия белән ун елга якын яшәп, инде өч балалары булуга да карамастан, Гөлшәрифәгә күз атып йөри, юк-бар сәбәпләр табып ул килгән йорт тирәсендә әйләнгәли башлады һәм, хәтта Гөлшәрифәнең апасын очратып, «тау хәтле бүләк» вәгъдә итеп, бер генә тапкыр күрештерүен сорады.

— Кит аннан, Мәүләви, хатының, бала-чагаларың булганны белгән килеш ничек мин үз сеңлемне синең белән күрештерим ди?

— Ни бит, Гөлшакирә, мин бит соң... теге ни, хатыным ни бит минем... Бер күрешкәннән сеңелеңнең укасы коелмас әле, коеласы коелган бит аның,— диде Мәүләви «мескенлеген» бик тиз онытып, күзләрен усал ялтыратып.— Кара аны, Гөлшакирә, кирәгем чыкмыйча калмас әле...

— Янама, яме, Мәүләви. Андый вакытлар узган хәзер...

Соңрак, еллар узгач, Гөлшакирә дүрт баласы белән сугышның башында ук тол калгач та бер генә тапкыр да «кирәге» чыкмады Мәүләвинең...

Шул араларда гына авылга кайткан зимагур Шәкүрҗан утырмадагы Гөлшәрифәне ябыштырып чыгарды.

Мәүләвинең авыл советында секретарь чагы иде, Шәкүрҗан белән Гөлшәрифә язылышу кәгазе алырга дип килеп кергәч тә нишләргә белмәде. Шулай да, үз ирегендәге кеше түгел, рәис агай кушкач, тиешле кәгазьне бик пөхтәләп язып бирергә тырышты.

«Туктале, зимагур,— дип уйлады ул эченнән генә,— кайчан да булса бер эләгерсең минем кулга, бу юлы инде теге вакыттагы кебек калдырмам...»

* * *

...Мәүләвинең атасы Риян агай, авылның бай кешеләреннән саналмаса да, ярыйсы гына таза хәлле иде һәм Мәүләви дә, авылның шыр ярлы егетләре янында түгел, күбрәк үзеннән баерак тормышлылар ягына елыша төште. Мәүләви зимагурлыктан башы чыкмаган Шәкүрҗан белән аралашмады. Чөнки тегесе әле шахтага, әле Урал ягындагы заводларга китеп йөри, авылга да кайтып киткәли генә иде.

Революциядән соң булды бу хәл.

Көннәрнең берендә авылга баштанаяк коралланган ак чехлар отряды килеп керде. Баштарак шомланып калган авыл кешеләре, чехлар андый-мондый усаллык күрсәтмәгәч, беркадәр тын алдылар. Хәтта кыюраклары чит халыкның өелешеп авыл буйлап йомырка, ипи һәм күрше авыл чувашларыннан дуңгыз салосы җыеп йөргәннәрен күзәтергә дә чыктылар. Ак чехлар командиры һәм аның белән унбишләп кеше Риян

абзыйның яңарак салган йортына кереп урнашканнар иде, аш-су әзерләүне, дөресрәге, дуңгыз салосын йомырка белән кыздыруны да хуҗа хатынга йөкләделәр. Мәүләвинең әнисе киреләнмәкче, «савыт-саба пычратып» димәкче иде, кая ул? Мәүләви аларның кәеф-сафа коруларын келәт чормасына яшеренгән җиреннән, үзе әмәлләгән ярыктан күзәтеп ятты. Акларның кыланышлары, кием-салымнары, елгыр атлары, ишегалдына өчаяк-өчаяк ясап куйган мылтыклары, җиргә кадаган озын-озын сөңгеләре Мәүләвине аз гына да куркытмады, киресенчә, күңеленә ярыйсы гына хуш килде. Шундагы үз иш егетләре сыман күкрәк киереп, кәеф-сафа корып, рәхәтләнеп йөриселәре килеп китте Мәүләвинең. Ни генә әйтсәң дә этисе гаять коры, тоткан җиреннән кырт өзә, әйткән сүзеннән чыксаң, җиткән егет дип тормаучан иде. «Авылга кызыллар да, ниһаять, аклар да килде,— дип уйлады келәт чормасында качып ятучы Мәүләви,— ләкин бер-берсеннән ни белән, кай яклары белән аерылалар соң алар? Тегеләр дә, болары да безгә бер генә зыян-зарар китермәде, шулай булгач, безгә кайсы влач та бер түгелме? Ярый әле, Зыятдин малайлары Сәхиб белән Әгъләм һәм зимагур Шәкүрҗаннар камсамулга тупланып, ызба-читәлнә оештыра башлагач та, кайберәүләр кебек, алар янына ашыкмадым...»

Мәүләви үзенең ялгышмавыннан бик канәгать булып ятты. Чөнки замана болганчык иде, кызыллар килде, аларны аклар куды, хәзер әнә тагын кызыллар чигенде, ак чех дигәннәре килеп тулды. Хәер, Мәүләви күреп ята: әлегә алар камсамулларга да тимиләр, бары тик кәеф-сафа кору белән мәшгуль...

Мәүләви, нәтиҗәне чыгаруын чыгарса да, поскан җиреннән төшәргә ашыкмады, аны нәрсәдер тотып тора иде. Шул вакыт, ак чехлар мәҗлесенең кызып җиткән бер мәлендә, тыкрык ягыннан нииндидер шау-шу ишетелде. Ул да түгел, шау-шу артыннан кемнәрнеңдер кычкырышканы килеп җитте. Мәүләви тыкрык ягындагы ярыкка капланды. Тыкрыкка күз ташлауга, мәчеткә йөргәндә генә кия торган яшел төстәге чапаннар киеп алган Шәрифулла һәм Ногман байларның ярсудан кызарынган йөзләрен күрде. Алар артыннан ук чехлар утырган төшкә таба куллары бәйләүле өч-дүрт кешене этеп-төртеп китерделәр. Тырышыбрак караса, ни күрсен: камсамул Сәхиб белән Әгъләм, аларга иптәшкәдер инде, яшьләрне котыртып йөрүчеләрдән Шәкүрҗан белән Нуретдин да шунда булып чыкты. Дүртесенең дә бит-башлары канга буялып, күлмәкләре ертылып беткән иде.

Нәрсә эшләгәнен үзе дә аңлап бетермәстән, этисенең: «Таш яуса да чыгып күренәсе булма!»— дигән кисәтүен онытып, баскычтан төште дә «кызык» карарга барып басты Мәүләви.

Шәрифулла белән Ногман байның чиртсәң каны чыгардай йөзләре мондый киеренкелектән тагын да кызарына төшкән, шуңа күрә алар гадәттәгедән бик яман усал күренәләр иде. Бигрәк тә Шәрифулла бай тузына, Мәүләви уенча, әлегә кадәр бер генә ярамый торган эш тә кылмаган камсамулларның «бозыклыгы» турында тузга язмаганнарны сөйли иде.

Башта Мәүләви авызын ачып тыңлап кына торды. Әмма Шәрифулла бай: «Алар бит әле иртәгә мәчет манарасын кисәргә җыенганнар иде»,— дигәч тә, берничә кеше егетләрне юл тузанына егып кыйный башлагач, нииндидер бер коткыга бирелеп: «Әһә, сез әле мәчет манарасын кисәргә йөрисезмени?» — дип, Шәрифулла бай сүзен кабатлый-кабатлый, авылдашларына бер-икене типкәләп алды. Кызулык белән типсә типсен иде инде, ләкин тизрәк үз урынына ычкынасы булган аңа. Тик күрәчәк дигән нәрсә якаңнан бер эләктереп алса, котылырмын димә икән.

Мәҗлестә ярыйсы гына кәефләнгән, чехлар белән килгән татар эфисәре:

— Камсамулларны болай гына, кыйнап кына үтерсәгез — бик җи-

көл котылачаклар бит. Аларның безгә бирәр файдасы тимәсме? Без алардан яхшылап сораштырыйк әле,— дип кулындагы алтатарын күккә төзеп атып җибәрде.

Кыйнаучылар да, кыйналучылар да урыннарында тынып калдылар. Ә теге татар эфисәре:

— Хәзер үк бу камсамулларны каравыл өенә илтеп ябыгыз,— дип боерды.— Карагыз аны, кыйнап үтерәсе булмагыз, өлгерерсез.

Шәрифулла бай, бу хәлгә бик үк канәгать булмаса да, кораллы эфисәргә буйсынды, кыйнауны туктаттылар.

Эфисәр кулындагы алтатары белән берничә егетнең күкрәгенә төртә-төртә:

— Менә син, син, син һәм... син,— дип Мәүләвинең алдында ук туктап калды, бераз аның күзләренә карап торды.— Менә син командирлары булырсың боларның. Гаскәриләр итеп алынганга санагыз үзегезне... Большевик иярченнәрен саклыйсыз хәзергә. Аңладыгызмы? Вон...

Мәүләви ни әйтергә белмәде, төркемдәгеләр арасыннан атасын эзләде. Ләкин атасының йөзенә чыккан ачуын күреп, чормадан төшкәне өчен эләгәсен чамалады.

Хәер, баштагы мәлне ул үзенең чехларга кушылуының бөтен мәгънәсен төшенеп тә җитмәде. «Боларны иртәгә кадәр качырмыйча саклыйбыз да, аннары өйләргә таралабыз»,— дип иптәшләре каршында белдекле булырга тырышты.

Төн үзәге таңга таба авышып, җир өстендәге караңгылык тагын да куера төшкән бер мәлне, каравыл өенең ишегеn кага башладылар. Камсамулларның куллары бәйләүле икәнлеген яхшы белгән Мәүләви, гадәтенчә, аны-моны уйлап баш авырттырып тормыйча, ишектәге терәүне читкәрәк алып куйды да әчкә атлады...

Һәм шул ук мизгелдә таза-нык куллар тозагына кабуын тойды. Йөрәге «жу» итеп китте Мәүләвинең, камсамуллар шулай ук усал булырлар дип башына да китермәгән иде ул, шуңа күрә ирексездән: «Өрәк!» — дигән уй башына сызылып керде.

Аңышуын тиз аңышты Мәүләви, ләкин соң иде. Колак төбендә генә Шәкүрҗан зимагурның:

— Эшең бетте, кодагый. Әйдә, Мәүләви, урманга качабыз. Үзебезнең партизан отрядын оештырабыз да чехларның тетмәләрен тетәбез, малай,— дип пышылдабрак үзенә дәшкәнен ишетте.

Ул арада камсамуллардан берсе, Нуретдин дигәне, печәнле арбада йоклап ятучы, ирексездән гаскәри булып чехларга кушылып китә язган авыл егетләрен уятып, хәлне аңлатып өлгергән иде. Авылдашларының күбесең, чехларга кушылып китәсе килмәгәндер, ни әйтсәң дә үзләренең урманы, шунда партизан булырга ризалаштылар.

Мәүләви дә ишегалдына чыкты, дөресрәге, Шәкүрҗан алып чыкты. Аңа соңгы тапкыр:

— Йә, Мәүләви, безнең белән китәсеңме, әллә без сине үз итеп кенә, күпме вакыт саклап тордың бит, тукмап алыйк та, чехлар маңгаеңа пуля кундырмасын өчен аяк-кулларыңны бәйләп калдырыйкмы? — диде.

Ул көч-хәлгә:

— Бул... мый суң, егетләр... Урманга китсәм, әти үтерер... Бәйләгез, зинһар... Сезнең эзегез суынганчы тыным да чыкмас,— дип ялына-ялвара башлады.

Авылдашлары Мәүләвигә ышанып ук бетмиләр иде бугай, кычкырыр-нитәр нияте булса дип, авыз-борынын канга буяп кына түгел, авызына сасы мунчала тутырып, шуның өстәвенә каравыл өенә кертеп, ишекне яхшылап терәүләгәч кенә урманга, ак чехларга каршы көрәшергә киттеләр.

Җәйге төн кыска була, ул арада авыл артындагы таллар, аннан арырак җәйрәп яткан Кәрәкә күленең өсте таң алдының тылсымлы

пәрдәсенә уралып-уралып калган иде инде, шуңа күрә иртәнге салкынлык озын-озак тоткарланмыйча, җылы нурларга кушылып, таралып та бетте. Куркуыннан, егетләрнең үз итеп кенә тукмавыннан, иң кыены — авызындагы сасы мунчаладан арына алмыйча азапланудан аптыраган Мәүләви: «Кайчан гына берәрсе килеп чыгар икән, эти генә булса күрмәсен иде»,— дип ята-ята каравыл өенең тәмам яктыруын да абайламыйча калган иде.

Ак чехлар, алардан битәр теге татар әфисәре нишләткән булыр иде үзен, әйтүе кыен, тик Мәүләвинең баярак ычкына язган бәхете кошы яңадан каравыл өе янына килеп кунды. Янгын каланчасындагы күзәтчеләр Искеавыл урманына таба күрсәтеп нидер кычкырыша башлады. Алай да теге татар әфисәре Мәүләвинең янбызына тибеп, сыңар кабыргасын сындырырга өлгерде.

— Бәхетең, селәгәй, кызыллар килә, югыйсә җелегеңне корытасы идем. Большевик иярченнәрен ничек качырганыңны сөйләткән булыр идем... Артык шатланма, озакламый әйләнеп килербез, исеңә төшерермен әле,— дип аты янына ашыкты.

Бәхеткә каршы, Мәүләвиләр авылына аклар бүтән кермәде, шул качудан эзләре суынды.

Урманга качып өлгергән егетләр кызылларга тап булганнар, аларга кушылганнар иде. Авылга кайтып ата-аналары белән саубуллаштылар да акларны куа киттеләр.

Сәхиб белән Әгъләм, егерменче еллар ахырында кайтсалар да, авылда озын-озак тормыйча Чистайга укырга киттеләр. Шәкүрҗан белән Нуретдин кызылармеец булып җир читендәге Байкалга, аннары Кырымга барып Фрунзе кул астында сугышып йөргәннәр. Аннары тагын шул шахталарына төшеп бәхетләрен җир астыннан эзләп караганнар. Сирәк-сирәк авылга кайткаладылар кайтуын, әмма Мәүләви алар белән очрашырга атлыгып тормады, тегеләр дә Мәүләвине сагынып килмәделәр. Беренче тапкыр Мәүләви, күп еллар үткәч, авыл советында секретарь булып утырганда, Шәкүрҗан белән йөзгә-йөз очрашты.

— Теге вакытта чехлардан котылырга нык ярдәм иттең син безгә, Мәүләви туган,— диде Шәкүрҗан язылышу кәгазен кесәсенә тыга-тыга, күзләрен хәйләкәр ялтыратып, кәнсәләрдәге кешеләр дә ишетерлек итеп:

— Турысын әйтсәк, малай Мәүләви, безнең эшләр шәптән түгел, хөрти иде ул чагында... Ярый әле син туры килдең...

Мәүләвинең өстенә салкын су сиптеләр диярсең. Ул: «Шәкүрҗан тагын ни әйтер, минем куркаклыкны ачып салмасмы?» — дип шиккә төшә башлаган иде, юкка гына борчылган икән. Шәкүрҗан аның белән бүтән сөйләшеп тормады, саубуллашты да юлында булды. Хәер, Шәкүрҗан авылда даими яшәп калган булса, бер чишелмәсә икенчесендә чишелер иде сер капчыгының авызы, очып-очып чыгар иде Мәүләвинең «егетлеге». Әмма зимагурлыкка күнеккән Шәкүрҗан яшь хатынын ияртеп тагын Урал ягына китеп барды. Мәүләви аңа кирәкле кәгазьләрне, гадәтенчә, сузмыйча, бер килүдә тутырып бирде...

Шуннан соң дистә ярымга якын ел узды да китте. Мәүләви ул елларда утырган урынында ярыйсы гына ныгыды, районнан килүчеләрне кунарга еш-еш алып кайткалады, дөрес сүзләр сөйләргә шомарды, авылдашлары алдында үзен күрсәтә белде, ышанычка да иреште. Шуңа карамастан, секретарьлыктан уза алмады. Әйтерсең, кемнеңдер нык кулы аның чабуыннан тотып тора, алга таба, югарырак урынга җибәрми тота иде.

Ниһаять, сугыш... Өрлектәй ир-егетләр, авылның тоткасы булып яшәгән аталар һәм аларның уллары санаулы көннәр арасында ут эченә киттеләр дә бардылар.

Сугышка ярамаган гарип-горәбәдән тыш дүрт-биш кеше калды калуын, ләкин аларның калуларыннан калмаулары хәерлерәк иде. Ни-

хәл итмәк кирәк, сугыш ул һәрвакыт ир-егетләрнең иң яхшысын, ышанычлы һәм куркусызларын алып китәргә ярата торган нәмәрсә...

Мәүләвине кайчан да булса авыл советы рәисе, аннары колхоз җитәкчесе итеп куярлар идеме-юкмы, ләкин ул бермәлне авылда иң ышанычлы, эшкә яраклы бердәнбер кеше булып калды. Дөрес, сугыш башланган көнне үк аны авыл советы янында, билен кузгатып, арт саны белән егылган җиреннән ат арбасына салып кайтардылар һәм шул көннән соң ул бөкрәебрәк, таза тамыр таякка таянып эшкә килде. «Бер утыргач утырам, үземнең эшләремне караштыра алам»,— диде ул рәискә. Эш житәрлек иде, куяр кешесе дә булмагач, калдырдылар. Соңрак, Мәскәү янындагы җиңүле һөҗүмнәрдән соң, Мәүләвинең хәле бераз яхшыра төште, биле ярыйсы гына турайды, ләкин таягын ташламады, электәгедәй хәленә дә кайтмады, таякка таянып, бөкресен чыгарыбрак йөри бирде... Кырык бишенче елның көзенә кадәр шулай яшәде ул. Аннары Мәүләви Казанга больницага китте һәм өч атна дигәндә элеккегедәй төп-төз ир-ат булып кайтып төште.

* * *

Ярый, укучы гафу итсен, төп сүздән ераграк тайпылганбыз икән. Без бит Мәүләви агайны урманнан кайтып атын тугарган, бал бидоннарын бушатып торган хәлендәрәк ишегалдында калдырган һәм Гөлшәрифә карчык турында сөйли башлаган идек, шунда кайтыйк әле.

Гөлшәрифә кайнар йөрәкле, кулында ут уйната торган хатын иде. Мәүләви аны кабат кырык өченең җәендә ике баласын ияртеп, унбишкөнлеген биләүсәләп куенына кыскан хәлдә авылга кайткан көнне күрде. Күрде һәм таң калды... Кырык бишне яңа гына тутырган бу хатын тазалыгы, йөреш-килбәте белән дә җимешле алмагач кебек үзенә тартып тора иде. Аның эштә янып-кабынып китүен, күңеленнән рухи матурлык, сәламәтлек бөркеп торган чагын күрсәң: «Бу бит утыз тирәләрендә генә, җанга ятып, иркәләү-назлауның барлык серләрен яңа гына ачып җиткергән»,— дип уйламый мөмкин түгел.

Мәүләви нәкъ шулай уйлады һәм: «Ярый, минем кулга төшмичә калмас, сәбәбе чыгар, вакыты килер әле»,— дип күңеленә беркетеп куйды.

Гөлшәрифә авылга кырык өченче елның уттай кызу җәендә, июньнең егермеләре тирәсендә кайтып төште. Иренең әнисе, туксанның өске ягыннан баручы Гатифә карчык аларны бусагасыннан атлатмады, якын да җибәрмәде...

— Болай да ашарыбызга сыңар бер телем калмады, ачка үләр хәл юк, өстебезгә тагын дүрт кашык ала алмыйбыз,— дип кырт кисте.

Юк, Гөлшәрифә кебек хатын барыбер югалып калмады. Өч көн дигәндә үз куллары белән ташландык өйләренең мичен көйләп морҗасын чыгарды. Күршедәге чуваш авылына барып дүрт тәрәзәлек пыяла алып кайтты да үзе үк аларның берсеннән-бер уч төбе кадәр китек калдырмыйча күзен-күзгә кисеп куйды. Күршеләренең моңа исләре китте. Дүртенче көнне зуррак ике баласын шушы өендә калдырып станциягә китте һәм бишенче көнне ике олау әйберен төяп кайтып керде, өенең тәрәзәләренә ап-ак пәрдәләр элде, түрдәге иске сәкене җыештырып, чаршаулы бүлмәгә әвереләдерде. Балаларның моңарчы боегыбрак торган йөзләре, таныш әйберләрне күргәч, ачылып китте, көлү-шаяру тавышлары ишетелгәли башлады.

Шул ук кичне, караңгы төшеп килгәндә, Гөлшәрифә Мәүләвиләргә килеп керде, хәл-әхвәл сорашкач та рәисне (кырык беренче елның көзендә үк, бүтән кеше булмаганга күрә, Мәүләвине авыл советы рәисе итеп куйганнар иде) олы якка дәшеп чыгарды.

Кәрамия бу хәлгә телсез калды, кулындагы чәйнеген идәнгә төшереп ватты... Тагын унбиш-егерме минуттан Мәүләви хәтле Мәүләви keләтеннән үз куллары белән биш пот бодай оны үлчәп Гөлшәрифәнең кечкенә арбасына чыгарып салгач та... өянәге тотып кече як идәненә сыгылып төште.

Тагын биш минуттан Мәүләвинең кулында биш пот түгел, унбиш пот он бәрабәренә торырлык затлы күн пальто күргәч кенә аңына килде... Шәкүрҗанның ике-өч тапкыр киеп карарга гына өлгергән кыйммәтле пальтосы иде ул.

* * *

Шулай итеп, кайтуына атна-ун көн тулган көнне Гөлшәрифә авыл хатыннары белән утауга төшкән иде инде.

Мәүләви бу хатынның булдыклылыгын, үз дигәненә ирешә белүен, эшкә дигәндә кулында ут уйнатуын күрде һәм ничек кенә булса да күңелендәге кылларын тарткалап карарга уйлады. Эзләгән кешегә җае да бик озак көттермәде, аяк астыннан диярлек килде дә чыкты.

Сугышка кадәр тимер-томыр җыеп, вак-төяк белән әвеш-тәвеш китереп йөрүче, бертуктаусыз колагы шешеп йөдәткәнгә күрә ничә каралса да «яраксыз» дип табылган кибетче Кандала Зәйдулласы белән төн урталарына кадәр тамак чылатып утырган Мәүләви, абынасөртенә кайтып барганда, Күмәк юлыннан авылга таба утларын яктыртып килгән машинаны күрде. «Нинди машина булыр бу, нишләп йөри?» — дигән уй Мәүләвине янгын сүндерүчеләр йортына ышыкланырга мәҗбүр итте.

Шофер да, Гөлшәрифә дә яшеренеп эшләмиләр иде, алып кайткан утыннарын да яшереп-нитеп тормыйча урамда калдырдылар. Мәүләви аңлады: күрше авыл урманында тимер юл кирәк-ярагына дип киселгән агачларны станциягә ташучылар машинасы иде ул. Мондый утынны каян гына алганнар, сораганнармы-юкмы? Өелеп яткан агачларны никадәр генә караштырса да, агачлардан тимер юлчылар келәймәсен таба алмады Мәүләви. Шулай да... сынап карарга, форсаттан файдаланып Гөлшәрифәнең күңел кылларын чиртергә, һич булмаса хатынның күңеленә шом салырга булды рәис.

Иртәгесен, көтү белән бергә, авыл советына китте Мәүләви һәм, гадәттә йөри торган урамын узып, тыкрыкка керде, шуннан соң гына Гөлшәрифәләр турына килеп чыкты, беренче тапкыр күргән кеше кебек, сузып кына сызгырып куйды.

Гөлшәрифә ишегалдында йөри икән, авыл советы рәисенең утын янында басып торуын күреп, шунда чыкты. Капка ачып торасы юк, чөнки бу хатын капкасын ясатып өлгермәгән иде әле.

Урамда бүтән кеше-кара күренмәде.

Мәүләви, арт санын сузарга онытмыйча, ләкин өлгер адымнар белән Гөлшәрифәнең янәшәсенә үк килеп басты.

— Син, Гөлшәрифә, карап-карап торам да, кеше урманга барырга ат таба алмаган бер вакытта машина белән китертәсең утынны,— диде муенын ата каз кебек суза төшеп.— Урланган утындыр инде бу... Сугыш вакытында, кәнишне, моның өчен, район белеп алса... рәхмәт әйтмәсләр...

Гөлшәрифәнең каушаганы күренмәде.

— Мин, Мәүләви абзый...

Авыл советы рәисе аны шундук бүлдерде:

— Мин сиңа нинди абзый булыйм, абзый түгел мин сиңа...

— Ярый алайса, Мәүләви генә диярмен... Миңа утын кирәкмиме? Балаларга аш-су пешерергә, ишегалды тирәләрен беркадәр кешенеке шикелле итәргә кирәктер ләбаса...

— Шулаен шулай да соң,— дип сузды Мәүләви,— барыбер, ничек

инде ул, кеше урманга барырга ат табалмыйча йөргән бер вакытта... машина кадәр машина белән утын китереп аударырга, ай-һай...

Гөлшәрифә аны-моны дәшмәде, Мәүләви дә: «Рөхсәтең бармы?» — дип сорамады, ничек килгән булса шулай, арт санын сузыбрак авыл советы ягына таба китеп барды.

Кичкырын, караңгы төшеп беткәч кенә, Гөлшәрифәнең тәмам йөрәген алырга, куркытырга һәм җае чыкса, үз дигәненә ирешергә уйлап, ахирәте Кандала Зәйдулласына керде. Беравыктан алар икәү чыктылар да, анда-монда борылып тормыйча, Гөлшәрифә ишегалдына барып керделәр, хатынны чакырып чыгардылар.

— Менә, Гөлшәрифә канәт,— диде Мәүләви бик житди кыяфәтле булырга тырышып,— әйттем бит, районга ишетелсә дип... Милитсе нәчәлниге үзе, ишетәсеңме, үзе чылтыратты. «Син нәрсә, Мәүләви, ди, дәүләт утынын урлатып ятасың анда, ди. Штубы тикшергән, актын язып, каракны иртәгә алдыма бастырган бул, ди... Акты язарга, бу утынны авыл советына алырга туры килә инде...

Гөлшәрифәнең кемлеген, зирәклеген һәм тормышны ярыйсы гына күргән хатын икәнлеген чамалый алмаган иде шул Мәүләви. Югыйсә бераз аптырабрак калган Гөлшәрифәгә карап: «Калтырап төште бу, куркыттым мин моны»,— дип уйламас һәм:

— Әгәр дә... ни... балаларың йоклагандыр инде... риза булсаң... Шуның белән эшне бетерербез...— дип үзенең йөгәнсез ниятен ачып салмас иде.

Мәүләви тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, тик өлгерә алмыйча калды. Әллә кайсы арада кулындагы әзер акт Гөлшәрифә кулына күчте! Хәер, ул гына булса ярар иде дә... Мәүләвинең күз карасы кебек саклап йөрткән кыр сумкасы, аның белән бергә авыл советы мөһере, һәм... берничә хатын-кызны сугыш ягына окоп казу эшләренә җибәрмичә калдырырга дип исемнәре тутырылган белешмә (тагын кеше күзенә күрсәтергә ярамый торган ялган кәгазьләр дә бар иде) Гөлшәрифә кулына күчте. Аннары сумка, мәче койрыгыдай каешларын уйнатып, хатынның күлмәк изүенә кереп тә югалды...

— Әгәр дә кагыласы булсагыз, кабахәтләр,— диде Гөлшәрифә ачулы күзләрен яндырып.— Иртәгә синең бу сумкаң районадагы тиешле кешеләр алдында булыр... Иремнең фронтта сугышып йөрүен, аның нинди орган вәкиле икәнлеген аңлатырлар анда синең томана башыңа...

Мәүләви коелды да төште, чөнки ул сумкасындагы ялган белешмәязуларның үзенә үк тозак буласын белә иде.

— Рөхсәтең бармы? Каян һәм ничек алдың бу утынны? дип сорыйлар аны, пред-се-да-тель! — диде Гөлшәрифә мыскыллабрак һәм тораташтай каткан Мәүләви белән Кандала Зәйдулласына усал караш ташлады, ир-атныкыдай йодрыгын селтәп алды да өенә кереп югалды.

Бераздан аңнарына килеп, тегеләр нихәтле генә тырышсалар да, Гөлшәрифә алар янына чыкмады, ишеген ачмады.

— Оятсызлар, җирбитләр, фронтовик хатынын ничек мәсхәрәләргә икәнлеген күрсәтәм әле мин сезгә! Болай булгач, яхшы чакта күземнән югалмасагыз, хәзер үк чыгып бөтен авылны күтәрәм,— дигәч кенә әзләре суынды, тавыш-тыннары бетте.

Кандала Зәйдулласы нишләгәндер, әмма Мәүләвинең төн йокылары качты ул чакта...

* * *

Соңгы елларда «Гөлшәрифә абыстай» дип, төче телләнеп яшәргә ярата башлаган Мәүләви капкадан килеп керүче карчыкны күргә әнә шушы хатирәләрне бүгенгедәй итеп күз алдыннан уздырды. Гомеренең ахырына таба барган саен кайчандыр усаллыгы тигән, рән-

жетелгән кешеләр янына барасын, алардан бәхиллек сорарга туры киләчәген ныграк чамалый иде ул. Мәүләвинең җаны, вөҗданы кабер чите якынайган саен ныграк тыпырчына, хуҗасына тынгылык бирми...

Әнә, Мәүләвинең «яхшылыгы» тигән кешеләрнең берсе — Гөлшәрифә карчык килеп тә керде...

Урманнан кайтканда ук кешеләр янында сүзне ничегрәк башларга кирәген чамалап-чамалап караган иде Мәүләви. Хәтта аның аңында, Гөлшәрифә карчыкка башлап барырга кирәк, дигән уй да кузгалып алган иде. Ләкин Гөлшәрифә шулкадәр көтмәгәндә килеп керде ки, тик торганда аның белән узгандагы рәнҗетелүләр турында ничек итеп сүз башларга бит әле?

«Кәрамия өйдә җитмәсә... Аның алдында теге хәлләр турында сөйләшеп буламыни? Абзагыз үз тормышын үзе ашап махмырлаган кеше сыман тәүбә кылып йөри, акылы җиңеләймәгәнме? дия башлар. Аның торма теленә тарысаң...»

Гөлшәрифә инде Мәүләви янына ук, арбаның теге ягына килеп баскан, бал тулы савытларга чекрәеп карап тора иде.

— Ай-һай, Мәүләветдин, быел, мәйтәм, балың бигрәкләр дә мул ахрысы. Елдагыча бәягә булса, миңа да берәр чиләк бирерсең, Мәүләветдин... Кияү кайтырга тора, аларга иде... Акчасын, былтыргыча, үзе кайткач бирер, калдырмас...

«Теленә тилчә чыккыры! — дип, Мәүләви эченнән генә әтисе белән бертуган Кәшиф агай малаеның малаен искә төшерде.— Ул малай актыгына да заманында бик нык каныгып йөргән идем түгелме соң? Әйе, булды бугай шул, булды. Берничә мәртәбә генә дә түгел, гомерлеккә кыерсытты бугай ул малайны Мәүләветдин агасы».

* * *

Әтисе сугышта иде аның. Хәер, аңа хәтле үк армиядә командир иде бугай. Сугыш башланып үзе фронтка алынгач та, хатынын бәләкәй малае белән авылга кайтарып җибәрде. Дөрес, хатыны безнең якныкы түгел түгелен, исеме дә хәзергәчә ишетелмәгән — Сагыну иде аның. Исләрне китәрерлек чибәр иде, каһәр суккыры! Аннары бит әле Мәскәү хәтле Мәскәүнең үзендә хезмәт иткән, авылдан китеп командир булган кешенең хатынына күтәрелеп карау, аңа күз сирпеп тел тидерү үзе дә бер горурлык... Шулай уйланды ул вакытта Мәүләветдин. Ул вакытта акча җыючы агент кирәк иде, каян башына килгәндер Мәүләвинең: «Эшләргә уйламыйсыңмы, хөрмәтле Сагыну,— диде ул елмая төшебрәк.— Син бит кем, Сагыну, минем туганнан туганымның хатыны буласың инде. Әгәр дә мәгәр эшләргә уйласаң, менә бу өстәл буш тора, килерсең дә утырырсың, ямe?»

Шул ук кичне Мәүләви үзенең әлеге тапкырлыгын Кандала Зәйдулласына сөйләп бирде. «Ни әйтер икән бу?» — дип кеткелдәп көлде.

Кандала Зәйдулласы хатын-кыз дигәндә ирлек тамыры нык кеше иде. Мәүләви аның нәфесен белми түгел, белә, хәтта андый юлда бергә-бергә булганнары да бар.

— Шә-әп, Мәүләви, шәп уйлап чыгаргансың син моны, малай,— дигән булды ул күңелендә көнчелек чыпчыгының уяна башлавын тоеп.— Шәп!

Мәүләви шәп уйлап чыгарганын үзе дә аңлый, тик ул бу тапкырлыгының Сагыну дигән хатын алдында көчсез, беркатлы тырышлык икәнлеген генә белми иде әле. Хәер, озак көтәргә туры килмәде аңа, Сагынуның ныклыгын беренче омтылыштан ук татыды. Болай булды: көннәрдән бер көнне аларга ничектер икәүдән-икәү генә күрше авылдагы сельпо җыелышыннан бергә кайтырга туры килде. Алты чакрым җир Мәүләвинең өлгер атына ни тора ул! Ләкин Мәүләви агай

кайтырга ашкынмый иде, шуңа күрә авылдан Болын юлына чыгуга атны үз иркенә куйды, атлатып кына кайта башлады. Үзе сикәлтә саен Сагынуга табарак елышырга тырышты. «Әлбәттә, авылның мокыт хатыннары булса,— дип уйлады ул,— болай ук нәзакәтләнеп тормас идем, атны әнә теге үзәнлектән инеш ярындагы әрәмәлеккә таба борыр идем... Ә анда житкәч инде нишләргә кирәклеген дә белер идем аныйсын... Әллә соң тәвәккәлләп карарга мы?».

Шулай да Мәүләвинең кыюлыгы житеп бетми иде әле. «Ни әйтсәң дә, бу сиңа юк-бар сүзгә карап кына сары май сыман эреп төшмәс, закун-макунны белә, чукынган»,— дип уйлады ул. Әмма барыбер тынычлана алмады, жае чыккан саен сүзне шушы яккарак борырга тырышты.

Хатынның йөзе житди, бераз гына агарынып төшкән иде ул. Мәүләви андый нәрсәләргә игътибар итүне кирәк санамады, дилбегәсен алган булып Сагынуның жилкәсенә кулын салды.

Йә, ходай! Бирсә дә бирер икән бу хатынга тавыш кырыслыгын!

— Мәүләви абзый, хәзер үк ал кулыңны! Моннан соң минем алдаавызыңны ачып теләсә ни сөйлисе булма,— диде Сагыну һәм, сикәлтә жае туры килгәндерме, Мәүләви соңыннан да ни уйларга белмәде, икенче мизгелдә рәис юл читендәге кар өстенә тәгәрәп төште. Ә Сагыну аңа таба әйләнеп кычкырды: — Пычрак ниятең, Мәүләви абзый, шушы юлда коелып калсын, яме. Ерак түгел, нибары ике чакрым ара, жәяү дә кайтып житәрсең...— һәм урталай бөкләнгән дилбегә очы белән атның сыртына кундырды: — Әйдәле, малкай, әй-дәә!..

Шунда Мәүләвинең күңеле беренче мәртәбә сыкрап куйды, ләкин әле ул бу хатынны үз янына эшкә алуына үкенергә өлгермәде. Бу тойгы аңа соңрак, ниятләгәннәре чынга ашмагач килде. Аннары колхоз рәисе Әгъләм булып Әгъләмнең тырышлыгы Сагынуның ныклыгына бәрелеп сынды. Сагыну аларны якын жибәрү генә түгел, һәрберсенә тиешле жавап кайтару жаен да тапты. Иң соңыннан, районнан еш кына килеп йөрүче вәкил агайның да тырышлыгы бушка киткәч кенә... (аларны жаен туры китереп, районнан кайтышлый, Болгана авылында бер фатирга керттеләр һәм үзләре чыгып тайдылар). Ләкин кая ул? Вәкил агай ярты сәгать тә үтмәс борын тунсыз-нисез, оекбаштан килеш күршегә килеп ишек кагарга мәжбүр булды. Чуаннары тулды, түземлекләре бетте Мәүләвиләрнең, Сагынудан үч алу турында уйлый башладылар...

Шулай итеп, кырык дүртенче ел житте...

Ниһаять, жаен таптылар. Дөрес, Мәүләви үзе эшләмәде ул эшне. Авыл советы секретаре Әхмәдулланы котыртты, ә ул инде яшьрәкләр белән сөйләшкән. Тегеләрне, ФЗӨгә жибәрмәскә вәгъдә итеп, Сагыну апаларының шкафыннан заем билетларын урлап чыгарга кушкан. Икенче көнне килсәләр, шкаф ачык, заем билетларыннан жилләр искән... Сагынуның нурлы йөзләре бик тиз каралды, гайрәте сүнде, күзләре дә әллә нишләде... Шул көнне Мәүләви, юк эшен бар итеп, вакытны сузарга тырышты. Сагынуга да ниндидер йомыш табып башкалар белән бергә кайтарып жибәрмәү жаен тапты. Ниһаять, караңгы төште, кеше-кара күренми башлады. Мәүләви жайлап кына сүз башлады:

— Кем, Сагыну канәт, менә бит ничек килеп чыкты. Нишлибез инде? Районга хәбәр итсәк, утыртасыларын көт тә тор. Дәүләт заемнарын югалткан өчен рәхмәт әйтмәсләр...

Сагынуның үз хәле хәл иде, дәшмәде. Мәүләви аның дәшмәвен ямьшы белән килешүгә санады. Моңарчы да шундыйрак алым белән кайгыдан сыгылып төшкән хатыннарның күңеленә юл ачкалаган иде.

— Әй, Сагыну, Сагыну канәт,— диде ул тагын.— Син соң нигә әле шулай каты күңелле булдың? Ирем кайтыр дисеңме? Юк, кайтмый инде ул. Менә, бүген генә районнан жибәрделәр бу хәбәрне...

Сагыну аның янына килде, күзләрен тутырып өстәлдә яткан кәгазьгә карады. Әмма иренең һәлак булуы турында язылган юлларны укырга өлгерә алмады, Мәүләвинең көчле куллары аны биленнән урап тоткан иде.

Мәүләви үзен-үзе белештермичә диярлек:

— Сагыну, теләсәң, әгәр дә теләсәң... валлаһи газыйм, Карамия апагызны аерып җибәрәм. Соң бит... син хәзер тол хатын... Әнә бит, ирең ни... юк бит инде... Минем хатыным булырсың... Алам мин сине, бернигә дә карамыйча алам, валлаһи,— дип тезәргә кереште. Аның куллары Сагынуның күлмәк изүенә үрелә башлаган иде инде. Шушы пычрак кулның салкыны Сагынуны айнытып җибәрде, тетрәндергеч хәбәр аңын томалауга карамастан, ул бар көчен туплап сикереп торды. Ике куллап Мәүләвинең күкрәгенә төртеп җибәрде. Мәүләви артка таба чигенеп барды-барды да аяк астында туры килгән эскәмиягә абынып идәнгә барып төште. Егылган уңайга башы белән имән өстәлнең аягына бәрелде. Күзләреннән бүрек кадәрле ут ялтырап чыкты һәм ул авыртудан күзләрен йомды, аңын югалтты.

Икенче көнне Сагыну эшкә килмәде. Мәүләви башын бәйләгән, сораучыларга: «Кичә төнлә сельсоветтан кайтканда нәрсәгәдер абынып егылдым, башым тишелде»,— дип утырды. Тәрәзәне төнлә үк Кандала Зәйдулласы төзәтеп куйган иде инде. Иртүк авыл советы йортына Сагынуның каенанасы, Мәүләви атасының бертуганы Кәшиф агай хатыны килеп керде.

Бу карчыкны авыл кешеләре ихтирам итәләр, аның турында бер генә начар сүз дә ишеттермиләр иде. Хәер, гомере буена эшләп, унбер бала үстереп, шуларның җидесен сугышка озатып, хәзер инде дүртенчесенең үлеме турында хәбәр алган җитмеш яшьлек карчыкны ни нәрсә өчен яманларга ди соң?

Мәүләви аны күрүгә беркадәр югалып калды. «Яхшыга килмәгән бу, яхшыга түгел»,— дип уйлап өлгерде.

— Син, Мәүләветдин, гомерең буе кешеләргә явызлык кылдың. Сәвит властына нәрсәң белән генә ярыйсыңдыр, монысын мин белмим, әмма улларыбыз фронтта җан коеп сугышып йөргәндәге кыланмышларың өчен... Халыкның күзе яхшы күрә. Бервакыт килеп ходай орыр әле, менә күрерсең,— дия-дия карчык күзләрен яулык очы белән сөртеп-сөртеп алды.— Кая минем улымның кәгазе? Син, Мәүләви, аңа пычрак кулларың белән кагыласы булма. Әнә ул алып бирсен,— дип секретарьга төртеп күрсәтте.

Карчык укый белми иде, ләкин моңарчы өч улына килгән «кара кәгазь»ләрнең дә шундый икәнлеген аңлаудан йөрәгенең кысылып-кысылып куюын сизде һәм бер сүз әйтмичә, хәтта күзләреннән яшь бөртекләре чыгармыйча кичәге эскәмиягә килеп утырды.

Авыл советындагыларның берсе бер сүз әйтмичә аска карап, эш эшләгән булып озак утырдылар...

Ниһаять ана урыныннан торды, баягыдан йомшаграк тавыш белән әйтте:

— Менә монда киленнең шкафыннан урланган заем билетлары. Бүген төнлә кайсыгыздыр болдырдагы мәче йөри торган тишеккә кыстырып киткән... Санап алыгыз,— диде.

Тагын дәшмәделәр. Сагынуның кайдалыгын сораучы булмады. Берәздән Мәүләви секретарь Әхмәдуллага баш какты. «Санап ал!» — дию иде.

Әхмәдулла заемнарны берәмтекләп санады да Мәүләви алдына өстәлгә куйды, аннары тиз-тиз генә нәрсәдер язды һәм аны Сагынуның каенанасына бирде.

Сагыну шул көнне үк, баласын каенанасына калдырып, авылдан чыгып китте. Әгәр шул минутларда аңа кем дә булса берәү: «Син, Сагыну, поездларга ышанып утырып китмә, бер алып киткәч тә кире

кайтармый алар»,— дип акыллы киңәшен биргән булса икән... Андый кеше юк иде шул, кызганычка каршы.

* * *

Гөлшәрифәнең кияү дигәне әнә шушы Сагынуның каенанасына калдырып киткән малае иде. Аты ни атлы иде соң әле? Хафиз иде шикелле.

Шул малай актыгы, үзе бот буйлык кына булса да, гаять чая, үткеннәрнең үткене иде бит. Алты-жиде яшьлек чагы иде бугай, колхоз рәисе Мәүләвинең жанына тиеп, ындыр табагына ияләште бит. Аның хатын-кызларын әйт син, шул малай актыгының килделе-киттеле жырлавын тыңлаган булалар да, чалбар кесәсенә бөртек тутырып жибәрәләр... Тегенә шул гына кирәк: ай күрде, кояш алды — өенә таба йөгерә.

Шулай бер көнне Мәүләви, тарантасына кырын ятып кына, төшке аштан соң сирәк-мирәк тешләре арасына кысылып калган ит кисәкләрен шырпы белән казый-казый ындыр табагына бара. Аның бик гайрәтле, яшь айгырын жигеп йөри башлаган вакыты иде. Ләззәтләнеп кенә барган төштән яшь айгыр корт чаккандай бер читкә сикерде, кыелып кереп тарантасын әйләндереп ташлады. Дөрес, әллә кая китә алмады, ауган тарантасны беркадәр өстерәп барды да туктап калды. Ләкин Мәүләвинең кабыргаларын санап-санап алган, аркасындагы тиресе ярыйсы ук каезлап өлгергән иде.

Егылган ачуданмы, аркасының сызлавыннанмы, Мәүләви тәгәрәгән жиреннән яман бер ачу белән сикереп торды. Туры килүен әйт әле син аны: әлеге малай актыгы, Мәүләви абзасының тәгәрәп төшкәнен, сыкрана-тукрана тарантас астыннан үрмәләп чыкканын карап, авызын тыялмыйча ыржаеп тора. Ә кесәсе... Мәүләви үзен-үзе белештермичә, кулындагы камчысын болгый-болгый малай янына ыргылды. Кызыктан исе киткән малай аны-моны сизеп өлгергәнче, Мәүләви күлмәгеннән эләктереп тә алды тегене. Ир куәте белән килеп тотуга малайның болай да ярыйсы гына сизрәгән күлмәге якасыннан алып итәгенә кадәр аерылды да төште. Мәүләви аның кулын тагын да ныграк кысты. Авыртудан малайның кулбаш сөяге яңгырап куйды, эченә кадәр әллә нинди авырту сызылып төште. Әмма иптәш малайлары Хафизны юкка гына: «Хафиз батыр — дөбер-шатыр»,— дип үртәмиләр иде. Беренче авырту бераз басыла төшүгә ул: «Аһ, син Мәүләви-Шәүләви, арт санын да жәлләми»,— дип үртәшеп кычкырды һәм тешләрен үзен тоткан кулның беләзек турысына батырды.

Кулы авыртудан Мәүләви үзенең кемлеген, әлеге баланың балалыгын онытып, дегеткә манчып йомшартылган камчысын малайның шәрә сыртында биетә башлады.

Мәүләви, малайга беренче тапкыр киерелеп сукканда ук, күз кырые белән генә авылга төшке ашка кайтучы хатыннарның якынлашуларын күреп алган иде. Ләкин бер кызып киткәч тиз генә туктый алмады. Аның кан баскан күзләре малайның арык аркасына чыккан каракучкыл эзләрне, аннары баланың юл тузанына сыгылып төшкәнен дә күрмәде түгел, күрде, әмма туктый алмады...

Бер төркем хатыннарның аһ та ваһ килеп: «Мәүләви абзый, нишләвең бу? Баланы үтерәсең бит... Имансыз, кансыз нәрсә»,— дигәннәрен ишеткәннән соң гына Мәүләвинең аңы бераз ачылгандай итте.

Шул ук мизгелдә аның якасыннан тотып күлмәген урталай аердылар. Аннары ялангач аркасына дистәләгән бал корты берьюлы уклары батыргандай булды. Аның аркасын аркылыга-буйга кемдер камчы белән яра башлады.

Шау-шу арасыннан Мәүләвинең колагына:

— Тукта-а, нишлисең, Зәйтүнә... Утырта бит кабәхәт җан, утырта үзеңне өтермәнгә... Котырган бүре белән бер бит ул... Туктаааа! — дигән сүзләр кереп калды.

— Китмим... Туктамыйм, үтерәм сабакыны! Ни хакы бар аның атасы сугышта үлгән баланы канга батырганчы кыйнарга... Кит-ее-геез, үте-е-рәм сабакыны! — ди иде Зәйтүнә күңелендәге бар ачуларын кулындагы камчыга салып.

Әгәр дә мәгәр шул ук минутта Зәйтүнә кулыннан ычкынмаса, исән җире калмаячагын аңлады Мәүләви. Чөнки Зәйтүнә сугыш башланган елны ук Мәүләвинең кармагына эләгүчеләрнең берсе иде... Һәм Мәүләви, җаен туры китереп, Зәйтүнәнең аягын үз аягына эләктереп кискен генә тартып куйды. Моны көтмәгән Зәйтүнә кизәнгән камчысын болгый-болгый юл читенә чалкан авып төште. Аны шундук хатыннар уратып алды.

Малай янында да берничә хатын-кыз кайнаша, ләкин аның үлеметереме икәнлеге билгесез, малайда җан әсәре сизелми иде.

Мәүләви хатыннар уртасындагы Зәйтүнәнең: «Җибәрегез, җибәәәр!» — дип ыргылып-ыргылып алуын, малайның һаман хәрәкәтсез ятуын карап-карап торды да сабан туенда йөгерүчеләрдән дә арурак тизлектә авыл ягына ыргылды...

* * *

Кәрамия белән Гөлшәрифә болдыр алдына җиргә җәелгән, сапсары итеп юылган юкә такталар өстендә башмакларын салып калдырдылар да өйгә кереп югалдылар. Аркаларына сузылып төшкән чәчәкле яулыклары гына күз алдында уйнаклап калды.

«Бирешергә исәпләре юк әле боларның,— дип көнләште Мәүләви Кәрамия белән Гөлшәрифәгә карап.— Кәрамия инде ярар, миннән байтакка яшьрәк, ачлык-ялангачлыкны күрмәде, гомере буена Мәүләви көен көйләп кенә яшәде. Калхуз эшендә дә ватылмады. Ә менә Гөлшәрифә минем яшьтәге кеше бит. Эшне дә эшләмәде, тормышның төрле якларын да күрмәде түгел, бик күп күрде...»

Теге вакытта Мәүләви һәм аның дус-ишләре «үксез малай» вакыйгасын томалап калдырырга, алай гынамы, колхоз рәисенә кул күтәрде, камчы белән яралап бетерде дип, шаһитлар туплап Зәйтүнәне судка бирергә җыенганнар иде. Бөтен эшне шушы Гөлшәрифә бозды, корт чаккыры нәмәстә... Кем уйлаган аның шулай итәсен, райкомның яңарак килгән беренче секретарена кадәр җитәсен... Хәер, бер тапкыр авызы пешкән Мәүләви башын эшләтеп карарга тиеш булган да бит. Уйлап бетермәве харап итте Мәүләвине. Болай да кылган «яхшылыклары» байтакка җыелган иде бугай. Инде һәлак булган фронтовик баласын канга манчып кыйнавы да өстәлгәч, җитмәсә Зәйтүнәне судка биреп гаепләргә маташуын күргәч, авылдашлары, бигрәк тә фронттан кайтып өлгергән ир-атлар да кузгалгач, Мәүләви урыныннан очты... Ярый әле каты шелтә биреп булса да партиядә калдырдылар. Бергә ашаган дуслары да онытмады, ярыйсы гына төшемле яңа урын табып бирделәр ул чакта...

Мәүләви тегесен-монысын эшләгән булып өйгә кермичә торды, вакытны сузарга тырышты. Бал савытларын да келәткә кертеп урнаштырды. Атына ашарга бирде, ызбруйларын да һәркайсын үз урынына пөхтәләп җыйды. Әтисе аңа һәрвакыт: «Ерак җыйсаң, якыннан алырсың!»— дип өйрәтә иде. Мәүләви ул яктан әтисенә охшады, әйберне җыя белде. Һәркайсының төгәл урынын булдырды. Әгәр дә мәгәр куйган әйбере билгеле төштә булмаса, ул чагында инде өйдәгеләр рәхим-шәфкать көтмәсен, дулапмы-дулый иде Мәүләви. Хәер, соңгы елларда аңа

бу хакта дуларга туры килми, чөнки балалары барысы да читтә урнашып беттеләр, үз ояларын булдырдылар. Кунакка кайткан оныклары бабаларының кырыслыгын беләләр, әйберне кузгатмаска тырышалар иде.

Бакчада сизелеп, күзгә бәрелеп торган тәртип. Бу бакчаны Мәүләви моннан егерме биш еллар элек урман каравылчысы булып эшләгән елларда утыртты. Авылда беренче үк булмаса да, Мәүләви яшәгән очта мондый бакча юк иде әле. Элек моңа исе китми иде: бакча тек бакча, кешедә юк нәрсә миндә бар дип кенә карый иде. Ә бүген... карале. Алмагачлары гына да ничәмә-ничә сортлы икән бит аның. Кайберәүләрнеке кебек, аннан-моннан, урманнан алып кайтып утырткан кыргый алмагачлар түгел инде. Менә монысы бигрәк тә татлы, сусыл алмалар бирә. Мичурин шәһәреннән, урманчылар киңәшмәсенә барган жиреннән алып кайткан иде аны Мәүләви. Үз баласыннан да болайрак тәрбияләп үстерде. Алмаларын гына күр син аның, алмаларын! Дөрес, әле пешеп, өлгереп житмәгәннәр, әмма авыз итәргә, кабып карарга буладыр.

Мәүләви келәт буеннан озын таяк алып килде, алмагачның кояш күбрәк төшә торган ягыннан бер алманы селкетеп сабагыннан өзде. Жиргә төшермичә генә ике куллап үрелеп тотып алмакчы иде, өлгерлеге житеп бетмәде.

Элек булса ул, һичшиксез, тозлап-борычлап сүгенер иде, ә бүген исә үзе дә сизмәстән: «Әй, матурым, менә ничек тулгансың бит син, инде пешә дә башладыңмы? Әйдә, әйдә, тырыш, алмакаем, тырышып пеш. Мәүләви абзаң авыз итәрлек булсын»,— дип сөйләнә-сөйләнә пинжәгенең итәге белән алманы сөрткәләп, теленә тидереп, ялап-ялап карады. Дөрес, хәзер инде ясалма тешләр электәгеләре кебек капкан жирдән умырып тешли алмыйлар, шуңа бераз гарьләнде Мәүләви һәм кесәсеннән чалгы пәкесен чыгарып, алманың кызара башлаган төшеннән кисеп авызына капты. Алмага чынлап та тәм кергән иде. «Кеше дә шушы алма кебек бит инде,— дип уйлады ул яраткан алмагачына әллә нинди, сәер күзләр белән карый-карый,— юктан гына бар була, аннары үсә, матурая, пешеп житә. Хатын-кыз кебек. Аннары кемдер берәү кила дә өзеп ала...»

Мәүләви көлемсерәп куйды. Чөнки бу уй күңеленә хуш килгән иде. Мәүләви хатын-кыз турындагы уеннан канәгать булды. Әйе, бу яктан сынатмады Мәүләви, сынатмады... Дөрес анысы, Гөлшәрифә белән Сагыйну атлылары аның тамагына татлы алма түгел, урманда үскән кыргый алма булып тыгылды тыгылуын... Ләкин, нишлисең бит. Мәүләви булдыра алганын эшләде, булдыра алмаганын юк...

Сугыш башлангач та өзгән беренче «алма» аеруча татлы тәмнәре белән шатландырды аны. Жимешнең сафлыгын белеп, шуңа күрә аерата ләззәтләнеп өзде Мәүләви. Кырык беренче елның көзендә Мәүләви инде ир-ат белергә тиешле барлык серләрнең төбенә төшкән кеше иде, шуңа күрә теге зимагур Шәкүрҗанның сеңелесе Зәйтүнәне тырнагына эләктергәч тә мәчедән ким уйнамады.

Зәйтүнә авыл советында йомышчы булып йөргән атна иде. Мәүләви аның дежурда кунасы төнен көтеп алды. Аның инде планы корылган, уйланасы уйланган булганга, кичкырын эшләрен бетергәндәй итте дә чыгып китте.

Мәүләви төнге әтәчләр кычкырыр алдыннан авыл советы ишеген шакыды. Телефон янында дежур булып калган Зәйтүнә куркулы тавыш белән:

— Кем бар анда? Ни кирәк?..— дип кычкырды.

— Мин бу — Мәүләви абзаң... Ач ишегеңне, йокы капчыгы...

Авыл советы рәисенә ачмый хәлең юк, Зәйтүнә эскәмиягә жәелгән иске сырмаларны тиз генә мич арасындагы сандык өстенә алып ташлады да ашыгып барып ишек келәсен ычкындырды. «Ни булды, Мәү-

ләви абзый, берәр ашыгыч эш чыктымы әллә»,— димәкче иде Зәйтүнә, әмма рәис аңа авызын ачарга ирек бирмәде.

— Син, кем Зәйтүнә канәт, нишләп йоклап ятасың. Сугыш вакыты икәнлеген белмисеңме әллә? Телефон шалтыраса... ишетмичә калсаң?..— диде ярыйсы гына кырыс тавыш белән.— Моның өчен, моның өчен беләсеңме нишләтәләр...

— Соң бит, Мәүләви абзый, бөтенесе дә шулай итәләр. Телефон бит, бакчы, монда гына. Ишетәм мин аны.

— Яп ишекне, төшер киләсен, нәрсә авызыңны ачып каттың.— Бу юлы инде Мәүләвинең тавышы йомшара төшкән иде. Аннары бөтенләй миһербанлыга әйләнде: — Кара аны, бүтән алай итәсе, төнлә телефонны калдырып йоклыйсы булма, яме.

— Белмәдем, Мәүләви абзый, шулай кирәк икәнлеген. Сыңар күземне дә йоммам моннан соң...

— Ярар, шулай итәрсең.

Мәүләви салмак адымнар белән үзенең гадәттәге урынына барып утырды. Куыклы лампаның телен күтәрә төшеп өстәл тартмасыннан ниндидер кәгазь алды һәм утны яңадан бастырыбрак куйды.

— Менәгенәк, Зәйтүнә канәт, сугыш ягына, нығытмалар казырга егерме ике хатын-кыз җибәрергә кирәк дигән кәгазь килгән иде. Шул тынычлык бирми бит әле, кемнәрне җибәрсәң дә жалкы инде. Ирләре сугыштагыларның, үч иткәндәй, итәкләре тулы бала-чага...

Зәйтүнәнең йөрәге дерт итеп куйды: «Әни белән әбине кем карар, мине җибәрсәләр, икесе дә урында ятып диярлек торалар»,— дип уйлап алды ул, ләкин дәшмәде, эскәмиядә утырып торуын белде.

Мәүләви абзый исә бу минутларда йөзенә искиткеч авыр уйлар, кешеләрне чит җирләргә җибәрергә туры килгәнгә гасабилану билгеләре чыгарып, ике кулын чигәләренә куйган килеш Зәйтүнәне күзәтә иде. «Ничек тәэсир итте минем сүзләр моңа, үзен җибәрерләр дигән уй башына кердеме-юкмы?»

— Менә, Зәйтүнә канәт, синең кабек яшь-кыркынны җибәрергә туры килер, ахрысы,— диде ул, ниһаять, һөҗүмне дәвам иттереп.— Илнең башкаласына куркыныч яный. Барыбыз да хәленнән килгәнчә якларга тиеш инде аны...

Зәйтүнә коелып ук төшмәде төшүен, әмма ләкин Мәүләви абзыйның үзен һичшиксез җибәрәчәген аңлап алды.

— Анысы шулай да бит, Мәүләви абзый, мин дә барыр идем, тик менә өйдә ике карчык — берсе дөм сукыр, берсенең аяклары...

— Фашист илбасарлары бөтен җирне кырып-себереп килгән вакытта, Зәйтүнә канәт, андый юк сәбәпне бар итеп булмый,— диде һәм алдындагы кәгазьне үзенә якынрак китереп: — Синең фамилияң ничек йөри соң әле, әтиеңнеке кебекме?

Аңлады Зәйтүнә Мәүләвинең әнисе белән әбисен калдырып сугыш астына җибәрәчәген, аңлады һәм ихтыярсыздан сулкылдап елап җибәрде.

Ә Мәүләвигә шул гына — Зәйтүнәнең ихтыяры йомшарган, күңеле дулкынланган вакыт кирәк иде дә инде. Ул катгый карарга килеп урыныннан чыкты, тырпайган бармакларын кызның җилкәсенә куйды, аның сискәнеп китүен сизде.

— Я, канәт, алай ук бетерешмә, син бит җиткән кыз инде... Барасың килми икән, бармассың. Хәзер барыбер синең кебекләргә ират юк. Әрәм булып ятканчы... Менә мин сине гел авылда гына тотармын. Даими йомышчы булырсың... Яме, ризамы?

Зәйтүнә яшь иде шул әле. Мәүләвинең нәрсә теләгәнен һәм нәрсәгә ризамы диюен төшенеп өлгергәнче әллә нишләп китте, үзе дә сизмәстән иягеп кагып «әйе» дигәндәй аваз чыгарды. Шуны гына көтеп торган Мәүләвинең куллары, корыч кыршау сыман, кызның биленнән эләктереп алды һәм мич артындагы сандыкка җәелгән сырмалар өсте-

нә тәгәрәтте. Зәйтүнәнең бер генә мизгелгә аңы ачылгандай итте. Ул: «Нишлисең, Мәүләви абзый, җибәр»,— диярге тырышып карады. Тик... өлгерә алмады. Мәүләвинең авыр гәүдәсе өстенә капланды да Зәйтүнәнең тынын томалады...



* * *

— Әтисе, әтисе дим, нишләп кермичә йөрисең? Чәй өлгерде бит инде. Гөлшәрифә абыстай көтә,— диде бакча капкасына килеп баскан Кәрамия, иренең үзалдына кулларын болгаштырып кем беләндер сөйләшүенә гаҗәпләнеп.— Әйдә, кер инде...

Мәүләви барыбер ашыкмады, җайлап кына кулларын юды, битләрен сөртте, аннары урманнан кайткан арада җәй көннәрендә үзе йоклый торган верандага кереп өс-башын алыштырды һәм шуннан соң гына «Аллаһе әкбәр» дия-дия олы якка чыкты. Аның башында менә дигән кара бәрхет түбәтәй, өстендә үтүкләнгән күлмәк һәм мәчеткә барганда гына кия торган яшел чапан иде.

Гөлшәрифә карчык Мәүләвине күргәч тә: «Менә бит ничек, бу кешенең үз гомерендә ниләр кылганын белмәсәң, изгеләрнең изгесе дип уйларсың. Чын татар карты булган бит бу, сөбханалла»,— дип уйлап алды.

Мәүләви агай үз урынына әйбәтләп утырды һәм шуннан соң гына кулларын күтәреп:

— Ягез, дога кылып алыйк,— диде һәм, хатыннарны көтеп тә тормастан, кычкырып ук булмаса да, ишетелерлек көйләп укып җибәрде:

— Я илаһе...

Өчесе берьюлы битләрен сыпырып алдылар.

— Йә, Гөлшәрифә, сәламәтлегең ничек, ни эшләр бетереп йөрисең? — диде Мәүләви, эчкерсез сорашудан бигрәк, тиешле гадәткә буйсынып.— Кияүләрең кайтып-китеп йөриләрме?

— Ходайга, шөкер әле, Мәүләви, бер кузгалгач, йөреп китәм шулай.

— Әйдә, Гөлшәрифә абыстай, җитеш әле, чәеңне бүлеп куй, суына торсын,— дип бүлдерде аларны Кәрамия.— Син дә, әтисе, җитеш...

Гөлшәрифә, аңа әллә ни игътибар итмичә, баягы сүзен җөпләп китте:

— Йөреп торабыз әле, Мәүләви, яшебез байтак булса да. Менә яшьрәкләр бирешә... Сезнең урамга килеп чыгуымның сәбәбе дә шул. Мәрхүм Шәкүрҗанның сеңелесен, Зәйтүнәне әйтәм әле. Соңгы сулышларын алып ята мескенем.

— И, карале, онытып та торам. Мин дә иртә якта кереп чыккан идем,— дип сүзгә кушылды Кәрамия.— Мескенем, бигрәкләр дә газаплы үлемгә дучар булды инде. Теге яман нәрсә икән ләбаса аңарда. Ходай язмасын, әйеме, Гөлшәрифә абыстай?

Мәүләвинең гәүдәсе бу вакытта табын артында утырса да, чынлыкта исә ул Гөлшәрифә җиткергән хәбәрне ишетүгә сискәнеп китте.

«Йа хода,— дип уйлап куйды ул,— бакчада чакта әле генә мин бит нәкъ шушы Зәйтүнә турында уйлап алган идем. Баксаң, бер дә юкка гына исемә килеп төшмәгән икән. Аның хәлләре яман диген... Ә бит... Әйе, теге вакытта атна буена Зәйтүнәне авыл советыннан җибәрмичә йөртте Мәүләви. Ул чагында аңа яшьлеге ничәмә мәртәбәгә артып кайткан сыман булды.

Ул чакларда таңнан торып та авыл советына ашыга иде Мәүләви, кичкырын кеше таралып беткәч тә шунда барып кайту хәйләсен тапты.

Ниһаять, көннәрдән беркөнне Зәйтүнә аны «шатландырды» — үзенең авырга узуын әйтте. Алай гына да түгел, кеше алды, кеше арты

дип тормыйча авыл советы бинасында тиктомалдан укшый башлады. Районнан килгән бер вәкил каршында шушы хәл кабатлангач, Мәүләвигә шом керде. «Әгәр дә мәгәр бу хәл халыкка мәгълүм булса, район җитәкчеләренә җитсә — көт тә тор урыныңнан очып фронт дигән мәхшәр эченә барып төшәсеңне, дигән уй аның тынычлыгын югалтты.— Котылырга кирәк бу рәхәттән, тизрәк котылырга».

Һәм... тагын өч-дүрт көннән Зәйтүнә бичара, туктаусыз елаудан шешенгән күзләрен юеш кулъяулыгы белән сөртә-сөртә, Мәскәү тирәсенә оборона ныгытмалары казырга китте. Мәүләви исә Зәйтүнәнең фамилиясен китүчеләр исемлегенә керткәннән соң, ашыгыч эш табып, бер атнага Чистайгамы, әллә Казанның үзенә үкме китеп барган иде...

— Йә, ходаем, кодрәтең киң, шушы бичара Зәйтүнәгә газапсыз үлем бир,— диде Мәүләви һәм кулларын күтәреп, Зәйтүнәнең соңгы сулышларын җиңеләйтүне сорап, ясин чыгарга тотынды. Аның теле дога укыды, әмма аңында: «Тизрәк, тизрәк керергә кирәк шул Зәйтүнә янына, сорап калырга кирәк аңардан бәхиллек. Урманнан алып кайткан яңа бал кертергә кирәк, шифасы бар...» — дигән буталчык уйлар өере белән кайнашты.

Шул вакыт Мәүләвинең колак төбендә генә урманда төннең-төн буена бимазалап чыккан Тавыш:

— Мәүләви, үзең беләсең... Доганң кабул булырмы? Без шулай сөйләштекме соң? — диде.

Бу юлы Мәүләвигә ихтыяры хыянәт итте. Ул әрнеп: «У-у-х!»— дип куйды, догасын укып бетергәч «Амин!» дияргә дә көче җитмәде.

Гөлшәрифә белән Кәрамия мондый очракта укый торган доганы яхшы беләләр, алар кирәген укып бетерделәр дә күзләрен күтәреп Мәүләвигә карадылар, аның дога кылуын көттеләр. Ләкин Мәүләви дога укыган хәлендә ни үле, ни тере килеш катып калган, аның мытырдавы ишетелми, иреннәре кара көйгән, күзләре зур-зур ачылып, пыялаланып калган иде.

Беренче булып хәлне Гөлшәрифә төшенде. Ул тиз генә битен сыйпап алды да урыныннан тора башлап:

— Ни, нәрсә булды сиңа, Мәүләветдин? — диде. Кәрамия ык-мык килә башлады. Ул гүя телен йоткан, әйтәсе сүзләрен онытканн иде.

Гөлшәрифә урыныннан торып, өстәл тирәли әйләнеп Мәүләви янына килде һәм җилкәсенә кагылды:

— Мәүләветдин, Мәүләветдин дим, ни кылануың бу дога укыганда? Карале, минәйтәм, үлдеңме әллә? Мәле, чәй тот әле...

Мәүләви аның тавышын ишетеп торды, җилкәсенә төрткәнне дә сизде, әмма ничек торган булса, шул кыяфәтендә калды.

Ниһаять, ул битенә таба күтәргән кулларын төшерде, кан басып өлгергән күзләрен челт-мелт иттереп торды һәм шуннан соң гына янәшәсендәге Гөлшәрифәгә таба борылып:

— Кем ни... Гөлшәрифә килен... Ни бит... Теге, үзең дә беләсең инде, безнең хәзерге хәлләрне... Бер аягыбыз белән теге дөнья бусагасында басып торабыз... Син... Теге вакытлардагы усаллыкларым өчен мине... нитә, бәхилли күр инде,— дип әйтеп салды.

Гөлшәрифә дә, Кәрамия дә аның телгә килүен күрделәр, бик үк бәйләнеп бетмәгән сүзләрен ишеттеләр, ләкин мәгънәсен аңламадылар. Бигрәк тә Кәрамиянең үз колагы белән ишеткән сүзләргә исе китте. Китмәслек тә түгел бит: илле елдан күбрәк бергә яшәп, ул Мәүләви авызыннан бер генә кырын эше өчен дә кешедән гафу сораганын, аннан да бигрәк бәхилләшүен ишетмәде. Ул Мәүләвине мондый нәрсәгә сәләтле кеше дип санамый һәм иренең орды-бәрде телен генә аңлый торган халәткә күнеккән иде.

— Нә-мәс-тәә? — дип Кәрамия баягы урынына «лып» итеп яңадан утырды.— Әй, ходаем, җиңеләйгәнме соң әллә бу?..

— Жиңеләймәгән, курыкма, Кәрамия, жиңеләймәгән ул. Урман шулай уйландырган аны, урман... Ялгызлыктандыр...— диде Гөлшәрифә һәм Мәүләвигә караган килеш өстәде: — Син, ни, Мәүләветдин, ни дип әйтим... жыена башларга иртәрәк түгелме соң әле сиңа... Мин нәрсә дим инде? Әгәр дә шушы сүзләрне әйтерлек хәлгә килгәнсең икән, кем әйтмешли, узган эшкә салават.

Гөлшәрифә сүзеннән туктап тирән сулыш алды, ихтыярын туплады һәм «булган эш булган» дип, кырыс тавыш белән дәвам итте:

— Бигрәкләр дә кешеләрнең үзәкләренә үттең шул, Мәүләветдин. Мин нәрсә, мин бәхилләрмен, син бит миңа усаллыгыңны эшләп өлгермәдең... Аннары, Шәкүрҗанымның әйберләре хакына булса да авыр чакта онын сатып бирдең... Ярар инде, аларны искә төшереп, усаллыкка каршы усал сүз әйтеп яшәмибез бит,— дип тезеп китте.— Син әнә, кияү шушы көннәрдә кайтырга тиеш иде... Туганнан туганыңның баласы бит, аңардан нит... бәхилләт... Теге вакытта, кесәдәге бөртек өчен, бигрәк тә үзәкләренә үтеп кыйнадың бит мескенкәемне... Дөрес, син ул вакытта хатыннардан үзеңә тиешле җәзаңны алдың. Борынгы китапларда шулай язылган: кеше үзе кылган явызлыкның җәзасын табарга тиеш, диелгән. Син һәрвакыт җәзаңны ала килдең, синең оятсыз яңакларыңа сукмадылар түгел, суга килделәр. Әмма ләкин син, Мәүләви, йөзеңдәге канлы төкерегеңне жиңнәрең белән сөртә-сөртә яңа кабахәтлек эшләргә ниятләдең. Миңа нәрсә, мин сине бәхилләрмен, Мәүләви, ә менә Сагынуны бердәнбер улыннан аерылып китәргә, аларны мәңге күрешмәскә мәҗбүр итүең өчен... Сагыну, бичаракаем, сагышка түзә алмыйча йөрәге ярылып үлгән. Хәзерге мәлдә үлем түшәгендә ятучы Зәйтүнәне шундый хәлләргә төшереп газаплауларың өчен, Мәүләви... мин алар өчен бәхилли алмыйм. Үзе ни әйтер... Бәлки, өзелмәгәндер әле...

Һәм Гөлшәрифә сулкылдап елый башлады. Кәрамия исә, аңа карап, иренең шундый түбәнлеккә төшүен дә онытып жибәрде, шулай ук күзләрен сөртеп-сөртеп алды. Ләкин Кәрамиянең күңелен шатлык биләп алды. Яшерен-батырын түгел, ул бит, турысын әйткәндә, узган еллар дәверендә җан тынычлыгын югалтып яшәвендә Гөлшәрифә, Сагыну һәм Зәйтүнәләрне дә гаепли иде. Ә инде болай килеп чыккач...

Мәүләви Гөлшәрифә сөйләгән һәр сүзне ишетеп барды. Ишетү генә дә түгел, ул сөйләгән вакыйгаларны телевизордан күрсәтелгән кебек итеп күз алдына китереп барды. Теге вакыттагы урак өстен, тузанлы юлны, Сагыну малаеның ялангач аркасындагы канлы эзләрне күрде. Ап-ачык итеп, бүген генә булгандай итеп күрде... Ул да түгел, Мәүләвинең хәтере Гөлшәрифәгә мәгълүм булган, ләкин аның кияве Хафизга кагылышлы икенче бер вакыйганы да эзләп тапты.

* * *

...Мәүләвинең ул чагында инде колхоз рәисе түгел, аннан төшергәннән соң берничә ел урман каравылчысы булып эшләгән, яңа урынының тәмен татыган һәм шуңа күрә теге вакыттагыдан да битәррәк кылана башлаган чаклары иде. Сугыштан соңгы берничә ел эчендә кешеләрнең тормышы беркадәр яхшырды, халык иркен сулыш алып жибәрде. Хезмәт көненә дә элеккечә граммлап түгел, килолап бирә башладылар. Икмәге булгач, акчасы да күренгәләде. Сугыш кырларыннан кайткан иргетләр дә бөтенләй юк түгел иде. Тормыш үзенекен итә, кыенлыкларны жиңеп чыккан авылдашлары сугыш елларында тәмам тузган, искергән, утын булмагач сүтеп ягылган каралты-кураларын, йорт-жирләрен яңартырга керештеләр. Мәүләвинең эше бермә-бер артты, утыннан тыш, төзелешкә ярардай урманны кистерү мәшәкатьләре дә өстәлде аңа.

Ул көнне Мәүләвинең халыкка билгеләнгән делянканы барларга, кемгә нәрсә бирергә, ә кемнән нәрсәне яшерергә кирәклеген чамалап

куярга барышы иде. Элеккеге кебек талчыбыктан үргән тарантаста булмаса да, үрәчәле арбасында, хуш исле печәнгә кырын ятып, җәйге эсседә аерата азган кигәвеннәрдән качарга тырышып кына атның лырт-лырт юыртып баруына йокымсыраган иде Мәүләви. Ниндидер сикәлтәдән соң башын күтәреп карады. Йөзьяшәр имән ботакларыннан төшкән күләгә астына куелган, коры-сары төялгән кечкенә арбаларны һәм арба астында җырлап ятучы ике малайны күреп алды.

Арба астыннан малайларның тигезсез тавыш белән җырлавы ишетелә иде:

Без барасы юл арасы —
Телефон баганасы.
Без үсәргә өлгермәдек,
Чукынды заманасы.

Малайлар җыр белән шул кадәр мавыкканнар иде ки, дегетләнгән арбаның тавыш-тынсыз килеп туктаганын, аннан Мәүләвинең җайлап кына төшкәнен, кулына теге чактагы каеш камчысын алганын һәм йомшак адымнар белән яннарына килеп басканын да ишетмәделәр.

— Әһә, менә алар урман ерткычлары! — дигән сүзләр белән берьюлы һаваны кисеп алган камчы малайларның күләгәдән тышка чыгып торган ялан балтырларын чагып алды.

Малайлар, балтыр итләрендәге ярадан кан чыгып өлгергәнче, арба астыннан атылып чыктылар да алны-артны карамыйча арыш арасына кереп югалдылар. Мәүләви, билгеле инде, аларны шундук танып алды.

— Качмагыз, урман ерткычлары, барыбер танырдым мин сезне. Арбаларыгызны да таныдым бит. Берегез Сагыну малае Хафиз, икенчегез Мөсәлим картның яшь хатынына ияреп килгән нәмәрсә... Чыгыгыз хәзер үк! Чыкмасагыз... чыкмасагыз арбагызны балта белән тураклыйм...

Беренче булып Хафиз аңына килде, үзеннән буйга ике тапкыр биегрәк Нәбинең арыш арасыннан сикерә-сикерә йөгергәнен бераз карап торды да әйтте:

— Тукта, Нәби...

Нәби теләр-теләмәс кенә туктады, аның күзләре урман ягында иде.

— Әйдә,— диде Хафиз икеләнергә, кире чигенергә урын калдырмыйча.— Без... без бит икәү, шул Убыруттан куркып торабызмы?

Хафиз инде Мәүләви камчысын татыган, аннан соң да ятимлеге аркасында тегене-моны күргәләгән малай, уникене тутырган иде. Ләкин барыбер, ирләргә каршы беренче тапкыр чыгуы булгангамы, арыш арасыннан имәнгә таба атлаганда бераз икеләнеп калды. Ләкин, Мәүләвинең арба чәкүшкәсен һәм тәгәрмәчне салдыра башлаганын күреп, икеләнүеннән тиз арынды, атылып барып Мәүләвинең сыртына сикерде.

— Тимә-ә-ә-ә! — диде ул теш арасыннан гына сыгып.— Тимә безнең арбага, Убырут!

Малайның чаялыгын белгән Мәүләвигә шул сүзләр житә калды. Ул кискен хәрәкәт белән малайны аркасыннан бәреп төшерде дә өстенә ятты. Ләкин икенче мизгелдә хәрәкәтсез катып калды. Мәүләви арбасындагы ау мылтыгын кысып тоткан Нәби:

— Җибәр Хафизны, җибәр дим. Югыйсә атам! — дип кычкыра-кычкыра якынлашып килә иде.

Мәүләвинең күкрәгендә нәрсәдер чәнчешеп алды. «Атачак, халык дошманы, ике дә уйламас»,— дигән уй аны торгызып бастырды. Ул малайларга:

— Ярар, әтәчләнмәгез,— диде.— Мин бит сезне куркытмакчы гына идем. Бу коры-сарыны җыйган өчен, урманны чистарткан өчен мин үзем сезгә юньлерәк утын бирергә тиешле...

Малайлардан беркатлылык чыгып бетмәгән иде әле, ышандылар тагы. Нәби мылтыгын җиргә таба юнәлтте, аннары бөтенләй җиргә ташлады. Бәхетсезгә җил каршы, дигәндәй, Мәүләвинең мылтыгы корылы бул-

ган икән, җиргә бәрелүдән ул һич көтмәгәндә гөрселдәтеп атып җибәрде. Малайлар да, Мәүләви үзе дә авызларын ачып тынып калдылар. Ләкин урманчы алданрак аңына килде:

— Үтерәләр, караул, үтерәләр! — дип, юлдагы тузанны туздыра-туздыра авыл ягына таба йөгерде.

Хафиз белән Нәби бер-берсенә карашып тордылар-тордылар да, эчләрен тотып, шаркылдап көләргә керештеләр.

Ләкин иртәрәк көлгәннәр икән. Алай-болай булмасын тагы дип, Мәүләвинең атын иманнән ерак түгел агачка бәйләп куярга да өлгермәделәр, шул вакыт алар янына колхоз председателе Мостафа абыйлары утырган «Победа» килеп туктады. Аның белән бергә машинадан Мәүләви дә чыкты.

— Менә бит нишлиләр, Мостафа туган,— диде Мәүләви.— Эт симерсә, иясен тешли, диләр. Шуның шикелле, болар да симергәннәр, тәннәренә ит ябышкан ач бетләрнең, мине атып үтерергә җыендылар...

Мостафа абыйларын яхшы белә малайлар, бигрәк тә Хафиз аны яхшырак белә, чөнки авылга алып килеп председатель итеп сайлагач та аны Хафизларга керттеләр. Вакытлыча торырга дип. Шул чагында малай аның белән дуслашып алган иде.

— Ялганлый ул, Мостафа абый,— диде Хафиз.— Менә карагыз... без ял итеп ята идек... Ә ул Убырут...

Мәүләви аңа:

— Күрсәтермен мин сиңа! — дип җикеренмәкче иде, колхоз башлыгыннан яхшысынмады булса кирәк, шуннан ары узмады. Ул арада малайлар чалбар балакларын күтәрделәр. Камчы эзеннән саркып чыккан кан укмашып ката башлаган иде инде.

— Ярый, кайтыгыз авылга. Үзем сөйләшермен урманчы белән, тавыш чыгармас, бәлки,— дип, Мостафа абыйлары ике арадагы ызгышка чик куйды.

— Уф алла, үзең саклый күр, ходаем,— диде Мәүләви үзенә таба чекрәешеп карап торган Кәрамия белән Гөлшәрифәгә игътибар итмичә диярлек.— Әллә ни күрсәтерләр әле болар, әллә ни...

— Юкны сөйләмә, атасы, нәрсә күрсәтик ди без сиңа! — диде Кәрамия һәм үзе тагын: «И ходаем, җиңеләйгән ахрысы бу, җиңеләйгән», дип уйлап алды.— Филшерне чакырыйкмы соң әллә?

Мәүләви инде үз-үзен кулга алган иде, урыныннан торды да хатынын үртәгәндәй итеп:

— Филшер, филшер, нәрсә белә соң ул синең филшерең,— дип сөйләнә-сөйләнә ишегалдына таба юнәлде.

— Әйдә, Гөлшәрифә, киявеңә дигән балны биреп үк җибәрим булмаса. Чиләгең-фәләнең бармы соң?

Гөлшәрифә моны көтмәгән иде, аннары кияве дә: «Икенче тапкыр Мәүләвидән бал сорама!» — дип кисәтеп киткән иде. Ләкин авызыннан бер чыгып очкан сүзне кире кайтарып булмый, килешергә туры килде.

— Чиләгем юк югын Мәүләветдин, үлчәп калдырсак... Мин әйтәм, чишмәгә төшкәндә арбаңа куя барыр идең инде. Әйдә алайса, шулай итик соң.

* * *

...Кәрамияне Мәүләвигә көчләп диярлек бирделәр. Хәер, көчләп дип әйтү дөреслеккә туры килеп үк бетмидер, бәлки. Чөнки әтисе, тирәякның иң бай кешесе үк булмаса да, урта хәллеләрдән югарырак кеше иде. Чистайга барган-кайткан чагында үзләренә кунакка кереп, ара-тирә кунып чыккалаучы Риян агай туганлашу турында сүз кузгаткач та Кәрамияне чакырып: «Кызым,— диде,— син инде җиткән кыз, менә яхшы гы-

на урын күренеп тора, сине Риян абзыеңның Мәүләви исемле улына сорыйлар. Ризамы син, юкмы — иртәгә иртә белән әйтерсең. Бар, анаң һәм туган-тумачаларың белән сөйләш, киңәш, әгәр киңәшәсең килсә»,— диде.

Кәрамия әтисенең холкын, үз дигәненнән беркайчан да кайтмый торган кеше икәнлеген белә иде.

Мәүләви ярамаслык кеше булып чыкмады. Яратмады түгел Кәрамияне, бик яратты. Өйләнешкән елларында, әле колхозлар башланганчы, хәер, аннан соң да сугыш башланганчы диярлек, Мәүләви аннан битәр хатын-кызга күз салмады. Кичкырын Кәрамиянең берәр гаебен табып, орышып күңелен төшерсә, шул ук төнне кочагына алды... Шуңа күрә Кәрамия аңа сигез бала табып бирде, бөтенесен үстерде, урнаштырды. Ире кайтарган малны җыя бирде. «Каян алдың? Нигә алай итәсең? Нигә болай түгел?» — дип төпченмәде. Мал табу ир эше, анда синең катнашың булмасын, дип әнисе үгетләгән иде, шул сүздән беркайчан да чыкмады Кәрамия һәм уңды. Шундый булуы белән Мәүләвигә ошады, торабара инде Мәүләви холкындагы бик күп сыйфатлар аңа да күчте... Кыскасы, Кәрамия үз тормышыннан канәгать булып яши белде. Колхозга керделәр, кеше ничек яшәсә, шулай яшәделәр. Җаен белеп кенә электән туплап калган малларына урын таптылар.

Кәрамия сукыр түгел, бөтенесен дә күреп торды. Дөрес анысы, сугыш елларында Мәүләви котырынмады түгел, бик нык котырынды, азгынлык тамыры чыккан вакытлар булды бугай... Ләкин Кәрамия телен аркылы тешләп түзде. Хәер, бала-чага үстерү кайгысы җитәрлек иде аның. Килеп әйтсәләр көйде, анда да кешегә күрсәтмәде.

Илле тугызынчы елда бугай, беренче балалары, бердәнбер уллары Сәгъдулла Кәрамиянең йөрәккәйләрен телгәләде. Колхозның баш бухгалтеры булып әйбәт кенә эшләп, яшьтәшләре әллә ниткән ФЗӨгә, аннары армиягә китеп бишәр-алтышар ел хезмәт итеп йөргән чакларда идарәдә утырды-утырды да, өч баласы тугач, акылын югалтты. Бөгелмәдәге бер марҗага ияләште. Атна-ун көн саен Казанга дип китте дә, үз станцияләрен узып китеп, Бөгелмә аша кайта торган булды. Иптәшләре көлешә-көлешә: «Сәгъдулла тагын стансасын узган да Бөгелмәгә җиткәч кенә күзләрен ачып җибәргән»,— дип сөйләнделәр. Кәрамия Сәгъдулласының болай йөрүләренең яхшылык белән бетмәсен белде, йөрәгенең әллә кайдагы җепселләре аркылы сизде. Мәүләвиенә әйтеп-әйтеп тә карады. Ләкин Сәгъдулла инде атасын тыңлаудан узган иде. «Әнә синең урманың, шуны сакла, урлап бетермәсеннәр. Урманда җен-пәри бар диләр, кем икәнлегеңне бик яхшы беләбез, телеңне тыеп кына йөр»,— дип көлде.

Эчү, эчү харап итте Сәгъдулланы. Шул аракы дигән нәрсәгә ияләшмәсә, Бөгелмә марҗасының котырыгына да карамас иде... Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас бит. Колхозның җитмеш биш мең сум акчасын алып китеп югалды Сәгъдулла көннәрдән бер көнне. Бөтен район шаулады, очраган бер кеше Кәрамиягә төрттерү җаен тапты... Кәрамия айдан артык, Сәгъдулласы табылганчы урамга чыгарга, кеше күзенә күренергә оялып яшәде... Табылуын табылды Сәгъдулла, әмма ләкин җитмеш биш меңнең биш тәңкәсе дә калмаган иде. Ун елга утырттылар балакайны... Ун елга! Тик бәхете бөтенләй үк юк түгел икән, әтисе элекке танышлары аркылы эш йөртә-йөртә яңадан суд ясауга иреште. Алты елга калдырдылар...

Кәрамиянең үзәген өзгән, Мәүләвиен ул вакытларда кыралмас хәлгә җиткергән икенче вакыйга Сәгъдулласы төрмәдән кайткач булды.

Әтисе, аңа урын булсын дип, пенсиягә чыкты, үз эшенә Сәгъдулланы урнаштырды, акылга утыргандыр инде утырган җирендә, диде. Ләкин Сәгъдулла аннан бик үзгәреп, холкы бөтенләй начараеп кайткан иде. Эшкә урнашып өлгермәде, көн саен эчеп-исереп, хатынына бәйләнә башлады. Кайсыдыр кычыткан теллесе аңа: «Син өтермәдә чакта хатының

тик кенә ятты дип беләсеңме әллә?» — дип ычкындырган, оятсыз нәрсә. Хатыны шундый икән, үкенмәс тә иде. Хәер, исереккә нәрсә аңа, бәйләнергә җай чыксын да үзенең холкын күрсәтсен.

«Бүре башын табакка салсаң да тәгәрәп төшә»,— диде Мәүләви һәм көннәрдән бер көнне урман каравылчылары башлыгына болай дип гариза язды:

«Хөрмәтле иптәш! Сезнең карамакта урман каравылчысы булып эшләүче Сәгъдулла Риянов үз вазифаларына салкын карый. Шуның өстенә, даими рәвештә эчүчелек белән шөгыльләнә. Каян алып эчә диегез әле? Урман сатып эчә. Болай барган очракта озакламый урманның эзе дә калмас. Тирә-юнь авылларга гына түгел, еракларда килгән кешеләргә дә сата ул эшкә ярардай агачны. Әгәр дә мәгәр юньсезне эшеннән алмасагыз, мин бу хакта югарыдагы органнарга хәбәр итәргә тиеш буламын. Ә инде аның урынына кеше кирәк була калса, рәхим итегез, мин сезгә ничәмә-ничә еллар буена тугрылыклы хезмәт иттем. Үз урыныма үзем керермен».

Сәгъдулланы эшеннән куып чыгардылар да Мәүләвине алдылар. Теге шул ачудан бер атна чамасы эчеп йөрде дә авылдан китеп югалды. Ике айдан соң гына аның Куйбышев өлкәсендәге бер совхозга барып урнашуын белделәр. Озакламый ул хатыны белән балаларын кайтып алды һәм шуннан соң уникe ел буена ник бер хәбәре килсен?!

Күптән түгел генә Кәрамиягә җиткерделәр: Сәгъдулла бәгырькәенең ике аягын да бот төбеннән диярлек кисеп алганнар икән. Тагын шул «яшел елан» аркасында, чучка баласы кебек, юл чокырында ятып йоклаган, ди. Мәүләвие белми әле бу хәлне, белми. Ничек әйтергә дип баш ватты Кәрамия. Өзгәләнүен өзгәләнде, ләкин ата белән улы арасындагы таш койманы — дошманлык коймасын үтеп чыга алмады. Иң кыены — улының хәлен белергә дә барып кайта алмады.

Кәрамия шушы хәсрәтенә баткан килеш озак утырды һәм, ниһаять, салкынча идәнгә салган намазлык өстенә авып йоклап китте.

* * *

Мәүләви нишләргә белмичә ишегалды белән бакча арасында бәргәләнеп йөрде. Авыл урамына чыгу, үлем түшәгендә яткан Зәйтүнә янына кереп бәхиллек сорау, урамда очраган башка кешеләр белән сөйләшү кирәклеге ихтыярын параличлаган иде. Аның башына килгән беренче аңык уй: «Урманга китәргәме әллә?» — дигән уй булды. Ләкин тиз генә ныклы карарга килә алмады, тегеләй дә, болай да уйлап карады. «Китсәң, тагы кичәгедәй... Китмәсәң, кем йөрмәс урманда? Болай да Мәүләвинең урманда умарталар асравына кырын карап йөрүчеләр бар».

— Ярый, алайса, карчыкка чишмә суы алып кайтыйм әле. Юл уңае дигән булып Зәйтүнәләр турында да туктармын. Анда, мөгаен, кеше күптер әле, аннары күз күрер,— диде, ниһаять, Мәүләви үз-үзенә һәм бакчадан ишегалдына чыкты.

Кояш инде Кала елгасы башына ук барып җиткән, димәк, аңа тагын Мәрҗән тавына менеп җитәсе дә урман артына төшеп югаласы гына калган. Аның тирәсендә бераү дә юк иде. Ләкин ул инде хәзер бераүгә дә ишеттермичә уйланудан да курка, чөнки аның уйлаганы шул ук мизгелдә Тавышка барып ирешә иде.

Ул җиргә чүгәләгән җиреннән ничек торуын, атын кай арада җигүен, су савытлары белән бергә, Гөлшәрифәгә дигән чиләккә һәм Зәйтүнәгә дип тагын бер литрлы банкага бал тутырып куюын һәм капкасын ачып урамга чыгуын сизмичә дә калды. Боларның барысын картларга хас пөхтәлек белән, еллар буена канына сеңгән гадәте буенча уйламыйча диярлек башкарды ул.

Ат тамагын туйдырган, урамда йөреп керү җае чыкканга күрә аеру-

ча елдамлык белән капкадан чыкты, дилбегә тартканны көтмичә үк уңга борылды һәм, Озын урамны аркылы чыгып, Совет урамына керде. Ләкин Мәүләви соңгы вакытларда атын чаптырып йөрергә, бигрәк тә авыл урамында, яратып бетерми иде. Шуңа күрә ике йорт арасын узуга атны тыя төште, адымга күчерде.

Шул арада бераз гына алдарак, хуҗалары киткәннән соң да утыз елга якын моңаеп яшәгән, ниһаять, моннан ике-өч ел элек бөтенләй ишелеп төшкән йортның алабута, әрекмән һәм кычыткан оясына әверелгән ишегалдында басып торган кешеләрне күрде.

Уртадагы бердәнбер ир-атны үзенә таба борылып карар-карамас борын ук танып алды Мәүләви.

«Нәүшир?!»

Әйе, шушы урындагы йортта туып, сугышка кадәрге гомерен шушы урамда, Мәүләви йөргән урманда күмер яндырып, туздан дегет кайнатып йөргән, аннары колхоз башлангач та мал көтүе көтеп гомер иткән Нәүшир иде бу!

«Туктамыйча, исәнлек-саулык сорашмыйча китү ярап ук бетмәс инде,— дип фикер йөртте Мәүләви,— җитмәсә бит аның хатыны туганнан туганым, Кәшиф абзыйның Сәрбиҗиһаны була түгелме соң әле. Кем әйтмешли, әйдә, ярар, туктап сөйләшеп алганнан берни булмас...»

Ләкин хәтер, әй, бу хәтер дигән нәрсә! Мәүләви тузган-таралган йорт-җирнең үлән каплап киткән ишегалдында басып торучы кунаклар турында атын туктатты. Арбасыннан картларча салмаклык белән төште. Мал-туар кермәсенгә тотып куйган киртә янына кадәр унбиш-егерме адымны атлаганчы аның хәтере ничәмә-ничә еллар астында катлам булып ятып калган нәрсәләрне әйләндереп өлгерде.

...Нәүшир сугышның беренче көннәрендә үк фронтка китеп барды. Мәүләви моны ачык хәтерли. Авылда аның хатыны Сәрбиҗиһан, берсеннән-берсе яшьрәк биш баласы — дүрт улы һәм үзе китеп атна-ун көн үткәч тә дөньяга килгән бердәнбер кызы калды.

Ишегалды уртасында басып торган, хәзер инде үзе дә түбәтәйле картка әверелгән Нәүшир белән Мәүләви арасында булган ярыйсы гына котсыз вакыйга да бар иде шул.

Кырык җиденче елның чатнама суык кыш уртасы иде. Сугышта яралангач та хезмәт фронтына, Чиләбедәге Танкоградка җибәрелгән һәм шунда тимерче һөнәрен үзләштереп төпләнергә уйлаган Нәүшир зәмһәрир суык көннәрнең берендә авылга кайтып төште. Берме-икеме көн авылда туган-тумачаларын күреп йөргәннән соң колхоз идарәсенә килеп керде. Мәүләвинең җитәкчелектә эшләвенең соңгы елы иде инде. Әмма ул кышны Мәүләви дә, бүтән авылдашлары да аның озакламый урыныннан очасын белмиләр иде әле. Шуңа күрә Мәүләвинең гайрәтле чагы, ни җитте кеше белән сөйләшеп торуны кирәк санамый. Нәүширне күргәч тә: «Сиңа, дезертир, нәрсә кирәк?» — дип, бүлмәдәге кешеләр алдында ук тегеңәргә ябышты.

Элеккеге еллардагы, сугышка кадәрге Нәүшир булса, билгеле инде, авызыннан сүз чыкмаган булыр иде. Ләкин Мәүләви ялгышты.

— Кем ул, әйтеп күрсәтегез әле яңадан, дезертир була? — дип, Нәүшир Мәүләвинең каршысына ук килеп басты.

— Кем булсын, син булмыйча,— диде Мәүләви.— Минме әллә, минме үземнең хатыным белән җиткән улларымны алып колхоздан качарга җыенучы? Ә? Минме, әллә синме? Беләсең килсә, мин сине авылдан җибәрергә җыенмыйм. Менә шул...

Нәүшир Мәүләвине бүлдермичә тыңлап бетерде һәм — гомердә булмаган хәл! — Мәүләвинең каршысына ук килеп басты.

— Хәзер үк, ишетәсеңме син, Убырут, хәзер үк дезертир дигәнең өчен гафу сора!

Аның бу сүзләре тынып калган бүлмәдә шулкадәр көтелмәгәнчә яңгырады ки, Мәүләви дә, аның янындагылар да беравык тынсыз торды-

лар, аннары гына барысы берьюлы көлеп җибәрделәр. Көлмәслек түгел иде шул. Мәүләви белән авылда болай сөйләшүче юк та юк инде, әмма бит колхоздан китәргә җыенучы, шуңа кирәкле белешмә алырга килгән кеше рәис белән шулай сөйләшә.

— Нәрсә, нәрсә дидең Мыштым Нәүшир? Нәрсә дидең?

Мәүләви ачуыннан үз тавышына үзе буылып килде. Ләкин Нәүширне инде болай гына куркытып булмый, ул инде өч елын сугышның алгы сызыгында уздырган, яраланганнан соң бөтен илгә танылган Танкоградка барып эшчеләр арасында яшәгән, анын өстәвенә...

— Мин, Мәүләви, синең кебек, сугышка бармас өчен арт санымны өстерәп йөрмәдем. Дүрт тапкыр яраландым, кырык сигез тапкыр немец тылына чыгып, синең шикелләне генәме, менә мондый баһадирдай илле ике фашистны үзебезнең командованиегә алып кайтып тапшырдым. Аннары Танкоградка — ут эченә чумдым. Менә шулар өчен...— Нәүшир шулай диде дә өстендәге пальтосының төймәләрен ычкындыра башлады. Мәүләви дә, бүтәннәр дә «я, ни кырырсың икән?» дигәндәй аңа текәлделәр. Ул арада Нәүшир пальтосын як-якка ачып җибәрде һәм авылдашлары (алар арасында фронттан кайтучылар да бар иде) Нәүшир күкрәгендәге Кызыл Йолдыз, Бөек Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Дан орденнарынын өчесен дә күрделәр.— Я, Убырут, минме дезертир??

Бүлмәдәгеләр шым булды, ләм-мим бер сүз әйтүче табылмады. Нәүшир исә ул арада акрын гына пальтосын төймәләде һәм Мәүләвигә борыла төшеп:

— Мин, Мәүләви, синең янына башка кереп тормам, ерак яшәмисең, күршедә генә, кирәкле белешмәне кертеп бирерсең. Башка монда киләчәк кеше түгел мин,— диде дә, авылдашларына «Их, сез!» дигәндәй үпкәле караш ташлап, идарә бүлмәсеннән чыгып китте.

Нәүшир бүтән килмәде. Мәүләви исә, белешмәләрне ясатып куйса да, кертеп бирергә ашыкмады.

Бер атна чамасы уздымы-юкмы, көннәрнең берендә, Мәүләви иртәнге ашка кайткан җиреннән Нәүширнең барлы-юклы әйберләрен ат олавына төяп, хатыны һәм малайларын ияртеп, кызын чанага утыртып станса юлына таба авылдан чыгып баруын күрде. Башта ачуыннан нишләргә белмәде Мәүләви. «Тәки бөтен авыл алдында хур итеп китә бит, нуҗәли Мыштым Нәүширдән шуны кайтармыйча җибәрәм?» — диде ул үз-үзенә. Икенче мизгелдә урыныннан кубып тунын эзләп алды һәм капка төбендә күшәп торган аты янына ыргылды. Бер селтәнү белән коймадан дилбегәне ычкындырды, икенче хәрәкәте белән аны-моны төшенмичә торган хайванның авызын ерта язып артка чигендерде, чанасын аудара язып Нәүширләр артыннан юлга чыкты.

Тегеләр, аны-моны уйламыйча,— качып китмиләр ич,— озата баручылар белән сөйләшә-сөйләшә атлыйлар иде. Арттан килгән айгырның өсләренә менә язып туктавыннан куркышып юлның ике ягына сибелделәр. Мәүләви дилбегәсен чанасына ташлады да сикереп төште.

— Кем, кем сиңа, Мыштым, колхоз атын бирде?

Шул сүз белән тамагына тыгылган ярсуын бераз тышка чыгарган Мәүләви олауда яткан озынча сырма юрган төргәген кар өстенә тәгәрәтеп төшерде. Анда Нәүширнең бәләкәче, үзе сугышка киткәч туган кызы булыр дип башына да китермәде ул. Ләкин кияргә җылы киеме булмаганга шулай төрелгән кыз, кар өстенә барып төшкәч, ачы тавыш белән кычкырып елап җибәрде:

— Әнииеем!

Шушы аваз Нәүширгә әллә нинди, хәзергәчә булмаган көч бирде. Ул олавындагы әйберләрне як-якка туздырып йөрүче Мәүләви янына килде, тимерченең чыныккан куллары башбаштакның тун якасыннан эләктереп күтәреп алдылар һәм юл читенә бәрделәр...

— Исәнмесез,— диде Мәүләви ташландык ишегалды уртасында басып торучыларга.— Кемнәр йөри монда дисәм...

— Әйбәтләр әле, Мәүләви абзый, үзең исән-сау гына йөрисеңме?— дип җавап кайтарды аңа ярыйсы гына тулы гәүдәле, ләкин инде, күренеп тора, кимендә җитмеш тирәләренә җиткән хатын.

«Карале, кара, Сәрбиҗиһан бит бу,— дип уйлап өлгерде Мәүләви, эчке яктагылар ишегалды уртасыннан бирерәк килгән арада.— Тегесе ни, Нәүшир инде аның».

— Нәүшир дисәң инде,— диде Мәүләви танымаганга салышыбрак.— Ай-яй, Нәүшир туган, гайрәтле егет идең, син дә картайгансың түгелме соң?

Нәүшир, ирексездән, үзләре киткән көнне, кышкы юлны исенә төшерде. Әлеге «гайрәтле егет идең» дигән сүзләр Мәүләви авызыннан беркадәр астыртын яңгырады. Чөнки шушы вакыйгага кадәр Нәүширнең авылдагы бер генә кеше алдында да гайрәтен күрсәткәне булмаган иде. Алай гынамы, аңа авылдашлары бер дә юкка гына «мыштым» кушаматы такмаган иде, әлбәттә.

— Болай әйбәт кенә әле, Мәүләви, әйбәт кенә,— диде Нәүшир дә киртә янына килеп җитеп, күрешергә кулын суза-суза.— Тик менә тәрәзәләр генә тирли башлады бераз, күзләр диюем. Әйдә, булмаса күрешеп тә алыйк инде... Ничәмә ничә еллар күрешмәгәнгә...

«Хәтерли, онытмаган!» — диде үз-үзенә Мәүләви дә ике куллап күрешкән арада.

— Әллә кайтырга уйлыйсызмы, дисәм? Картайган көнегездә туган авыл тартадыр инде.

— Кая инде ул, Мәүләви, хәзер вакыт узды. Балалар да башлыкүзле булып беттеләр. Оныклар үсеп җитте.

— Шулайдыр шул, шулайдыр...

— Ата-бабалар, үзебез туган нигез бит, Мәүләви, сагындыра. Бәлки соңгы кайтуларыбыздыр. Менә Сәрбиҗиһан да көчкә генә җыенды... Шикәр авыруы интектерә аны да...

— Юкны сөйләмә, Нәүшир, хәзер фатирларыгыз да бардыр. Дөньялар да, аллага шөкер, тыныч тора,— диде Мәүләви сүзне «теге вакыйгалардан» еракkарак күчерергә тырышып. Ләкин ул хәлләрне Нәүшир дә, аның хатыны Сәрбиҗиһан да онытмаган иде. Алай гынамы, ун-унбер яшьләрендәге баласын тотып торучы яшьрәк, чибәрлеге йөзенә чыккан каратут йөзле кызлары да онытмаган булып чыкты.

— Син бит инде ул, Мәүләви абзый, мине иске юрганга ураган килеш кар өстенә тәгәрәтүче, әйеме?— диде картларның сүзен бүлеп, тегеләрне беркадәр аптыраштарак калдырып.— Әти белән әни гел искә алып сөйлиләр иде...

Мәүләвинең йөзенә кайнарлык бәреп чыкты, ләкин ул аны сиздермәскә тырышты. Әмма җавапсыз калдырып та булмый иде, шуңа күрә:

— Кем дип әйтим, атыңны белмим, сеңлем... Теге чакта булгандыр инде... Без дә бит монда үз кайгыбызны гына кайгыртып яшәмәдек...— дип башлаган сүзен ахырынача җиткерә алмады, төнге Тавыш аңа:

— Менә, күрәсеңме, Мәүләви, кырык эш кырык елдан соң да онытылмый ул... Тизрәк бәхиллек сора Нәүширдән,— диде.

Мәүләвинең йөзе кинәт баягы кайнарлыгын югалтты, агарып калды, тамагына әллә нәрсә килеп тыгылды, аның күзләре әлҗе-мөлҗе килебрәк Нәүширгә, аның янындагы хатыннарга карады.

«Ишетеләрме?»

Ләкин Тавыш, күрәсең, Мәүләвигә генә ишетелә торгандыр, кайткан кунакларның йөзендә андый-мондый билге чалынмый иде.

Нәүшир кызына карап алды:

— Ярый, кызым, узган эшкә салават дигәндәй, әллә кайчангыларны искә төшермик,— диде беркадәр суза төшебрәк.— Буласы булган да беткән инде аның...

— Әйе шул, дөрес әйтәсең, Нәүшир,— диде Мәүләви.— Син инде, Нәүшир, минем теге вакыттагы кызулыкны оныта алмыйсыңдыр... Ярар, үзең әйтмешли, узган эшкә салават... Без нитик... алай-болай булып китсәк, минем дә бу араларда хәлләр бик мактанырлык түгел, бәхилләшик, Нәүшир, яме...

Мәүләвинең тавышында теге вакытлардагы тәкәбберлекнең эзе дә юк иде инде, шуңа күрә Нәүшир аңа карап-карап торды да:

— Тынычлан, Мәүләви, үзең беләсең, мин кешенең усаллыгын күңелдә озын-озак сакларга яратучылардан түгел,— диде.

Ни хикмәттер, әңгәмә әллә ни шатландырырдай булмаса да, Мәүләвинең кәефе яхшырып китте, гомерендә беренче тапкыр күкрәгендә юмартлык хисе уянды һәм китә башлаган җиреннән кире борылып Нәүширгә:

— Син, күрше дисәм дә ярый, кордаш дисәм дә урынлы, нит әле, Нәүшир, кичкырын үзеңме, берәр кешенеме җибәр әле безгә. Бераз аерткан бал алып китәрсең,— диде һәм Нәүширнең җавабын көтеп тә тормыйча дилбегәсен капылт алды. Ат урыныннан кузгалды, Кушкаен чишмәсе ягына таба юыртып китте.

* * *

Төрле хатирәләр бимазалый башлаган көннәрендә Мәүләви, авылда сер уртаклашырдай кешесе булмаганга, умарталары янында җан тынычлыгы табарга дип урманга күчте дә инде. Анда ичмасам кеше күзеннән качып, кортлар белән мавыгып, онытылырга мөмкин иде... Әмма кеше заты үз күңеленнән, вөҗданы хәтереннән беркайчан да качып котыла алмый икән ләбаса.

Шушы уй башыннан узган мизгелдә Мәүләвинең күзләре таш күпер өстеннән чыгып баручы бер хатынга төште. Ярыйсы гына таза гәүдәле бу хатын элек болай ук матур киенеп йөрми иде бугай... Мәүләвинең хәтерендә ул нишләптер иске фуфайка, ниндидер тукымадан тегелгән алъяпкыч кигән килеш калган икән...

Әйе, Сәлимә атлы хатын бит әле бу. Тукта соң, ни өчен әле Мәүләви аны күрде, күрү генә түгел, таныды да? Аңа кадәр узган хатын-кызларны, алар арасында өлкән яшьтәгеләр дә бар иде, танымыйча узды. Монда нәрсә дә булса булырга тиеш. Мәүләвинең соңгы вакытларда аерата зирәгәйгән, сизгерләнгән күңеле бер дә юкка гына болай итмәстер...

— Чү, Мәүләви, туктат атыңны, төш арбаңнан, төш тә сөйләш син бу хатын белән,— диде Мәүләвигә каһәр суккан Тавыш юк җиреннән бар булып.— Кырык алтынчы елның җәендә син бу хатынга тиктомалга каныга башладың. Дөрес бит?

— Түгелгән тулы булмаган кебек, үткәнне елап кына кире кайтарып булмый инде аны,— диде Мәүләви моннан бер минут кына элек теленә дә килмәгән сүзләрне әллә кайдан чыгарып.

— Юк, хәтерлә, хәтерлә син, Мәүләви, ничек итеп бу хатынның өенә барып кергәнеңне. Тавык фермасына эшкә кушарга дип бардың син аның янына... Йә, хәзер хәтереңә төштеме?

...Әйе, ул көнне Мәүләвинең ачуы чыккан иде шул. Чыкмаслык та түгел, тавыклар үләргә тотынды, моңарчы фермада эшләгән кылый күзле Рәхия: «Атсагыз да бармыйм анда»,— дип карыша башлады. Аның белән яхшылап сөйләшергә кирәк булгандыр бәлки, әмма Мәүләви аны кеше колагы түзмәслек итеп әрләүдән тәм тапты. «Бар алайса ычкын моннан, мин сиңа күрсәтермен әле»,— дип куып ук җибәрде. Шул вакыт кайсыдыр: «Әнә бит Таубашы Җирбулатның хатыны Сәлимә бар, шуңа кушарга кирәк»,— дип киңәш итте. Озакламый Мәүләви менеп тә җитте. Тегеләр, Сәлимәнең уллары, идәнгә тезелешеп ятканнар да зур табактан аш чөмерәләр иде. Барып керүгә Мәүләвинең ачуы шуларга төште, бигрәк тә олы малайга ачулы иде ул. «ФЗӨгә дигәч тә бугазыңны

ертып «чирлим мин» дип жалу бирдең, ашарга дигәч бер дә чирләмисең икән әле»,— диде һәм табын уртасына барып керде дә агач табакны күтәреп алды. Ул яртылаш тулы иде әле. «Менә хәзер белермен, ничек итеп урак өстендә ашап ятарга икәнлеген күрсәтермен»,— дип сөйләнә-сөйләнә, кече малайның елый башлавына карамастан, табакны күтәреп ишегалдына чыкты һәм болдырга баскан килеш табактагы яшькелт «ашны» җиргә сипте. Шул тирәдә генә чемченеп йөргән ике-өч тавык шундук йөгерешеп килделәр дә җиргә төшкән яшькелт-күксел «ит»ләрне чүпләргә керештеләр. Ләкин ничек тиз чүпләргә керешсәләр, шулай ук тиз генә ташлап та киттеләр. Мәүләви болдырдан төшеп «ит» кисәкләренә карады һәм... ни әйтергә белмәде. Аш түгелгән урында кычыткан яфрагыннан башка бер генә бәрәңге кисәге йә булмаса токмач әсәре юк иде...

— Чү, инде, нишләвең бу, Мәүләви абзый? — диде Сәлимә гаебенең нәрсәдә икәнлеген белмәгәнгә отыры да аптырап.

— Малайларыңны тый, бакча артыгыздагы басудан арыш башагын җыеп «сугалар икән» дигән җалу килде өсләреннән,— диде Мәүләви, акланырга тырышып.

— Соң бит, Мәүләви абзый, бер безнең балалар гына чемченми инде анда, бөтен авыл баласы шунда бара, нишләсеннәр бичаралар?

— Ярар, озын сүзнең кыскасы,— диде Мәүләви.— Хәзер үк тавык фермасына төш тә Рәхия урынында эшли башла, кара аны, кичкырын кереп карармын...

Шулай диде дә Мәүләви артына карамыйча капкага таба атлады, ләкин аның колагында Сәлимәнең кече малае елаган тавыш тагын берике йортны узганчы ишетелеп торды әле.

Шул ук кичне Мәүләви, әйткән сүзендә торып, тавык фермасына сугылды. Бу бина колхозның башка фермаларыннан бер читтәрәк тора иде, шуңа күрә Мәүләви килгәндә аның тирәсендә Сәлимәдән башка бер генә җан иясе дә күренмәде.

— Йә, ничек, барамы эш? — диде Мәүләви тавыкларга җим сибеп йөрүче Сәлимәнең шәрә балтырларына, алъяпкыч астыннан күтәрелеп торган мул күкрәкләреннән күзен ала алмыйча. «Монда чуртым да юк, хәзер үк хәл итәргә кирәк... Ире сугыштан кайтмады, әллә ни карышып та тормас бу»,— диде Мәүләвине котырткан дәрт.

— Әйдәле, йомыркаларны кая җыю, кемгә, ничек бирү һәм аны кая язып куярга кирәклеген күрсәтим,— диде ул Сәлимәгә.

Мәүләвинең баягы дулавыннан арынып бетмәгән Сәлимә берсүзсез аның артыннан иярде. Бергәләп тавык караучылар фураждыр-нидер сала торган бүлеккә керделәр.

Сәлимә кергәч, кем әйтмешли, аның бу эштә сакалы агарган иде инде. Мәүләви ишекнең келәсен төшерде һәм турыдан-туры:

— Син, Сәлимә, ярыйсы гына елдам хатын күренәсең, менә шушында тәмен белеп кенә эшләрсең... Балаларыңа да бирер йомырка булса да алырсың... Моның өчен мин синең яныңа кергәләрмен, яме,— дип хатынга якынрак килде, биленнән тотып алды.

Сәлимә Мәүләвинең кем икәнлеген, авылдагы кайберәүләрне нишләткәнен яхшы белә иде. Беренче мәлне, Мәүләви биленнән тотып алгач та (нибары егерме җиде яшь!) тәне чымырдап, чигәләренә кайнар кан йөгереп менгәнне тоеп алды. Ләкин шул ук минутта күз алдына Җирбулаты, аның сугышка чыгып киткән минуты килеп басты. Шул ук мизгелдә чигәсендәге кайнарлык бөтен тәненә салкын чирканчык булып чыкты, йөрәгә уелып төште. Әйтерсең, Җирбулаты аңа: «Нишләвең инде бу, Сәлимә җаным? Гомергә дә сиңа хыянәт итмәм дигән идең бит?» — дип эндәште. Сәлимә арткарак чигенде:

— Юк, Мәүләви абзый. Безнең балалар сугыш елларында кычыткан яфрагы һәм алабута белән яшәргә дә күнеккәннәр инде, синең колхоздан урлап алырга кушкан йомыркаларыңны ашый алмаслар алар. Бугазларына тыгылыр... Кагыласы булма!

Сәлимә ишеккә якынрак килде, keләне ычкындырды да тышка чыкты, аннары ферма бинасыннан авылга таба юнәлде.

Мәүләви Сәлимәне менә шушында, хәзерге күпер урынындагы агач күпер өстендә куып җитте. Атыннан төште, Сәлимәнен үзе белән өеннән алып килгән чиләген күпер тактасына куеп җикеренергә тотынды:

— Ах син, халык дошманы, ах син, сабакы, фермага төшеп җитмәдең, колхоз малын урларга керештеңме? Карагыз әле моны, карагыз... Әй, кемнәр анда, килегез әле, килегез дим тизрәк... Карак тоттым, килегез, шаһит булырсыз...

Алачык артыннан ике кеше килеп чыкты. Берсе Кандала Зәйдулласы, икенчесе клубта эшли башлаган яшь кенә егет.

— Менә күрдегезме,— диде Мәүләви күпер тактасында торган чиләккә күрсәтеп.— Бүген генә тавыклар янына эшкә җибәрдем, карагыз, күрегез әле мәльгунны, халык дошманын, ярты чиләк йомырканы эһ тә итмичә... Оятсыз!

Сәлимәне өенә җибәрмичә авыл советында бикләп куйдылар. Икенче көнне участковый милиционер — сыңар күзле Митяев килеп төште һәм тиешле актлар язылганнан соң «каракны» районга алып та китте. Шулай итеп, Мәүләвинең «җиңел кулын»нан Сәлимәне ике елга Ерак Көнчыгышка җибәрделәр. Сугышта һәлак булган Җирбулатының өч улы өй уртасында утырып калды...

Кояш инде күренми, ул Мәрҗән тавы артындагы урман эченә кереп югалган иде. Күк йөзе аяз, кичәге яңгыр болытлары күптәннән каядыр ерак-еракларга китеп югалганнар. Авыл өстендә ярыйсы гына бөркү һава эленеп тора. Мәүләви беренче тапкыр күрде: сыерчыклар инде бала очыралар, ләкин урманнарга алып китмәгәннәр икән әле.

Атлы килгәнне күреп, күпернең җәяүлеләр йөри торган тар күтәрмә сукмагына кучкән Сәлимә «Тпру!» дигән тавыштан ук таныды Мәүләви абзыйны. Чөнки Сәлимә аны үзләре янындагы Кушкаен чишмәсенә суга килгәнен ике көннең берендә күреп кала иде. Ләкин Сәлимә Себер урманнарында эшләп кайтканнан соң утыз елдан артык гомер эчендә Мәүләви белән бер генә тапкыр да исәнләшмәде. Хәер, ул гына да түгел, Мәүләви дә аның белән исәнләшмичә уза иде.

Мәүләвинең үз янына җитәр-җитмәс борын атын туктатып арбасыннан төшә башлавын күргән Сәлимә беркадәр гаҗәпләнебрәк, ирексездән диярлек туктап калды. Мәүләви аңа беренче булып эндәште:

— Исәнме-саумы, Сәлимә килен,— диде ул хатынның йөзенә күтәрелеп карамаска тырышып.— Ни хәлләрдә йөрисең, оныкларың үсәләрме?

— Яхшы гына, йөрибез әле бер көйгә. Оныклар да үселәр дисәң ярый. Олысы быел армиядән кайтты.

— Кит аннан, шундыйлармы? — дип гаҗәпләнде Мәүләви.— Ай-яй, бу гомер дигәнең, минәйтәм, Сәлимә килен, уза да китә икән...

— Шулай шул, Мәүләви абзый, гомер уза. Беркайчан да тузмас, тормыш дилбегәсе кулларыннан ычкынмас дип уйлаган кешеләр дә ычкыналар... Әле менә Яңа урамның Хәснурые очрады. Суга менеп бара. Шуның белән дә сөйләшеп тордык... Теге ни, Әгъләм абзыйны да санатурга киткән җиреннән кайтарганнар, ди. Йөрәгенә инфарктмы шунда, нәрсәме булган, ди... Шундый кодрәтле кешене дә егып салган инде...

Мәүләви калтыранып куйды. Күрәсең, чынлап та ерак йөрми иде теге дөньяга китәр вакытлары. Әгъләм бит әле ул Мәүләвидән бер-ике яшькә яшьрәк иде бугай...

Бу хәбәр Мәүләвине шулкадәр тетрәндереп җибәрде ки, ул хәтта бермәлгә Сәлимәне ни өчен туктатканын да онытыбрак торды. Ул арада күпер төбенә автомашина килеп туктады һәм түземсезләнеп Мәүләвигә кычкырта башлады. Шулвакыт Мәүләви Сәлимә янына ни өчен туктаганын исенә төшерде. Ләкин, ут чыккан диярсең, машина шоферы гудогын һаман ачы тавыш белән кычкырта иде.

— Син, Сәлимә, туктап тор әле, зинһар өчен. Минем сиңа әйтәсе

сүзем бар. Хәзер атны гына чыгарып куйыйм инде,— диде Мәүләви һәм дилбегәсен селкеп җибәрде.

Машина кап-кара тузан өермәсе туздырып узып китте.

— Син, Сәлимә, теге вакыттагы нәрсәләрне онытмыйсыңдыр инде...

— Ничек итеп онытасың ди аны. Өч балан, йөрәк парәңне япа-ялангач һәм ач килеш утыртып калдыр да...

Мәүләви ни әйтергә кыймыйча торды. Ләкин биредә озын-озак туктап торырга да ярамый иде. Авыл кешеләре беләләр бит Мәүләвинең Сәлимәгә кылган «игелеген», ни уйларлар?

— Син инде, Сәлимә, әгәр дә булдыра алсаң, бәхиллә мине, яшьрәк чак иде бит, күрәсең, влач кулга эләккәч тә чаманы...

— Юк, Мәүләви абзый! Еланның аның агына да ләгънәт, карасына да нәгъләт, ди халык. Узган эшне кузгатырга яратып ук бетермәсәм дә, онып алмыйм аларны. Күрмәгәнемне күрсәттең. Кабахәт син, Мәүләви абзый. Кешеләрне халык дошманы дип сүгә идең. Ләкин син үзең авыл халкының дошманы идең. Син авылга гына түгел, илгә дә дошман идең... Син безнең Җирбулатлар дөмектергән фашист мәльгуннарыннан да усалрак дошман идең. Кызганыч, синең чын йөзеңне ачучы булмады, мине түгел, сине җибәрергә иде ул тайга якларына... Сине, Мәүләви абзый, ит тураткыч аша үткәрсәләр дә бәхилләрлек түгел...

Әле өшетеп, әле пешереп-пешереп алган сүзләрдән котылыр өчен хәзер үк кузгалып китәргә кирәклеген чамалый Мәүләви, ләкин баскан урынына кадаклап куйганнар диярсең, кузгалып китә алмый иде. Ә Сәлимәнең берсеннән-берсе усалрак сүзләре аңа көтүченең озын чыбыркысы сыман кисеп-яндырып бәреләләр, кайчандыр бу авылда үзеннән дә көчлерәк кеше юк дип уйлап, ышанып йөргән Мәүләвинең тәне аша йөрәгенә үтеп керәләр, аны берөзлексез кыйныйлар...

* * *

Чишмә буенда кеше юк иде. Дөрес, чишмәдән арырак, су буендагы, үләнлектә казлар төркем-төркем булып утыралар. Кайсылары каңгылдаша-каңгылдаша утырган җирләреннән күтәреләләр дә ава-түнә атлап яңадан яр кырыена киләләр. Гаилә башлыгы — ата каз ярның иң текә төшенә килеп баса, янәсе ул үрнәк күрсәтергә тиеш. Һәм, чынлап та, «га-га-га» дип нәрсәдер әйтә дә канатларын җилпеп җибәрә, су өстенә барып төшә. Олы-олы каз булып үсеп җиткән бәбкәләр, беркадәр шаярышып алырга сәбәп чыкканга шатланып, аерата ярсулык белән күтәреләләр. Ләкин алар инде ярыйсы ук ит туплап өлгергәннәр, тиз генә очып китә алмыйча, канатларын җилпеп аталары янына суга төшеп бәреләләр. Кайсылары гына житезлек белән төшкән уңайга йөзеп-йөзеп китәләр.

Мәүләви боларның берсен дә күрмәде. Ул хәтта казларның төркем-төркем булып утыруларына, каңгылдашып елгага таба атлауларына, очып-мәтәлеп суга төшүләренә бөтенләй игътибар итмәде. Бу минутларда аның соңгы көннәрдә җанына тынычлык бирмәгән уйлары да әллә кая ерак-еракларга китеп югалган иде. Шуңа күрә Мәүләви үзенең чишмә янында икәнлеген күргәч кенә нәрсә эшләргә тиешлеген чамалап алды һәм, ничәмә-ничә еллар буена күнегелгән гадәтенчә, атын чишмә уласынын янына китереп бастырды.

Мәүләвинең күңелендә эчпошыргыч, алай гынамы, әллә нинди шомлылык өстәп торган бер бушлык хөкем сөрә иде. Битарафлык иде бу. Тик моны Мәүләви үзе аңламады, гомумән ул андый төшенчәләрнең дөньяда булуын, кемнәрнеңдер шуны атап сөйләшүләрен уена да китереп карамады.

Әмма аны ялгызлык, шомлылык дигән нәрсә куркыта иде. Шушы курку булса кирәк, ниһаять, аның бу минутларда катып калган ми җисеменә тәэсир ясады һәм ул кешене кеше иткән җисемнең кайсыдыр күзә-

нәкләре аша битарафлык халәтеннән чигенә төште. Мәүләви узган төннән соң беренче тапкыр: «Нигә бу Тавыш ишетелми соң әле?» — дип уйлап куйды, җилкәләрен җыера төшеп беркадәр күтәреп торды.

Тавыш ишетелмәде.

Әйтерсең, Тавыш шундый түбәнлеккә төшәргә, гадәттә исәнләшмичә дә узган кешеләр алдына барып: «Теге чактагы эшләрем өчен бәхиллек бирегез инде»,— дип сорарга мәҗбүр итмәде аны.

— Аһ син, халык дошманы, ах син, мәлгунь! — диде уйларлык сәләте кайтканны сизеп Мәүләви.— Җендер син, әллә нәрсәдер син, югыйсә кешене шундый хәлгә төшермәс идең... Әйе, әйе шул, сарыкның анын егылганы да күренми, дөянең сөрлеккәне дә күренә...

Үзен дөя итеп хис итеп алган Мәүләви тагын да нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин сәер халәт аны үзенә йомып өлгерде.

Мәүләви улак очына элеп куйган чиләгенең тулып ташуын, янәшәсендә басып торган атның чирәм чемченә-чемченә урыныннан кузгалып китүен, казларның яшь бозаулардан куркып бәрелә-сугыла елгага таба ыргылуларын да күрмәде. Ул бары тик Тавыш әйткәннәрне генә тыңлый, аның сүзләрен аермачык ишетә, әмма мәгънәсенең тирәнлеген барыбер төшенеп бетми иде. Баягы халәт Мәүләвинең тагын аңын томалый башлаган, күзләрен күрмәс, колакларын ишетмәс иткән иде.

Ләкин Мәүләвинең күндәм атында, кем әйтмешли, адәм акыллары бар. Ул чирәмгә никадәр генә үрелергә тырышса да, аркалыгы бушатылганга күрә, арба аумаслык түгәрәк ясап хуҗасы янына килде, аның хәрәкәтсез торуын, улакка эленгән чиләкнең күптән тулуын күреп, кабарынкы иреннәре белән Мәүләвинең җилкәсенә төртте...

* * *

Кушкаен чишмәсеннән ничек кузгалып китүен, авыл урамнарыннан кайткан чагында кемнәрнең очравын, аларның ни әйтүен берсен дә күрмәде-ишетмәде Мәүләви. Ниһаять, ул атының үз капкаларына төртелеп туктавыннан аңына килеп чынбарлыкка әйләнеп кайтты.

Мәүләви салмак хәрәкәтләр белән арбасыннан төшеп капканы ачты. Һәм бары тик шунда гына ишегалдының арткы өлешендә күләгәдә торган, урта бер җиренә кызыл хач төшерелгән аксыл төстәге «Рафик» машинасын күрде.

«Ыскурый пумыш» түгелме соң бу? Тагын нинди зәхмәт күземә күренә соң»,— дип уйлап алды ул һәм ашыгып барып әлеге машинаны «Чынмы бу, әллә чагылышмы?» — дигәндәй, кытыршы бармаклары белән капшап-капшап карады.

Әйе, бернинди дә чагым[1]-фәлән түгел, чып-чын машина иде бу.

Шулвакыт Кәрамиянең ачынулы елавы ишетелде:

— Йә инде, Мәүләви, нигә кереп күрмисең бердәнбер улыбыз Сәгъдулланы... Ике аяксыз килеш китергәннәр ләбаса!

Мәүләвигә әллә нәрсә булды. Ул өйгә улы янына керү, яки борылып килеп хатыны Кәрамияне тынычландыру урынына бичара атының тезгендилбегәсенә барып ябышты, аның иреннәрен авызлык тимере белән ертып-канатып, арбасын аударырдай дәрәҗәдә кинәттән малкайны борып алды.

Мәүләвинең кинәт котыруына аптыраган алаша яңадан капкага таба ыргылырга мәҗбүр булды. Үч иткәндәй, арт күчәр очы капканың имән баганасына эләкте. Никадәр генә көтсәң дә ул үзе ычкынмаячак иде, шуңа күрә ат мускулларындагы барлык көчне туплап киерелде һәм алга сикерде. Күчәр очы имән баганада эз калдырып, сыдырылып чыкты.

[1] Чагым — мираж.

Шуны гына көткән алаша кушаяклап чабарга кереште. Дилбегәсен тотарга өлгергән Мәүләвинең барлык сөякләре, эчке әгъзалары селкенәләр, тегендә-монда бәреләләр, тик ул аларны бөтенләй сизми, бары тик: «Тагын берәү кайткан, тагын берсе минем йөрәгемне телгәләргә, җанымны ашарга кайткан»,— дип уйлый һәм ирексездән: «Теге дөньяга озатасыз бит... Нигә мине бу кадәр газаплыйсыз, бәгырькәйләремне телгәлисез»,— дип әйтергә тырыша, әмма аның теле тамак төбенә ябышкан, авызыннан ниндидер бәйләнешсез һәм мәгънәсез авазлар тупламасы гына өзек-өзек булып чыга иде.

Мәүләви каеш камчысы барлыгын бөтенләй исеннән чыгарган иде. Алашасы сыртына дилбегәнең артып калган очы белән шапылдатып суга-суга иркенгә, Мүкле елга ягына бара торган басу юлына чыкты. Атны алга, карурман кочагына, ялгызлыкка таба ашыктырырга тырышты.

Унбиш-егерме минут үттеме, юкмы, Мәүләви урман буена барып җитте. Колхоз җәйләвенә алып баручы юлдан борылып, Якты Күл ягына таба китте. Биредә инде баягы хуш исләргә исәпсез үләннәрнең, алар арасында өлгергән кура җиләге, кара карлыган, җыелмыйча калган бөрлегән исен дә чамалап була иде. Ләкин, басудагы өлгергән икмәк исен тоймаган кебек, ул аларның сихәтләндерүче, кеше җанына ләззәт һәм сәламәт рух өстәүче көчен бөтенләй тоймыйча барды.

Уң яктагы урманга инде төн караңгылыгы иңгән, сул якта, әллә ни еракта да түгел, авыл утлары җемелдәп-җемелдәп күренә, теге яктагы басулардан ындыр табагына кайткан машиналарның утлары бирегә, шомыртлык урманына кадәр килеп җитә һәм искиткеч озын нур көлтәсе белән агач башларын сыйпап-сыйпап ала, төнге урманга серлелек өсти.

Ул да түгел, Мәүләвинең борынын ярып, әллә нинди начар ис кера башлады, тирә-юньдә баягы хуш исләр булмагандай югалдылар. Мәүләви башта аңышмыйча торган иде, аннары исенә төште колхоз басуының иң читендә, ләкин урманга кермичә казылган үләт базлары бар, ул шуларга якынлаша... Гадәттә, Мәүләви бу базлар янынан әллә ни игътибар итмичә, борынын җыебрак булса да узып китә ала иде. Әмма хәзер бу төштән тыныч кына үтә алмады. Уйламаган-көтмәгән җирдән Мәгафурның, аңа кадәр әтисе Риянның: «Убырут син, Мәүләви, үләт базы тирәсендә үсеп утыра торган, файдасызлыктан интегүче гапгади шайтан таягы»,— дигән сүзләре калыктылар.

Элеккеге Мәүләви булса, бу авыр хатирәләрне үзеннән ераграк куарга тырышыр, берәр усал сүз ычкындырыр, фәлән-фәсмәтән дияр иде. Ләкин бүген инде аның күкрәгендә моңа җитәрлек көч тә, дәрман да калмаган, мыскыллап таралып беткән иде.

Бу минутларда озын-озын усаклар, төз юкәләр, өрәңге һәм карамалар, шомыртлар, хәтта утрау-утрау булып үскән ап-ак каеннар да шомлы караңгылыкка күмелгән, үле тынлыкка чумган кебек иде. Ләкин Мәүләвигә шулай тоела гына, чынлыкта исә борынгы урман үзенең тулы канлы төнге тормышы белән яши, тирә-юньгә яфракларын коя, хуш исләрен тарата; янәшәсендәге борынгы авылда яңа уңышны җыеп алу көрәше бара, ындыр табагында яшьләрнең дәртле җырлары яңгырый. Анда инде хәзер Мәүләви карт узган тормыш түгел, бөтенләй яңа, үзгә тормыш шаулый һәм киләчәкнең Мәүләвиләрсез көннәре күренеп тора иде.

Шушыларның дөреслеген раслагандай, күктә көмешсыман ай калкып чыкты һәм авыл өйләренә, колхоз корылмаларына, күк йөзенә таба карап баккан сенаж башняларына, ындыр табагына, тау-тау өелгән ашлык өемнәре тирәсендә җырлый-җырлый эшләүче яшьләргә үзенең нурларын сибәргә кереште.

*1982—1983.*
*Чаллы — Дубулты*

## Мансур Шаһимәрданов

# ӨЧ ЧАКРЫМ ЮЛ

ХИКӘЯ



Тәслимә түти хәбәр көтә иде. Чак кына шылт иткән тавышка да сагаеп, тыңлана башлый ул. Менә-менә кемдер капканы ачып җибәрер кебек. Аннары түти хыялын эшкә җигә. Ишегалдында итекләрен каккач, ул кеше, баскыч сайгакларын шыгырдатып, болдырга күтәрелер, кармаланып ишекне ачар, әллә ничаклы салкын ияртеп, өйгә килеп керер, исәнләшер һәм: «Ай-һай, көне дә көне!» — дип, бияләен салып, кызарган уч төпләренә өрер, бармакларын угалар. Шуннан соң гына ул кеше кул сырты белән мыегындагы бәсләрне сыпырып төшерер, шатлык-куаныч тулы күзләрен түтигә төбәп:

— Тәки морадыңа ирештең бит, Тәслимә апа! — дияр. Әйе, шулай дияр. Аның әйтәчәгенә түтинең иманы камил. Карчык хәбәр китерәчәк кешенең исемен дә белә, изге китап сүзләредәй итеп, шул исемне еш кабатлый: «Гарәпшә!..»

Тәслимә түти бүген дә көнозын тәрәзәдән күзен алмый Гарәпшаны көтте. Елганың теге ягындагы авылдан җигүле ат чыккан саен алданды. «Бәлки әнә тегесе улдыр»,— дия-дия өметләнде, җанына туңарга ирек бирмәде. Шулай, күңеле белән яшь бала сыман очынып өметләнгән бер мизгелдә, түтинең тормышка мәхәббәт тулы күзләре стенадагы сурәткә тукталды. Ничәнче мәртәбә инде йөрәге тетрәнеп куйды: елганың теге ягындагы авылдан килен булып төшкән чагы хәтеренә килде. Җәй уртасы иде, ахры. Атна буе яуган яңгырдан соң дәррәү кыздыра башлаган кояш җир өстен инде тәмам катырып куйган иде. Юлларда, көзгедәй булып, эреле-ваклы күлдәвекләр җәйрәп ята. Гүя, катлы-катлы ак болытлар һәм зәңгәр күк җиргә төшеп яткан да, шул күлдәвеккә танавын төртеп эчәргә кыймый тора.

Һидият белән Тәслимәнең солы басуы буйлап җигүле атта җәйләүгә таба китеп барышлары иде.

— Булды, җитте,— дип сөйләнде Һидият,— йолдызларны күп санаттың, Тәслимә, инде бергә кушылып, дөньяның матурлыгын балалар белән күреп яши башларга вакыт!

Тәслимә башын артка ташлап тын гына көлде, аннары:

— Киләсе елга... шомыртлар чәчәк атканда, яме, Һидият! — диде шаяртып.

Тәслимә, чынлап та, биргән вәгъдәсендә торды. Туйны зурдан кубып үткәрделәр. Һәм, ниһаять, ике яшьнең йолдызлы кичләр, айлы төннәр, шаяру-бәхәсләшүләр, кызып китү һәм чак кына үпкәләшүләр белән тулы гомере, ике чишмәдәй бергә кушылып, тирән елгадай тын гына,назлы гына ага башлады.

Һидияткә эш төткәреп булмады. Тәслимә дә иреннән ким куймый иде. Һади каенатай бәхетле иде. Бибисара әнкәй дә иреннән ким сөенмәде. Көтү

---

Мансур ШАҺИМӘРДӘНОВ *(1950) — яшь язучы. Журналда проза әсәре белән икенче мәртәбә катнаша. Казанда яши.*

куа чыккач, хатыннарга киленен мактый. Яшелчә бакчасында кыярларга су сипкәндә дә ызандашларына: «Шөкер, әйбәт киленгә тиендек»,— дип сөйли.

Әмма бу тату тормыш озакка сузылмады. Көннәрнең берендә ил өстенә сугыш ябырылды. Тормыш елгалары кибә-корый башлады, чәчәкләр-гөлләр сулды, җирләр янып көйде, күкләрне төтен басты.

Бик күп асыл ир-егетләргә ияреп, Һидият тә сугыш сәфәренә чыгып киткән иде. Шул китүдән кире әйләнеп кайтмады. Һади каенатай да кайтмады. Бибисара әнкәй дә кыска гомерле булып чыкты. Шулай итеп, Тәслимә елга аръягындагы йортта берьялгызы торып калды.

Ә гомер дигәнең саллар шикелле агып үтә дә китә икән. Бүгенге көн дә үтте инде. Әнә, кояш байый. Гарәпша килмәде, ахры...

Тәслимә түти тәрәзә яныннан кубып китте. Күңеле борчулы, бимазалы иде. Бер-бер хәл булдымы икән әллә? Әмма бу сорауга ул җавап таба алмады.

Карчык ут кабызды. Чәйләр эчеп алды. Аннары, ак җирлеккә кыңгырау чәчәкләре төшерелгән чаршауны аралап, мич артыннан кабасын тартып чыгарды. Йон эрләргә кереште. Гарәпшаның хатыны, син оста эрлисең дип, күп итеп йон биргән иде. Кышкы озын төннәрдә артык ямансулап киткәндә бик ярап куя бу кул эше.

Тәслимә түти, моңаеп, мавыгып, озак һәм күп итеп эрләде йонны. Ниһаять, күзләрен йокы баса башлады. Түти караватка менеп ятты.

Карчык тирән итеп сулыш алды, күкрәк читлегендә гүя зур куыш барлыкка килде, кан тамырларында талгын гына дулкыннар тибрәнде. «Их, килде рәхәт заманнар! Әмма...— дип уйлады түти, соңгы елларда күргәннәрен, кичергәннәрен бер җепкә тезеп.— Кеше дигәнең рәхәткә чыдый алмый башлады хәзер: бер-беренә этлек арты этлек кыла, куенында үч, йөрәгендә явызлык йөртә. Ни өчен? Мае артыкка күрә. Элек без, станцадан чана тартып кырыгар чакрым кайтканда, бер-беребезгә игелек кылу турында гына хыяллана идек. Димәк, кешене кайгы-хәсрәт берләштерә. Тук тормыштан гарык кеше бәхетнең ни икәнен аңламый. Элек без, хәсрәт чикми акыл керми адәм баласына, дип җырулар җырлый идек. Ә хәзергеләрнең җырлары... Шуңа күрә дә олыны — олы, кечене кече итү бетте. Кем көчле — шул алга чыга, кемнең кулында — шуның авызында...»

Карчык көрсенеп куйды. Өй эчендә сәгатьнең ашыкмый гына текелдәве ишетелә иде. «Чикерткәләр дә сайрамый хәзер,— дип уйлады түти,— тараканнар да йөгерешми, чебеннәр дә кырылып бетте. Кыр казларына, кыр үрдәкләренә төшеп йөзәр күл калмады, булганнары да, төпләренә ләм утырып, саегып киптеләр, корыдылар... Элек күлләр тирән, балыклы, таллы, камышлы иде, сулары чиста иде. Элек халык бердәм иде. Хәзер халык таркалды да, вакланды да...»

Тәслимә түти чак кына терсәгенә күтәрелә төште. Тәрәзәдән тулы ай, аксыл күкнең бер чите, бәсәргән агачлар һәм елганың теге ягында берәнсәрән генә утлары белән туган авыл караеп шәйләнә иде. «Әнә безнең урам,— дип уйлады карчык.— Мин туган нигездә хәзер авыл советы... Елганың теге ягындагы авылга барып кайтыр өчен, өч чакрым юл үтәргә кирәк, чөнки турыдан күпер юк!»

Түти тәрәзәдән күзләрен алды, башын ипләп кенә мендәргә куйды. Шул күпер хакында булырга тиеш иде инде ул зарыгып көткән хәбәр. Бу хәбәрне аңа район советыннан Гарәпшә китерергә тиеш иде. Килмәде бит...

Карчык йоклап китте. Уянгач та, өй эченең салкынаюын тоеп, җылы юрган эченнән чыгарга иренеп ятты. Кояшның бакыр төбендәге нурлары тәрәзә бозларында сүрән генә булып җемелдәшә башлаганда исенә килде. Бүгенге көннең күңелсезлекләр алып килмәвен теләп, урыныннан торды. Нафталин исе аңкып торган чиста киемнәрен киде. Караеп ыржайган мич авызына сак кына иелеп, ут кабызды. Йөзенә ал шәүлә төште. Ачык һавада күп итеп утын яргач, әлегрәк әнис алмасыдай кызара торган иде аның бит урталары. Хәзер ничек икән? Яшь чагында аңа алма битле Тәслимә диләр иде...

Түти күлмәк җиңнәрен терсәгенә тикле сызганып юынды. Чиккән сөлге белән йомшак кына итеп сөртенде. Һидият көрәшеп алган тагын бер чиккән сөлге бар әле зур агач сандыкта. Анысы, күпер төзелеп беткәч, сабан туена сөлге җыеп йөрүче «никрут» егетләргә бирергә дип, адарынып куйды инде түти.

Карчык караватка болан сурэтле бэрхет келэм җэйде. Кызыл атлас тышлы дүрт мендэрен икешэрлэп ике почмакка куйды. Мендэрлэр өстенэ ак челтэр корды. Аннары күэс янына килде. Камырлар да матур булып кабарган икэн!

Менэ, соскыч белэн кисэү тотып, мич авызына иелде ул: кояшлы көнне талгын җилдэ тирбэлгэн кызыл чэчкэлэрдэй җем-җем итүче күмерлэрне чуенга тутырды, бөккэннэрне пешэргэ тезеп куйды, корымлы юшкэне башка ис тимэслек һэм шул ук вакытта мичнең җылысы да чыгып бетмэслек итеп кенэ япты. Аннары көзгедэй итеп агартылган самавыр тирэсендэ мэш килде. «Гарэпша уннардан да калмас инде ул; бэлки, иртэрэк тэ килеп җитэр эле, йөрэге түзмэс»,— дип юана башлаган иде, шул мизгел ян тэрэзэне кемдер шакыды.

Гөллэрне аралап, Тэслимэ түти тэрэзэгэ капланды: көмеш болытларны, ак тауларны, тагын эллэ нэрсэлэрне хэтерлэткэн кар бизэклэрен сулышы белэн эретеп, тышка күз салды — авыл советында җыештыручы Нэсимэ икэн — чаңгы белэн килгэн! «Сэвиттэ эшлэүчелэр, гадэттэ, йомышка-фэлэнгэ Нэсимэне чаптыралар»,— дип борчулы уйлап алды түти. Гүя шунда күк күкрэде, тау-ташлар ишелде, җир тетрэде, шул мэхшэр эчендэ кинэттэн Гарэпшаның чал мыегы, чак кына кәкрерәк борыны, ач яңагы һэм чулак кулына тоткан кызыл унлык күренеп китте. «Ышан миңа, Тэслимэ апа! Мин дэ башкарып чыкмасам, ул күпер эшен тагын кем генэ булдыра алыр!» — дип ант итэ кызмача гарип...

Карчык исенэ килде: «Хэзер... хэзер!..— дип, өстенэ киенэ башлады.

Капканың теге ягында, айның ундүртенче кичэседэй балкып, Нэсимэ басып тора иде. Нэсимэ гади генэ итеп киенгэн. Лэкин ул кирэк чакта кала ханымнарының да күзлэрен кыздырырлык итеп киенэ һэм табигать биргэн чибэрлегенэ тел-теш тидермэслек итеп кенэ бизэнэ дэ белэ иде. Нэсимэне авылда гадел булуы өчен хөрмэт итэлэр, чөнки ул тормышның җелеген суырып алырга җыенмый, кем эйткэндэй, күккэ сикерми, барына риза булып яши белэ. Аның кебеклэр инде унны бетерүгэ, калага китеп, эллэ кем булдылар, Нэсимэ эле һаман авылда — авыру энкэсен саклап ята.

Нэсимэнең көлэч йөзенэ карап: «Юк, бу пошаман хэбэр китермэгэн,— дип уйлады карчык,— авыр хэбэр китерсэ, кызның йөзе болай якты булмас иде». Һэм ул Нэсимэнең сэламен алды. «Шөкер, бер көйгэ кыймылдап ятам эле»,— диде. Аннары ул кызны өенэ чакырды.

Түти артыннан Нэсимэ өйгэ керде. Өй эченэ, тэмле булып, майда пешкэн ризык исе чыккан иде. Нэсимэ үзе дэ сизмэстэн төкереклэрен йотып куйды. Колагында салмыш Гарэпшаның: «Беренче сорт пешекче ул Тэслимэ»,— дигэн сүзлэре яңгырап киткэндэй булды.

Мех эчле курткасы белэн йон башлыгын чөйгэ элде кыз һэм аннары, өй эченең пакьлегенэ соклана-соклана, өстэл янына килеп утырды.

Тэслимэ түти исэ кызның яшьлегенэ, тазалыгына сокланды: шундый шэп кызның бүгенгэчэ кияүсез яшэп ятуына ачынды. Аннары: «Энисенэ бердэнбер бала шул»,— дип, нэтиҗэ ясап куйды.

Түти белэн кыз, кара-каршы утырып, чэйлэр эчэ-эчэ, тормыш, көнкүреш хэллэре турында җай гына сүзгэ керешеп киттелэр.

Карчык тыштан сабыр күренэ. Эмма аның күзлэре һаман Нэсимэдэ. Ул, эчтэн тынычсызланып, хэбэрнең тизрэк эйтелүен көтэ иде булса кирэк. Лэкин Нэсимэ, нишлэптер, ул хакта сүзне үзе башларга җөрьэт итми тора иде. Бераздан инде карчык түзмэде, серне чишэргэ вакыт икэнлегенэ ишарэлэгэндэй, Нэсимэгэ сорау бирде:

— Монда килгэндэ Гарэпшаны очратмадыңмы?..

— Кичэ кибет буенда күрдем. «Сул кулымны фриц өзеп алмаган булса, ул күперне күптэн саласы кеше идем инде мин», дип, ике бабай каршында күкрэк сугып тора иде.

— Э-э-э,— диде түти. Аннары: «Миннэн эҗэткэ алган унлыкны суга салып йөргэн чагы булган инде алайса»,— дип уйлый-уйлый, чокырына чэй агыза башлады.

— Гарэпша абыйга эйтеп яздырган гаризаңны...— диде Нэсимэ, түтинең текэлеп каравына уңайсызланып, күзлэрен алсу тырнакларына төбэп, һэм аннары, сүзлэрем ничегрэк тээсир итэр икэн дигэндэй, карашын янэ карчыкка төбэде.— Район советында тикшергэннэр дэ, гаризаның азагында: «Хэзер инде ерак юлга чыга алмыйм, аякларым үтереп сызлый, ике авыл арасына күпер салдырыгыз», дигэн сүзлэрнең астына кызыл белэн сызганнар да, кичекмэстэн чара күрергэ дип, авыл Советына җибэргэннэр...

Тәслимә түтинең күзләре очкынланды, яңакларына алсу төс иңде кебек. Ул хәтта эчә торган чынаягын куеп, берәр сүзне ишетмичә калмыйм тагын дигәндәй, тын алырга да куркып, Нәсимәнең авызына гына карап утыра башлады.

— Авыл советында...— дип дәвам итте Нәсимә,— астына кызыл сызган җөмләләрне хәтәр нәрсәләргә юрап бетерделәр. Һәммәсенең дә күңелендә тик бер генә уй: нишләргә? Бәйләнчек карчыкның бимазалавыннан ничек котылырга?

Нәсимә сүзләреннән бүленеп, чокырда калган чәен эчеп куйды да, дәвам итте:

— Совет әгъзалары бу мәсьәләне чишә алмыйча үзара пышын-пышын гына бәхәсләшкән арада, председатель аягүрә басты да: «Иптәшләр, Тәслимә апаны картлар йортына озатырга кирәк, минемчә»,— дип ташлады. Тегеләрнең тынып калуларын өнәмичә: «Өен сатып китәр, билгеле»,— дип өстәде. Шуннан соң калганнары да: «Шулай шул, шулай итәргә кирәк»,— дип, председатель сүзен хупладылар...

— И-и-и,— түти, Нәсимәнең сөйләп бетергәнен дә көтмичә, куллары белән битен каплады.

Карчыкның иңбашлары дерелди, арык тәне ток тоткандай калтырап-калтырап китә иде.

— Ни өчен...— дип үкседе түти.— Кемгә зыяным тиде икән соң минем...

Түтине юатырдай йомшак-иркә сүзләр әйтмәкче иде Нәсимә, әйтә алмады. Чөнки мондый чакта хәлгә кереп, кызганып әйткән сүзләрдән генә елаучының йөрәгенә җиңеллек килмәячәген ул аңлый иде.

— Картлар йорты кирәкми миңа,— дип дәвам итте карчык яшь аралаш.— Минем үз йортым бар ич. Күрәсең бит: яңа әле ул. Артистлар авылга килсә дә, гел миңа кертәсез бит. Яныма торырга һәр елны укытучы кызлар кертәм. Узган көз дә кертәсе идем, күпер булмагач, эшкә йөрергә ерак дип, килмәделәр. Салсыннар күпер!..

Нәсимә урыныннан купты:

— Сезең хөрмәтең өчен зур рәхмәт, Тәслимә апа...— дип киенә башлады.

Карчык эндәшмәде. Ул әле һаман, очкылык тоткандай, үкси иде. Бары тик Нәсимә чыгарга кузгалгач кына, урыныннан торып, кызның кулларын тотты, тутырып күзләренә карады: ни әйтергә теләде икән ул?!.

Елга буйлап китеп барганда инде Нәсимәнең дә күзләреннән яшь ага иде.

...Шулай итеп, Тәслимә түти алдына зур сорау килеп басты: нишләргә? Гомер иткән нигезне бөлдереп, һәр аткан таңда кояшның чыгуын сагынып каршы алган шушы әрәмәле су буйларын калдырып китсенме ул?!. «Китмим,— дип үз-үзен дәртләндерде түти, ниһаять.— Гомер кичергән нигеземнән бер карыш та... Әйе... менә... хәзер...» Шкаф тартмасын ачты, чүпрәк-чапраклар арасыннан бәләкәй генә төенчек тартып чыгарды. Сөйләнә-сөйләнә киенде, өй ишегенә йозак салды, капка тимеренә аркылы таяк куйды да, сукмак буйлап яр читенә килеп җитте.

Елганың теге ягында шау-шу иде. Анда мәктәп. Балалар.

«И, күпер булса!..— дип уйлады түти.— Мин ул балаларны өемә чакырып сыйлар идем. Балалар да, бу ялгыз әби дип, йомышымны тыңларлар иде...» Карчыкның күзенә яшьләр килде. Ничәмә-ничә еллар инде Тәслимә түти шундый хыяллар белән яши! Әгәр авыл советы рәисе Ханиев күперне җимертеп ташламаган булса, аның бу өметләре тормышка ашкан да булыр иде. Ә Ханиевнең күперне җимертүе — бәләкәй авылны зур авылга китереп кушкач та, Тәслимәнең күчәргә теләмичә, элеккечә үз нигезендә, теш-тырнагы белән дигәндәй, япа-ялгыз яшәп ятуына үч итеп иде. Күперне җимерткәч, Тәслимә көн саен өч чакрым үтеп эшкә йөри алмас, арыр, талчыгыр, түзмәс, өен сатып, колхоз үзәгенә күчеп килер, дип, фикер йөрткән иде Ханиев, әмма ялгышты. Тәслимә һаман күчмәде, эшен дә ташламады, пенсиягә чыккач та байтак еллар ферма юлын таптады. Ул чакларда әйбәт иде әле, биш ай буена юлны кыш кыскарта — елга өстенә боз ката. Ә менә берничә ел элек, нефтьчеләр бораулап киткән җирләрдән кайнар чишмәләр бәреп чыккач, елга өстенә кыш көне дә боз катмый башлады. Бик зур бәла иде бу Тәслимә түти өчен. Бу бәладән котылуның бердәнбер юлы — күпер иде. Әмма ул күперне, кирәксенсәләр дә, салдырабыз дип, зурдан кубып йөрүчеләр юк иде шул. Бер кулын фриц өзеп алган Гарәпша да баш төзәтергә акчасы булмаганда гына (матур апасының хәлен белер өчен, янәсе) килеп чыга һәм үзенең сукыр киңәшләрен биреп китә иде. Тәслимә түти, Гарәпшаның киңәшен

истә тотып, бер көнне куак таягына таянып, өч чакрым ераклыктагы авылга — советка юл тотты. Ханиев райүзәктән кайтып җитмәгән иде әле. Бер хатын исә, шәлме-нәрсәме бәйләп утырган төшеннән башын күтәрми генә:

— Син яшәгән җир совхозга керә бит хәзер, апа, күперне совхоз төзетергә тиеш!— дип сүзен бетерде.

— Әйтүләре җиңел дә, килеп-китеп йөрүләре авыр шул,— дип, түти аксый-туксый кайтырга кузгалды. Шулай да ул ун чакрымдагы совхозга барып, җитәкчеләрне эшләреннән бүлеп, күпер турында сүз кузгатып карады. Анда да аңа: «Ул төбәктә безгә күпер кирәкми һәм синең өчен генә күпер чаклы күпер салдыра алмыйбыз, син, инде иң яхшысы, давай, безгә үзең күчеп кил!» — диделәр.

«Ә мин анда күчеп нишлим... мине анда кем белә?— дип уйланып кайтты юлда түти.— Мине хәзер туган авылымда да оныттылар диярлек, елга бер генә исләренә төшерәләр, анда да каладан артистлар килгәндә генә...»

Колакка кыңгырау чыңнары ишетелде, балаларны дәрескә чакыра булса кирәк. «Һай, былбыл балаларыдай сайрашалар, бәгырьләрем!— дип уйлады карчык.— Их, күпер булса! Югыйсә, елганың теге ягындагы авылга кибеткә-мазарга барып кайтыр өчен генә дә...» Түти елмайгандай итте. Исенә совхоз җитәкчеләре әйткән сүзләр килеп төшкән иде. «Апа, яшәреңә кыен булса, монда күчеп кил», имеш. Җүләрләр! Җәннәтне ташлап кем тәмугка керсен, әкәмәт! Гарәпшә да шулай ди. Туган нигеземне онытмадым мин, кайтып, өй салып яшәячәкмен әле, ди. Гөрләтеп эшләргә яшьлеге, балта-пычкы тотарга ике кулы булмаса да, дәртләнә бит картлач. Күпер генә салсыннар, имеш. Күперне салсыннар өчен яздык ич инде без ул язуны...

Тәслимә түти учы белән күз яшьләрен сөртте. «Бөтен өметем төенчектә!» — дип уйлады ул һәм туры сукмактан тау төшә башлады.

Авыл советына килеп җиткәндә төш авышкан иде инде. Ханиев, өенә кайтырга дип, кабинеты ишегеннән чыгып килә иде. Елап күзләре кызарып беткән түтине күргәч, Ханиевнең йөзен кара болыт баскан сыман булды. «Бу карчык хәзер аһ-зарларын түгә, күз яшьләрен агыза башлаячак»,— дип уйлады ул. Аны өендә хатынының абыйсы (Мәскәүдән кайткан) көтеп утыра иде. Ул электрон сәгатенә карады һәм тиз-тиз генә:

— Бүген кабул итмим, эш сәгатем чыкты,— диде.— Иртәгә килерсең, апа, иртәгә, ишетәсеңме!

Түтинең хәле китте, күз аллары караңгыланды: егылмасам гына ярар ие, дип торганда, түр бүлмәдән Нәсимә чыкты.

Ханиев ни өчендер аклы-кызыллы булды.

— Үзе гаепле!— диде ул, кесәсенә салып куйган ачкычларын кире чыгарып.— Үзе кибеп корышкандай үҗәт булгач соң!..

Ханиевнең фирәзә кашлы алтын йөзек кигән бармаклары сизелер-сизелмәс кенә дерелди иде.

Эчкә уздылар.

Идәндә зәңгәр сызыклы кызыл палас. Кыйммәтле мебель. Ханиев чит илдә эшләнгән өстәл артына кукыраеп кереп утырды. Иреннәрен бөрештереп, мыекларын күпертеп, тартмадан ниндидер кәгазьләр алды да, түтинең борын төбенә китереп тотты:

— Картлар йортына җибәрәбез сине... Менә документлар тутырылган инде. Картлар йортына, аңладыңмы!

Тәслимә түти аяклары астындагы идәннең чайкалып китүен тойды. Егылып китүдән аны Нәсимә генә тотып калды.

— Юк, юк, дөрес әйтмисең, ялганлыйсың, Җаһид!— диде Нәсимә.— Апаның ризалыгы юк, син аны берничек тә картлар йортына җибәрә алмыйсың!..

Нәсимәнең соңгы сүзләре түтигә шифалы тәэсир итте. Ул тураеп басты. Куеныннан төенчек тартып чыгарды да председательнең алдына куйды. «Өендәге бөтен документ-кәгазьләрне җыеп килгән инде бу!» — дип уйлады рәис. Шуңа төенчеккә орынмады.

— Нәрсә бу?— дип кенә сорады.

— Акча!— диде түти.— Күпер салдырырга сезнең акчагыз юк икән дип, ишеттем. Монда минем гомерем буе эшләп җыйган акчам: салдырыгыз күпер!

Ханиев тиз генә җавап бирмәде. Баш бармагын чигәсенә терәп, уң кулына тоткан ручкасы белән өстәлне шакый-шакый уйланды: «Карчык бик белеп әйтә, безнең акчабыз юк. Дөрес, бар, ләкин ул аз. Әнә, икенче ел инде авыл

советы бакчасының рәшәткәләрен сырлап-бизәкләп эшләтә алмый изаланам. Инде тирә-юньдә бер дигән останы да таптым. Әмма бәяне кыйммәт сорый.— Һәм ул түтигә карап куйды, аннары түенчеккә күз төшерде.— Әгәр дә бу акчаларны шул изге эш өчен сарыф итсәк, ә?!.— дип, хәтта шатлыгыннан кулын кулга сугып куйды. Аннары бик тәкәллеф белән, йомшак кына итеп, карчыкка сүз катты. Түти исә якын да килмәде:

— Юк, күпер салдырыгыз, бары тик күпер генә салдырыгыз,— дип, үз сүзләрен өскә чыгара торды.

Ниһаять, Ханиев:

— Ярый алайса, балта осталарын ялла да, ул күперне үзең салдыр!— дип, урыныннан торды.

Тәслимә түти председательнең каршына ук килеп басты.

— Риза булмыйлар шул, авыл советының рөхсәте кирәк, диләр. Алайса, Җаһид энем, күпер салу өчен рөхсәт кәгазе бир миңа!

— Андый кәгазьне мин бирә алмыйм,— диде Ханиев кырт кисеп. Һәм, кабул итү сәгате чыкканлыгын аңлатып, ачкычларын кулына алды.

Тәслимә түти бары тик зират буена җиткәч кенә исенә килде. «Кара инде бу Җаһидне, бигрәк тә юньсез икән!»— дип, шәл чите белән күзендәге яшьләрен сөртте.

Өенә кайтып җитте дигәндә караңгы төште. Ул тәмам эштән чыгып арган иде. Чәй дә кайнатып тормады: көчкә урын җәйде дә салкын юрган эченә кереп ятты.

Тәрәзәдә томан, томан... Елга да, теге яктагы авыл да күренми: буран купкан иде.

* * *

Буран төнозын котырды. Нәсимә, керфек тә какмыйча, җил-давыл тавышына колак салып, уйланып чыкты. Тәслимә түтине кызгана иде ул. Торып әнисен карады: әни кеше тигез сулыш алып йоклый. «Юк, Тәслимә апаны картлар йортына җибәрттермим,— дип куйды кыз.— Күпер белән эш барып чыкмады инде... Иң дөресе — Тәслимә апаны үзебезгә яшәргә алып кайтам. Әни каршы төшмәс әле».

Бу төнне Гарәпша да йоклый алмады. Махмырдан тубал булган башын юеш сөлге белән урап, ах-ух килеп йөрде. Намусы газаплый иде аны. Әйе, белде бит ул шулай булачагын, барысын да алдан сизде, әмма Тәслимәдән бу дөреслекне яшереп, эчәргә акча алу өчен, алдашып йөрергә мәҗбүр булды. Ниһаять, абзый: «Тәслимәне үзебезгә чакырам,— дип уйлады.— Кыз кияүгә киткәннән соң бушап калган бүлмә бар, шунда яшәр! Ә хатын? Хатын нәрсә ул, монда әлегә мин баш!..»

Җаһид исә чибәр хатынының җылы куенында тыныч үткәрде бу төнне. Таң атты. Буран басылган иде. Җаһид хатыны белән эшкә китте. Мәктәп янында хатыны аннан аерылып калды.

Тыкрыктан килеп чыккач, авыл советы каршында Нәсимәне күрде.

— Җаһид, районнан шалтыраттылар, артистлар килә икән. Нишлибез, аларны шул Тәслимә түтигә урнаштырабызмы?— диде кыз ашыга-ашыга.

— Шуңа булмый тагын кая булсын! Нәрсә, бу юлы киреләнер, дисеңме?

— Белмим, Җаһид. Тик мин Тәслимә түтигә ул сүз белән баралмыйм, үзең сөйләш.

— Бар, алайса, чакыр Гарәпшаны, ат җиксен, үзем сөйләшәм карчык белән.— диде Җаһид.

Ат яшь, таза һәм йөгерек иде. Тиз килеп җиттеләр.

Капка аша атлап, өйалды ишеген күмгән карны көрәп бетергәнче, Җаһид белән Нәсимә кара тиргә баттылар. Бу вакытта сыңар куллы Гарәпша абзый арлы-бирле йөренеп торудан, атка печән каптырудан башка нәрсәгә ярамады.

Ниһаять, эчкә үттеләр.

Тәслимә карчык, ахрысы, ишеген кар басканга гаҗизләнеп йөргән-йөргән дә, инде юрганына күмелеп, караватта ята иде. Ханиевкә эшне ничек тә җайларга, карчыкның күңелен күрергә кирәк, шуңа күрә ул өй эчен яңгыратып сәлам бирде. Карчыкның үпкәсе бик зур күрәсең, боларга таба әйләнеп тә карамады. Нәсимә, каударланып, аптыраулы кыяфәт белән түтигә таба иелде, аның кулына сак кына кагылды. Гарәпша абзый гына бу минутта, нидер сизенеп, бусагага утырды.

Тәслимә түтинең тәне урамдагы кар кебек салкын иде.

# МАНСУР ШАҺИМӘРДӘНОВ ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА

Бу хикәяне укый башлагач ук сизеп аласың: авторның беренче тапкыр гына каләм тибрәтүе түгел. Яхшы ук шомарган, азмы-күпме тәҗрибә туплаган кул белән язылган әсәр безнең алда. Темасы белән дә хикәя игътибарны тиз яулап ала. Сугышның беренче айларында ук тол калган, инде ничәнче дистә еллар буе күңелләре тулы һич төзәлмәс-бетмәс моң-хәсрәт эчендә яшәүче фидакарь килен-җиңгиләребез (хәзер инде әбиләр) турында хикәя. Дөрес, бу темага инде әсәрләр аз язылмады. Ләкин сүз меңнәр-миллионнар хәсрәте турында бара икән, бу турыдагы моңлы җырның да агудан туктар чиге буламыни?!

Укый торгач, хикәянең халык күңелендәге тагын бер яраны кузгатканын белеп алабыз. Тәслимә карчык инде бетеп бара торган авылда берьялгызы яшәп ята икән. Аны яшь гомереннән үк моң-сагышлы һәм газаплы тол тормышка дучар иткән сәбәп ачык — мәңге ләгънәтле сугыш. Ә менә Тәслимә карчыкны картлык көнендә авылдашларыннан аерып ялгызлыкта калдырган сәбәп нәрсәдә? Бу сәбәп инде — безнең үз арабызда. Ул — гамьсезлек, мәнсезлек, кеше кадеренең соң чиктә кимеп калуы, бюрократизм, әхлак һәм кешелеклелек кануннарының түбәнәюе.

Күрәбез, хикәя гаять мөһим һәм актуаль темага язылган. Ләкин, мәгълүм булганча, әсәрнең әдәби кыйммәтен әле теманың актуальлеге генә бәһали алмый. Шул мөһим һәм актуаль теманы автор ни дәрәҗәдә сәнгатьле итеп күрсәтә алган да, үз сүзен ничек итеп әйткән?

Бу сорауга өзеп кенә җавап бирүе кыен. «Менә, ичмасам, язып караган!» дип тел дә шартлатып булмый, яисә: «Әй, билгеле нәрсәләр ич инде болар!» дип кул да селти алмыйсың.

Шулай да хикәя укучының күңел кылларын әллә ничек кенә тибрәтеп ала. Әйдәгез, аның битләренә тагын бер кат күз салыйк әле, кайсы төшләрдә тибрәнде икән күңел кылларыбыз? Тәслимәне гомер иткән нигезен ташлап колхоз үзәгенә күчеп килергә өндиләр. «Җәннәтне ташлап, кем инде тәмугка керсен, әкәмәт!» — ди карчык. Күпләр күңелендәген чагылдырып, нәкъ халыкча әйтә дә бирә. Ул зур авыл ерак та түгел — елга аръягында. Мәктәп исә бөтенләй якын — яр буенда ук. Балалар шау-шуын, кыңгыраулар чыңлавын Тәслимә көн саен тыңлап, ишетеп тора. «И күпер булса!.. Мин аларны өемә чакырып сыйлар идем. Балалар да эшләремне эшләшер иде», — дип хыяллана карчык. Ләкин арада күпер юк... Күпер юк, әйләнечтән өч чакрым юл. «Хәзер инде ерак юлга чыга алмыйм, аякларым үтереп сызлый, ике авыл арасында күпер салыгыз», — дип, карчык инде район советына гариза юллаган. Район советында бу сүзләрнең астына кызыл белән сызып, кичекмәстән чара күрергә дип, авыл советына җибәргәннәр. «Чара күрергә» дигән күрсәтмә бирелгән — өстән бурыч төшкән. Авыл советында «чара күрәләр»: Тәслимәне картлар йортына озатырга карар кылалар... Рәсми яктан караганда, аларның бу эше дөрес кебек. Әнә шул «дөрес» карар, укучыга мәгълүм, кеше гомерен нинди фаҗига белән тәгәлли.

Менә ни өчен бу әсәр укучыны битараф калдырмый.

Хикәянең, әлбәттә, канәгать калмаслык урыннары да бар, дидек. Иң беренче, Тәслимә карчык язмышын фаҗигагә китергән бюрократизм күренешләрен үзендә конкрет чагылдырган Җаһил Ханиев образы һич тә тиешенчә эшләнеп житмәгән. Аның тискәре образ икәнен без беренче очрашуда ук сизенеп, шунда ук күреп алабыз. Менә, Тәслимә карчыкны күрүгә, Ханиевнең «йөзен кара болыт басты». Менә ул: «Бу карчык хәзер аһ-зарларын түгә, күз яшьләрен агыза башлаячак», дип уйлап куйды. Аның Тәслимәгә беренче сүзе: «Бүген кабул итмим, эш сәгатем чыкты. Иртәгә килерсең, апа, иртәгә, ишетәсеңме!» Тагын: «Картлар йортына җибәрәбез сине, менә документлар җыелган, картлар йортына, аңладыңмы?!» һәм «усал итеп елмайды». Менә ул урынына «кукраеп кереп утырды». Мондый ачыктан-ачык күренеп торган кара буяуларны автор Ханиев образына шактый мул сала.

Үзеңнең дә күзәткәнең бардыр, Мансур, тормышта бит хәзерге бюрократларны һич тә алай беренче күрүдә үк танып ала алмыйсың. Аларның йөзен алай ук «кара болыт» басмый; киресенчә, бик тә мөлаем елмаялар алар, йөрәгеңә сары май булып ятардай бик дөрес сүзләр генә сөйлиләр. Тагын әле кырыкмаса-кырык төрле битлек киеп алган була алар. Ә син укучыга әзер-кире образ бирәсең, шуның белән тормыш һәм әдәби дөреслеккә каршы киләсең. Тормыш дөреслеге — әдәбиятның иң көчле коралы. Моны аз гына да исеңнән чыгара күрмә, Мансур!

Әдәбиятның төп коралы булган сүз турында да әйтеп китмәсәк, безнең әңгәмә һич тә тулы булмас. «Хикәяңнең теле әйбәт кенә, ләкин...» кебек бу уңайдан еш ка-

батлана торган мөһер сугарга һич җыенмыйм. Әмма, хикәяне укый башлагач ук, «түтинең иманы камил», «илаһи бер мәртәбә», «изге китап сүзләредәй итеп», «тормышка мәхәббәт тулы күзләре» кебек тәгъбирләргә очрап, мин сагаеп калдым. Кыскасы, сүзләрне һич тә җитәрлек уйлап тормастан файдалану әсәрдә логикасызлыкны тудыра, образ бөтенлеген җимерә, әнә шул илаһи сүзләрне урынсыз файдаланып, без аларның олуг мәгънәсен никадәр кадерсезлибез. Хикәядә урынсыз килеп кергән сүзләр генә түгел, озын-озын ялгыш җөмләләр дә бар. Сугыш башлануын син: «...Чәчәкләр-гөлләр сулды, җирләр янып көйде, күкләрне төтен басты»,— дип тасвирлыйсың. Татарстан җире өчен мондый күренеш тудыруның мәгънәсез икәнлеген раслап тору кирәк микән? Әлбәттә, мин хикәянең беренче — редакциягә тәкъдим ителгән вариантын укып фикер йөртәм. Хикәя, бәлки, редакция хезмәткәрләре тарафыннан бераз гына үзгәртелер. Әмма бу язмам бер синең өчен генә түгел, башка яшь каләмдәшләремә дә файдалы булыр дип уйлап калам.

Ә менә хикәяңдәге бер образ — сугыш инвалиды Гарәпша образына ныклап тукталасы килә. Баштарак ул үзенең буш вәгъдәләре, «Сул кулымны фриц өзеп алмаган булса, ул күперне күптән саласы кеше идем инде мин»,— дип, кызмача баштан күкрәк сугулары белән укучыда әле тискәре хис уята. Әмма хикәя ахырына таба аның сизгәнбелгән хәлдә Тәслимәне алдап йөрүе өчен вөҗдан газабы кичерүе, «Тәслимәне үзебезгә чакырам. Ә хатын? Хатын нәрсә ул, монда әлегә мин баш!» дигән карарга килүе укучы фикерен үзгәртә дә куя. Тагын бер уңышлы деталь: Тәслимә карчыкның көрт күмгән ишеген күрәп кергәндә «...сыңар куллы Гарәпша абзый арлы-бирле йөренеп торудан, атка печән каптырудан башка эшкә ярамады». Әнә бит, үз күзәтүләреңә таянган, уңышлы кулланган детальләр образны никадәр җанландыралар, хикәянең эчке мәгънәсен никадәр арттыралар. Гарәпша — гәрчә ул әсәрнең төп герое булмаса да, хикәядә иң уңышлы образ.

Хикәянең «Өч чакрым юл» дигән исеме уңышлы димәс идем. Тәслимәнең картлык көнендәге ачы язмышына, күргәнебезчә, гаделсезлек, кешеләргә игътибарсызлык, кеше кадере булмавы, бюрократизм сәбәпче. Ә бюрократизмның асылы җитәкчелекнең гади хезмәт халкыннан аерылган булуыннан гыйбарәт. Хикәядәге вакыйгага якынрак итеп әйтсәк, бюрократизм җитәкчелек белән хезмәт кешесе арасындагы күңел күперен аяусыз җимерә. Шуңа күрә дә хикәяне гади генә итеп «Күпер» дип атау отышлырак булмасмы? Аннан соң, А. Гыйләҗевнең «Мең чакрым юл»ын кабатлауга да охшый төшә хикәянең бу исеме.

Әйтергә теләгәнемне А. П. Чехов сүзләре белән очлап куясым килә. «Язарга өйрәнү — артыгын сызарга өйрәнү ул», дигән Чехов. Әйе, сызудан, бозудан, кабат-кабат язудан курыкмаска, иренмәскә кирәк. Яхшы әсәр, гел эзләнсәң, ныклап эзләнсәң генә туа. Сер итеп кеңә әйтим, Мансур, минем дә, менә кырык елдан артык инде, сызарга-бозарга һаман да өйрәнеп җитә алганым юк әле. Сиңа уңышлар телим.

**Рафаил ТӨХФӘТУЛЛИН.**

## ПУБЛИЦИСТИКА

**Мәрди Рафиков**

# БҮДӘНӘ ГЕНӘ ЕЛЫЙМЫ?

Сыек болытлар, язгы йомшак җил исә башлау белән, таралып, юкка чыкты. Кояш ялтырады. Борынга җылы туфракның хуш исе бәрелде. Шушы мизгелдә әй бер ләззәтләнәсе иде дә... Ләкин юл авыр, баткак.

Елга үзәнлеген көч-хәл белән үткән машинабыз, бөтен егәрлеген җыеп, өскә үрмәли башлады. Шофер, мыеклы яшь егет, үзалдына сөйләнә һәм рульне уңгасулга боргалый текә урыннарда, газга басып, машинаны үкертеп-үкертеп ала. Безнең белән ерак колхозга барырга чыккан ханым андый чакта уфтанып куя, шомланып ишек тоткасына ябыша.

Тау өстенә азапланып мендек. Юл моннан түбәнгә таба китә, калкулыклар арасыннан йөгерә. Аяк асты да бераз кипшергән кебек. Ләкин ерак китәргә насыйп булмады: машина туктап калды.

— Бензинны ашап бетердек,— диде шофер, гаепле кеше кебек.— Көтәргә туры килә.

Күлдән ерак түгел генә туктаганбыз икән. Калкулыклар арасында югалып калган сулыктан тирә-якка өзлексез бакылдаган тавышлар тарала, бу авазлар, ниндидер шаушуны хәтерләтсәләр дә, язгы һавада дәртле һәм аһәңле булып ишетеләләр иде.

Беренче булып кысынкы күзле, киң битле, өстенә зәңгәр куртка кигән агроном егет телгә килде. Ул няге белән күлгә ымлады да:

— Көннәр утырыр, бакалар туй башлаган,— диде. Бу гади генә әйтелгән хәбәр юлдаш ханымны ифрат кызыксындырды бугай, ул, күзләрен очкынландырып, төпчешә башлады:

— Баканың туе буламыни?

— Әле ничек кенә!

Язгы бу тамаша турында сөйли-сөйли агроном күңелләребезне тәмам кузгатты. Узучы автомашинадан бензин теләнү-юнәтү өчен шоферны юлда калдырдык та өчәүләп күл буена төшеп киттек.

Чын басу күле. Тирә-ягында кәсле чирәме дә юк. Су читеннән үк — балчык башлана. Андагы ерганакларга караганда, явым-төшем һәм кар сулары шушы күлгә ага. Мондагы язгы тормыш бигрәк кызык.

Туй күлнең сайрак җирендә, иске камышлар һәм суүсем калдыклары арасында бара. Ямь-яшел зур-зур бакалар, чирәм өстендә әүмәкләшеп уйнаучы малай-шалай кебек, гаҗәеп тамаша оештырган: шаяралар, сикерешәләр, йөзәләр. Тавышлары колак пәрдәсен яра: берсе «ба-ка-ка» дисә, икенчесе «какак» дип куя. Дистәләгән, йөзләгән бакадан гаҗәеп хор хасил була. Мәгънәсез генә дә бакылдамыйлар бугай, чөнки артларында коры үлән сабакларына беркетелгән кара тимгелле, лайлалы «тастымаллар» кала. Алар су өстендә чайкалалар, әмма, үләнгә беркетелгәнгәдер, үз урыннарында калалар. Бакылдыклар уылдык чәчә. Бу күл — шушы җан ияләренә табигать бүләк иткән бик уңай сулык.

Машинага яңадан утыргач та сүзебез гел бака туе турында булды. Калган юлны гәпләшеп үткәрдек. Нигә шау-шулы, ыгы-зыгылы җыеннарны бака туе белән чагыштыралар? Нигә күл хуҗаларының үзләренчә ләззәтләнүләрен ямьсез сүз боткасына тыкрылар? Башка шундый уйлар тула иде, чөнки бу күл күренеше безнең күңелләргә хуш килде.

Кабат бер елдан, уракка төшәр алдыннан, юл уңаенда күлгә тагын сугылган идек. Күл моңаеп калган кебек тоелды. Су өстендә ямь-яшел бака шәле чайкала, башка суүсемнәр дә бар. Ләкин күлнең төп хуҗалары юк. Ник берсе чупылдасын!

Соңрак белдек: мондагы басуларга аммиак суы керткәннәр. Яңгыр сулары исә күлгә

аккан, агулаган. Бака күлендә тормыш беткән. Яңа тормыш кайчан килер? Килерме? Яңарырмы?

Апас белән Каратун арасында, олы юл буендагы түгәрәк күлдә дә шундый хәл булган иде бит. Аммиак эретмәсе күлгә эләккән, су өсте үле кәрәкәләр белән тулган иде. Тончыкканнар, харап булганнар. Йөрәк әрнерлек хәл иде бу.

• • •

Без кайчак, үзебез дә уйламыйча, табигатькә карата әллә нинди акылсызлыклар эшләп ташлыйбыз, шул ук табигатьнең үзеннән ачы сабак алганчы, кылганнарыбыздан канәгатьләнеп йөргән булабыз.

Безнең җирне шифаландырган гумуска (уңыш бирүче, файдалы катлам) баеткан тирес-черемәбез бар иде. Аны икенче планга калдырып, минералларга табына башладык. Хәзер химия промышленносте крестьян ихтыяҗын канәгатьләндерергә омтылып, елга утыз миллион тоннага якын минераль ашлама чыгара. Уңыш белән туфрактан никадәр гумус суырабыз. Аны химия белән генә тулыландыра алмыйсың. Белгечләр хәзер үк инде туфракның минераллаша баруы турында сөйлиләр. Бу уфтану яки сыкрану түгел, бу — сагаю, кисәтү. Ләкин һаман «алга барабыз»: күп микъдарда сыек ашламалар кулланугa ирештек. Ә нинди мал ул, әйтик, аммиак суы?

Аммиак суы игенчегә герметик вагон-цистерналарда килә. Противогазлар киеп бушаталар. Апас агрохимиклары Каратун тимер юл станциясендә саклагыч төзеп куйдылар: җитмешенче еллар башында ул 350 тонналык иде, хәзер өч мәртәбә артты. Колхоз басуларына да ундүрт мең тонна аммиак суы сыешлы баклар куйдылар. Аны басуга сиптергәндә, элек тургай җырын тыңлап, ләззәтләнеп эшләргә күнеккән тракторчы егет көннәр буе противогаз киеп эшләргә мәҗбүр. Ашламаны туфракка шулай кертәләр. Ләкин ул җилдә буланып оча. Җан иясен тончыктыра. Уңыш шулай кыйммәткә төшә.

Игенче өчен генә түгел. Табигатьне дә корыта. Тимер юлчылар Апас агрохимикларына карата дәүләт арбитражында дәгъва кузгаттылар. Чөнки станция җирендәге саклагыч куркыныч була башлады. Аммиак суы эссе һавада булана, тирә-юньдәге үсемлекләрне, җирне көйдерә. Җил белән шактый еракка исүе, төзәлмәслек зарар китерүе мөмкин. Урман тезмәләре белән нәкъ шундый хәл килеп чыккан. Зур мәйданда юл сагында торган бик күп агачны утсыз-ялкынсыз «дөрләткәннәр». Андагы җир дә озак елларга сафтан чыккан. Якын-тирәдә ялгыш кына да кош, хәтта чикерткә тавышы да ишетмисең. Үле җир! Ә андый саклагычлар бихисап. Җавап бирүче генә юк. Аммиак базасының тимер юлның яшел зонасында, торак йортлар, предприятиеләр янәшәсендә кем кушуы белән төзелүен дә төгәл белмиләр. Күренеп тора: табигатькә карата битараф яшәргә, җаваплылыктан качарга күнегеп киләбез. Иң беренче әхлакый җаваплылык турында онытa башладык. Үзебез противогаз киеп эшлибез, ә башкасын санларга да теләмибез.

Шушында тирән бер сулыш алыйк та узганебезгә сәяхәт кылыйк. Әйтик, печән һәм урак өстенә бөтен авыл белән ихлас күңелдән әзерләнә идек. Әле аның чүп утау кебек киеренке чагы да бар иде. Игеннәр тишелеп, буйга киткәч, яше-карты кырга чыга, рәткә басып, басу иңләп утә. Чүп үләннәрне шулай юк иттеләр. Чүп үләннәренә каршы чәчү әйләнешендә дә биологик ысул белән көрәштеләр. Чөнки кешеләр саф күңелле, табигать бөтенлегенә, чисталыгына битараф карамыйлар иде. Ә иген арасында вак чебиләре белән йөргән асыл кошларны күрү нинди сөенечле иде.

Хәзер башкача. Табигатькә индустриаль цивилизация һөҗүм итә. Басуда чүп утап йөргән элеккеге крестьянны техника һәм химия алыштырды. Шушы куәт белән табигатьне авызлыкламак булабыз, ә ул үз законы белән безгә удар артыннан удар ясап кына тора.

Менә гыйбрәтле һәм күңелгә борчу сала торган бер документ:

«Апас районы ветлабораториясе, «Восход» колхозыннан китерелгән сенажны токсикологик тикшерү нәтиҗәсендә, аның килограммында «2,4-Д» калдыгы 0,25 миллиграмм булуын, бу азыкның сөт терлекләренә ашатырга ярамавын хәбәр итә.

Ветлаборатория мөдире Ф. Гайнетдинов.»

Бу хатны район Советы башкарма комитетына җибәрәләр. «Ульянково» колхозыннан тикшерүгә китерелгән кукуруз силосында да агу калдыгы нормадан өч мәртәбә күбрәк булуы ачыклана. Тагын чаң кагарга туры килә: басудан алынган продуктларда азотлы тозлар күбәйгән.

Менә тагын бер документ:

«Ульянково», «Восход», Киров исемендәге колхозларда сөт һәм сөт продуктларын, Подберезье май заводында майны тикшерү нәтиҗәсендә, сөт һәм сөт продуктларында «2,4-Д» булуы ачыкланды.

Карар бирдек: Киров исемендәге, «Восход», «Ульянково» колхозларыннан Подберезье май заводына сөт кабул итүне туктатырга.

Баш санитар врач М. Гыйниятуллин».

Токсикологик лаборатория безнең акылсызлыкка менә нинди хөкем чыгарган. Ярый әле сизгерлек күрсәткәннәр, юкса, агулы ризыкларны кулланып, кеше сәламәтлеген куркыныч астына куяр идек!

Шундый хәлгә җиттек — яшелчә һәм бәрәңге, бөртекле фураж һәм түтәлдән, басудан җыеп алынган башка ризыкларны да куллану алдыннан тикшерергә мәҗбүрбез. Үзебезгә ышаныч бетте: моннан да аянычрак хәл була аламы?

Агулы матдәләр терлек азыгына һәм ашамлыкларга ничек эләгә? Чүп үләннәрне, бил бөкмичә генә, химик юл белән «утыйбыз»! Чөнки кеше береннән-бере хәтәр, береннән-бере кыйммәт гербицидка ия булды һәм шуны уңга-сулга чәчә. Үзен алдау, тынычландыру өчендер, исемен дә латиннан алган: гербицид. Безнеңчә — «үлән үтергеч». Агуны сиптерү өчен машиналар кулланабыз, самолетлар чакыртабыз. Калачка дигән бодай, сөт-майга дигән кукуруз кырлары өстендә агу бураны уйный. Чүп үлән, шул ук билчән — бөгелеп төшә, ләкин урып-җыйганда, комбайнга эләгә, салам һәм силос белән фермага кайта. Терлек азыгындагы агу калдыгы шулай ашамлыкка күчә.

Бервакыт «Правда» колхозында булган хәл күңелне әрнеткән иде. Бу колхозның бодай басуында билчән күтәрелә. Белгечләр Казаннан, авыл хуҗалыгы үсемлекләрен химик саклау станциясеннән самолет чакыралар. Р. А. Зарипов командалыгында экипаж килә. Самолет, гербицид төяп, һавага күтәрелә, басу өстенә сиптерә. Билчән исә һаман үсә икән, чөнки агулы химикатны җил башка якка очырган. Ул зур хезмәт һәм чыгымнар куеп үстерелгән сиксән гектар шикәр чөгендерен юк иткән. Соңрак булса да, ул җиргә кабат чөгендер чәчеп карыйлар — тишелми. «Чөгендерне боз сукты» дип акт төзү белән чикләнәләр. Агу төягән очкычлар кайчак авыллар, сулыклар, урман һәм әрәмәлекләр өстеннән дә үтә, җирдә агуланган күлләр, көйгән-янган агачлар кала, хәтта бәрәңге бакчалары көеп чыга.

Авыл хуҗалыгы химиясе флора һәм фаунага никадәр зыян сала? Хәзер колхоз-совхозларда агу-химикатлардан файдалану өчен махсус техника парклары барлыкка килде. Аларга саклану чараларыннан башка якынлаша алмыйсың. Әмма басуларның да һәр карышында җанлы тормыш булуын бераү дә башына китерми. Басу кошлары оя тибә, бала чыгарып үстермәк була. Без исә аларның үзләрен дә, балаларын да ризыкларын да агу белән коендырабыз. Аннары гаҗәпләнеп йөрибез: кая китте җырчы тургайлар, сөйкемле бытбылдыклар, кыр тавыклары? Ләкин беребез дә агулы химикатларга тотынганчы, табигать календарен искә төшерми, картограммада басуның кошлары, җәнлекләре күп яшәгән урыннарны билгеләми. Бу сүзләрне югары белемле агрономнарга җиткерергә телим. Басуга тиктомалга агу сиптергән агроном мактаулы эшенә хилафлык кыла. Басуда бер бүдәнә генә елыймы? Җиргә күз салсаң, үлән сабакларын игътибар белән күзәтсәң, мыжгылдап торган бөҗәкләрне күрәсең. Анда без санга сукмаган тормыш бара. Галимнәр, гадәттә, бөҗәкләрне төркемнәргә бүлгәндә, яртысын битараф саныйлар, калган өлешен тәп-түгәл итеп файдалы һәм зарарлылар исәбенә кертәләр. Балаларның бармак очына кундырып: «Яңгыр булса — оч-оч!» дип иркәләгән кызыл калканлы камкасын гына алыйк! Басуны, һавадагы торымтай кебек үк, корткычлардан саклый бит ул. Без исә камка кебек бик файдалы бөҗәкләрне дә метафос, карбофос, хлорофос һәм башка зарарлы зәһәр химикатлар белән агулыйбыз.

Соңгы елларда туфракны көздән үк гербицидлар белән эшкәртү гадәткә керде. Бу — зарарлы бөҗәкләргә һәм ашлыклардагы авыруларга каршы эшләнә. Ләкин шул ук җирдә файдалы бөҗәкләр дә кышлый ич! Җир сөрүче һәм туфракны кислород белән баетучы суалчанны кая куярсың? Тегеләре аяк сузганда, болары елмаеп торырга тиешме? Бөҗәкләрне тоташы белән кырып салгач, туфракны кем тазартыр, кем баетыр?

Якын күршебез Чувашиядә игътибарга лаек тәҗрибә бар. «Ленинская искра» колхозында агулы химикатлар куллануддан баш тартканнар. Үсемлекләрне саклауда бары тик биологик чаралар кулланалар. Чүп үләннәренә каршы чәчү әйләнешендә көрәшәләр. Үсемлек корткычларына каршы игенчеләргә файдалы бөҗәкләр һәм кошлар булыша. Төклетуралар өчен йөзләрчә оя корганнар. Чокырлар үзенчәлекле табигый «заповедникка» әверелгән, аның ярларын агач утыртып ныгытканнар, көтү йөртү тыелган. Кыргый умарта кортлары үрчетүгә һәм культуралы үсемлекләр серкәләндерүгә күп әһәмият бирелә. Колхозда киек кошлар аерым саклауда тора. Аларга оялар ясау, җимлекләр кую, кыр тавыгы һәм бүдәнәләр өчен тын урыннар җиһазлау гадәткә кергән. Минераль ашламаларны исә төгәл норма белән махсус картограмма буенча кертәләр. Хуҗалыкта үсемлекләрне биологик саклауны оештыру өчен энтомолог штаты булдырылган. Бу чаралар зур уңыш алырга мөмкинлек биргәннәр.

Апастаниләр эшләп була соң? Үсемлекләрне саклау станциясе инспекторы агроном Тәлгать Фәсхетдинов белән сөйләшкәндә, шушы мәсьәләгә ачыклык кертергә тырыштым. Монда да корткыч бөҗәкләргә каршы биологик юл белән көрәшү мөмкинлеге бар икән ич! Кулланып та караганнар. Гадәттә борчак чәчүлекләрен метафос дигән агу белән

коендыралар иде. Берсендә энтомалофаглар, ягъни корткыч бөҗәк ашаучы бөҗәкләр, кулланып караганнар. 1800 гектарга трихограмма дигән вак чебен җибәрелгән. Шул элпе канатлы бөҗәкләр үсемлекләрне корткычлардан бик тиз арындырган. Гербицид кулланылмаган борчак һәм люцерна җирендә камка кебек файдалы бөҗәкләр үрчеп киткән. Кайбер басуларда биологик препаратлар — тере бактерияләр кулланылган. Авыл кешесенең теңкәсенә тигән колорадо коңгызына каршы да битоксибацилин дигән шундый препарат биргәннәр. Мактап бетерә алмыйлар. Чүп үләннәренә каршы да биологик юл белән көрәшә алабыз ич. Галим агроном әйтер: «Билчәнгә каршы иң йогынтылы корал — сабан»,— дияр. Ә аңар бүген кытлык юк, чөнки промышленность авыл хуҗалыгына ел саен диярлек ике йөз меңнән күбрәк трактор сабаны бирә. Ал, тәмен белеп куллан, файдасын тиз тоярсың! Чәчү әйләнешебез дә бар. Шөкер, соңгы елларда чиста пар җирләре дә булдырдык кебек. Иген культураларының чиратлашуын да төгәлрәк тәэмин итәргә тырышабыз. Барысына тирәнрәк игътибар итәсе иде дә бит, юк, чәчү әйләнеше төгәл сакланмый, өстәмә-өстәмә дип, чиста парның да бер өлешен азык культуралары белән биләп куябыз. Технология, җирдән файдалану тәртибе бозыла, басуларны тагын чүп баса. Тагын химиягә ябышабыз.

Химик продуктларны, бигрәк тә агулы химикатларны еш һәм күп куллану яки файдалану принципларын бозу аяныч хәлләргә китерә. Ел саен районда агуланган әллә ничә кешене больницага салалар.

Апас районында 138 мең гектар сөрү җире исәпләнә. Туксан мең гектарында агулы химикатлар куллану планлаштырыла. Шуннан чыгып гербицидлар кайтарыла: елга 415 тонна — бер районга шушы кадәр агу! Салам, силос аша сөткә-майга күчкән теге «2,4-Д» гербициды — кырык тонна! Монда экологик тәрбия турында нинди сүз булырга мөмкин?!

Мәсьәләнең тагын да куркынычрак ягы бар әле. Колхозга кайтарылган гербицидларның бер өлеше, «һава шартлары начар булды», дип, файдаланылмыйча кала. Ун-унбиш мең гектар җир эшкәртелми. Монысына сөенер генә идең, әмма файдаланылмаган агуны кая куярга? Бер Апас районында гына да утыз тоннага якын агу «янга калган». Бер арба тирес кенә түгел, елга ярына чыгарып түгә алмыйсың. Тирән коелар казу, агухимикатларны шунда тутырып дөмектерү турында сүз бара. Башка төбәкләрдә дә шундый план яши. Күңел тыныч түгел. Җир җиде катлы диләр. Аның су юллары бар. Гербицид шул юлга сарыкса, көннәрдән беркөнне агулы чишмәләр барлыкка килсә? Җир астына агу яшереп, хилафлык эшлибез түгелме?

• • •

Бер елны миңа Мамадыш районында мелиорация эшләренең торышы белән танышырга туры килде. Инеш тамагында, уйсулыкта гасырлар буе ялтырап яткан, җикән камышлы һәм балыклы күлне ералар иде. Фәрман бирелгән, тикшеренергә һәм каршы сүз катарга ярамый: әйтелгән — эшлә! Ләкин уникe гектарлы күлнең ни зарары бар? Фәрман бары бик сазлыкларны киптерү хәрәкәтенә кушылу теләгеннән чыгып кына бирелгән. Ул елларда мелиорация, җир яңарту дип тәкърарлек һәм челәннәрнең туган сазлыкларына аждаһадай машиналар белән килдек, сайрар кошлар оя типкән, бала үстергән һәм шунда яшәп иген кырларын саклаган әрәмәлекләрен кырып ташладык. Торфлы сазлыкларны актаргач, чишмәләр югалды. Эшебез гамәлгә ашмады, ә туган як табигате зур зыян күрде. Шундый башбаштаклыкларга карап, ихтыярсыздан уйланып каласың: интенсив файдаланып, күпмедер отарсың, әмма ахыры кызганыч булыр. Чөнки табигатьтә экологик диверсия акланмый.

Алкын сулы Иделебезгә генә күз салыйк! Каскадлы электростанцияләр аның алкынлыгын бетерде. Тәтештә Идел тормышын күзәтүче оешма бар, аны «күл станциясе» дип атыйлар. Шуның мәгълүматларына караганда, елга елдан-ел ярлылана бара. Куйбышев сусаклагычы барлыкка килгәнче, бу тирәдән елга 23,6 мең центнер балык тотканнар. Сусаклагыч башта балыкны биш мәртәбә күбрәк биргән, аның продуктлылыгына шаккатканнар. Ләкин озакка түгел, елга тормышы бозылган, балык кимергә тотынган. Хәзер балыкчылар күбрәк суүсем сосалар. «Күл» авырый, балык интегә.

Бервакыт Идел балыкчылары Кайбыч балык хуҗалыгына зур гозер белән килгәннәр: «Чуртан маймычлары чыгарып бирегез әле»,— диләр. Тагын аяныч хәл. Иделдә санитар чуртаннар кимегән, авыру балыклар күбәйгән, балыкчылыкка һәлакәт яный башлаган.

Балыкта гынамы соң хикмәт?! Идел буе урманнарын, бай печәнлекләрен, җиләкле әрәмәлекләрен сагынып сөйлиләр. «Сельская молодежь» (№ 1, 1983) Кама Тамагы районындагы «Кама» колхозының, зур су килгәнче, Идел үзәнендә, андагы утрауларда мең гектарга кадәр бай печәнлекләре булуын тасвирлый. Иркен яшәгәннәр. Илгә дә биргәннәр. Байлык су төбендә калган. Хәзер колхоз сугару системасы булдырган. Елга суын коры җиргә куалый, азмы-күпме печән үстерә. Идел буендагы бөтен хуҗалыклар да шундый хәлдә калды. Нинди зур байлыкны суга салдык!

Иделдә генә түгел, Зөя елгасы буендагы колхозлар да печәнне күп әзерлиләр иде.

Аның бассейнындагы Бола, Гөбнә елгалары буйларында билдән печән тора иде. Хәзер юк. Сугарып маташабыз,— файдасы аз. Нишлисең? Үткәнгә — салават!

Вак елгалар киптеләр, корыдылар. Чөнки авылның матур традицияләрен югалттык. Шунда үскәнгәдер — миңа Чирмешән якын. Ул ярларыннан салкын чишмәләр бәреп торган, саф сулы, балыклы гаҗәеп матур елга иде. Суы мөлдерәп торды, ярларында былбыллар сайраган куе таллык иде. Югалттык. Ярлары ишелгән, чүпләнгән. Атлар йөздергән тобаларда үрдәк чумарлык су юк. Чишмәләре кибә.

Мин Чирмешән елгасы турында сөйлим. Ә бүген кайсы елгага элеккечә сокланып карый алабыз? Барысы да бер үк аяныч хәлдә. Элек авыл янындагы елгага ләксән тартып, кубай сугып, тегермән буасы буалар, хәтта исемсез инешләрдә дә чыбыктан табан түшиләр, буа корылмасы күтәрәләр иде. Чирмешәндә унбишкә якын су тегермәне корыла, кайберләре дүрт ташлы була иде. Авыл халкының буа үзәген өзәргә җыенып йөрүләре гаять зур вакыйга санала иде. Элек мәшһүр Зөядә дә тегермән буасы корганнар. Зөя суы бер тегермәндә һәм берьюлы егермегә якын ташны әйләндергән һәм базар оны биргән. Мөлдерәп торган буалар җир асты суларын күтәргән, чалуларны, яшелчә түтәлләрен баеткан. Чишмәләрнең көр сулавы да шуннан. Шушы бизәкне, шушы байлыкны тәмам югалтабыз бит. Кайтарасы, он өчен булмаса — суы өчен гап-гади генә буалар буасы иде!

Хәер, бу иренүдән яки юньсезлектән түгелдер. Замана кеше кулына йөзләгән ат көчле машина бирде, меңьяшәр игенчегә мелиоратор дигән исем такты. Җирне актара, ярны ишә, туфрактан кичү сала, балчыктан буа бөя. Яр буена куәтле насос урнаштырып, торбалар сузып, су кудыра. Монысын сугару дип атыйбыз. Яңгырдан соң буасы ерылса да, аптырап, кәефсезләнеп калмый, тагын ярны иштерә, матурлыкны талый. Әле аның планлы дигән «изге» эше бар, аны үтәү өчен кыш көне кар өстенә известен, кайчак минерал ашламасын сибеп йөри. Планын үти, эш хакы һәм бүләк ала. «Башбаштаклык!» — дип әйтмибез, мактыйбыз. Ә андый мелиораторның никадәр зарар салуы уебызга да килми.

Әстерхан якларында булганда, миңа Идел тамагы белән танышырга мөмкинлек бирделәр. Иделнең сурәтен ботак-чатаклы, куе ябалдашлы пәһлеван агач итеп күрәсең. Идел диңгезгә шулай тармакланып кушыла. Анда — кошлар дөньясы. Шушы урында Ленин декреты белән Октябрьдән соң тыюлык оештырылган. Анда бик күп еллардан килгән галимнәр фәнни эш алып баралар. Тыюлыкның мәйданы, төзегәндә, егерме биш мең гектар исәпләнгән, хәзер илле мең гектардан арта. Нәрсә исәбенә дип уйлыйсыз? Елганың «ботакларын, ябалдашын» күз алдына китерегез. Гади чишмәдән туган Иделгә озынлыклары ун чакрымнан да ким булмаган 151 мең елгачык һәм инеш суын бирә, 2600 елга турыдан-туры кушыла. Андагы балчык буалар, кар өстенә сибелгән химик продуктлар, ташкынлы су белән киләләр дә Идел тамагына дуен булып утыралар, тал һәм камыш белән ныгыйлар. Суднолар йөртү өчен канал казып-чистартып торырга туры килә. Менә нинди мәшәкатьләр тудырабыз.

Хәзер галимнәр Идел тамагындагы дуенны ашлама урынына файдаланырга тәкъдим итә. Дуенның минераль һәм органик матдәләргә бай булуы ачыкланган. Шикәр җитештергәндә дефекат кала, ул игенчегә тәкъдим ителә. Җир ашлауда файдаланалар. Безнең пәһлеван Иделебез дә, диңгезгә чыкканда, мелиораторның «юньсезлек дефекатын» тамагына утыртып калдыра икән ич!

Елгаларны кемнәр генә пычратмый! Нефть якларында нефтьчеләрдән зарланалар. Идел арты районнарында да елгаларга тынычлык юк. Бола күп сулы һәм балыклы елгалардан санала иде. Тегермән ташын әйләндергеч буа да кормыйлар. Аны крахмал заводыннан чыккан пычрак сулар агулады, балык качты.

Иделнең эре кушылдыкларыннан саналган матур һәм үзенчәлекле Зөя елгасын да сафтан чыгарабыз. Ел саен балыгы һәлак була. Төрледән-төрле комиссияләр килеп шау-шу күтәреп йөриләр. Файдасы юк. Барысы да — алдан күрә белмәү бәласе. Нигә дип предприятиеләрне елгага терәп салалар? Зөя буенда да шикәр һәм чүпрә заводлары, башка предприятиеләр утыра. Дөрес, фильтрлаучы корылмалары бар. Буа шикәр заводының фильтр кырлары Зөя үйсулыгына урнашкан. Чистартылган суны Зөягә агыза алалар. Шуны онытмыйк: Идел арты районнары шикәр чөгендерен елдан-ел күбрәк җитештерәләр. Эшкәртү дә арта, фильтр кырлары киңәйтелми. Зөя буенда урнашкан Чынлы шикәр заводында да шундый хәл. Бу заводлар пычрак суларын турыдан-туры Зөягә агызмас дип кем ышандырыр? Ә безнең Зөя суыдай табигать һәйкәлләре саф килеш сакланырга тиеш!

* * *

Кабул итү бүлмәсенең ишеге ачык иде. Кайбыч лесхозы директоры Илгиз Хафазов белән эчкә үттек. Министр белән кызыклы, шул ук вакытта борчулы әңгәмә башланды. Республиканың урман хуҗалыгы министры Әбүзәр Гаянович Гаяновны яшел дәрьябызның киләчәге хәвефләндерә, урман үстерү һәм аның байлыкларыннан файдаланудагы җи-

тешсезлекләр сыкрата икән. Чыннан да, табигатьнең иң матур бизәге, байлыгы саналган яшел дәрьяны ни хәлгә куйдык? Министрның дәгъвасы белән килешмичә булдыра алмыйсың. Кеше урманга карата рәхимсез һөҗүм башлады. Бу хәл исә урманчылыкта өстәмә мәшәкатьләр китереп чыгарды.

Миңа Кайбыч урманнары күптән таныш. Мондагы имәнлекләр теләсә нинди гарасатка каршы торырлык итеп үскәннәр иде. Аларны да кеше «иҗат иткән», план дип аталган гарасатка буйсындырдылар, урман сирәгәя бара. Ә киләчәге нинди? Хәзер монда яшь имәннәрне ялгап тимер челтәр белән киртәләнгән диләнкеләрдә үстерәләр. Туйраларны поши һәм кабан дуңгызы харап итә. Гомер булмаган бу хайваннарны Тау ягы урманнарына китереп үрчеттеләр. Урманчы фикере белән санашып тормадылар. Хәзер бәласеннән интегәбез: яшь агачларны зарарлыйлар, түтәлдәге имән үсентеләренең орлыгын актарып алалар, кырмыска оясын туздыралар. Әле анысы гына җитмәсә, урманга ферма көтүен кертеп, яшел дәрьяны такыр басуга әйләндерәләр.

Урманга көтү кертү өчен вәхши булырга кирәк. Мәгълүм ки, урман өч катлы булып үсә: түбәндә зелпе, каракош, гөлҗимеш, бүре юкәсе кебек куаклар, кычыткан, аю табаны, сәрдә кебек озын сабаклы үсемлекләр, башка үләннәр үсә. Урманны уникаль сусаклагыч дип бәяләгәндә, шушы беренче катны истә тоталар. Мүк үзе генә ни тора! Яңгырда аның һәр килограммы дүрт литрга якын су «җыеп» кала. Шул дым икенче катка кадәр үскән шомырт һәм миләшләргә, аннан да биегрәккә — өченче каттагы имән, юкә һәм усакка бирелә. Җитәрлек дым алмаган агач очыннан корый башлый һәм һәлак була. Ә без табигатьнең шушы законын аңларга, белергә теләмибез. Көтүдән таптату урман өчен коточкыч бәла санала. Үләне корый, мүк кибә, дым юкка чыга. Агачлар җәй уртасында ук саргая башлый. Көтү артыннан урманга да мелиоратор кертергәме?

Беренче кат — агач тамыр җибәрә торган җир. Орлыклар да шунда коела, шыта. Ә үзе чәчеп иң яхшы орлыклардан үскән урманны таза һәм көр була диләр. Агачлар арасында утлап йөргән меңләгән баш сыер урманга табигый рәвештә күтәрелергә ирек бирми. Урман белгечләре бәхәсләшеп тә карыйлар, хәтта кайчак халык суды аша дәгъва белдерәләр. Җирле властьнең акылсыз фәрманын кире кагучы юк.

Бервакыт Тәтештә күптәнге дустымны очраттым. Мондагы урман хуҗалыгында эшли. Яраткан хезмәтен калдырып китәргә җыенган. Нигә? Сәбәбен ачык итеп аңлатты:

— Идел буе урманнарында терлек көтү катгый тыела,— диде ул.— Райбашкарма җитәкчеләре шуны аңларга теләмиләр, язга чыгу белән, терлекләрне урманга куып кертергә боералар. Елга сагында торган уникаль урманнар харап була. Кем җавап бирер?

Юк, гомеренең иң әһәмиятле чагын урман үстерү һәм саклауга биргән кешенең куркаклыгы түгел, бюрократ җитәкчеләрнең кыланышына бойкоты бу аның.

Идел суы күтәрелгәч, яр буйларында хәтәр шуышмалар барлыкка килде. Киң елгага «аяк салындырып» утырган Кама Тамагы эшчеләр поселогының яңа асфальт җәйгән бер урамы Иделгә убылып төште. Могҗиза белән генә исән калган өйләрне ашыгыч рәвештә күчерергә туры килде. Тәтеш шәһәренең гөрләп торган бер урамы елгага шуыша башлады. Күчене чаралары күрделәр. Урамнар гына түгел, таулар, басулар шуыша. Табигать ваемсызлыктан үч ала.

Һәркем үз урынында хуҗа булсын. Урманны урманчыга бирик, бөтенлеге турында ул кайгыртсын! Ә властьтан белер-белмәс файдаланучы һәм табигатькә карата вәхшилек кылучы җитәкчеләргә зур дәгъва белдерергә кирәк иде! Колхоз һәм совхозлар йөзләрчә гектарда терлек азыгы игәләр. Көзен мактанышалар: берсе, имеш, ике еллык силос әзерләгән, икенчесе сенаж һәм печән белән бөтен каралтыны тутырган, саламын тозлап-сулап базга салган. Әүвәл шапырыналар, ә февраль-мартта терлекләргә азык җитми башлый. Нәкъ менә шундыйлар, кар киткәч үк, көтүне урманга куалап кертә.

Урман тирәннән өйрәнүне таләп итә. Аланнары, печәнлекләре бар аның. Тик урман печәне, басудагы белән чагыштырганда, бер айга соңрак өлгерә. Ләкин җирле власть фәрманы белән, яфрак һәм үлән әзерләргә килгән кешеләр, урманны вакытсыз кыркып ташлыйлар. Җәйгә кергәч үк яшеллек дөньясын талау башлана. Урманга һәм аның байлыкларына бернинди кагылышы булмаган оешмалар, һичнинди нигезсез, терлек азыгы әзерләргә боерык бирәләр һәм балта-пычкылы бригадаларны урманга кертеп җибәрәләр. Соңгы елларда бу бик зарарлы күренеш тәмам гадәткә әйләнде. Урман ботарларга шәһәрдәгеләрне ярдәмгә җибәрәләр. Фермага бу «яу» ташыган агач ботаклары һич тә ярдәм итми. Бу һәркемгә билгеле, ләкин туры сүзне әйтүче генә юк. Ә урманчыларга: «Шыпырт, урман — дәүләтнеке!» — дип кенә җибәрәләр.

Май, июнь айларында Идел өсте тынып кала, балыкчы көймәләре «комда кызына», һәвәскәр балыкчылар кармакларын, күрсәтелгән урында, ярдан гына салалар. Балык уылдык чәчкәндә, Иделнең тынычлыгы шулай саклана башлады. Моңа күнегеп киләбез. Бу тәртип закон белән, балыкчының намусы белән ныгытыла. Урманның хәлен аңлаучы гына юк. Кошлар да бит май һәм июньдә бала чыгаралар, яшел дәрьяның кадерле санитарларын үстерәләр. Ләкин алар нинди аяныч хәлдә: нәкъ шушы вакытта диләнкеләрдә

бихисап бензопычкылар жуылдый, автомашиналар, тракторлар үкерә. Утын кисәләр, утын ташыйлар! Кая монда бичара кошка оя тибәргә?! Сыеныр урын таба алмый. Кайдан килеп керде мондый гадәт? Элек язгы-җәйге чорда урман авызы ябык була торган иде. Утын әзерләү һәм ташу белән көзге-кышкы якта гына шөгыльләнделәр. Нигә урманны да Иделне саклаган кебек вакытлыча япмаска?!

Бервакыт урманчының чылбырлы трактор юлына аркылы төшүен күрдем. Тракторчыны шелтәләп үк ташлады: «Күзең чыкканмыни, түйраларны изәсең бит!» — ди. Дөрес бит әрле, җәйге урманга килеп кергән трактор астында никадәр үсенте, шытып та өлгермәгән орлык изелә?! Алар бит урманның киләчәге!

1982 елда «Неделя» (№ 18) болай язды: «Гадәттә Мәскәү янында шәһәр тирәсенә ял итүчеләрнең саны бер көндә ике-ике ярым миллион була. Өч миллионга кадәр дә җитә! Рәсми мәгълүматларга караганда, кайбер урыннарда урман-парк зонасының бер гектарында бер көндә җиде йөзгә якын кеше йөри! Һәм һәркем өенә чәчәк бәйләме алып кайтырга һәм вазага куярга тели...» Чәчәк кенәме соң?! Матбугат тагын мондый мәгълүматлар бирә: илебезнең Европа өлешендә шәһәрдә яшәүче һәр кеше елга уртача унөч мәртәбә урманга чыга, шул чакта дүрт мәртәбә учак яга, бер мәртәбә чатыр кора. Ленинград урман хуҗалыгы идарәсе ял итүчеләрнең бер атна эчендә генә дә ягулык һәм чатыр кору өчен якынча бер кубометр агач тотуын ачыклаган. Ә Мәскәү университеты студентлары бервакыт Клязьма сусаклагычы тирәсендә унике мең учак санаганнар! Безнең Татарстанда да көне җиттеме, урман аланнары да шәхси һәм дәүләт машиналары, арба таккан тракторлар белән тула. Табигатьне «үлеп яратучылар» урманнарга төзәлмәс яра сала.

Утызынчы елларда, мәсәлән, урманнарда иркенләп йөри алмый идек. «Шәхси транспорт» — кул арбасы белән коры-сары җыярга барсаң гына да, җәзасын шунда ук татыйсың — арба көпчәкләрен тураn ташлыйлар иде. Бала-чаганы җиләклектән кудылар. Чикләвек җыю өчен махсус билет кирәк иде. Кеше урманга кызыгып карау белән канәгатьләнде. Ә хәзер урман — безнеке, хокук закон белән ныгытылган. «РСФСР урман кодексының 87 нче статьясында: «Гражданнар урманнарда ирекле йөрергә, кыргый җимешләре, чикләвек, гөмбә, җиләк һ. б. җыярга хаклы»,— диелгән. Ләкин бу — агачлар илендә үз белдегең белән теләсә нәрсә эшләргә ярый диган сүз түгел. Урман сакчылыгының үз кагыйдәсе, халыкка хезмәт күрсәтү тәртибе бар. Әлеге кодекста «Гражданнар урманнарда янгыннан саклану кагыйдәләрен үтәргә, агачларны һәм куакларны сындырмаска һәм кисмәскә, урман культураларына зарар китермәскә, кырмыска ояларын, кош ояларын туздырмаска тиешләр»,— диган сүзләр дә бар. Урманда йөрергә ирек алгач, бу кагыйдәләрне санга сугабызмы соң? Юк шул. Аның яшәешенә, җәнлекләр һәм кошлар дөньясына зур зарар салына. Соңгы елларда республикабыз урманчылары, гражданнар теләген исәпкә алып, ял итү өчен махсус урыннар булдыра башлады. Игелекле кешеләр кора, кемнәрдер шуны ватып-җимереп китә. Андый кеше, браконьер, урманда меңләгән баш терлек куалап йөрүче, җәнлек өннәрен, кош һәм кырмыска оясын туздыручы кебек үк, табигатькә зур зарар китерә.

Урманга якын дус, яхшы мөнәсәбәт һәм булышучы кирәк. Министрдан башлап гади ял итүчегә кадәр бу хакыйкатьне аңларга тиеш. Без әле, кызганычка каршы, мондый дәрәҗәгә җитмәгәнбез.

* * *

Бездә җир, су, урман кодекслары кабул ителгән. Анда иң алга халык ихтыяры куелган. Экологик кризисны кисәтердәй яңадан-яңа карарлар да кабул ителә. Җирле Совет сессияләрендә, Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыяте һәм аның урыннардагы оешмаларында җитди мәсьәләләр күтәрелеп торалар, махсус комиссияләр дә төзелә. Соңгы вакытларда шау-шулы, ыгы-зыгылы әңгәмәләр тагын да күбәйде. Бака туен хәтерләтә. Әмма табигатькә чын-чынлап ярдәм кулын сузучы, аңа зарар китерүчеләргә каршы актив көрәш оештыручы әлегә юк.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ

**Журналыбыз битләрендә бер елдан артык дәвам иткән бәхәсне йомгаклауга багышлап редколлегиянең махсус утырышы үткәрелде. Укучыларга шул утырыштагы чыгышларны тәкъдим итәбез.**

## Нил Юзиев:

Журналдагы бәхәснең әһәмиятен мин, беренчедән, тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре өчен хәзерге эстетик фикерне, шагыйрьләрнең психологиясен, шагыйрь белән шагыйрь, шагыйрь белән тәнкыйтьче, шагыйрь белән укучы мөнәсәбәтләрен өйрәнү өчен үзенчәлекле материал бирүендә күрәм. Моңа кадәр әдәбият фәнендә шагыйрь, гомумән язучы психологиясен өйрәнүгә тиешенчә әһәмият бирелмәде. Шагыйрь ул, барыннан да элек, шәхес бит әле. Аның дөньяны, чынбарлыкны, әдәбиятны, тәнкыйтьне кабул итүе үз шәхси «мине» аша бара. Шагыйрьләрнең менә шушы, шәхси, субъектив хасиятләре — үзләрен, каләмдәшләрен бәяләве — аларның чыгышларында ярылып ята. Шагыйрь психологиясен өйрәнү белән генә чикләү дә тулы булмас иде. Басылган материаллар тәнкыйтьчеләр һәм редактор психологиясен өйрәнү өчен дә кызыклы.

Икенчедән, бәхәс бүгенге шигъриятнең торышына кагылышлы аерым «авыру нокталар»ны — заман рухын сурәтләүдәге йомшаклыкларны күрсәтүе, шигырь китапларын басуга һәм таратуга бәйле кимчелекләрне ачуы, шагыйрьләрнең тәнкыйть тарафыннан талант югарылыгына нисбәтән бәяләнү заруриятенә игътибар юнәлтүе белән дә файдалы.

Өченчедән, бүгенге поэзия турындагы сөйләшү хәзерге заман эстетик фикерендә, әдәби тормышыбызда туган яңа тенденцияләрне күзәтү ягыннан да гыйбрәтле. Яңача фикерләүнең сөйләшүгә йогынтысы сизеләме? Сизелә икән. Хәзерге үзгәртеп кору заманының рухы бәхәс барышында да күренде. Үзенә күрә бу дискуссияне ил күләмендә барган әдәби хәрәкәттәге үзенчәлекләрнең бер миниатюрадагы чагылышы дип карарга да була. Беренче чиратта бу үзенчәлек бәхәстә демократизмның киң чагылыш табуында күренә. Ул үзенә күрә хәзерге күп сүзле, озын митингларны да, матбугатта барган дәгъвачел бәхәс-тарткалашуларны да хәтерләтеп куя. Елдан артык дәвам итүе дә (бу үзенә күрә — рекорд, моңа кадәр болай озын сузылган бәхәсләрне хәтерләмим), анда һәр теләгән әдипнең һәм укучының катнашуы да, географик яктан Казан белән генә чикләнмәгән булуы да шушы демократик рухның чагылышын гәүдәләндерә. Аеруча мин укучыларның актив катнашуларын һәм аларның шагыйрь белән тәнкыйтьче мөнәсәбәтенә кагылышлы үтә нечкә мәсьәләләрдә туган дорфа сөйләшүләрне ипле рельска күчерергә булышуларын билгеләп үтәр идем.

Кыскасы, бәхәстә заманыбызның рухы бер яклы гына түгел, ә катлаулы агышы белән, каршылыклары белән, һәм уңай, һәм тискәре тенденцияләре белән чагылды.

Дүртенчедән, поэзия турындагы сөйләшү хәзерге тәнкыйтьнең торышын күзалларга, аның алдында торган бурычларны билгеләргә дә ярдәм итәр дип уйлыйм. Ни өчендер тәнкыйтьчеләр бәхәскә актив катнашмадылар, төп сүзне нигездә шагыйрьләр һәм укучылар алып барды. Сөйләшүнең бер уңай ягы итеп мин анда яшь тәнкыйтьчеләрнең шигърияткә кагылышлы әйбәт кенә фикерләр белән чыгыш ясауларын (Ә. Сәхәпов, Г. Гыйльманов, Ф. Бәширев һ. б.) күрсәтер идем. Бер әйбәт шигырь турында сүз алып барган яшь тәнкыйтьчеләр төркеме дә бездә шигырь тәнкыйте буенча өметле резерв булуы турында фикер уята. Шул ук вакытта безгә шигърияткә кагылышлы теоретик фикерләүне үстерү, тирәнәйтү турында да уйларга кирәктер. Поэзия тарихын бүгенге көн күзлегеннән торып язып чыгу да көн тәртибендә тора.

Сөйләшү барышы бәхәс, дискуссияләрне оештыру эшен югарырак баскычка күәрү кирәклеге турында да фикер кузгата.

Сөйләшүдәге кайбер кимчелекле якларга беркадәр кагылып узган идем. Әйткәемчә, анда заманның демократик рухы чагылу белән демократиядән тиешенчә файалана белмәвебез дә күренде. Мине тәнкыйть фикерләренең кыю һәм кискен әйтеүләренә, ачыктан-ачык сөйләшүгә каршы чыга дип уйламагыз тагын, һич юк. мма тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть принципиаль нигездә, демагогик пәрдәләргә өренмичә барырга тиеш. Сөйләшүдә исә демократия чикләреннән читкә чыгып китү ә, житди сөйләшүне шагыйрьләрнең үзара мөнәсәбәтләрен яки тәнкыйтьче белән агыйрь мөнәсәбәтләрен «ачыклауга» юнәлеш тотканнары да очрап куйды. Моменты файдаланып, каләмдәшенең кайсы да булса җиреннән чеметеп алу, үч алу, урынсыз гаеп ыргытып, тамгалап узу күренешләре дә урын алды — болар, аз булса да, өйләшүне ямьсезли һәм үзеннән читләштерүгә этәрүче хасиятләр булды. Киләчәктә искуссияләр уздырганда шәхси мәнфәгатьләр җирлегендә барган тарткалашуларга рынны кыса төшәргә, бәхәсләшү культурасын югарырак күтәрү турында уйларга ирәктер.

Сөйләшүдә бәхәсле һәм каршылыклы фикерләр күп әйтелде. Бәхәс булгач, шуай булырга тиеш тә инде ул. Шулай да минем үземдә үткәнне һәм бүгенгене инарь итү рухы мәкаләләрдә күбрәк яңгырамадымы икән дигән фикер калды. Үзгәреп кору барышы шигъриятькә дә, әдәби мираска да яңача күз ташлауны сорый һәм өмкинлек бирә. Шул уңайдан хәзер матбугатта әдәбият белеме һәм тәнкыйтьне дә, алалар әдәбиятын да, поэзияне дә бөтенләй юкка чыгарып ташлаган мәкаләләр күенә башлады. Шигърияттәге хәлне нииндидер афәт, шигъри бушлык рәвешендә үзаллау белән дә мин үзем килешмәс идем. Заманны сурәтләү буенча бөтен әдәият җилкәсенә төшкән йөкне, бурычны бер поэзиягә генә кайтарып калдыру дөес булмас иде. Хәзер хаклы рәвештә көрәшнең алгы сызыгына публицистика чыкты. мма әле бу шигърият үз бурычын үтәми, заман «аңардан элеккеге рухи һәм әхлакый уклыгы өчен үч ала» дигән сүз түгел. Әйбәт шигырьләрне элек тә укыганнар, хәзер ә укыйлар. Поэзияне укучыларның ничек кабул итүе буенча безнең бит социологик икшеренүләр үткәргәнебез юк. Шул нигездә генә сөйләшүне чын фәнни нигездә лып барырга мөмкин. Торгынлык чорында милли нигилизм киң тамыр җибәрүе әбәпле китапларның тиражы азаюына шигъриятне генә, шагыйрьләрне генә гаепәү дөрес булмас иде. Торгынлык елларында да шагыйрьләрнең төрлесе булды. Шәес культын, торгынлыкны фаш итү буенча безнең шагыйрьләрнең алып барган өрәшенә без күз йомарга тиеш түгелбез. Тормыштагы кимчелекләргә ул чорларда иң ыю рәвештә баш күтәрүчеләр — шагыйрьләр иде дисәк, һич хата булмас. Публиистикада шәхес культына карата хәзер әйтелә торган гомуми тәнкыйди фикерләрнең айтагын безнең шагыйрьләр моннан кырык ел, утыз ел, егерме ел элегрәк әйтәлдылар. Шигъриятнең төп миссиясе дә менә бүгенге үзгәреш чорын хәзерләүдә актив атнашу булды. Әдәби тәнкыйтьтә баш калкыткан мондый нигилизм күренеше — ткәнне һәм бүгенге рухи казанышларны тулаем инкарь итү — тормыштагы соиаль-политик, экономик үзгәрешләр белән әдәбият-сәнгатьтәге үзгәрешләрне тәнәл китереп караудан килеп чыга булса кирәк. Ә аларның үсеше еш кына туры килми.

Тормыштагы катлаулы иҗтимагый шартларда туган хәл-әхвәлләрдә бер поэзияе генә гаепләргә омтылу кебек тенденция тәнкыйтькә карата да күренеп калды. Тәныйтьчеләрне шигъриятнең дошманнары итеп күрсәтергә омтылу, бу фикерне Ахмаова, Пастернакларга булган мөнәсәбәт белән дәлилләүнең хаталыгы исбатлау соамый кебек. Тәнкыйтьчеләрнең дә бит төрлесе бар. Хәтта бу мәсьәләләрдә тәныйтьчеләрдән уздырып җибәрүче язучылар да аз түгел. Моның сәбәбен шул чорардагы әдәби-эстетик мөхиттән, сәяси-әдәби юнәлеш бирүчеләрдән эзләү дөресрәк улыр. Менә минем алда «Горизонт» журналының үткән елгы (1988) 9 саны ята. анда 1958 елның 31 октябрендә СССР Язучылар союзында Б. Пастернакны тикшеүгә багышланган җыелышның стенограммасы басылган. Тәнкыйтьчеләргә караанда монда шагыйрьгә күбрәк шул чорның танылган, күренекле язучылары һөҗүм сыйлар. А. Ахматова фаҗигасендә дә төп гаеп тәнкыйтьчеләрдә түгел, ә шул чорың дөрес юнәлештән тайпылган догматик фикерләвендә.

Бәхәсне оештыру ягыннан да кимчелекләр булды булса кирәк. Бәхәс ничектер зак кына вакыт кузгалып китә алмыйча торды. Моңа дискуссиянең башлангыч мәкаәсе дә бәлки тәэсир ясагандыр. Ул диалогта мәсьәләне киң итеп, төрле аспекттаую, бәхәснең төп юнәлешләрен билгеләү җитенкерәмәде. Шуңа күрә дә сөйләшүәге таркаулык, кем нәрсә тели, шул турыда сөйләү омтылышы ахырга кадәр диярек дәвам итте. Сөйләшүдә күпчелек урынны шагыйрьләр биләү сәбәпле төп игътиар шагыйрьләрне борчыган «урын бүлү», үпкә белдерү мәсьәләләренә кереп китте. у исә заман күтәргән күп җитди мәсьәләләрне читтә калдыруга сәбәпче булды.

Киләчәктә дискуссияләр оештырганда югарыда әйтелгән якларга игътибар итү, бәхәсләшү культурасын күтәрү, сөйләшүне интеллигентларга хас дәрәҗәдә алып бару сорала.

## Аяз Гыйләҗев:

Елдан артык дәвам иткән, әле сүнә язып тәмам сүрелгән, әле кызып-дөрләп киткән бәхәс тәмамлана... Сиксән сигезенче ел әдәби хәрәкәтебездә шигърият хакында барган бәхәс тә тарихыбызга сеңеп калыр. Иң әүвәл су башына — бәхәснең бисмилласына, Вакыйф Нуруллин белән Рафаэль Мостафинның кереш мәкаләсенә кайтып карыйк. Вакыт аяусыз хөкемдер, былтыр ел башында гына басылган, кайбер кызыклы гына күзәтүләре дә булган мәкалә бүген рухи искергән, бик еракта һәм бик бәләкәй булып калган икән! Вакыт шул кадәр тиз аккан, ел дәвамында газета-журналларда шул чаклы яңалыклар, без белмәгән, белә дә алмаган мәгълүматлар басылган ки, безнең «Туп аттык!» дип башлаган керешебез, сыңар черки безелдәгән кебек кенә калган! Бәхәснең чын бәхәс булып оеша алмавына, моназарачылар сүзнең юнәлешен чамалап бетермәвенә кереш сүзләрнең гади, гадәти һәм вак булуы да сәбәп булгандыр дип уйлыйм. Шул уңайдан атаклы Литва драматургы Казис Саяның «Сукырлар» исемле пьесасы хәтергә төште. Торгынлык заманында кайберәүләрне нык ук кытыклаган, тиз арада тыелган бу әсәрнең үзәгендә бер төркем сукырлар тормышы бәян ителә. Сукырлар к а я д ы р барырга җыеналар, алар к а я д ы р барырга тиеш. Тик кайсы якта хак юл икәнен генә белмиләр. Кинәт арадан берәвесе аерылып чыга да: «Мин беләм! Без нәкъ менә уңга барырга тиеш!» дип өндәү сала. Кузгалалар, шау-гөр килеп баралар да баралар һәм... карурманга барып төртеләләр... Адашалар. Юл җебен икенче бер батыр ала: «Юк, ди ул, без сулга барсак кына максатыбызга ирешербез!» Ур-ра! Шау-гөр килеп, нык өметләнеп, сулга китә болар. Баралар, баралар, адәм йөри алмаслык сазлыкка барып чыгалар... «Юк!» дип батырая өченче сукыр, «безгә артка барырга кирәк иде. Хак юл шунда!» Бүтән сөйләп торуның кирәге юк сыман, әлбәттә, артка да барып карыйлар сукырлар, алга да тартылалар, нәтиҗә бер: юл эзләп гел юлсыз якка кереп китәләр...

Үпкәләштән булмасын, бәхәскә катнашучылар шактый уйландыра торган фикерләр дә әйттеләр, сискәндереп тә җибәрделәр, ләкин, минемчә, бәхәсләшүчеләр берсе әйткәнне икенчесе ишетмәде дә кебек, һәркайсы дөрес юлга чакырды, өндәде, әмма ул юл кая кадәр илтә, кая алып бара ала, без, укучылар, белми калдык. Чөнки бәхәснең сырт сөяге, укмаштырып торган үзәге табылмады. Үзәк читтә калды. Сүз бүгенге шигъриятебезнең бүгенгесе, аның хәл-әхвәле һәм к е м г ә хезмәт итүе турында барырга тиеш иде кебек. Бәлки мин ялгышамдыр, шигырь теориясенең тирәнлегенә йөзеп керергә җыенмыйм. Шигърият турында бәхәсләшү бик деликатный мәсьәлә, шагыйрьләр алар халкыбызның нерв җепләре, шулай да мин болайрак уйлыйм...

Бүгенге татар шигъриятенең хәле, егәре, югарылыгы ничек бәяләнә? Моны ил халыкларының поэзиясе белән янәшә куеп караганда бик ачык күреп чагыштырырга мөмкин. Миңа калса, безнең шагыйрьләр арасында үзенчәлекле, талантлы иптәшләр күп, татар шигыре ил алдында да, дөнья алдында да сынатырлык түгел! Шагыйрьләребез «күп һәм төрле-төрле». Теләсә нинди зәвыклы, нәзберек укучының рухына яраклык шигъри үрнәкләрне табып була бүгенге шигырьләрдән. Халык аһәңнәре, аның нечкә-саф хисләре хакында укыйсың килә икән — Гамил Афзал, Нури Арслан шигырьләрен генә алыйк! Әле безнең бик зур шагыйребез, милләтебезнең вөҗданы Гамил Афзал иҗатына чын бәяне бирә алганыбыз юк. Нури аганың шигърияте дә таләпчән өйрәнүне көтеп ята. Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалимнәрнең фәлсәфи югарылыкка ирешкән, гамьле уйлар уйлата торган әсәрләре шигърияттә хис белән фикер бердәмлеген эзләгән иң таләпчән укучыны да ризыкландырырлык түгелмени?! Теләсә кайсы телдә дә горур яңгырардай шигырьләр иҗат итеп яши бу талантлы шагыйрьләребез. Р. Гатауллин, К. Сибгатуллин, Ә. Баян, Ш. Галиев, И. Юзеев поэзия кырларыбыздан ничәмә-ничә бәрәкәтле уңыш җыймадыlarмыни? Дөрес, рухи игезәкләр Ш. Галиев белән И. Юзеев соңгы елларда беркадәр кабатлаулар сукмагыннан барсалар да, алар икесе дә, әүвәлдә, халкыбызга һәр җәһәттән тугры хезмәт күрсәткән иптәшләр. Минем үземә, бераз гына алардан соңрак тавыш биргән, әмма тавышлары нык, көр һәм ап-ачык ишетелгән шагыйрьләр якынрак дисәм, чордашларым миңа рәнҗемәсләр дип уйлыйм. Үзем белән янәшә яшәгән каләмдәш шагыйрьләр хакында мин җай чыккан саен җылы сүзләремне әйтә килдем, җәлләмәдем. Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов җаным көткән, халкыбызның җанын уч төбендә тота алган зат булды. Фәлсәфи яктан ул Равил Фәйзуллиннарга тартылса, шигъриятенең яңгырашы, эчке моңы, тәэсир көче белән Тукайга, Х. Туфанга, Г. Афзалларга тартым. Аның «Тукайдан хатлар» поэмасы русның зур шагыйре Евг. Евтушенко поэмаларын хәтерләтеп яңгырый. Мөдәррис гади шагыйрь генә түгел, ул татар халкының тугры улы,

ың күз-колагы, сердәше, фикердәше. Ул халкыбызга Тукайны тагын бер баскыч
ары күтәреп бүләк итте. Татар поэзиясенә яңа аһәң, яңа төсмерләр һәм кыю фикер-
р алып килгән Рәшит Әхмәтҗановның иҗатын кайбер иптәшләр күрәләтә кыерсы-
п килделәр. Бу шаукым әле бүген дә үзен сиздерә. Зөлфәт, Нияз Акмалов, адымна-
ı көннән-көн ныгый барган Харрас Әюпов, бунтарьлыгын дөрес юлга төшереп бар-
н Ркаил Зәйдуллин, шигырьләрен хак публицистика белән бизәргә көче җиткән Га-
нур Моратовлар халкыбызның һәр кешесенә кадерле, зарур сүзләрне хисләр дөнья-
на төреп әйтә ала торган талантлар. Хатын-кызларыбызны гына алыйк! Без Гөл-
ат Зәйнәшева исеме белән иртән авызыбызны ачабыз да, аның исеме белән кич-
ребезне тәмамлыйбыз. Гөлшатның бәрәкәтле иҗатына карата да зур сүзләребезне
тергә вакыт җиткәндер лабаса!.. Ә Клара Булатова иҗаты?.. Кларaның садә,
керсез шигырьләрендә чорыбыз хатын-кызларының язмышы тулысынча чагыл-
ыймыни?! Салисә Гәрәева, Лена Шакирҗанова, Флера Гыйззәтуллина, Эльмира
әрифуллина, Фирая Зыятдиноваларның нәтиҗәле иҗатларын һәр көн күреп, куа-
п яшәмибезмени?

Кыскасы, татар шигърияте бүгенге көндә һәр тарафтан егәрле, көчле, төрледән-
рле талант ияләрен туплаган күпкырлы шигърият.

Һәм шул шигърият бүген кемнәргә хезмәт итә? Аның кайнарлыгы, сүнмәс дәрте,
рлелеге кемнәргә юнәлтелгән? Һәм ул кемнәр күңеленә барып керә ала? Керә ал-
ый икән, ни өчен?

Бәхәскә катнашкан яшь тәнкыйтьчеләребездән Әхмәт Сәхапов болай диде: «Җан
шына китап сату буенча без РСФСРда иң соңгы урынны билибез!» Бу җөмләдә
ие «җан» сүзе сискәндерә. Димәк, безнең бүгенге поэзиябез татар халкының җа-
на хуҗа була алмый икән әле! Менә шундый аянычлы уйга китерә җанны өшетә
рган шушы сан!.. Атабыз да атабыз, безнең мишенебез юк икән лабаса!

Без «тисә тиенгә, тимәсә ботакка!» дип яшәүче ваемсызлар булып чыгабыз
гелме!?

Дачада мин бик кызыклы күрше белән яшәп ятам. Зиннур Мәгъсумов ул, сугыш-
н соңгы елларда Украинада бандеровчыларга каршы көрәшкән, яраланган, аннан
нрак гомере буе «Урак-чүкеч» заводында эшләгән, коммунист, хәзерендә пенсиядә.
 еш кына бер көймәдә аның белән балыкка керәбез. Җор кеше, татарча мәзәкләрне,
екдотларны меңне белә! Яраткан шагыйре Такташ! Әгәр кешенең яраткан шагый-
, табынган иҗатчысы бар икән — бу инде төшеп калган зат түгел! Ул тормышны аң-
ый, чөнки аның рухи ярдәмчесе бар. Шагыйрь — кеше җанының хуҗасы. Ша-
йрь — маякчы ул, җитәкләүче, кеше гомеренең бизәкчесе. Бүген Казан, Чаллы
амнарында канга-кан килгән үсмерләрнең җаннары юк, суык аларның күңелләре.
ушкин да юк аларга, Тукай да. Кешенең яраткан шагыйре — ул аның җан сакчы-
. Зиннур Мәгъсумовлар буынында әле татар шигъриятенә табынган, Тукайларны,
кташларны алла итеп санаган затлар бар иде. Әле моннан егерме еллар элек тә
тар шигъриятен иман иткән укучыларыбыз бар иде. Гамил Афзалны бик күпләр
лә! Илдар Юзеевның беренче поэмаларыннан өзекләрне егетләр кызларга атап
тларына теркиләр иде. Элегрәк һәр хат җыр белән тәмамлана иде!..

Һәр чын шагыйрь үз «яраннарын» таба, һәр укучы (әгәр аның җаны тере милли
н икән!) үзенә остаз-шагыйрь сайлап ала һәм бу ике җан бер-берсен тутырып яши-
р.

Әгәр бүген без «җан башына» китапларны иң аз таратабыз икән — бу арадаш-
к, шигърият белән укучы арасы, өзелгән, өзелеп җитмәсә дә күперләр җимере-
ргә тора дигән сүз... Арада карурман йә упкын, шигърият ни әйткәнне халык инде
етми, ишетсә дә аңламый, мие чүп-чарлар белән томаланган, аңа татарың ни дә,
агыйрең ни! Менә нәрсә аяныч! Безнең бәхәсчеләр тырышып-тырышып шигырь
елеше мәсьәләләрен чишәргә тырыштылар, темаларны ачыкладылар, казанышла-
быз, аянычларыбыз турында сүз көрәштерделәр, ә укучы, халык, милләт, теле-
нең һәм милләтебезнең үтә аяныч язмышы бер читтә кала килде.

Нигә без халкыбызның хәл эчендә икәнен шушы бәхәстә күтәреп чыга алмадык?..
әр укучыбыз юк икән, ни өчен без тырышып-тырмашып иҗат итәбез! Алга омты-
быз?! Нигә?! Чынлап һәм ныклап уйлаганда беренче чиратта шигъриятне үзгәртү
ында түгел, тормышыбызны, яшәешебезне, милли мәсьәләләребезне хәл итәргә ки-
. Һәм шигъриятнең бүгенге иң зур бурычы да шул инде — тормышны, кешеләрнең
кын үзгәртү дә бер дәрәҗәдә аңа йөкләнгән! Нигә без бу турыда изү чишеп, бил-
буып, йодрыкларны җиң эченнән чыгарып сөйләшмәдек икән?!

Мине иң нык борчыган мәсьәлә шул булды.

Йомгак ясап әйткәндә, мин халкыбызның егәренә ышанган кебек үк шагыйрь-
ребезнең көченә дә ышанам. Дөнья үзгәрер, һаман яхшы якка омтылыр, үтә авыр,
ген булса да — өметне өзәргә ярамый!

## Азат Әхмәдуллин:

Редколлегиянең сөйләшүендә төп бурычны мин бүгенге поэзиябезгә бәя бирүдән дә бигрәк, тәкъдим ителгән темага сөйләшү ничек барды, аның уңай һәм кимчелекле яклары нидән гыйбарәт дигән сорауларга җавап бирүдә күрәм.

Бәхәснең башлануында ниндидер ачыксызлык, оешып җитмәү бар иде: беренче мәкаләләрдә сүз поэзиянең үзе турында булудан да бигрәк, гомумән әдәбият, гомумән иҗат проблемалары, бигрәк тә оештыру мәсьәләләре хакында барды. С. Хафизов, бигрәк тә Т. Галиуллин мәкаләләре белән сүз үз эзенә төште, поэзия бәхәстә алгы планга чыкты. Нәтиҗәдә һәм, гомумән алганда, сөйләшү кызыклы һәм файдалы булды. Кызыксынып укырлык материаллар шактый басылды. Быелгы 1 санга кадәр чыккан 29 материалдан 17-18 е турыдан-туры темага карый торганнар булды, кай ягы белән булса да укучының игътибарын җәлеп итәрлек иделәр.

Шулай да бәхәснең «үтә-бурыч»ын (сверх-задачасын) мин бүгенге катлаулы заманыбызны чагылдыруда поэзиябезнең урынын дөрес билгеләүдә, бүгенге шигърияте безнең шул заман сорауларына җавап эзләп ирешкән казанышларын күрсәтүдә, гомумән бүгенге татар поэзиясенең азмы-күпме тулырак картинасын тудыруда күргән-теләгән идем. Тулы картина туды дип кистереп әйтүе, кызганычка каршы, мөмкин түгел.

Монда сөйләшүгә шигырьне һәм шигъриятне яхшы белә һәм нечкә аңлый торган Н. Юзиев, Р. Мөхәммәдиев кебек тәнкыйтьчеләрнең катнашмавы да билгеле бер роль уйнагандыр, әлбәттә. Әдәбиятка да, аерым жанрларга карата да нечкә күзәтүләргә ия булган Н. Фәттах, Г. Ахунов, Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, М. Госманов һ. б. кебекләр дә тавыш-тын чыгармадылар. И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Зөлфәт шикелле шагыйрьләрнең катнашмавыннан да бу сөйләшү күп нәрсә югалткандыр.

Ә инде бәхәскә катнашып, чыгыш ясаган шагыйрьләрдән Әхсән Баян, Гәрәй Рәхим, Нури Арсланов, Әхмәт Рәшитов, Роберт Миңнуллиннар сөйләшүгә җанлылык өстәделәр, кайбер бәхәсле, урыны белән кабул итүе авыр булган фикерләренә дә карамастан, диспутның кайнарлыгын тәэмин иттеләр.

Бәхәс «заман һәм шигырь» дип аталган иде. Заман үзенчәлекләрен шигърият ярдәмендә аңлый һәм аңлата белү җитәме бездә? Сорауга җавап ачылып бетмәде. Ләкин барлык мәкаләләрнең рухыннан чыгып караганда «җитми» дигән җавап дөрестер кебек. Культ чорында да, торгынлык елларында да әдәбиятыбыз, шул җөмләдән поэзиябез дә, асылда ярымдөреслек белән, бизәлгән тормыш материалы белән эш йөртте. Ул вакытларда иҗат ителгән күпчелек әсәрләр белән чынбарлык арасында, хакыйкать ноктасыннан килеп караганда, шактый зур аерма күрәбез. Хәзер исә гел бертөрле матурлык төсләренә күнегеп беткән шагыйрь алдында гаҗәеп төсләр күплеге һәм байлыгы ачылып китте — заманыбызның байлыгыннан һәм катлаулылыгыннан, яңа төшенчәләрдән килеп туган төрлелек бу! Ә шагыйрь аптырабрак калды, фәлсәфи яктан да, рухан да ул аларны сурәтли башларга әзер түгел булып чыкты. Монда шагыйрьнең үзеннән дә бигрәк, чор, замана, кичәге көн гаепле, әлбәттә. Ләкин иҗади кыюлыкның җитмәвен дә танырга тиешбез.

Тагын да бер момент. Кичәге ярымдөреслек әдәбиятыннан бүгенге чын мәгънәсендәге художестволылыкка (ә дөреслек — художестволылыкның төп билгесе!) күчеп баруыбызны, һәрхәлдә, шулай булырга тиешлекне барыбыз да таныйбыз. Ләкин поэзиябезнең аксакаллары Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов һ. б. турында сүз чыкса, әйтерсең лә, алар ул чорларда да гел дөреслекне генә язган дигән фикер уздырабыз. (Мәсәлән, моны Г. Рәхим мәкаләсендә күрергә мөмкин.) Әйе, алар ул чордагы әдәбиятның алдынгырак, «сул канатын» җитәкләгәннәр, алар поэзиясендә дөреслек күбрәк. Чөнки художестволылык югарырак (яки киресенчә). Шулай да, әйдәгез, икърар итик: шул вакытлардагы гомуми шартлар һәм эстетик тенденцияләр нигезендә һәм тәэсирендә андый алдынгы шагыйрьләр дә ярымдөреслек рухында күп яздылар. Әгәр дә бүгенге шартлар, бүгенге демократия һәм курыкмыйча сөйләү мөмкинлекләре булса, бу талантлы художниклар тагын да әллә нинди шедеврлар биргән булырлар иде...

Сөйләшүдә шигърият һәм шигырь турында М. Горький әйткәннәр, авторы искә алынмый гына, кат-кат яңгырады: «Шагыйрь — чорның күзе, колагы һәм вөҗданы»,— дигән ул.

В. Г. Белинскийда бу фикер тагын да тулырак яңгырый: «Һичбер шагыйрь үзеннән-үзе: үз кичерешләре белән дә, борчулары белән дә, шәхси бәхете аркылы да бөек була алмый. Һәрбер шагыйрь, аның борчулары һәм бәхете җәмәгатьчелекнең һәм тарихның җирлегеннән тирән тамыр җәйгәне, шагыйрь, димәк, җәмгыятьнең, заманның, кешелекнең теле һәм вәкиле булганы өчен генә бөек».

Тел төбен аңлыйсыздыр: бәхәс-сөйләшүдә шагыйрьнең шагыйрьлек роле, гомумән шагыйрь шәхесе турында сүз булмады. Хәлбуки, поэзиянең гражданлык егәрлеге аны иҗат итүче шагыйрьнең шәхси сыйфатлары белән дә нык бәйле. Шагыйрьнең җәмгыять тормышында актив катнашуы аның иҗатын активлаштырып кына да калмый, аның иҗатының дәрәҗәсен күтәрә. Ә бит бездә шешә белән дус булып, милләт язмышын, халык язмышын айныганда гына кайгыртып яшәүчеләр дә юк түгел. Шигырь дөньяны танып-белү теләге белән генә язылмый, ә аны яхшырак, матуррак итү теләге белән дә сугарып языла. Ә иҗтимагый тормыштан аерылган кеше ни дәрәҗәдә халкының бүгенге ихтыяҗларын тирән аңлый да, аның киләчәктәге урынын дөрес билгели?!

Бәхәстә укучыларның үзләренә дә урын киң бирелде, унбишләп чыгыш булды. Болар, бердән, сөйләшүне җанландырды. Икенчедән, әле поэзиябезнең укучылар каршында абруе бар икәнен күрсәтте, аның тормышчан җирлеген күрергә ярдәм итте.

## Мәдинә Маликова:

Шигърият — рәсем сәнгате кебек үк, хисле дә, нәзберек тә, һәр барчабызның күңелләренә бик тансык та бер дөнья ул. Аның хәзинәләре хакында сүз кузгатканда, без тере, җанлы, үтә дә үзенчәлекле әйбер хакында сөйләшкәнебезне аңлап тотынырга тиешбез.

Тиешле ноктага басып карыйбызмы без аңа, яктылыкны көйләдекме, күңел кылларыбыз кирәгенчә тартылганмы? Игътибарны тупладыкмы, артка, як-якка борылып, һәртөрле вак-тояккә дикъкатебезне сибеп вакланмыйбызмы?

Минем уемча, мондый сөйләшүне без шигъриятебезнең иң гүзәл әсәрләре каршына басып башлап җибәрергә тиеш идек. Җыр-шигырьгә тартылмаган таш күңелле адәмнәр дөньяда сирәктер, бигрәк тә безнең халкыбызда. Таланты-көче барын-югын исәпләп тормыйча, йөрәк тибрәнешләрен такмак итеп әйтергә һәм шуны башкаларга ирештерергә ашкынучылар да җитәрлек. Бу омтылыш бик табигый, әмма аннан һәр очракта да шигырь дөньяга килә дигән сүз түгел. Шигърият түтәлләре тирәсендә кычыткансы, тигәнәге, тузганагы, ромашкасы күп үсә һәм үсәчәк. Мин үзем асыл гөлләрдән генә торган дөньяны күз алдыма да китерә алмыйм, андый дөньяда, бәлки, чәчкәләрнең матурлыгы күзгә дә күренми башлар иде. Шунлыктан, бездә такмакчылар яисә графоманнар үрчи дип борсалануны мин кысыр хәсрәт дибрәк кабул итәм.

Мәсьәләнең икенче ягы аннан бик күпкә мөһимрәк: бармы бездә чын шигърият әсәрләре? Шигъриятнең дәрәҗәсе беренче чиратта аның казанышлары белән билгеләнергә, гөл чәчәкләренең гүзәллеген түтәл читендә үсеп чыккан әрем куләгәләмәскә тиеш. Тезмә итеп язылган һәр юлга туктап тормасак та буладыр. «Яшь каләм иярләренең беренче китапларына бик күп акча тотыла», диләр. Ә безнең китаплар бик күп мең сумнар керем китерә. Бу — беренчедән. Икенчедән, әгәр шул беренче китаплардан бер генә шигырь җырга салынып, миллион кеше тыңласа һәм җырласа, тотылган чыгым кайтарыла. Без яшьләрдән бу акчаны кызганмаска тиешбез.

Мин үзем безнең шигъриятебез хәзинәләргә бик бай, тик без ул байлыкны барлап, тиешле яктылыкта яктыртып, аны карау, кабул итүнең нәкъ тиешле ноктасын билгеләп, халыкка җиткерә генә алмыйбыз дип исәплим. Әле шушы арада гына миңа хатын-кызларыбызның шигъри китапларын актарып чыгарга туры килде. Йөрәкне кузгата, күңелне җилкетә, күзләрне яшьләндерә, җан азыгы бирә, сафландыра торган күпме әсәрләр таптым мин аларда! Күпме шигырьләр, музейларның караңгы, кысан запасникларында бикләнеп яткандай, халыкка билгесез булып кала әле безнең! Ике-өч мең тираж белән, күрексез тышлык эчендә, сары кәгазьдән, юлларны бер берсенә терәтеп дигәндәй тыгызлап басылган китаплар чыгару — ул әле шигырьне халыкка илтеп җиткерү дигән сүз түгел. Информация ташкыны көчәйгәннән-көчәйгән бу заманда нәкъ менә тәнкыйтьчеләр китапларга сибелгән асыл ташларга укучыларның игътибарын юнәлтә алырлар иде. Яхшы шигырь үзенә юл ярып кенә ышанып ятып булмый. Әгәр әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр бик күп көч куймаган булса, мөгаен, Пушкин да бөтен даһилыгы белән безнең чорның һәр кешесе күңеленә килеп ирешә алмаган булыр иде.

Әйе, безгә караңгыда калган әсәрләребезне яктыга чыгарырга, аларның иң асыл, кыйммәтле якларын тиешенчә яктыртырга, чын бәһасен ачыклап бирергә кирәк. Бәя биргәндә бизмәннәр турында да бик нык уйларга кирәк. Әйтик:

*Кистем таллар, иштем баулар,*
*Саллар салдым суларга.*

*Барыр юлым уңга да бит,*
*Җилләр исә сулларга...*
*(Хәсән Туфан.)*

*Егерме гасырлык халык—*
*Мәңгелек башы гына.*

*Баш идерә баш очына*
*Куелган ташы гына.*

*(А. Минһаҗева. «Болгарда уйланулар».)*

— кебек юлларны нинди герләр белән үлчәргә дә, нәрсә белән чагыштырырга?

Шигърият хакында салкын күңел белән сүз алып барып булмый. Бәлки шуңадыр, бу бәхәстә миңа аеруча шагыйрьләрнең мәкаләләре уңышлы булып тоелды. Әхсән Баянов, Гәрәй Рәхим, Роберт Әхмәтҗанов, Әхмәт Рәшитов, Рахмай Хисмәтуллиннарның сүзе миндә зур теләктәшлек тапты.

Ә тәнкыйтьчеләр?

Кайбер очракларда аларның сүзе артык тыныч сөйләнде шикелле. Һәм бу сүз шагыйрьләргә төбәп әйтелде кебек. Кайбер очракларда тәнкыйтьчеләр шагыйрьләргә барыр юлны күрсәтергә, хәтта әйдәп барырга тиешле дигән фикер әйтелә. Ләкин шагыйрь үзе халыкны әйдәп барырга тиешле илһам иясе бит. Әгәр ул башка бирәү күрсәткән юлдан күндәм атлый һәм хәтта аның бармагына тотынып бара икән, ул нинди әйдәүче булсын?

Минемчә, тәнкыйтьченең изге, зур бурычы — беренче чиратта шагыйрь белән укучыны табыштыру, очраштыру. Бу — һич тә шагыйрьләрнең каршында тәнкыйтьченең дәрәҗәсен төшерү түгел. Тәнкыйтьченең бәясенә, аның сүзенә карап, шагыйрь үз бәясен белә ала, үзенең кая барганын, кай тарафка әйдәгәнен ачыклый. Бу үзе дә бик олы нәрсә.

## Флүн Мусин:

Бу дискуссия моңа кадәр булганнары белән беркадәр аваздаш та, шул ук вакытта кайбер моментларда алардан аерылып та тора. Иң мөһим аермаларның берсе, минемчә, сөйләшүдә катнашкан кайбер иптәшләрнең хәзерге хәбәрдарлык һәм демократия рухында үз фикерләрен курыкмыйча әйтүләрендә. Поэзиядә тәнкыйтьтән өстен торган яки бөтенләй диярлек тәнкыйть игътибарыннан, шуның белән бергә киң җәмәгатьчелек игътибарыннан да читләштерелгән, күләгәдәрәк калдырып киленгән шагыйрьләр мәсьәләсенә игътибар бирү дә дискуссиянең яңарак сыйфатларыннан исәпләнергә тиеш.

Башка дискуссияләрдәге кебек, монысыннан да мин хәзерге әдәбиятыбыз, бу очракта поэзиянең торышын ачыклауны көтмәдем. Чөнки мондый максатка бары махсус фәнни тикшеренүләр ярдәмендә генә ирешергә мөмкин. Шулай да сөйләшүдә әлеге мәсьәлә буенча аерым кызыклы гына күзәтүләр ясалуын әйтергә кирәк.

Гомумән алганда исә миндә бу дискуссиянең максаты ачыкланып җитмәгән яки ул хәзерге таләпләр югарылыгында ук алып барылмады дигән тәэсир калды. Исеме «Заман һәм шигырь» дип бирелгәч, мин анда сүз күбрәк шигъриятнең заман тормышында ничек катнашуы, илдә үзгәртеп кору процессына ничек булышуы турында барыр дип уйлаган идем. Чөнки бүгенге көндә әдәбият-сәнгатьнең иң төп һәм иң изге бурычы шуннан гыйбарәт. Халык та, партия дә хәзер алар өстенә шушы бурычны йөкли. Моңа әдәбият-сәнгать әһелләре, әлбәттә, беренче чиратта кешеләрнең күңелләре аша, аларны җәмгыять тормышын яңарту өчен актив көрәшкә рухландыру юлы белән ирешә алалар.

Безнең хәзерге поэзиядә бу яктан эшләр ничегрәк тора соң? Аның халыкта авторитеты ни хәлдә? Шушындыйрак сорауларга да җавап көткән идем мин яңа гына тәгәлләнгән дискуссиядән. Мондый сорауларга җавап бирелмәү һич тә очраклы хәл түгел, минемчә. Чөнки хәзерге поэзиянең генә түгел, гомумән әдәбиятның тормышыбызда тоткан урыны мәсьәләсе бездә бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, монда аерым фараз кылулар гына очрый. Хәлбуки, безгә хәзер әдәби иҗатның практик нәтиҗәсе, укучыларга нинди йогынты ясавы турында да ныклабрак уйланырга кирәк. Әдәби дискуссияләрдә дә бу мәсьәләгә игътибар бирелсен иде.

## Ризван Хәмид:

Әдәби бәхәс материалларын яңабаштан һәм рәттән укып чыккач, мин үзем шәхсән канәгатьлек хисе кичердем. Бу, һичшиксез, кирәкле һәм шифалы сөйләшү булды, шигъриятебезне күзаллауда яңа төсмерләр ачылды, борчылырлык проблемалар билгеләнде, дөреслеккә якын «диагноз» куелды.

Укучыны иң нык инандырганы һәм куандырганы — әдәби бәхәснең югары зәвыклы булуы, минемчә. Төпле һәм эчкерсез, гамь һәм ваем белән тулы фикерләр өстенлек итте. Шигъриятебез бүген дә бай, бүген дә үткен икән!

Әмма, шулай да, әдәби бәхәс, кызганычка каршы, бераз сагайта да. Кайбер авторлар бәхәс трибунасының ни дәрәҗәдә олы икәнлеген истән чыгардылар сыман. Яисә, киресенчә, нәкъ шуны файдаланып эш иттеләр. Югыйсә, җыелышларда яки секция

утырышларында гына үзара иптәшләрчә әйтеләсе сүзләрне җитмеш меңле аудитория каршысында кычкырмаслар иде! Мисал өчен, кайбер шагыйрьләрнең коллегалары иҗатына пәйгамбәрләрчә хакыйкать хуҗасы буларак кистереп бәя бирүләре үч алырга тырышуны хәтерләтә. Үз иҗатының күләгәдәрәк калуының сәбәпләрен популярлык казанган авторлардан күрү һәм аларны «фаш итәргә» тырышу саксызлык кына түгел инде. Дөрес, плюрализм заманы, һәркем үз фикерен беркемнән дә курыкмыйча, авыз тутырып әйтә ала. Ләкин бит әйтүнең дә культурага сыймаганнары була. Нури абый Арсланов бик вакытлы искәртә: әдәбият «әдәп» дигән сүздән ясалган. Бәхәскә катнашкан укучылар моны кайбер әдипләребезгә караганда әйбәтрәк беләләр ахрысы, дорфалык һәм мин-минлек тезгенен алар катырак тота белүләрен күрсәттеләр.

## Әхәт Гаффар:

Әдәбият бәхәссез яши алмый. Борынгы заманнарда ничек булгандыр, моны инде һичкем белмәс — шаһитнамәләр калмаган, таш хәрабәләр телсез. Ә Тукай чорында әдәби бәхәсләр шактый ярсу куелган. Толстойның Шекспирны кабул итмәгәне кебек, Г. Ибраһимов та «Тукай шагыйрьме, түгелме?» дип язып чыккан. Моның ише кабыргасы белән куелган бәхәскә чын бәяне фәкать халык кына бирә. «Борынын каната-каната» фәкать тарих кына ачыклый.

Әйе, ялгышулар булды. Бөек Пушкинны бер селтәнү белән тарих чүплегенә ташлап калдырырга омтылган вакытлар булды. Тукайны «вак буржуаз шагыйрь» дип игълан итеп, безнең мәдәниятның башын чабып ата язмадылармыни? Тора-бара Пастернак, Анна Ахматова кебекләрнең бугазларыннан алдылар. Хәсән Туфан, Фатих Кәримнәрне, халык дошманы дип хөкем итеп, Себерләргә сөрделәр. Халык та шагыйрьләр һәм җәлладлар арасына калкан рәвешендә басарга атлыгып тормады. Ул кая төртеп күрсәтсәләр, шул тарафны сүгәргә дә күп сорамады. Ул шуңа мәҗбүр ителде. Әгәр дә мин бер заманны: «Чын шагыйрь төрмәләрдә генә тизрәк җитлегә»,— дип чыкканмын икән, бу тәгъбирнең асылында хакыйкать ятканын танырга кирәк. Моңа Муса Җәлил язмышы мисал.

Әлбәттә, сүз беркадәр вакланудан — ягъни шигырь китапларын бастырып чыгару нәшрият кесәсенә сугудан, кайбер шагыйрьләрнең китаплары кибет киштәләрендә тузан җыеп ятуларны искәрүдән башланган иде. Кыскалык өчен, башкаларны кабатламас өчен, шуны әйтәм: әгәр мәдәниятка бәгъзеләр табыш чыганагы итеп карыйлар икән, бүгенге заманда әдәбиятның мәет кортлары кимерә башлаган әхлагыбызны дилбегәдә тотучы төп көчләрнең берсе булганлыгын танудан баш тарталар икән, әйдәгез алайса, татар китабы басарга бирелгән эт теле калынлыгындагы акчаларыбызны дуңгызлар симертүгә тотыйк.

Тагын шунысы да бар: бүген исән шагыйрьләрнең китаплары дәүләт кесәсенә суга икән, бу чыгымны вафат шагыйрьләребезнең китаплары капламыймыни? Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан шигырьләрен, Г. Ибраһимов, М. Галәү, Г. Әпсәләмов прозасын бастырып сатудан нәшрият һәм дәүләт күпме табыш ала икән? Нигә моның санамыйбыз? Ахыр килеп, бу чыгымнарны безнең проза китаплары да каплый түгелме?

Икенчедән, Тукай шигырьләрен, «Кыйссаи Йосыф» китабын, төрле дастаннарыбызны төн йокламыйча елый-елый укыган халкыбыз бүген шигырь китаплары сатып алуның тәмен югалткан икән, моңа кем гаепле соң? Шулай ук шагыйрьләр микәнни? Сталин һәм аның тарафдарлары халыкны шул дәрәҗәгә җиткерде ки, шагыйрь белән укучы арасында төпсез упкын хасил булды.

Без ни өчен шигъриятнең бер асыл сыйфатын сайлап алып, шул хакта сөйләшә алмадык, ә бәлки күбрәк шагыйрьләрнең шәхси сыйфатлары тирәсендә тулгандык? Чөнки төрлечә фикер йөртүдән моңарчы мәхрүм ителеп килгәнгә күрә, җәмгыятьтәге кара таплар хакында сүз йөртүдән куркытылып бетерелгәнгә күрә, безнең аңыбыз бик түбән даирәләр тирәсендәрәк буталырга өйрәнде. Экономикада нидер тиешенчә түгел икән, колхоз бригадирын яки цех мастерын тәнкыйтьләүдән узмадык. Әхлак тәрбиясендәге җитешсезлекләр хакында сүз кузгалса, башлап язучыларга таш яуды. Тегеләре дә, болары да бәйле, юаш халык. Әдәбиятта түрәләрнең яраткан язучылары барлыкка килде. Шулар калыбына сыеша алмаган һәркемгә түбәнсетеп карадылар, күрмәмешкә салыштылар. Үткенрәк, тавышыңны күтәребрәк сүз катсаң, син — сөйкемсез сөяк. Кемнең шул хәлгә каласы килсен? Менә китте стандарт шигырьләр, игезәк шигырьләр, тешсез шигырьләр.

Бездә шагыйрьнең чәнечкесеннән куркалар. Ләкин ул чәнечке гөрләп чәчәк атып утырган роза гөле сабагының чәнечкесе ләбаса!

Минемчә, шигърият турындагы бәхәстә шушыларны һәм шуның кебек нәрсәләрне ачыклау җитмәде. Берәүләребез шигырьләрне шагыйрьләрнең язмышыннан аерып

тикшерде, бүтәннәребез шагыйрьләрнең шәхесләрен микроскоп пыяласына куйды. Нәтиҗәдә безнең шигъриятебез шактый фәкыйрьләтеп, бичаралатып күрсәтелде.

Инде, чыннан да, илаһиларны әзрәк дип тапканбыз икән, күктә кояш белән айның да берәр генә икәнен искә төшерик һәм йолдыз белән йолдыз арасында зур бушлык ятканын онытмыйк.

Мин Аяз Гыйләҗев фикере белән килешәм: татар шигърияте бүген мең еллык тарихының яңа сәхифәләрен яза. Шигырь сәнгатьтә, җәмгыятьтә үзенең социаль көчен кире кайтара. Утызынчы, кырыгынчы елларның канлы дәһшәте генә кире кайтмасын!

## Марсель Галиев:

Һәр халыкның бөек шәхесләре бар. Әмма һәйкәлләр күбрәк шагыйрьләргә куела. Моның сәбәбе нидә? Берьяклы гына аңлату да мөмкин түгелдер. Зур шагыйрь, үлгәннән соң, гадәти шәхес киемennән чыгып, үзенең шигърияте биеклегенә күтәреләә һәм легендага әверелә. Җирдәге тормыш агышыннан биектәрәк торган шигърияtнең ярлары һаман алгарак чигенә тора, заман-вакыт аны куып җитә алмый, әхлак-эстетик нормалар үзгәрсә дә, үз чоры гаменнән чыгып, яңа төсмерләрен ача гына бара. Метафора, аз сүз белән тыгыз мәгънә бирә алу кодрәте кеше гомерен озайтырга тырышу, вакыттан алгарак сикерергә теләүдән туадыр мөгаен. Һәр халык үзенең үткәне һәм киләчәге арасында хәтерен мәңгеләштерү өчен, маяклар итеп, сөекле шагыйрьләрен постаментка менгерә, ягъни шигърият каршында баш ия.

Әнә шундый илаһи көчкә ия галиҗәнап поэзия турында сөйләшүне югарырак тонда алып барырга иде. Мәкаләләрнең күбесе поэзиябез казанышларын бәяләүдән читләшеп, аның тирәсендәге хәлләргә, укучыга әһәмияте булмаган мәсьәләләргә артыграк басым ясады. Нишлисең, бәхәс культурасына ни дәрәҗәдә ирешүебезне күрсәтеп торган фалдыр бу.

Популярлык, шигъриятькә мәхәббәт тәрбияләү хакында сөйләшәбез. «Казан утлары»н, бик нык киметеп әйткәндә, йөз мең кеше кулына ала дип карыйк. Ә безнең шигырь китаплары ике-өч мең данә басыла. Димәк без 997 мең укучыга бөтенләй таныш булмаган әсәрләр, авторлар турында сөйлибез. Радио авазы республика чикләреннән саркып кына чыга. Телевидениене якын-тирә районнарның хәтсезе карый алмый. Бердәнбер юл — эстрада кала. Сәхнә бары тик юморга хирес. Әнә шулай итеп капма-каршы килеп тармакланган күпме проблемалар калка.

Тукайның «Шүрәле»сен белмәгән татар кешесе юктыр. Сәбәбе? Бу әсәр мәктәп дәреслекләренә кертелгән. Йөз меңнәрчә тираж белән кабат-кабат басылган. Бусы бер. Икенчедән, «Шүрәле» сюжетлы шигырь. Хикмәт шунда: иксез-чиксез шигърият дәрьясыннан хәтер нигәдер әнә шундый сюжетлы шигырьләрне каерып ала. Ренат Харис диюгә мин «Ат иярләү» поэмасын искә төшерәм. Равил Фәйзуллинның «Кем шакымас толлар ишегән» дигән шигырен, Зөлфәтнең аюга пычак белән барган, мәхәббәт каршында самими абзыен («мәхәббәт») күз алдына китерәм. Һәр шагыйрьнең иҗат хәятында әнә шундый трагик тормыш детале салынган һәм башка әсәрләрдән җыеп торган алтын баганалары булырга тиеш. Әсәрдә трагедия табигый ноктасына җитсә, кеше күңеленә шәфкать нуры салып, бәгырен ачып ташлый. Ялган оптимизмга күңел капкалары ябыла. Ә күпме каләм тузган шундый үтә күренмәле, эт сикертә торган көйгә такмаклар язып...

Ел буена барган сөйләшү-бәхәстә шигырьнең хикмәте, сүз егәре, матурлыгы, ачышлары турында читтән өйрәтеп, акыл биреп түгел, ә укучы белән янәшә торып, бергә-бергә сокланырга, уйланырга кирәк иде. Кызганыч, бай шигъриятебез каршында без тагын бурычлы калдык.

## РЕДАКЦИЯДӘН

Шулай итеп «Заман һәм шигырь» дискуссиясен йомгаклар чак җитте. Билгеле булганча, бу бәхәс Р. Мостафин белән В. Нуруллинның журналыбызда басылган (1988 ел, 1 сан) әңгәмәсеннән башланып киткән иде. Бәхәсне дәвам итеп, аннан соңгы һәр санда 2-3 материал дөнья күрде һәм дискуссия вакыт ягыннан ел ярым чамасы барды. Әдәби бәхәстә барлыгы 42 кеше катнашты. Аларның 9 ы шагыйрь, 1 се прозаик, 6 сы тәнкыйтьче, 12 се яшь тәнкыйтьче һәм 14 е укучы иде.

Дискуссия барышы нәрсә күрсәтте соң?

Анда катнашкан бик күп авторлар хаклы рәвештә шуны билгеләп үттеләр: мең еллык тарихы һәм гаять бай традицияләре булган татар шигърияте бүген дә көчле һәм ил-күз алдында сынатырлык түгел. Аның сафында өлкәннәр дә, урта һәм яшь буын шагыйрьләр

дә актив иҗат итәләр. Газета-журналларда һәм китапларда халык күңеленә хуш килердәй шигырьләр, поэмалар басыла. Әйбәт кенә әсәрләр радио һәм телевидение аша да, сәхнәдән дә яңгырыйлар. Аларның байтагы замандашыбызның рухи юлдашына әверелә, татар совет поэзиясе хәзинәсен тулыландыра.

Әлбәттә, үсештәге, хәрәкәттәге һәрбер күренеш кебек, шигърият алдында да һәрвакыт яңа бурычлар һәм хәл ителәсе проблемалар туа тора. Дискуссия аларны да ачыкларга ярдәм итте.

Чорыбыз катлаулылыгын һәм драматизмын чагылдыруда әле безнең поэзиягә еш кына очракларда кыюлык җитми. Замандашларыбыз йөрәгендә кайнаган бик күп җитди хисләр һәм кичерешләр бүгенге шигъриятта калку урын таба алмый.

Шулай ук хәзерге поэзия әсәрләренең сәнгатьлек дәрәҗәсен, шигърилеген, укучыга тәэсирен — образлылыгын көчәйтү буенча да шагыйрьләребезгә тырышлыкны арттырасы бар. Шигъри егәре аз булган, көпшәк эчтәлекле яки яңа мәгънә алып килмәгән строфалар санын да киметү сорала.

Бәхәс барышында шигырьне пропагандалау эшен көчәйтү кирәклеге дә әйтелде. Иң яхшы шигырьләр вакытлы матбугат битләрендә үзләренең лаеклы урынын алырга тиеш. Ярыш чоры тарафыннан үзенә йөкләнгән зур гражданлык бурычын ул кыюрак, тулырак үтәргә тиеш. Шулай ук радио-телевидение һәм сәхнә аша да иң яхшы әсәрләрне пропагандалау буенча әле файдаланылмаган мөмкинлекләр бар.

Иң мөһиме, әлеге чаралар ярдәмендә күп меңләгән халык массаларының шигърияткә карата игътибарын булдырырга, мәхәббәтен уятырга кирәк. Авыл, район һәм республика күләмендә шигъри ярышлар уздыру традициясе яңарса да яхшы булыр иде. Анда җиңүчеләрнең ел саен апрель аенда үткәрелә торган шигырь бәйрәмендә катнашулары исә әдәби бәйрәмебезне тагын да күркәмрәк, халыкчанрак, киң масштаблырак итәчәк.

Яшь буында шигърияткә мәхәббәт тәрбияләү — бик зур социаль, әхлакый һәм эстетик проблема булып тора. Дөресен әйтергә кирәк, әлегә бу эш безнең халыкта һәм мәктәпләребездә үтә начар куелган. Шигъри тәрбия җитмәү ул — гармоник шәхес булмау дигән сүз. Бу — күп төрле күңелсез күренешләргә, тенденцияләргә юл ачу дигән сүз!

Яшьләрне шигъри күңелле итеп тәрбияләү өчен, әлбәттә, тәрбиячеләр үзләре поэзияне яратырга, аны нечкә тоярга тиешләр. Димәк, республикабыз югары уку йортларында — иң беренче чиратта Казан дәүләт университетында һәм педагогия институтында студентларга, димәк — булачак укытучыларга — шигъри тәрбия бирүне төрле юллар белән көчәйтү хакында бик нык уйлыйсы бар. Әлеге уку йортлары милли культураны үстерү учаклары булып әверелергә тиешләр! Алардан халык шуны көтә, чор шуны таләп итә! Безнең югары уку йортлары мәктәпләргә — бүгенге тәрбия эшенең иң кайнар фронтына — чын энтузиаст яшьләрне җибәрергә тиешләр!

Шунысын да истән чыгармаска кирәк: шигырь аша без халкыбыз күңелен, аның рухын һәм җанын тәрбияләбез, формалаштырабыз. Димәк, шигырь ул — сәнгать кенә түгел, ул тәрбия чарасы да, ул идеология дә! Шуңа күрә шигырьгә һәм шигырь китабына караш та бик җитди булырга тиеш. Аңа товар дип кенә карау һич тә дөрес түгел!

Шигырь китапларын халыкка җиткерү эшендәге, аерым алганда китап сәүдәсендәге зур җитешсезлекләр укучыларыбызда хаклы ризасызлык тудыра. Илебезнең төрле регионнарында татар китабына заказлар җыйнауның оештырылмавы да, халыктагы зур ихтыяҗ өйрәнелмәү һәм искә алынмау да, бигрәк тә китап сәүдәсендә культура түбән булу — эшкә нык зыян китерә. Китап сәүдәсендәге кадрлар мәсьәләсе аеруча дикъкать сорый. Без аларны заман таләпләренә җавап бирердәй, җитди эш кешеләре итеп әзерлибезме? Бу өлкәдә таләпләр йомшармадымы? Китап кебек олы рухи хәзинә белән эш иткәндә гаять зур җаваплылык сорала. Милли шигырь китаплары исә бүген үзләренә бигрәк тә көчле игътибар сорыйлар.

Поэзия тәнкыйтен активлаштыру кирәклеге дә дискуссиядә үзәк тема булды. Өметле яшь тәнкыйтьчеләр күренүне күп авторлар канәгатьлек белән искә алдылар. Ләкин бүгенге поэзия белән шөгыльләнүче профессиональ тәнкыйтьчеләрнең азлыгы урынлы борчылу уята. Поэзиянең иң актуаль проблемаларын вакытында күтәрү, көндәлек матбугат битләрендәге әдәби тәнкыйтьнең оперативлыгына ирешү — әле бурыч булып тора.

Шулай ук әдәби бәхәс барышында күп кенә бүтән кимчелекләр дә ачылды. Аларның берсе — катнашучыларга дискуссия культурасы җитенкерәмәү. Ул — бәхәстә төп сүзне эзлекле рәвештә дәвам итә алмау булып та, уртак бурычларны онытып, үз мәнфәгатен генә кайгырту булып та, гадел тәнкыйть сүзен күтәрә алмау булып та һ. б. рәвешләрдә чагылды. Алдагы дискуссияләрдә болар кабатланмасын иде.

Бәхәстә укучыларның шактый актив катнашуы һәм аларның татар халкы яшәгән регионнардагы хәлләрне яктыртуы уртак эшебезне яхшыртуга, һичшиксез, булышачак.

Дискуссия тәмам. Анда катнашкан авторларга редакция үзенең зур рәхмәтен белдерә. Киләчәктә дә безнең белән элемтәдә торыгыз!

## Гариф Ахунов

# БҮГЕНГЕ ТАТАР РОМАНЫ

КАЙБЕР КҮЗӘТҮЛӘР

Моннан нәкъ ун ел элек РСФСР Язучылар союзының Проза советы үзенең бер утырышын Казанда үткәрде. Татар язучыларының 12 романын һәм повестен тикшереп, фикер алышканнан соң, Советның председателе — күренекле рус совет язучысы Сергей Павлович Залыгин болай диде:

— Күреп торабыз, татар прозасы бүген билгеле бер югарылыкка күтәрелгән. Моны берәү дә инкарь итә алмый. Бу — яхшы. Инде алга таба тагын бер адым атлар өчен, сезгә, хөрмәтле каләмдәшләр, гаять зур тырышлык белән, күңел газаплары һәм тетрәүләр кичереп, вакыт-вакыт инстанцияләрдә кире кагылып, каргалып һәм тиргәлеп, армый-талмый эшләргә, аңлы рәвештә фидакарьлеккә, гражданлык батырлыгына барырга туры киләчәк. Культура дөньясында туган вакыйгалар гомер буе, гасырлар буе кемнәрнеңдер бөек фаҗигаләре белән бәйле булган. Ерак китәсе юк, сезнең Тукай, Җәлил, Ибраһимовлар — моның мисалы.

Әйе, әнә шул ифрат дәрәҗәдә житди һәм олпат киңәшмәдән соң ун ел вакыт узып китте. Минемчә, бу Сергей Залыгин әйткән «тагын бер адымны атлар өчен» җитәрлек вакыт. Әлеге чорда прозабызда, аның бигрәк тә роман жанрында бер адым алга китү өчен без нинди тырышлык куйдык? Нинди күңел газаплары кичердек? Аңлы рәвештә нинди фидакарьлеккә, гражданлык батырлыгына бардык? Ирешкәннәребез нәрсәне раслый, нәрсәне кире кага?

Иң әүвәл сан ягына күз салыйк. Ун ел эчендә без 20 дән артык роман иҗат иткәнбез. Бу — ифрат зур сан. Әгәр аларның һәркайсы ил күләмендә чыгардай вакыйга булса, халыкта танылса, без чиксез зур байлык тудырганыбызны аңлар идек. Юк, без коры шапырынудан, барыбыз да бердәй тигез югары кимәлдәге романнар иҗат иттек, дип әйтүдән ерак торабыз. Әмма бер хакыйкатьне шулай да танымый мөмкин түгел. Татарстан язучыларының IX, X съездларының ясалган хисап докладларына күз салсак, без анда биш ел саен 10 яки 12 роман язылып барганын күрербез. Димәк, ел саен ике роман язылу — бу инде стабильләшкән сан. «Сугыштан соңгы чорда бер елга 6-7 роман язылган вакытлар да бар иде»,— дип әйтүче дә табылыр. Бәхәсләшмибез, бар иде андый бер чор: «Тукай», «Язгы җилләр», «Намус», «Онытылмас еллар», «Алтын йолдыз», «Җәяүле кеше сукмагы» сугыштан соңгы беренче елларны, тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, 1948 елны басылып чыктылар. Алар татар романының алтын фондына керделәр. Шуннан соң Габдрахман Әпсәләмов романнары, Атилла Расих романнары дәвере башланды.

Бу урында мин укучыларның игътибарын бер нәрсәгә юнәлтү кирәк дип уйлыйм. Сугыштан соң балык көтүе кебек дәррәү килгән романнар утызынчы елларда бик озак әзерләнгәннәр иде инде, сугыштан соң алар өермәле-давыллы илһам белән, тыныч тормышны, язу өстәлләрен сагынган каләм ияләре тарафыннан ак кәгазьгә төшерелделәр генә. Кан коюлы, фаҗигале авыр Ватан сугышындагы дүрт елны, аңарчы узган елларны бергә кушып исәпләсәк, ул романнардан соң прозада башланган һәм биш елга сузылган кытлыкны да китереп кушсак, әлеге җиде роман бер елга берәү дә туры килми икән. Озак туа роман, зарыктырып-көттереп туа. Шуңа күрә кабатлап әйтәм, соңгы 10 елда ел саен икешәр-өчәр роман иҗат ителәбаруны безнең ирешкән тизлегебез, язу культурабыздагы уңай ягыбыз, җитлегүебез дип карарга кирәктер. Ләкин ирешелгән уңыш беренче чиратта сыйфат белән үлчәнелә. Инде күбебез укып чыгарга өлгергән романнарның барысы да Виктор Астафьевның «Моңсу детектив», Валентин Распутинның «Пожар», дөнья күләмендә дан алган Чыңгыз Айтматовның

«Буранлы тукталыш» яки «Ахырзаман» романнары белән янәшә куярлыкмы? Без, авыр гына көрсенеп: «Юк шул!» — дип әйтергә эзер торабыз. Ләкин аһ орырга ашыкмыйк. Рус әдәбиятының үзендә дә, күп милләтле совет әдәбиятының башка төбәкләрендә дә бу романнар белән янәшә куярлык романнар әллә ни күп язылмады, алар бармак белән генә санарлык. Әгәр инде әдәби хәзинәләребезнең урынын чынлап торып билгеләргә телибез икән, без булган барлык байлыгыбызга хуҗаларча карап, объектив бәя бирергә, татар романының 150 еллык үсеш тарихында аларның нинди урын тотканлыкларын ачык һәм төгәл билгеләргә тиеш булырбыз.

Бездә озак вакытлар тарихи роман булмады. Тарихи роман тусын өчен, беренчедән, социаль җирлек, тарихка дөрес караш булдырырга кирәк иде. Безне илнең зур тарихчылары Сталин репрессияләре дәверендә һәм торгынлык дип яман аты чыккан чорларда монгол-татар яулары белән гел бутап йөрттеләр. Татар дигән халыкны тиргәү хрестоматик дәреслекләрдән башлап, нәниләр өчен чыгарыла торган «Мурзилка» һәм «Веселые картинки» кебек журналларга тикле үтеп керде. Миңа алтмышынчы елларда, өлкән агаларыбыз Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Хәсән Туфаннар киңәше белән, РСФСР Язучылар союзының халыклар дуслыгы һәм интернационализм тәрбияләү мәсьәләләренә багышланган бер Пленумында татар халкына карата матбугатта булган ямьсез күренешләргә карата махсус чыгыш ясарга туры килде һәм моны рус әдәбиятының Леонид Соболев, Сергей Залыгин, Владимир Чивилихин кебек зур язучылары хуплап каршы алдылар. Моның белән мин нәрсә әйтергә телим? Тарихи романнар татар әдәбиятында тусын өчен, кабатлап әйтәм, билгеле бер социаль җирлек һәм шул эшкә гомерләрен багышлаган талантлы язучыларның тууы кирәк иде. Андый кешеләр җитеште. Нурихан Фәттах аңлы язучылык тормышын шушы эшкә багышлады. Бераз соңрак Мөсәгыйт Хәбибуллин үсеп чыкты. Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар» романы, Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» романы галимнәребез, әдәбият белгечләребез тарафыннан җитди тикшеренүләргә, монографик хезмәтләр язуга лаек. Телне нечкәләп белгән, тарихны вәземләп өйрәнгән Нурихан Фәттахның язу алымы, материалны роман кебек эпик жанрга туплау хасияте шундый ук үзенчәлекле галимне таләп итә. Тарихи жанрда тел стилен тапкан Мөсәгыйт Хәбибуллин да игътибарлы вә ихтирамлы тикшеренүчегә мохтаҗ. Ә минә тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның әлеге тарихи романнарга «авантюрноромантические романы» дип мөһер сугуы күңелдә рәнҗү тудыра, халкыбызның рухи байлыкларына бик өстен торып, җиңелчә бәя бирүебезне раслый. Бу романнарның төп җирлеге — реализм. Аларда беркадәр күтәренке пафос, әкият-легенда стиле дә бар икән, роман авторларының борынгы үткәнебезгә чиксез дулкынланып һәм хәтта, мин әйтер идем, поэтик югарылыктан торып бәя бирүләреннән килә. Без бит Чыңгыз Айтматов романнарындагы миф элементларына каршы килмибез, аларны табигый һәм закончалыклы күренеш итеп бәялибез. Мин үзем, мәсәлән, Нурихан Фәттах романнарында да, Мөсәгыйт Хәбибуллин романнарында да социаль геройларның, заман төсмерләренең ачыграк чагылуын теләр идем. Чыңгыз хан, Батый хан, Пугач явы, Иван Грозный, Аксак Тимер, Салават батыр хакындагы, Абай хакындагы романнарда заман билгеләре, тарихи-документаль фактлар ярылып ята. Безнең тарихи романнарда да тарихи чор төгәлрәк сурәтләнсә, әлбәттә, аларның камиллеге, сәнгатьчәлеге тагын да арта төшкән булыр иде, ышандыру көче дә артыр иде. Монысы — изге бер теләк. Әмма татар әдәбиятында тарихи жанрның чынлап торып аякка басуын соңгы еллардагы җитди уңышыбыз, әдәбиятыбызның бер адым алга атлавы дип карарга хакыбыз бар. Тарихи романнарның авторлары, минем уйлавымча, Казан ханлыгына, аңардан соңрак чорларга да тотынырга тиешләр әле. Өстән албасты кебек басып торган диктат дәвере, Брежневлар, Сусловлар дәвере узды. Акны ак дип, караны кара дип язар заман килде.

Тарихтан башлаганга күрә, Ибраһим Салаховның «Имәннәр тамыр җәйгәндә» исемле тарихи-революцион романына күз салыйк. Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр», Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар», Атилла Расихның «Ямашев» романнарыннан соң бу, ихтимал, тарихи-революцион темага язылган иң көчле романдыр. «Казан утлары»нда кыскартып басылган вариантыннан соң китап булып тулысынча басылганын кабат укыдым. Дөресен әйтим, романны уку барышында күңелдә ике төрле тойгы кала: беренчесе — бу без көткән роман: колачлы, монументаль! Икенчесе — бу тигезсез язылган роман. Әсәрнең күпчелек өлешендә сәнгатьчә сурәтләп, югары сәнгать алымнары белән тарихи вакыйгаларны, шәхесләрне ачып бирү бар. Казах халкының гореф-гадәтләре, гамәлләре, йолалары, психикасы, йөреш-торышы — һәммәсе тәфсилләп язылган. Мәхмүт Галәү романнарыннан ук килә торган төгәллек, конкретрешне детальләп сурәтли белү бар монда. Җирле халык белән бергә, казах даласына каяндыр күченеп килгән татарлар, мишәрләр, руслар, ягъни патшаның атлы казаклары тормышы гаять

дәрәҗәдә белеп, төбенә-тамырына төшеп язылган. Романның бу өлеше дулкынландыра, җанны кузгата. Алыгыз күкләр күкрәп, мәчетне җимереп ташлаган гарасатны, алыгыз азанчы мәзиннең һәлакәтен, алыгыз карт казак Җәфрәтил Җамалетдинының җорлыгын! Минем андый да тапкыр, үткен һәм зирәк картны бер генә романыбызда да күргәнем юк.

Роман фикерләвенә хас колач бар монда. Дала бар, дала буйлап агылган сарык көтүләре бар, томаннар, болытлар, чыклар, шакаллар, зәңгәр күкләр һәм шул күк астында газап чиккән, михнәттән яшьләй һәлак булган халык вәкилләре бар. Бер халыкның гына түгел, төрле халыкның вәкилләре. Аерым өстенлек алып, симерүдән нишләргә белмәгән казачий атаманнар, кыйнап үтерелгән ярлы казаклар, күңелне баскан моң бар. Романда егерменче гасыр башының яшенле-давыллы атмосферасы бар.

Ләкин роман тигез язылмаган. Яшь казак Госман Әбдерәшитовның Япон сугышында катнашуы чамадан тыш схематик бирелгән. 1905 ел вакыйгалары да йөгертеп сөйләп чыгуга, КПСС тарихын иллюстрацияләүгә корылган. Сүзем һавада асылынып калмасын өчен, мисал китерәм:

«Март аенда Мукдан (Манбян) каласы янында рус-япон җир гаскәрләренең соңгы каты бәрелеше була. Рус гаскәрләренең японнарга каршы торырлык, өстенлек алырлык мөмкинлеге булуга карамастан, генерал Куропаткин үз армиясенә чигенергә приказ бирә.

Апрель аенда Лондонда РСДРПның III съезды ачыла».

Минә шундый тәссез, әдәбият белән уртаклыгы булмаган информация, коп-коры хәбәр әллә ничә биткә сузыла. Кая китте алдагы бүлекләрдәге җете бизәкле, образлы тел? Кая китте алдагы гаярь казак Госман? Ансатрак юлдан китте түгелме автор?

Бу очракта «Иманнар тамыр җәйгәндә» романының авторы рус-япон сугышын да, 1905 ел революциясен дә әдәби әсәргә сәнгатьчә тукыма итеп кертер дәрәҗәдә өйрәнмәгән һәм ул урын, тәнкыйтьчеләр термины белән әйткәндә, «ак тап» булып калган.

Эзлекле итеп тасвирлау, романның архитектоникасын булдыру, сюжет-композиция бөтенлегенә ирешү мәсьәләсендә мин «Иманнар тамыр җәйгәндә» романына озаклабрак тукталдым. Моның сәбәпләрен аңлый торганнардыр дип беләм. Безнең байтак кына романнарыбызда буш урыннар, ак таплар бар. Шул сәбәпле талантлы әдипләребез иҗат иткән романнарның да кайберләре әнә шундый җитди кимчелек аркасында укучы күңеленә тәэсир итү көчен киметәләр.

Узган тормышыбызны сурәтләү — соңгы елларда язылган романнарда иң җитди эшкәртелгән, иң зур җаваплылык белән өйрәнелгән өлкә. Соңгы елларда без татар әдәбиятында, аның роман жанрында п о л и т и к  р о м а н туды дип авыз тутырып әйтә алабыз. Аяз Гыйләҗев белән Алексей Литвин бергәләп иҗат иткән «Августның алтысына кадәр» һәм «Августның алтысыннан соң» дип аталган ике кисәкле роман бу жанрның мөмкинлекләрен, Казанда һәм Идел буе төбәкләрендә барган революцион вакыйгалар, сыйнфый көрәшләр, аяусыз бәрелешләрне публицистик кайнарлык, документаль дөреслек белән ачып салдылар. Роман ил күләмендә үткәрелгән КГБ конкурсының бүләген алды.

Прозаик Мәхмүт Хәсәнов та роман өлкәсендә бүгенге көнебезне сурәтләү аркасында түгел, егерменче-утызынчы еллар хакыйкатен, шәхес культы тудырган зинданнарны, шул фаҗигаләрне үз башларыннан кичергән геройларны иҗат итү аркасында иреште. «Язгы аҗаган», ихтимал, Мәхмүт Хәсәновның күп санлы романнары арасында иң җитлеккәне, иң камиледер. Монда кайнап торган зур, катлаулы, фаҗигале тормыш кына түгел, монда тормышка, безнең чынбарлыгыбызга яңача караш та бар. Ничектер газета очеркына тартым стиль белән язарга күнегеп киткән, телдә байтак кына шаблоннар җибәрә торган Мәхмүт Хәсәновның теле бу әсәрдә моңарчы ирешкәннәрдән бер баш югары, геройларның тышкы портреты да, психологик портреты да төгәл, ышандыргыч. Биредә тормыштагыдан күп өлеш югарырак күтәрелгән, гомумиләштерелгән Иргали һәм Гази образлары бар. Катлаулы, заман фаҗигасен ача торган масштаблы образлар. Романда «күңел диалектикасына» игътибар зур, эстетик яктан кызыклы ачышлар бар. Әйтик, тормышның заманга бәйле сәхифәләрен әсәрнең тукымасына төрлечә сибү, бүгенге көнне егерменче-утызынчы еллар белән, шул дәвернең трагедияләре белән, Ватан сугышы гарасаты белән бәйли белү бар.

Әсәр хаклы рәвештә Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге премиясенә лаек булды — бу очракта рәсми фикер белән халык фикере кушылды, тәңгәл килде. Минем уемча, «Язгы аҗаган» соңгы елларда татар романы ирешкән казаныш саналырга, русчага да тәрҗемә ителеп, илебез әдәбиятында лаеклы үз урынын алырга тиешле. Ә иң мөһиме кайбер тәнкыйтьчеләребезнең: «Торгынлык чорында татар әдәбиятында, рус әдәбиятындагы кебек, басылмый яткан әсәрләр иҗат ителмәде»,— дигән уй-

дырма фикерен юкка чыгара торган роман бу. «Язгы ажаган» нәкъ менә торгынлык чорында язылып, озак кына басылмый ятты.

Бәхет сәгате сукканны көтеп яткан романнарның икенчесе — Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» әсәре. Шәхес культы чорының барлык дәһшәте, барлык мәкерлеге, социализм идеяләрен гариплэндерүе, Сталин һәм аның мәртәтләренең совет кешеләрен кол дәрәҗәсенә төшерүләре бу әсәрдә аяныч язмышлар аша ачылган. Аерым китап итеп чыгарган чакта, чамадан тыш вак детальләрдән арындырылып, гомумиләштерелгән нәтиҗәләр, фәлсәфи фикерләүләр дә өстәлсә, бу роман тагын да ныграк отачак.

Соңгы еллардагы романнарыбызның уңышы үткән көннәребезне чагылдыру белән бәйле икәнен Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләр дә раслап тора. Моны мин беренче чиратта Хисам Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым» исемле романнарына карата әйтәм. Өч романда да автор, сугыш гарасатын 18 яшеннән үк үз җилкәсендә күтәргән, сугыштан бер аягын калдырып кайткан ветеран тормышның зур хакыйкатендә. Виктор Астафьев сүзләре белән әйткәндә, «окоп хакыйкатендә» әйтеп бирә. Европаның сугыш мәйданнарында тәҗрибә туплаган кансыз һәм аяусыз фашизм образы, гитлерчылар палачлыгы бөтен буйга ачып бирелә. Әлерәк кенә мин кайбер романнарыбыздагы көпшәклекне, буш урыннарны әйткән идем. Хисам Камалов романнарында андый урыннар юк. Автор сугыш гарасатындагы көнне һәм төнне, томаннарны һәм сазламыкларны, салкын-юеш окопларны һәм блиндажларны, зур җиңү хакына алып барылган чамасыз авыр физик хезмәтне җентекләп сурәтли. «Безне өйдә көтәләр» романында сугышның утлы өермәләре кешеләрне күмеп китмиләр, киресенчә, аларның зурлыгын, кешелек батырлыгын һәм рухи матурлыкларын калкурак итеп ачалар.

Күңелне иң сөендергәне шул: Хисам Камалов романнан романга үсә, әдәби осталыгын камилләштерә, тел-сурәтләү чараларын үткенәйтә, халыкчан итә бара. «Үлгәннән соң яздым» романы, баштагы ике романнан аермалы буларак, баталь картиналарга корылмаган. Сугыш картинасы, зарурилыктан чыгып, бер генә урында, барлык дәһшәте белән сурәтләнелә. Роман үзәгендә шәфкать туташлары. Яралы солдатларны, командирларны коткаруда алар башкарган эшне күңелләрне тетрәтерлек итеп тасвирлый автор. Аягы яраланып, соңыннан ампутацияләнгән Әнвар Фазлыев һәм аны, сабый баланы төргәндәй, юрганнарга төреп, күкрәгенә кысып җылыткан, җанын саклап калган Ася Миншина, Василий Теркинга һәйкәл куйган төсле, урамнарга һәйкәл итеп бастырып куярдай образлар. Бөек Ватан сугышы безнең романнарда беркайчан да бу дәрәҗәдә зур, фаҗигале, героик һәм моңсу итеп сурәтләнмәде. Әгәр без Хисам Камалов романнарын оригиналдагы көче белән русчага тәрҗемә итә алсак, алар совет әдәбиятында иң зур һәм иң популяр әсәрләр белән янәшә баса алырлар иде. Эшләргә кирәк бу эшне, кичекмәстән эшләргә кирәк. Менә шул чакта без күп милләтле совет әдәбиятындагы каләмдәшләребезгә: «Бөек Ватан сугышын чын дөреслеге белән, тирән һәм акыллы-тәэсирле итеп яза алырдай прозаик үсеп җитте бездә. Ул, Константин Симонов кебек, шагыйрьдән үсеп чыкты»,— дип әйтә алырбыз.

Әхсән Баянның «Таш китап» романына, гәрчә ул дүрт-биш ел элек дөнья күргән булса да, тәнкыйтьчеләрнең кулы җитмәде. Моның сәбәпләрен аңлау кыен, әлбәттә. Кайбер укучылар, хәтта язучылар арасында да, бу әсәр авырдан укыла, дигәнрәк фикер булып алды. Бу очракта Чыңгыз Айтматовның сүзен кабатларга мәҗбүрмен. Әдәбиятта чын әсәр, акыллы, тирән әсәр җиңел укылмаска тиеш. Андый әсәр озаклап, уйланып укылырга тиеш. Кешенең уй-тойгыларын яңартмый торган, кызык өчен генә язылган җиңелчә беллетристика сәнгать була алмый. Без җиңеллеккә, арзанлы мәзәккә тамашачыны театрларда да күп өйрәттек инде, шунысы да җитеп торыр. СССРның халык артисты, атаклы режиссер Г. Товстоногов «Правда» газетасында бастырып чыгарган бер мәкаләсендә (17 ноябрь 1986) драматургиядә В. Распутин, Ч. Айтматов, В. Быков, Д. Гранин, В. Астафьевлар булмауга үкенә. Мондый язучыларның әсәрләрендәге тирәнлеккә, яңалыкка, колач киңлегенә соклана. Ирешәсе иде драматургиябездә дә шул югарылыкка, акыл байлыгына, ди.

Инде Ә. Баяновның «Таш китап» романына килгәндә, мин аны эшчеләр тормышына багышланган әтрафлы җитди роман дип саныйм. Тик әдәбият белгечләре аны аерым алып түгел, беренче китабы «Ут һәм Су» белән бергә, бербөтен итеп карап өйрәнергә тиешләр, минемчә.

Әхәт Гаффарның «Тегермән ташы һәм бодай бөртеге» романы — илебез әдәбиятыннан һәм дөнья әдәбиятыннан өйрәнеп, алга зур максатлар куеп язылган әсәр. Дөнья белән аяк терәп сөйләшә автор. Болары мине сөендерә. Тик аның татарчадагы теле мине үрти, үчекли. Русчадан калькалар күплеге акылга барып җитә, хисне кузгатмый. Кем ничек уйлый торгандыр, мин үзем, авылда үскән кеше буларак,

калька телгә берничек тә күнегә алмыйм.

Мәдинә Маликованың «Шәфкать» исемле романы элегрәк «Ак давылда тал бөресе» дип атала иде. Татарстан язучыларының X съездында без әле аңар беренче исеме белән бәя бирдек. Минемчә, хәзерге исеме уңышлырак, чөнки ш ә ф к а т ь сүзенә мораль-әхлакый мәгънә дә салына. Русча Мәскәүдә Елена Корнеева тәрҗемәсендә басылып чыккан китап та «Милосердие» дип атала. Һәм ул әсәрнең материалына, врачлар тормышына, ягъни кешеләргә шәфкатьлелек эшләүчеләр тормышына туры килә. Романга моңарчы бирелгән уңай бәя белән бәхәсләшмим, тик авторның «Кар сулары» хикәясендәге теле миңа ягымлырак, мамыклырак булып тоела. Бәлки шуңа күрәдер, «Басып сайрар талы бар» исемле яңа романының, 30 мең тираж белән аерым китап булып басылып чыккан әсәрнең, тел-сурәтләү чараларындагы алга китеш, образларны сурәтләүдәге, пейзаж бизәкләрендәге ягымлы җылы мөнәсәбәт күңелгә якын булып китә. Роман жанрына бик тәвәккәл тотынган беренче хатын-кыз авторыбызның җаваплылык тоеп эшләве, икенче романында бер адым алга атлавы, һичшиксез, күңелле хәл.

Соңгы елларда татар әдәбиятының тормышның төрле-төрле өлкәләреннән материалны роман жанрына алуын, тирән катламнарга һәм каты токымнарга юлыгуын уңай күренеш дип санарга кирәктер.

Бик зур үткенлек, гаять йөгерек тел белән язылган һәм укучы мавыгып укый торган «Мәңгелек яз» романында кызыклы вакыйгалар, мәзәкләр, көлкеләр, ут чәчрәтеп сөйләүләр бар. Талантлы автор язганы әллә каян күренеп тора! Тик нигәдер безне роман канәгатьләндереп җиткерми? Ник алай? Туган-үскән авылы Гөберчәк кешеләрен моңарчы легенда дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли алган Мөхәммәтебез ник бу әсәрдә калыша? Романның төп кимчелеген миңа кырык биш ел буена колхоз председателе булып эшләгән һәм шул хакта үзе «Икмәк кадере», «Авылым гадәтләре» исемле китаплар язган Фәйзи Галиев әйтеп бирде: «Мөхәммәтнең каләме бик тә йөгерек, аз мәйданда күп информация бирә белә ул. Юморы да егылып көләрлек була. Әмма колхоз председателен төп герой итеп аласың икән инде, аның эшен биш бармак кебек белергә кирәк. Якташыбыз яңа заман председателенең вазифаларын белеп бетерми, шуңа күрә чикләвекнең эче, Ибраһим Гази әйтмешли, буш булыбрак чыккан. Автор председательне мәхәббәт маҗарасына, очраклы мәзәкләргә ураган. «Укучы әсәрне укый бит» — дигән сүз йөри, ләкин ул сүз мине юатмый. Аның «Торналар төшкән җирдә», «Кеше китә — җыры кала» повестьлары, «Каз канатлары», «Фронтовиклар» романнары төшле чикләвекләр рәтендә иде...»

Бүгенге көнне сурәтләгән романнардан Газиз Кашаповның «Язмышыңа ышан» романы Татарстанда атом электростанциясен салучыларга багышлана. Әлеге дә баягы бер кимчелек — романда буш урыннар булуы әчне пошыра. Мин әсәрнең уңай якларына һич кенә дә күз йомарга теләмим. Биредә Вергилий Дикопольцев, Фазыл Айбулатов, Гайәр Сәфәров кебек төзелеш җитәкчеләренең кызыклы образлары бар. Без аларда Батенчук, Бибишев, Салахов кебек талантлы оештыручыларны таныйбыз. Ләкин алар берсе дә әсәрдән аерылып үзбаш яшәрлек, халык теленә керерлек образларга әйләнмәгәннәр. Хикмәт, күрәсең, шунда: аларның шәхси тормышлары, интим мөнәсәбәтләре, гаиләдәге гамәлләре мавыктыргыч, әмма производстводагы гамәлләре төссез, сөйләшүләре сүлпән, сузынкы булып чыккан. Минемчә, бу хәл Газиз Кашаповның ашыгуыннан түгел, тәҗрибәсезлегеннән килә. Производство кешеләре хакындагы әсәрләрнең чамадан тыш аз язылуын исәпкә алсак, бу әсәр һәм тәнкыйтьчеләр, һәм проза секциясе игътибарында булырга тиеш иде. Хәлбуки ул эш роман «Казан утлары»нда басылганчы да, басылганнан соң да эшләнмәде. Ә бит барчабызга да мәгълүм, Галина Николаеваның рус әдәбиятында шаулаган «Битва в пути» романы матбугатта басылып чыкканчы уннан артык язучы һәм тәнкыйтьче кулыннан уза. Автор үзе оештыра бу эшне, үзе үтенә каләмдәшләреннән. Сугыштан соңгы чорларда зур романнарны проза секциясендә бик җентекләп тикшерү, авторга киңәшләр белән ярдәм итү практикасы бездә дә бар иде. Ул хәзер бетте. Минемчә, ул файдалы, зарури эшне кабат гамәлгә кайтарырга кирәк. Шунсыз, ягъни коллектив акылыннан башка, без ил күләмендә вакыйга булырдай зур әсәрләр, һәр яктан җитлеккән романнар тудыра алмабыздыр.

Соңгы елларда нефтьчеләр тормышыннан ике роман иҗат ителде. Берсе — Шамил Бикчуринның «Тирән катлам»ы, икенчесе — Җәмит Рәхимовның «Кыядагы чәчәкләр»е. Ш. Бикчурин романына карата әдәби тәнкыйть өнәмичәрәк язды, беренче романыннан калыша дигән фикер тудырып өлгерде. Мин, мәсәлән, ул фикерләр белән килешеп бетмәс идем. Себер дөньясын зур итеп ачу, аның табигатенә, җир байлыкларын эзләп табучы фидакарь кешеләргә карата авторның җылы, ихтирамлы мөнәсәбәте романны укучыга якын һәм кадерле итә. Әгәр инде бүгенге көн югарылыгыннан, җир-суларга, экологиягә мөнәсәбәт күзлегеннән карап, ил язучылары күтәр-

гән принципиаль мәсьәләләр, тәнкыйть сүзеннән килсәк, романга, әлбәттә, зуррак таләпләр куярга була.

Җ. Рәхимовның «Кыядагы чәчәкләр»ендә дә Себер киңлекләре, тайга кедрлары, сазламыклар, черкиләр, адәм баласының юлына киртә булып төшкән күп төрле авырлыклар бар. Автор күзәтүчән. Кешеләрнең портретлары, характерлары да чагылып-чагылып китә, тик шуларны бербөтен итеп сюжет-композициягә туплау җитенкерәми. Заманында романнар остасы Габдрахман ага Әпсәләмов безне, ул чагында әле яшь язучыларны, болай дип өйрәтә иде: «Әсәр язылып беткәч, аның баш героеның линиясен карап чыгыгыз. Аерым алып. Әгәр баш геройның линиясе өзелмәсә, әсәр бөтен булыр, аны укырлар». Минемчә, Җ. Рәхимов ул эшне эшләмәгән әле, әсәрнең байтак урыннарында баш герой сызыгы өзелә, энә шул романны кызыксынып, аерылмыйча уку мөмкинлеген киметә.

Әлеге әйтелгәннәр инде романнар, повестьлар язу өлкәсендә тәҗрибә туплаган, тормышның ачысын-төчесен байтак күргән авторларга, Эдуард Касыймов белән Барлас Камалга да кагыла. Э. Касыймовның «Шиңмәсен гөлләрең» романы да, Б. Камаловның «Өзелмәсен өметең» романы да хезмәт кешеләренә багышланган. Б. Камаловныкы авыл механизаторы Илфат Маннуровның, герой механизаторның җиргә, игенчегә булган мөнәсәбәтен сурәтләсә, аның шифаханәдәге авыр кичерешләре аша аталар һәм балалар мөнәсәбәтен күтәрсә, урыны-урыны белән психологик тирәнлекләргә дә төшә алса, икенчесе — Э. Касыймов романы Кама буендагы автогигантның тирә-як авылларга, шушы елга буендагы халыкларга йогынтысын ача. Э. Касыймовның «Чулман — оныклар елгасы» нинди зур мәшәкатьләр белән басылып чыккан булса, монысы да шундый ук авырлык белән, алты-җиде ел редакцияләрдә йөргәннән соң гына дөнья күрә алды.

Эшчеләр һәм игенчеләр турында язылган биш-алты роман хакында, нәкъ менә бүгенге көн әсәрләре хакында сүз йөрткәннән соң, гомумирәк сүзне, җыйнабрак әйтелә торган сүзне дә укучыга җиткерү кирәктер. Таләпләр аеруча зур, аеруча кискен куелган заманда бүгенге көнгә караган романнарга карата зурдан кубып сүз әйтүе кыен. Бәлки торгынлык елларында бу әсәрләргә карата мәдхия дә яуган булыр иде. Тел-сурәтләү чараларына тел-теш тидерерлек түгел аларда, геройлары да күз алдына басалар, әмма алар никтер күңелдә бөтенлек, тулылык хисе калдырмыйлар. Бу әсәрләргә «изге гамь» (Хәсән Туфан термины) җитми бугай. Дөнья һәм илләр язмышы, җир-сулар язмышы өчен, халыклар язмышы өчен борчылу җитми шикелле. Виктор Астафьев Красноярск каласында яшәп, «Моңсу детектив»ны язды, ул анда корсаклы хатынны канауда суеп яткан ПТУ үсмерен тасвирлады. И ябырылды язучылар, и ябырылды тәнкыйтьчеләр! Ул чакта үзгәртеп корулар килеп җитмәгән иде әле. Озак та узмады, безнең Казаныбызда үсмерләр кулларына күсәк күтәреп, пычак тотып, дөнья бетереп сугыша башладылар. Биш-алты ел алдан, Себер каласында яшәгән хәлдә, Астафьев Казан үсмерләренең киләчәген ничек күрә алган? Валентин Распутин «Пожар» романында бәлагә тарыган йорттан әйбер урлаучыларны сурәтли. Бу соң үзләре эшләгән завод-фабрикалардан, комбинатлардан әйбер ташучы, йортларына мал җыючы комсызлар түгелмени? Мин әлерәк кенә сүз йөрткән романнарда — бүгенге заманның кала һәм авылын яктан романнарда — андый күрәзәчелек бармы? Ай-һай! Атилла Расихның «Сынау» романында андый күрәзәчелек, балалар тәрбиясенә төкереп карау аркасында килеп чыккан күңелсезлекләр, ата белән бала дәгъвасы бар. Шул ук А. Расихның «Кыш узар», «Ике буйдак» романнарында (торгынлык чорында ук иҗат ителгән романнарда) бүгенге көнне, үзгәртеп кору кирәклеген, аның зарурлыгын алдан күрү бар. Шул яңача фикерләүне тәнкыйтьчеләребез күрмәделәр. «Кыш узар» байтак еллардан соң дөньяга «Язгы авазлар» булып чыкты. Ә безнең тәнкыйтьчеләр алдан күреп иҗат иткәннәр арасына Әмирхан Еники белән Аяз Гыйләҗевне генә кертеп йөриләр. Ә Әхсән Баян? Ә Хәсән Сарьян? Ә Фаил Шәфигуллин? Аларны ник күрми тәнкыйтьчеләребез? Ә бит Әмирхан ага Еникине дә әдәби тәнкыйтьчеләребез заманны алдан күрүче дип «Саз чәчәге» һәм «Әйтелмәгән васыяте» аркасында гына атыйлар. Әдипнең илле еллык иҗат җимешенең нәтиҗәсе булган «Соңгы китап» ник анализланмый? Гади бер истәлекләр исеме тагылган бу китап киң полотнолы роман-хроника бит! Йорт алып бару, аренда, мал-мөлкәткә мөнәсәбәт бу роман-хроникада гаҗәеп бер нечкәлек һәм ихтирам белән язылган бит! Өстәвенә әле бу китапта безнең әдәбиятта беркайчан да булмаган яңалык бар. Портрет алымының иң югары кимәленә күтәрелә автор. Кеше портреты, атлар портреты, йортлар, урамнар, хәтта калалар портреты бар. Әнә шул портрет осталыгына тәнкыйтьчеләребез яшьләрне юнәлтергә тиеш иде.

Яңарыш тизрәк барсын өчен яшьләргә таянырга кирәк. Соңгы елларда, бигрәк тә ике съезд арасында, без яшьләрне азрак кайгырттык шикелле. Юкса роман жанрына бер Рашат Низамиев кына килмәс иде. Күбрәк булыр иде алар. Сүз уңаеннан,

мин Р. Низамиевның данлы музыкант, Ватан сугышында бик яшьләй һәлак булган Фәрит Яруллин ядкаренә «Атаклы кешеләр сериясеннән» роман язуын хуплыйм. «Язмыштан көчлерәк» исемле роман-хроникада автор поэтик югарылык белән публицистик кайнарлыкны бергә куша алган. Әсәрне укыйлар, сүз куерталар укучылар. «Казан утлары» редакциясенең бер утырышында редколлегия членнары әсәрнең җитди, сәнгатьчә булуын билгеләү белән беррәттән, анда әле сугыш турында, афәтләр турында, шәхес культы дәвере террорлыклары турында уйлану җитеп бетмәвен әйттеләр. Китап итеп чыгарган чагында талантлы яшь романчыбыз аларны да уйлап бетерер дип ышаныйк.

Себер ягыннан «Иртеш таңнары» романын язып җибәргән Я. Зәнкиев иптәш тә күңелдә өмет уята. Роман моңарчы без күрмәгән Себер ягы кешеләренең кызыклы образларына бай булуы белән генә түгел, үзенә генә хас, кабатланмас тел үзенчәлекләре, Себер чишмәләре төсле яңа бер агынтысы белән дә игътибарга лаек.

* * *

Инде йомгак ясап карыйк. Менә без соңгы елларда язылып дөнья күргән егермеләп романны күздән үткәрдек. Татар романының бүгенге хәле мөшкел түгел икәнлеге аңлашылса кирәк. Димәк, Сергей Залыгин әйткән «билгеле бер югарылыкны» саклау да, аннары ул югарылыкка нәрсәдер өстәргә теләү дә бар. Монысы Хисам Камалов, Нурихан Фәттах, Мәсгыйть Хәбибуллин, Мәхмүт Хәсәнов, Әмирхан Еники, Атилла Расих, Ибраһим Салахов романнарына — тарихи һәм сугыш романнарына кагыла.

Ләкин тынычланырга иртә. Бик иртә. М. С. Горбачев Һиндстан журналистлары белән бер әңгәмәсендә илдәге борылыш дәверенә карата менә мондый сүз әйтте: «Кешеләр үз хәлләреннән риза булып, ваемсыз яши башлаганнар иде. Партия аларның халык алдындагы җаваплылыкларын исләренә төшерде».

Бу сүзләр безгә, язучыларга да, кагыла. Булган хәлебездән риза булып утырудан туктарга, алга таба тагын бер көчле омтылыш ясарга кирәк булыр. Ул хакта без Татарстан язучыларының XI съездында ачыктан-ачык, ихлас күңелдән сөйләшербез дип ышанам.



# Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу

## ТУГЫЗЫНЧЫ ДӘРЕС

Алдагы дәресләрдә гарәп әлифбасына нигезләнгән татар язуын телебезгә яраклаштыру буенча Октябрь революциясенә кадәр үк мәгълүм күләмдә эш башкарылу турында әйтелгән иде инде. Әмма татар әлифбасына рәсми реформа Октябрь революциясеннән соң гына, егерменче еллар башында ясала. 1923 елда кабул ителгән татар әлифбасы әнә шул реформалар нәтиҗәсендә дөньяга килә. Реформаның төп максаты татар орфографиясен тагын да камилләштерү, уку-язуны җиңелләштерү була, әлбәттә.

Бу дәвердә татар әлифбасына кертелгән яңалыклар нигездә түбәндәгеләргә кайтып кала.

Әлифбада сузыклар һәм ярым сузыкларны билгеләү өчен алты хәреф алына.

ئا - а, ه ـه - ә, و - у - ү, ۇ - о - ө, ی - ый - и, й
ئ - ы - е.

Тартык хәрефләрне куллану да тәртипкә салына: гарәп теле өчен хас булган ص, ط, ظ, ض хәрефләре татар сүзләрендә язылмый. Тартык авазларга тагын бер хәреф — һәмзә ئ өстәлә.

Сузык авазларга башланган сүзләрдә сүз башында һәмзә хәрефе языла. Мәсәлән, атна - ئاتنا; Идел - ئیدل; акбур - ئاقبور; ил - ئیل; ыргак - ئرعاق; үзәк - ئۇزەك

Ы-е авазларын белдерү өчен кулланылган ئ хәрефе ачык иҗекләрдә генә язылган, ябык иҗекләрдә язылмаган. ۇ хәрефе сүз башында иҗек ачык булса да, ябык булса да язылмаган. Мәсәлән, тырыш - ترش

белем - بلم; тел - تل; теш - تش; керем - كرم; чыгым - چعم;

О-ө — ۇ хәрефе сүзнең беренче иҗегендә сүз башында гына языла. Ачык иҗекләрдә ئ язылган. Мәсәлән:

оста - ئۇستا; төрле - تۇرلی; төрлесе - تۇرلسی;
остасы - ئۇستاسی; йозак - یۇزاق; көлтә - كۇلته

Кайбер сүзләр янәшә килгән ике یی һәм ике وو белән язылалар, ул янәшә хәрефләрнең беренчесе сузыкны, икенчесе аңа ияреп әйтелә торган ярым сузыкны белдергән. Мәсәлән: тиеш - تییش; җыен - جیین;
салуы - سالووی; куык - قووق

| Аерым хәреф | Әйтелеше | Сүз башында | Сүз уртасында | Сүз ахырында |
|---|---|---|---|---|
| ئا | А | ئا | ـا | ـا |
| ئە | Ә | ئە | ـە | ـە |
| ب | Б | بـ | ـبـ | ـب |
| ت | Т | تـ | ـتـ | ـت |
| پ | П | پـ | ـپـ | ـپ |
| ج | Ж | جـ | ـجـ | ـج |
| چ | Ч | چـ | ـچـ | ـچ |
| ح | Х | حـ | ـحـ | ـح |
| د | Д | د | ـد | ـد |
| ر | Р | ر | ـر | ـر |
| ز | З | ز | ـز | ـز |
| ژ | Ж | ژ | ـژ | ـژ |
| س | С | سـ | ـسـ | ـس |
| ش | Ш | شـ | ـشـ | ـش |

| Аерым хәреф | Әйтелеше | Сүз башында | Сүз уртасында | Сүз ахырында |
|---|---|---|---|---|
| ع | Г. | عـ | ـعـ | ـع |
| ف | Ф | فـ | ـفـ | ـف |
| ق | К | قـ | ـقـ | ـق |
| ک | К | کـ | ـکـ | ـک |
| گ | Г | گـ | ـگـ | ـگ |
| ڭ | Ң | ڭـ | ـڭـ | ـڭ |
| ل | Л | لـ | ـلـ | ـل |
| م | М | مـ | ـمـ | ـم |
| ن | Н | نـ | ـنـ | ـن |
| و | W | و | ـو | ـو |
| ئیـ | И | ئیـ | ـیـ | ی |
| ئو | У, Ү | ئو | ـو | ـو |
| ئۇ | О, Ө | ئۇ | ـۇ | ـۇ |
| ئُ | Ы, Е | ئُ | ـُـ | یُ |

Сүз ахырында килгән п авазы, шул сүзгә сузык аваздан башланган кушымча ялгангач ничек әйтелсә, шулай язылган.

кап - قاپ; каба - قابا;

тап - تاپ; таба - تابا

Башка теллардән кергән сүзләрдә — иҗек һәм сүз ахырында б, д авазлары үзгәртелмичә язылган. Мәсәлән, максат - ماقساد; завод - زاۋود;

клуб - كلوب; сәбәп - سەبەب

Лар-ләр күплек кушымчасы һәрвакыт لار - لەر рәвешендә генә язылган.

Бер үк хәрефләр белән язылган һәм калын да, нечкә дә укырга мөмкин булган сүзләрне бутамау өчен, калын әйтелешле сүзләрнең алдына калынлык билгесе " ا " куела. тәз - تۆز; тоз - تۇز; өч - ئۆچ; оч - ئۇچ,

Әгәр дә сүз составында ع ، ق ، ﻏ хәрефләре булса, бу сүзнең калынлыгын әлеге хәрефләр белдереп торганлыктан, андый сүзләрнең алдыннан калынлык билгесе куелмаган.

торба - تۇربا; тозак - تۇزاق; кочак - قۇچاق; кыргыч - قرغچ

188 биттә татар әлифбасының 1923 елда кабул ителгән варианты.

*Дәресләрне Җәүдәт МИҢНУЛЛИН һәм Рәшит КАДЫЙРОВ алып бара.*

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының 22 мартта узган ачык җыелышы татар әдипләренең шәхси архивларын җыю һәм саклау мәсьәләләренә багышланды. Әдәбият галиме Н. Юзиев доклады буенча фикер алышуларда С. Баттал, Б. Гыйззәт, И. Нуруллин, Г. Ахунов, Ә. Рәшитов һ. б. катнашты. Алар бу юнәлештә эшне яхшыртуга юнәлдерелгән байтак тәкъдимнәрен әйттеләр.

Җыелышта шулай ук коммунист язучы Рашат Низамиевның иҗат отчеты тыңланды. Танылган прозаик Г. Ахунов язучының соңгы елларда төрле жанрларда уңышлы эшләвенә югары бәя биреп, иҗат юнәлешенең дөрес юлда булуын ассызыклап күрсәтте. Язучылар И. Нуруллин, С. Сабиров, М. Шабаев, М. Галиев һ. б. Р. Низамиев әсәрләренә җентекле анализ ясадылар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

16 мартта тәнкыйть һәм шигърият секцияләренең берләштерелгән утырышында әдәбият галиме Т. Галиуллинның «Иҗат чишмәләре» дигән китабы нигезендә шигърият һәм халык авыз иҗатының үзара бәйләнешы хакында зур сөйләшү булды. Фикер алышуларда әдипләрдән Н. Арсланов, Ә. Баянов, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин, Р. Гатауллин, Э. Нигъмәтуллин, Ә. Мәхмүдов, Н. Лаисов, К. Латыйп, Р. Миңнуллин, Ф. Галимуллин, Ә. Сәхапов, Х. Әюпов, Р. Бохараев, Ф. Зыятдинова, Ш. Мостафин, И. Ганиева катнашты.

## ӘДИПНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ

27 мартта К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында танылган татар совет язучысы Әмирхан Еникига 80 яшь тулуга багышланган әдәбимузыкаль кичә булды. Аны кереш сүз белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әмирхан Еникига «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелгән иде. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев юбилярга шушы исем бирелү турында Грамотаны һәм мактаулы билгене тапшырды, чын күңелдән котлап, аңа сәламәтлек һәм иҗат уңышлары теләде.

Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында әдәбият белгече Ф. Миңнуллин сөйләде. Юбилярны филология фәннәре докторы Ф. Мусин, Татарстан китап нәшрияты директоры язучы Р. Мөхәммәдиев, Казан университеты проректоры, тарих фәннәре докторы М. Госманов, «Азат хатын» журналы редакторы Р. Туфитулова һ. б. котлады.

Кичәнең икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

Юбилей кичәсендә КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, партия өлкә комитетының икенче секретаре А. А. Родыгин, партия өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ПОЛИТИК ШИГЫРЬ КИЧӘСЕ

М. Җәлил истәлегенә багышланып үткәрелә торган традицион политик шигърият кичәсе быел 22 февральдә Казан авыл хуҗалыгы институтының яңа бинасында булды. Татарстан Язучылар союзы һәм Татарстан телевидениесе уздырган бу кичәдә М. Җәлил шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Шагыйрьләрдән Р. Гатауллин, Ш. Маннапов, Х. Әюпов, Р. Вәлиев, Э. Шәрифуллина, Ә. Синугыл (Ташкент), Г. Садә, Н. Акмалов, Ә. Мәхмүдов, Л. Лерон, Р. Зәйдуллин, Г. Моратов, рус шагыйрьләре Н. Беляев, Р. Кожевникова үзләренең шигырьләрен укыдылар.

## ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ

17 мартта язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында күренекле шагыйрь Әнвәр Давыдовның тууына 70 ел тулуга багышлап кичә үткәрелде. Шагыйрьнең тормышы һәм иҗат юлы турында Гәрәй Рәхим сөйләде. Р. Фәйзуллин, К. Латыйп, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Мингалим, И. Юзеев, Ә. Давыдов турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар, аңа багышланган шигырьләрен укыдылар. Артистлар Р. Сәхәбиев, Р. Дәминов һ. б. башкаруында шагыйрь сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

Кичәдә катнашучылар арасында шагыйрьнең хатыны Нина Прокофьевна, якташлары һәм туганнары бар иде.

## ҖОМГА КИЧӘЛӘРЕ

В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында «Җомга кичәләре» дип исемләнгән кичәләр циклы оештырыла. Аларда танылган галимнәр, әдәбият-сәнгать һәм җәмәгать эшлеклеләре тамашачылар белән очрашалар. Шундый кичәләрнең беренчесе

20 январь кичендә шагыйрь Р. Фәйзуллин иҗатына багышланган иде.

Соңгы айларда күренекле әдипләр А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Р. Харис, И. Юзеев, галим һәм язучы М. Госманов белән очрашулар — әдәбият сөючеләр күңелендә тирән эз калдырган мәдәни бәйрәмнәр булды.

## ЯҢА ФАКУЛЬТЕТ

23 мартта Казан дәүләт университеты Гыйльми советының киңәйтелгән утырышы булды. Татар филологиясе бүлегенең киләчәктә үсеш мәсьәләсен тикшереп, гыйльми совет 1989—1990 уку елында филология һәм тарих факультетлары базасында яңа факультет — «Татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультеты» булдыру турында карар кабул итте. Әлеге факультетның биш кафедрасы булачак: татар теле; татар әдәбияты; татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы; татар халкы тарихы; Көнчыгыш телләре кафедралары.

## ЯРДӘМ ФОНДЫНА

2 мартта Казанның «Юность» культура йортында республикабызның танылган язучылары, җырчылар һәм биючеләр, театр артистлары, журналистлары катнашында зур әдәби-музыкаль кичә булып узды. Анда җырчылар В. Гыйззәтуллина, З. Шәрифуллина, Г. Сафиуллина, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Н. Ихсанова, фольклорчы-галим Ф. Әхмәтова, шагыйрәләр Ф. Гыйззәтуллина, Э. Шәрифуллина, прозаиклар К. Тимбикова, Ф. Бәйрәмова, журналистлар Э. Әдиятуллина, Ф. Низамова, биючеләр Д. Вәлиева, Р. Сафиуллина һәм Финляндиядән килеп университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем алучы Айнур Нисаметдин чыгыш ясадылар. Кичә бергәләп «Туган тел»не җырлау белән тәмамланды.

Мондый концертлар башка культура йортларында да дәвам итәчәк. Аларны үткәрүдән кергән акча Әрмәнстанда җир тетрәүдән каза күргәннәргә ярдәм фондына, Казанда Салих Сәйдәшевка һәйкәл салуга һәм Татар иҗтимагый үзәге фондына да китәчәк.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

15 нче февральдә Әлмәт язучылар оешмасында әдәби ел йомгаклары булып узды. 1988 елда басылган әсәрләр турында докладлар белән Ә. Габиди һәм Ф. Садриев чыктылар. Китап булып һәм вакытлы матбугатта басылып чыккан әсәрләргә җентекле анализ ясадылар.

Фикер алышуларда язучылар Җ. Рәхимов, Р. Мозаффаров, Э. Мөэминова, А. Хәсәнов, К. Булатова, Ф. Галиева, М. Мөгыйнова, Р. Вилданова, Н. Әхмәдиев катнаштылар, докладларга һәм әсәрләргә карата фикерләрен белдерделәр, әдәби хәрәкәттәге проблемаларга тукталдылар.

Җыелышта Әлмәт якларында туган татар галиме һәм әдәбиятчы Риза Фәхретдинев исемендәге премия булдыру турында карар кабул ителде. Бу премия ел саен нефть якларында иң яхшы эшләүче әдәби берләшмәгә биреләчәк.

4 мартта КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин, ТАССР культура министры М. М. Таишев, КПСС өлкә комитетының культура секторы мөдире Р. С. Насыйбуллин Әлмәт язучылары, шәһәр драма театры артистлары, рәссамнар белән очраштылар. Очрашу вакытында үзгәртеп кору чорында иҗат интеллигенциясенең роле, язучының иҗат активлыгы, республикадагы милли культураларны үстерү турында җанлы әңгәмә барды.

## ЯҢА КОНКУРС

ТАССР Культура министрлыгы, ТАССР Кинематографистлар союзы, ТАССР Язучылар союзы, Бөтенроссия культура фондының Татарстан бүлеге җирле (милли) материалда нәфис фильм өчен иң яхшы әдәби сценарийга конкурс игълан итәләр.

Конкурска тәкъдим ителә торган сценарийлар татар халкының тарихын һәм көнкүрешен, бүгенге көн проблемаларын чагылдырырга тиеш.

Сценарийлар татарча да, русча да кабул ителә. Булачак фильмны татар телендә төшерү, аннары рус теленә тәрҗемә итү күздә тотыла.

Конкурста җиңүчеләр өчен түбәндәге премияләр билгеләнде:

Бер беренче — 2200 сум;

Бер икенче — 1500 сум;

Ике өченче — 800 сум.

Сценарийларны тәкъдим итү срогы — 1990 елның 1 мартына кадәр.

Материалларны, машинкада 4 дана бастырып: Казан, Кремль, III подъезд, ТАССР Культура министрлыгына (конкурска) җибәрергә.

Белешмәләр өчен телефоннар: 32-53-19, 53-29-92.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Күпьеллык нәтиҗәле әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен язучы Нурихан Фәттах, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 18 январь Указы нигезендә, РСФСР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# ТАҖЛЫ ШӘМАИЛ

Сүз матди нәрсә түгел, ул турыдан-туры кешенең аңына, җанына, күңеленә тәэсир итә. Шул күзлектән карaганда, Коръән аятьләре — поэтик иҗат шедевры, художестволы-сәнгатьле фикерләү үрнәге, мәгънәсе белән колачлап бетергесез мифлар һәм әкиятләр тупланмасы да ул. Анда борынгы кешенең дөньяны күзаллавы, аның үз-үзен тоту кагыйдәләре, табигатькә һәм мохиткә мөнәсәбәте дә гәүдәләнә. Үткән чорның бөек шагыйрьләре Гете һәм Пушкин Коръәннең бөтен галәмне иңләгән колачлылыгы, фәлсәфи тирәнлеге белән юкка гына сокланмаганнар, күрәсең һәм алар үзләре дә «Коръәнгә охшату» дигән әсәрләрен язып калдырганнар. Бөек рус шагыйренең Коръән таҗы булган «аятел көрси»не укып таң калганы, шуннан чыгып, борынгы кешеләрнең дөньяны күзаллавын аңларга тырышуы, аны үз әсәрләрендә файдаланырга омтылуы мәгълүм.

Кешенең рухи камиллеккә, хисләр бөтенлегенә, эстетик гүзәллеккә тартылуы — барысы да сүз сәнгатенең сурәтләү чарасы булган хәрефләрдә җисми чагылышын таба, камил сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелә. Биредә гарәп хәрефләренең үзенчәлеген, асыл мәгънәсен югалтмыйча, бизәк-орнаментка әйләнә алу сәләтен дә күрсәтеп узарга кирәк. «Гарәп хәрефләренең гүзәллеге геометрик алынмаларның, гүзәл инсан (кеше) гәүдәсенең торышларын хәтерләтә», дип яза төрек галиме Исмәгыйль Хакки Балтачы углы үзенең «Төрекләрдә язу сәнгате» дигән китабында (Әнкара, 1958). Сәнгать тарихында хәрефләрне кеше сынының сыгылмалылыгы, кеше йөзенең матурлыгы — каш, ирен, күз — белән чагыштыру яшәп килүе дә билгеле.

Матур язу күзне иркәли, гүзәллек үрнәге тудыра. Менә шунлыктан, шәмаил иҗат итүчеләр гарәп хәрефләреннән үзләренчә чәчәк-бизәк тудырырга омтылганнар да. Ул гына да түгел, билгеле бер тәртиптә урнаштырылган сүз тезмәләре үз чиратында нинди дә булса сурәтне гәүдәләндерә. Әйтик, мәчет манарасы, кошлар, чәчәкләр, нәфис савыт-саба һәм хәтта стильләштерелгән кеше йөзе булуы да мәгълүм. Татар шәмаилләренә табигать күренешләре, архитектура истәлекләре, авыл манзарасы килеп керә, хыялый гөлләр сиздермәстән үзебезнең як табигатенә хас кыр чәчәкләренә, канәфергә, мәк чәчәкләренә әверелә.

Ислам дине элементларына халкыбызның мифологиясе, әкиятләр дөньясы ялганып китә, милли мәдәният чаткылары калку күренә. Алар, барыннан да элек, канатлы гыйбарәләр, әйтем һәм мәкальләрдә ачык чагыла. Татарстанның Теләнче Тамак авылы мөгаллиме Ишалиннан алынган шәмаилдә, мәсәлән, Габдулла Тукайның «И туган тел» шигыре урнаштырылган. Республикабыз Сынлы сәнгать музеенда саклану чы «Таҗлы шәмаил»дә алтынланган гөмбәз астында мондый юллар-бизәкләр китерелгән: «Сәламәти инсани, фи хифзәти лисани», ягъни «Кешенең сәламәтлеге — аның теленең чисталыгында». Бүген дә без әйтергә тиешле, гаять тирән мәгънәле сүзләр түгелмени болар?!

Алдынгы иҗтимагый эстетик тенденцияләрнең тәэсире, дөнъяви мәдәният үсеше йогынтысы шәмаилләргә дә тәэсир итми калмый. Сурәтләү чаралары катлаулана, милли күптөслелек өстенлек ала, алар инде тамбурлап һәм укалап чигүне дә, зәркән сәнгатен һәм чамчәләп күн чигүне дә хәтерләтә. Осталар хәтта шәмаилләрдә үз исемнәрен дә күрсәтә башлыйлар. Мөхәммәтҗан Сәетов, Әхмәт Сәлиев, Гарәфетдин Исхаков исемнәре безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Музейга Казанның Мәрҗани мәчете тапшырган «Таҗлы шәмаил» дә бай бизәкләү рәвеше аеруча калку гәүдәләнә. Халкыбызда борын-борыннан киң кулланылган төсле витражны хәтерләтүче бу әсәрдә төсләр һәм бизәкләр уены хәрефләр бизәге белән җанлы кушылып кына калмый, хәтта алгы планга чыга. Өрәңге яфраклары, изге гөл һәм нур чәчеп торучы чәчәкләрнең сурәтләнүе тирән мәгънәгә ия: «модерн» стиленең халык сәнгате ысуллары белән бердәм үрелүен ачык чагылдыра. (Тышлыкта: татар авылларында киң таралган шәмаилләрнең бер төре).

Халык гамәли сәнгате әсәрләре буларак, шәмаилләр бай тарихыбызны чагылдыра, профессиональ сәнгать үсешенә сизелерлек йогынты ясый. И. Зарипов, Р. Килдебәков, Р. Заһидуллин иҗатында без моның ачык чагылышын күрәбез.

**Р. ШАҺИЕВА.**
Татарстан сынлы сәнгать музее гыйльми хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казан кремлендәге чиркәү күренеше. XIX гасыр. Инглиз рәссамы Э. Турнерелли эшеннән репродукция.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗ КОМПАСЫ

Туган телебездә күпме китап басыла? Алар табигатьне һәм кеше эшчәнлеген ни дәрәҗәдә чагылдыра? Кемнәр иҗат итә аларны? Бу китаплар кайда басыла? Аерым елларда ничә әсәр дөнья күрә? Аларның күләмнәре, тиражлары нинди?

Кызыксынучан кеше татар китабына кагылган әнә шундый сорауларга җавап эзләсә, хәзер аңа рәхәтләнеп ышанычлы белешмәлек тәкъдим итәргә мөмкин. Ул — Татарстан дәүләт китап палатасы бастырып чыгарган, түбәндә аталган ике томлы «Татар китаплары» әдәбият күрсәткече. Бу җыентыкларда 1917 елның ноябреннән 1940 елның ахырына кадәр туган телебездә дөнья күргән күпчелек әсәрләр теркәлгән.

Китап палатасы хезмәткәрләре Энисә Хисамова, Фәрдия Җиһаншина, Раушания Сафиналарга бу белешмәлекне төзү җиңел булмагандыр. Чөнки Татарстан китап палатасы 1926 елда гына оештырылганлыктан, элегрәк чыгарылган әдәбият бер үзәккә җыеп киленми. 1926 елдан соң да Татарстаннан читтә нәшер ителгән китаплар Казанга тулысынча тупланып барылмый. Гражданнар сугышы, хуҗалык җимерекле-ге дәверендә милли культурабыз хәзинәсен кайгыртучан рәвештә саклау гомумән тормышка ашырылмый. Китап палатасы 1938 елга кадәр елъязмалар чыгару белән бөтенләй шөгыльләнми. Менә шунлыктан татар совет китабының тулы исәбен алу һәм аларны тасвирлау озак елларга сузыла. Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни, В. И. Ленин исемендәге СССР һәм республикабыз дәүләт китапханәләре, Бөтенсоюз китап палатасы хәзинәләре, бүтән фондлар, күп кенә библиографик басмалар, елъязмалар, нәшрият планнары күздән кичерелә. Гарәп, латин хәрефләрендәге язулар хәзерге графикага күчерелә, китап исемнәре русчага да тәрҗемә кылына. «Авторларның, редакторлар, тәрҗемәчеләр һәм төзүчеләрнең исемнәр күрсәткече», «Китап исемнәре күрсәткече», «Китапларның басылу урыннары күрсәткече» төзелә. Китап палатасының элекке хезмәткәрләре Ә. Булатов, М. Искәндәрева, галим Ә. Кәримуллин һәм башка белгечләрнең ярдәменә таяну белешмәлекнең фәнни төгәл һәм камил җыйналуына булышкан.

Шулай да анда әлеге дәвер китаплары тулысынча кертелгән диеп булмый. Төзүчеләр искәртүенчә, «сәяси әһәмиятләрен югалтканлыктан», 300 ләп китап читтә калдырыла. «Киң катлау укучыда кызыксыну уята алмаслык әсәрләр» дә, әлегә акланып җитмәгән (Г. Исхакый иҗаты һ. б.), читтә басылган һәм Казанга килеп җитә алмаган хезмәтләр дә монда урын алмый әле. Укучылар истә тотсын — «Шундый басмалар хакында китап палатасына хәбәр итүчеләргә күрсәткечне төзүчеләр алдан ук рәхмәтләрен белдерә»!

Ике томлыкта барысы 9601 басма теркәлгән. 1932 дә — 863, 1931 елда — 870 (тиражы 8 млн. чамасы), 1930 да — 684, 1929 да — 625, 1928 дә — 500, 1927 дә — 504, 1926 да — 520, 1925 тә — 507 исемдә китап басылган икән. Шул исәптән Мәскәүдә — 1109, Уфада — 385, Самарада — 115, Свердловскида — 93, Оренбургта — 48, Әстерханда — 45, Стәрлетамакта — 33, Бөгелмәдә — 25, Харьковта — 18 исемдә китап дөнья күргән. Татар телендәге басмалар Баку, Горький, Новосибирск, Пермь, Пенза, Саранск, Саратов, Сталинград, Ташкент, Томск, Тубыл, Ульяновск, Чиләбе һ. б. җирләрдә дә нәшер ителгән.

Библиографик күрсәткеч татар китабының темага байлыгын да калку раслый. Нәкъ менә 20—30 елларда, халкыбызның аң-белемен күтәрү өчен, марксизм-ленинизм классиклары, күренекле галимнәр, сәнгать эшлеклеләре әсәрләре, фәннең, хуҗалыкның төрле тармакларын яктырткан хезмәтләр күпләп туган телебезгә тәрҗемә ителә. Алар арасында мәктәп, техникум, югары уку йорты дәреслекләре аеруча күп була. Байрон, Шиллер, Пушкин, Лермонтов, Мольер, Сервантес, Гюго, Толстой, Горький, Золя, Лондон, Гоголь, Тургенев, Чехов, Тагор, Мопассан һ. б. атаклы язучыларның әсәрләре, әдәби мирасыбыз, үз каләм ияләребезнең китаплары зур тиражлар белән чыгарыла. Нәшрият базасының киңлеге, кадрларның күплеге укучылар ихтыяҗын вакытында канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә. Мисалга, немец әдибе Э. М. Ремаркның дөньяны шаулаткан «Көнбатыш фронтта үзгәрешләр юк» романы туган телебездә асыл нөсхәсеннән бер генә ел соңгарып дөнья күрә!

«Татар китаплары» ике томлыгы белән Совет дәвере милли китабыбыз дөньясын тасвирлау нигездә тәмамланды. 1941—1945 елларда нәшер ителгән басмаларыбыз «Китап елъязмасы»нда (Казан, 1973), аннан соңгылары 1946 елдан бирле чыгып килгән агымдагы «Китап елъязмасы», 1961 елда нигез салынган «Татарстан матбугат елъязмасы»нда теркәлеп килә.

Ике томлы «Татар китабы» җыентыгын булдырырга теләүчеләр түбәндәге адреска мөрәҗәгать итә ала: 420084, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. ТАССР китап палатасы.


Т. РАМАЗАНОВ.

---

ТАТАР КИТАПЛАРЫ. Библиографик күрсәткеч. 1 том. Казан, 1979. 372 бит. Тиражы 1500. Б. 1 с. 30 т.
2 том. Казан, 1986. 480 бит. Тиражы 1200. Б. 1 с. 80 т.

Бәясе
Цена 90 тиен.
коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)